

# КАЗАН УТЛАРЫ

11
НОЯБРЬ
1979

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**11**

НОЯБРЬ
1979


## Бу санда


М. ХӘБИБУЛЛИН. Хәтер ярлары. Повесть . . . 3

ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Ш. МАННАПОВ. Син шундый җир. Шигырьләр . 48
М. КАЮМОВ. Юлда. Шигырь . . . . . . . . 49
Р. БАЙТИМИРОВ. Туган як җылысы. Шигырьләр 50
М. МАЛИКОВА. Янартаулар яктысында. Повесть 51
Г. ЛАТЫЙП. Күңелдә — яз. Шигырьләр . . . . 111
З. МАНСУРОВ. Вакыт агышы. Шигырьләр . . . 114

ОЧЕРКЛАР

Р. ЮСУПОВА. Чәчәкләр бәйләме . . . . . . 117

ШӘРӘФ МӨДӘРРИСНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Х. ГОСМАН. Шагыйрь үткән юллар . . . . . 122

ШӘРИФ ХӨСӘЕНОВКА 50 ЯШЬ

Т. МИҢНУЛЛИН. Драматург . . . . . . . . 125

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IX СЪЕЗДЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

СЪЕЗДДА ЯСАЛГАН ДОКЛАДЛАР

Г. АХУНОВ. КПССның XXV съезды карарлары яктылыгында Татарстан әдәбияты проблемалары . . . . . . . . . . . . . 128
А. РАСИХ. Прозабыз турында . . . . . . . 143
Н. ЮЗИЕВ. Хәзерге татар совет поэзиясенең үсеш тенденцияләре . . . . . . . . . 150
А. ӘХМӘДУЛЛИН. Татар драматургиясенең хәзерге хәле . . . . . . . . . . . . . 155
М. МӘҺДИЕВ. Ике съезд арасында әдәби тәнкыйтьнең үсеше . . . . . . . . . . 159
Ш. ГАЛИЕВ. Балалар — тормыш чәчәкләре, җимешләре нинди булыр! . . . . . . . . 165
М. ЗАРИПОВ. Заман һәм традицияләр бәйләнеше . . . . . . . . . . . . . . : 170



КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ
КАЗАН


. . . . . . . . . : 170

И. ЮЗЕЕВ. Шәҗәрәнең очы кемнәрдә! . . . . 173
Г. ПАУШКИН. Алга барырга кирәк . . . . . . . 177
Ә. МАЛИКОВ. Һәр вакыт юлда . . . . . . . . 179

ЧЫГЫШЛАР

М. ВӘЛИЕВ. Иҗатка — таләпчәнлек . . . . . . . 183
З. НУРИ. Тагын да кыюрак адымнар белән . . . 186
С. МИХАЛКОВ. Эшлекле сөйләшү . . . . . . . 188
Съезд кабул иткән карар . . . . . . . . . . 190

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2. Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов (баш редактор урынбасары), Шамил Бикчурин, Аяз Гыйләҗев, Марсель Зарипов, Зөлфәт, Шәйхи Маннур, Фәрваз Миңнуллин, Туфан Миңнуллин, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Кояш Тимбикова (җаваплы секретарь), Нил Юзиев, Сибгат Хәким, Мирсәй Әмир.

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Т. Шакирҗанова*

Производствога бирелде 24/VII-1979 ел. Басарга кул куелды 16/X-1979 ел. ПФ 09046. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83300 экз. Заказ Ц-303. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ХӘТЕР ЯРЛАРЫ

ПОВЕСТЬ[1]

## 14

Халисә гомеренең кайсы мәлендә үзалдына пышылдап сөйләшә башлавын хәтерләми. Элек ул эченнән генә уйлана торган иде.

Тәрәзә төбенә песнәк килеп кунды, тук-тук, тук-тук итеп нидер чукый да башлады. Шулай ризык соравымы? Халисә кичә балконга карбыз төшләре чыгарып куйган иде. Шуны ашыймы сылу кошчык. Тәрәзәдән күренеп торган каен яфракларында уннарча төс, гүя анда яңгырдан соң салават күпере төшкән.

Гайсә йоклый, мышнап-мышнап йоклый, ә Халисәнең күзенә һаман йокы керми. Соңгы атналарда аның бөтен уй-хисләре, өйрәнгән гадәтләре буталды, тәмам болганып китте. Өенә дә ят бер квартирага кайткан кебек кайтып керә. Гайсә уянды, чалкан әйләнеп ятты.

— Син кем белән сөйләшеп ятасың? — диде ул, күзләрен ачмый гына. — Үз-үзең белән генәме? Беләсең килсә, шизофрения чире шулай башлана, шуны исеңнән чыгарма.

Гайсә, үз сүзләреннән үзе канәгать калып, Халисәнең күкрәгенә кулын салды. Халисә ул кулны акрын гына читкә алып куйды.

— Йокла.

— Йокы туйды, торырга вакыт. Күрәм, синең бүген иртәдән үк кәефең юк. Кичә булды кичә...

— Әнә теге көя күбәләгә йокы бирмәде, кичә кичтән үк кереп калган иде, леперди дә леперди.

— Көя күбәләге? Тот та үтер үзен.

— Юк, мин куркам, үзең үтер. Минем бүген чынлап та кәефем юк.

— Кичәге хәлгә үпкәләмисеңдер бит?

— Ни дип әйтим? Шуны аңламыйм, нигә син операциядән баш тарттың? Алай булгач, нигә аны больницага яткырдыгыз?

— Ә син аны һаман да күрмәденме әле?

[1] Ахыры. Башы унынчы санда.

— Хикмәт андамы? Син миңа үзең өчен җавап бир. Консилиум булгач, операция ясау-ясамау мәсьәләсен хәл итүне сиңа калдырганнар. Ә син баш тарткансың...
— Әйе шул.
— Ни өчен?
— Рисковать итәсем килмәде, — Гайсә торып утырды, юрганын ачып идәнгә аякларын салындырды. — Аның бу якты дөнья белән бөтенләй хушлашуы бар. Кан тамырлары, нерв җепселләре җөй эчендә шундый хәлгә кереп чәбәләнгән, бер алла белсә белер. Шуларны күрә торып операциягә керешимме? Минем аны үтерәсем килми, начармы, яхшымы, ул минем мәктәп дустым.
— Минем дә...
— Һә, синең дә... Дусларны эттән талатмыйлар, Халисә җаным. Гафу ит, үткән хәл, әмма булган хәл.
Халисә башын читкә алды, почмаккарак посынды, бер мәл сүзсез ятты.
— Нигә соң Валентина Петровна операция ясарга кирәк дип бара?
— Алынсын, алайса. Үз-үзенә ышана икән, ясый бирсен.
— Ничек ул берүзе алынсын? Консилиум нәтиҗәсе аңа билгеле түгелмени? «Ярамый» дигәнгә карамастан, үз белдеге белән эш итү булып чыкмыймы бу? Син бит хирургия бүлеге мөдире. Никонов белән Байдигинны мин яхшы беләм. Аларның икесенең берсе дә синең сүздән чыкмаячак, шулай ук берсе дә кисеп кенә сүз дә әйтә алмаячак. Бер Валентина Петровна риза, ләкин аның фикере белән син чутлашмыйсың. Бу мәсьәләдә икегез ике фикердә кала бирәсез икән, башкаладан консультант чакырыгыз.
— Валентина риза, — Гайсәнең тел төбендә ирония бар иде, — ләкин өстенә бик күпне ала башлады әле ул хатын. Үз эшен тәгәл башкарса да, бик хуш дисәм, ни әйтерсең?
— Ул кеше өчен минем вөҗданым һаман газапланганны онытма син. Минем аркада гарип калган ул!
— Шуннан ни? Мин нишләргә тиеш инде? Мөмкин булмаган операцияне ясаргамы?.. Юк инде, рәхмәт. Минем әле эшлисем, кеше рәтендә яшисем килә.
— Ә аның... Аның кеше рәтендә яшисе килмиме? Син... син эгоист, Гайсә!
— Җитәр. Иртә таңнан талый башлама. Торып чәй куй, ашат һич югы. Валентина Петровнага да, башка берәүгә дә үзем алына алмаган операциягә рөхсәт бирә алмыйм. Хакым юк.
— Син ни сөйләгәнеңне беләсеңме, Гайсә?
— Чамалыйм бераз. Нәүфәл үзе дә, миңа калса, бер дә операция ясагыз дип өзгәләнми әле. Ә менә син, дускаем, тәмам шашар дәрәҗәгә җиттең... Минме аңламый башладым сине, синме минем хәлемә керергә теләмисең... Плотников бүген-иртәгә пенсиягә китәргә йөри. Сәламәтлек саклау министрлыгында мине аның урынында калдыру турында сүз бара. Шундый чакта мин катлаулы операциягә керешим диме. Беләсең килсә, мин аның уңышлы үтәсенә ышанмыйм. Кем белә, бәлкем ул операция минем үз язмышымны кыл өстенә куяр.
Халисә торып утырды, чәчен төзәткәләде, үрелеп, урындык башындагы халатын алды.
— Валентина Петровна алына икән, алына бирсен. Аның югалтыр кешесе юк. Югалтасын югалтты бугай инде, — диде Гайсә, ярсына башлап.
— Эчле кеше син, Гайсә. Кеше кайгысына куана гына беләсең.
— Куану түгел бу, кызгану. Миңа калса, алар арасында роман туып килә. Андый вакытта операциядән кем баш тарта алыр икән. Аннары кем инде үзенең булачак ирен нормаль кеше итеп күрергә теләми.

— Үз акылыңдамы син, Гайсә!

— Зиһенем үтә үткен әшли, дускаем, аллага шөкер, үз акылымда.

Халисә дәшмәде, кухняга узып чәй куйды да, ваннага керде, бик озак көзгегә карап торды. Гайсә әйткән нахак сүз шул кадәр ачуын чыгарды аның, кулларына чаклы калтырый. «Коточкыч ялган, Гайсә аны ачу белән генә ычкындырды, Валентина Петровнага ачуыннан гына, Валя аның фикере белән килешмәгәнгә. Ә андыйларны Гайсә күрәлми, — шул ук вакытта Халисә үз-үзен дә тирги иде. «Мин, йомшаклык күрсәтеп, үз-үземне әрнешүгә дучар иттем, мин кеше ышанмастай юләрлек эшләдем. Хәзер шул кеше өчен көне-төне шашынам!.. Тиле, тиле мин».

Ваннадан чыгып табын әзерләгәч, ул креслода журналлар актарып утырган Гайсә янына килде, кайнарланып киткән маңгаен иренең шәрәләнә башлаган башына салды да тынып калды. Гайсә, журналын өстәлгә ташлап, хатынын кочып алды.

— Син мине яңадан болай ачуланма, Гайсә, яме?

— Минме, — диде Гайсә, гаҗәпләнүен яшермичә — минме сине ачуландым?

— Ачуландың...

— Ярый, синеңчә булсын. Кичер. Тик сиңа да бер шарт куям: моннан соң юк-бар белән минем дә башны катырма.

— Әйе... Әйдә чәй эчәбез.

... Халисә соңгы көннәрдә ике ут арасында яши иде. Ул моны үзе дә сизә, тоя, болай яшәүләре мәхшәр икән ләбаса, тәмам күңелләре тулышты, мөлдерәп ташып китәргә генә тора, ичмасам, эчендәгеп сөйләп бирердәй кешесе булса икән, юк бит, Валя үзе хәсрәт эчендә кайный. Болай икегә бүленеп яшәве дә бик кыен, тормыш болай дәвам итсә, килер бер көн, куык кебек шартлар, ни әйткәнен белештермәс хәлгә җитеп, үз-үзен тыя алмыйча Гайсәгә ташланыр, иренә мәңге кире кайтарып алмастай, берсеннән-берсе яман сүзләр әйтер, соңыннан кая керер җир таба алмый оялыр һәм гомер буена үкенеп йөрер. Шушындый уйларыннан соң аның Гайсәгә назланасы килеп китә, ул тик торганда аңа сырпалана башлый, моның чын сәбәбен аңлап бетермәгән ир: «Ни булды сиңа, Халисә?» — дип гаҗәпләнә кала иде.

Шуларны күңеленнән кичерә-кичерә чәй эчеп утырганда Халисә иренә карап-карап алгалады, соңыннан, чынлап та, күңеле нечкәреп китеп, бит очларындагы мәхәббәт чокырларын тирәнәйтеп елмайды, иренең башыннан сыйпап алды. Әчке бер рәхәт тоеп утырган Гайсә аның кулын үз иреннәренә тигезде һәм бик гади итеп:

— Эшкә китәргә вакыт, — диде.

## 15

Кадыйр дерт итеп сискәнеп уянып китте, күргән төше тәэсиреннән аерыла алмыйча уйланып ятты. «Мәскәүгә тикмәгә генә чакырмаслар, — дип уйлады ул. — Төшемдә дә Мәскәүгә бара идем, әллә поезд, әллә самолет белән шунда, поездымы бәрелде, самолетмы челпәрәмә килде — шуңа уянып киттем, ахры. Төшкә караганда Мәскәүдә эшләр шәптән буласы түгел икән. Җитмәсә нииндидер агач башына килеп төштем. Анысы инде кинода күргәннәр килеп кергән булса кирәк»...

Зиһене ачылуга, Кадыйр тирә-юньгә колак салды. Иртә иде әле, өйдәгеләрнең барысы да йоклыйлар, Кадыйр хатынының мышнавына игътибар итте. Зөһрәнең шулай йоклавы аңа бүген бигрәк ят тоелды, ә бераздан хәтта ачуы килде. Ә бит элек бер дә алай түгел иде. Кадыйр һәр чак торып чәй куяр, берүзе бер өстәл янына утырып эчәр, киенеп эшенә чыгып китәр, ә хәләл җефете рәхәтләнеп, мышный-мышный йок-

лап калыр, ләкин иренең моңа ник бер тапкыр эче пошсын, җаны кыйналсын. Гүя ул хатыны яныннан да торып китми, ә буш караваттан торып китәр иде. Бүген исә эче актарыла. Изрәп йоклап яткан хатынына торган саен ачуы кабара барды Кадыйрның. Ул ачуы чыгуның төп сәбәбе нидән булуын да белә, әмма үз-үзе белән һичнич кыла алмый иде.

Түзмәде, торды. Ялан тәпиләре белән йомшак аю тиресенә басуы булды, күңеле Төмән якларына омтылды. Аю тиресен ул Төмәннән алып кайткан иде. Тирене күргә, Зөһрә аны чут-чут үбә башлады, ирен күккә чөеп мактарга керешге, соңыннан тирене диванга җәеп салды да бөгәрләнеп ятты. «Мин хәзер шунда гына йоклыйм, Кадыйр, син теләсәң нишлә»,— диде. Хатынның бу кыланышына ни әйтергә белми телсез калган Кадыйр ишекне шап итеп ябып йокы бүлмәсенә узды, йөрәге кабаруга түзә алмыйча янә әйләнеп чыкты.

— Беләсең килсә, аны идәнгә җәяләр, — диде ул, тәмам гаҗизләнеп.

— Идәнгә җәйсәләр, идәндә йоклыйм,— диде хатын, иренең тузынуына игътибар итмәстән.

Зөһрәсенең чын табигатен әле булса белеп бетермәгән Кадыйр яңак итен чәйнәүдән ары уза алмады, шаулап-гөрләп өйгә Гөлүсә кайтып керде һәм ачуы чыгудан шартлый язган этисенең муенына сарылды. Шуннан соң Кадыйр барысын да онытты, һәрхәлдә, онытырга, Зөһрәнең шул кыланышына игътибар итмәскә тырышты. Тик менә бүген, үтереп эче пошканда, аның җитәкче булу-булмавы бизмәнгә салынып үлчәнергә торганда, Зөһрәнең гамьсез рәвештә йоклап ятуы узгандагы хәлләрне янә бер яңартып алды. Кадыйр көрсенеп куйды.

Бүлмәдә гадәттәгедән дә тынчу, тәрәзәләр томаланганга һава җитми. Форточкаларны Зөһрә ачтырмый, көньяктан җил искәндә бүлмәгә күмер катламыннан нефтькә ияреп чыккан күкерт газы исе тула һәм тын юлына каплана, болай да какшаган нервыларга тия. Шул сәбәпле шәһәрнең бу төбәгеннән күп кенә семьялар башка районнарга күчеп киттеләр. Халык күченә башлагач, Зөһрә дә пырлап караган иде, Кадыйр аңа: «Күчсәң үзең генә күчеп кит, без моннан беркая да китмибез!» — дип кырт кисте. Теге вакытта хатынның авызын шулай томаласа да, шушы яман газ исенә тора-бара үзенең дә күңеле болгана башлады. Андый чакларда ул, астма авыруы белән интеккән кешедәй, һавага сусый, машинасы кулында булганда, Бөгелмә юлына чыга, тауга менеп саф һава сулый торган иде. Тиздән бу ят ис бетәр, скважиналарны томалап файдалануга күчеп яталар бит, Нәүфәл шулай тырыша. Ләкин Кадыйрның хәзер ул турыда уйлыйсы килмәде. Бүген аның күңелендә бер генә теләк: күптән барган бәхәстә өстен чыгарга, Идрисовтан да, Кудрявцевтан да — икесеннән дә өстен чыгарга! Мәскәү, әлбәттә, ике якның берсен генә яклар һәм шул чагында инде ике кешенең берсе гамәлдән сызылыр. Кадыйр кырысрак уйлый уйлавын, әмма хәл шуңа барып терәлсә, мәсьәлә, һичшиксез, нәкъ менә кемнеңдер урыныннан алынуы белән тәмамланачак.

Кадыйр кухня ягына узып чәй куйды, тиз арада юынып-кырынып алды, аннан-моннан гына капкалады да, юлга җыена башлады. Әүвәл ул Зөһрәне уятырга, Мәскәүгә китеп баруы турында әйтергә теләгән иде, тегесе аның өй тутырып лап-лоп басып йөренүенә дә уянмагач, гел кулын селтәде. Юл йөри-йөри шомарып беткән портфеленә иң кирәк нәрсәләрен генә салып, шыпырт кына өйдән чыгып китте. Хәер, Зөһрә аның күп вакытта кай тарафларга таба китеп баруын да белми кала торган иде. «Монысын белмәве тагы да хәерлерәк булыр», — дип уйлады Кадыйр, урамга чыгып тротуар буйлап атлый башлауга.

Салкын җил исә, тротуар буйлап өзелгән агач яфраклары йөгерешә. Кадыйр плащ якасын күтәреп куйды, муенын җыера төште.

Әйе, министрлыкта да күрәзәләр һәм әүлияләр утырмый утыруын. Килеп керүгә ятма турында сорашырга тотынырлар, шул турыда бәйнә-бәйнә сөйләгәндә, кирәк информация җыярлар.

Кадыйр адымын тизләтә төште. Бәхәс кызып, нинди дер конкретлык ала башлагач, әлбәттә, Идрисов соңгы «козырен» ачып салачак: ятманың чын мәгънәсендә сүнә баруын диаграммалар белән исбат итәргә керешәчәк. Ышанмаслык та түгел шул, идарә җир мае алуны айдан айга киметә бара, нефтькә нярепп чыккан су күләме сиксән, хәтта туксан процентка җиткән скважиналар саны артканнан-арта.

Уйлый калсаң, йөзләгән-меңләгән скважинаны бушка дияргә эшләтү гафу итмәслек хәл инде дә... Шуңа карамастан, Кадыйр да Нәүфәлнең идеясен яклап, министрлыктагыларга ятманы циклап файдалану идеясен тәфсилләп аңлатыр, бу ысулның киләчәге турында нык лы дәлилләр китереп сөйләр. Тик аның хәленә керер кеше булырмы? Азмы илдә сүнеп барган ятмалар. Кадыйр күзлегеннән чыгып эш иткәндә, барысы да чан тутырып нефть бирергә тиешләр булып чыга түгелме? Нәүфәлгә ансат, идеяне бирде дә бер читтә йөри, менә син шуны Мәскәүдә яклап кара. Берләшмәдә бит яңа идеяне танырга да теләмәделәр, Идрисовның исәп-хисапларын нигезлерәк дип таптылар. Дөрес, Нәүфәл идеясе белән кызыксынучылар да булды, тик алар идеяне күтәреп килүче Кадыйрның хәленә керүдән ары китә алмадылар. Хәер, республикадагы йөздән артык ятмадан җир маен әйбәт кенә суыртып торганда, Берләшмә белгечләренә нинди дер сүнеп барган ятма турында сүз куерту артык вак мәсьәлә булып күренде, күрәсең. Идеяне яклап чыгучыларның берсе Берләшмәнең геология бүлеге начальнигы Наташа булды. Шунда кинәт кенә канат үсеп китте Кадыйрга. Ул хәтта киңәшмәдә янәдән кулларын болгый-болгый яңа ысулны исбат итәргә кереште. Баш инженер белән идарә начальнигы арасындагы бәхәсне министрлыкка җиткерүчеләрнең берсе, һичшиксез, Наташа Кудрявцева иде. Кадыйр бу турыда бик әйбәт белсә дә, геология бүлеге начальнигына рәхмәт әйтергә ашыкмады. Әмма күңеленнән шуңа иманды: Наташага таянырга була.

Мәскәүгә китәр алдыннан ул үз янына Сибирцевны чакырып алды һәм алар бөтенләй башка нәрсәләр турында бик озак сөйләшеп утырдылар, министрлыкта хәл ителәсе мәсьәлә аларга гүя кагылмый иде. Сәләтле геолог булуына карамастан, идарәдән ары китә алмаган, кырык яшь тутырып та гаилә бәхетен тоймаган, гаять дәрәҗәдә йомшак табигатьле, чамасыз сабыр холыклы, ифрат итагатьле, хәтта бераз йомыкый Сибирцев Кадыйрның зур таянычы иде. Баш геологны күрдеме, Кадыйрга әллә ниткән тынычлану килә һәм ул, соңгарыбрак булса да: «Ник миңа да бу кеше кебек сабыр булмаска икән? Йокыдан калам, күңел тулы хәвеф, үткән өчен үкенү, киләсе өчен хафалану», — дип үртәлеп уйланып куя торган иде.

— Ә сез кыю кеше, Кадыйр Сөнгатович. Мин беләм бит, Идрисовны Кудрявцев үзе яклый, ә сез бер үзегез.

— Минем дә яклаучылар бар, Михаил Михайлович, бар. Мин икеләнеп калган чакта шулар куәт бирә. Гаделлек бар әле, Михалыч.

— Гаделлек барын-бар ул. Тик аны яклаучылар саграк кылана башладылар. Җылы урыннарын югалтудан шүрлиләрме шунда, зур түрәләргә ярарга тырышуларымы...

— Ә мин, киресенчә, кайбер нәрсәләргә төшенә башладым кебек, Сөнгатович.

— Сезгә җиңел, ә утлы күмер кем кулында? Синең кулыңдамы? Әллә соң идея бирүче кулындамы?!.. — Кадыйр, үзенә урын тапмыйча, торып йөренергә кереште. — Менә кем кулында ул утлы күмер, — диде ул, кулларын сузып.

— Сез җитәкче кеше, Кадыйр Сөнгатович. Утлы күмерне кулда тоту гына аз әле сезгә. Йөрәгенә идея уты капкан җитәкче аны тормышка ашырырга да тиеш.

Кадыйр кабинет уртасында тукталып калды, гүя кемдер аның җилкәсенә кулын салды. Ул үтә гаҗәпләнгән бер кыяфәттә баш геологка текәлде. Гомер-гомергә син мөкиббән киткән кешеләр була, ул — синең идеалың. Ләкин көннәрдән бер көнне таш ярылып су чыга: идеал кешең сиңа бөтенләй башка ягыннан ачылып китә. Бу көтелмәгән хәлдән, сәер күренештән бер мәлгә таң каласың, әйтер сүз таба алмыйторасың. Кадыйр да Сибирцевның соңгы сүзенә бер мәлгә ышанмыйча аптырап калды. Инде аны да бу идея өчен янмауда гаепләсәләр? Көлгә әверелеп бара кебек тоела башлады инде ул шушы идеяне тормышка ашыра-ашыра.

Сибирцев белән булган сөйләшүдән соң ул бик озак исенә килә алмый торды. Хәтта баш геолог чыгып киткәч тә Кадыйр тынычлана алмый җәфаланды. «Менә, ичмасам, сөйләштек! Андый эшкә бик тиз генә фатиха бирерләр дип өметләнгәнсеңдер син, кадерле Михалыч», — дип үзалдына сөйләнде Кадыйр.

Кичке якта, Мәскәүгә китәр алдыннан, ул Нәүфәл янына больницага сугылып чыкты. Энесе палатада бер үзе ята иде. Кулларын баш астына куйган да, түшәмгә карап уйга чумган.

— Сәлам! Нинди проблемалар хәл итәсең тагын? — дип сорады Кадыйр, көр күңелле булырга тырышып. — Абыең синең идеяне якларга Мәскәүгә китә, ә син больница караватында ауныйсың!

— Чынлапмы?! — Нәүфәл сикереп торды.— Ул идея шунда кадәр үк барып җиттеме?! — Егет абыйсының сүзенә ышаныр-ышанмас бер кыяфәттә иде.

— Белмәмешкә салышуыңмы, чынлап торып белмәдеңме?

— Җиңгәчәй әйткән иде әйтүен. Идарә эшләре белән барасың дип уйлаган идем...

— Ә бу идарә эше түгелмени? Үз өстенә алган икән, абыең син уйлаганны тормышка, һичшиксез, ашырыр, аңа башкача чара калмады. Шулай, энекәш! Үзеңнең хәлләр ничек?

— Операция көтеп ятам.

Кадыйр, урындык алып, караватк янынарак килеп утырды, кулын энесенең тез өстенә салды.

— Кем ясарга алына?

— Валентина Петровна Меженкова.

— Гайсә риза булмадымыни? Сәмигуллин дим. Бергә үскәнсез бугай бит?

— Меженкова да бик әйбәт хирург диләр. Миңа исә барыбер, — диде Нәүфәл, күзләрен читкә яшереп.

Кадыйр энесенә текәлебрәк карады. Операция алдыннан булган йокысыз төннәрдәнме, Нәүфәлнең кызарган күз төпләренә ялтыравык капчыклар асылынган иде.

— Анысын үзең кара инде, — диде Кадыйр, энесенә карата кызгану хисе уянудан күзләрен читкә алып. — Син мине гафу итә күр инде, берни алып килә алмадым. «Спутник»ларың эшләп ята,— дип сүзен бүтәнгә күчерергә ашыкты Кадыйр. — Егетләрең өченче төбәкне корып яталар.

— Беләм, егетләр килеп йөриләр, җиңгәчәй дә, Гөлүсә дә килә. Рәхмәт инде. — Нәүфәлнең йөзе ачыла төште. — Министрлыкка хәтле барып җиттем диген, ә?! Ярый ла хәлгә керсәләр, аңлата алсагыз, дим.

— Зыян юк. Ятып калганчы атып кал диләр бит. Аның каравы, мин белеп барам: бу хәлдән соң я элеккечә түрә булып калам, я баш долой, — дип шаяртты Кадыйр.

— Тотса мәскәүләр якаҥнан дисең инде, — Нәүфәл авыз чите белән генә көлемсерәп алды.
— Анысы бер хәл. Менә Гөлүсә башка кайгы салды әле. Унсигезе тулмаган, кияүгә чыгарга җыена.
— Ярата икән, чыга бирсен. Яшь чакта үзегез әллә яратмадыгызмы?! — Нәүфәл көлеп җибәрде.
Кадыйр аның шыксыз селкенгән башына, җилкәсе төшебрәк калган кулбашына, өстендәге уңган, болыттай аксыл-күк төстәге халатына, көлгәндә янтаеп селкенеп торган гәүдәсенә игътибар итте.
— Иртәрәк әле аңа, Нәүфәл, — диде Кадыйр боегып.
— Ярату гаепме? Яраткан кешенең кулы юмарт, күңеле шат була, диләр.
— Куй булмаганны, гашыйк кеше дивана белән бер ул. Ярар, мин китим. Юл кешесенең юлда булуы хәерле.
... Мәскәүгә барып гостиницага урнашкач кына, аны ниндидер юллар белән Зөһрә эзләп тапты. Телефоннан хатынының тавышын ишетүгә, үтә гаҗәпләнә калган Кадыйр бер мәлгә ни әйтергә белми аптырап калды.
— Кадыйр, бу нинди хәл инде, әйтми-нитми китеп баргансың?
— Кызгандым, бик тәмле йоклый идең, татлы төшләр күрә-күрә...
— Ташла әле шул шаяртуыңны. Мәскәү кибетләреннән кирәкяраклар карамассыңмы диган ием. Туй якынлаша... — Һәм Зөһрә Кадыйр алып кайтырга тиеш булган әйберләрнең исемлеген җентекләп тезеп китте.
— «Зөһрә, Зөһрә, шулай ук без гомер буе бер-беребезне аңламыйча яшәдекме? Синдә туй кайгысы...» — дип ачынды Кадыйр.

## 16

Ятмага тәүлегенә күпме күләмдә су кудырыла?
— Егерме мең тонна чамасы.
Әйтерсең Кадыйр институтта профессорга сынау бирә. Идрисов белән Кудрявцев өстәлнең бер ягында утыралар, Әмиров икенче якта, әтүр өстәлне бер итеп министр урынбасары урнашкан, тәрәзә янындагы журнал өстәле янында — стенографистка. Кызый яшь, бик чибәр, ниндидер эстрада артисткасын хәтерләтә, тырнакларын җете кызылга буяган, иреннәрендә дә шул төстәге помада, күз кабакларында куе зәңгәрсу-шәмәхә, кыйгач кашлары, сөйләшеп куйгандай чиратлашып, бер төшәләр, бер күтәреләләр, яза башлаганда сул кашы күтәрелә, язып беттеме—уң кашы сикерә, кашларның уйнавы аның җавапларына көйләнгән сыман тоелды Кадыйрга.
— Сез тәкъдим иткән ысул белән без дә, фәнни-тикшеренү институты белгечләре дә, бик җентекләп танышып чыктык, Кадыйр Сөнгатович. Бу фәнни хезмәтнең киләчәге һичшиксез бар, перспективалы ысул дип әйтер идем. Кем ул ысул идеясе авторы Нәүфәл Әмиров? Исәп-хисапларын да үзе ясадымы?—дип кызыксынды министр урынбасары.
— Ул егет—рядовой инженер-автоматчы, Анатолий Иванович. Расчетларны да үзе ясады. Идарәнең баш геологы Сибирцев аларны өр-яңадан тикшереп чыкты. Килеште. Бик төгәл исәпләгән, дәлилле диган нәтиҗәгә килде.
— Күренеп тора, башлы инженер. Мондый зур хезмәткә бер ялгызы тотынып, аны ерып чыгарлык булгач, талантлы инженер дияр идем мин аны.
Кадыйрның ярыштан килгән чаптар атныкыдай дөп-дөп типкән йөрәге бераз тынычлангандай булды, хәтта сулышы кимеп китте. Ул

жиңүле карашын Кудрявцевка төбәде. Аның бу карашы: «Юк, Виталий, министрлыкта юләрләр утырмый! Төшенгәннәр бит идеянең асылына!» — дия иде кебек. Кудрявцев исә аның шулай тантана итүен әллә күреп тә белмәмешкә салышты.

— Институт белгечләре бу ысул авторы белән кызыксындылар, идеяне биргән инженер белән якыннанрак танышасылары килә. Бәлкем аның фәнни-тикшеренү институтында эшләргә теләге бардыр? Күренекле галимнәр кул астында эшләсә, фән моңардан отар гына иде.

— Сүз дә юк. Ләкин анысы инде аның үз эше, — диде Кадыйр министр урынбасарына.

Кудрявцев ваемсыз бер хәлдә, бер ноктага текәлгән килеш, әңгәмәне тыңлый бирде. Идрисов та сүзгә кушылырга, үз фикерен әйтергә ашыкмады, ул, башын ия төшеп, куен дәфтәренә нидер язып-сызып утыра иде.

— Белгәнемчә, Кадыйр Сөнгатович, сезнең идарә бүген тәүлегенә ун меңгә якын тонна нефть биреп ята.

— Унөч мең тонна биреп тора идек әле моңарчы. Ләкин ятма интенсив төстә сулана, бу ысулны куллану ятмада калган нефтьнең ниндидер күләмен алырга мөмкинлек бирер иде, скважиналардан файдалану срогын озайтыр иде, — дип, тагын канатланып китте Кадыйр.

— Миңа, иптәшләр, — министр урынбасары бу юлы аларның өчесенә дә мөрәҗәгать итте, өчесенә дә күз төшереп алды. — Бирегә без идарә начальнигы белән баш инженерын тикмәгә генә чакырмадык. Виталий Семенович, Берләшмә вәкиле буларак, сезне дә дәшәргә булдык. Мәсьәлә шунда: бер үк идарәдә эшләүче ике кеше капма-каршы фикер белән килгәннәр, дәлилләре дә нигезле. Ике капма-каршы фикер, иптәшләр. Кадыйр Сөнгатович, идарә мөдире буларак, яңа ысулга таянырга ният тота, ятмадан файдалануның срогын озайтырга, анда калган илле процент нефтьне, ниндидер күләмдә, әлбәттә, циклла файдалану юлы белән алырга исәпли. Кызыклы фикер, әйтер идем, перспективалы ысул. Әмма аны куллана башлаганчы безгә бик нык уйланырга кирәк. Бездә һәр тонна нефть исәптә икәне барыгызга да мәгълүм. Сез бирган «кара алтынның» бер өлеше «Дружба» нефть үткәргеченә китә. Ысул ысул белән, шул ук вакытта Берләшмә алдында торган бурыч турында да онытмасагыз иде, — дип, янә өчесенә дә мөрәҗәгать итте министр урынбасары. — Инде, Кадыйр Сөнгатович, сезнең идарә ниндидер сәбәпләр аркасында нефть бирүен киметә икән... — министр урынбасары Кадыйрга төбәлгән килеш бер мәл уйланып утырды, аннан карашын Кудрявцевка күчерде, — ул вакытта сезгә, Виталий Семенович, нефть чыгарудагы барлык резервлардан файдаланырга туры киләчәк. Шул чакта гына яңа ысулны кулланып карарга, икенче төрле итеп әйткәндә, — ятмада сынау үткәрергә рөхсәт бирә алабыз.

Кудрявцев утырган җирендә борсаланып, җилкәсен җыерып куйды.

— Ай-һай, Анатолий Иванович, булдырып булыр микән. Сүнә барган ятмалар һаман ишәеп килә, иптәш Әмиров җитәкләгән идарә соңгы квартал планын үти алмады. Берләшмә нәкъ менә сез әйткән резервларны эшкә җигәргә мәҗбүр булды.

— Димәк, резервлар бар әле сездә, — министр урынбасары, мәсьәлә шулай чишелергә тиеш дигәндәй, алдында яткан кәгазьгә кулындагы каләме белән нокта куйды. — Һәрхәлдә, ятмадан циклла файдалану ысулы буенча, Виталий Семенович, сынауны сез үткәрә алмыйсыз икән, илебез зур, урын табылыр, табарбыз.

Бүлмәдә бер мәлгә тынлык урнашты. Министр урынбасары сүзләреннән соң Кадыйрның күңелен чын мәгънәсендә бәйрәм тантанасы биләп алды. Юк, бу гади генә җиңү түгел иде аның өчен.

— Иптәш Идрисов, — министр урынбасары бу юлы баш инженерга мөрәҗәгать итте. — Сезнең тәкъдимегез белән дә без якыннан таныштык, экономистлар белән киңәштек, — Идрисов, уклау йоткан шикелле, утырган җирдә катып калды, йөзеннән кан качты. — Һәм, әйтергә кирәк, докладыгызда күрсәтелгән күп кенә дәлилләр белән без тулысынча килешәбез.

Кадыйр, һични аңламастан, әле министр урынбасарына, әле Кудрявцевка карап алды. Урынбасарның сүзне кисәк кенә борып алып китүенә Кудрявцев үзе дә аптырабрак калган, әңгәмәнең юнәлеше шулай кинәт үзгәрер дип ул да көтмәгән иде күрәсең. Идрисовка да, ниһаять, җан керде, агарынып киткән йөзенә алсулык йөгерде. Стенографистка кыз гына һаман шул кыяфәттә үз эшен дәвам итте — нәзек кыйгач кашлары һаман да бер төшәләр, бер күтәреләләр иде.

— Ничек инде, Анатолий Иванович,— диде Кадыйр, үзе дә сизмәстән.

Министр урынбасары көлемсерәп куйды, мәгәр аңлатырга ашыкмады.

— Чөнки иртәме, соңмы, ятма барыбер сүнәчәк, бу котылгысыз хәл, үлгәнне терелтеп булмый,— дип, утырган урынында турая төште Идрисов.— Дәүләт шул бер идарәне промысел итүдән генә миллионлаган сум файда табачак.

Китте тезеп, китте Идрисов — гүя алмачуар чаптарга менеп атланды. Төпле дәлилләр, саннар китерде, һәммәсе нигезле, исәпләнгән, төгәл иде. Кадыйр баш инженер китергән саннарның төгәллегенә исе китеп утырды, Идрисов әйтерсең һәммәсен дә ЭВМда исәпләтеп алган иде. Аның төгәл саннар белән эш итүенә министр урынбасары да гаҗәпләнә калды, урыныннан торып йөренә башлады, барысын да язып өлгерә микән дигәндәй, стенографисткага күз төшереп алгалады.

— Бездә яңа гына эшкәртелә башлаган күмер катламы бар, — диде баш инженер.

— Менә-менә, ә сез, Виталий Семенович, резервлар юк дип барасыз, эзләнә торгач табыла икән бит,— диде министр урынбасары һәммәсен гаҗәпләндереп.

— Күмер катламы... Сиртмәле насослар куепмы? Күпмегә төшәчәк ул нефть?— диде Кудрявцев.— Минемчә дә, Анатолий Иванович, иптәш Идрисов идарәне промысел итеп кенә калдыру турында дөрес фикер әйтте. Баш инженерның дәлилләре, әйтер идем, төпле, нык уйланылган, барча мисаллары конкрет, җитди. Без хәзер промыселларда район инженерлык-технология службалары системаларын корып ятабыз. Берләшмәдәге җитмеш процентка кадәр скважина бер үзәктән идарә итүгә күчереләчәк. Бу үзгәрешләр — чор таләбе. Шундый үзгәрешләр барганда сүнеп барган ятманы эшкәртүче коллективны идарә итеп калдыруның, мина калса, һич кенә дә хаҗәте юк, Анатолий Иванович. Ахырда барыбер без аны промысел итәргә мәҗбүр булачакбыз.

— Идарә хәтле идарә язмышын алай тиз генә хәл итәргә ашыкмыйк әле, Виталий Семенович. Без аңа кайчан да өлгерербез. Менә сез бүген шушы идарә биргән нефтьне киметмәү мәсьәләсендә ныклабрак уйласагыз иде,— диде министр урынбасары һәм, Идрисов ягына борыла төшеп:— Бу турыда Вәгыйзь Исламович ничегрәк уйлый?— Идрисов ни сәбәпледер җавапсыз калгач, янә Кудрявцевка карады министр урынбасары.— Уйлашыйк, иптәшләр...

— Безнең Берләшмәдә мәңге эшләрдәй бер генә скважина да, бер генә катлам да, бер генә ятма да юк, Анатолий Иванович. Юк андый резервлар бездә. Аз-маз булган хәлдә дә бүген иптәш Әмиров идарәсе биргән кадәр нефтьне чыгару гаять читен, хәтта мөмкин түгел дияр идем мин. Ятмадан без шулай файдаланабыз икән, тиздән тук-

сан биш процентка чаклы су ала башлаячакбыз. Кыскасы, алтын бәясенә төшәчәк ул нефть, Анатолий Иванович.

...Кадыйрның күңеле тынычлана төште, министрлыктагы очрашудан, гомумән алганда, ул канәгать иде. Яңа ысулны сынап карарга министрлык үзенең ризалыгын бирде дияргә була. Бирегә килүенең иң мөһим нәтиҗәсе шул иде. Дөрес, идарә һәм Берләшмә алдына куелган бурычлар да гаять җитди, аерата ул җитәкләгән идарәгә күп нәрсә йөкли — моңа кадәр биргән нефтьне киметмәү. Җиңел булмас. Инде киләчәктә дә ятма сүнүгә таба бара икән, баш инженер тәкъдимен исәпкә алып, промысел итәргә һәм якындагы идарәләрнең берсенә кушарга дигән карарга килделәр министрлыкта.

## 17

Чаң какмыйлар иде, ләкин Нәүфәл чигә тамырларының дылк-дылк тибүен чаң суккан тавыш белән чагыштырды. Дылк-дылк-дылк-дылк. Чигә тамырлары типкән саен бер нәрсә белән бер ритмда сугып торалар. Дылк-дылк-дылк... Чаң тавышы колакларны чыңлата, йөрәккә ук булып кадала. Тәндә авырту юк сыман, ә аяк-куллар гүя синеке түгел, бөтен күз аллары караңгыланыр дәрәҗәгә җитеп томалана. Ичмасам, укол салсыннар иде. Кулларны кымшатып та булмый. Башына: «Кул-аякны бәйләп куйганнармы әллә?»— дигән уй килә. Ул да түгел, күз алдында утлар уйный башлый, бераздан ул тоташ кызыл төскә, аннары сары төскә керә, кукселләнә һәм Нәүфәл үзенең ниндидер упкынга очуын тоя. Кемдер аның авыз-борынын каплый. Сана, ди. Һәм үзе үк «бер, ике, өч...» дип санап китә. Нәүфәл аңа ияреп санамакчы була, егермегә чаклы саный... Кисәк кенә зиһене ачылып китә. «Авызга каплаган масканы ташласаң иде, — дип уйлый ул.— Ни өчен мин ризалык бирдем. Үлеп куйсам? Яшәр идем әле шушы кыяфәтемдә дә. Яшәдем бит әлегә чаклы...»

...Аңына ул бик акрын килде, күз алдында һәммә нәрсә йөзә, дулкында чайкалган көймә кебек, кайчак убылып-убылып китә иде. Башта һични күрмәде, күзләрен киң итеп ачса да, күз алдында тоташ күк пәрдә эленеп торды. Муен тирәли утлы күмер куйганнар кебек, шул тикле кызыша, пешергән әйберне үрелеп алып ташлыйсы килә.

— Мин күрмим,— ди ул бөтен көчен җыеп.— Күрмим.— Аның бу зәгыйфь тавышын ишетүче дә юкмы әллә?

— Хәзер күрерсез,— йомшак кына дәшкән хатын-кыз тавышы бик ерактан ишетелә.

Сестра аның күзенә төшереп бәйләгән марляны ача төште.

— Мин исәнме?

— Балакаем... Аңына килде... Ул аңына килде! — җиңгәчәсенең тавышы ачыграк ишетелде.— Аллага шөкер, күзен ачты...

Күзен йөртеп, Нәүфәл тавыш килгән якка карады, әмма һичкемне дә күрмәде. Тик бераздан гына, томан пәрдәсе аша, күзенә Зөһрә җиңгәчәсенең йөзе чалынып китте, һәм ул да шундук югалды. Тагын эзләнде — ниһаять, тапты. Ак косынка бәйләгән, өстенә ак халат кигән Зөһрә караватт башына таянып каршында басып тора, аның һәр вакыт эчке дәрт белән янган күзләре сүнгән-сүрелгән, түгәрәк мөлаем йөзе агарынып-тартылып киткән.

— Ике көн бит инде, ике көн! Укол артыннан укол. Күпме кан салынды, авызыннан кислород өзмәделәр. Валентина Петровна тәмам ашаудан язды, ничек аяклары йөртә икән бичараны,— икенче хатын тавышы тоныграк ишетелә, әмма һәр сүзен аңлады Нәүфәл.— Әйтәм бит, хәлләре бетте инде, бичаракайның. Менә шулай инде алар, һәр

авыру өчен кайгыра-кайгыра үзләре чиргә сабышалар, үз гомерләрен яртылаш кыскарталар.

— Муен пешерә, җиңгәчәй. Утлы күмер бастырып куйдыларммы әллә?

Күз алдындагы томан пәрдәсе ачылгандай булды, тора-бара тирә-юнь актыра барды, хәзер инде җиңгәчәсен генә түгел, аның янында басып торган юанрак гәүдәле, битен җыерчыклар сырлаган олы яшьтәге нянаның йөзен дә яхшы күрде Нәүфәл.

— Пешермичә... Яна да, көя дә инде ул, бәгырькәем, яна да, көя дә, — дип кабатлады няня. — Өзелгән сеңерне ялгап куйдылар бит, балакай, ничек авыртмасын ди. Хәзер сиңа кымшанырга да ярамый, кан тамырларың өзелеп куюы бар.

— Бу хәтлесен каян беләсең соң син, Камәрия апа? — дип сорады Зөһрә нянядан.

— Ишетеп торам ич, ничәмә-ничә көн шуның турында сөйлиләр. Шуны да белмәскә, апаң утыз биш ел инде больниста, утыз биш ел, балакаем.

Йомшак кына басып, ишектән озын гәүдәле сестра килеп керде, аның кулында ярты литрлы шешә, дару ампулалары. Ампулаларны ул иплəп кенә тумбочка өстенә тезде, шешә авызын чишеп шытырдавык кәгазьне алды да андагы сыекчаны Нәүфәлнең баш очында эленеп торган пыяла савытка коя башлады.

— Тагын бер яртыны өстәп җибәрик әле үзенә, берəз хәл керә төшсен,— ди ул. Үзе елмая. Әше беткәч ул шешәне янә тумбочка өстенә урнаштырды һәм шешә авызын янә шул шытырдавык кәгазь белән каплап куйды. Аның житез бармаклары белән ампуланың очын шартлатып сындырып алуын, шприцка дару суыртып, Нәүфәлнең беләгенә укол кадавын өчесе дә шым булып карап тордылар.

Сестраның һәр хәрәкәтен Нәүфәл күз дә алмыйча күзәтеп ятты, әйтерсең хәзер, менә шул уколдан соң, утлы бөжрәдәй кыскан авырту басылачак һәм йөрәк әрнүе бетәчәк иде. Әмма сестра укол салса да муен тирәсендәге сулкылдау кимеми, Нәүфәлнең түземе җуела, ул ыңгырашып куя.

— Ыңгыраш-ыңгыраш,— ди аңа няня.— Хәлең җиңеләя төшәр. Хатын-кызга бала тапканда тикмәгә генә кычкырырга кушалармы әллә? Ыңгыраш, кычкыр. Мин сезнең тавышка өйрәнгән инде.

Юк, бу чатнауга түзмәле түгел. Нәүфәл күзләрен йома, тешләрен кыса.

— Үтәр ул, үтәр, балакаем, авыртуы да үтәр. Түз, җаныкаем, бер-ике көннән рәтләнә дә башларсың, боерган булса,— дип өстәде җиңгәчәсе.

Авырту дулкын-дулкын булып килә, чигә тамырларын көйдереп ала, зиһенне томалый, һәммә нәрсә күздән яза, тагын бераздан аңына килә Нәүфәл, янә зиһене ачылуын тоя.

Сестра каядыр чыгып китте, ул да түгел, алар врач белән килеп керделәр. Нәүфәл Валентина Петровнаны таныды.

— Ай-һай, йоклап та карадыгыз,— диде врач, Нәүфәл янына килеп, пульсын санады.— Яшибез болай булгач, Нәүфәл Садриевич, яшибез.

Ул елмая, ап-ак тешләре күренә, ә күзләрендә һаман борчылу сизелә — талчыгу билгеләре. Нәүфәл аңа күзе белән генә елмайды.

— Рәхмәт сезгә, Валентина Петровна. Күпме борчылулар, тынгысызлык китердем мин сезгә!— дип пышылдап кына әйтте. Ул үз тавышын үзе дә ишетмәде, ләкин врач аны аңлады.

— Зарар юк, Нәүфәл Садриевич. Сез сәламәтләнәсез икән, шунардан да зур шатлык юк безгә. Сезнең бәхеттән Роман Гурьевич килеп чыкты, ул безнең республиканың клиник больницасында эшли,

атаклы хирург, медицина фәннәре кандидаты, докторлыкка диссертация якларга җыена. Ул булмаса, бу катлаулы операциягә мин берүзем генә тотына да алмас идем һәм ул операциягә миңа һичкем дә рөхсәт бирмәс иде. Бәхетегез бар икән. Операция бик әйбәт узды, һәммәсе дә төгәл эшләнде, ә калганы...— Валентина Петровна Нәүфәлнең кул сыртын чәбәкләп алды.— Калганы инде, дускаем, сезнең үзегездән тора. Режим һәм безнең һәр таләпкә һичшиксез буйсыну.— Валентина Петровна тавышын түбәнәйтә төште, Нәүфәлнең колагына гына пышылдагандай, аңа таба иелде.— Дөресен генә әйткәндә, сез мине бик куркыттыгыз, ай, ничек куркыттыгыз! Мине генә түгел. Әнә Зөһрә ханым һаман һушына килә алмый әле,— дип елмаеп, Зөһрәгә карап алды хирург.

— Гаеп миндә, Валентина Петровна,— дип, ниһаять, телгә килде Зөһрә дә.— Операция ясату турында сүз кузгатучы мин идем бит. Үзем үгетләдем, үзем сөйләштем. Ул-бу булса...— Зөһрә түзмәде, яшенә тыгылып янә сүзсез калды.— Мин... Мин...

— Я, я, Зөһрә ханым, сез арыгансыз, сезгә ял кирәк. Бернинди гаебегез дә юк. Киресенчә, бик дөрес эшләгәнсез үгетләп. Күптән кирәк булган аңа безгә килергә.

— Ахыры хәерле булсын инде. Рәхмәт сезгә, Валентина Петровна...— дип, Зөһрә һаман күз яшен сөрткәләде.

— Барыгыз, Зөһрә ханым, кайтып ял итегез. Нәүфәл Садриевичны карарга кеше бар, бер ялгызы калмас.— Хирург хатын урындыктан торды, тәрәзәгә таба атлады.— Күрегез, яңа көн дә туып килә,— диде ул, алсуланып килгән кояш чыгышына таба карап.

— Я ходаа, нинди матур көн туып килә,— дип куәтләде врачның сүзен няня.— Иншалла, тиздән рәтләнер, мин әйтте диярсең. Бар, алтыным, бар, тыңла духтырның сүзләрен, кайтып ял ит. Мин дә шунда гына торырмын, бер дә борчылма...

...Нәүфәл йокламады, ниндидер томан эченә кереп югалып-югалып кына алгалады. Авырту әле кимемәгән, дулкын-дулкын булып эче әрнешү кабатланып тора, чигә тамыры ярсып тибә дә тибә. Няня һаман үз урынында утыра, башын игән килеш йокымсырый. Нәүфәл аягын кузгатып карады — ул хәрәкәтләнде, ләкин ярты гәүдә таш кебек авыр, гүя өстенә комлы капчык салганнар. Инде яктырды һәм тәрәзәгә кояш нурлары сарылды, шунда Нәүфәл ишек янында берәүнең басып торганын күргәндәй булды, ул аны бик аз, кырын күзе белән генә күрә кебек, ләкин ул кеше бар, ишек янәгына сөялеп берәү тора сыман иде. Нәүфәл үзенә-үзе ышанмады, миңгерәгән бер хәлдә күзгә нәрсә чалынмас. Андый вакытта кеше күңеленә үткән гомердәге иң изге, иң кадерле мизгел килә. Ул аны, шушы мизгелне, үлем түшәгендә янә бер күзаллыйдыр, ул мизгел хәтердә балавызга манчылган сыр кебек сакланып кала — димәк, мәңгеләшә. Халисә эт өстерү белән генә түгел, аның күңеленә башка ягы белән дә сеңеп калган, чишмә буе, ниһаять, кыңгыраулы алан — һәммәсе күз алдында. Әмәхәббәтме соң бу, әллә яшьлектәге мавыгуларның берәве генәме? Нәүфәл моңа әле булса җавап бирер дәрәҗәдә түгел, аны ачыкларга теләми дә. Аның Халисәне күрәсе килде — бары тик шул гына иде бу мәлдә теләге. Күргәч ни әйтәсен дә белми иде ул, ләкин күңел дигәнең алҗысына, йөрәк ярсый. Егет ул эшләгән больницага ятты, үлем белән якалаша, ә изге затның әле булса кереп хәлен белгәне юк. «Ник килми ул, ни гаебем бар минем аның алдында?»— дип өзгәләнде Нәүфәл. Шушы өзгәләнү, сагыш-кайгы аны әрнешүдән читкә алып китте, рухына көч бирде.

Тагын күзләрен тирә-юньгә йөртеп алды Нәүфәл һәм ишек янында басып торучы берәүне күргән кебек булды. «Ә бәлкем ул килгәндер, Халисә басып торадыр?» Чигә тамыры һаман дылк-дылк тибә. «Чи-

бәр хатын чибәр ир сайламый, чибәр хатын саф ир сайлый»,— дип кем әйткән иде соң әле аңа? Һич хәтергә төшми. «Халисә, кайда соң син, ник якын килмисең! Мин сине күрмим!» Уңайлабрак башын борырга итә Нәүфәл, көчле авыртудан тирә-юньдәге бар нәрсә томан эченә кереп югала, ул упкынга оча, янә аңын җуя. Бераздан тагын аңына килә, бөтен тәнендә ниндидер оеп киту тоя, күзен ача. Көн яктыра барган саен әрнешү дә арта сыман. Баш әйләнә, күңел болгана. Нәүфәл ишек ягына янә кырын күз салды, тик инде яктырып килгән палатада йокымсырап утырган нянядан башка берәүне дә күрмәде. «Минем күзгә генә шулай күренгәндер. Нишләп килсен ул, нигә кирәк мин аңа»,— диган уйлардан арына алмый җәфаланды. Аның тамагы кипте, иреннәрендә ут көйрәде, ә эчәргә һаман бирмиләр, кан тамыры аша ниндидер сыекча гына җибәреп торалар иде. Няня аның кипшенгән иреннәрен вакыт-вакыт юеш марля белән сөртеп ала да шунда ук йокымсырап китә. Нәүфәлнең һичнинди чыдар әмәле калмады, ул ыңгырашты, «су, су...» дип пышылдап карады. Ә няня утырган килеш оеп киткән, черем итә. Сәгать ничә икән? Дүрт, биш, алты? Алты түгелдер, иртә әле... Зиһен томалана, авырту көчәя бара, ул инде ыңгыраша да алмый, янә аңын җуя... «Мөгаен, шулай үләләрдер»,— дип уйлана ул сүлпән генә.

Аңына килгәндә, әлеге няня аның иреннәренә юеш марля тигезә иде. Нәүфәл моны күзләрен ачмас борын ук тойды. Беләктә янә бар сыман, авырту сизелмәсә дә, авырлык сизелә. Күзләрен ачты, күз алдында саргылт-яшел тәңкәләр бии, шулар арасында ак башлыклы берәү чалынып-чалынып китә сыман, менә ул югала, күксел дулкын эченә кереп эри, тагын килеп чыга.

— Җитәр! Туктатыйк,— дип боера кемдер.

Һәм янә Нәүфәлне йокы баса, юк, йокы да түгел, ә ниндидер авыр томан эчендә кала ул. Ләкин колак ниндидер сүзләрне ишетә. «...Нәүфәл, җаным, бу мин! Ач күзеңне! Син терелергә тиеш, ишетәсеңме, терелергә тиеш!..» Күзләрен ача, әзләнә, ниндидер саргылт-яшел тәңкәләр биешкәнен күрә башлый, бераздан алар да югала... «Башның хәле үзгәрми, ә кеше сөйләшүен ишетәм. Таныш бер аваз... Бу — син!»

## 18

— Валентина Петровна, нервыларына зыян килмәгәндер бит. Нигә атна буена сөйләшә алмый ул?

— Булмас. Кичә Роман Гурьевич шалтыратты. Шеше кимегәч, сөйләшә башлар, ди, ашыктырмагыз, тавыш җепселләренә авырлык килмәсен, ди.

Гайсә башын иеп, уйланып утырган хирург хатынга озак итеп карап тора — сынап, аның хәленә керергә теләп карый. Әйе, хирург һөнәре җиңел эш түгел, һәр чак кеше гомере, кеше язмышы белән бәйле нәрсә, ләкин мондый тәвәккәллеккә бару... «Әйе, минем бу операцияне ясарга алынмавым дөрес булган. Ярый әле, Роман Гурьевич килеп чыкты, Валентина Петровнаның эшләре хөрт булачак иде, алай да бәхете бар икән хатынның. Бәлкем мин остарак та ясаган булыр идем, шул ук вакытта миңа ярамый да иде, бергә үстек... Халисә... Ул аны әле булса ярата, шушы хәлендә дә, караватта хәрәкәтсез ятканда да, чиратсыз дежурстволар ала, тик аның янында гына булсын, тик аңа гына игелек эшләсен. Гаебен юарга исәбеме, яшьлектә эшләгән хатасын төзәтергә теләвеме? Аңламассың... Ләкин ул сине аңлармы, Халисә»,— дип уйланып утырды Гайсә.

— Бүген хәле бераз аруланды кебек. Ләкин хәрәкәт...

— Бөтен хикмәт тә шунда шул — хәрәкәттә, Валентина Петровна, шуңарда, җанкисәгем.

Валентина күтәрелеп өлкән хирургка карады, аның «җанкисәгем» дип сөйләшүенә гаҗәпләнде булса кирәк, зәңгәр күзләрендә сәер шик уянды, ләкин Сәмигуллинның вакыт-вакыт бик тә төче итеп сөйләшүен исенә төшерепме, артык дәшмәде.

— Кайгырмагыз, нәтиҗә ясарга иртәрәк әле. Өметләребезне өзмик,— дип, Гайсә җиңелчә генә Валентинаның кулын сыйпап куйды.

Валентинага аның бу хәрәкәте ошамады. «Әйтерсең сабый баланы тынычландыра»,— дип, тегенең кыланышына аптырап, торып ук басты.

— Миңа обход ясарга вакыт. Сез дә барасызмы, Гайсә Ильясович?

— Юк, юк. Башка чакта. Бүген минем бик җитди эшем бар.

Валентина чыгып китте. Гайсә дә бүтән дәшмәде. Ул бөтенләе белән Халисәсе турында уйга чумган иде. Ир буларак Гайсә аны яратты, булдыра алган кадәр изгелек эшләргә тырышты, ә ул... Ул һаман Нәүфәлне ярата микәнни? Халисә булмаса, мөгаен, ул үзенә менә дигән хатын тапкан булыр иде, үзен өзелеп сөйгән хатын да таба алган булыр иде. Әйтик, шул ук Нәзиләгә өйләнгән булса? Дөрес, кыз аннан ун яшькә кечерәк, соң, яшьтәмени хикмәт, хикмәт бит берберенне аңлауда, яратуда. «Ә ул мине аңлый, алла итеп күрмәсә дә, пәйгамбәрдән ким күрми. Ә Халисә? Ни турыда уйлый микән бу хатын? Тилергән димә инде шуннан соң. Кемне кем белән чагыштыра, кемне кем белән алыштыра бит. Ире таза-сәламәт кеше, сирәк һөнәр иясе, районда аны һәркем белә, күпме кеше аллага табынгандай табына. Ә теге кем? Караватыннан кузгала алмыйча ятучы инвалид. Ярый, бер вакыт кузгалыр да, йөгереп тә китәр, әмма тулы канлы кеше була алырмы? Кәкре муенына тагын бер зәгыйфьлек өстәлсә, гомергә тавышсыз калса? Юләр димә инде син бу хатын-кызны. Аек фикер йөртүне һичнигә санамый, аңа хис кирәк, хис белән яши! Белмим, озакка җитәрме ул хис ялкынын, Халисәкәем? Дөрләп янарсың да, бер мәлне кисәү кебек каралып калырсың. Шуннан кемгә кирәгең булыр икән?!»

Халисәнең бу кыланышына ачуы шул чаклы кабарды Гайсәнең, бертуктаусыз янак итен чәйнәде, нервыланды. Үч алу уе аңа операция вакытында үзенә инструментлар биреп торучы Нәзилә белән күзгә-күз очрашкач килде. Операция беткәч тә, кул юганда да Гайсә янә кызга карады. Кызның куе коңгырт чәчләре бөртегенә чаклы ак косынка астына кыстырылган, бит-борынын маска каплаган, шуңамы чем-кара күзләре тагы да зураеп калган шикелле. Сокланырлык, акылдан шаштырырлык күзләр. Моңа кадәр кызның чибәрлегенә сокланып йөрсә дә, аның күзләренә болай текәлеп караганы юк иде әле аның.

— Бергә кайтырбыз, Нәзилә. Киткәндә миңа сугылырсың, мин операция турында яза торам,— диде ул аңа операция тәмамлангач.

Нәзилә каш астыннан гына карап алды, мөлаем итеп елмайды, кара күзләре елтыр-елтыр килде.

— Егетең көнләшер дип куркасыңмы әллә?..

— Минем егетем юк, Гайсә абый.

— Ай-һай, бер дә ышанырлык сүз түгел бу, шундый сылу, чибәр кызның егете булмый диме. Берәр яры киттеме әллә?

Кыз дәшмәде, кеткелдәп көлеп кенә алды.

— Ник көләсең? Хак сүзгә җавабың шулмы?

— Кызык,— диде кыз.— Болай гына...

Кеше вөжданы, аның йөрәге кебек үк, беркайчан да йокламый ул, һәр вакыт уяу булыр. Вөжданы йокымсыраган кеше икейөзләнүчән, гамьсезләнүчән, кыскасы, вөжданы юкка чыкса, кешенең йөрәге дә сүнә, сүрелә. Бу вакытта ул эшләгән һәр игелек кысыр була, бөтен килеш-килбәтендә, кыяфәтендә, үз-үзен тотуында рәсмилек, ясалмалык өстенлек итә башлый. Кеше итагатьсезләнә, ваклана, чөнки вөждан — ул кешенең шәүләсе, ул аның җаны. Ансыз адәм эшләгән һәр игелек юкка чыгар иде. Әйе, күз яше маңгай тире түгел, намусы саф булмаган хәлдә кешене барыбер вөждан газабы кимерәчәк. Вакыт хафалы кеше өчен генә кадерле. Дөнья мәшәкате өчен хафаланмаган гамьсез зат, мүкләнеп беткән таш кебек, сырлы, кытыршы, эшкә яраксыз була.

Нәзилә белән янәшә атлаганда Гайсә әнә шул турыда уйлады. Кайчандыр ул үз бәхетемне инде мин күптән таптым дип йөри иде, табылганны югалту куркынычы тугач, чын хәлне объектив рәвештә бәяләргә тырышты. Ләкин фикерләренең очын-очка ялгый алмады. Чынлап та, бәхетеңне табу — җан тынычлыгымы? Вөжданың газаплана икән, бу бәхетме? Аның болай сәрхушләнеп йөрүе кемгә кирәк?

Гайсә, шундый буталчык уйларына чумып, сүзсез генә атлый бирә. Мондый халәттә ул күптән, бик күптән булганы юк иде инде. Моңарчы ул үз дәрәҗәсенең түбән татып, тормыштагы үз урынын яхшы белеп, юлга нык басып йөри торган иде, соңгы вакытта бу ныклыгы шактый какшады, хәтта җитди операция ясаган вакытта да кинәт Халисәне күз алдына китерә, хатынының Нәүфәл өчен өзгәләнүе, тик «аның» өчен генә яшәве аны шаштырыр дәрәҗәгә җиткерә, шул хәл исенә төшүгә, кинәт нурсызланып калган күзләре бер ноктага текәлә, тик куллар, шушы эшкә өйрәнгән, гадәтләнгән куллар гына күнеккән эшне төгәл башкаралар иде. Нәкъ менә шундый чакларда аңа Нәзилә шакката, хирург белән ни булганын белүдән битәр, аның гадәти хәрәкәтендә сүлпәнлек күреп күзләре зурая, гадәттә күзләр белән генә сөйләшергә өйрәнгән, хирургның ярым-ярты хәрәкәтеннән, карашыннан аңа нинди инструмент кирәклеген аңлаган Нәзилә дә бер мәлгә аптырап кала иде. Гайсә кызның кашлары җыерылуын күрә һәм аңа курку килә: өстәлдә яткан авыру өченме, кыз өченме, үзе өченме? Шушы курку кинәт аны айнытып җибәрә. Ул тынычлана, бөтен игътибарын операциягә юнәлтә.

Әйе, нигә соң әле бу тикле лаф орырга, онытылып хәлләргә җитеп кайгырырга тиеш ул? Аның яраткан эше бар, бу өлкәдә ул районда бер хирург дияргә була. Аны хөрмәт итәләр, һәр киңәш-сабагына колак салалар, аңа менә шундый яшь, чибәр кызлар гашыйк була.

Янәшәсендә Нәзилә атлый. Ул чәчкәдән чәчкәгә кунып, очынып йөргән күбәләктәй — җиңел атлый, ул шат, ул, мөгаен, бу минутта бәхетледер. Нәзилә нидер сөйли, ул да булмый, кеткелдәп көлеп ала. Озакламый ул да, Гайсә сүзсез баргангамы, кинәт кенә тынып калды.

Төннәрен, операциядән соң, алар еш кына шулай бергә кайталар иде. Гайсә кызны һәр вакыт өенә кадәр озатып куя. Кайта-кайтышлый алар операциягә җентекләп анализ ясыйлар, аерата катлаулы операция уңышлы тәмамланган чакларда Нәзиләнең түбәсе күккә тия. Гайсә дә аеруча күтәренке күңелле, шат була, кызга бер-бер артлы мәзәкләр сөйли, аны көлдерә иде. Күпме кирәк яшь кызның күңелен күрү өчен. Гайсәнең бүгенге халәте Нәзиләгә дә ят иде, күрәсең.

— Гайсә абый, без инде сезнең белән бергә шактый вакыт эшлибез, бер-беребезне яхшы беләбез дип уйлый идем. Әйтегез әле, сер булмаса, ни булды сезгә? Сез бөтенләй үзгәрдегез, коллективтан читләшәсез. Миннән дә...

— Ни дип әйтим, Нәзиләкәй, сиңа? — Гайсә кинәт туктап калды,

каршысына килеп баскан кызның бүген аны аерата гаҗәпләндергән шомырт-кара күзләренә карады.

Аның бу туры карашыннан кыз уңайсызлану тойдымы, торган урынында таптанып алды, болай да зифа гәүдәсенә бик ипле яткан кызыл плащын рәтләгән булды, күзенә төшкән чәч бөртекләрен берет астына яшерергә кереште.

— Сезнең турыда, Халисә апа турында төрле сүзләр йөри, Гайсә абый... — дип ачыктан-ачык әйтеп салды кыз. Һәм шунда ук, әйткән сүзләреннән оялыпмы, башын түбән иде.

— Сөйлә-сөйлә, Нәзилә. Ник туктадың? Башлаган сүзне тәмамла инде.

— ... Имеш, Нәүфәл абый Халисә апаның яшьлек мәхәббәте, ә сезне... — янә әйтимме-юкмы дигәндәй, тотлыгып калды Нәзилә.

— Нәрсә, мине?

— Сезне ул яратмый, диләр. Юк-юк, мин ул гайбәткә ышанмыйм. Сезне аның белән чагыштырып буламы соң? Сез... Сез бит шундый акыллы. Ә кулларыгыз? Алтын алар, мин беләм, мин күрәм бит. Юк, сез һичкем белән дә чагыштырырлык кеше түгел. — Кыз, ике кулы белән битен каплап, елап ук җибәрде.

Гайсә ни кылырга, ни әйтергә белмичә каушап калды.

— Тынычлан, җаныкаем Нәзилә. Син арттырасың, мәсьәләне катлауландырасың. Гап-гади хәлләрне дә үзеңчә күрәсең, димме. Әйдә, кайтыйк. Соң инде, әниең борчыладыр.

— Әни Шалтыга китте, мине беркем дә көтми, Гайсә абый, — кыз битеннән кулын алды, кулъяулык белән күз яшьләрен сөртеп куйды.

Кабат янәшә атлап киттеләр, Гайсә кызның җилкәсенә кулын салып, аны сөеп алды.

— Син бик тә, бик тә яшь шул әле, Нәзиләкәем, артык турылыклы димме. Ә тормыш ул бик катлаулы, син әле аңламыйсың, бик күп нәрсәләрне аңламыйсың...

— Мин бит барысын да күреп йөрим, Гайсә абый.

Моңа кадәр кызның йөзендә беркайчан да үзе өчен кайгыру чалымнары күрмәгән Гайсә тәмам аптырап калды. Операция вакытында үз вазифасын сүзсез генә, төгәл итеп үтәгән кыз да аңарда үзгәрешне күргән. «Әйе, бөтен дөньямның асты өскә килде бу Нәүфәл белән, әйтерсең җен алмаштырды, — дип уйлап алды Гайсә. — Мин гел кара коелып йөрим, үз-үземне күрәлмас дәрәҗәгә җиттем». Әмма ул Нәзилә белән сөйләшкәндә аек фикер йөртә иде. Ә бит Нәзилә дөрес әйтә. Соңгы көннәрдә Гайсә Халисәне битәрләүдән, аның кыланышларын яманлаудан, аны гаепләүдән артык берни дә эшләмәде. Моңарчы алар бер-берсен аңлап яшәделәр, Халисәгә яки үзенә кыенлык килгәндә бер-берсенә ярдәмгә килделәр. Гайсә үзен шулай тынычландырырга тырышса да, эчке сыкравы кимемәде. «Нигә соң әле миңа гына кирәк бу гаилә татулыгы? Кайчанга хәтле бу авыр йөкне бер мин генә тартырга, җаваплылык тоярга тиеш?»

Нәзилә янә тынып калды, башын түбән игән килеш атлый бирде. Яшьлек хисләрендә йөзеп, ваемсыз гына яшәргә иде дә бит, юк, гүзәлкәй, кеше кайгысын кайгырта, кеше хәсрәте белән яши. «Ашыкма, Нәзилә, өлгерерсең әле, сиңа да килер ул яныр-көюләр. Гаилә юллары сикәлтәсез булмый, дөнья бу», — диясе килде Гайсәнең Нәзиләгә, әмма дәшмәде. Операция вакытында башына килгән баягы уеннан ул үзалдына оялып китте. Нәзилә аңа укучы бала укытучысына гашыйк булган кебек гашыйк, яшьлекне гел юкка гына дивана чак димиләр шул. Шул изге мәхәббәтне бүтән нәрсә белән бутап, гафу ителмәслек хата ясап куюы бар ич Гайсәнең. Ә куйса ни! Ул мине үлеп ярата. Кемгә тәтегәне бар мондый яратуның?..

Өй тирәли үскән ае каеннар караңгылыкка чумган. Тирә-юнь тып-тын. Тымызык кына яңгыр ява.

— Менә кайтып та җиттек, Нәзиләкәй. Күтәр әле, күтәр башыңны. Нинди моң бар синдә? Иң бәхетле чорың ич синең, Нәзиләкәй! — Гайсә кызның иягеннән тотып башын күтәрде, күзләренә карады. Багана башындагы лампочкадан шәмәхә-зәңгәр яктылык төшә, бу төс Нәзиләйөзенә операция өстәлендә яткан авыру чырае бирә.

— Я, я, кыю бул. Ә хәзер елмай. Болай боегырга бер генә сәбәп тә юк ич.

— Гайсә абый, мин... мин... — көтмәгәндә кыз аның күкрәгенә капланды да елап җибәрде.

«Тиле син, тиле, шул кирәк сиңа,» — дип үз-үзен орыша-орыша, Гайсә кызның калтыранган гәүдәсен күкрәгенә кысты, аның йомшак битләреннән сыйпаштырды, яшь тулы күзләрен үбеп алды. Нәзилә, аның муенына сарылган килеш, тынып калды. Бер генә мизгелгә акылын җуйды шул чакта Гайсә, башы әйләнеп, бөтен тәне буйлап кайнар дулкын узды. Үз-үзен онытып, иреннәре белән кызның кайнар иреннәрен эзләде. Шунда ук: «Тукта! Нишләвем бу!» — дип, үзен бик тиз кулга алды. Инде тынычланып калган кызның һаман да әле яшьтән кипмәгән күзләрен бармак очлары белән сөрткәләде, берет астыннан сибелеп төшкән чәчләрен рәтләде.

— Гафу ит мине, Нәзиләкәй, зинһар, гафу итә күр.

— Юк-юк, ни өчен миңа алай дип әйтәсез?! Мин сезне күптән, бик күптән якын күрәм, Гайсә абый. Сез минем өчен кояш кебек, якты көн кебек. Сез булмасагыз, бу дөньяда яшәүнең бер кызыгы да калмас шикелле...— кыз ашыкты, әйтәсе сүзен әйтеп бетерергә теләде. Гайсә абыйсы аны бүлдерер, моннан битәр тыңламас, бүтән аңа мондый җай беркайчан да килмәс һәм бу сүзләрне яңадан әйтергә ул һичкайчан кыймас кебек тоелды. — Сез тылсымга ия кеше, Гайсә абый. Шушы кулларыгыз сезнең искиткеч эшләр эшли, нинди катлаулы операцияләрне ювелир төгәллеге белән ясыйсыз. Мин сезнең алтын кулларыгызга гашыйк. Сезнең һәр сүзегез, һәр карашыгыз минем күңелгә шатлык өстәгәнне белсәгез икән. Юк-юк, сез гаепле түгел. Халисә апа сезне аңлап кына җиткерми...

— Нәзиләкәем, бүген синең күңелең искиткеч соклану хисе белән тулышкан. Тыңлыйм да сине, көнләшеп куям. Минем дә шундый көннәрем бар иде. Синең әле сабый бала кебек саф чагың. Шуның өстенә фантазерка икәнсең бит әле, чын-чынлап фантазерка. Ләкин зарар юк. Мин дә сине яратам, бик тә... туган сеңлемне яраткандай... Син үзең хирург булырдай кеше, теләгең булса, бәлки бер мәл хирургия серләренең нечкәлекләренә төшенерсең; минем кебек хирург булырсың, бәлки әле миннән дә уздырырсың, ә?..

— Әйе, әйе, Гайсә абый, рәхмәт сезгә... Гафу итегез мине... Озатыгыз мине. Бергәләп чәй эчәрбез, — кыз кинәт кенә йөгерә-атлый ишеккә таба китте. Гайсә аның аяк тавышларын тыңлап торды, икенче мәлдә ул кызны куып җитте һәм култыклап алды.

Өздереп искән әрсез җил плащ чабуларын уйната, куенга керә, арка буйлап йөгерә, тәнне кымырҗыта. Бәреп яуган яңгыр, яшь бөртекләре кебек, бит буйлап йөгерешә. Ә ирендә Нәзиләнең әче яшь тәме, юләр яшьлекнең кысыр кайгысы.

*

* *

— Гайсә Ильясович! — Дежур сестра каршыга йөгерә иде. — Әмировның хәле начар, пульсы югалды.

Гайсә йөгерә-атлый баскычтан менде, кабинетка кереп өстен алыш-

тырды, икенче катка чапты. Бишенче палата тулы врачлар, сестралар. Нәүфәлгә ясалма сулыш алдыралар, укол салалар. Ашыгып килеп кергән Гайсәгә Валентина Петровна хәтта күтәрелеп тә карамады, авыруның йөрәгенә тышкы массаж ясавын дәвам итте. Нәүфәлнең баш очында Халисә ясалма сулыш аппаратының эшен күзәтә, йөзе агарынган, күксел-кара күзләре эчкә баткан. Кемдер система хәзерли, һәммәсе эш белән мәшгуль.

— Ни булды, Валентина Петровна?

— Кинәт кенә хәле начарланды, — диде Меженкова. — Торып утыра башлаган.

Гайсә авыруга карады. Яңаклары эчкә баткан, йөзендә кан әсәре калмаган иде. Яраны каплаган марля коры, димәк, хәл начарлануы кан югалтудан түгел. Шок. Сестра авыруның венасын таба алмый азаплана. Валентина Петровна бер мизгелгә генә массажны туктатып тора, мониторга күз сала.

— Юк кына бит, — ди ул, аннары кул аркасы белән маңгаеннан тир бөртекләрен сөртеп янә массажга керешә.

— Сестра! Йод бир, спирт! Энә, озынын! — Гайсә җитез кылана. Энә күкрәк читләрен тишеп йөрәккә керә, шприцта ал кан күренә. — Хлористый кальций! — Икенче шприц белән ул янә бер укол ясый.

— Пульс бар! — ди Валентина Петровна.

Барысы да монитор ягына борылып карыйлар, зәңгәрсу ут ноктасы сикергәләп алды һәм сирәк кенә йөрәк циклын яза башлады. «Бар, бар,» — диештеләр һәммәсе дә һәм җиңел сулап куйдылар.

— Артерияне ачабыз, венага салу файдасыз. Скальпель, зажимнар, яра киңәйткечләр! Тиз! — дип боерды Гайсә. Артериягә җибәрәбез басым белән. — Валентина Петровна аның белән ризалашып ияк кага.

Система рәтләнеп куелгач, Гайсә тәрәзә янына китеп басты, аркасын салкын стенага терәп хәл алды, ә үзе һаман Нәүфәл турында, аның хәзер генә кыл өстендә калган язмышы турында уйлады. Шул рәвештә Гайсә сестрага боерык артыннан боерык бирде: нинди дару, күпме күләмдә, кайсын кайчан бирергә кирәклеген әйтеп торды. Ә мониторда ут ноктасы сикерә-сикерә Нәүфәлнең йөрәк ритмын яза барды. «Ул яшәячәк! Яшәячәк! — ди сыман иде һәрбер йөрәк циклы.

Гайсә хатыны ягына карамаска тырышса да, аларның карашлары ниндидер бер мизгелдә кисешеп алды. Хатынының күзендә елмаю чалымнары күрүгә, үзе дә ирексездән елмаеп куйды: «Рәхмәт сиңа, Гайсә, мең рәхмәт!» — ди кебек иде аңа хатыны.

— Рәхмәт сезгә, Гайсә Ильясович! — диде Валентина Петровна.

Дежур врач кан басымын үлчәп, пульсын тикшереп һаман авыру янында торды, Нәүфәлнең тамагына куелган трубканы алып, аппаратны сүндереп куйды.

— Ни өчен рәхмәт, Валентина Петровна?

— Килеп өлгерүегез өчен рәхмәт.

— Мин өлгермәсәм, үзегез дә нәкъ мин эшләгәнне эшләр идегез. Иң мөһиме, кешене үлем тозагыннан алып калдык.

— Барыбер... бергәләп җиңелрәк. Аннан сезнең белән булганда үз-үзеңә ышанарак төшәсең, — дип куйды Валентина Петровна.

Халисә аларның сүзләренә кушылмый, ул, хәлсезләнеп, караватянындагы урындыкта утыра.

Нәүфәлнең сулышы тигезләнде, чыраенда яшәү нуры белена башлады.

— Нәүфәл Садриевич, Нәүфәл Садриевич! — дип уяткандай итте авыруны Валентина Петровна.

Нәүфәл күзен ачты, тирә-юньне карап алды. Халисә, аягүрә басып, күзен алмыйча аңа карап торды, әйтерсең ул ниндидер могҗиза күтә

иде. Палатаның түшәм-стеналарыннан Нәүфәлнең күз карашы Валентина Петровнага күчеп тукталды, ул врач хатынга көч-хәл белән елмайды, аннан карашы белән ул Халисәне тапты, күз алмыйча аңа карап торды, күз читеннән елтырап яшь бөртеге тәгәрәп чыкты һәм ак җәймәгә төшеп җәелде, тап булып сеңеп калды.

— Хәлең ничек, Нәүфәл? — дип сорады Халисә.

— Ярыйсы, — диде Нәүфәл, ишетелер-ишетелмәс кенә.

— Гайсә дә монда.

Авыруның карашы янә палата буйлап йөрде, тәрәзәгә төште, Гайсәне эзләп тапты, аңарда тукталды. Врач һәм авыру, ике кеше бербереннә карап тордылар да, сөйләшкәндәй, икесе берьюлы елмаештылар.

Кояш чыга, нурлары челтәрләнеп зәңгәр һавага үрелә, өй түбәләрен капшый, тәрәзәләргә куна, тәрәзә каршысына басып торган Халисәнең күз яшен киптерә.

## 19

Агач башларына тиеп болытлар йөзә, сибәләп кенә яңгыр ява. Кадыйр кабинет тәрәзәсеннән караган да битараф бер кыяфәттә урамны күзәтә. Акташ тавы ягында да күк йөзен томалап болытлар йөзә. Сибәли дә сибәли яңгыр... Мәскәүдән кайтуына ун көн булды инде, Кудрявцевтан ник бер хәбәр булсын, һич югы, шалтыратып хәлен белешсен иде. Идрисовның да күзгә-башка чалынасы килеп тормый, күрәсең. Ә Кадыйрның җаны айкала. Кай якка булса да хәл ителсен иде бит инде...

Министрлыктан кайтып төшкәч тә Кадыйр киңәйтелгән идарә утырышы җыйды. Идарә каршындагы биш катлы өйнең тәрәзәләрендә утлар сүнгәнче гәпләшеп утырдылар. Нефть чыгару күләмен киметмәү өчен өстәмә резервлар эзләнде. Утырышка Татарстанда беренче буровойларны корып йөргән чал чәчле агайлардан башлап, әле яңа гына институт тәмамлап килгән яшь белгечләргә кадәр катнашты. Промысел җитәкчеләре нефть алу мөмкинлекләрен янә бер тапкыр җентекләп тикшереп чыктылар. Эзли торгач, шактый гына резервлар табылды кебек, барысын да яңабаштан исәпләп карадылар. Тик, юк, табылганы «хәерчегә ямаулык» кына булып чыкты. Бөтен өмет күмер катламыннан файдалануны тизләтүдә иде. Ләкин аны тиз генә җайга салу җиңел булмаячак.

... «Нигә суза икән бу Кудрявцев, нигә җанны кыйный. Юри шулай эшләвеме? Шалтыратам — юк, шалтыратам — юк», — дип, һаман Кудрявцевны орышты Кадыйр.

Зөһрәсе шалтыратты-шалтыратты да, ахры, тынып калды, иренең тиз генә кайтмасына ул да ышанды бугай. Кадыйрның чынлап та өйгә кайтасы килми, гомумән, кабинетыннан да чыгасы килми иде. Ул мәктәптән кайтып баручы балаларны күрә, алар бүген ашыгалар, төньяктан искән җил аларны да куалый сыман. Урамнан туктаусыз машиналар үтеп тора. Карашы коймадагы афишага туктала. Зур концерт булачак. Җырчылар Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, тагын әллә кемнәр. «Безнең концерт алда әле, зур концерт. Эх, Виталий, Виталий, шундый чакларымда да ярдәм кулы сузмассың микәнни?!» — дип эчтән сыкрап куя Кадыйр. Ничә төн рәтләп йоклаганы юк. Юкка башымны бәйләдем, ахрысы, бу Нәүфәл идеясе белән. Кама якларына гына күчеп китәсе булган да, чирәшмәс иде шушы сүнеп яткан ятма белән. Тәмам салды бит кеше күңеленә коткы бу Нәүфәл дә, иҗау сарбае. Башлы үзе, шайтан малай. Нефтьне судан һәм тоздан арындыруны торбаларда ук үткәрүне, скважиналардан группалап герметик рәвештә

файдалануны искиткеч төгәллек белән башкарып чыкты. Хәзер анә бу ысулны башка идарәләрдән килеп өйрәнеп йөриләр.

Идарәдән чыгуга, ул Нәүфәл янына больницага кирәргәме, юкмы дип бер мәлгә икеләнеп торды. Икенче мәлдә борылды да өенә таба кайтып китте. Кыскасы, әле булса очына чыкмаган мәсьәлә турында сөйләшеп, терелеп җитмәгән энесен борчыйсы килми иде аның.

Яңгыр һаман сибәли дә сибәли, асфальт юлга күлдәвек-күлдәвек сулар җыелган, машина көпчәкләре астыннан пычрак су чәчрәп, яшел газоннарны ямьсезли. Кадыйр тротуардагы күлдәвекләрне урап-урап үтте. Күлдәвек күзенә баса-баса аны резин итек кигән яшүсмер кыз узып китте. Кадыйр үз урамына борылды. Чаттан дүртенче өй аныкы, өченчесе — Идрисовныкы иде. Күршесе бульдог этен ияртеп алмагачлар арасында йөри, «Тынычланган, ахры, бу», — дип, үте сытылып алды Кадыйрның һәм адымын тизләтә төшеп үтеп китте. Үз йортына керү белән Зөһрәнең нидер пешеренүен сизде, бөтен ишегалдына тәмле ис таралган иде. Кадыйрның тамак төбе кытыкланып китте. Тамак колы булмаса да, ни сәбәпледер, коймак, кыстыбый, бәлеш, өчпочмак кебек камыр ашларына ул аеруча мөкиббән китә, туймастай ашарга керешә иде. Шуңа ул өйгә керә-керүгә үк хатыныннан сорап куйды:

— Әнисе, ни бу, нинди тәмле ризык пешерәсең, исе урамга ук таралган?

— Өчпочмак. Нәүфәл янына барып килергә исәп.

— Хәле ничек?

— Муены турайган. Кәефе ару гына. Йөри башлады. Синең турыда сорашты. Мәскәүдән кайтканнан соң янына барганың юк, борчыла, ниләр җимереп кайтты икән абый, ди.

Кадыйр плащын салды, аягына чүәк элде, кухняга узып өстәл янына утырды.

— Әйе, аңа ансат. Ятманы файдаланудан ун көнгә туктатып тор да, вәссәлам. Ә бүген идарә тәүлегенә ун мең тоннага якын нефть биреп ята.

— Шул нәрсәне эшләсәң, юләркәем, сине шушы эшеңдә калдырырлар дип беләсеңме? Идрисовың син китмәс борын урыныңа утырырга тожрап тора.

— Куй, — диде Кадыйр. — Ичмасам, син дә канымны кайнатма. Сибирцев җанга тигәне дә бик житкән. Анысы тагын приказ языгыз да элегез, Сөнгатович, дип җанга тия.

— Аңа котыртырга гына булсын. Аңа нәрсә? Аңа җавап бирәсеме? Биргән хәлдә дә ялгыз башы. Барысы да... син яккан утта кызынырга торалар. Я, кулыңны ю да, әйдә, ашарга утыр, өчпочмагым суына.

Кадыйр юынып килгән арада Зөһрә табынын әзерләгән иде инде.

— Әллә, мин әйтәм, атасы, Нәүфәл янына икәүләп барып кайтыйкмы?

— Анда барып, күңелен генә ярсытып кайтырмын, бармыйм.

— Беләсең килсә, — дип сөйләнде хатын, чәй көйләгән арада, зур сер сөйләргә җыенган бер кыяфәттә. — Ул мескен һаман шул тутсыл чырайлы Сәмигуллин хатынын ярата икән бит. Палатага шушы хатын килеп кердеме, тәмам күзләре елтырый башлый...

— Безнең нәсел туры җанлы, гомер буена бер кешегә табынып яшәде. Яшьлек гыйшкы әле булса сүрелмәгән икән, ярата бирсен.

— Син дә гел берәүгә табынып яшәдеңме? Миңа гына?

Кадыйр күзләрен салмак кына күтәреп, хатынына карап алды.

— Сиңа гына табынам, — диде арыган бер кыяфәттә.

— Миңа гына, — диде Зөһрә, үпкәләгән, үртәлгән бер рәвештә. — Нигә соң Натальяны күрүгә күзең тона, һичкемне күрмәс буласың. Мине сукыр дип уйлыйсың бугай.

— Куйчы. Башка кайгың булмаса, бусы — кысыр. Бар, барырга җы-

енган җирене озай. Миннән дә сәлам юлла. — Кадыйр, ашаудан туктап, чәен болгатып утырды. — Ятманы туктату турында сүз кузгатса, абыең син кайтканнан бирле шул хәл белән чиләнә, диген. Артыгын куертма. Идрисов белән Кудрявцев һаман идарәне промысел итеп калдырырга йөриләр.

Больницага барырга дип киенгәч, ни сәбәпледер, Зөһрә иренең аркасына килеп сыенды.

— Гөлүсә ялга да кайта алмады, ачуланма инде, атасы.

— Барып җитте бугай инде ул кыз да, хәерле булсын.

— Ни булган әле кызыңа? Аның урта бармактай йөргән егете бар, бүген-иртәгә өйләнешергә йөриләр. Беркөнне сокланып карап тордым әле буласы киявгә: буйчан, чибәр, үзе инженер буласы кеше.

— Буйчан, чибәр... Ну-у, хатын! Нишләргә исәбең аның буе белән? Кое сиртмәсенә куярга исәбең юктыр бит... Юкмы?! Шулай булгач. Нигә сиңа аның сорнай буе?! Нигә?.. Акылы булсын. Ату тапты сүз, буйчан, чибәр... Ярминкәгә чыгарырга исәбең юктыр бит үзен?..

— Һи-и, синең шул булыр инде, сөйләдең ни дә, сөйләмәдең ни син юләргә. Я, ярый, китим...

Була шундый минутлары Кадыйрның, гүя кинәт зиһене ачылып китә һәм ул, дөньяви хәлләргә хәзер генә төшенгәндәй, үткәндәге хаталары өчен уфтанып куя. Теге вакытта хәтта иң изге мәхәббәтеннән, өзелеп сөйгән кызыннан да ваз кичте. Имеш, нигә ашыгырга, моңардан гүзәлрәге очрар әле. Ә ул очрамый да очрамый икән. Очраса да ул түгел, бөтенләй башка, чит-ят ук булмаса да, күргән саен күңелне тетрәтми, җанны җылытмый. Шулай гомер уза, балаларың үсә, ә теге яшьлектәге мәхәббәтең кабатланмый да кабатланмый. Дөрес, кайчак зиһене ачылып, үткәннәргә анализ ясарга керешкәч, үз-үзенә хөкем чыгара Кадыйр. Булган-үткән мәхәббәтен уенга кайтарып, яңадан тусам алай итмәс идем дип көлә. Күңелен җылытып торган беренче мәхәббәте генә: «Нишлисең син, Кадыйр, мине югалтканың җитмәгәнме!» — дип, йөрәккә шом салып, житдирәк уйларга мәҗбүр итә.

Гадәттә, эш-хезмәт турында уйлый башладымы, Кадыйрның үткән хәлләре турындагы кысыр уйлары икенче планга күчә, алга, беренче рәткә үзенең бөтен кырыслыгы, чынлыгы, үткерлеге белән сайлаган эшенә тугрылыгы килә иде. Әмма ятманы туктатып торуга приказ яздымы, аның шәхсән язмышы шунда ук хәл ителәсен дә белә иде ул.

Кадыйр каты чәй эчте, аннары түр якка узып, креслога утырды. Шунда телефон шалтырады.

— Ә-ә, Михалыч, сәлам! — диде ул Сибирцевның таныш тавышын ишетүгә. — Юк шул әле, һичнинди хәбәр юк. Әйе, вакыт үтә... Барып кайтмыйча да булмас, әмма бушка йөрү генә булыр дип шикләнәм. Хәбәр итми калмас иде... Аның тәкъдименә яңа мәгълүматлар өстәден?.. Без көткәннән дә нәтиҗәле булачак?! Рәхмәт, шатландырдың!.. Приказ язарга да эшкә керешергә дисең... Рәтләнер?.. Ә киресенчә булса нишләрбез? Нигә шулай димме? Ә бәлкем күңелем сизәдер. Дөньяда һичкем кулланмаган ысул ич!.. Дөрес анысы, җиңүчеләрне хөкем итмиләр итүен. Ләкин килерме соң ул җиңү безгә? Аңарчы безне себереп ташламаслармы? Логика безнең якта дисең дә, тик логика бит дага түгел, аны бер теориягә таянып кына бөгеп булмый, эксперементлар үткәрә-үткәрә генә сынала инде ул логика дигәне дә, кадерлем Михалыч. Воронцов та сабыр итәргә куша шул, район комитеты исә ятманы туктатып тору турында ишетергә дә теләми...

Сибирцев белән сөйләшкәннән соң Кадыйр, креслога ята төшеп, күзен йомды, йокымсырагандай шул халәттә Зөһрә больницадан кайтканчы утырды. Ләкин бу тышкы тынычлану гына иде, тирәндә, йөрәк төрендә пыскып кына нидер көйри. Ул көйрәүнең, ниһаять, бер чиге булыр микән?..

Кеше үсә диләр, әйдә, үсә бирсен, тарсынмыйк, ахыр чиктә житәкче булып алгач, барыбер туган илгә файда китерү өчен эшләячәк ич. Инде бу юнәлештә үзен күрсәтә алмый икән, бүтәне бик тиз хәл итәлә: телиме-теләмиме, аны җиңелрәк, көче-сәләте җитәрдәйрәк эшкә күчерәләр. Әйе, түрә булган кешегә түш киереп, аяк өсте йөрү генә азрак икән шул әле, иң әүвәл ул үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен исбат итү өчен жаны-тәне белән эшләп күрсәтергә тиеш. Аннары түрә булу бар кешегә килешеп тә җитми ул. Берәүләрне ул чынлап та күтәрә, шәхес итә, ә инде икенче берәүләрне бөтенләй юкка чыгара, дәрәҗәсен югалтуга кадәр җиткерә.

Сәмигуллин больницага эшкә килгәч тә врачларның күбесе: «Кыяфәте килгән, баш врач булыр бу», — диделәр. Халык әйтсә хак әйтә бит, шулай булды да. Дөресен әйтергә кирәк, аның бу эшкә болай тиз ризалашуына аптырабрак калучылар да булмады түгел. Ләкин Сәмигуллин үзе бу турыда һичкем белән сүз куертып тормады. Берәү белән дә киңәшмәде, барысын да үзе хәл итте: «Эшлим», — диде. Дилбегәне кулга алуга, ул башы-аягы белән эшкә чумды. Баш врач булып утыруның икенче көненнән үк Гайсә кабинетына врачларны, бүлек мөдирләрен чакырып сөйләште, эш шартлары, анда булган комачаулыклар, кыенлыклар белән кызыксынды, кыскасы, беренче көннән үк үзен кайгыртучан җитәкче итеп күрсәтергә тырышты.

Бу хәл хатыны белән икесе арасында соңгы вакыттагы салкынлыкка тагын бер боз кисәге өстәде. Халисәсен ул кабинетына чакырмады, аның белән, гомумән, сөйләшмәде, киңәшмәде.

Яңа баш врачның кайгыртучанлыгы кемгә ничек тәэсир иткәндер, ә менә Валентина Петровна Гайсә янынан чыгуга Халисәгә әйтә салды:

— Менә, ичмасам, начальник дисәң дә начальник бу Гайсә Ильясович. Беләсеңме ни ди? Мин, хөрмәтлем Валентина Петровна, сезнең хәлегезгә керәм, түзегез, кеше башынаниләр төшми, ди. Минем турымда аталарча кайгырта икән бит. Җитмәсә, безнең язмышлар уртак, Валечка, икебез дә хирург, икебезнең дә... Шуннан ары бер сүз дә әйтмәде. Ни бу, Халисә? Бәлкем син беләсеңдер, ни дигән сүз бу?

Халисә, аңламаганга салышып, җилкәсен җыерды:

— Белмим шул, Валя.

— Их, Халисәкәй, Халисәкәй! Ахирәтем дип йөрим үзеңне, эчемне бушатып, серләремне сөйләгән булам үзеңә. Ә син?.. Ярый, башкаларны әйтмә дә инде, ә миннән ни яшергән буласың?! Үпкәләдем әле үзеңә. Бу ниткән сер яшерү тагын! Бөтен коллектив синең турыда сөйли, ишетмәмешкә салышуыңмы?..

— Кеше сүзе кеше үтерә, диләр, Валя. Бу көннәрдә мин шул чаклы арыйм. Нәүфәл исән-сау котылса, иңнәремнән зур йөк төшәр сыман, әгәр белсәң! Бик катлаулы безнең мөнәсәбәтләр, Валя, ни дип әйтсәм дә аңламассың кебек. Гайсә һич кенә дә аңларга теләми, көннән-көн читләшә генә барабыз. Әйтмим, яшь чакта без Нәүфәл белән бер-беребезне яратышкан идек, ләкин ул бик күптән булган хәл. Әй, шул вакытта бүгенге акылым булса икән, Валентина!

— Өзгәләнмә ул тиклем, Халисә.

— Юк-юк, хатын-кызга акыл дигән нәрсә кырыкка җиткәндә генә кирә икән ул, Валя.

— Кайберәүләргә ул кырыктан соң да керми, Халисә...

... Кичке якта эштән кайткач, Халисә аш әзерләде, әмма бер ялгызы булгангамы, әллә инде аруы җиткән идеме, бүлгән ашына калак

та тыкмыйча, залга чыкты, аякларын җыеп креслога утырды. Гайсә әле кайтып җитмәгән иде.

... Менә ничә көн инде Гайсә аңа дәшми йөри. Бергә, бер өстәл артына утырып ашамыйлар, икесе дә өйдә туры килгәндә Гайсә үз бүлмәсенә кереп китә һәм эшкә китәргә вакыт җитмичә чыкмый: укый-язамы, йоклыймы, радио тыңлыймы — билгесез. Ничәмә-ничә көн инде Халисә үзенчә яши, Гайсә үзенчә. Әлбәттә, ир кеше буларак, әдәп саклау йөзеннән, беренче булып ул сүз катарга тиеш иде. Тик ул кайтып чишенә, юына, Халисә пешергән ашны бүлеп ашый, чәй көйләп эчә, үзе ашаганнан соң савыт-сабаны юып куя да, креслода утырган Халисәне гел күрмәгәндәй, зал аша үз бүлмәсенә уза, хәтта бикләнә. Иртән чыгып юына-кырына да, әзер ашны ашап-эчеп, янә савыт-сабасын юып, ничек кайтып кергән булса, шулай ук дәшми-тынмый эшенә чыгып та китә.

Халисә дә иренең бу кыланышын гүя күрмәде, үз кайгысы үзенә бик җиткән иде. Әйдә, дәшми икән, шулай йөри бирсен, аңа гына тимәсен. Шулай дип уйласа да, Гайсәсе Нәүфәлне үлемнән алып калганнан соң Халисәнең эче поша башлады. «Ни гаебе бар соң әле аның минем алда?» — дип уйланды хатын...

Ләкин бу уе да хәленә ачыклык кертмәде.

Уйлана-уйлана утыра торгач, Халисә, үзе дә сизмәстән йокымсырап китте. Ул Гайсәне каршына килеп баскач кына күрде.

— Тиешле чиккәчә барып җиттек бугай инде. Ай була, бер өстәл янына утырып ашаганыбыз юк. Мине бүген барысы да кереп котлады, ә син кайтып киткәнсең. Начармы-яхшымы, мин синең ирең бугай бит, — ир шулай башлады сүзен, гәрчә авыр башласа да, соңыннан шактый шома, көйле сөйләп китте. Ул бер читтә торып, урындыкка барып утырды да, аякларын халат астына җыеп, креслода йомылып утырган хатынына карамый гына, телевизордан сөйләгән диктордай, тезде дә тезде. Юк, ул язмышыннан зарланмады, хәтта хатынын да хурламады, әйтерсең хатын-кызлар тугрылыгы турында аудиториядә лекция укый иде.

Хатынының һични күрмәс күзләре белән бер ноктага текәлеп, аны һич тыңламагандай утыруы Гайсәнең ачуын кабартты гына. Иренең тавышы торган саен көрәя барды. Халисә шунда гына телгә килде.

— Син бит, Гайсә, кандидатлык диссертациясе өчен шактый бай материал тупладың, аны яклау турында хыялланып йөри идең. Үз хыялыңа мине дә ышандыра алган идең. Нигә ул түрәлек сиңа, нигә алай бик тиз ризалаштың баш врач булырга?

— Мин ни теләгәнемне яхшы беләм. Анысын калдырып торыйк. Мине бүген синең миңа булган мөнәсәбәтең, тугрылыгың борчый. Кешедән яхшы түгел дип тә уйламыйсың.

— Ул — авыру, Гайсә. Ә мин — врач. Син дә врач. Аннары ул безнең яшьлек дустыбыз. Һәм ул бүген дуслар терәгенә мохтаҗ. Ә син әллә ниләр сөйлисең.

— Кайчан шулай кече җанлы, нечкә күңелле кеше булып киттең әле син, Халисә. Теге я бу сәбәпләр аркасында яшьлектә тормышка ашмаган хыяллар турында аһ-уһ килеп яшәвеңне әйтүем. Ә бит тормыш хыялга караганда күп тапкыр усалрак. Бар хыял да тормышка ашса икән ул,— Гайсә кузгалды, килеп хатынының янәшәсенә чүкте, тезләренә кулын куйды, күзләренә карады.— Син мине гафу ит, Халисә. Бәлкем мин кайбер нәрсәләрне аңлап та бетермимдер. Дөрес, авыру кешенең күңеле нечкә һәм зәгыйфь була. Тик син булмаганда минем дә күңелем зәгыйфь ич. Хәтта эшемдә дә миңа кырын карый башладылар... Миңа җиңел дисеңме?

Гайсә торып басты, кресло артына чыгып, Халисәнең иңнәренә кулларын салды. Халисә дәшмәде, башын иеп утыра бирде.

## 21

Көннәр уза торды, Кадыйрның нервысы тәмам какшады. Түземлеге бетте дигәндә, ниһаять, аңа Кудрявцев шалтыратты. Ләкин аңардан күңеленә өмет салырдай бер генә җылы сүз дә ишетмәде Кадыйр. Кудрявцев һаман нефть таләп итте.

Идарәдә күмер катламына күчү ашыгыч барса да, нефть алу көннән-көн кими, скважиналар интенсив төстә сулана иде, ягулык чыгару тәүлегенә ун мең тоннадан җиде мең тоннага төште. Бу хәлгә Воронцовның да эче поша башлады. Партком секретаре идарә начальнигы кабинетына кергә:

— Нишлибез, Кадыйр Сөнгатович? — дип сүзсез калды. Производство мәсьәләләренә килгәндә моңа кадәр тулысынча идарә начальнигына ышанган партком секретаре да, соңгы көннәрдә аерата тиз сулана барган скважиналар турында хәбәрдар булгангамы, борчылуын яшермичә, бер ара тез башын ышкыштырып утырды.—Олы максат өчен янсаң да ярый, диләр, Сөнгатович. Конфликтсыз булмас. Аннары сынаулар кала, ә теорияләр һәм идеяләр киләләр дә китәләр, диләр түгелме?..

— Мин бу мәсьәләдә министрлыкта үз фикеремене әйттем инде. Чират Берләшмәдә, Кудрявцевта, — диде Кадыйр.

— Их, сугыш тәртипләре җитми безгә! Өстеңә ажгырып танк килгәндә икеләнеп торып булмыйдыр шул.

— Куертмагыз әле ул хәтле, Владимир Поликарпович.

— Куертып торасы калмады инде, куерасы куерган. Идея теоретик яктан нигезләнгән, министрлык үзе кабул итте. Ә без ул ятмабызда сынау үткәрә алмый иза чигәбез. Югыйсә, баш геолог та, тукталып торганнан соң, ятма бермә-бер артык нефть бирәчәк дип бара.

— Ә бирә алмасак?

— Беләм, моның өчен башыбыздан сыйпамаслар. Ләкин мин сынау ягында. Олы максатка ирешүләр корбансыз булмый, Сөнгатович.

— Һәркем үз урынында җаваплы.

— Алай булгач көтик, — диде Воронцов кинаялэп. — Мин әлегә кадәр шуны төшенә алганым юк: нәрсәгә өмет тотасыз сез? Кудрявцевкамы? Ә бит ул нефть бирүче түгел, идарәләр биргән нефтьне җыючы гына. Безгә билгеләнгән план башка идарәләргә дә бирелгән. Димәк, ысулны сынау һәм сынамау мәсьәләсен тик бер үзебез хәл итәргә тиеш булабыз.

Воронцов чыгып киткәч Кадыйр үзалдына: «Приказ язгызыз, имеш. Приказны язгач, кем башы келәм өстенә очачагын белгәнгә генә әйтәсең син аны, дускаем», — дип уйланды.

...Салкынча көзге һава Әмировның зиһенен сафландыра төште. Аяк астында яңгырдан җебеп калган көзге яфраклар. Октябрь ае көчен сыный. Мәрхәмәтсез ай, бар яшеллекне рәхимсез төстә юкка чыгаручы, салкын сулышы белән һәммә үсемлекне өтеп ала торган ай. Бүген Кадыйр күңелендә дә гүя шушы октябрь көне иде.

Больница баскычларыннан ул акрын гына менде. Нәүфәл өчен абыйсының ул яткан палатага килеп керүе көтелмәгәнрәк хәл булды күрәсең, аптырап калды. Операциядән соң муены турая төшкән егетнең, абыйсын күрүгә, кәефе күтәрелеп китте.

— Утыр, абый, менә моннан, түрдән узып утыр, — дип өтәләнде ул.

— Рәхмәт. Ничек, терелеп буламы инде?

— Киләсе атнага чыгарабыз дип торалар.

— Утыр үзең дә, ник болай атлы казак кебек басып торасың? Гафу ит, янына да килә алмадым, эш тә эш. Бетәсе түгел.
— Мин белмиммени хәлеңне?! Аның каравы, җингәчәйнең киткәне дә булмады. Рәхмәт инде. Бүген әнә коймак пешереп китергән.
— Утыр әле, Нәүфәл. Киңәшкә килдем. Нишлибез? Сынауны үткәреп булмас кебек бит. Берләшмә ярдәм итми, ә бездә бернинди мөмкинлек юк. Аласы нефтьне арттыру түгел, көн саен кимetә барабыз. Ә биредә кайберәүләр ятмаларны туктатып торыйк дип теңкәгә тияләр. Приказ яз да бир, диләр. Ә бу хәл өчен абыеңның муены калса да, башы очар.
— Производствога яңалык кертү, эксперимент — ул үзенә күрә революция, абый. Революционерларча хәл итегез.
— Сиңа ансат. Беләсеңме абыең шушы идарәдә күпме эшли?
— Беләм. Шуңа әйтәм дә. Сибирцев риза. Ул хәтта цикл арасын кимегергә була дип бара. Дәлилләре ышанычлы. Мин дә килештем.
— Ни генә булмасын, Берләшмәдән «добро» алмыйча, мин бу эшкә керешә алмыйм.
— Ун көн, бары тик ун көн. Ә бит соңыннан нефть алу егерме процентка кадәр артачак.
— Ә артмаса? Артмаса нишләтерләр абыеңны. Уйлыйсыңмы син бераз шуны, юкмы? — дип ярым тавышка кычкыра Кадыйр.
— Прогрессив алымнарны кыю рәвештә производствога керткән җитәкче мактауга гына лаек.
— Кызма әле. Утыр. Бу бит сиңа чәч кырку түгел. Бер хакыйкать бар. Прогрессив ысул өстәмә чыгымнарсыз производствога кертелгәндә генә экономистлар бездәйләрне гафу итәләр.
— Ләкин бит соңыннан артык нефть алыначак.
— Менә шунысы шиклерәк шул әле, туганкаем.
Кайтырга чыккач Кадыйр: «Аңа ансат, барысы да, сөйләшеп куйгандай, приказ язарга кушалар», — дип уйлады. Машинасын ул җибәргән иде инде. Бөтен шәһәр буйлап җәяү атлады. — Әйе, аларга ансат. Ә җавапны бер миңа бирәсе».
Инде эңгер иңеп килә, әле бер тәрәзәдә, әле икенчесендә балкып утлар кабына. Һәр тәрәзәдә тормыш, үзенә бер дөнья. Шуларның берсендә булса да аңардагы кайгы бармы икән? Юктыр.
Төньяк тарафта күк йөзе аяза башлады, гүя бер сылу шәмәхә иңдергән күз кабакларын акрын гына ача иде, офыкта кызның зәңгәр күзләре. Офык чите ачыла башлауга, көнбатышка алсу пәрдә эленде һәм ул кызыл әләмдәй җилфердәп тора башлады, ул да түгел, көнчыгыш яклап беренче йолдызлар кабынды. Шул йолдызларны вәземләп санаган кеше бар микән? Егет кеше сөйгәнен исенә төшергән саен йолдыз атыла диләр бит. Моны аңа Наташа әйткән иде. Яшь чакта, Уралда практика үткәндә, караңгы төндә, инрә-иңне куеп инеш буенда утырганда... Я хода, бу балалар тагын каян табышканнар. Әллә соң Наташа белән минем арадагы ялганып та, әлегә кадәр өзелеп тә җитмәгән мәхәббәт җебебезне шушы балалар мәхәббәте аша бәйләргә булдымы бу гыйшык алласы? Минем әле булса Наташаны яратуыма инанып: «Сүнмәс-сүрелмәс мәхәббәтегез балаларыгызга күчсен», — дидеме әллә ул?..
— Озак йөрисең, атасы. Гөлүсә кайтты. Унсигез яшем тулуга ЗАГСка гариза бирәбез, ди. Зинһар, гайрәтеп чигермә, ата була күр. Ул синнән ризалык алырга кайткан.
— Куйчы, үгетләмә. Риза дидем бит инде. Үзе ничек тели, шулай эшләсен.
Түргә узды. Гөлүсә диванда утыра, китап укый, аякларын халат астына җыйган.
— Исәнме, кызым.

— Әйбәт кенә әле, әтием.

Кадыйр ары сугылды, бире сугылды да йокы булмасенә узды.

— Урын җәйсәң икән, Зөһрә.

— Шулай иртәме? Ашамадың да?..

— Тамак тук минем. Берәр йокы даруың-фәләнең юкмы?

— Булыр. Нишләвең бу? Чирләмәгәнсеңдер бит?

— Юк. Арыдым. Бир әле даруыңны.

Дару эчкәннән соң Кадыйрның тел төбендә сәер тәм калды. Ләкин юкка эчте ул даруны — барыбер йоклый алмады. Эч пошу беткән кебек булды, тик күңелгә һаман тынычлык килми. Кемдер аңа әйткән иде: «Кеше эшләп арымый, эшли белмәүдән арый», — дигән иде. Хак әйткән, эшли белмәгән кеше ял да итә белми. Әллә соң һавага чыгып керәсеме? Бу Гөлүсә тагын... Яңа укырга керде, нигә ашыгырга. Их, бала-бала...

Торып киенде дә, алгы якка чыкты. Гөлүсә һаман китап укый. Сәгать төнге унберне сугып ята.

— Гөлүсә, син дә йокламыйсың икән. Әйдә чыгып бераз йөреп керик. Әниең яттымы?

— Ятты, — диде кыз һәм дәшми-тынмый гына киенде, сизелер-сизелмәс кенә әтисенә сирпеп караштыргалады.

Урам тын иде. Күк йөзе чалт аяз. Айлы төн — аязу билгесе. Күк йөзен урталай ярып киек каз юлы сузылып ята. Кадыйр Гөлүсә белән янәшә атлый. Дәшми. Ә һавада ай, йолдызлар, киек каз юлы.

— Әтием, беркөнне Наталья Ивановна синең хакта сөйләде...

— Биш ел бергә укыдык, сөйләр нәрсәләр бардыр, — диде Кадыйр, гамьсез калырга тырышып.

— Әти, сез чынлап та бер-бергезне яраткан идегезме?

«Кирәкмәс иде, нигә кирәк иде балаларга сөйләргә. Сер итеп сакларга ярамый идеме? Мин бит менә саклыйм, сакладым», — дип, эченнән Наташага үпкәсен белдерде Кадыйр.

— Яратышкач, нигә соң кавышмадыгыз, әтием?

— Язмыш. Ул теләмәде. Сережаның булачак әтисен сайлады. Үзенә ахыр чиктә егетләр түгел, кызлар парны сайлый, кызым.

— Беренче мәхәббәт онытылмый, диләр. Син аны әле дә яратасыңмы, әтием?

Кадыйр бастырылып-саташып яткан җирдән уянып киткән кешедәй хис итте үзен. Мөлдерәп торган тулы айдан асфальт юл өстенә көмеш нурлар коела, яфраклары сирәгәеп калган тротуар буендагы агач башларыннан җил йөгереп уза, Гөлүсә үземе сөйли, тыкылдап барган туфли үкчәләреме тирә-юнь белән сөйләшә. «Нигә инде балаларга сөйләргә иде, — дип һаман нәүмизләнүен белде Кадыйр. — Яраттым, яратам дидем, диям, әле тагын әйтермен. Ә син ул турыда балаларга сөйлисең. Кешенең иң кадерле, иң изге серен ачасың».

— Яшьлектә ялгышулар, алданулар була ул. Ә чын мәхәббәт сынала-сынала гына ныгый, кызым. Без әниең белән әйбәт гомер иттек. Ярату яшьлектә үзенә бер төрле, ә олыгайгач үзенә бер төрле була. Сезнең мәхәббәткә дә күп сынаулар үтәсе бар әле. Гомер буена шулай ал да гөл булыр дип уйласаң ялгышуың ихтимал. Ә Наталья Ивановна... Ул да, бәлкем, башта бик яраткандыр да бит... Шуңа күрә әйтәм, кызым, ашыкма, өлгерерсең әле.

— Ярый, әтием, мин аны сынап карармын, — дип көлә-көлә, Гөлүсә әтисенең беләгенә килеп сарылды.

— Син шаркылдама әле алай. Ярый, сез бер-берегезне яратасыз ди. Өйләнешүгә кадәр килеп җиттегез менә. Шулай да минем күңелдә бер шик йөри: гаилә тормышы сезгә гүя курчак уены. Сережаны

гына алыйк. Гаилә кадәр гаилә корырлык ирме соң әле ул? Кем исәбенә яши? Әти-әнисе исәбенә. Үзе эшләп, үзе тир түгеп тапкан ние бар? «Ява» мотоциклында җил куа. Кем акчасына алган? Әтисенекенә. Я, гаилә кордыгыз, ди, һаман шулар исәбенә яшәрсезме? Кая аның егетлеге. Бер мәхәббәт белән генә дөнья көтеп булмый, кызым. Ышан, бу минем генә сүзем түгел. Тормыш сынавын җиңә алган кеше генә хатын-кыз өчен чын мәгънәсендә ир-канат була ала. Шунда гына ике йөрәк мәхәббәте чын һәм саф була. Сезнең гыйшык әле, кызым, сабын куыгы гына ул. Беренче кыенлык килү белән юкка чыгуы бар.

Гөлүсә әтисенең кулыннан тартты — бу аның туктап тор дигәне иде.

— Ә хәзер нишләргә тиеш инде мин? Миңа үнсигез тула, гариза яздык. Син дә риза булган идең.

— Әниең шулай теләде. Әниең дә гомере буе балда-майда йөзгән кеше. Нужада яшәмәде, авырлык кичермәде.

— Алай булгач, мин аңа утлар-сулар гизеп, карурманнар кичеп, таулар кисеп, дию пәрие патшалыгыннан мине табып алсаң гына синеке булам дип әйтәм, — диде Гөлүсә, күләргә тырышты, әмма кисәк тынып калды, ә күзләрендә ай нурлары җемелдәп куйды. Шуннан ул. — әйдә, кайтыйк инде, әтием, — диде.

— Ярый. Бар, син кер. Мин идарәгә барып килəм.

Каравылчы Кадыйрга ишекне көттереп кенә ачты, картның йокыдан күзләре чекерәйгән, уянып җитмәгән идеме, ишекнең келәсен алуга сукрана башлады.

— Йөрисез шунда...— диде, мәгәр Кадыйрны таныды булса кирәк, күзләре түгәрәкләнде, карт солдатларга хас җитезлек белән тураеп басты.

— Йокы туймадымы әллә, бабай? Янбашыңа тоз төшәр дип тә курыкмыйсың үзең.

— Һәй, туганый, Кадыйрҗан, синмени әле бу, танымый торам тагын. Ни, теге, Меженков шулай төнлә килеп кергәли торган ие. Кабинетына керәдер ие дә, диванда бөкшәеп йоклый торган ие. Хатын янына кайтасы килми ди торган ие, ахыр тәмам бизде бит җанашыннан. Барыбер китте энә. Ир-атны бәйләп тотып булмый шул.

— Их, бабай, күпне беләсең дә соң үзең. Кабыз әле утларыңны.

«Нинди диван ул тагын, кем куйдырган?» — дип уйлады Кадыйр икенче каттагы кабинетына күтәрелгәндә.

— Иртән бик иртә уятыймы?

— Мин йокларга дип килмәдем, бабай.

— Ярый соң, бигайбә алсаң. Эшләргә килдең була инде болай булгач...

Ниткән хәл бу: үз-үзенә урын тапмыйча изалана. Нигә батыраеп кына керешә алмый. Күңелдәге бу шикне ни белән юарга, нәрсәгә таянып ныклы бер фикергә килергә?..

Нәүфәл хәзерләгән технологик документларны өстәлләргә җәеп салды һәм янә һәр битне карап чыкты Кадыйр. Ятма 1957 елда бораулалнып бетте, 1958 елда үзе үк ятмадагы скважиналарның куелыгын бермә-бер киметергә тәкъдим бирде. Әмировның тәкъдимен теләми генә кабул иткән берләшмә, идарә шул күләмдәге нефтьне тапшыруын дәвам иткәч, бу ысулны калган идарәләргә дә шулай эшләргә кушты. Элек егерме гектарга бер скважина утыртылса, Кадыйр тәкъдименнән соң, хәтта яңа ачылган ятмаларга да кырык гектарга бер скважина куя башладылар. Бер бораулаган скважина дәүләткә биш мең сумга төшүен исәпкә алсак, шактый файда китерерлек тәкъдим иде, югыйсә. Тик нефть өлкәсендә баш ватучы галимнәрнең кайсысынадыр бу тәкъдим ошамаган һәм ул (Кадыйр ул галимнең хәтта фамилиясен исенә



Милли электрон китапханә · Хәтер ярлары

төшерергә дә теләмәде) һәр ятма үзенә бер организм дип, Кадыйрның тәкъдимен бик үк юкка чыгара алмаса да, нык кына суытты. Ә ул биргән тәкъдимне кулланган җирдә кулландылар, кулланмаган җирдә юк. «Ярый, анысы үткән хәл. Менә хәзер ятма сунүгә таба йөз тота, елына 80—90 метр тизлек белән хәрәкәт иткән су һәм нефть контакты ятманың үзәк өлешенә житеп килә. Бу хәлдә, ятма инде соңгы сулышын алып ятканда, аны файдаланудан туктатып торудан нефть чыгару артырмы? Арткан хәлдә ни исәбенә артырга тиеш? Нәүфәл төрле төбәкләрдә бүленеп-тыгылып калган ком-алевролитлы токымнардан алыначак ул нефть дип бара. Шуны фәнни яктан исбат итәргә маташа, баш геолог Сибирцев аны яклый, хәер, мин дә яклыйм, тик план дип кенә бугазга басмасыннар иде. Әйе, бер уйлаганда ун көн эчендә барысы хәл ителәчәк, нибарысы ун көн. Аннары — я идарә, я промысел. Әллә соң барысына да кул селтәп килешергәме? Бүгенге көнгә ятмадан проектта каралган нефть запасының илле процент тирәсе алынды ич инде. Шул җитмәгәнме? Кай илдә, нинди ятмадан шуннан артык нефть запасын чыгара алганнары бар әле?! Юк, тиз генә булмас та. Виталий әйткән яңа оешучы идарәгә китеп барсам?..»

Кадыйрның тәмам башы катты. Өстәлгә башын салды да, ниһаять, күзләрен йомды.

...Иртән аны чынлап та каравылчы уятты.

— Кадыйр туган, тор инде, техничкалар килә башлар, — дия-дия түргә үтте, өстәл өсләре тулы кәгазьләргә карап тел шартлатып алды. — Һай, эшегезне дә әйтер идем инде, туганый.

Уянуга, ул үзенең кайда икәнен абайламый торды, кичә кичтән эчкән йокы даруы үзенекен иткән бит, уйланып кына ятам дигән җирдән йокыга ук киткән ләбаса.

— Уятуың өчен рәхмәт, бабай.

— Меженков кеше-мазар килгәнче чыгып китә торган иде. Әллә мәйтәм, туганый, син дә аның көненә калдыңмы. Күңел бит ул, хатын-кыз аздырам дисә безнең халыкны аздыра да аздыра инде. Күз —маржа, күңел — дәрья диләр.

— Их, бабай, бар иде ул безнең дә яшь чаклар, саламнан тәртә каерып чикерткә җиккән чаклар. Беләсезме, бабай, сезгә кем булырга калган?

— Буласын булдым инде мин... Кем итәр идең?

— Артист.

— Әртист үк! Булмас ла, — карт сакалынаябышып бер тын көлемсерәп торды. — Нибуч анда миннән кәмитрәкләр дә бардыр.

— Синдәй юктыр, күргәнем булмады.

— Анысы хак. Карчык булып карчык, мәрхүмә, печән базары кәмите булма әле дип орыша торган иде.

— Бер ялгызың калдың инде алай булгач?

— Хак, туганый. Көтмәде, мәрхүмә, ашыкты. Ату, гелән бергә барырбыз, Хикмәтулла, дип әйтә торган иде. Ул анда хур кызы инде. Эштән кайтуга, гелән күгәрчендәй гөрләп каршы алыр иде. Хөрт минем эшләр хәзер, Кадыйрҗан туганый. Тигез яшәүләргә житми икән ул...

— Ә син бер дуадак карчык тап. Синдәй телеңә җор кошы төкергән картка кем килмәс.

— Соң инде, туганый.Карчыгым көтә. Гомер иткән кешең онытылмый икән ул...

Кайтырга чыгып үз урамына борылуга, Кадыйр каршысына килүче Зөһрәне күрде.

— Ни булды сиңа, Кадыйр! Кая югалдың?!

— Идарәдә. Эш чыкты.
— Я ходаем, куркуларым. Гөлүсәсе телен йоткан көенчә дәшмитынмый Әлмәткә китеп барды, монысы идарәдә йоклап ята.
— Ярар инде.
— Виталий Семенович шалтыратты, — диде Зөһрә.
Кадыйр дәшмәде. Атлавын белде. Сөйләшми генә өйгә керделәр. Зөһрәнең иреннәре дага рәвешле ишелеп төшкән керфекләрендә яшь бөртекләре. Хатынының күзендә яшь күрү Кадыйрга кыен иде. Ул аны үз гомеренә кызганды һәм инанды: кызгану белән дә кешене яратып була икән.
Кадыйр бер телем ипигә май якты, әмма кабарга онытып, тау ягыннан чыгып килгән кояшка карап тора башлады. Нур өстенә нур өеп, тирә-юньгә көлтә-көлтә көмеш җепләр бөркеп кояш чыгып килә. Дингез буенда шулай бер тапкыр кояш чыкканны күзәткән иде ул. Иртә иде әле, коенучылар бармак белән генә санарлык. Зөһрә йоклап калды, ә төнозын Наташа турында уйланып яткан Кадыйр диңгез ягына атлады. Су өстендә вак-вак дулкыннар йөгерешә, алар яр читенә җитәләр дә, шаярышкан сыман, төрле төстәге чуер ташлар өстенә үрлиләр, — әйтерсең су кызы бармаклары белән мәрмәр ташларны капшый, ир-ярны шулай сөя, ярата сыман. Менә диңгез өстенә кояш нурлары төшә, аның нур көлтәсе зур магистральгә охшап офык читеннән яр буена таба да сузылып ята. Шунда, шул мәлдә нәкъ шул көлтә яткан төштән, су кызыдай булып, Наташа килеп чыкты. Хатынның шоколад төсенә кергән тәнендә энҗеләр җемелди, ярга таба чыга башлауга, сылу гәүдәсе очып китәргә җыенган алиһә сурәтенә керде һәм шунда хатын яр читендә басып торучы Кадыйрны күрде. Күрде дә ни әйтергә белми бер мизгелгә аптырап калды. Кадыйр әгәр скульптор булса, Наташа туктаган мизгелне, ихтимал, таш сында мәңгеләштерер иде. Хатын бик тиз исенә килде, ул үз итеп, бераз кылана төшеп елмайды, аннары башын чайкап алды, сары резин башлыгын салды. Аның иңнәренә сибелеп төшкән аксыл-сары чәчләрендә кояш нурлары чагылды. Кадыйр күзләрен йомды, бу күренеш чын түгел кебек иде аңа, төшендә генә күрә сыман тоелды.
— Тилекәй, шулай сөзеп карама, күз тидерерсең...
Кадыйр аңа җавап бирмәде, хатынга таба атлады һәм, килә-килүгә, кулына күтәреп алды да диңгез эченә кереп китте. Күп еллар элек булгандагы кебек, Наташа үзе дә, ир-егетнең тәвәккәллегенә буйсынып, муенына сарылды.
— Төшер, Кадыйр, — диде хатын бил тиңентен диңгезгә керүгә. — Ишетәсеңме, җибәр, Зөһрә күрсә ни әйтер?..
— Я, аша инде, нинди мәрткә китү тагын ул, — диде Зөһрә, иренең кулына ипи тоткан килеш уйланып утыруын күреп.
Кадыйр, гаепле кеше сыман, дерт итеп китте, нишләп утыруына яңа гына төшенгәндәй, кулындагы май яккан ипигә карады.
— Гөлүсә өчен борчылма, — диде аннары ни әйтергә белми аптыраудан. — Кояш кебек әйләнер дә кайтыр. Сыналыр чагы. Сынала-сынала ныгый кеше. Ныгысын. Тормыш әле аны болай гына сынамас. Дөрес, бераүләргә ул сынау гел дә килмәскә мөмкин, андыйлар су агымына эләксәләр агалар да агалар, менә синең белән безнең кебек. Ә аның алай агасы килми, күрәсең.
— Акыл сатып утырма әле. Алдына куйганны аша да эшеңә ашык. Виталий Семенович шалтыратты дидем түгелме үзеңә. Тикмәгә булмас, Кама буендагы яңа корылып яткан идарәгә-фәлән күчерергә исәбе бардыр. Гөлүсә өчен эчең тырналмасын, машинаң бир дә Әлмәткә үзем барып кайтам.

— Машина ватык.
— Алайса, автобус белән китәм.
— Бара күр...

## 22

Таныш, бик күптәннән таныш йөз, таныш күзләр, таныш елмаю, бит очларындагы таныш уентыклар, гомер буена гел аның турында гына уйлангангамы, әллә кайчан үз булып беткән гәүдә-сын ул — Халисә. Әйе, гүя ун елдан артык гомер узмаган да, гүя яңа танышып йөргән яшь чаклары. Күңелдә шундый хис булгангамы йөрәк ярсына, кемдер, каядыр әйди сыман. Күз алдында якты нурлар уйный, шул вакытта аның янына Халисә килеп баса. Күрде дә Нәүфәл көткән кешесен таң калды: шул ук елмаю, шул ук чалымнар, шул ук караш. Егетнең уе-хыялы, тормыш куанычы, илһамчысы, үкенүле яшьлек мәхәббәте, шатлыгы, бәхете — һәммәсе ул Халисә. Килгән тәки, димәк, ул да аның өчен борчылган, аның турында уйлаган, тизрәк сәламәтләнүен теләгән.

Менә ул бер кәлимә сүз дәшмәстән Нәүфәлнең маңгаена дару исе килеп торган йомшак кулын салды. Егетнең йөрәге кысылды, күзләрен ачарга коты алынып ятты. Түзмәде, маңгай өстендәге кулны кысып тотты. Хатын-кыз кулы, уч төбенә эләккән нәни җәнлектәй, кемнәндер ярдәм-шәфкать сорады, аны җибәрүләрен үтенде, тыпырчынды, чәбәләнде, ахыр, бу теләгенә ирешә алмавына инанды булса кирәк, тынып калды.

Нәүфәл кулны кайнар иреннәренә китерде, уч төбен, аннары һәр бармак битен үбеп чыкты һәм, нәүмизләнеп, әсир төшкән кулны яңагына кысты. Сөйләгәннәре бар иде Нәүфәлгә саф мәхәббәттә иң әүвәл йөрәкләр аваз сала дип, аннары күзләр сөйләшә, шуннан соң гына хисләр телгә күчә дип. Нәүфәл аның сөюен йөрәк тибешеннән тойды.

— Халисә, — диде ул, пышылдап кына. — Рәхмәт сиңа, меңмең рәхмәт, килүең өчен, керүең өчен...

— Җибәр, Нәүфәл, сиңа сөйләшергә дә, дулкынланырга да ярамый. Ишетәсеңме, Нәүфәл...

Нәүфәл күзләрен ача һәм янә аның йөзен күрә, тик ул аңа хәзер томан эчендә кебек, күзләрендә әллә яшь, әллә яктылык шулай чагыла.

— Син елыйсың, Халисә?

— Йокла, Нәүфәл. Мин китим, — диде Халисә һәм иелеп Нәүфәлнең битеннән үбеп алды. Егетнең бит очына кайнар яшь бөртеге тамды. — Йокла...

Нәүфәлнең тел очында әйтелмәгән сүз эленеп калды, бер мәлгә ул үзен очып-очып та әле булса җиргә төшеп җитә алмаган көзге яфрак, яисә яр буена дулкын чыгарып ташлаган маймыч хәлендә хис итте. Аның йомшак, ягымлы итеп әйткән бәрхет тавышы йөрәккә сары май булып ятты. Күңелгә янә бер яшерен сер өстәлде, ул сер болай да ярсу йөрәкне җилкендерә, ул шундый саф, чишмә суы диярсең, чылтырчылтыр килеп ага — янә очрашу өмете бөтен җан-тәнен били. Әйе, ул аның бәхете, өмете, ул аның өчен изгеләрнең изгесе, яшәү өчен ышаныч, шул ук вакытта ул аңа әле булса табышмак. Моңа кадәр ул тормышын хыял белән генә баета ала иде, хәзер ул аны, гомер буена эзләгән кешесен тапты. Тапты!

Нәүфәл эченнән очынып ярсынды, нәүмизләнеп китте, кипшеренгән иреннәрен ялады һәм аваз салып:

— Таптым! — диде.

Күрше караваттагы бабай аңа сәерсенеп карап алды, әмма сүз катмады, стена ягына таба әйләнеп ятты.

Шул көннән алып Нәүфәл аны һәр көнне көтте, ә ул исә ике-өч көнгә бер генә, анда да бик боек, моңсу кыяфәттә килеп керде. Шундый көннәрдә ул аз сөйләште, җәүһәр сулы тоньк күзләрен почмакка текәп, уйга калгалады, аннары, сәбәп табып, чыгып китү ягын карады. Нәүфәл моны, әлбәттә, аңлый иде. Бу көннәрдә, мөгаен, Халисә, дә, ташу суына эләккән йомычкадай, кай ярларга чыгып ятарга белми каңгырып йөридер. Ул ир хатыны. Нәүфәлнең аны яратырга хакы булса да, үз янына чакырып алырга кыймады. Шуңа карамастан, Халисә палатага килеп керүгә ул кояшка баккан көнбагыш чәчкәседәй аңа тартылды, ачыктан-ачык булмаса да, әле булса тәүгечә яратуын сиздерде. Аның бу кыланышына Халисә ни әйтергә белми кисәк аптырап калгалады: «Юк, кирәкмәс», — дигән сыман башын чайкады. Әмма Нәүфәлнең үз туксаны туксан иде, гүя ул хатынның кинаяләрен аңламады да, аңларга да теләмәде.

Әйе, Халисәгә ир ташлаулары җиңел булмаячагын Нәүфәл бик яхшы белә иде, ләкин үзе белән һични кыла алмады, күңеле-йөрәге белән аңа тартылды.

Әйтәсе дә юк, хатын-кызга ир ташлау тел белән әйтеп бирә алмаслык эчке конфликт ул; аның ир ташлау конфликтына берничә ирнең язмышы сыя алыр иде, мөгаен. Ни генә булмасын, хатын-кыз алдына бу мәсьәлә килеп баса икән, иртәме-соңмы ул иренә: «Мин синнән китәм», — дип әйтергә мәҗбүр. Дөрес, кайчак бу сүзләрне уенын-чынын кушып әйтеп ташлаучылар да була, чөнки гаилә булгач, савыт-саба шалтырамый тормый, әмма бу сүзләр төбендә хет мыскал гына хакыйкать булдымы, җәнҗалның аерылышуга хәтле житүен көт тә тор. Мондый авыр хәлне бар кеше дә салкын канлылык белән генә уздырып җибәрә алмый. Китүче хатын да, каласы ир дә гаять дәрәҗәдә вөҗдан газабы кичерәләр. Шушы әрнүле ачы хакыйкать йөрәктә тирән, мәңге җуелмас эз калдыра. Китә үч алулар, судтан-судка йөрүләр, ике якның икесе дә бер-берсенә торган саен нәфрәтләнә, усаллана баралар. Юк, җиңел түгел, җиңел булмады ир ташлаулары хатын-кызга, җиңел бумас та. Әйе, үзе эчке газап кичерү генә житмәгән, моның янына аны бу хәле өчен үзе эшләгән коллективында хөкем итәләр, «әдәпсез» хатынны бик рәхәтләнеп акылга утыртучылар табыла. Аннары икенче ягы да бар бит әле. Ярый инде шушы кимсетүләрне, кичерә-кичерә сайлаган яңа кешең соңыннан синең кадереңне белсә... Ә белмәсә, синең теләкләрең белән исәпләшмәсә?! Ә бердәнбер көнне онытылып китеп: «Кеше калдыгы», — дип, җаныңа ут салса? Ә бит дөнья булгач, шул хәлнең дә булып куюы ихтималы бар.

Тук-тук, тук-тук, тук-тук... Йөрәк тибә. Юк, йөрәк түгел икән, коридордагы аяк тавышлары шулай ишетелә. Әллә соң «ул» киләме. Шулай дип уйлауга, әлеге ритм тагын тизләнә: тук-тук-тук, тук-тук-тук...

Нәүфәл чарасызлыктан караватына торып утырды. Ишектә сестра күренде.

— Әмиров, уколга! — дип боерды ул һәм борылып китеп тә барды.

Укол кадаганда сестра аңа:

— Соңгы уколыңны алдың, Әмиров. Җитте. Моннан соң үзең ашап түл җый, — диде. — Әпетитым юк дисәң, һавага чыгып йөр. Утырма караватыңда көннәр буе. Бу палатадан икенче картны операциягә салалар инде, ә син һаман рәтләнә алмыйсың...

Сәгать уннарда палатага Валентина Петровна керде.

— Хәерле иртә, Әмиров!

— Иртәсе хәерле, Валентина Петровна. Кайчан чыгарасың инде мине моннан?

— Киләсе атнага дип торабыз. Хәлегез ничек соң, муен бик борчымыймы?..

— Хет штангы күтәр, Валентина Петровна. Менә уйлап утырам әле,ниләр генә биреп котылып булыр микән дип сездән. Муенымны турайттыгыз. Әле булса күңел ышанмый, уянып киткән саен капшап карыйм. Көлмәгез. Сез минем өчен хәзер илаһи җан, Валентина Петровна. Беләсезме, сез кем? Сез — фәрештә. Исән булсам, бирөдән чыгуга, мин сезгә һәйкәл куячакмын. Начальник булуым белән, әлбәттә.

— Берәрсенә гашыйк булмагансыздыр бит, Әмиров? Безнең кызлар мут.

— Больницадан чыгуга ук өйләнәм, Валентина Петровна. Менә ничек шатландырдыгыз сез мине. Бирегез әле шул алтын кулларыгызны. — Ул хирургның кулларыннан алды, үпте. Ул куллардан эфир, ниндидер дару исләре килә иде. — Татлы, йомшак куллар, сихергә ия куллар, — диде егет тәүге үҗәтлеге белән сөйләвен дәвам итә-итә, анлары кинәт: — Гафу итегез, Валентина Петровна, терелү бәхетеннән бу...

— Сез, Әмиров, гаҗәп кызык кеше икәнсез, — хирург хатын каш астыннан гына хәйләкәр елмаеп куйды һәм кузгала башлап: — Болай булса, мин сезне тагын бер ун көн яткырам. Миңа мондый татлы сүзләрне ишетү бик рәхәт.

— Сез беләсезме кем, Валентина Петровна? Сез изге җан, сез борынгы грекларның мәхәббәт алласы. Менә сез кем, кадерле Валентина Петровна!

— Юк, Әмиров, кабат әйтәм, мин сезне тагын бер ун көн яткырам. Сез шагыйрь икәнсез бит. Я-я, сәламәтләнегез.

...Икенче көнне ул бик иртә уянды. Валентина Петровна китүгә, янына Сибирцев килгән иде, аның белән бик озак сөйләшеп утырдылар. Сибирцев абыйсының тиз арада приказ язуын үтенә. Баш геологның болай конкрет төстә таләп итүе Нәүфәлгә ошады, Кадыйр абыйсы килгәч, ул үзе дә аңа шундыйрак сорауны биргән иде, ләкин тегесе нигәдер кистереп җавап бирмәде. Ә баш геолог төпле дәлилләр китерде, катламнан циклап файдалану мәсьәләсендә ул срокны кыскартырга була дип исбат итәргә тырышты. Нәүфәл аның дәлилләре белән килеште һәм Сибирцевка хөрмәте нәкъ менә шул минуттан бермә-бер артты. Үзең уйлап тапкан һәм күңелең шуңа тәмам ышанган идеяне башка берәүнең яклап чыгуы, хәтта аны камилләштерү йөзеннән өстәмә тәкъдим кертүе ихтирамга лаек булмаслык та түгел иде. Тәкъдимнең нидән гыйбарәт икәнен аңлау белән Нәүфәл Сибирцев китергән формулалар, саннар, исәпләүләр эченә кереп чумды. Хәйран калырлык иде шул: Сибирцев аның идеясенең эченә үтеп керә алган һәм уңай якка төпле тәкъдимнәр китергән.

Нәүфәл баш геологның бөтен кәгазьләрен алып калды һәм иртәнге караңгыда ук торып шулар белән утырды. Сибирцев тәкъдиме аның фикерен тагы да ныгыта төште. Таң ата башлагач, Нәүфәл коридорга чыкты, йокымсырап утырган няня яныннан шыпырт кына узып, тышкы ишекне ачты. Октябрьның иртәнге салкынча һавасы яңа гына ярасы җөйләнгән муенны көйдереп алгандай итте. Нәүфәл йомшак сөлгене муенына урап бәйләде, халатына төренә төште. Октябрь төне агачларга чигү чиккән, урман өсте — келәм, тротуарда — палас, тау, күк йөзе, хәтта таң атуга агарынып калган ай кыйпылчыгы да күгел-

җем томан эчендә тулгана, тик кояш чыгышында гына аксыл-сары чаршау эленгән. Аяк астындагы төрле төстәге яфракларда кырау бизәкләре төшкән япма. Больница койкасыннан ук башланган урман өстендә «андромеда томанлыгы». Урман эченә килеп керүгә кушкаенга тап булды. Табигатьнең нинди кылануыдыр, ике каен арасына бер яшь имән килеп кысылган, каеннар күптән инде яфракларын койганнар, имән исә тәкәббер рәвештә яфракларын саклап утыра. Дөрес, яфраклар саргайган, төссезләнгән, димәк, горурлык та инде вакытлыча гына. Килер салкын кыш, имәннең дә яфракларын рәхимсез өчыртып алып китәр. Нәүфәлгә моңсу булып китте. Менә ике көн була инде аның Халисәне күргәне юк. Нигә килми, ник күренми? Әллә соң Гайсә аны-моны сизендеме?.. Ул бит тормыштагы һәммә нәрсәне бераз рәсмиләштерүчән кеше. Нәүфәл хәтеренә аның яшьлек иптәше нәкъ менә шул ягы белән сеңеп калган иде. Андый кешедән нечкә хисләр эзләмә. Гүзәллекне дә ул үзенчәрәк күрә. Ә бит гүзәллекне күрә белү ул матди дөньяны танып-белү дигән сүз. Гүзәллек ул — сәнгать. Сәнгать исә матурлык, нәфислек. Гүзәллекне күрә белү, аңа бәһа бирә белү, кешене кеше итүче сыйфатларның иң камиле, иң зарури булгандыр, мөгаен.

Нәүфәл больницага кайтып акрын гына икенче катка күтәрелде. «Ни өчен мин Халисәне генә битәрлим әле, ник үзем аның янына бармаска? Бүген ул дежур тора. Менә хәзер эгәр?..» — дип уйлады Нәүфәл һәм, үзе дә сизмәстән, өченче катка күтәрелә башлады.

Больницада беркайчан да тыныч булмый. Бервдә һәр чак кемдер ыңгыраша, кемдер саташа, кемдер авыртынуга түзә алмыйча кычкырып куя. Ләкин шифаханәдә гадәттән тыш тыныч чаклар да булгалый. Бүген шундый көн иде. Өченче катка менүгә Нәүфәл, йөрәк тибүен тоеп, туктап калды. Әле бик иртә булу сәбәпле, озын коридорның түр ягына өстәлгә башын салып сестра черем итә. Төш күрә, ахрысы,— әле йокы аралаш елмая, әле кашларын җыерып куя, әле иреннәрен кыймылдата. Шуннан аяк очларына баса-баса гына үтеп, Нәүфәл ары атлады — врачлар булмәсенең ишеген сак кына ачты. Өстәл. Ак башлык кигән берәү шуңа башын салган. Иртәнге йокы төнге йокыдан күп тапкыр татлырак була, диләр. Егетнең йөрәгә дерт итеп китте. Башлык астыннан бөселеп чыккан чәчләр, баш астына салган кул аныкы иде. Нәүфәл өстәл кырына килеп басты. Йөрәге тагын ашкынып тибә башлагач, бер мәлгә ни кылырга белми аптырап калды. Кичәгенәк, көтмәгәндә аның белән бер палатада ятучы карт ана: «Яратасың. Ә ул ирдә бит. Юк димә, күрәм ич, аллага шөкер, сукыр түгелмен. Ярый, яраткан өчен төрмә юк»,— дигән иде.

Менә Нәүфәл артык дулкынланудан калтыранган бармаклары белән хатынның башлык астыннан чыккан чәчләрен рәтләштерә, юк, бармаклары йомшак чәчләргә тимәде дә бугай, шулай тоелды гына.

— Халисә,— дип пышылдады иреннәре. Юк, тавышы бөтенләй чыкмады, идәнгә төшеп, каядыр почмакка кереп сеңде, ачык форточкадан очып чыгып китте.

Коридорда аяк тавышлары ишетелде. Нәүфәл тагын аяк очларына гына басып, ашыга-ашыга икенче катка төште, палатасына кереп караватына утырды. Күрше карт йоклый иде әле.

«Нигә мин аны уятмадым, йөрәгем тулы татлы сүзләремне әйтәлмәдем? Нигә болай кыюсыз, ник шундый мин?»

— Түз,— диде шунда күрше караваттагы карт күзләрен ачып.— Түз, егет. Синдә да килер ул мәхәббәт. Килә ул, исән-имин яшәгән таза кешеләрдән берәүне дә читләтеп үткәне юк әле аның.

— Ә син йокла, йокла, бабакай. Операциягә диделәр түгелме үзенә...

— Язмыштан узмыш юк, энем. Әнә син ирдәге бер затка күз атасың, ул да янына керә-чыга йөри. Ә нигә бу? Гаилә ныклыгын дәүләтебез үз канаты астына алганга ярты гасырдан артык вакыт үтте түгелме?

Тыңлады да Нәүфәл картны, тыңламады да. «Әйе, ул ирдәге хатын, аның үз дөньясы дөнья...»

...Больницадан чыгасы көннең иртәсендә Нәүфәл яткан палатага Валентина Петровна обход башлануга ук керде. Нәүфәлгә ул аеруча сөйкемле, мөлаем һәм шат күренде, шул ук вакытта хирург хатынның йөзендә нинди дер борчылу да бар иде. Өстендә гадәттәгечә ак халат, куллары кесәләрендә, ак калфагы астыннан коңгырт чәч тәлгәшләре чыккан, халат изүеннән ирләрнекечә тегелгән кофта якасы күренә. Ә йөзендә...

— Менә, Әмиров, шатлыклы минутлар да үтүчән икән бит, дускай. Сезгә дә чыгар вакыт житте. Тотасы иде дә бит, юк, булмый бит, шуа да чыга кулдан — ефәк тасма кебек икән ул шатлык дигәнең. Белмим, ни хикмәттер, Әмиров, сез мин көткәннән дә тиз терелдегез. Күрәм, бүген кәефегез дә әйбәт. Тик бер киңәшем бар сезгә: авыр эшкә жигелергә ашыкмагыз.

— Әйләнә-тирәдә хәзер көз көннәре түгел шикелле миңа, Валентина Петровна, яз көннәре сыман, билләһи менә. Күңел ярсына хәтта.

Аларның сөйләшүләренә көнләшепме, күрше караваттагы карт тамак кырып куйды. Ул соңгы көннәрдә нигәдер сөйләшми башлады, әллә инде хәленең хөртлегеп белеп, күзләрен гел бер ноктага текәп ята бирә. Валентина Петровна аның хәл-әхвәлен сораша башласа да, авыру карт ләм-мим әйтмәде, врач та тегеңә бары артык борчылмаска кушып чыгып китте. Икәү генә калгач, Нәүфәл:

— Ә син курыкма, бабакай, бу хатын кулларында мең чиргә шифа бар. Курыкма, барысы да әйбәт булыр... — дип, картны юатты.

Карт шуннан соң да дәшмәде, юрган астыннан кулын чыгарды да имән бармагын гына кыймылдатып, егетне үз янына дәшеп алды.

— Кайсысы синеке, кайсысын ныграк яратасың?

Картның тел төбен шунда ук абайлап алган Нәүфәл ирен чите белән генә елмаеп куйды.

— Болай шаяртыр рәтең булгач, яшисең әле син, картлач. Кайсысын ярату мәсьәләсенә килгәндә, мин аларның икесен дә яратам. Берсен кешелеклелеге өчен, икенчесен... икенчесен... мин аны яшьтән үк ярата идем, карт төлкем.

— Бу мәсьәлә синең дә телеңә күчә башлаган икән. Минем күптән күчте инде ул. Өйлән, вакыты узып китүе бар, бер уздымы, телгә күчә ул, каһәр төшкере нәмәстә, аннан харап, ир түгел син, гайбәтче, — диде карт һәм, сүзе бетүен аңлатып, стена ягына таба әйләнеп ятты.

«Беренчедән, — диде Нәүфәл үз-үзенә, — мин аның күзенә карап бер уемны да әйтә алмаячакмын, икенчедән, мин аны күрергә телим дә, теләмим дә шикелле түгелме? Ярый, күрдем, ди, каршына килеп утырдым, ди, шуннан ни әйтермен? Мин сине яратам, әйдә, Халисә минем белән Бөгелмәгә, мине институтка эшкә чакыралар диярменме? Ә ул шаркылдап көлеп жибәрсә? Юк инде, мин аңа алай дип әйтә алмыйм. Мин аңа хат язам, әйе, ни барысы хат».

Кулына кәгазь-каләм алды, тик ак биткә хәрефләр төшмәде. Ни турында язарга тиеш соң ул аңа? Ахыр чиктә тәвәккәлләде. Рухи көчсезлеге өчен ул үз-үзен битәрләргә кереште. Күңеле нечкәреп, гажиз-

ләнеп китте, моңа кадәр булып торган борчулар, аны көтеп зарыгулар, күңелдәге шик-шөбһәләр кинәт юкка чыкты.

«Халисә, багучылар баккан язмышларга мин ышанмыйм, ышанмадым да. Әмма унҗиде яшемнән алып, бүгенге көнгә кадәр эш ыгы-зыгыларыннан бушаган вакытларда күңелемдә һәр чак сез булдыгыз. Больницага яткач, мин яткан палатага кергәләп, хәлемне белгәләп йөрүегез өчен мең-мең рәхмәт. Сезнең бу адымыгыз миндәй сырхауга зур каһарманлык булып тоелды. Бала чагымда миңа әнием еш кына Сак белән Сок бәетен җырлый торган иде. Ул кошларның кавыша алмавына мин ышанмый идем. Чөнки безне мәктәптә алай тәрбияләмәделәр. Ничек инде канатлары булган кошлар кавыша алмасыннар, ди. Әйе, тәрбия бездә башкарак шул. Баксаң, Сак белән Соклар безнең арада да барлар икән бит. Гафу итегез, гел юк нәрсә турында язам бугай. Мин, Халисә, сезне күптән гафу иттем инде. Гомер буена романтик мәхәббәтем белән тагын бер очрашу хыялында яшәдем. Әлбәттә, мин сезне гомьсез бер көндәмлек белән ир колы булып яшәүче хатыннар рәтенә кертергә теләмим. Шул ук вакытта мөлаем-шук мизгелгә ышанып, кемгә дә булса няреп кай тарафлардадыр чыгып китә алуыгызга да ышанмыйм. Рационалистлар заманы килә. Шуңа карамастан, кайчак сайланган кешең белән бергә тора алмас хәлләргә каласың. Бер-ике көннән мин Бөгелмә фәнни-тикшерену институтына эшкә китәм. Нинди дә булса әйтер сүзләрегез бар икән, мин сезне кичке сәгать җиделәрдә Кыңгыраулы алан каршындагы асфальт юлда көтәрмен. Килмәсәгез, бәхетле булыгыз!

Нәүфәл».

Врач Сәмигуллинага бирерсез дип, больницадан чыкканда Нәүфәл зәңгәр конвертка салган хатны ишек янында торучы апага бирде.

— Бирермен, бирермен, улым. Ул бүген дежурга килә, — диде карчык.

«Без мәхәббәт кадерен яшьтән үк белә алмадык, мәхәббәтебез алдында баш иярга теләмәдек. Бу — хакыйть. Икенче тапкыр аерылышуыбызның төп сәбәбе шул гына. Хәрәкәт көче каршылык көченә һәр вакыт тәңгәл килде», — дип уйлады Нәүфәл, больница ишеге алдыннан чыгып барганда.

Шулай да өметен өзеп бетерүе түгел иде әле бу, әмма больницада ятканда Халисә керә йөргән көннәрдәге канатлар юк иде инде. «Сак белән Сок» кошлар булмаганнар шул. Ни сәбәпледер яшьлектә кавыша алмаган ике гашыйк булган һәм халык шуңа багышлап бәет чыгарган. Мәңгелек бәет, мәңгелек проблема.

## 23

Берләшмә аны борчымады, нәкъ менә шул хәл Кадыйрның нервысын талкыды. Кудрявцев — менә кем кирәк иде аңа бүген. Юкса ул берничә көннән, нервы авыруы алып, больницага ятачак. Аның чарасызланып уйлануларын белгән кебек, төштән соң Кудрявцев шалтыратты.

«Ниһаять, — диде Кадыйр сабыры төкәнүен тоеп. — Ниһаять».

— Тыңлыйм. Әйе, мин, Кадыйр. Кем килә? Наташа! Виталий, бу ни инде тагын?! Ник үзең дә килмисең? Эшең күп дип... Берләшмәнең геология бүлеге начальнигы нигә килә соң?.. Килгәч белермен дисеңме...

Трубканы куйгач та Кадыйр бер тын кулын телефон трубкасыннан ала алмый торды. Бу шалтыратуны бик тә, бик тә көткән иде ул.

ләкин сөйләшү килеп чыкмады. Димәк, аңа бөтен булган яңалыкны Наташа китерәчәк, Наташа җиткерәчәк.

Кадыйр урамга чыкты, җәяү китте. Октябрь аеның суык эңгере сыек томан алып төшкән. Өй тәрәзәләренең барысында да ут балкый. Кадыйр алма агачлары арасына юнәлде. Зөһрәнең атна-ун көн саен өй җыештыра торган гадәте бар иде, инде ул шуңа керештеме, өйгә кайтып кермә — һәммә нәрсәнең асты-өскә килгән булыр. Өйдә шул хәлдер дип уйлап, Кадыйр сәгать чамасы алмагачлар арасында йөргәнды.

«Ник Виталий үзе түгел, ә Наташа килә икән? — дип уйланды ул әле дә булса күңеле тынычлана алмаудан гаҗизләнә барып. — Ник килә икән тагын бу Наташа?»

Сүнеп барган ятма белән эш итүче җитәкченең батыруы авыр булмас. Кудрявцев һичшиксез нык кул белән эш итә. Ул Кадыйрның һични кыла алмавына әллә кайчан инанган инде. Чынлап та, ни кыра ала хәзер Кадыйр? Идарәне промысел итсәгез итәрсез, мин биредә калам, дип әйтүен көтәме әллә бу Кудрявцев? Гади инженер булыпмы?.. Зөһрә ничек пырлар, Наташа ни уйлар? Хупларлармы аның бу каһарманлануын? Аның бу адымын эшчеләр ничек аңлар? Әллә соң барысына да кул селтәп Кама буйларына китеп барыргамы? Елгасы ни тора, яшәү урыны. Башлап җибәрүләре җиңел булмас булуын. Шулай да гади инженер булып бирегә калуга караганда...

Соңгы көннәрдә Кадыйр Кудрявцев тәкъдиме белән килешү хисе тәэсирендә яши башлады. Күңел көннән-көн күндәмләнә бара иде. Хәер, аның канында түгелме бу күндәмлек? Болай уйлануы, сөйләнүе үз дәрәҗәсен төшермәскә тырышудан гына түгелме?.. Чынлап та шулай түгелме соң!.. Әлбәттә, Берләшмәнең геология бүлегендә Наташа утырмыйча, башка берәү утырса ни әйтергә белер иде ул. Бәлкем әле Виталий тәкъдименә дә риза булыр иде. Әмма бу хәлдә... Аннары ул гына да түгел. Юк! Аңарда да ихтыяр көче бар, замандашларына әйтер сүзен әйтер ул. Әйтер!

Тәрәзә ягына күз ташлап, хатынының болгануын күрмәгәч, Кадыйр ишеккә юнәлде. Зөһрә аны яшьле күзләре белән коридорга чыгып каршы алды.

— Нигә болай барча бүлмәләрдә утлар яна?

— Куркам, куркам, Кадыйр, — диде хатыны һәм, яңадан сүз әйтә алмаудан гаҗизләнә барып, ни кылырга белми түр якка кереп китте.

— Ни булды сиңа, нинди чебен тешләде тагын? — дия-дия аның артыннан атлады Кадыйр.

— Гөлүсә Түмәнгә киткән, — диде Зөһрә башын да бормыйча. — Әллә булмаса син берәр нәрсә әйттеңме үзенә?

— Китсә кайтыр, — дип, Кадыйр кухня ягына таба борылган иде, Зөһрә аның алдына ук чыгып басты.

— Сережасы үз-үзенә урын таба алмый. Наталья Ивановна, Виталий Семенович аптыраудалар. Бу ни инде тагын?!

— Нигә киткән? Әнисе буларак сиңа да әйтмәдемени?..

— Әнә хаты. Анда да әйтмәгән.

— Мин белмим. Һәрхәлдә, аңа баш алып чыгып кит дип әйтмәдем... Бәлкем дөрес эшләгәндер.

— Ни сөйләгән буласың тагын, Кадыйр. Әллә уйнаштан туган баламы ул сиңа, бәгырьсез ир!?

— Куйчы. Кайтыр. Бәлки Сережага кәҗәләгәндер бераз. Үтәр. Менә күрерсең, әйләнер дә кайтыр.

Кадыйр өстәл янына утырды, аш көтеп тора башлады. Зөһрә һаман тынычлана алмады, бу хәлдә кемне гаепләргә белмәүдән гаҗизләнә иде хатын.

— Бер-бер нәмәрсә әйттеңме әллә дим? Ник дәшмисең?..

— Йөрер-йөрер дә кайтыр дим ич инде. Нужа күреп үскән кызың түгел, юкка хафаланма.— Кадыйр канаты сынган коштай йөрүче хатынына карамаска тырышты. Кыен иде аңа. Гөлүсәнең китеп баруына бетереп үзен гаепләмәсә дә, күңел түрендә ят бер нәрсә тырманды, түзмәде, ашавыннан туктап, түр якка чыкты, кызының кош теле хәтле генә кәгазьгә язган хат кисәген алып килде һәм нигәдер кычкырып укып чыкты.

«Әти-әни, мин дөнья гизеп, бераз эшләп кайтырга булдым. Үпкәләмәгез. Түзәр әмәлләрем калмаса кайтырмын. Гөлүсә».

— Әнә бит, үзе дә кайтырмын, дигән. Юкка күзләреңне бетермә,— диде Кадыйр, хатынын тынычландырырга тырышудан битәр үзен акларга теләп. — Сережа белән боткалары пешмәде микән әллә?

— Сережасының күзләренә ак-кара күренми. Эзләргә чыгып китәм дип өзгәләнә, бичаракаем. Аңа да рәтле сүз әйтмәгән.

— Иртәгә Наташа килә, — диде Виталий. — Мин тагын аны эш мәсьәләсендә килә дип торам, ә ул әнә ничек икән әле.

...Наташа сәгать уникеләргә генә килеп төште. Кадыйр аны Зөһрә янына өйгә кайтыр дип уйлаган иде, Берләшмәнең геология бүлеге начальнигы туры аның кабинетына килеп кергәч, аптырабрак калды. Наташаның өстендә күн тужурка, башында да шундый ук күн берет. Чын геолог кыяфәте. Наташа һични булмагандай шаулапгөрләп түргә узды, Кадыйрга үз итеп кулын суузды. Кадыйр аның кулын бер тын җибәрми торды, күзләренә бакты һәм шундук сиздегамьсез күренергә тырышуы гына, күз төпләренә хәтле сагыш җыерчыклары өелгән.

— Утырырга да мөмкин булырмы?

— Әлбәттә, әлбәттә!

— Менә хәл-әхвәлләрегезне белергә килдем. Ни җимертеп ятасыз?

— Эшләр шәптән түгел, Наташа. Белмиме, белеп сорыйсыңмы?..

— Юк, мин дә белеп бетермим, Кадыйр. Хәер, белеп бетермәм дә кебек, — диде геолог хатын һәм утырган урыныннан кинәт күтәрелеп ятма картасы янына узды. — Миңа баш геологың кирәк. Аның белән бөтен ятманы йөреп чыгарга тиешмен.

— Берләшмәдән нинди дә булса задание алып килүең түгелдер бит? Идарәне ябарга, промысел итеп кенә калдырыргамы?

— Ятманы янә бер җентекләп тикшерергә исәп. Яңа техника кайтты. Идел-Урал районындагы төрле стратиграфик горизонтларда калдык-постык нефть объектлары барлыгы күптән билгеле булса да, вакыт тимәдеме, техника җитмәдеме шунда, шуларны яңабаштан барларга кирәк. Сиңа мәгълүм булырга тиеш, соңгы елларда Күмер-Пермь катламнары эшкәртелә башлады. Нефтьнең бер катламнан икенчесенә, аннан өченчесенә күчү мөмкинлеге бар. Шуңа ревизия үткәрергә булдык. Бу эшне уңышлы башкарып чыгу өчен импульс-нейтронлы разведка куллану камилрәк булыр дип таптык. Бөтенсоюз техник бораулау фәнни-тикшеренү институты галимнәре катламда яшеренеп калган нефть «күлләрен» алып бетерү нияте белән «тамырлы скважина» дигән ысул тәкъдим итәләр. Бу ысул ятмада калган ягулыкны алып бетерүгә үк китермәсә дә, шактый өстәмә нефть алуга ярдәм итәчәк. Йоклаган ятмаларны уятырга вакыт җитте, Кадыйр. Кереш шуңа беренче булып?

— Берсен хәл итмәгән, икенчесенә керешергәме?

— Беләм, яңалыкка юл яру җиңел булмас. Яткан таш астында су акмый. Ярый, ул турыда җитеп торыр. Кил әле, утыр әле, янәшәмә, сүзем бар сиңа.

— Ышанасыңмы, Наташа, соңгы мәлдә биредә үземне читтән күзәтүче бераү итеп сизә башладым.

Кадыйр кузгалмый торгач, Наташа үзе аның янәшәсенә килеп утырды. Кадыйрның борын яфракларына затлы хушбуй исе килеп бәрелде.

— Кадыйр әйт әле, Гөлүсә кая китте? — Зинһар мине гафу итә күр, Сережаны шулай яратмавы булдымы Гөлүсәнең?

— Без барыбыз да, Наташа, кешенең иң газиз серләренә хәтле белергә телибез. Әмма бу хәл үзебезгә кагылганда, нигәдер хәтта булган серләребезне дә тирәнгәрәк яшерергә тырышабыз. Исеңдәме... Ни сөйләп утырам тагын, минем әллә кайчан булып үткән мәхәббәтемә мохтаҗмы ул хәзер, дигән сүзләр?

— Исемдә, Кадыйр, барысы да исемдә. Тик берүк калдырчы ул турыда. Без — без инде, ул вакыттагы гаепләрне нигә ачыклап маташырга, моннан ни үзгәрер... Их, Кадыйр, Кадыйр, мин үкенеп куймыйммы кайчак...

Әйе, мәрхәмәт һәм шәфкать көткән зәңгәр күзләр үзенә карап тормаса ниләр әйтеп ташлар иде микән бу хатынга Кадыйр. Белмимени ул Кадыйрның әле булса шул күзләрне өзелеп-өзелеп яратуын?! Белә. Бик әйбәт белә. Юри кыерсыта, үткән эшкә салават дип юри әйтә. Ә бит, җаным, кайчандыр син дә мине шулай ташлап чыгып киткән идең...

— Кайтыр ул, Наташа.

— Какма мине, Кадыйр. Каксаң без барысын да югалтырбыз. Миңа кайчак бу дөньяда бер шул балалар һәм синең өчен генә яшим кебек тоела. Хәер, син аны үзең дә беләсең. Хак булды, без кавыша алмадык, һич югы, ул бәхеткә балаларыбыз ирешсен иде дип яши идем. Шуңа куанып, шуңа өметләнеп...

— Кирәкмәс, Наташа. Нигә инде безгә хәзер театр сәхнәләрендә генә әйтелә торган төче сүзләр. Сиңа ни бирә дә ул сүзләр, миңа ни куаныч китерә. Мин бит бик әйбәт беләм, сине Гөлүсәнең китеп баруы борчый. Кемнең горурлыгына кагылды кызның бу тапкырлыгы, егетнеңме, белмим. Ә мине, Наташа, гомер буена синең миңа булган мөнәсәбәтең борчыды.

— Юк-юк, Кадыйр, зинһар алай дип әйтә күрмә.

— Куйчы. Кешелек кайчан да булса ирләрен өзелеп сөярдәй дару табар микән бу хатыннарга. Табар микән?! Юктыр, тапмастыр. Виталий белән гомерен уздырып бара, мине ярата, минем өчен генә яши, имеш.

— Кадыйр! Туктал. Юкса мин шушы минуттан сиңа мәңгегә хөрмәтемне югалтачакмын, мәңгегә, ишетәсеңме, мәңгегә?!..

Кадыйр, башын иеп, бер тын дәшми утырды, аннары Наташаның кулларыннан сак кына алды.

— Бу дөньяда синнән якын кешем юк минем, Наташа. Син һәр чак куанычым булдың. Бәлкем Сережа аңа саксызрак бер-бер сүз әйткәндер. Кайтыр ул, Наташа, яратса, үпкәсе тиз сүрелер. Мин дә бит сине гомерем буена кичерә кием. Ә, бәлкем, киресенчә, артык өзелеп ярат канга китеп баргандыр. Үз-үзен сынау өчен. Бер шагыйрь әйткән бугай: «Кыска гомерле изгелек — шул ук яманлык ул», — дип. Кайтыр ул, кайтмаса, Сережасы эзләп табар...

— Сережа соңгы курста укый, мөмкин хәлме?

— Яратса бик мөмкин хәл.

Тел очына нинди сүз килгәндер — Наташа әйтмәде, күн беретына йөзен төртте, елмайды да кебек, сулкылдамады да, бары тик тар иңбашлары гына калтырап торды. Кадыйр аның калтыранган иңбашына авыр кулын салды, аннары ике кулы белән иңнәреннән кысып тотты да күзләренә карады.

— Елама, Наташа. Кайтыр ул...

Наташа бер мизгелгә Кадыйр күкрәгенә башын төртергә ымсынган кебек булды, әмма икенче мәлдә инде торды да сумкасыннан кулъяу-

лык чыгарды, бер читкәрәк китеп, күзләрен сөрткәләде. Аннары Кадыйр каршына килеп басты да:

— Тап кызыңны, Кадыйр, Сережа өчен түгел, минем өчен тап, — диде.

Кеше акылының фикерләү мөмкинлеген үлчи торган прибор булса һәм шушындый хәлләрдә аның ни теләгәнен үлчәсәң, мөгаен, котың алыныр иде, вакыт-вакыт без бөтенләй баш югалтырдай эшләр эшләп ташларга әзер булабыз икән бит.

— Гөлүсә үзе кайтырга теләрме икән соң?.. Миңа калса, Сережа аның кай тарафларга чыгып киткәнен беләдер. Андый хатаны без үзебез дә ясадык түгелме, шул җитмәгәнме, Наташа?!

— Сезгә кунарга бармыйм. Бара алмыйм, гафу ит. Урнаштыр мине гостиницага. Кичен күрешербез, тагын сөйләшәсем бар... Ә хәзер миңа Сибирцев кирәк. РИТС[1] ларны йөреп чыгар. Идарәнне промысел итеп калдырырга чынлап җыеналар.

Кадыйр дәшмәде, өстәл янына үтеп, Сибирцевны чакыртты.

... Кич кайтып ашагач, Кадыйр янә идарәгә барам дип җыена башлады, телевизордан дәвамлы кино карау дәрте белән һәммәсен онытып җибәргән Зөһрә аның сүзләрен ишеттеме-юкмы, дәшмәде. Урамга чыккач Кадыйр тирән итеп сулыш алды, көзге салкынча һава үпкәнең һәр куышына тулып, сеңеп калганчы бер урында торды. Күк йөзе тулы йолдызлар җемелди, атылалар — кемнеңдер йөрәгенә юл сызып төшәләр иде. «Егет сөйгән кызын исенә төшергән саен йолдыз атыла», — дип елмаеп куйды Кадыйр.

Урам тулы яшьләр шаулаша, җырлый, чыр-чу килә. Кич җиттеме, һәр көн шулай, элек алар арасында Гөлүсә дә була иде, Әлмәт егете белән йөри башлауга, урам егетләре кыздан шундук читләштеләр. Тротуар буйлап утыртылган юкәләр дә йолдызлар шыбырдап тулган күккә төбәлгәннәр, яшел-сары, кызыл-күк яфракларын койгач, алар да шыксызланып калган. Ул да түгел, кайсыдыр форточкасын ачып җибәрде һәм урамга: «Ой вы, кони, мои кони» дигән җыр чыкты. Кадыйр гостиницага таба китте. Аның йөрәге: «Мәхәббәт алласы юк диләр, бар икән ул, бар. Бу дөньяда могҗизалар булмый диләр. Наташаның аны чакыруы могҗиза түгелме!» дип юкка кинәнә иде.

Ишек янында торган хатын аңа сораулы караш ташлады.

— Мин Кудрявцева янына.

— Рәхим итегез, ул сул яктагы унынчы люкста. Яңа гына кайтып керде.

Белсәң икән бу адәми затның эч серләрен: ник бераүгә тартыла икән дә, ник икенче бераүдән ничек котылырга белми иза чигә микән бу күңел дигәнең? Сөйгән кеше хәтта үзе дә әйтә алмыйдыр моның нигә шулай булуын. Чөнки йөрәккә йөгән киертеп булмый, ул һәр нәрсәдән өстен, һәр әсирлектән азат.

Тук-тук китереп ишек шакылды.

— Әйе, рәхим итегез.

Бусаганы атлап керүгә, Кадыйрның исе-акылы китте. Наташа моннан күп еллар электәге кебек алсу йон күлмәктән иде. Бәйрәм саен институтка шул күлмәген киеп килә торган иде Мәскәү кызы Наташа Жукова. Бүген аның өстендә нәкъ шул күлмәк түгелдер, мәгәр шул булмаса да, Кадыйр өчен бик тә, бик тә якын күренде хатын. Чәчләре күпертелгән, кыйгач кашлары дугаланып киткән.

— Әйдә, өстеңне сал да, түрдән уз! Гостиницагыз пөхтә икән, гел өйдәге кебек хис итәм үземне.

— Наташа, бәлкем кая таба булса чыгып керербез.

[1] РИТС — район инженер-техник службасы.

— Әйдә ресторанга. Бармы монда ресторан? Шулай булгач?! Исеңдәме...

«Истә булмыймы соң, сораган була тагын».

— Әйдә, — диде Кадыйр бераз көттеребрәк. — Сибирцев белән ничек йөреп кайттыгыз?

— Сибирцевың синең хыялый кеше, акыллы, — диде Наташа, җыена башлап. — Ул кая эшләсә дә югалмас. Синең энең идеясен яклый, ниндидер өстәмә тәкъдимнәр дә керткән икән. Сезнең ятмага импульс-нейтронлы өстәмә разведка үткәрергә рөхсәт бирдек дигәч, гел күзләре янды. Күкерт кислотасы белән өстәмә нефть алуга керешүе, ләкин тау инспекциясенең моңа каршы булуы, ә аның бу адымын синең хуплавың турында кайнарланып сөйләде. Туктале, — дип кинәт Кадыйрның терсәгеннән алды Наташа. — Зөһрә кая? Нигә аны да алып килмәдең?

— Эштә ул, дежурда, — дип, Наташаны үз гомерендә беренче тапкыр алдады Кадыйр һәм шуңамы бурлаттай бүртенеп чыкты. Наташа аның бу халәтен күрсә дә, күрмәмешкә салышты.

— Синең белән ресторанга кереп утыру минем гомерлек хыялым иде, — диде Наташа урамга чыгып янәшәдән атлап киткәч.

— Кызганыч, Зөһрә генә эштә, өчәүләп утырыр идек.

Аскы якта өс киемнәрен биреп биркалар алдылар, Наташа биркасын Кадыйрның уч төбенә салды.

Алар кереп утыруга, өстәл янына официант егет килеп басты, тышына чәчкәләр төшерелгән меню бирде.

— Нәрсә эчәбез?

— Үзең сайла, татарлар аш-суга остарак, — диде Наташа.

Түр яктагы нәни сәхнәдә өч-дүрт егет нидер уйнарга җыена, берсе тырышып-тырышып электрогитарасын көйли. Официант егет килеп заказ алып китте, бераздан өстәл түренә бер шешә шампан килеп утырды, Кадыйр шампанны бокалларга койды.

— Сине бирелә танымыйлармы соң, Кадыйр?

— Танысалар ни?

— Идарә начальнигы. Ят хатын белән ресторанда... Зөһрә ишетсә?..

— Кодагыймы син миңа, юкмы?

— Син телисеңме соң аның шулай булуын, Кадыйр?!

— Телим дә, теләмим дә, Наташа.

— Ә мин телим. Кавышсалар, ичмасам балаларыбыз сөешеп туймаслар иде. Хәерле булсын, ул бәхетне татырга насыйп булмады.

— Кем гаепле соң моңа?!

— Ярый, Кадыйр, калдырыйк. Беләсең килсә, мин дә, син дә...

Шампанны әз-әз генә итеп йота-йота эчтеләр, оркестр вальс уйнауга кереште. Бер төркем яшьләр иренеп кенә биергә төштеләр, Кадыйр өстәл астыннан Наташаның аягына басты.

— Әйдә бер бөтерелеп киләбез, Наташа.

— Их, Кадыйр, Кадыйр. Мин тиле чакта шулай бер ресторанга чакырган булсаң икән ул. Я, ярый, әйдә...

— Наташа, Наташа, — Кадыйрның тәмам тыны кысылды, шундый үз, таныш, якын иде хатынның күз карашы, хәтта бер мәлгә әйтер сүз таба алмый йөдәде. — Син һаман гүзәлсең. Күзләреңдә йолдызлар җемелди, йолдызлар...

— Тиле дә инде үзең, Кадыйр. Гүзәл булгач, ниемә теге вакытта ук Казаныңа алып китмәдең. Хәзер... Юк инде, юк. Зинһар гадирәк булчы.

— Теләсәң ни әйт, сине әле дә булса яратуым хак. Иң авыр вакытларда күз алдыма киләсең дә басасың, шуннан күңелләрем тынычланып китә. Әйт әле, Наташа, алла хакы өчен, чынын гына әйт әле, нигә без

бергә була алмадык, кем комачаулады. Виталий түгел бит, әйт әле, түгел бит?!

— Кадыйр, мин ул вакытта зур шәһәр кызы идем. Сиңа идеме соң минем ни теләгәнемне аңларга?! Зур шәһәрләрдә яшәгән, шау-шуда үскән кызлар рационалист булалар. Дөрес, алар өчен саф мәхәббәт тә ят түгел, күп рәхәтлекләрдән дә авыз итәселәре килә. Кызыктыручылар күп була зур шәһәрдә үскән кызларны, Кадыйр.

— Сәбәбе бер ул гына да булмагандыр. Ярый, үткән эшкә салават. Хәзер әйт әле миңа, Наташа, бирегә бер шул Гөлүсә өчен генә килдеңме?

— Юк, Кадыйр, синең өчен дә. Әйдә әле утырыйк, — алар өстәл янына килеп утырдылар, табынга китерелгән ризык-нигъмәтләрне капкалап алдылар. — Берләшмәдә зур үзгәрешләр булырга тора, Кадыйр. Шефны Мәскәүгә министрлыкка алалар.

— Берләшмә башына Виталийны куярга җыенмыйлардыр бит?

— Белмим, аның кандидатурасы да күрсәтелгән бугай, — Наташаның бүген эш турында сөйләшәсе килми иде, шампан эчеп алганнан соң аның күзләре тагы да зәңгәрләнә төшкән сыман, елтырыйлар, елмаялар иде. — Әйдә, яшьләр белән биеп киләбез.

Яңача биергә керешеп, яшьләр арасында тулгандылар, икесенең дә бит очлары алсуланды, бик тиз хәлләре бетте.

— Тынычрак итеп биеп булмый микәнни бу көйгә.

— Уф, тәмам арыдым. Рәхмәт, рәхмәт, Кадыйр. Кайчан тагын шулай биер идек.

— Туйда.

— Туйда! — Наташа аңа сәерсенеп карап алды. — Алып кит әле син мине моннан, Кадыйр. Җәһәннәмнең үзенә алып кит, ризамын...

Баш түбәсенә йолдызлар коела, аяк астында сары яфраклар кыштырдый, тротуар буйлап тезелеп киткән фонарьлардан көмеш сукмаклар сузылып ятхан.

— Минем нигәдер елыйсым килә, Кадыйр. Әйдә кәрәбез...

Ишек янында утырган хатын алар артыннан кызыксынып карап калды, Кадыйр аңа әйләнеп нидер әйтергә теләгән иде, ни өчендер тыелды.

Керделәр. Наташа ут алды. Янә аны яшьлектәге күлмәгендә күрүгә, Кадыйрның эче жу итеп китте. Була шундый эссе, җылы җәй көннәре, кичкә таба офык читенә өер-өер болытлар бөяләә, кояш баеганнан соң офык чите алсулана, ул төс торган саен куера барып, тоташ кызылга маныла, ә бераздан, күктә ай калыккач, сөйләп тә, язып та бирә алмастай мең төрле төскә керә офык. Шундый кичләрдә, күк капусы ачылгандай, кинәт аҗаган уйнап ала, ниндидер бер мизгелгә бөтен тирә-юньне яктырып китә, йөрәккә шом сала. Аҗаган уйнаганда кыз сөйгән егетенең горур йөзен күреп кала, кызның күңеле йомшара, күндәмләнә, назга сусый һәм ул егетенең кочагына иңә баруын сизми дә кала. Егет аның чәченнән сыйпый, аҗаган уйнаган төннәрдә кызларның чәчләреннән көмеш чаткылар сибелә, алсу иреннәренә татлы бал төшә. Бу төннәрдә кызларның күзләре зурая, кара таплары белән күзен иңли, аҗаган уены аларның йөрәкләрен ярсыта, күңелләрен котырта, кагыл аның шул вакытта иңнәренә сибелеп төшкән чәчләренә — яшен исе килә башлый. Тәмам ярсый, иләсләнә егет шул искә һәм түзәр әмәлләре калмагач, сөйгәненең кулыннан ала да чәчәк исе килеп торган болынга таба алып китә, кинәт кенә күндәмләнеп калган кыз һичбер сүз әйтми, буйсына егеткә, дәшми, аларның йөрәкләре генә сөйләшә бу минутларда.

Кадыйр авылда туып үсте. Ни сәбәптәндер нәкъ менә шушы минутта Кадыйрның күз алдына аның туган авылы килде. Гүя ул Наташаның кулыннан алган да болынга әйди, ә офыкта бертуктаусыз аҗаган

уйный, Наташаның иңнәренә сибелеп төшкән чәчләреннән чаткылар сибелә...

«... Кадыйр, безгә соңыннан бик-бик оят булыр. Безнең балаларыбыз бер-берсен яраталар...» — ди кебек аңа Наташа.

Наташа аның чынлап та куенынан сыдырылып чыга, тәрәзә каршына барып баса, тaң гөленең тычкан колагы хәтле генә яфракларын сыйпаштыра. Хатын баядан бирле шул таң гөле янында басып тора, ә Кадыйр креслода утыра...

— Наташа, гафу ит, син хаклы, балалар хакы бар...

Кадыйр тәрәзә каршында басып торучы Наташа янына килде, хатын аның яңагыннан сөйде, үз итеп, якын итеп сөйде. Наташа кулыннан таң гөле исе килә иде.

— Ә син сөйлә, Кадыйр, сөйлә, шулай җиңелрәк була ул...

— Мин китим инде, Наташа, Зөһрә югалткандыр. Тыныч йокы сиңа.

## 24

Зөһрә аны боек кына каршылады.

— Нәүфәл Бөгелмәгә күчеп китте. Институтка эшкә чакырганнар,— диде ул һәм, кәефе юклыгын сиздереп, янәдән бер кәлимә сүз дәшмичә эчке бүлмәгә кереп китте.

Кадыйр аңардан: «Ни өчен миңа әйтмичә китте тагын?» — дип тә сорамады, йокы бүлмәсенә узды. Аның бүген берәү белән дә сөйләшәсе килми иде.

Икенче көнне бик иртә, көтмәгәндә Наташа килеп керде. Яңа гына уянып киткән Кадыйр ике хатын — булачак кодачаларның аңгәмәсен теләр-теләмәс кенә тыңлап ята. Әмма үзе турында сүз чыккач, терсәгенә таянып күтәрелә төште, колакларын торгызды.

— Виталий миңа дигән урын тәкъдим итте, Зөһрәкәем, юк кына бит, риза түгел. Ичмасам син әйтеп кара әле үзенә. Ир — баш булса, хатын — муен диләр бит,— дип сөйләнде хатыннарга хас бераз ясалмалырак тавыш белән Наташа. — Энесе дә киткән икән инде.

— Әйтмәгән кая инде. Тыңлыймы соң ул ташбаш изге сүзне. Тискәре бит ул, Наташа. Әллә соң чыгып китәм дип куркытыйммы үзен? Ниндидер ысул, өстәмә нефть кирәк аңа. Ә хатыны, кызы? Миһербансыз, шул гына.

Наташа нигәдер дәшмәде. Әңгәмә Гөлүсәгә күчте һәм хатыннар кухня ягына кереп киттеләр.

Кадыйр сак кына торды да одеколон белән генә битен сөрткәләштереп алды, киенде һәм шулай ук сак кына өйдән чыгып китте.

Каравылчы карт аңа ишекне бик тиз ачты. Таныды да, шунда ук телгә килде.

— Иртәләдең бу арада, туганый. Һаман дөнья куабыз диген, әй!

— Куабыз. Тик куып җиткән нәрсәләр азаеп бара кебек.

— Ә син кизәнеп кенә калма, сук, өздереп сук. Ике уйлаган бер отар, бер уйлаган өч отар ди иде минем әткәй мәрхүм. Йөргән таш шомара бит ул, беркөн шулай синең энең килеп керде. «Ач!» — ди бу. Ачтым. «Абый мондамы?» — ди. Юк, дим. Борылды да чыгып китте. Тәвәккәл күренә ул энең. Тәвәккәл ир — ил баласы, йомакай ир — йорт танасы ди торган иде мәрхүм әткәй.

Кадыйр дәшмәде, икенче катка, кабинетына күтәрелә башлады. Нигәдер картның соңгы сүзе колак яфрагына эләгеп, бер мәл яңгырап торды. «Тәвәккәл ир — ил баласы»...

Өстәл янында ул бераз тынычлана төште. «Ярый, приказны яздым, ди. Шуннан ни? Нефть бирүне киметергә барыбер юл куймаслар. Резервтагы бөтен чаннарны тутырганда да көндәлек планны үтәү өчен нибары ике-өч көнгә житәчәк ул нефть. Аннан ары нәрсә?!.

Кул астында ак кәгазь, каләмнәр, карандашлар. Кадыйр каләм алды да яза башлады.

Приказ

24.07. № 196

Промысел һәм цех начальникларына:

1. Күмер катламын эшкәртүгә керешә бару белән беррәттән октябрь аеның 25 нче көнендә девон катламыннан нефть алуны туктатырга. Катламнан сыек ягулыкны тагы да күбрәк күләмдә алу максаты белән идарә «катламнан циклләп файдалану» ысулын сынауга керешәчәк. Катламга су кудыру станцияләренә девон куенына су кудыруны дәвам итәргә. Баш геолог иптәш Сибирцевка шушы прогрессив ысулны сынауга керешүебез турында рәсми рәвештә Бөгелмә фәнни-тикшеренү институтына хәбәр итәргә.

2. Теге я бу төбәктә калган нефть «күлләрен» суыртып бетерү максатыннан чыгып, скважиналарга капиталь ремонт уздыру начальнигы иптәш Покровскийга, бораулау конторасы директоры иптәш Вагинга тиз арада бөтенсоюз техник бораулау фәнни-тикшеренү институты галимнәре тәкъдим иткән «Тамырлы скважина» ысулын бораулауга керешергә.

Идарә начальнигы К. Әмиров.

Секретаре килүгә, Кадыйр приказны машинкада басарга һәм шул сәгатьтә ук барлык промыселларга, цехларга, бораулау конторасына жибәрергә боерды.

Бераздан кабинетка килеп кергән баш геологка ул:

— Приказ язылды, Михалыч. Сынагыз ысулны. — Баш геологның йөзендә гаҗәпләнү галәмәтләре иде, әмма Кадыйр аңа бөтенләй игътибар итмәде. — Бүгеннән үк керешегез. Башлап институтка хәбәр итегез, — диде.

Сибирцев бер сүз дә әйтмәде, җавапны бергә тотасылары булса да, таякның юан башы идарә начальнигы Әмировка төшәсен белгәнгәме, Кадыйрның хәленә керергә теләпме:

— Мин бүген үк хәбәр итәрмен, Кадыйр Сөнгатович, бүген үк,— дип, борылып чыгып китте.

Менә дүрт көн инде девон катламыннан бер тонна да нефть алынмый. Дөрес, тишек-тошыкны ямау өчен күмер катламыннан ниндидер күләмдә суыртыла, аның белән генә план тутыру һич тә мөмкин хәл түгел иде. Соңгы көннәрдә Кадыйрның йөрәге сизелер-сизелмәс кенә «уйнарга» тотынды. Врачлар инфаркт алдыннан шулай була диләр. Түзәрме йөрәк?.. Сынау тагын бер атнага якын барачак. Ә түзәргә иде. Иң мөһиме сынауның уңышлы узуы һәм алынасы нефтьнең артуы иде. Шунда, тик шунда гына идарәгә җиңү киләчәк. Энесе Нәүфәл белән баш геолог Сибирцев көн-төн кырда, РИТСларда югалып йөриләр. Кайтып кергәннәре дә юк. Кадыйрның өстәлендә соңгы мәгълүматлар. Катламда басым арта бара. Торбалар түзәрме? Тагын күпме куарга мөмкин ул суны? Шуннан нинди нәтиҗә булыр?..

Кадыйр су кудыру станцияләрен һәр көн әйләнеп чыга иде, бүген дә шунда юнәлде, тик кабинетында ук күңелендә ашкыну тойды. Нигә, кая ашкына бу күңел!?

Машинасына утыргач, ул шоферына сорау бирде:

— Тиз йөри беләсеңме?

— Кирәге чыкса, очабыз аны, Сөнгатович.

— Алайса, әйдә, әнә теге иң биек тауга юл тот.

Юл буендагы агачларны тоташ яшел стена итеп машина алга очты. Менә ул тау. Менә ул Кадыйрның күңелен үзенә җәлеп иткән, ни өчендер иртәдән бирле үзенә тартып алган биеклек, менә ул кешене тиңсез тәвәккәллекләргә өнди торган изге урын. Таулы картлары нигәдер бу биеклекне изге урын дип йөриләр иде.

Кадыйр машинадан төшеп тау кыясына таба атлады. Еракта-еракта, күз күреме җитәр-җитмәс җирдә борынгы Болгар иленнән калган нигездер хәрабәләр, сыек болытлар арасында җимерек таш пулат тулгана. Аста, түбәндә — мәшһүр елга. Гашыйклар елгасы. Ул зәңгәр тасма булып, тау буйлап сузылган. Арырак — хәтфә болыннар, әрәмәлекләр, тугайлар. Урман-әрәмәләр күкселләнеп калган. Көз. Рәхимсез вә шәфкатьсез көз. Кадыйр тау кыясында таралып утырган мең яшәр карама агачы янына атлады. Аның иң югары ботагына козгын кунган. Ничәмәничә кеше гомерен яшәгән һәм үз гомерендә бик күп яулар, сугышлар, афәт-фаҗигаләр күргән үткер һәм очлы күзле козгын ашыкмый гына тирә-юньне күзәтә. Бик күп үзгәрешләр булгандыр аның гомерендә борынгы Болгарның бу почмакларында да. Кош Кадыйрны күрми, ул еракка-рак карарга, ерактан күрергә, ерактагы хәлләрне күзәтергә өйрәнгән. Киләчәк аңа иртәгә туасы көн генә түгел, киләчәк аңа — алдагы йөз еллардыр, мөгаен. «... Бүгенге белән генә яшәү безгә дә ят нәрсә. Миңа да...»— дип уйланды Кадыйр, машинасына таба кузгала башлап. Йомшак утыргычка кереп утыруга, ул шоферына:

— Идарәгә. Акрынрак кайт, — диде.

Кадыйр Берләшмәгә нигә чакыруларын бик әйбәт чамалый иде. Ләкин ни белән бетәсе аның өчен караңгы иде. Әйе, кеше үз гомерендә һаман сынау үтә, имтихан тота. Мәктәп бер хәл, институттагы икешәр, өчәр тапкыр кергән сынаулар да тора-бара онытыла, әмма кеше өчен сынауның иң җитдие, иң кыены башкарган хезмәтендә була. Ул җаваплы көннәр Кадыйр өчен дә килеп җитте. Нигәдер шушындый вакытларда якыннар искә төшә. Кичә Кадыйр кызы Гөлүсәдән хат алды. Нигәдер кыз аны әнисенә түгел, әтисенә язган. Себердә, Төмәндә торалар. Дүрт курсны тәмамлап киткән Сережа, читтән торып укуга күчкән һәм үзәк РИТСта диспетчер булып эшли икән. Гөлүсә оператор һөнәрен үзләштергән. «Себерлеләр, — дип үзалдына елмайды Кадыйр. — Менә, кызым Гөлүсә, син дә үз бәхетеңне таптың. Әтиең генә үз бәхетен тапмый да, югалтмый да яши бирә, яши бирә», — дип уйлана барды ул, кайчандыр Наташага укыган бер шигырьнең юлларын исенә төшерергә тырышып. Ләкин хәтер ярлары тәгаен гел элеккечә генә тормый икән, җимерелә, үзгәрә, төссезләнә, сипләгән өйдәй ямьсезләнә, саега бара икән. Шуңа карамастан, Кадыйр гомерендә хәтерләрдәй нәрсәләр аз түгел иде.

## 25

Күңел дигәнең гел дәрья сыман икән, бер мәлне ярсып, ташып китә, кинәт ишелеп килгән бәхеттән үз-үзеңне кая куярга белми башлыйсың. Гинекологтан чыгып, больницага таба атлаганда Халисә моңарчы булган бернинди бәхетләр белән чагыштырмастай зур бәхет хисләре кичерде. Әйе, ул бәхетле һәм шат иде. Шатлыгы тутсыл йөзенә бәреп чыккан, алсу битләренә гүзәллек билгеләре салган иде.

Врачлар кабинетына да ул балкып килеп керде. Валентина Михайловна, яңа аткан роза чәчәгедәй кабынып киткән Халисәне күрде дә, сокланулын яшермичә башын чайкап куйды:

— Бәхет өләшкән төштә булдыңмы әллә?

Врачлар бала табу йортын шулай дип йөртәләр иде.

— Әйе, Валечка. — Халисә, плащын салмыйча гына, хирург хатын янына килеп утырды. — Беләсеңме, Валечка, канат куйсалар, билләһи, очып китәрмен кебек. Шул хәтле бәхетле мин бүген.

— Аңламадым?

Халисә ишек ягына карап алды, Валентина Михайловнаның колагына пышылдап нидер әйтте, ул арада бүлмәгә Җәмилә килеп керде һәм ике врачның серләшүләрен күреп, карт хатыннарга хас кызыксыну белән шым булды. Ләкин Валентина Михайловна нянины күреп алды.

— Ни бар, Җәмилә апа?

— Менә Халисә Хәйдәровнага хат биргәннәр ие.

— Хат?! — диде Халисә һәм сикереп торды да аны барып алды, унҗиде яшендәге кебек баш очына күтәреп, сикергәләп куйды. — Хат, хат!

Һәм шунда гына Халисә врач хатынның да, нянының да үзенә сәерсенеп чиксез зур дикъкать белән карап торуларын абайлады.

— Гафу итегез, Валентина Михайловна, сез дә, Җәмилә апа. Гафу итегез. Шатлыклы көнем бүген минем.

Ишектән Валентина Михайловнаны чакырып алдылар, Җәмилә ишек янында басып калды, хатынның Халисәгә тәгаен тагын нидер әйтәсе килә иде.

— Халисә акыллым, күзең бармы синең. Ни бит, Гайсә...

Нидер сизенеп, Халисә аны бүлдерде:

— Җәмилә апа, зинһар башка вакытта, зинһар!

Хатын аны сүзсез аңлады, шунда ук чыгып китте.

Халисә кулындагы хатны әйләндереп, тулгандырып карады. Ул хатның кемнән икәнен адресын күргәч тә шәйләп алган иде, тик хәлнең асылына төшенми генә торган иде бугай. Хәзер ул барысын да аңлады. Нәүфәл больницадан киткән һәм аңа нибарысы хат язып калдырган. Хатны ачты, укыды. Һәм бер ноктага текәлгән килеш, уйга чумды. Шулай бер тын утыргач, сәгатенә күз төшерде. Сәгать кичке алтыны күрсәтә иде.

«Нишләргә, — дип кинәт күтәрелеп, ишекле-түрле йөренергә тотынды Халисә. —Нишләргә, нишләргә тиеш мин хәзер?!

Хатын-кыз бәхете нидән гыйбарәт? Әле генә, менә бу хатны алганчы тойган бәхеттән түгелме? Шуннан, шуннан. Юк, ул хәзер бу адымны мәңге ясый алмас. Мөмкин түгел. Тегесен дә, монысын да югалткан хәлдә дә аның хәзер бөтенләй башка куанычы бар — баласы булачак. Ул хәзер ялгыз түгел, аның киңәшер кешесе бар, булачак. Тагын бер кат гафу ит мине, Нәүфәл, тагын бер кичер. Сез ирләр бер хакыйкатьне аңларга тиешсез: безнең ярты бәхетебез сездә булса, ярты бәхетебез — ә бәлкем әле күбрәгедер дә! — үзебез тапкан, үзебез баккан балабызда.

Дежурдан Халисә иртәнге сәгать җидедә кайтты. Гайсә инде торган, ваннада юына иде, ишек тавышын ишетүгә, үрелеп карады. Гайсәнең йөзендә сабын күбекләре, ә үзе елмая. Халисәгә ул цирк клоунына охшап күренде. Шуңа булса кирәк, ул тыенкы гына көлеп куйды. Гайсәгә шул җитә калды, авызын кыйшайтып тупас кына әйтте:

— Чәй куйган, кулыңны ю да табын хәстәрли тор.

«Нигә әле мин ул хәтле баш алып кайгырам, — дип уйланды Халисә табын хәзерләгәндә. — Бу дөньядагы хатын-кызның өчтән бере генә ир бәхетен тоеп яшәсә яшидер, аларның күбесе якты киләчәккә өмет итә, тормышында ниндидер могҗиза булуын көтә. Ә ул могҗиза килми дә, килми. Ә ул сиңа килде, Халисә. Бала булып». «Мин бәхетле, мин хәзер ялгыз түгел, ялгыз түгел, ялгыз түгел!» — дип кычкырасы килде аның.

# ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА




## Шамил Маннапов

### Син шундый җир

Син шундый җир:
Җан җылысы синдә—
Яхшы орлык шытмый калмый инде.
Халкым күңеле кебек уңдырышлы,
Туган җирем—Татарстан җире.

Син шундый җир:
Бөтен дөнья буйлап
Таратса да төрле заман җиле,
Синең ямьне, синең тәмне җуймас
Синең уллар—Татарстан җире.

Күп күргәнсең,
Күтәргәнсең күпне,
Өркетмәгән, селкетмәгән бере.
Халкым кебек чыдам авырлыкка,
Туган җирем—Татарстан җире.

Зур түзелеш мәйданнары итеп
Тикмә сайлаганмы илем сине?!
Халкым күңеледәй иркен җир син,
Туган җирем—Татарстан җире...

## Әгәр сагынсаң...

Әгәр сагынсаң бала чагыңны,
Чаллыга бар син, КамАЗга бар син.
Кайчандыр шырпы кабыннан йортлар
Төзегән дусларың анда табарсың.

Әгәр сагынсаң яшьлек ярыңны,
Бар син КамАЗга, бар син Чаллыга.
Комбинезон кигән кызларның берсе
Синең сөйгәнең—танып ал гына.

Әгәр сагынсаң туган ягыңны,
Кайт син Чаллыга, кайт син КамАЗга.
Туган ягыңның бар төсен-ямен
Күрерсең шушы мәңгелек язда.

# Мөхәррәм Каюмов

## Юлда

Көне-төне машиналар чаба,
Кыр казлары кебек тезелеп.
Сыгылса да тап-тар басма кебек,
Юл сукранмый—нинди түземлек!

Шатлык үтә—сөендерә юлны—
Бер йөрәккә ничек сыядыр?
Кайгылары имәннәрне бөгәр,—
Авырлыгын юл да тоядыр...

Кәрван-кәрван машиналар килә,
Почет беткән әллә атларга?
Кемнәр кайта?
Ак кулъяулык болгап
Кемнәр китә—кайсы якларга?..

Без дә юлда...
Мәңге сәфәрдә без!
Машинабыз яшел—Ил атлы.
Еллар аның җитез тәгәрмәче,
Изге уйлар—алтын канаты.

Әтиләрнең фатихасы шундый:
Аның руле безнең кулларда.
Тизлек кирәк, тизлек! Сәгатенә
Йөз дә сиксән белән куарга...

Без бу юлда беренчеләр әле,—
Әмма үзе күптән бик таныш.
Якты максат алга ашкындыра,
Коммунизм—соңгы тукталыш.

Ишекне ач—әйдә, дуслар керсен,
Чын дусларга—урын иң түрдән.
Бергә-бергә үтү күңеллерәк
Кылдан нечкә вакыт-күпердән.

Яман күзләр читтән күзәтәләр,
Тик яманлык безгә ят нәрсә.
Дошманны да читләп узмыйбыз без
Ярдәм сорап кулын күтәрсә...

Көне-төне бертуктамый чаба
Машинабыз яшел—Ил атлы.
Чокырлардан исән-имин чыга,
Изге уйлар—алтын канаты...

Без бу юлда беренчеләр әле,—
Әмма үзе күптән бик таныш.
Якты максат алга ашкындыра,
Коммунизм—соңгы тукталыш.

## Рамазан Байтимиров

### Туган як җылысы

●

Әллә инде әйтеп күнегелгән,
Гадәтеме телнең, күңелнең:
Нефтьне без бер дә икеләнми
Кан тибеше дибез илемнең.
Безнең якның тоя җылылыгын
Дус немецлар, поляк, чех иле...
Кан тамыры нефть юлы булса,
Республикам—йөрәк шикелле.

●

Туган як ул туып үскән җирең,
Йорт нигезе анаң-атаңның.
Чыгып китсәң — туган республикаң,
Дөнья гизсәң—газиз ватаның.
Ерак киткән саен туган яклар
Киңәйтәләр шулай үз ярын.
...Галәм гизүчеләр туган як дип
Әйтәләрдер бөтен Җир шарын.

Мәдинә Маликова

# ЯНАРТАУЛАР ЯКТЫСЫНДА

ПОВЕСТЬ

Зуфирә тәрәзә янына килде дә ах итте: куаклыклар белән чуарланган үзәннән төрле төсләргә манчылган томан күтәрелә. Шәһәр читендәге йортның тугызынчы катыннан карап торган Зуфирә ул томанны бөтен төсмерләре белән күрде. Томан диярлек тә түгел, үтә күренмәле киң пәрдәләр кебек — һәр төс берсе-икенчесеннән кискен аерылып тора. Бу пәрдәләр яңгырдан соң юылып чистарынып калган, кичке ямансулык белән өртелгән табигать күренешен әкияттәге тылсымлы дөньяга якынайталар. Әнә кызыл пәрдә, сарысы, яшеле, зәңгәре, шәмәхәсе. Бәй, бу салават күпере ич! Дөресрәге, салават күперенең туып килгән чагы! Менә нинди булып туа икән ул! Күпер диярлек тә түгел, итәге куак башларына орыныр-орынмас тора, аның аша ерактагы елганың текә ярлары да, урман каплаган калкулыклар һәм ул калкулыклар арасындагы ак биналар да, төрле төсләргә манылып, аермачык күренә.

Зуфирә гомердә бер була торган бу күренештән күзләрен ала алмады. Салават күпере тотып алып булмый торган, ләкин даими бер хәрәкәт белән үзгәрә барды: торган саен аның итәге ераккарак шуышты, башы, болытлардан арынып килгән күк гөмбәзенә җайланып, бөгелә барды. Күтәрелгән, ерагайган саен, аның төсләре дә тыгызланды, ачыкланды, ныгыды, пәрдәләр тарайды һәм тасмалар рәвешен алды. Ниһаять, бала чактан таныш салават күперенә әверелде. Зуфирәнең баш очыннан офык артына, кояш чыгышына юл салды ул.

Кайларга барып тоташты икән аның офык артындагы очы? Урал тауларын кичеп, Себерне иңләп үтеп, океанга барып җитмәдеме икән? Ак пароходтагы үткен зәңгәр күзле ир-егетнең баш очыннан Зуфирәгә таба юл салды микән әллә ул?

Юкка гына кабынырга тиеш түгел бит инде мондый гүзәллек, берәр хикмәте булырга тиеш аның, берәр мәгънәсе! Бер-берсен эзләп зарыккан күңелләрне тоташтырырга тиеш ул...

Зуфирә өстәле янына килеп утырды, чәчелеп яткан каләмнәр, буяу тартмалары, кәгазьләр арасыннан пумалачыгын алды, аны банкадагы

суга манды да, ашыгып, катыргы кисәгендә буяулар изәргә керeште. Хәтердә тоныклана башлаганчы, кәгазьгә төшереп каласы иде бу күренешне — салават күперенең туып килгәнен.

Ул яшел киңлекне, ерак елга ярын, урманлы калкулыкларны сызгалады, алар өстеннән үтә күренмәле төсле баганалар сузды... Бөтенесе әле генә Зуфирә күзәтеп торганча иде кебек, ләкин шул ук вакытта бөтенләй башкача иде. Чөнки кәгазьдәге салават күпере — бары тик төсле томан гына, бары тик табигатьнең гадәттән тыш матур бер күренеше генә булып кала бирде, әмма бер-берсенә тартылган күңелләрне тоташтырган юл була алмады. Кәгазьгә сызылган төсле тасмалар беркая да ашкындырмый, чакырмый, күңелне тынгысызлап сызландырмый иде.

Зуфирә эреле-ваклы рамнар, кәгазь төргәкләре тулы шкаф, зур өстәл, карават арасындагы тар мәйданда әрле-бирле йөренде. Аннары стена кырыена сөялеп торган ике рамны үзенә таба борды.

Аның берсенә, акварель белән, сары чәче кашлары турыннан киселеп, маңгаен каплап торганга һәм ике яктан таралып төшкәнгә күрә, түгәрәк йөзе рамга салынгандай тоелган хатын портреты ясалган иде. Хатынның соры күзләре нәрсәдер эзләгәндәй бик җитди һәм борчылып карый. Зуфирәнең автопортреты иде бу. Ул өстәлдән кечкенә көзге алып, бер үзенә, бер рәсемгә карады. Рәсемдә ул олы сыман күренә, яше кырыкка җиткәне бик нык сизелә иде. Үзенә карап аңа берәү дә кырык яшь бирмәс — йөзен чәче белән рамга алып йөргәнгә, башын югары тотканга һәм бигрәк тә буй-сыны кызларча ыспай булганга, олыгайганы сизелми иде Зуфирәнең. Акыл белән түгел, йөрәк белән яши торган кеше ул, ә андыйлар тиз картаймый.

Ләкин хикмәт картлык-яшьлектә түгел, хикмәт Зуфирәнең хәтта үз сурәтен дә күңеле теләгәнчә яза алмавында иде. Тыштан караганда, охшаган да ул үзенә, әмма шул ук вакытта бөтенләй чит тә, чөнки сурәттәге хатынның күз карашында, йөзендә күңел тирәнлеге сизелми, Зуфирәнең кайнар йөрәге чагылмый иде.

Акварель белән ясалган икенче портреттан үткен зәңгәр күзле, киеренке кашлы, нык иякле бер ир кеше карап тора иде.

«Нигә мин һаман шушылай көчсез, — диде Зуфирә, пышылдап, ир кеше сурәтенә. — Беләм дә бит югыйсә ничек кирәген, сизәм бит, күңелемнең тулып ташуын буяулар белән башкаларга нигә җиткерә алмыйм икән?»

Алгы якта ишек ачылып ябылганы ишетелде.

— Әни! Син өйдәме? — дип сорады яшь тавыш. — Миңа хат юк идеме?

— Юк иде шул, кызым, — дип җавап бирде Зуфирә. Үзе авыр көрсенеп куйды: ул да кызы кебек үк хат көтә, әмма бүген почта тартмасыннан газеталардан башка нәрсә чыкмады.

Халидә шал-шолт итеп алгы бүлмәдә туфлиләрен салып ыргытты да кайнар сулышы, дәрте белән бүлмәне тутырып, әнисе янына килеп керде.

— Кем бу, әни? Космонавтмы әллә?

— Нишләп космонавт булсын ул?

— Көчле, сәламәт, омтылышлы кеше төсле бит. Ничектер безнең буй җитмәслек сыман үзе. Чит. Ерак... Салкын...

— Ерак ерагын, Тын океанда ук... Әмма салкын түгел, чит түгел...

Зуфирә рамны стенага борып куйды. Сурәттәге кешене буй җитмәслек салкын иткән нәрсә — әлеге дә баягы шул каләм көчсезлеге иде. Ул кеше Зуфирәнең дөньяда иң якыны, иң газизе бит югыйсә.

— Әйдә чәй эчәбез, — дип, Зуфирә сүзне икенчегә борырга ашыкты.

Кухняда кара-каршы чәй эчкәндә, Зуфирә сиздерми генә кызын күзәтте. Үсте инде Халидә, тәмам аякка басты, училищеда укып һөнәр

алды, хәзер кием кисүче булып эшли. Ә энисе аны үзе кебек, юк, үзеннән дә оста, талантлы художник итү турында хыялланган иде. Ничә еллар художество мәктәбендә укытты. Әмма кыз табигать күренешләрен, сюжетлы рәсемнәр, натюрмортлар ясыйсы урында, хикмәтле итеп киенгән кыз сурәтләре төшерә иде. Бишенче класстан ук, «кием конструкторы булам», дип сөйли башлаган иде, шулай итте дә.

Кызык, Зуфирә шикелле анда-монда бәргәләнеп, кырыкка житеп тә хыялына ирешә алмаган ана белән, җил кайсы якка иссә шунда авышып торган аумакай атадан ничек туган диген шундый бала! Төсе-бите белән нәкъ этисе үзе: эре дулкын ясап торган йомшак коңгырт чәчләре, яшел күзләре, озынча йөзе, күбәләк канаты кебек матур уелган иреннәре, яңак уртасындагы чокырлары — бар да этисенеке. Буйга да этисе кебек озын булып үсте — Зуфирәгә өстән карый хәзер.

Тик кызның йөзендә ныклык, үҗәтлек ярылып ята, яшел күзләр туры-акыллы карыйлар — бу аның этисенә охшашлыгын бөтенләй диярлек юкка чыгара иде. Холкы белән этисенең капма-каршысы ул. Алдан үзенә юл сызып куйган да, тайпылмыйча, тайчанмыйча шул юлдан бара. Андыйлар ышанычлы, нык була, алар белән яшәү рәхәт дөньяда.

Мәхәббәт мәсьәләсендә дә шундый нык һәм тугры булыр, ахры, аның юлы. Художество мәктәбендә ук Айрат исемле бер малай белән дуслашып йөри башлаган иде, моңарчы башка берәүгә күз дә салып караганы юк. Зуфирәгә ошамый малай, йомыкый, хәтта җебегән булып тоела. Ул Халидәгә дә йомшак кына итеп моны әйтергә тырышып карады. «Мин аны синнән яхшырак беләм, эни,— диде Халидә, ыкмыкка юл куймыйча. — Әйбәт күңелле малай ул. Якыннанрак танышкач, синең фикерең үзгәрәчәк әле». Өзде дә куйды, энисен телсез калдыргандай итте.

Хәзер менә егет армиядә. Халидә аны башка бүтәнгә борылып та карамыйча, ак йөз белән көтеп алачак.

Халидә, тәрәзә аша каядыр ерака карап, үз уйларына чумып утыра иде. Менә ул нәрсәгәдер елмайды, бит очлары чокырланып, йөзе мөлаемланып китте. Мондый чакта ул энисенә бигрәк газиз була, аны кечкенә чагындагы сыман күкрәккә кысасы килә иде.

— Бүген кара бәрхет күлмәк тектерергә китердeләр,— диде Халидә.— Бәрхетне тегү шул хәтле азаплы, эни, син күз алдына да китерә алмыйсың!

Чәй эчкәч, ул кинога җыена башлады.

— Шундый шәп картина, ди. Безнең кызлар мактап туймый. «Гашыйклар турында романс». Әйдә син дә!

— Юк, кызым, ашыгыч эшем бар.

— Тагын яңа китап өчен рәсем ясыйсыңмы?

Зуфирә китаплар, журналлар өчен рәсемнәр ясый.

— Юк, үз эшем,— диде ул.— Беләсеңме, минем күңел түремдә бик зур хәзинәләр тутырылган бер сандык ята. Шуның йозагы бикле, ә ачкычы югалган. Шуңа ачкыч ясыйсым килә, шул сандыкны ачып, хәзинәсен кешеләргә бүләк итәсем килә.

Халидә рәхәтләнеп көлде, сеңлесен кочаклагандай итеп, нелеп энисен иңнәреннән кочып алды.

— Ну, яса алайса ачкыч! Байыйсылары бар икән әле халыкның!— диде дә, бөтерелеп чыгып китте.

Әмма Зуфирәгә ялгыз уйланырга ирек бирмәделәр — ишек кыңгыравы чылтырады. Ишекне ачкач, ул иң элек берәүнең ак күлмәген күрде, аннары гына, башын артка ташлап югарырак карагач кына, каршында ире, дөресрәге, моннан ике ел элек аерылган ире Эльвир

торганлыгын аңлады. Эльвирның кулында зур гына кара портфель, аркасында таныш чехол белән аккордеон асылган иде.

— Ярый әле, өйдә икәнсең,— дип җиңел сулады ул.— Үзең генәме әллә?

— Халидә чыгып киткән иде әле.

— Сиңа бер йомышым бар иде,— диде Эльвир каядыр читкә карап.— Җүләр йомыш... Җүләрлек белән килдем мин сиңа...

Зуфирә, каушавын яшереп, шаярып җавап бирергә тырышты:

— Җүләрлекнең иң зур белгече мин бит инде... Шуны уйлап килгәнсеңдер.

Аның бу сүзләреннән Эльвир иркенәеп киткәндәй булды, ул, күрәсең, ишек төбеннән борып, куып җибәрмәгәйләре, дип куркыбрак килгән булгандыр да, каты сүз ишетмәгәч, тынычлана төште. Зуфирә, артка чигенебрәк, аңа керергә юл бирде.

Эльвир ишек төбендә үк аркасыннан аккордеонын төшерде, портфелен куйды. Икесе дә ни әйтергә белми тынып калдылар. Эльвир ачык ишек аша залдагы җиһазны күздән кичерде — ул бу йортта бары бер генә тапкыр, анда да бөтен нәрсәнең асты-өскә килгән чакта — әнисе мәрхүмәне күмгәндә генә булган иде, шуңа күрә бу юлы бар нәрсә өр-яңа булып тоелды.

Зуфирә ирен күзәтте. Инде күптән аңа күңел сүрелгән, йөрәк түрендәге иң кадерле урынны башка бирәү — үткен зәңгәр күзле, киеренке кашлы кеше алган, дип уйлый иде ул. Ләкин нигә соң, аны күргәч, йөрәк, кабыргаларга бәреп, кагарга тотынды?

Табигать Эльвирны ясаганда материалын да, вакытын да, тырышлыгын да кызганмаган. Кыз чагында ук Зуфирә аның күзгә бәрелеп торган йөзенә сокланып туя алмый иде. Аның керфекләренә — бөгелеп торган, очы алтынлангандай саргаеп килгән куе керфекләренә, шул керфекләре арасыннан нур сирпегән яшел күзләренә караган саен карыйсы килә иде. Аңлатып булмый торган ямансулык, ярдәм сорау, оялчанлык бар иде аның карашында.

Гашыйк булып йөргән чакта да, өйләнешкәч тә, Зуфирә күп тапкырлар аның портретын язды, ләкин бер генә тапкыр да ул карашның серен бирә алмады. Ә ансыз Эльвир Эльвир түгел, ансыз аның сөйдергеч һәм көйдергеч мөлаемлыгы югала, бетә иде.

Була бит шундыйлар ир-ат халкы арасында, сабыйларча саф, ямансу караш белән хатын-кызларның йөрәгенә ут салалар. Син аларны кызганасың, үзеңнең бар мәшәкатеңне ташлап, алар көен көйлисе килә. Ә инде кызгану, үз көеңне онытып, аның мәшәкате артыннан йөрү теләге кузгалды исә, гыйшык шырпысы сызылды дигән сүз.

Зуфирә хәзер яхшы аңлый моның хикмәтен, әмма барыбер Эльвирның яшькелт күзләреннән сирпелгән тылсымнан котыла алмый икән әле.

— Тормышны әйбәт көйләгәнсең икән син,— диде Эльвир кыйммәтле телевизорны, әйбәт җиһазны, тәрәзә төбендә чәчәк атып утырган яраннарны, тамчы гөлләрне күздән кичереп.

— Комачаулаучы юк бит хәзер,— диде Зуфирә төрттереп. Ул инде аны бер каршылыксыз өенә керткәненә үкенә башлаган иде.— Я, ни йомышың бар?

Эльвир очлары алтынсуланып бөгелеп килгән куе кара керфекләре арасыннан бер карады да:

— Син мине хәзер теләсә нишләтә аласың, Зуфирә,— диде.— Теләсәң иректә калдырасың, теләсәң төрмәгә илтеп тыгасың...

— Төрмәгә?.. Эш шуңа ук барып җиттемени инде?

— Эш... Минем гаеп белән килеп чыккан эш түгел ул. Әмма кызуында электерсәләр, илтеп ябулары да ихтимал. Суынганнарын көтәргә кирәк.

— Кемнең суынганын? Утырып сөйләшик әле.

Эльвир җиңеләеп китеп диванга таба узды. Зуфирә өстәл янына урындыкка утырды.

— Ачыграк итеп сөйлә әле, зинһар,— диде Зуфирә.

Эльвир рестораннан кайткач, яшь хатыны Румия белән икесе арасында дәгъва купкан, Эльвир хатынын этеп җибәргән дә, тегесе йөзе белән өстәл кырыена барып төшкән. Кыскасы, хатын хәзер больницада ята икән, туганнары Эльвирны таш капчыкка илтеп тыгарга ажгырып йөриләр, ди.

— Синең хатын-кызга кул күтәрә торган гадәтең дә бармыни әле?

— Әллә юри кыланып, егылмакчы булып, ялгыш бәрелде шунда...

Эчкәч, Эльвирның йөзеннән сөйкемле нур качып, күзләре пыялаланып, шәфкатьсезләнеп калганын белә иде Зуфирә. Андый чакта ул аннан читтәрәк булырга тырыша торган иде. Бәлки шуның белән генә ул аның йодрыкларыннан котылып калгандыр да, кем белә.

— Эчкән булгансыңдыр инде, үз-үзеңне белештермәгәнсеңдер.

— Ул хәтле авыз тутырып «эчкән» диярлек түгел идем үзе, гадәттәгечә, чама белеп кенә. Алла, аның чәрелдәвенә адәм түгел, фәрештә чыдамас...

— Ә мин сезне бик бәхетледер дигән идем.

— Соң бәхет шул инде менә — өч елдан сигез елга чаклы төрмә баландасы чөмерү күз алдында тора. Минем язмыш кына түгел бит монда. Бала бар, Халидә. Әтисе арестант булса, кыз бу гарьлекне ничек кичерер? Җитеп килә бит инде, егетләр карый торган чагы, кияүгә барасы килер...

Эльвирның юләр йомышы менә нәрсәдән гыйбарәт икән: хатыны терелеп чыкканчы, чит күзләрдән югалып тормакчы ул. Ә аның өчен иң җайлы урын — Зуфирә квартирасы. Бераү дә аны биредән эзләмәячәк, сорасалар да, Зуфирәнең аларны кертмәскә тулы хокукы бар. «Әһә, үзегез минем иремне тартып алдыгыз да, хәзер, менә мыскыл итеп, аны моннан эзләгән булып йөрисезме!»— дип, куды-чыгарды.

— Җил-давылдан минем артка ышыкланырга инде алайса ниятең?— диде Зуфирә гаҗәпләнеп.

— Иң якын кешем монда бит, бала монда,— диде Эльвир, аның күзләренә сабыйларча туры һәм гөнаһсыз карап.

Зуфирә әйтер сүз тапмады: нәрсә бу, оятсызлыкмы? Әллә, чыннан да, сабыйларча беркатлылыкмы? Мөлдерәпләр карый бит, юньсез, Зуфирәнең куып чыгармасын белеп тора!

Зуфирә кухня ягына чыгып китте, чәй куйды. Куллары һәр эшне күнегелгән хәрәкәт белән үзләреннән-үзләре башкарды, ә үзе зал ягыннан килгән авазларны тыңлады.

Менә Эльвир алгы бүлмәгә чыкты, аккордеонын алды булса кирәк. Менә аның бармаклары клавишлар буйлап йөгереп уздылар. Ул бары тик аңа гына хас йомшак моң белән яшьлектәге көйне уйнап җибәрде:

«Сагынып килдем, күрми китәм,
Чыкмый калма иртәгә...

Зуфирәнең күңелен тетрәндереп, ихтыярын сындырып, тәкатьсез итеп, үзенә буйсындырыр өчен уйный иде ул моны. Урынына, җаена, кәефенә карап, көйләрне төрлечә уйный белә бит ул. Кичәләрдә, табыннарда — дәртле, җиңел, кискен итеп, Зуфирә өчен генә булганда — яшерен бер мәгънә салып, башкаларга сиздерергә ярамый торган оялчан, нечкә, тирән хисле итеп уйный ул. Андый чакларда әйтерсең лә аның аккордеоныннан көй түгел, ә бер күңелдән икенче күңелгә түгелми-чәчелми, икәүгә генә аңлаешлы сер агыла...

Нәкъ шушы серле моңы белән Зуфирәне баштанаяк үзенә әсир итте дә бит инде ул... Аның көче һаман бетмәгән икән әле, йөрәген-

нән саркыган сернең Зуфирә күңелендә үтеп керә торган юллары һаман күмелмәгән икән. Бу көй хәтердә картина-картина итеп истәлекләр яңартты. Менә алар училище залында икәүләп биниләр. Кайсы училищеда соң әле? Зуфирә укыган художество училищесындамы, әллә Эльвир укыган музыка училищесындамы?

— Сез шундый җиңел бисисез, очып йөргән кебек кенә. Ничек мин сезне моңарчы күрмәгәнмен... Кайсы яктан сез?

— Бөгелмәдән...

Менә алар паркта, Зуфирә башына сары яфраклардан такыя үреп кигән дә, фонтан суына иелеп, шәүләсенә карый, үзеннән бигрәк янында басып торган Эльвирны күрә.

— Такыя сиңа шундый килешә,— ди Эльвир...

Менә алар парлашып Эльвирның әнисе Сабира карчык каршында басып торалар, булачак каенананың Эльвирныкы төсле яшькелт күзләре кызны чәнчеп-чәнчеп алгандай итә, ә Эльвир сөйгәненә көч биреп елмая: «Курыкма, без икәү бит!»— ди.

Менә алар парлашып загстан чыгып киләләр... Чәчәкләр, котлаулар...

Ә теге якта: «Сагынып килдем... сагынып килдем...»—дип аккордеон өзгәләнә.

*

* *

— Әтиең килде.

Халидә, ишектән кереп, туфлиен салырга дип иелгән иде, башы тагын да түбәнрәк иелде.

— Ә ник килгән?— диде әнисе шикелле үк пышылдап.

— Күрергә... килгәндер.

— Моңарчы безне күрми яшәде бит әле... Озакка килгәнме инде бу юлы?

— Вакытлыча... Ә бәлки, син рөхсәт итсәң, берничә көн торыр да.

— Ә аннары?

— Аннары яши торган җиренә кире китәр.

Халидә күтәрелеп әтисенең күзләре белән әнисенә карады.

— Нәрсә килеп сарып йөри ул әрле-бирле:... Монда кунак йортымы әллә?

— Шулай кирәк аңа... Бер җайсызлык килеп чыккан...

— Әһә, җайсызлык килеп чыкканда без исенә төшкәнбез икән. Син теләсә ни әйт, мин аны кертмәс идем.

— Авызыңнан җил алсын! Кем турында сөйләгәнеңне беләсеңме? Әтиең турында сөйлисең бит син?

— Әтием булгач, хыянәт итмәсен иде! Башка... кеше янына китеп, ул синнән дә бигрәк миңа хыянәт итте, беләсең килсә!

— Ярый-ярый... Монда бәхәсләшмик... Зинһар, хәзергә телеңне тый, тупасланма...

Залдан шылт иткән тавыш та ишетелми, Эльвир ана белән кызның ни сөйләшкәнен ишетергә тырышып утыра иде булса кирәк. Ата белән кыз чит кешеләр кебек күрештеләр. Эльвирның Зуфирәне сихерли торган нурлы карашы кызының нәкъ үзенеке төсле яшькелт күзләренә тәэсир итми иде. Чәй янында Эльвир аннан аны-моны сораштырырга тырышып карады, ләкин Халидә, тәрәзәгә караган килеш, «яхшы», «ярыйсы» дип җавап биргәләп торгач, сүзнең очы-очка ялганмады.

Өстәл янында авыр тынлык урнашты. Чынаякка балкашыкның бәрелүе һәм Эльвирның чәйне шапырдатып чөмерүе дә сискәндереп җибәрә иде.

Зуфирә, үзен биләп алган тәэсирләрдән арынып, иренә җентекләбрәк, төпченебрәк карады.

Бергә яшәгәндә кешенең картайганы, үзгәргәне артык сизелми, уналты ел эчендә Зуфирәгә ире гел үзгәрмәгән шикелле тоела иде. Ә хәзер менә аның картайганлыгы нык сизелә. Кайчандыр Зуфирәнең башын әйләндергән егет икән дә димәссең үзен. Зуфирә сөйгән егетнең чәче дулкынланып, киң маңгаен түгәрәкләндереп каплап тора иде,— ә бу кешенең чал керә башлаган чәче маңгай өстендә ике уем ясап артка чигенгән. Бит очларында ике чокырчык бар иде — бу кешенең ике яңагында алар урынында тирән ике буразна сузылып яткан.

Ләкин болар гына зыян итмәс иде. Кайбер ирләргә сирәгәйгән чал чәч тә, җыерчыклар да килешеп кенә тора, йөзләренә бәреп чыккан зирәк акыл, ихтыяр көче, кешелеклелек, мөлаемлык аларны хатын-кыз өчен күп егетләрдән дә сөйкемлерәк итә.

Кызганычка каршы, еллар үтү белән кыяфәте үзгәрсә дә, күз карашы, йөзендә чалынган рух рәвеше үзгәрмәгән Эльвирның, аның яшькелт күзләре әле һаман балаларча беркатлылык, сафлык, ышанучанлык белән, ярдәм сорап карыйлар. Ә мондый караш аның яшендәге ир-егетне бизи алмый шул инде.

Зуфирә аска карап: «Ә соң үзем?» — дип, эченнән генә уйлап куйды. Әлбәттә, инде ул үзе дә күптән егерме яшьлек кыз түгел. Элекке Зуфирә юк инде, элекке Эльвир да юк, алар икесе дә кайсыдыр ерак елларда калганнар, ә биредә, бу йортта, бу өстәл янына алар урынына бөтенләй бүтәннәр очрашкан. Ләкин теге, яшь гашыйклар башларыннан кичкән хәлләрне онытмаганнар. Ул хатирәләр бу икәүнең арасында җимерелмәс киртә булып тора.

...Зуфирә залдагы диванга Эльвирга урын җәйде, ә кызын эчке бүлмәгә — «мастерское»ндагы караватка үзе белән бергә яткырды.

Халидә көрсенгәләп, шактый вакыт боргалангач, тагын баягы «ник килгән» дә «кайчан китә» кебек сүзләрне озайта башлаган иде. Зуфирә уйчан гына:

— Сиңа өлкәннәр турында андый катгый хөкем чыгарырга иртәрәк әле,— дип пышылдады.— Синең әтиеннең күңеле беркайчан да начарлыкта түгел иде. Ул гел әйбәт, тигез, матур яшәүне генә теләгән иде. Һәркем дә үзе теләгәнчә генә яшәп бетерә алмый, бөтен фаҗига дә шунда.

— Ничек инде үзе теләгәнчә булмасын? Безне ташлап китәргә кем кушкан аңа? Нинә тапкыр күрдем мин аларны урамда, оялмыйлар да, култыклашып баралар... Бусы мине күреп туктагач та, тегесе читләшми, һаман ябышкан килеш тора, күзен тасрайтып! Ничек мин шунда аның белән сөйләшим дә, ничек итеп мин аңа әти дип дәшә алыйм?

— Ул теләгәнчә килеп чыкмады шул, теге хатын теләгәнчә килеп чыкты. Аның ихтыяры көчлерәк булган, димәк. Әтиең йомшак күңелле кеше бит синең.

— Йомшак күңелleme? Алайса ул нигә авыру әбине ташлап чыгып китте, ә?

Халидә кабынып китеп яткан урыныннан торып утырды. Аның яшь йөрәге хәтта әтисе кылган бер генә гаделсезлекне дә гафу итәргә теләми иде.

— Язмышына үзе хуҗа була алмады ул, аның бар гаебе шунда,— дип кабатлады Зуфирә. — Ә язмышка хуҗа булу өчен бик зур ныклык кирәк. Ходай сиңа үзең теләгәнчә яшәргә язсын, ходай сиңа бер нәрсә теләп тә, башкача көн күрүне язмасын!

— Аны ходайдан сорап торасы юк. Һәркем үзе теләгәнне һәм үзе яхшы дип тапканны эшләргә тиеш!

— Яшь шул әле син,— дип, аның чәченнән сыйпады Зуфирә.— Йокла әйдә, борсаланма, югыйсә миңа да йокы бирмисең...

Халидә, көрсенеп, әнисенә аркасы белән борылып ятты.

*
* *

Ах, Халидә, Халидә, әгәр кеше үзе теләгәнчә генә яши алса икән... Эльвирның уе тамчы да начарлыкта түгел иде. Аларның хыяллары изге иде, матур иде... Менә алар икесе дә укуларын тәмамлыйлар, Эльвир матур-матур җырлар яза, филармониядә концертмейстер була. Исеме генә ничек яңгырый: «концертмейстер». Зуфирә кешеләрне таң калдырырлык, күңелләрне тетрәтерлек картиналар яза. Аларның ике балалары — бер уллары, бер кызлары — туа. Кызлары музыкант була — фортепианода яки скрипкада уйнаучы, ә уллары художник...

Кая алар — Эльвир язасы җырлар? Кая Зуфирәнең кешеләрне шаккатырырлык картиналары?

Яза алмады Зуфирә аларны. Училищедан бик зур өметләр белән чыккан иде югыйсә, аның «Укытучы» исемле картинасына комиссия «бишле» куйган иде. Әмма аның хәзергәчә халыкның «бишле»сенә лаек булырлык әсәр иҗат иткәне юк әле...

Ә Эльвир... Ул хәтта укуын да тәмамлап чыга алмады. Өйләнгәндә аның тагын бер ел укыйсы калган иде әле. Ләкин аны соңгы курска кертмәделәр, училищедан куып чыгардылар, ул хактагы приказны Зуфирә озын коридор стенасына эленгән тактадан үз күзләре белән укып кайтты. Эльвир үзе аңа бу хакта әйтмәгән иде. Ул, әлбәттә, төп фәненнән — музыкасыннан ярыйсы гына өлгереп бара иде, аңа сәләте дә җитәрлек, уйнарга да ярата иде. Тик менә тарих, философияне алдыра алмаган.

Шул чакта Зуфирәнең хәтеренә бер кыздан ишеткән сүз килде. Әле укыган чакта ук, Эльвир белән танышып йөрешә башлаган вакытта, Зуфирәнең дус кызы:

— Ә минем бер таныш кызым синең егетеңне бик яхшы белә икән,— дигән иде.— Бергә укыйлар.

— Эльвир турында ни сөйли?— дип, ярым шаярып сорады Зуфирә. Әмма җавап бик җитди яңгырады:

— Максатсыз кеше ул, ди. Ник яшидер бу дөньяда, аңламыйм, ди. Үпкәләмә, мин ишеткәнемне әйтәм. Белеп торуың яхшырак, соңыннан үкенерлек булмас...

— Үзенә карамаганга үч алуы түгел микән?— дип сорады Зуфирә каушавын, рәнҗүен эченә йотарга тырышып. Ул күп кенә кызларның Эльвирга кызыгып йөргәнен яхшы белә иде.

— Егете бар ул кызның, бик яратышып йөриләр.

«Максатсыз»... Соңыннан кат-кат искә төште бу сүз.

Еллар узган саен, кешеләрнең генә түгел, үзеңнең дә кемлегеңне яхшырак аңлый барасың. Хәзер шуны белә Зуфирә: яшьтән мавыгучан холыклы булды ул. Кешенең берәр матур, яхшы ягын күрсә, шуңа сокланып, аны һәр яктан бик әйбәт дип күз алдына китерә. Соңыннан ул кешенең берәр җитешмәгән ягы ачылса, үзен алдангандай хис итә, рәнҗи, үпкәли, газаплана иде.

Аның балалар журналында эшләүче бер танышы бар, Мөршидә исемле. Зуфирәгә кат-кат әйтә ул:

— Нишләп син кешеләрне идеал итеп күз алдына китерәсең? Һәр кешенең була яхшы ягы, була начар ягы. Моның миңа ошамаган яклары бардыр бит дип, алдан ук күңеләңә уеп куя торган бул. Аннары

аның яхшылыгын күргән саен сөенерсең, үзеңә рәхәт булыр. Инде начарлыгын күрсәң, артык көенмәссең. Табигый дип кабул итәрсең.

Мөршидә белән килешсә дә, аның хаклыгын аңласа да, күңеле-йөрәге белән моңа өйрәнә алмады Зуфирә. Эльвирның училищены ташлавын да, үз-үзенә урын таба алмыйча, туктаусыз бер эштән икенчесенә күчеп йөрүен дә бик авыр кичерде ул, бик олы хәсрәт дип кабул итте. Үзе гел бишлегә генә укыганга, һәркем үзенә тапшырылган яки үзе теләп алынган эшне ахырынача тиешенчә башкарып чыгарга тиеш дип саный иде ул. Бу аңа сулыш алу шикелле үк табигый тоела, шулай булмаганда, ул чиксез гаҗәпләнә иде.

Эльвирның хыянәте дә Зуфирәнең башына сыймас бер хәл булды.

Ул чакта алар бер бүлмәле кечкенә квартирада яшиләр иде әле. Зуфирә мәктәптә укыта, Эльвир — культура сараенда һәвәскәрләр түгәрәгенең җитәкчесе иде. Каенанасы җәй башында Халидәне алып авылга кунакка китеп барды, алар икәү генә калдылар.

Ул хыянәт дигән нәрсә кинәт кенә булмагандыр инде, шактый элек башлангандыр. Зуфирә аны электәнрәк сизәргә тиеш иде. Артык беркатлы булмаса, эчендә җаны булган хатын иренең ятлар белән шаяруын тоймыйммы соң! Ләкин сизмәде Зуфирә, үз күзе белән күргәнче, иренең тугрылыгына ышанып яшәде.

...Зуфирә дәрескә кергәч кенә абайлап алды: балаларга күрсәтергә дип әзерләп куйган альбомы өйдә онытылган икән. Ул укучыларны мәктәп янындагы бакчага алып чыгып, этюд ясарга кушты да, үзе тиз генә кайтып килергә булды: ерак ара түгел, егерме минутта әйләнеп килеп була иде.

Ишекне ачкач, бүлмә уртасында, шәрә беләкләрен күтәреп, чәчен төзәткәләп торган ялан аяклы ят хатынны күрде һәм башта югалып калды: әллә инде саташып кеше өенә барып кердеме? Аптыраудан бер читтәрәк басып торган Эльвирны башта шәйләмәде дә.

— Нишлисез сез монда?— дип, теленә килгән беренче сорауны әйтте.

Хатын, кулларын төшереп, аңламамышка сабыша тагын дигән сыманрак көлемсерәп куйды, калын, шешенгән иреннәре арасыннан ике алтын теше ялтырап күренеп китте.

Шунда гына Зуфирә аны таныды: күрше ресторанның буфетында эшләүче Румия иде бу. Бервакыт, һәвәскәрләр концертына баргач, Эльвир аны, менә дигән драма артисткасы, әнә нинчек матур укый шигырьне, дип күккә күтәреп мактап утырган иде. Талант кадәресе ничектер, әмма төсе-кыяфәте шәп иде хатынның. Ике бит алмасы янып тора, буе-сыны бар, кара чәчләре иңнәренә таралып төшкән, хәтта ямьшек борыны да аңа бер бизәк кенә булып тора иде шикелле. Бөтен зал аның шайтан уты шикелле яктырып торган зур коңгырт күзләренә карап дөньясын оныткан иде. Нәрсәдер вәгъдә итә, каядыр чакырып, ымсындырып елмая иде ул күзләр. Клубта аны нигәдер «Кармен» дип атап йөртәләр иде. Бер заман кино түгәрәге һәвәскәр фильм төшереп азапланганда, аны төп рольгә куеп караганнар. Эльвир шул фильмга музыка язам дип хыялланып йөргән иде, бәлки танышлыклары да шуннан башлангандыр.

...Ике хатын шулай бер-берсенә карап тордылар. Ә Эльвирның оялганы да, кыенсынганы да сизелмәде, ул нелеп диван-караватасыннан үкчәсе ачык ак түфлиләр алды да Румиянең аяк астына ыргытты. Карменның аяк тырнаклары канга манчылгандай кып-кызыл итеп буялган иде...

Эльвир аны хатыныннан аркалап чыгарып җибәрде.

Зуфирә, культура сараена кереп, Румиянең адресын белде дә аларга китте.

Кырыйларына тигезле-тигезсез киез кагылган ишекне кечерәк кенә буйлы, арык йөзле бер ир ачты. Нишләптер солдат гимнастеркасыннан иде ул һәм бу аны яшәртеп, бөтенләй малайсытып җибәрә иде. Зуфирәне күрүгә аның йөзе тагын да озынчаланып агарып китте, күзләре зур ачылды. Әйтерсең лә ул менә хәзер бик каты яра ясаячакларын белә, әмма котылу чарасын күрми иде. Яраланып егылган атлар үзләренә төбәлгән мылтык көпшәсенә шулай гаҗиз булып карыйлардыр, мөгаен.

Әмма Зуфирә күрүккә баса алмады. Бер генә мизгелгә башын иеп, иренен тешләп торды да, тыныч булырга тырышып:

— Румия өйдәме?— дип сорады.

— Румия?.. — дип кабатлады ир кеше калтыранган тавыш белән— Юк, ул эштә бит...

— Ярый алайса, эшенә керермен инде.

Шулай диде дә, мамык кебек йомшарган аякларына җайсыз басып, баскычтан төшеп китте.

Эльвир үзен гаепле санар, ә мин аны озак гафу итмәм, ялынדырмын, үкендерермен, дип уйлаган иде ул. Ялгышты. Эльвир ялыну гына түгел, башлап сүз кушарга да ашыкмады.

Алар икесе дә үз көйләре белән яши башладылар. Зуфирә китапжурналлар өчен рәсем ясый, кухняда үзенә кирәгенчә итеп җыелмалы өстәл ясатып куйды. Эльвирның андый эшкә кулы бармый иде. Мәктәптән бер останы ялларга туры килде. Зуфирә кичләрен шул өстәл янында озак-озак утыра. Әмма кирәкле рәсемнәр урынына кәгазьдә ямьшек борынлы, зур күзле хатын-кыз сурәте, янсә яраланган ат шикелле тилмереп карап торган ир йөзе калкып чыга...

Ә Эльвир соң кайта, гадәттә бераз салмыш була, кухняга кереп чәйнектән салкын су салып, голт-голт эчә дә, бүлмәгә чыгып китә. Әйтерсең лә хатынын күрми дә! Ашарга бирәр нәрсә дә кирәксенми ичмасам, тамагын әллә кайда туйдырып кайта!

Алар шулай, сөйләшмичә, ике атна яшәделәр. Ләкин сүз белән аңлашмасалар да, Эльвир хатынының күңелен йомшарту юлын тапты. Ул аккордеонын кулына ала да, яшь чакта Зуфирә яраткан көйләрне уйнап җибәрә.

«Сагынып килдем, күрми китәм...» — дип өзгәләнә аккордеон, көйнең әллә нинди тыкрыкларына кереп, адашып йөри, кемнедер эзли, эзли, таба алмый... Сагышлы моң йөрәккә үтеп керә, үзәкне өзә, күзгә яшь тутыра, тәкатьсез итә... Әйтерсең лә Эльвир тылсымлы авазларны кармак итеп Зуфирәнең йөрәгенә ташлый, каптыра, кармакка бәйләнгән җепнең икенче очын үзенең хәрәкәтчән, озын, сизгер бармакларына ныгытып урап куя.

«Юк, беркайчан да гафу итмәячәкмен мин сине, беркайчан да!» — дип пышылдый Зуфирә, әмма сизеп тора: беркайчан да бу кармактан ычкына алмаячак, ычкынырга теләмәячәк аның йөрәге! Чөнки аның авырттыруы, сызландыруы да татлы... Зуфирәгә өстәлендәге кәгазьләр өстенә капланып елаудан башка чара калмый, ул бары тик елаганын Эльвир белер дип кенә курка...

Озак уйнамый Эльвир, аккордеонын куя да, шакылдатып кәнәфи караватны җәя. Үпкәләшкәннән бирле ул, хатынына үч итеп, юри шул җайсыз, тар, биш яшьлек Халидәгә генә ярый торган урында йоклый. Моңарчы парлап йоклаган диван-караватка гына түгел, әнкәсенең зур шифоньер артындагы караватында тау булып күпереп торган чигүле зур мендәрләренә дә орынмый. Кызының кечкенә мендәрен баш астына сала да, аның юрганын ябына. Башыннан ук бөркәнеп ята, аяклары юрган астына гына түгел, ятакка да сыймый кала.

Өч атнадан каенанасы белән Халидә кайтты, аларны каршы алырга вокзалга Зуфирә белән Эльвир икесе ике яктан килеп бастылар.

Үсеп, матураеп киткән кызының йомшак тәнен күкрәгенә кыскач, аның чәченнән аңкыган юкә чәчкәсе исен тойгач, Зуфирәнең йөрәгендәге таш тәмам эреп беткәндәй булды. Кыз бер кулын әнисенә, икенчесен — әтисенә сузды, кош баласы кебек йомшак куллары белән һәр икесенең бармакларын кысып тотты, аларны аерылгысыз итеп бер-берсенә тоташтырып куйгандай итте.

Өч атна буена котсыз торган өйгә бердән ямь керде, җылылык иңде. Каенана вагоннан төшкәндә үк бөрешкән, картайган кебек күренгән иде, бусагадан атлап кергәч, тизрәк яту ягын карады, чәй эчүгә күзләре йомыла башлаган Халидә үз урынына — элеге шул кәнәфи караватка үрмәләде.

Зуфирә ирен гафу итәргә теләми иде әле, ләкин нишлисең, икесенә бер урын калган, карт ана белән сабый каршында дәгъвалашу килешми... Зуфирә карышмакчы булып карады, пышылдап кына аңа рәнҗүләрен әйтмәкче булды, ләкин сүзләре бер назлану, җиңелчә үпкәләү сыман гына булып килеп чыкты. «Я инде, ялгышлык белән генә булды, бәндә хатадан хали түгел, сине генә яратам бит инде...» — дип, кайнар кочагына алган иренең сагынылган куенында бер йомарлам май кебек эреде дә төште Зуфирә...

Алар килештеләр, татулаштылар, ләкин хыянәтнең эзе калды. Зуфирә үзен ничектер бөтенләй үк булмаса да, ярым-ялгыз итеп сизә башлады, инде башка беркайчан да ире каршында ахыргача ачылып китә алмады.

*

* *

Кухня яктан суыткычның гүләгәне ыграк ишетелә башлады, ишек ачылып китте бугай. Зуфирә, истәлекләреннән аерылып, башын мендәрдән калкыта төште. Әйе, бүлмә ишеге ачылган икән, дөресрәге, ачканнар, әнә караңгыда әллә нинди куркыныч өрәк кебек шәйләнеп, ак майка, кара трусик кигән шәүлә басып тора. «Зуфирә! — ди ул, каты пышылдап. — Зуфирә!»

Тавышка Халидә уянды, әллә бөтенләй үк йокламаган булганмы, караватны каты шыгырдатып әйләнде дә әнисенең күкрәгенә йомшак беләген салды. Ишек әкрен генә ябылды, шәүлә чигенеп юк булды.

Зуфирә үзалдына елмаеп куйды. Ах Эльвир, Эльвир, инде картаеп киләсең, күпме гомер үтте, ә син һаман әле Зуфирәне элекке чаралар белән буйсындырмакчы буласың!

«Балык тирәнне, адәм яхшыны эзли», — ди рус мәкале. Югыйсә адәм баласы балыкка охшарга тиеш түгел бит, җайсызны үзенә җайлы итә белергә тиеш. Көчле, уңган кешеләр шулай итәләр дә. Ә менә Эльвир кебекләр, чыннан да, тирәнне эзләгән балык шикелле, җайлыны гына эзлиләр, җайсызлыкка бер генә дә түзә алмыйлар. Нәни кызы белән дә көе барда гына уйный-шаяра торган иде ул, бала елый башлады исә, хатынына я әнисенә илтеп тоттыра иде. Анысы ничектер табигый кабул ителә, ир кешегә бу килешеп тора сыман иде. Ә менә әниләре Сабира карчык чиргә сабышкач, Эльвирның бу холкы бик тиз сиздерде, сиздерде һәм күңелне үзеннән биздерде.

Сабира карчык электән дә хәтерсез иде, үзе җыеп куйган әйберне эзләп җаны чыга торган иде, берәрсенә сүз кушам дисә, «Эльвир, Халидә, килен» дип, хәтта әллә кайчан суга батып үлгән улы Хатипның да исемен кушып, бер-ике тапкыр санап чыга торган иде.

Боларына күптән күнеккәннәр иде инде. Ләкин менә бер заман каенананың ашка-шикәр, җимеш суына эремчек салу, чәй янына килеңенең буяуларын китереп кую, ишекне шар ачык калдырып чыгып китү кебек гадәтләре күренә башлады. Ә бер көнне ул эштән кайткан киленен: «Кем син? Ни кирәк?» — дип каршы алды.

Җәй уртасында Эльвир бләи Зуфирә, кызларын алып, өчәүләп диңгезгә бардылар. Сабира карчыкны авылдагы туганнарына кайтарып тордылар. Авылдан кайткач, карчык аларның берсен дә танымады. Эльвирдан бөтенләй курыкты: «Бу алагаем ир нишләп йөри монда, мине кияүгә бирмәкче булалармы әллә?» — дип, аннан качарга тырышты, Зуфирәдән: «Кем анасы син?» — дип сорашты. Карчыкны өйдә ялгызын калдыру куркыныч була башлады.

Эльвирны каты күңелле, шәфкатьсез дия алмас иде Зуфирә. Ул әнисен чын күңеленнән кызгана иде, аны терелтү өчен бөтен чараларны күрергә, кулыннан килгәнчә тырышырга әзер иде. Әнисе больницада чакта көн аралаш аның янына барып торды, өйдә чакта — карашты.

Әкренләп, сиздерми генә, каенана кайчан ятканын-торганын, ни ашаганын-эчкәнен белмәс хәлгә килде. Ул бары тик бер генә нәрсәне уйлый, күрә, белә иде: Кама аръягындагы Мәүләшә авылын, зират очында инешкә арт белән утырган иркен, агачлы ихатаны, яшел чирәм үскән урамны һәм шунда каз бәбкәләре көтеп йөргән уналты яшьлек кызны — үзен. Аның бөтен омтылышы, бар хыялы бер ноктага төбәлде: Мәүләшә авылының зират очындагы яшел чирәмле, өянкеле ишек алдына кайтып китәргә. Инде ул ихатаның нигезе үк әллә кайчан юкка чыкканын, авылның бар халкы биш ел элек күрше Баекка күчеп утырганын, Мәүләшә урамнарында хәзер шикәр чөгендере үсә торган иркен басу җәелеп ятканын Сабира карчыкның илле елга кире киткән зиһененә бернинди чара белән дә сеңдерү мөмкин түгел иде. Күп еллар шофер булып эшләп, бандитлар тарафыннан үтерелгән ирен дә, суга батып үлгән улын да, үзе кичергән кайгыларын да онытканиде ул.

Аның Эльвирныкына охшаш күзләреннән мөлдерәп сабыйлык, риясызлык, ялвару карап тора иде. Һәм ул күзләрне күргән саен, кызганудан Зуфирәнең йөрәге сызланып куя иде.

Баектагы туганнарына кайтарып карадылар — анда тора алмады карчык, кар дими, яңгыр дими, көнне-төнне белми, киенеп-нитеп тормый, ишек-капкаларның ачык чагын туры китердеме, кояш чыгышына таба күз тотып, Мәүләшәсен эзләп китә икән ул. Туганнар: «Моннан ары үз өстебездә тота алмыйбыз, чыгып китәр дә, катып үләр, гөнаһысы безгә булыр, аны гына карап торыр кешебез юк», — дип хәбәр җибәрделәр. Эльвирның маңгае җыерылды, иреннәре кысылып, шома яңакларында чокырлар урынына буразналар ярылып керсә керде, әмма зарланырга кыймады, алып килде әнисен.

Тагын больницага салдылар карчыкны. Ләкин анда барган саен: «Кайтасым килә, кайтарыгыз инде!» — дип үзәк өзгеч ялваруы белән Зуфирәнең җанын актаргандай итә иде ул.

Зуфирә күп уйланды. Бер кыйсса исеннән гел чыкмый иде. Бер адәм картаеп хәлсезләнгән атасын крокодилларга ашатырга сөйрәп бара икән. Артыннан кечкенә улы йөгереп килә, ди, моның. «Әй син нишләп йөрисең?» — дип сораган аннан әтисе. «Син картайгач, сөйрәп илтәсе юлны карап кайтасым килә», — дип җавап биргән аңа улы.

Алып кайтты Зуфирә карчыкны, Эльвирга каршы килеп алып кайтты.

Ләкин «Өйгә кайтам!» — дигәндә, Сабира карчык кала квартирын түгел, ә үзенең Мәүләшәсен күз алдына китерә иде, билгеле. Ул ак яулыкка тегене-моны салып чыга да китә, әллә ничә тапкыр аны шаушулы шәһәр урамнарында каңгырып йөргән җиреннән көчкә эзләп таптылар.

Карчык белер-белмәс газ кабызып, бәла-каза чыгармасын тагын дип, Зуфирә кухня ишегенә йозак ясаткан иде. Аңа Халидә каршы килде. Ул әбисен яклый башлады, чирле карчыкка карата аз гына салкынлык яки гаделсезлек булганын сиздеме, кызы шундук чәчрәп чыга

иде. «Нишләп син аны бүлмәдә бикләп асрыйсың? Кеше бит ул, хайван түгел!» — диде ул әнисенә кухня ишеген бикләгәч. «Син мәктәптә, мин эштә, кайтып керүебезгә янып я газга тончыгып үлеп куйса, нишләрбез?»

Урын өстендә яткан хастаны карау мең тапкыр җиңелрәк. Сабира карчыкның зиһене ни чаклы зәгыйфь булса, тазалыгы шул хәтле яхшы иде. Чыгып китәм дип талпына башласа, Зуфирә аны үзе генә тыеп тора алмый иде. Бәхетенә каршы, ул карчыкның бер нечкә кылын тапты. Бер көнне ишектән керүгә: «Кызым, син өйдәме?» —дип сораган иде, шифоньер артындагы караватын шыгырдатып, Сабира карчык урыныннан кузгалды: «Монда, мин монда», — диде ул әнисенә җавап биргән бала шикелле. Шуннан соң карчык киреләнә башласа, Зуфирә аңа: «Кызым, тыңла әле сүземне!» — ди торган булды. Тик бер шарты бар иде: Халидәгә дәшкәндәй яратып, ягымлы итеп һәм аналарча таләпчән әйтергә кирәк иде бу сүзне. Юри генә әйткәнне тыңламый, ялганны сизә иде карчык.

Борынгы греклар болай дигәннәр: «Әгәр аллалар адәм баласын җәзаларга теләсәләр, алар аның зиһенен алырлар». Бу очракта исә әйтемне болай дип тулыландырырга кирәк иде: «Әгәр ходай тәгалә кешене иң зур газапка дучар итәргә теләсә, ул аннан зиһенен чуалткан кешене еллар буе тәрбияләтер».

Белә иде микән Сабира карчык үзенең ни чаклы бәхетсез икәнен, аңлый иде микән үз фаҗигасен? Аңламый иде бугай ул аны. Карчыкны бары тик бер генә нәрсә ашкындыра, борчый иде: кайтырга Мәүләшә авылына, үзенең уналты яшьлек чагына кайтырга. Кайчак, сирәк кенә, Зуфирә аның кулларын-битләрен юганда, карчык кинәт аңына килгәндәй була:

«Син минем киленем бит!» — ди, күзләре ачылып, нурланып китә, ләкин шунда ук бәбәкләре тагын сәламәт кешедә булмый торган тоныкелтыравык пәрдә белән каплана, карчык тагын ярты гасырга кире китә иде.

Бик авыр сынау булды алар өчен Сабира карчыкның бу чире. Эльвир өйгә соңарыбрак кайта башлады, аннары кичләрен ресторанга эшкә йөри торган булды. «Акчасы булыр, — диде. — Ә өйдә минем ярдәмем күпме генә. Барыбер әни миннән курка, кача».

Төн урталары узгач кына кайта иде дә, ут та яндырмыйча чишенеп, авызыннан хәмер исе аңкытып, урын өстенә менеп ята иде.

Ул вакытта Зуфирә Эльвирның хыянәте турында, Румия турында уйламаска тырыша иде. Бер мавыгу, юләрлек кенә булгандыр ла ул мөнәсәбәт дип тынычландырырга тырышты ул үз-үзен. Ләкин үтә торган гына түгел иде өйдәге көйсезлек һәм Эльвир бу көйсезлектән котылып торырга җай чыкканда аннан баш тарта торган кеше түгел иде. Әгәр дә ул үз бурычын үтәү юлында бөтен кыенлыкларны җиңә торган көчле ихтыярлы һәм чын намуслы кеше булса, музыка өлкәсендә югалып калмас иде. Сәләтле иде бит ул! Нихәл итәсең, бер Эльвир гына түгел, сәләтле кешеләр күп, ләкин күбесе югалып кала.

Зуфирә хәзер Эльвир белән «Кармен» арасындагы хәлләрне аерма-чык күз алдына китерә. Менә Эльвир эч пошканнан тагын буфетка керә. Болай гына, бераз тамак чылатып чыгар өчен генә. Ә прилавка артыннан аңа утлы, ымсындыргыч күзләре белән елмаеп «Кармен» карап тора. Эльвирдамы соң инде ул карашка каршы торырлык ихтыяр? Зуфирәнең бәлки боларны белмәве хәерлерәк булыр иде. Ләкин андый эш беленми каламы соң?

Бердәнбер көнне иренең костюмын чистартып азапланганда, кесәсеннән Румиянең паспорты белән сатучы таныкнамәсен табып алды ул.

Гадәттәгечә Эльвир өйдә юк иде һәм аның кайчан кайтасы да мәгълүм түгел иде.

Зуфирә янә теге таныш панель йортка китте. Ишек ачылып, тузгыган чәчле «Кармен»нең ут чәчеп торган күзләрен, алтын тешләрен күрүгә, Зуфирәнең үз иренә, язмышына, үзенең көчсезлегенә, чарасызлыгына булган бар ачуы ургылып чыкты, ул үз-үзен тыя алмыйча, кулындагы паспорт белән катыргы таныкнамәне оятсыз күзләргә томырды:

— Кая куйган идең син боларны, әйт, кайда калдырган идең?

Румия бу кадәресен көтмәгән иде, чигенергә дә җай юк, артта тар коридор, ә өйгә кереп үзен фаш итәсе, тавышны зурга җибәрәсе килми иде, күрәсең. Ул, ике кулы белән битен каплап, почмакка сыенды. Эчтән аның ире килеп чыкты.

— Син дә йөрисең шунда, мин ир дип, җебегән!

Ир кеше җавап бирмәде, якынрак килеп, Зуфирәне беләгеннән эләктереп алды. «Я, булды, җитте...» Аның саңгырау, хәтта бераз битараф тавышы Зуфирәне айнытып җибәрде. Кечкенә, арык булса да, кулында гайрәт бар икән, эһ дияргә ирек бирмәде, беләгеннән ныклап тоткан килеш, баскычтан алып төшеп китте.

Алар йорт каршындагы эскәмиягә чыгып утырдылар, ир кеше кесәсеннән тәмәке алып кабызды, тирән итеп суырды. Гаҗәпләнмәгән иде ул, ни булды дип төпченергә дә исәбе күренми иде. Үзе бу юлы да погонсыз гимнастеркадан.

— Мәзәк кеше икәнсез сез, — диде, ниһаять, ир кеше. Аның күзләре бу юлы яраланган ат кебек түгел, ничектер көлемсерәп, хәтта Зуфирәне хуплап карый иде.

Аяк астында коелган өрәңге яфраклары кыштырдаша, салкынча җил ир кешенең сирәгәйгән аксыл чәчен мамык кебек тузгыта иде. Зуфирә сары яфраклардан такыя үреп кигәнен, суга карап үзенә, үзеннән дә бигрәк Эльвирга сокланган чагын исенә төшерде. Аңа салкынча булып китте, ул җилбәгәй җибәргән плащының чабуларын җыйды.

— Ә бәлки мин түгел, син үзең мәзәк кешедер? Нинди ир инде син! Хатының башкалар белән типтерә, ә синең исең дә китми!

— Күнектем инде. Өч ел буена ничек күнекмисең...

— Ничек шуны әйтергә телең бара? Ир башың белән ничек чыдыйсың?

Ир кеше тагын тирән итеп тәмәкесен суырды да, Зуфирәгә карамый гына:

— Сез ничек түзәсез соң? — диде. — Сезнең урында булсам, мин, мәсәлән, бер көн дә болай яшәмәс идем. Хатыннарга нәрсә, балалары үзләре янында кала, алимент алар кесәсенә тама, закон алар ягында, квартир аларга...

— Нәрсәгә сезгә квартир! Әгәр мин сезнең урында булсам, ул хатын белән бер һаваны суларга да риза булмас идем!

— Ә нишләр идегез?

— Китәр идем! Җир читенә олагыр идем!

— Ә нигә китмисез соң? Кем тота сезне? Балагызны алыгыз да китегез! Ә мин китә алмыйм, китсәм, бала аның кулында кала!

Зуфирә әйтергә сүз тапмады.

— Йодрык болгау ансат ул, — дип дәвам итте ир кеше әкрен тавыш белән. — Кешегә акыл өйрәтү дә кыен түгел. Әле менә узганында үзегез дә бик батыраеп килгән идегез, авыз ачып сүз дә әйтә алмадыгыз, борылып китеп бардыгыз бит.

— Мин сезне кызгандым ул чакта.

— Без икебез дә бер үк дәрәҗәдә кызганыч инде. Ә бәлки сез кызганычрактыр да әле. Чөнки мин бала хакына чыдап яшим. Минем акланыр чутым бар...

— Ю-ук, мин кызганыч түгел, кызганыч түгел! — дип сикереп торды Зуфирә. Әмма бу сүз әйтелгән иде инде. Юл буе теге ирнең «кызганыч, кызганыч» дигәне аның чигәсенә бәреп баргандай булды.

Һәм Зуфирә шул кичне бунт күтәрде.

Халидәсе иптәш кызына күлмәк тегешергә китте — кызга убиш яшь иде инде һәм ул тегәргә оста иде. Зуфирә Казанда әле беркем өстендә күренмәгән,боргаланып тегелгән, җирдән сөйрәлеп йөри торган сары юбка, аның өстеннән челтәрле ак кофта киде, күзләрен шәмәхә пыялалы зур шакмаклы күзлек белән каплады, плащын иңенә генә салды да, караватта, үз урынында яткан Сабира карчыкның өстеннән биклэп, «Аккош» ресторанына китте.

Ресторанның зур гына сәхнәсендә ыспай егетләр күзне чагылдырып ялтыраган барабаннарда, башка коралларда уйный, аларның уртасында, ахак аккордеонын күтәреп, Эльвир басып тора, ә оркестр артындагы пыяла экранда төсләр айкала иде.

Зуфирә, оркестрны күрмәгәндәй, өстәлләр арасыннан түргә узды, берничә урында ирләр урыннарыннан торып, аны үзләре янына: «Рәхим итегез!» — дип чакырдылар. Әмма Зуфирә урын сайлаган иде инде: түр почмактагы өстәл янында өч ир-ат утыра, яннарында хатын-кыз заты юк, бер урын буш, ә алларында ярым бушаган шешәләр, тәлинкәләр тезелеп тора.

Ул килеп баскач, өлкәнрәге, кызарган киң чырайлы, сары мыеклы, юан муенлы абзый, мөгаен, авылдан килгән берәр начальниктыр, авыр итеп кенә урыныннан кузгалды да: «Әллә урын эзлисезме, туташ? — дип сорады. — Әгәр үзегез генә булсагыз, рәхим итегез, утырыгыз».

Зуфирә тезен тезгә чәнчеп утырды.

Каршысындагы кечкенә чырайлы, зур күзлеге астыннан борын очы белән ияге генә тырпаеп торган, керләнгән якалы кешегә дәште:

— Гафу итегез, сигарет белән сыйламассызмы?

Тәмәке кабызып, түтенен югарыга, ак түшәм тишекләреннән карап торган төсле лампочкаларга өрде, сәхнәгә күз салды. Менә Эльвир кулына микрофон алды, йөрәккә мамык кебек ята торган йомшак тавыш белән: «Хөрмәтле кунакларыбызның үтенече буенча» — дигән булып яңа җыр игълан итте. Аннары микрофонның таягын үз буена җайлап озынайтты да кереш уйнады һәм, башын артка ташлый биреп, микрофоннан ерак китмичә җырлап җибәрде:

Үкенмимен инде, сыкранмыймын,
Ак чәчәкле язны дәшмимен,
Бар да үтте, алтын көзем җитте,
Кире кайтмас инде яшьлегем.

Аның ягымлы баритон тавышы микрофон аша көчәеп, бөтен залны биләп алды, күрше күршесен ишетмәс булды. Күңелгә ятышлы бу тавыш көйнең дә бөтен бормаларына керә иде. Ләкин иң кирәк җирендә нидер җитми, көйнең әйтеп бетереп булмый торган нечкә моңы, аркаларны чымырдатып, кешене ашкындыра торган бер көче юкка чыга иде. Нишлисең, җырда да, тормышта да шул «чак-чак» дигән нәрсә җитмәде Эльвирга... Хәер, ресторанга тәннәрне чымырдата торган көй тыңларга килми кеше. Эльвирның җырын, Зуфирәдән кала, күңел биреп тыңлаучы да юк иде. Берәүләр сикерешеп оркестр каршындагы мәйданчыкка чыктылар да, кем ничек булдыра ала, кем ничек тели, шулай сикеренергә, боргаланырга керештеләр. Икенчеләре исә, колак тондыргыч җыр, барабаннар дөбердәве, трубалар чинавы, аккордеонның кычкыруы аша, күршеләр белән өзелгән сүзне дәвам итәргә азапландылар.

Барысы да кызганнар, барысы да үзләрен көчле, әллә нәрсәләргә сәләтле һәм тәвәккәл итеп тоялар иде. Салават күпере биегән киң

экран алдында биеклектә басып торган озын, төз сынлы, эре сөякле, ак йөзле җырчы аларга бу эштә фатихасын бирә, моның белән генә туктап калмаска, тагын да татлырак ләззәткә омтылырга өнди иде. Чөнки аның җыры яшьлекнең кыскалыгы, мәхәббәтнең сагышы, бу дөньяда тулы бәхетнең юклыгы турында сөйли иде. Ахыр килеп һәркем күңелендә бер теләк туа: мөмкин булганны ычкындырмаска!

Ирләр Зуфирә каршына өч яктан өч бокал суздылар:

— Нәрсә эчәргә телисез? Акнымы? Коньяк? Шампанский?

Зуфирә аларның майлы күзләренә, чиксез соклануны, кызыгуны чагылдырган йөзләренә карап, эчтән генә көлемсерәп куйды.

Ул кулына бокал алып, юри Эльвирга күренерлек итеп күтәрде.

Җыр төгәлләнде, трубалар, барабаннар тынды, салават күпере боргаланган хәлендә, имгәнгән килеш хәрәкәтсез туктап калды, оркестрантлар, инструментларын куеп, сәхнәдән төштеләр — тәнәфес башланды. Эльвирның үзенә таба килгәнен күргәч, Зуфирә бокалын каршында утырган ирләргә таба сузды:

— Ягез, танышу хөрмәтенә!

— Бик рәхмәт, сезнең исәнлеккә!

Ләкин эчеп өлгермәделәр, Эльвир Зуфирәне күзләре белән йотардай булып утырган юан абзыйның иңенә кулын салды.

— Әз генә читкәрәк шуышыгызчы!

— Ә? Ни булган? Ни кирәк сезгә?

— Сездән берни дә кирәкми. Хатын белән бер-ике авыз сүз сөйләшәсе бар иде.

Юан абзый тәмам аптырап һәм куркып урыныннан торды. Эльвир утырды, абзыйны аркасы белән каплап, хатынына:

— Типтерәбезме? — диде.

— Син көн саен типтерәсең бит әле. Әллә миңа ярамыймы? Әйдә, икәүләшеп типтерәбез моннан ары!

— Бурычка эчәсеңме?

— Булса ни?

— Ә ничек түләрсең?

— Анысы минем эш!

Эльвир Зуфирәнең күзлеген тартып алды, аның өскә бөгелгән кара керфекләре арасыннан яшькелт нур бөркелде һәм бу нур күңелнең иң тирән почмакларын яктырткандай итте. Ир Зуфирә йөрәгендә һич тынмаган борчуны күреп алды.

Әтәчләнеп, кыланып, башсыз хатынга салышып утырган Зуфирәнең вөҗданында нинди ут янганын аңлап алды Эльвир.

— Ярый алайса, типтер, җаны теләгән елан ите ашаган!

Ул кире китеп барды. Зуфирә, елмаеп, тагын бокалын күтәрде:

— Әйдәгез, танышу хөрмәтенә эчәбез дигән идек бит!

Әмма өстәл тирәсендәге ирләрнең чырае үзгәргән, алар, айнып киткәндәй, Зуфирәгә куркып, шикләнеп карыйлар иде. Юан абзый нечкә тавыш белән:

— Без андый уеннарга катнашмыйбыз, сеңелкәш, — диде. — Син моннан күчеп үк утырсаң әйбәтрәк булыр. Киләсе кешебез дә бар безнең... Занятый бу урын.

Зуфирә кузгалып чыгып китмәкче иде. Ләкин торып басарга өлгермәде, кемдер аның беләгенә сак кына кагылды. Сыек гәүдәле яшь кенә бер егет икән. Биергә чакыра.

Сәхнәдә яңадан оркестр сиптерә, Эльвир җырлый иде. Зуфирә биючеләр арасына егет белән кара-каршы чыгып басты. Ничек боргаланасыкерә алса, шулай кыланып, кулларын өскә күтәреп биеде ул. Аның каршына әле бер егет, әле икенчесе килеп баса. Зуфирәнең хәрәкәтчән, ыспай гәүдәсенең бөтерелүе, салам төсле чәчләренең сибелүе, агарынган йөзендәге ярсу — бөтенесе Эльвир өчен иде: кара, күр, мин дә мон-

дагыдан ким түгел, әгәр теләсәм, бөтенесенең күзен шар итә алам, барысыннан уздыра алам! Сәхнәдә төсләр бии, тирә-якта картлар, яшьләр, чибәрләр, чибәр булмаганнар сикерешә, һавада ниндидер чиркандыргыч сөрем йөзә, ә сәхнә уртасында басып торган күк костюмлы чибәр аккордеонист өздереп уйнаган көеннән башка берни күрми, ишетми инде шикелле...

Көй тәмамлануга, Зуфирә ишеккә юнәлде, сыек гәүдәле егет аның артыннан иярде. Зуфирә киенгәндә ул да киенде, аның артыннан иярең чыкты. Эльвирга үч итеп, Зуфирә аны троллейбус тукталышына кадәр янынннан кумады. Бары шунда гына борылып:

— Ә син, энекәш, кая барасың? — диде. — Кара аны, хәзер ирем килеп җитәчәк, миннән ераграк тор.

Өй ишеген ачкач, әчтән тавыш-тын ишетмәгәч, ул шомланып: «Кызым, син өйдәме соң?» — дип сорады. «Монда мин, монда, алырга килдеңмени?» — дип, караватын шыгырдатты шифоньер артында каенана. Зуфирәгә Сабира карчык белән икесенең язмышлары уртак сыман тоелды: аларның икесен дә ташладылар, кызганмадылар. Ул хәлсезләнеп ишек яңагына сөялде. Халидә икенче бүлмәдә йоклый икән, йокысыннан уянып сикереп торды, ялан аяк әнисе янына килде:

— Ни булды, әни? Әллә авырыйсыңмы?

— Кызым, — диде Зуфирә, — моннан соң без әтиең белән бергә яшәмәбез инде. Ник дип сорама, үскәч барысын да аңлатырмын.

Халидә сорарга җыенмады да. Ул әтисенең гомумән йорттан читләшкәнен күптән тоеп яши иде.

Зуфирә кызын янына яткырды. Халидәнең кайнар тәне, татлы сулышы аның күңелен юатты, уйларын бер җепкә тезәргә көч бирде. Зуфирә бер нәрсәне бик яхшы аңлады: ул күпме генә тырышса да, хәзер инде Эльвир белән алар чын күңелдән яратышып, бер-берсенә ышанып һәм ихтирам белән яши алмаячаклар. Аларның мөнәсәбәтендә нәрсәдер өзелде, аны ялгау мөмкин түгел.

Шул көннән ул үзен ялгыз хатын дип күңеленә беркетеп куйды. Бар нәрсәне үзенчә хәл итә торган булды, тормышны үзе алып барды. Эльвирдан акча да сорамый иде, китап-журналларга рәсем ясый, аны сы булмаганда теләсә нинди эшкә алына: стенгазета ясарга да, лозунг язарга да. Берничә тапкыр Казан тирәсендәге колхозларга барып авыл урамнарына куяр өчен плакатлар да ясап кайтты. Алар Халидә белән икесе дә өс-башларын менә дигән итеп үзләре тегеп кияләр, өйгә әллә ни кирәк түгел, — кыскасы, акча җитә иде. Тик бу вак-төяк заказлар чын иҗат эшенә омтылган художник өчен зыянлы иде, билгеле: алар вакытны, көчне ала, кулны боза иде. Ләкин нишлисең, дип уйлый иде Зуфирә, ялгыз хатынның язмышы шул инде...

«Мин синең белән бүтән яшәмәячәкмен!» — дигәч, Эльвир башта иреннәрен генә кыйшайтып куйды. Ләкин көннәр үтә торды, алар бик аз сөйләшәләр, аерым йоклыйлар иде. Тора-бара болай яшәүнең гадәткә керә барганын һәм араларның ерагайганнан-ерагайганын сизеп, Эльвир бер-ике мәртәбә хатыны белән ныклап аңлашырга омтылыш ясады, элекке чараны искә төшереп, аккордеонын да уйнамакчы булды, ләкин Зуфирә аның сүзен тыңламый, ишеткәненә җавап бирми, ә аккордеон тавышы Сабира карчыкны куркыта иде.

Шулай аралар тәмам суынып киткәч кенә, аларның квартир чираты килеп җитте. «Мин синең белән яңа квартирга чыкмыйм», — диде Зуфирә иренә. «Үзегез генә чыгарсыз алайса», — диде Эльвир тыныч кына, һәм, чыннан да, артык ялынып тормады, киемнәрен генә алды да, Румиясе янына күчеп китте. Теге гимнастеркалы ирнең сабыр төбе сары алтын булып чыкмады, ничаклы сабыр итсә дә, ярый алма-

ды, чыгып китәргә мәҗбүр булды, Эльвир анын урынына йортка керде.

Яңа квартирдан өлеш дәгъваламавы һәм әйбер-мазар алмавы белән Эльвир үзенең вөҗданын тынычландырды. Ул чыгып китеп Зуфирәләр күченгәндә, Сабира карчык больницада иде, яңа йортка урнашып җитәр-җитмәс борын Халидә: «Әни, әбине алып кайтыйк», — диде.

Фәрештә түгел иде Зуфирә, ул каенанасының чирен сүзсез-авырсынусыз гына кичерде дип әйтеп булмый. Эшендә таныш укытучылар белән сөйләшкәндә дә, журнал редакцияләрендә дә карчыктан зарланып сөйли иде, гөнаһысы булды. Сөйләгән саен үзе дә аптырап: ничек түзәм икән, нәрсә хакына шундый газапларны үз иркем белән өстемә алдым икән, дип гаҗәпләнә, кайвакыт, карасын яшь хатын каенанасын дип кызып китә һәм шул ук көнне карчыкны Румия өенә илтеп куймакчы була иде. Ләкин өйгә кайтып: «Кызым!» дигән сүзгә Сабира карчыкның: «Мин монда», — дип мөлдерәп караганын күргәч җаны эри, аны әллә кемнәрнең ишек төбендә интектереп йөртә алмаячагын аңлый иде.

Карчыкның хәле тәмам начарайды. Төннәрен бик тынгысыз йоклый, ул уянган саен Зуфирә уяна алмый, йокы баса иде, шуңа күрә, каенана төнлә кая да булса чыгып китеп каңгырап йөрмәсен, я өйдә берәр бәла-казага тармасын өчен, Зуфирә караватта түгел, Сабира караваты янында, идәндә, аяк астында йоклый торган булды. Карчык урыныннан кузгалды исә, өстеңә баса, сикереп торганыңны сизми дә каласың.

Бер уянып, йокыны качыргач, күзләр йомылмый аптырата, башка әллә нинди уйлар кила. Зуфирә, эченнән генә, янындагы караватта авыр сулап, саташып йоклаган карчык белән сөйләшә. Карчыкны уяу итеп, үз акылында итеп күз алдына китерә ул.

«Менә син гомер юлыңны тәмамлап киләсең инде, әни. Әйт әле, сагынып искә алырлыкниләр эшләдең син бу дөньяда?»

«Минем яшьлегем...»

«Тукта, яшьлегең турында сөйләмә, хәтереңнән чыккан ярты гасыр турында сөйлә син миңа».

«Гомеремнең иң матур, иң гайрәтле чагында этиеңне карап өйдә тордым. Аны озатып калдым, каршы алдым...»

«Кеше үзенә тиң башка берәүне карар-тәрбияләр өчен генә киләмени бу дөньяга, әни! Тормышыңның мәгънәсе шуның белән генә чикләндемени?!»

«Атагыз мине туган ягымнан аерып алып китте. Үзенең эше авыр иде, ә минем кулымда һөнәрем юк иде. Ул сугышта чакта госпитальдә эшләгән идем дә бит, ул кайткач, тагын өйдә генә тора торган иттем. Ике бала да бар иде бит әле... Икесе дә ир балалар...»

«Әмма син улыңны намуслы кеше итеп үстерә алмагансың, әни! Ул сине дә, мине дә, хәтта баласын да кызгана белми.

Ир баланың анасына йөз мәхәббәте була, шуның туксан тугызы — хатынга, берсе балаларга күчә, ди халык. Кая соң Эльвирның сиңа булган йөз мәхәббәте? Алар синнән китте — безгә күчмәде. Кая чәчкән аларны Эльвир.»

«Олысы бик тәүфикълы, бик игелекле бала иде дә бит, гомере кыска булды, һич уйламаганда харап булды балакаем. Әле атагызны җирләгәнгә ел да узмаган иде... Ничек чыдагандыр бу йөрәк ул кайгыларга...»

«Чыдамаган шул, әни, чыдап бетерә алмаган...»

Шулай уйланып ята торган иде Зуфирә каенанасының аяк астында. Аннары үз тормышына борылып карый да: «Ә мин үзем, кырыкка җитеп, ни эшләдем соң әле?» — дип үзеннән сорау ала башлый иде.

Ул караңгы, төпсез билгесезлектән кыска вакытка гына җиргә килгән, гомер су кебек ага, аның инде яшәгән хәтле дә яшисе калмагандыр, ул бераздан тагын кире билгесез караңгылыкка китәр, юкка чыгар. Ә ул гомереннең чагылышын гына булса да кешеләргә калдыра алыр иде бит югыйсә, үзе кылган хаталардан башкаларны кисәтеп, үзе кичергәннәрнең сабагын биреп, үзе аңлаган матурлыкка аларны да инандыра алыр иде һәм аның хисләре үзеннән соң да озак вакыт җирдә яшәр иде. Табигать аңа моның өчен шундый зур мөмкинлек — сәләт биргән, ә ул бу зур бүләкне файдаланмый, үзе белән бергә кара гүргә алып китмәкче!

Иртән Зуфирә редакцияләргә ашыга, заказлар ала, үзе өчен акварельләр яза иде. Соңгы вакытта аның берничә эше — балерина, җырчы сурәтләре, әкиятләргә ясаган рәсемнәре республика художниклары күргәзмәләренә куелды.

Ләкин Зуфирә үзе моңа гына һич тә канәгать түгел иде.

Һәр газапның ахыры була, Сабира карчыкның интегүләренә дә бер чик килде. Кыш башында ул, ниһаять, дөнья куйды.

Аны күмеп кайтканнан соң, Зуфирә, ниһаять, бер җиңеллек кичерергә тиеш иде кебек. Ләкин алай булып чыкмады. Беренче атналарны бик кыен булды. Үлем җиленең өйгә керүе кеше күңеле өчен авыр нәрсә икән. Төннәрен кинәт сискәнеп уянып китә, аннары үзенең инде идәндә түгел, караватта ятканын абайлап, өйдә бер бушлык сизә иде Зуфирә. Көндез редакциягә яки нәшриятка барган чакларында, күнегелгән гадәт буенча, тизрәк эшен бетереп, өйгә кайтырга ашыга, бераздан гына аңына килеп: «Бәй, кая кабаланам болай? Ул юк бит инде»... — дип уйлап куя һәм бу уй аны тынычландырудан бигрәк сагышландыра гына иде. Сабира карчык — Зуфирәсез дөньяда яши алмый торган бер җан иясе иде. Ә бездән башка яши алмаган кешеләр кирәк бу дөньяда, ай кирәк алар...

*
* *

Хәер, әнә тагын берәүгә кирәк бит әле Зуфирә. Әлеге дә баягы шул Эльвирга. Әнә, тагын ишекне ачты, бүлмәгә үк бер-ике адым атлады. Керми генә тор әле! Зуфирә караватны каты шыгырдатып әйләнде, кызын уятты: «Җайлабрак ят әле, кулым оеды».

Эльвир тагын шым булып чыгып китте.

Ул да кырыгын узып бара бит инде. Төннәрен берүзе уйланып ятканда, вөҗданына ни дип аңлата икән узган гомеренең мәгънәсен? Үзенең ярдәменә, мәхәббәтенә мохтаҗ өч кешенең — кызының, хатынын, әнисенең берсенә бер игелек күрсәтмәвен, бары тик газаплар гына китерүен ни белән аклый икән? Тормыш ыгы-зыгысыннан котылырга тетләп, башларын мингерәйтеп, эчләрен бушатырга дип ресторанга килгән кешеләрнең күңелен ачтым, дипме? Ике хатын арасында буталып йөрдем, дипме?

Ә бит дөньяда бөтенләй башкача, ашкынып, ярсу белән, мәгънә белән яшәп була. Бар бит алай яшәүчеләр.

Өмит, мәсәлән.

Аларның кыяфәтенә бер караудан ук башкалардан аерып куясың.

Һәрхәлдә, Зуфирә аны бер күрүдә хәтеренә сеңдереп калган иде.

Узган елның август аенда, инде Сабира карчык хәсрәте бераз тынгач, Зуфирә Кара диңгез буена, Анапага барырга кузгалган иде. Халидә спорт лагеренда, Зуфирә ялгызы, кая барса да, нишләсә дә үз кулында, өйдә ни бар икән, дип борчылып торасы юк. Мондый иркенлекне аның беренче тапкыр кичерүе иде әле.

Кечкенә чемоданы белән этюднигын күтәреп, аэропортка барып утырды. Ялгыз хатынның язмышы бер: китсә — озатучысы, кайтса — каршы алучысы юк. Кадерле кешеләрне генә үбеп озаталар, кочак-кочак чәчәкләр күтәреп каршы алалар.

Билетын регистрацияләгәндә Зуфирә бер диңгезче артында туры килде. Зәңгәр китель җиңенә өч сары тасма — шеврон тегелгән иде. «Капитан», — дип уйлады Зуфирә. Уртача буйлы, хәрәкәтчән, нык гәүдәдә хәрби форма гадәттән тыш иплe утыра иде. Яны белән басып торганда, Зуфирә аның фуражка астыннан үткен караган зәңгәр күзләрен күреп алды. Бу карашы аның пөхтә итеп кырылган, нык иякле кырыс йөзен яктыртып, аңа мөлаемлык өстәп тора иде. Үзен бик иркен, тыныч тота, олы юл алдыннан алгысауның эсәре дә анда сизелми, урыннан-урынга күчеп йөрү аның өчен гадәти хәл иде булса кирәк.

Ул ялгызы түгел иде. Саргылт кримплен пальто кигән, чал чәчен бөдрәләткән, ябык кына бер апа белән иде ул. Чемоданын тапшырып, билетын регистрациягә биргәч, диңгезче, чал апаны култыклап алды да, аңа иелә төшеп, елмаеп, нидер сөйли-сөйли читкәрәк алып китте. Ул тузан бөртеге дә кунмаган ялтыравык ботинкалары белән идәнгә нык басса да, адымы җиңел иде.

Самолетта аларның урыны рәттән туры килде. Диңгезчеләр фуражкасын салгач, аның шома итеп таралган коңгырт чәчләре чигә турыларында чаларып җемелдәп куйды. Ләкин бу аны тамчы да бозмый, киресенчә, аңа могтәбәр кыяфәт кенә өсти иде. Зуфирә аның янында үзен кечкенә кыз шикелле хис итте.

Менә диңгезче стюардесса күтәреп килгән подностан пластмасса стакан алып, Зуфирәгә сузды: «Эчәсегез киләме? Рәхим итегез!» Аның тавышы калын иде. Капитаннарның тавышы диңгез җилләре белән көрәшеп, тозлы һавада чарланып, карлы-бозлы давылларда чыныкканга күрә, бераз карлыккан булырга тиеш дип уйлый иде Зуфирә. Юк, моның тавышында карлыкканлык сизелми, ләкин чын ирләрчә калын һәм көчле иде ул.

Зуфирә аңа рәхмәт әйтеп: «Сез Мәскәүгә хәтле генәме?» — дип сорады. «Юк, арырак, Камчаткага». — «Ә нигә соң кире якка очасыз?»— «Мәскәүдә йомыш бар. Аннары аннан туры рейс белән очу уңайрак».

Сүз шунда өзелде. Диңгезче Зуфирәнең кая баруы белән кызыксынмады, газета алып укырга кереште.

Мәскәү аэропортында чемоданнарын бирми шактый озак тоттылар, йөк ташучылар җитеп бетми икән.

Ниһаять, әйберләрне алгач, Зуфирә аптырап калды. Инде кая барырга, ничек төн үткәрергә? Башкалада танышлары юк, гостиница эзләп йөрергә дә соң. Зуфирә, нишләргә белмичә, тоташ пыяла стеналы, биек түшәмендә йолдызлар кебек бихисап лампочкалар янып торган шәһәр хәтле зур аэровокзалны күздән кичерде.

Капитан аның хәлен аңлап алды булса кирәк: «Сез хәзер кая барасыз?» — дип сорады. «Мин иртәгә иртән очам, Көньякка». — «Ә аңарчы?» — «Монда урын җитәрлек». Зуфирә мәйдан кебек иркен зал уртасына тезелгән кара күн тышлы утыргычларга ымлады.

Капитан бераз икеләнеп калды. Казанда алар бер-берсенә бөтенләй чит кеше булсалар, монда — ят җирдә — алар инде күпмедер дәрәҗәдә үз кешеләр — якташлар иде. Ә якташны ярдәмсез калдыру гөнаһ эш. «Алайса, әйдәгез, — диде ул катгый итеп. — Гостиницага барабыз».

Җавап та көтеп тормыйча, Зуфирәнең кулыннан чемоданын алды да, артына борылып карамый-нитми, шәһәр ягына чыга торган пыяла ишеккә юнәлде.

Гостиницада капитан Гасимовка урын калдырылса да, Зуфирә өчен буш урын юк иде. Капитан аны урындыкка утыртты, янына чемодан-

нарны куйды да, автомат телефоннан каядыр шалтыратты. Ярты сәгатьтән Зуфирәгә дә ике кешелек бүлмәдә, бер хатын-кыз янына урын таптылар. «Инде тамак ялгарга кирәк булыр. Егерме минуттан әзер булырсызмы? Мин сезнең ишеккә орынырмын», — диде капитан.

«Кара, ничек командовать итә! Корабтагы матросыңмы әллә мин синең?» — дип уйлады эченнән генә Зуфирә.

Әмма үзе белеп тора: капитанның аның белән шулай сөйләшергә хокукы бар иде. Ул, бүлмәгә керү белән, парадка әзерләнгән матрос шикелле тырышып, капитан белән очрашуга әзерләнә башлады. Чемоданыннан үзе теккән озын юбкасын тартып чыгарды, җиң очлары челтәрле кофта киде, баш артына тыгызлап төеп куйган сары чәчен сүтеп, тарап, иңнәренә салды, сөрмә тартты.

Әмма Гасимов андагы үзгәрешне гүяки күрмәде дә. «Әзерме сез? — диде баягыча ук катгыйлык белән. — Нинди тәкъдимнәрегез бар?» Тәкъдим турында Зуфирә бөтенләй уйламаган иде. Тагын капитан сүзен тыңларга туры килде. «Ресторанга керсәк, ничек булыр?» — «Мин каршы түгел, иптәш капитан!» — дип матросларча кычкырып җавап бирде Зуфирә. Аның бу җавабында үртәү дә, үртәлү дә ишетелде. «Алайса, бөтен тизлеккә алга, егерме өченче катка!» — диде капитан, аның шаяруын күтәреп алып һәм җиңелчә генә, ирен читләре белән генә елмаеп.

Гөлләр, сурәтләр белән бизәлгән ресторан залы, зур булса да, котсыз киң булып тоелмый, чөнки һәр өстәл аулаграк итеп куелган иде. Метрдотель капитанны ишек төбендә үк каршы алып, баш иеп, түрдәге өстәл янына озатты: «Рәхим итегез, сезнең урын менә биредә». Кай арада барысын да җайлап өлгерә бу кеше дип эчтән генә гаҗәпләнде Зуфирә. «Сез әле монда да сөйләшеп куйган идегезмени?» — дип сорады ул капитанның үзеннән дә. «Әгәр дә корабның ярты сәгатьтән кая барып җитәсен алдан белеп тормаса, нинди капитан була инде ул? Безгә танышырга вакыт түгел микән? Минем исемем — Өмит». «Ә мин Зуфирә. Ялгышмагыз: Зу-фи-рә». «Моңарчы ишеткән юк иде». «Әни әйтә иде, фарсыдан кергән исем, дия иде».

Ашарга китерделәр. Зуфирә капитанның көчле, зур кулларында уй-
нап кына торган чәнечке-пычакларга карады. Бу зур һәм нәзакәтле,
һәм шул ук вакытта бәләкәй әйберләрне дә бик пөхтә тота белә тор-
ган кулларга сокланып утырды.

Капитан аның исемен генә сорады да, онытты кебек, күтәрелеп тә
карамый. Әнә оркестр уйнап җибәрде, әнә кешеләр биергә чыкты, ә ул
чәнечке-пычаклары белән тәлинкәсендә казына. Зуфирә кәгазь салфет-
ка алып, сумкасыннан бер кап фломастер чыгарды. Игътибар итми-
сеңме, мине хатын-кызга да санамыйсыңмы? Без дә төшеп калган-
нардан түгел! Менә сезнең миңа матроска приказ биргән капитан ке-
бек... юк, капитан түгел, боцман шикелле эре генә сөйләшкән чагыгыз!
Борын чөелгән, ияк гадәттәгедән дә ныграк тырпайган, киерелеп маң-
гайга күтәрелгән кашлар үзләре генә дә ни тора! Бусы булдымы? Ә ме-
нә бусы телефоннан сөйләшкән чагыгыз! Ай-яй, авыз ерык, ә? Таныш
начальник белән сөйләшәсезме? Йөздән бал тама, борын да алай оч-
ланмаган, ияк тә тырпаймаган... Менә бусы, кашны җыерып, чәнти
бармакны тырпайтып, тавык кисәген пычак белән ботарлап азапланган
минут...

«Нишлисез сез анда?» Зуфирә башын күтәреп, аңа ачыктан-ачык
көлеп карады. «Сезнең образны мәңгеләштерәм». «Бирегез әле!» Өмит,
җавапны көтеп тә тормыйча, салфетканы үзенә тартты. «Әһә, тешлә-
шә дә беләсезмени әле сез!.. Ә башкаларны ясый беләсезме соң?»
«Юк, — диде Зуфирә. — Мин бары тик сезне генә ясый беләм». «Юк,
чыннан да, әнә теге официантканы ясагыз әле».

Зуфирә, яңа салфетка алып, берничә сызык белән, шөпшә биленә таянып, тәкәббер кыяфәт белән каядыр карап торган кызны сурәтләде. Ул үзенә дә охшаган, ләкин, эрелеге белән, гаҗәп көлке дә иде. Өмит, ашавын онытып, Зуфирәгә таба иелде, эчке кесәсеннән блокнот чыгарып, чиста битен ачып салды. Һәм беренче тапкыр күзе кинәт ачылгандай, якташына кызыксынып һәм ихтирам белән карады. «Әйтегез әле, Зуфирә ханым, бу һөнәргә кайда өйрәндегез?» «Иң элек мич алдында. Тәпи басып, мич алдына барып җитә башлагач, күмер белән мичкә, стеналарга сызгалый идем. Аның өчен арт сабагымны шактый укыттылар һәм урамга, тузанга чыгарга туры килде. Соңрак кәгазьгә каләм белән ясап булганын ачыкладым». Өмит, Зуфирәнең аңлашылмас серен чишәргә теләгәндәй, кашын киереп карап торды-торды да: «Да, бирсә ходай бирә инде андый сәләтне, ходай бирмәгәнне тартып алып булмый, — дип куйды. — Ә менә мин гомер буе кызыктым, ләкин рәтле генә итеп балта сурәте дә ясарга өйрәнә алмадым». «Аның урынына мин менә техниканы аңлаудан гаҗиз. Шушы яшемә җитеп иттарткычның ничек итеп итне туравын аңлап җиткерә алмыйм». «Машинаны аңлау авыр түгел, аңа салкын акыл белән дә ирешеп була, ләкин менә бу, — ул әле генә Зуфирә ясаган рәсемгә төртеп күрсәтте, — ә бу хис, тойгы, йөрәк эше. Могҗиза бу!»

Капитан әле моңарчы аңарда сизелмәгән йомшаклык белән кызыксынып, Зуфирәнең тормышын, нәрсәләр эшләвен сораша башлады. Карашы ягымлыланды, җылынды... Юлда очраган кеше белән borгаланып маташуның мәгънәсе юк, андый чакта, ходай каршындагы кебек, иң яшерен серләреңне ачасың да саласың.

Зуфирә барысын да кыска гына итеп сөйләп бирде. «Өлкән буын каршында бурычымны тулысынча үтәдем, дияргә була, — диде ул үзалдына уйлангандай. — Кече буын каршындагы бурычны үтәү дә ялгыз башыма төште. Ясаган иллюстрацияләрем дә ярыйсы гына уңышлы чыга шикелле. Акварельләремне дә яратам. Ләкин барыбер эшлисе иң мөһим эшне башкара алмадым кебек, иң кирәген, иң тиешлесен шушы көнгәчә әйтә алмавыма борчылам. Эчемдә ут кайный, дөрләп янган учак кебек, шуның ичмасам бер очкынын да кәгазьгә төшерә алмыйча гаҗизләнәм. Каләмем көчсез, төсләр миңа буйсынмый... Кайчак шулай була бит: бер җырчының тавышы матур, бәрхет шикелле, ләкин аны тыңлаганда синең ләззәттән һәм аңлатып булмый торган татлы бер ямансулыктан тәннәрең чымырдамый... Иртәгесен син аның җырын көйләп йөрмисең. Менә мин дә төсләр ярдәмендә кеше күңелендә иң матур хисләр кузгатырга, аларны изге эшкә өндәргә теләр идем. Барып чыкмый, әлегәчә эчемдә кайнаган ут белән кешеләрнең йөрәген яндыра алмыйм». «Талант мәсьәләсенә килгәндә, сездә ул җитәрлек булырга тиеш,— диде Өмит уйланып.— Гади, җиңел тасвирлыйсыз бит кешеләрне! Андый осталык художникларның да сирәгендә генә була. Бәлки сезгә колач җитмидер? Кешеләргә тәэсир итү өчен үзең шул утларда янарга кирәк бит! Мәсәлән, мине акыл һәм хискә баету өчен сезгә миннән күбрәк колач белән яшәү кирәк!»

Зуфирә сораша башлады: ничек ул ерак диңгезгә йөрүче корабларның капитаны булуга ирешкән?

«Дөньяда диңгез дигән нәрсә барлыгын ишетүгә, шунда омтылды күңелем. Җәйләрен авылыбыздагы инештән чыкмый идем, су ярата идем.

«Миңа аңлашылып бетмәгән бер сер бу: ни өчен кешеләрнең күңеле әллә кайларга, читләргә тартыла икән? Бераүләр бит туган җиргә кендеге белән береккән була. Кызыксынып чит якларга китсә дә, сагына, саргая. Ни өчен икенчеләр, үз ирекләре белән әллә кайларга китеп, гомерләрен чит җирләрдә үткәрәләр икән? Менә, сез, мәсәлән».

«Аның серен сез, сәнгать кешеләре, аңлатырга тиеш инде. Мин үзем дә күп уйлыйм ул турыда. Бигрәк тә диңгездә чакта. Туган җир сагындыра, ә кайтсаң, тагын шул диңгезгә ашкынасың... Менә Витус Берингны алыйк... Камчаткада аны бик ихтирам итәләр. Петропавловскийның нигезен шул кеше салган бит, шәһәрнең исеме дә аның кораблары — «Изге Петр» һәм «Изге Павел» исеме белән атала. Менә шул Витус Беринг Даниядә туып үскән кеше бит. Данияне мин үзем җылы, ямьле, кечкенә бер өй сыман итеп күз алдына китерәм. Борынгы җир, борынгыдан килгән сәнгать, ашап-эчәргә, күңел ачарга яратучы халык. Табигате дә талгын, артык салкын да түгел, артык эссесе дә юк, күңелне җилкендереп бер йөзеп кайтыйм дисәң, диңгезе дә янында гына. Үзеңә бер шәп хатын тап та яши бир, балалар үстер. Ләкин Беринг моңа гына канәгать булмаган. Нишләптер Россиягә килгән, иксез-чиксез Себер аша үтеп, Охот диңгезен кичеп, кыргый Камчаткага барып җиткән, анда кораблар төзеп, алар белән салкын диңгезләргә чыгып киткән — Америка белән Азия арасында су бармы, алар тоташканмы-юкмы икәнен белергә. Диңгезләрдә йөрүнең кыенлыкларын белмәгәнмени ул? Күп юлдашларының, ә бәлки үзенең дә шунда һәлак буласын уйламаганмыни? Белгән, бөтенесен бик яхшы аңлаган. Ләкин барыбер барган бит шунда. Ул ике сәяхәт ясаган. Яңа атаулар ачкан, Азия белән Американың тоташмаганлыгын ачыклаган. Күп юлдашларын югалткан һәм үзе дә Камчаткага кире кайтып җитә алмаган. Сөйләп бетергесез михнәтләр күреп, инде тәмам өметне өздек дигәндә, алар җиргә килеп җиткәннәр. Күп газаплар белән ярга чыкканнар. Ләкин әлеге җир буш атау булып чыккан. Зәңгеләдән тәмам шешенгән Берингны җиргә күтәреп алып чыгып, аннан-моннан корыштырган куышка яткырганнар, бераз җылынмасмы дип, ярты гәүдәсен туфрак белән күмгәннәр. Аннары хәле бик авырайганны күреп, туфракны алып ташламакчы булганнар. Ләкин Беринг, калдырыгыз, дигән, миңа шулай җылырак, дигән. Ул инде үләчәген, ямьле туган җирен — газиз Даниясен беркайчан да күрмәячәген белеп яткан. Ләкин үзен бик тыныч тоткан, хәтта шат күренергә тырышкан, чөнки башкаларның күңелен төшерүдән курыккан. Үзләренең билгесез атауда икәнлеген бик яхшы белсә дә, Беринг юлдашларына моны сиздермәскә, без Камчатка ярына кайттык, дип ышандырырга тырышкан. Ул шул хәлендә үлгән. Беринг атавын мәктәп дәресләкләреннән беләсездер бит? Шунда аның кабере. Бу экспедицияләрен башлаганда Берингка кырык җиде яшь булган, ул алтмыш бер яшендә үлгән. Димәк, безгә дә соң түгел әле нәрсәдер эшләргә, шулай бит?» «Сез дә шундыйлар токымыннан инде алайса!» — диде Зуфирә. «Нигә мин генә? Сездә дә яши ул тынгысызлык. Әле генә миңа сөйләп утырдыгыз бит. Кеше сыер кебек җылы абзарда гына яшәргә тиеш түгел. Ул үз тормышына шәм яктысында, хәтта электр лампасы яктысында гына карарга тиеш түгел. Ул үзенә янартаулар яктысында карарга тиеш бер заман». «Бәлки без аларны күреп, аңлап бетерә алмыйбыздыр», — диде Зуфирә уйлап. «Анысы инде сезнең эш — кешеләрнең тынгысызлыгын, изге хисләрен аңлау һәм башкаларга җиткерү, минемчә, кешене иң алдан әйдәп баручы нәрсә — аның күңелендә, йөрәгендә кайнаган ялкын, хис. Кеше бирәр нәрсәне башта күрә, сизә, тоя. Аннары гына акылы белән аңлый, аңлата, өйрәнә. Барлык ачышлар шулай ясала бит. Сизүне, ашкынуны, омтылуны аңлатып бирү кыен, аны көй, төс һәм сүз белән — кыскасы, сәнгать көче белән тасвирларга кирәк. Ә моның өчен күңелең белән шул кичерешләрнең киңлеген һәм тирәнлеген тоярга кирәк. Беринг ниләр кичергәнне белер өчен, аларны үз йөрәгең аша үткәрми булмый».

Зуфирә дулкынланып тәрәзә аша шәһәргә карады. Зур шәһәр, хисапсыз утлары белән җемелдәп, йөрәкләр тибешен чагылдыргандай

булып күренә, анда әле генә Өмит сөйләгән тынгысызлык чагыла шикелле.

Иртәгесен Зуфирә Анапага билгеләнгән рейс белән китмәде, иртүк барып билетын алыштырды. Ул арада Өмит тә каядыр барып йомышын йомышлап килде һәм алар шәһәр буйлап йөрергә чыгып киттеләр.

Моңа кадәр Зуфирә Мәскәүдә үткәндә-сүткәндә генә булып, ГУМ, ЦУМ белән метродан башканы күрә дә алмый иде, шунлыктан шәһәр баш әйләндергеч ыгы-зыгылы, кырмыска оясы кебек тынгысыз булып хәтеренә сеңеп калган икән.

Бу юлы Мәскәү Зуфирәгә бөтен гүзәллеге белән ачылды. Алар Кремльдә йөрделәр, бакчаларда ял иттеләр, мавзолейга керделәр, тын урамнар буйлап уздылар, хәтта ишегалларына кереп, бизәкләр төшкән борынгы биналарны карадылар. Кич белән театрга бардылар. Юл уңаеннан Өмит Зуфирәгә бер бәйләм чәчәк алып биргән иде. Спектакль тәмамлангач, Зуфирә аны, залдан үрелеп, сәхнәгә ыргытты. Монда чәчәкләрне сәхнәгә чыгармыйлар, ыргыталар гына икән.

Театрдан кайтканда Кызыл мәйдан аша үттеләр. Халык аз, мәйдан тыныч иде. Билгесез солдат каберенә кертмиләр иде инде, ләкин ниндидер чит ил делегациясе килеп, тимер капкаларны ачтылар, аларга ияреп, Өмит белән Зуфирә дә керде. Төн караңгылыгында зураеп, көчәеп киткән ут, ялкын телләренең шома мәрмәрдә чагылуы, өелеп торган чәчәкләрнең хуш исе, матур сын кебек сакта торган солдатларның кырыс һәм тантаналы йөзе — болар барысы да гади тормыш кына түгел, матур бер сәнгать әсәре кебек иде.

Аннан туры гостиницага кайтасылары килмәде. Алар Арбат урамына киттеләр.

Бизәп, сырлап, шул ук вакытта мәңге торырлык итеп нык салынган борынгы йортлар аларга үзләрен төзегән, үзләрендә яшәгән һәм яннарыннан узган күп буын кешеләренең язмышы, тормышы хакында сөйләп бара иде шикелле.

— Бер уйласаң, безнең гомер юлына бик күпләр үз йөрәкләрен түшәп калдырганнар бит. Беринг кебекләр һәр өлкәдә булган һәм алар алдагы буыннарның, ягъни безнең барыр юлларыбыз такыр булсын өчен аяк астына салганнар йөрәкләрен,— диде Өмит уйланып.

Дәвамын ул гостиницага кайтып җитеп аерылышканда гына әйтеп бетерде: «Минем хатын да тынгысыз җаннардан. Артистка. Сәнгать корбаннар сорый, дип, бала булдырырга ашыкмады. Аннан мин — диңгездә, ә ул һаман театрда эзләнә... Эзләнүдә ярдәм кирәк, ә мин ерак. Ярдәмчеләр якыннанрак табыла андый чакта. Хәзер инде мин диңгездән кайткан айларда да очрашмыйбыз... Гаиләне корбан иттек, ә максатка ирешә алмадык әле. Монысы бераз зарлануга охшап китте бугай. Гафу итегез...»

Ул иелеп Зуфирәнең кулын үпте, сулышыннан бармаклар пешкәндәй булды.

Өмитнең самолеты иртүк очты, Зуфирәнең берничә сәгать көтәсе бар иде әле. Капитанның билетын яздырып, чемоданын тапшырып чыккач, икесе дә бу аерылуның озакка икәнлеген, ә бәлки моннан ары бөтенләй очрашмаячакларын аңлап, балалар шикелле кулга-кул тотынышып, читкәрәк барып бастылар. Икесе дә йөрәкләренең бербереснә нык җепләр белән бәйләнгәнен тойдылар. Менә хәзер ул җепләр өзеләчәк, алар инде өзелә дә башлаган...

Зуфирә бизгәк тоткандай бөтен тәне белән калтыранды, калтыранганын Өмиткә сиздермәскә тырышты. «Ә син үзеңне янартаулар яктысында сынап карарга теләмисеңмени?— диде Өмит.— Син эзләнәсең бит, таба алмыйсың, ә андый чакта, бөтен кысаларны җимереп,

читкә китәргә кирәк». «Әнигә соң син мине хәзер үк үзең белән бергә китәргә үгетләмисең?» — Зуфирә шаярган сыман елмаерга тырышты, ләкин иреннәре аңа буйсынмадылар. «Ерак рейсларга бик зур әзерлек белән, барысын да ныклап алдан уйлап чыгарга кирәк, Зуфирә... Әгәр дә син үзеңдә шундый әзерлек, тәвәккәллек тойсаң, миңа язарсың, яме? Килерсең. Исеңдә тот, Зуфирә: бәхетнең зурысы кыюларга, тәвәккәлләргә генә килә».

Ике якка да ачылган пыяла ишектән самолетка утыручыларны гына чыгаралар, озатучыларны үткәрмиләр иде. Өмит, ашыгычлык белән иелеп, Зуфирәнең иреннәреннән үпте — гүяки аның йөрәгенә үз тамгасын салгандай итте. Зуфирә озын коридор буйлап аның ашыгып киткәнен карап калды.

Автобус кузгалгач кына Зуфирәнең исенә төште: ул Өмитнең адресын сорап калмаган иде...

*
* *

— Зуфирә!

Бу юлы Эльвир чалбардан иде. Хатыны җавап бирмәгәч, караваг янына ук килеп, ак җәймә аша аңа кагылды.

— Зуфирә, дим! Тор әле!

Халидә дә уянды, ләкин шым гына ятты, инде эш бу дәрәҗәгә җиткәч, атасы белән анасы арасына кысылуны яхшысынмады, күрәсең. Зуфирә башын калкытмый булдыра алмады:

— Ни кирәк сиңа?

Эльвир артка чигенә төшеп, караңгыда бик зур күренгән кулы белән үзенә таба кат-кат ишарә ясады:

— Чык әле! Бер генә минутка!

Зуфирә үзалдына көлемсерәп, ашыкмый гына йомшак жылы халатын алып киде. Чәчендәге тасманы сүтеп, кулы белән сыпыргалады. Зал ягына чыгып, ут кабызды.

— Кирәкми, кирәкми! — диде Эльвир, күзләрен чет-чет йомып.— Нәрсәгә кабызасың, гәзит укырга чакырмадым ла мин сине!

— Мөнәсәбәтләрне яктыртырга кирәк бит! Без йоклаган бүлмәгә кат-кат керәсең, кызыңнан оялыр идең, ичмасам!

— Нәрсә оялырга! Үзебезнең уртак балабыз.

Эльвир сүз ярышында җиңү өмет итми иде. Шуңа күрә, ниятләгәнен тормышка ашырырга омтылыш ясап, кочакламакчы булып, Зуфирәгә үрелде.

— Сабыр!

Зуфирәнең боздай сүзеннән бигрәк, йөзеннән, күзләреннән сирпелгән салкынлык аны чигенергә мәҗбүр итте.

— Я, ни сүзең бар иде?

Эльвир диванда таралып яткан ак җәймәгә утырып, чигәләрен ике
учы белән уды. Ярдәмгә мохтаж, көчсез, кызганыч бер малай булып
күренә иде ул бу минутта, хәтта гәүдәгә дә кечерәеп киткәндәй иде.
Зуфирәнең күңелендә ихтыярсыздан аның янына утырып, чигәгә кы-
сылган кул аркаларын, чәчләрен сыйпап, юату теләге уянды. Кеше-
ләр күңелендә үзенә карата шундый тойгы уятырга оста иде Эльвир.
Күрәсең, бу осталык та түгелдер, табигать биргән сәләттер... Зуфирә
шуны уйлап, күңелендәге кызгану хисен басарга тырышты. Эльвир
янына түгел, өстәл кырыендагы урындыкка утырды.

— Синең Беринг дигән кеше турында ишеткәнең бармы? — дип сорады.— Минем шуны беләсем килә: нәрсә мәҗбүр итте икән аны Дания кебек матур илне, рәхәт тормышны ташлап, әллә кая, җир читеннән ары чыгып китәргә?

Эльвир, башын күтәреп, аңа хәйран калып карады:

— Әллә саташа башлагансың инде,— диде ул, ниһаять.— Әни чире сиңа да йогып калды мәллә? Ниткән Дания? Нинди Беринг? Нәрсә син миңа төн уртасында мәктәп дәреслеген сөйләп утырасың?

— Башымнан һич китми менә. Шуңа соравым.

— Бүтән кайгың булмагач, баш катырырга анысы да ярап тора инде,— диде Эльвир, бераз йомшарып.

Зуфирә бу сорау белән Эльвирның фикерен тәмам чуалтып ташлаган иде. Ул бераз зиһенен җыя алмый утырды.

— Адаштырдың син мине, бөтен тормышны чуалтып ташладың,— диде ул, ниһаять, сызланып.—Әгәр син кеше төсле генә булсаң, мин дә бу хәлгә төшмәс идем.

— Син нәрсә, безне ташлап чыгып китүеңдә мине гаепләмәкче буласыңмы әллә!

— Синең бу Беринг турындагы кыйссаларыңа, иҗат, тормыш мәгънәсе, максат дип туктаусыз кыбырсуыңа таш күңелле адәм дә чыдый алмас, билләһи! Үзеңнән дә, миннән дә даһи ясамакчы бит син! Кешечә генә яшәү җитми сиңа! Һаман буй җитмәгәнгә үрелеп җан тартышу... Инде буең җитмәсенә ышангач, кулыңны аска төшерергә, тартышудан туктарга, тәнеңә, җаныңа бераз ял бирергә кирәк ләбаса! Дәреслекләрне бик яхшы беләсең бугай, Тукайның «Төлке һәм йөзем җимеше»н хәтерлисеңдер. Буй җитмәгәч, ул да бит:

**Йөземнәр чи, әле өлгермәгәннәр, пешмәгәннәр,**
**Бозарсың ашказаныңны, килешми эчкә алар,**

— ди. Буй җитмәгән әйбер эчкә ярамый ул, Зуфирә!

— Син шул төлке шикелле буй җитмәгәнне хурлап юанасың инде, алайса.

— Соң, төлкедән дә ахмак булып булмый инде!

— Минем югарыга үрелүем һәм сине дә шуңа этәрүем эчеңә тигән дә, тынычрак урын эзләп миннән китеп баргансың инде, алайса. Шулай димәкче буласыңмы?

— Ниһаять, син дә мине аңладың.

— Мин дә сиңа Беринг турында киная белән сөйләгән идем бит, Эльвир. Син мине аңламадың гына. Мин үзем дә Беринг артыннан китмәкче булам.

— Нишләмәкче?

— Китәргә ниятләдем әле мин, Эльвир. Еракка, җир читенә. Камчаткага, ә бәлки аннан да арыдыр...

Эльвир шаяртмыймы бу дигәндәй аның күзләренә балаларча беркатлылык белән тутырып карады.

— Чыннан да әйбәт фикер бит, ә,— диде аннары.— Ничек минем башка килмәгән әле ул. Китәргә кирәк, башны алып олагырга кирәк. Җир читенә үк качуның кирәге юк анысы. Аннан башка да бик әйбәт урыннар бар бит дөньяда. КамАЗ шикелле үсеп күтәрелеп килгән яңа калалар күпме. Йортлары салынып тора, тулай тораклары бар, культура сарайларын, башкалардан уздырып, мәрмәрдән төреп салалар... Биетүчеләр кирәк аларга, җырлатучылар кирәк. Минем ишеләрне кочак җәеп каршы алачаклар, барып бер аккордеонны гына тартып күрсәт...

— Рестораннарның да бик шәпләрен җиткергәннәр, ди, анда,— диде Зуфирә, ачы көлемсерәп.

— Әйе, анысы да идея...— Шунда гына Эльвир, хатынының көлгәнен аңлап, аңа карап куйды.

— Күрәсең безнең юллар төрледер, — диде Зуфирә салкын гына. — Болай булгач, тәмам ачыкланды мөнәсәбәтләр. Инде хәзер тынычлап йокласак та була.

— Зуфирә!

— Минем башка кешем бар, Эльвир...

— Башка кешең?— Эльвир уйланып торды. Башка кешесе булса, Зуфирә аны, Эльвирны, кертер идемени?

— Кем ул? Кайда ул? Камчаткадамы әллә?

— Әйе. Камчаткада.

— Соң ул аны белми дә калачак бит!

Юк, чыннан да, бу Эльвирның вөҗданы тәмам уянмас йокыга талгандыр, ахрысы.

— Эльвир! Минем үткәннәрне кабатлыйсым килми, сиңа күптән күңелем сүрелде инде.

Кире чыгып җиткәч, Зуфирә эченнән генә тагын шул ук сүзләрне кабатлады: «Үткәннәрне кабатлыйсым килми». Чыннан да, әгәр ул Эльвир белән килешсә, тагын бергә тора башласа, нәрсә булыр иде? Тагын шул кабатланыр иде: ничек тә булса ярашып яшәргә тырышу, баштарак Эльвирның күпмедер тыелуы, аннары тагын салгалавы, тагын хыянәте... Тик бу юлы әлек узган юлны бик кыска арада, бик тиз үтәр иде ул.

Юк, бер үк юлны кат-кат таптаудан мәгънә юк, гомер болай да кыска. Ничек дигән иде әле Өмит? «Бәхет бары тик кыюларга, тәвәккәлләргә генә килә»,— дигән иде. Ә кыюлар, тәвәккәлләр гел яңа юллардан йөриләр...

Ул чакта, көньякка, Анапага баргач, Зуфирә үзе дә бу сүзләрнең раслыгын сынап караган иде.

Анапада ул «Биек яр» дигән турбазада ял итте. Анда бер төркем кешеләрне җыеп, туристик походка алып киттеләр. Аркага авыр биштәрләр асып, диңгез буендагы бормалы-сырмалы, үрле-таулы юлдан, ташлыклардан, комлыклардан. Зәңгәр диңгез ярыннан, урман каплаган яшел калкулыклар күкрәгенә басып...

Арып-талып тиешле урынга барып җиткәч, кич белән учаклар ягып, шашлык кыздырырга кереште халык. Учак янган калкулыктан диңгез күренми иде.

Төнлә Зуфирә диңгездә коенырга булды. Аңа иптәшкә кеше табылмады, бары тик бер кыз белән бер егет кенә аны озата барырга ризалык бирделәр.

Шомлы, караңгы, куркыныч иде диңгез, тулы ай аңа серлелек кенә өсти, ерактагы корабның прожекторы, караңгылыкны пычактай ярып, дулкыннары саргылт нур канаты белән сыпырып үтә дә кинәт сүнә, аннары дөнья тагын да шомлырак булып кала иде.

Дөньяда бары ай, диңгез, Зуфирә генә иде шикелле. Салкынча су
башта тәнне көйдереп алды, дулкыннар аны эчкә кертергә теләмә-
гәндәй ярга этәрде. Ул, колачын җәеп, алар кочагына ташланды. Ә
эчтәрәк дулкыннар аны иркәләп тибрәтте, бөтен тәнне хәрәкәт шат-
лыгы биләп алды, шул ук вакытта астан, кара су төбеннән нинди дә
булса куркыныч җанвар килеп чыгып аяктан эләктереп алыр шикел-
ле иде. Зуфирә колачын җәеп җибәргән саен, суда көмеш тәңкәләр
сибелә. Нәрсә бу? Нинди тәңкәләр? Зуфирә моны ачыклара тиеш иде.

Иртәгесен коенганда ул серне ачыклады: колач җәйгән саен си-
белгән ул тәңкәләр — һава куыклары икән, алар ай яктысында шулай
җемелдәп күренгән икән...

Соңыннан, Казанга кайткач, Зуфирә бу хакта Өмиткә язып җи-
бәрде, бит тутырып рәсем ясады. Анда йөгерек дулкыннар да, тулган
ай да, прожектор нуры, көмеш тәңкәләр чәчеп йөзгән үзе дә бар иде.

Әйе, саубуллашканда ул Өмитнең адресын сорарга оныткан иде,
инде аны мәңгелеккә югалттым дип сызланган иде.

Көньяктан кайтып, пионер журналының редакциясенә баруга, аның
кулына конверт тоттырдылар. «Художник Зуфирәгә» дип язылган. Ху-

дожник Зуфирә аны алгач үз күзләренә үзе ышанмый торды. Өмит... Тапкан бит менә җаен, торган бит сүзендә. Өмит тапмыймы соң, ул онытамы әйткән сүзен!

Җир читенең аръягыннан хатлар озак килә, ләкин алар бер-берсеннән җавап көтеп тормыйлар, җаннары теләгән саен язалар иде. Ә җан теләмәгән көн булмый иде. Соңгы ел эчендә Зуфирәнең иң бәхетле минутларына әверелде ул вакыт — Өмиттән хат алу һәм кич утырып, чит-читләренә сурәтләр ясап хатлар язу.

«Синең хатларың рәсемле хикәя шикелле,— дип язган иде бер хатында Өмит.— Зинһар, ешрак яз, плавбазага барган саен буш кул белән кайтырлык булмасын. Миннән сәлам килми торса үпкәләмә, океанда почта йөри торган шома юллар юк. Ә мин үзем синең хатларыңны дога урынына кич саен йокы алдыннан укыйм...»

Зуфирә үзе дә сүзен сүзгә хәтерли Өмитнең хатларын. Менә әле хәзер дә, күзен йомып, күңеленнән укый ала:

«Америка ярлары буенда сельдь тотабыз. Монда безнең белән янәшә бик күп судноләр тора, төрлесе төрле илләрдән. Поляклар, инглизләр, немецлар, шведлар... Төнлә бөтенесендә утлар кабына, су өстенә тулы бер кала салып куйганнар диярсең».

«Өч көн инде шторм котыра, яңгыр ява. Безгә көненә өч тапкыр куе ботка пешерәләр, сыек аш пешереп булмый, казаннан чайпалып түгелә. Мондый чакта эш туктый, балык тотып булмый, эшсезлектән бөтен кешенең күңеле төшенке була. Әле бүген карап торам, ашаганда кара-каршы ике матрос әйткәләшеп алдылар. «Авызыңны чапылдатмый гына ашый беләсеңме син, юкмы?» — ди берсе. «Мин синең колагың селкенгәнгә чыдап утырам бит әле, сүз әйтмим»,— ди икенчесе. Алардан якын дуслар юк бит, югыйсә. Менә эшсезлек һәм кысан урында яшәү нишләтә кешене! Ләкин мин күңел төшенкелегенә бирешмим, судноның кайбер механизмнарын яхшырту турында тәкъдимнәр ясамакчы булам, шуларны уйлыйм, китаплар укыйм, синең хатларыңны укып юанам».

География дәреслегендә шундый бер рәсем бар: түгәрәк җир шарының ике ягында ике кеше басып тора, аларның аяклары бер-берсенә юнәлгән. Зуфирә үзе белән Өмитне дә шулай итеп күз алдына китерә иде. Һәм аларны аерып торган шар торган саен кечерәя бара шикелле иде, Зуфирә хәтта бөтен җир аркылы аның йөрәк тибешен, аның сагышын һәм януларын тоеп тора иде сыман. Күңелләр якын булса, кешеләрне җир шары гына ерагайтып, аерып тора алмый икән!

«Балык килә, балык, күтәреп кенә өлгер! Егетләр палубадан терекөмеш кебек тәгәрәп кенә йөриләр, күз иярми. Бөтен кеше җанфәрман эштә. Мондый чакларда безнең кәеф шәп инде. Бүген тагын плавбазага барачакбыз, синең бер кочак хатыңны берьюлы алырмын дип алдан ук сөенеп йөрим. Балык булса, барсы да була».

Зуфирә үзе дә тормышында булганның барысын язарга тырыша, ләкин билгеле инде, аның хатлары Өмитнеке кебек үк кызыклы, дәртле була алмый. Ничек яшисең бит!

«Бүген мин зур гына бер язучыбызның юбилеенда булдым әле. Китапларына иллюстрацияләр ясаган рәссам буларак, түргә утырттылар. Язучы белән хатыны менә болай утыралар иде (рәсем), кешеләр менә болай күңел ачтылар (биниләр, җырлыйлар — рәсем). Күрәсеңме, бөтен кеше парлы-парлы, мин генә моңлы-зарлы (рәсем). Ләкин мин бирешмим, сине исемә төшерәм дә, борынны югары күтәрәм (рәсем). Соңыннан тын урамнардан берүзем ялгыз кайттым. Кызганыч, без синең белән Казан урамнарыннан бергәләп уза алмадык әле. Йортларның тавышсыз кыйссасын бер ялгызым тыңладым. Аларның ак диварларына агачларның кара күләгәләре матур бизәк булып төшкән иде. Җил искән саен бизәкләр тирбәлә — ак стенада кара бизәк-

ләр... Безнең борынгы бабаларыбыз милли нәкыш үрнәкләрен шундый бизәкләрдән алганнар бит инде — үләннәрнең, чәчәкләрнең, агачларның чагылышы ул нәкыш».

Хатлар аларны бер-берсенә торган саен якынайтты. Алар инде очрашырга тиешләр, очрашмый кала алмыйлар һәм бу хакта хат аша килешеп тә куйганнар иде. Август аенда Өмит Камчаткадагы «Начики» дигән курортка ике путевка алып куячак һәм кайтып Зуфирәне алып китәчәк. Август — Камчаткада иң матур ай. Тыныч, җылы. Үләннәр кешедән биек булып үсә. Анда гына үсә торган татлы кара бөрлегәннең нәкъ өлгергән чагы. Әле менә газеталар Камчаткада өр-яңа янартау ата башлаган дип язалар. Тарихта күренмәгәнчә тәсле итеп, әллә ничә авыз ясап ата икән ул. Өмит яза, аны барып карарбыз, ди, Гейзерлар үзәнендә йөрербез, кайнар күлләрдә коенырбыз. Тын океанга барырбыз, ди.

Күп көтәсе калмады, бер-ике атна гына... Айдан да ким. Дөрес, көнен атап язмый Өмит, ул хәтле ерактан кайчан кайтып җитәренне алдан ук белү дә кыен. Ләкин барыбер күрешер көннәр якын инде. Озакламый аның телеграммасы да килер. Кайтыр алдыннан телеграмма бирергә вәгъдә итте бит ул. Зуфирә аны аэропортка каршы барып алыр.

Зуфирә үзалдына елмаеп, йокыга китте.

*
* *

Иртәгәсен Зуфирә, Эльвирны өендә калдырып, журналга рәсемнәрне илтә барган иде. Журналның рәссамы озынча битле, ачык йөзле, гел елмаеп, йомшак кына сөйләшә торган Зәбир аның рәсемнәрен мактап кабул итте.

— Бәхетле кеше күрәсегез киләме сезнең?— диде Зуфирә бүлмәдәгеләргә.

— Килә,— диештеләр елмаешып.

— Миңа карагыз менә — мин бәхетле. Мин Камчаткага китәм.

— Камчаткага?

Шундук бөтен редакция Зуфирә янына җыелды. Ник бара? Озакамы? Ничек курыкмыйча кузгала?

Зуфирә биек бинаның тугызынчы катыннан Идел белән Казанканың кушылган җиренә, елга киңлегенә сузылып киткән дамбаларга, аркасын бөкрәйтеп, елга аша сикергән күперләргә, йортлар арасында яшәреп күренгән агачларга карады:

— Күптән барасым килеп йөри иде инде, бер кузгалырга кирәктер бит. Югыйсә, картаела, аяклар йөрми башлар.

Бүлмәгә кәгазьләр күтәреп, кайчандыр Зуфирә белән бергә художество училищесын тәмамлаган, хәзер абруйлы график һәм ярыйсы гына картиналар авторы булган Илдус Зәйнуллин килеп керде. Күпереп торган бөдрә чәчендә ак бөртекләр күбәйгәннән-күбәя бара, калын иренле, киң борынлы түгәрәк йөзендә җыерчыклар да күренә, бил дә калыная. Ләкин, шуңа да карамастан, Илдус әле яшьләрчә киенеп йөри: кысан джинсы, шулай ук тәненә сыланып торган чәчәкле күлмәк, һәм бу аңа килешеп, яшь рухын белдертеп тора иде.

Илдус төргәкләрне бүлмә идәненә җәеп салды. Мәскәүгә күргәзмәгә дип әзерләгән эшләре икән.

— Анда озатканчы сезгә күрсәтергә булдым әле,— диде ул.— Туп-турысын әйтегез: кешегә күрсәтерлек җире бармы, юкмы? Анда йөз кызарткачы, монда дөресен беләсем килә.

Барысы да, Зуфирәне онытып, рәсемнәр өстенә иелделәр.

Кәгазь битләренә акварель белән КамАЗ күренешләре сурәтләнгән иде.

Дөрес, аның рәсемнәре бөек төзелештәге рухны, колачны, техниканың куәтен чагылдыралар, шуның өчен рәссамны гел мактап торалар, аның хезмәтләре альбомнарда, журналларда басылып чыга, төзелешкә керткән өлеше өчен ул медаль белән дә бүләкләнгән иде.

Ләкин, шуңа да карамастан, ул эшләрдә күңел җылысы җитеп бетми һәм моны рәссам үзе дә сизә, артык кәперәйми, мактанмый, күбрәк уйлана иде.

Хәзер менә аның бу эшләренә күз салгач, Зуфирә күңеле белән бер нәрсәне тоеп алды: рәссам монда бөтенләй башкача язган, рәсемнәрен йөрәк җылысы белән сугарган. Аларга караган саен карыйсы килә. Менә бер яшь пар әле генә загстан язылышып чыккан, дуслары белән бергәләшеп истәлеккә карточкага төшәләр. Кияү белән кәләш кенә туй киемнәреннән, калганнары эштән килгәннәр — комбинезоннардан. Аларның йөзендә камиллек, гади, риясыз хезмәт кешеләренә хас саф күңеллелек, ышаныч һәм киләчәктә үзләренең дә шундый бәхетле минутлар кичерәсенә өмет балкый. Бигрәк тә әнә читтәрәк кочаклашып басып торган ике кыз сөйкемле: менә без ниндиләр! дигәндәй чытлыкланып туп-туры карап торалар.

Башкалар инде, рәсемнәрне мактап, үз эшләренә таралыштылар, бары тик Зуфирә генә һаман рәсемнәргә карап тора иде.

— Мин сине мондый итеп белми идем әле,— диде Зуфирә Илдуска.

— Кешене белмәү гаҗәпмени, без күп вакытта үзебезне үзебез дә белеп бетермибез бит.

— Син үзгәрдеңме, әллә хәзер генә күңелеңне ачып бирә белә башладыңмы?

— Үзгәрәбездер дә инде, осталыкка ирешергә дә вакыт. Гомер үтә бит.

...Зуфирә кайтып кергәндә өйдә кеше юк иде. Халидә икенче сменага эшкә киткән, Эльвирның да портфеле белән аккордеоны гына тора, үзе юк иде.

Зуфирә «эш бүлмәсенә» керде дә, алдына кәгазь салып, акварель буяуларын якынрак тартты. Пумаласын алды. Эчке бер дулкынлану белән беренче сызымны салды. Илдусның иҗатында «теле ачылган». Зуфирәнең дә «теле ачылырга» тиештер бит инде!

Ул гомумән салкын кан белән генә эшли алмый, чынлап тотынганда күңелендә әрнүле дә, татлы да бер ярсулык тоя, әйтерсең лә йөрәгендәге януларны, көчне әкренләп бармаклары, аннары пумаласы аша саркытып кәгазьгә, киндергә күчерә иде. Бу ярсулык бөтен күңелнең, хәтта тәннең хәлен ала, шунлыктан ул озаклап утырып эшли алмый иде. Аның көнлек эш нормасы — ике сәгать, шуннан соң ул хәлсезләнеп диванга ава, кабат көч җыярга тырыша иде.

Бүген дә ул шулай ярсып эшләде. Кәгазьдә чыгынкы иякле кырыс йөз барлыкка килде, зәңгәр күзләр Зуфирәгә төбәлделәр, йөзнең кырыслыгын киметеп, кара кашлар дугаланып өскә күтәрелделәр. Аның баш очыннан салават күпере сузылды, яннан күбекләнеп дулкын күтәрелде...

Халидә кереп, әнисе артына килеп басты.

— Әни, әни, дим! Мин күрдем бит бу кешене! Күрдем, чыннан да ул иде, нәкъ үзе иде!

— Кайчан күрдең, кайда?

— Бүген күрдем, үзебездә.

Зуфирә гаҗәпләнеп башын күтәрде.

— Ни сөйлисең син, тиле кыз!

— Билләһи менә! Менә безнең ишектә, рамдагы шикелле итеп басып тора иде. Капитан.

— Кайчан?

— Бүген! Син чыгып киткәч! Мин ваннада чәч тарый идем. Шалтыраттылар. Шуннан... теге барып ачты. Ванный бүлмәсеннән чыксам, ул нәкъ рамдагы портрет кебек басып тора. «Эштә ул, эштә», — ди теге. Күрәсең, сине сорагандыр капитан. «Ә сез аның кеме буласыз, абыйсымы?»— дип сорады бу.

— Шуннан, шуннан ни дип җавап бирдегез?

— Миннән сорамый ич! Мин артта торам, карап кына. «Юк, мин аның ире булам»,— дип җавап бирде теге...

— Ничек дип?— Зуфирәнең йөзе агарынып китте.

— Ну... шул инде. Әни, тукта әле, нәрсә син, ни булды?

— Шуннан... капитан ни диде соң?

— Сәлам әйтерсез, диде бугай. Ну, хәтерләмим инде. Нидер әйтте, аңлап та җиткермәдем. Хушыгыз, диде кебек.

— Ә син, син авызыңны ачып карап калдыңмы?

— Нишләргә тиеш идем соң мин? Әни... тукта әле... Ну китте... Килер әле тагын...

— Берәр язу да калдырмадымы?

— Мин күрмәдем. Читтә тора идем бит. Әни, дим!

— Бар, кызым, бар, зинһар, чыгып тор әле, зинһар!

Зуфирә бөтен ачыклыгы белән: «Барысы да бетте!»— дип уйлады. Өмит кайткан, ул Казанда, бәлки бик якындыр, янәшә урамдадыр, ләкин Зуфирә аны әллә нишләсә дә таба алмаячак, ул хәзер җирнең теге ягындагыча ерак.

Кичкә таба Эльвир килеп керде.

— Әйт әле, нигә син үзеңне минем ирем дип игълан итеп йөрисең?

— Ә кем соң мин сиңа? Туганың түгел ләбаса!

— Бүген үк чыгып кит, ишетәсеңме? Хәзер үк эзең булмасын!

Зуфирә йөгереп кире эш бүлмәсенә кереп китте. Хәзер инде аны куып чыгарудан ни файда! Ат урлаткач, абзарны бикләдең ни дә, бикләмәдең ни!

Эльвир чыгып китте, берәр сәгать урамда йөреп керде дә, тагын кунарга калды. Аның белән ызгышып йөрүдән мәгънә юк иде инде. Зуфирә янында яткан кызын борчымаска, әйләнмәскә тырышып, төн буе ак түшәмгә карап ятты, яктыра башлагач та торды. Урамга чыгып китте. Ә сәгать сигезгә редакция ишек төбенә барып басты.

Һәрвакыт күтәренке күңелле Зәбир эшенә вакытында килә иде. Лифтта менгән арада Зуфирә аңа кайгысын әйтеп салды.

Зәбир юка иреннәре белән елмаеп тыңлады.

— Аны табуы кыен булмас, кеше энә түгел бит,— диде ул.— Инде танышларын белмисез икән, аэропорт кассасыннан белешеп була. Әгәр Камчаткага билетны моннан алса, аның кайсы рейс белән очасын шартлатып әйтеп бирәчәкләр. Кассада таныш бар безнең.

Чыннан да, тиз ерып чыкты бу эшне Зәбир. Берәр сәгать үтүгә Гасимов Өмитнең тагы ике көннән Камчаткага очасы тәгаен мәгълүм булды.

Сәгатьләрне генә түгел, минутларны санап көтте Зуфирә ул көнне. Менә нинди очракларда була икән ул — минуты — ай, сәгате — ел дигән чаклар!

Билгеләнгән көнне Зуфирә базарга барып бер кочак чәчәк сатып алды. Ак, кызыл, карасу гладиолуслар. Озату бүләге итеп түгел, очрашу хөрмәтенә бүләк итәр ул аларны Өмиткә. Чәчәкләрне бирер дә, үзе аның күкрәгенә капланыр, муенына сарылыр, кеше-карадан да кыенсынып тормас, тик аймылыш кына була күрмәсә иде, тик очрашсыннар гына иде! Өмитне билетын алыштырырга күндерер, инде баш-

ка чара калмаса, үзе шушы кечкенә сумкасын тоткан килеш аның белән бергә утырып китәр... Соңыннан Халидәгә хат белән барысын да аңлатыр. Зуфирә, алай-болай китәргә туры килсә почта тартмасына салырмын дип, Халидәгә дигән хатын да әзерләп куйган иде инде, өйдә язу да калдырып киткән иде.

Пыяла вокзалның ишеген атлап керү белән әллә каян күреп алды Зуфирә Өмитне. Йолдызлар арасындагы тулган ай кебек бөтен халык арасыннан күзгә ташланып тора иде ул. Елмаеп, талпынып, кешеләргә бәреләә-бәреләә, аның янына ашкынды Зуфирә. Ләкин нишләп соң әле капитан, йөзе белән аңа борылган килеш, бер хәрәкәтсез тора, нигә аңа каршы килми? Күрә бит ул аны, күрә... Нишләп соң әле Зуфирә якын килгәч, бөтенләй читкә борылды? Янындагы чал чәчле апага иелеп, нәрсәдер сөйләгән булып кылана?

Зуфирә әле һаман берни аңламыйча, аңларга теләмичә, чәчәкләре белән аның китель җиңенә тегелгән сары тасмаларга кагылып узды. Ә капитан исә чал апаның беләгеннән эләктереп, читкә тартты. Хәер, әнә Зуфирә тарафына да күз сирпеде. Ияге белән ишеккә ымлады. Тышкы ишеккә, янәсе. Бу ни дигән сүз? Күз алдында буталып йөрмә, чыгып кит, диюеме?

Ул Зуфирәне теге апага күрсәтергә теләмиме әллә? Ник? Ни өчен? Зуфирә узган елны да ул апаның Өмитне озатып калганын исенә төшерде. Кем ул? Өмитнең әнисеме, апасымы? Әллә тагын башка берәр туганымы? Хәер, «ирле хатынны» ничек инде туганнары белән таныштыра алсын ул? Гомумән кемне дә булса туганнарга күрсәтү бик җаваплы эш, ул яшьрәк чакта гына җиңел эшләнә, олыгайган саен моңа җаваплырак карыйсың. Шулай булгач, Өмиткә үпкәләп буламыни? Шул ук вакытта алар каршына барып, бу чал чәчле карчык алдында Өмиткә: «Кичә син минем өйдә очраткан кеше ул минем ирем түгел, аерылган ирем генә», — дип аңлатып торып буламыни? Кем ышансын андый мәгънәсез сүзгә?

Зуфирәнең күзләрен томан каплады, халык алдында үксеп елап җибәрмәс өчен ул ашыгып, кая басканын да сизмичә, кемнәрнеңдер чемоданнарына яны белән бәрелеп, аэровокзалдан ук чыгып китте. Аулак урын эзләп, кафе бинасы артына кереп качты һәм чәчәкләренә капланып елап җибәрде... Бераз күңелен бушаткач, башын күтәреп, койма артындагы такыр кырга — аэродромга карап тора башлады. Әнә ул кырның аргы башыннан, гөрелте белән бөтен тирә-юньне тетрәтеп, зур самолет күтәрелде. Кемнәрнең сөйгән ярларын алып күккә ашуы икән аның? Әнә койма кырыннан гына сузылган юл буйлап, район үзәкләренә очучы кечкенә самолетларга таба пассажирлар ташый торган сары автобус пырхылдап узып китте. Аның тәгәрмәчләре күтәргән тузан Зуфирәнең юеш битенә, чәчәкләренә бөркелде.

Кинәт колакка аэродром дикторының «Мәскәү» дигән сүзе чалынды. Зуфирә дерт итеп китте. Нишләп тора әле ул монда? Өмит хәзер шушы самолет белән очып китәчәк бит!

Ул вокзалда юк иде. Теге апа ишек төбендә Өмитнең таныш көрән чемоданы янында як-ягына карангалап басып тора. Күрәсең, Мәскәүгә очасы кешеләр чыгып китеп беткәннәр, ә Өмит юк, карчык шуңа борчыла иде бугай. Кая соң үзе? Әнә, ишектән кабаланып килеп керде, йөзе нигәдер бик борчулы, үкенүле. Аны күреп Зуфирә үзенең тагын бик аянычлы хата ясаганын аңлап алды: Өмит, мөгаен, аны эзләп йөргәндер, карчыктан читтә генә аның белән сөйләшү җаен эзләгәндер. Димәк, ул күзе белән ишарәләп Зуфирәгә: урамга чык, шунда сөйләшербез, дигән булган! Ә Зуфирә, ахмак, кеше тапмаслык урында качып, суган суы сыгып торды. Соң самолет очып киткәч еларга вакыты булмас идемени аның? Инде хәзер соң иде, соң иде!

Өмит аңа сау бул дигәнне белдертеп баш иде, карчык моны сизмәде, ул ашыга иде.

Самолет баскычы янында басып торучы форма кигән ыспай гәүдәле кыз Өмитне ашыктыра иде. Баскычка менгәч, капитан борылып кул изәде. Кемгә, чал чәчле апагамы, Зуфирәгәме? Зуфирә чәчәкләрен күтәреп болгады.

Шәһәр үзәгенә илтә торган троллейбуста Зуфирә чал чәчле апаны күздән ычкындырмаска тырышты. Кольцода төшкәч тә аның артыннан китте: әллә нәрсә булды Зуфирәгә — шушы карчыкны югалтса, Өмитне бөтенләй таба алмас шикелле тоелды аңа. Ичмасам, бер-ике авыз сүз алышасы иде. Карчыкка да ямансудыр, ул да якын кешесен бик еракларга озатып кайтып килә бит! Өмитнең әнисе үк түгел микән әле!

Зуфирә, карчык артыннан ияреп, җир асты юлына төшеп китте, универмаг янына барып чыкты, ул утырган трамвайга сикереп менде. Карчык кассадан билет алганда, аның янына барып басты да:

— Гафу итегез, мин бүген аэропортта улымны озаткан идем,— дип сүз башлады.— Сез дә шунда идегез бугай, ялгышмасам. Әллә сез дә улыгызны озаттыгызмы?

— Юк, улымны түгел, сеңлемнең улын озаттым әле мин,— диде карчык якты күзләре белән Зуфирәнең йөзенә туп-туры карап. Ул әйтерсең аның бөтен хәйләсен бик яхшы белеп тора иде.— Монда миннән башка туганы юк аның, үзләре Камчаткада яшиләр. Шуны бик ныгытып әйтеп җибәрдем әле, моннан ары ялгызың адашкан каз шикелле йөрмә болай, дидем. Килен белән икәүләшеп, парлап кайта торган булыгыз, дип колагына бик ныклап киртләдем. Килен бик әйбәт безнең, бик чибәр, тик соңгы елларны бәләкәй генә бозылышып алганнар иде бугай. Бик каты үгетләдем әле, килеш хатының белән, дидем. Икегез дә гөл кебек кешеләр, арагызга керергә атлыгып торучылар күп булыр, дип әйттем. Дөнья булгач, төрлесе була, бозылышып та аласың, әмма дә ләкин яшьли сөешеп кавышканга җитми, мәйтәм...

Зуфирәнең кулындагы чәчәкләре кинәт шиңеп төшкәндәй булдылар. Ул кабаланып:

— Ай, минем тукталышка җиткәнбез икән бит!— дип ишеккә ташланды.

Шул ук кичне бик бит кәгазь тутырып хат язды ул Өмиткә. Ләкин җибәрмәде. Хәзер ни генә язсаң да мәгънәсе юк иде инде. Элегрәк арадагы җир шары да кечкенә, үтә күренмәле сыман булып тоела, Зуфирә аның аркылы йөрәге белән Өмитнең күңелен тоеп-сизеп яши иде. Хәзер кинәт арадагы бөтен киртәләр — меңләгән чакрымнар, иксез-чиксез далалар, ерып үткесез урманнар, янартаулар, ташкын елгалар, океан дулкыннары — барысы-барысы үзләрен сиздерде, алар артында Өмит юкка чыгып эрегәндәй булды. Бер генә чара калган иде хәзер: хат конвертына язасы адрес буенча барасы да, Камчатканың Петропавловский каласындагы Балыкчы Даны дигән урамны эзләп табып, 17 йортка барып, 25 нче квартираның ишеген кагасы. Аны ачкан киң кашлы зәңгәр күзле кешенең күкрәгенә авып, күз яшьләренә ирек бирәсе. Калганы аның ихтыярында... Теләсә, яшәтер ул Зуфирәне, теләсә, аның гомеренә чик куяр. Чөнки хәзер Зуфирә өчен ансыз яшәүнең бер кызыгы да юк. Шуңа калганын уйлап торасы да юк.

* * *

Касса тәрәзәсе артында утырган хатын Зуфирәдән:

— Камчаткагамы? Сез анда яшисезмени? Паспортыгызны күрсәтегезче,— диде. Зуфирәнең Казан кешесе икәнен белгәч:— Милициядән рөхсәт алып килегез. Чик буе зонасы ул.

— Ә рөхсәт алсам, кайчанга билет булачак?

— Гадәттәгечә, егерме көн алдан сатыла билетлар.

Милициядә исә рөхсәт кәгазен әзерләү өчен ун көн вакыт китәчәген әйттеләр. Капитан Гасимовның сүзләре һаман раслана тора: ерак рейсларга озаклап, ныклап әзерләнәләр...

Шактый күңеле төшеп, бер сумка азык-төлек күтәреп кайтты Зуфирә. Лифт эшләми иде, ул тугызынчы катка баскыч буйлап йөгереп менеп китте. Аңа каршы уфылдап бер карчык төшеп килә иде. Ябык, бөкре, хәлсез, үзе култыксага ябышкан, киез ката кигән аякларын көч-хәл белән урыныннан кузгата. Зуфирә йөгереп менгән шәпкә аның янынннан җил тизлеге белән узып китте, берничә адымнан гына туктап, аска карады: «Я алла,— дип уйлады ул,— әгәр бәхетем булып, гомерем озын булса, минем дә картаеп шушы көннәрне күрәсем бар бит әле. Күп тә калмагандыр инде, һаман-һаман сикергәләп йөри алмам. Барырсың аннары җир читенә!»

— Әби! Кая барасыз болай? Кибеткә булса, йөрмәгез интегеп, әйтегез миңа ни кирәген, хәзер алып кайтып бирермен!

— Юк әле... уф... үземнең бер иреккә чыгып һава сулыйсым килгән иде... уф... таш капчыкта көннәр буе. Тын алыр хәл калмады...

Иртәгәсен Зуфирә аэрофлот кассасына йөгереп барды да Магаданга билет алды. Магадан Камчаткага чагыштыргысыз якынрак иде, билгеле.

*

* *

Унтугызынчы ноябрь көнне Камчаткадагы Петропавловский каласының күге болытлы, шомлы иде. Соры болыт кисәкләре, сопкаларга сарыла-сарыла, каядыр ашыгып чаба, йортлар арасыннан анда-санда тырпаеп калкып торган озын торбалардан ургылган кара төтенне усал җил төрле якка очыра иде.

Сопка араларыннан боргаланып-сыргаланып сузылган урамда автобустан Зуфирә төшеп калды һәм, көрсенеп, каршындагы бишәр катлы панель йортларга карады. Балыкчы Даны дигән романтик исемле урамны ул мондыйдыр дип уйламый иде. Җир читенә килеп, нәкъ менә Казанның яңа районнарындагы төсле стандарт йортлар арасында йөрермен дигән уй аның башына да килмәгән иде!

Менә шушы урамга килгән бит инде аның сагышлы, өмет һәм ышаныч тулы хатлары! Шушында килгән һәм шушы йортлар арасында йөргән ачы җил шикелле, юкка чыккан... Зуфирә хатларына ике ай эчендә бер генә җавап та булмады...

Зуфирә урам буйлап унҗиденче йортка таба юнәлде. Ай буе таптый инде ул бу урамны, бер ай эчендә, панель йортның көрәнгә буялган ишеген ачып, икенче катка әллә ничә тапкыр менде, йөрәк ярсуын басарга тырышып, ишек кыңгыравының коңгырт төймәсенә басты. Әмма кыңгырау күпме генә зыңгылдаса да, көрән ишек ачылмады, аның артында аяк тавышлары ишетелмәде.

Әмма һаман өметен өзми инде Зуфирә. Менә бүген, ниһаять, ул ишек ачылыр, бусага янында зәңгәр күзле, мәһабәт сынлы ир-егет күренер һәм ул Зуфирәне кочагына алыр, дип ышана иде ул. Шуннан өй эченә керерләр, Зуфирә чәчрәп чыгарга торган күз яшьләрен тыймас, яшь аралаш көлә-көлә үзенең бирегә нинди әйләнеч юллардан килеп ирешкәнен сөйләп бирер.

— Юлга чыкканыма өч ай инде,— дияр ул.— Мин монда турыдан гына түгел, Магадан аша килдем бит, дияр. Аннан килү ансатрак булыр дип өметләнгән идем, киресенчә, кыенрак булып чыкты. Анда мине белүче юк, пропуск бирергә риза булмадылар.

— Ә ничек килә алдың соң?— дип сорар Өмит шатлыгыннан балкып.

— Синең исемең барлык киртәләрне җимерде!— дияр көлеп Зуфира. Һәм бик җиңел генә итеп башыннан кичкәннәрне сөйләр. Магаданның бер клубында стендлар, плакатлар ясап, ашарлык акча эшләгәнен... Күңеле һаман диңгезгә тартылганын, бушаган саен шунда барып, этюдлар ясаганын сөйләр...

Охот диңгезенең карап торуга ук салкын, кырыс, усал дулкыннарын, томанга төренгән офыкны, су өстеннән сагышлы кычкырып очкан акчарлакларны төшерә иде ул кәгазенә. Ә кайвакыт җил салкынына йөзен каршы куеп, еракка карап, озак-озак басып тора.

Бер көнне шулай җил белән, дулкыннар һәм акчарлаклар белән сөйләшеп торганда, ул причал янындагы яссы палубалы баржа — плашкоут өстендә брезент киемле кешеләрнең ашыгып әрле-бирле йөргәнен күреп алды. Юлга чыгалар икән болар, дип уйлады, ярдан төшеп, якынрак килде.

— Әй, егетләр, кайсы тарафларга юл тотмакчы буласыз?

Агач мичкә тәгәрәтүчеләрдән берсе ачы җилдән кызарынган йөзен Зуфирага таба борды.

— Камчаткага,— диде.

— Алыгыз әле мине дә, ә?

— Без пассажирлар алмыйбыз.

— Мин пасажир түгел... Мин зур эш белән йөрим... Мине Камчаткада бик якын кешем көтә... Әгәр сезнең якын кешегез яныгызга килергә омтылса, ә башкалар аңа ярдәм итмәсә, ни әйтер идегез?

Ир кеше зур бияләйле кулы белән маңгаен сөртте:

— Якын кешегез диңгезчеме әллә?

— Ул — капитан!

— Хәзер, үзебезнең капитаннан сорыйм әле!

Шулай диде дә, ашыгып китеп барды. Озак тормады, кире чыкты:

— Сикер!— диде.

Зуфира болай ук кинәт буласын көтмәгән иде, каушап калды хәтта. Аның этюдниктан һәм кесәсендәге бер тәңкә акчадан башка нәрсәсе юк иде.

— Әйткән сүзең хак булса, сикер палубага!— дип кабатлады ир кеше.— Алдашсаң, ычкынып кал моннан, мин куып җитәрлек булмасын. Башка безнең күзгә чалынасы булма!

— Ал әле моны!— дип Зуфира башта этюднигын ыргытты, аннары үзе сикерде. Причалның нык такталарыннан тирбәлеп торган палубага барып төшкәч, чайкалып егыла язды, аягына чак басып калды.

— Бар, трюмга шыл,— диде ир кеше.— пешекче Марина янына. Палубада шәүләң дә күренмәсен.

Кая ул палубага чыгу! Стенага беркетелгән каты, тар ятактан ике атна буе башын да күтәрә алмады Зуфира. Инде ни күнеккән Марина да сукрана иде, чөнки стеналарга, почмакларга бәрелеп аның да тәне күгәреп бетте — диңгезнең бик тә тынгысыз чагына туры килделәр.

— Күрдем мин диңгездә йөзүнең рәхәтен,— дияр Зуфира үртәп Өмиткә.— Тик бер нәрсәне генә аера алмадым: әллә дулкын әйләндерә башны, әллә балык исе. Әкәмәт икән ул ис, корабтагы һәр кадакка сеңгән, палуба белән трюмны бер итеп чабып йөргән эттән дә балык исе килә!

Плашкоут Зуфираны Усть-Хайрюзово дигән поселокта төшереп калдырды да үз юлы белән китеп барды. Шактый хәлсезләнгән иде Зуфира. Шунлыктан үзенә яхшылык эшләгән диңгезчеләргә хушлашканда юньләп рәхмәт тә әйтә алмады.

Зуфирә Усть-Хайрюзовода шактый тоткарланды, кызы Халидәдән жылы кием-салымын, Магадандагы танышларыннан әйбер-карасын соратып хат язды, алардан посылка килгәнен көтте.

Ниһаять, Петропавловскийга килеп иреште. Инде бөтенесе җайланыр, дип өметләнгән иде. Ләкин монда да Өмитне очрата алмады.

— Тәмам аптырадым бит,— дип көлеп сөйләр Зуфирә Өмиткә.— Гостиницада урын юк диләр, баш тыгар җир юк. Ахырда җыештыручы булып ялландым. Ярты эш хакын үзләрендә яшәгән өчен түлим, яртысын ашарга җиткерәм. Шешә белән сөт, булка алам да, шулар белән тамак ялгыйм. Зарар юк, дигән булам, сугыш вакытында безнең әниләргә монысы да эләкмәгән әле, түзгәннәр...

Юк, мескен булып күренмәс Зуфирә Өмит каршында.

— Мин дә диңгезче булып китәргә ниятләдем бит әле,— дияр — БМРТга художество җитәкчесе булып ялландым.—БМРТ — большой морозильный рыболовный траулер дигән сүз икән, исеме чытыр-пытыр булса да, мәгънәсе бик зур. Кадрлар бүлегендә бик сөенеп алдылар, синдәйләр бик кирәк безгә дип әйттеләр. Җае туры килеп торганда нигә аңа Өмит алдында мактанмаска!— Алдан ук шактый акчасын да биреп куйдылар, хәзер инде мин гостиницада идән юып йөрмим, кунак булып кына яшим! Менә бер атнадан документлар әзер була, мин Находкага очачакмын, безнең БМРТ шунда ремонтта тора икән!

Шулай дияр Зуфирә, бер атнадан китәм дип, юри куркытыр Өмитне. Аның зәңгәр күзләрендә гаҗәпләнү, соклану, курку кебек төрле хисләрнең чагылышын рәхәтләнеп күзәтер. Әлбәттә, Өмит шунда ук каршы төшәр:

— Юк, мин үзем ярда чакта сине җибәрәмме соң!— дияр.

Әйе-әйе, ул кайткандыр инде, ул өйдәдер. Зуфирә аның кайдалыгын балык тоту флотларыннан да белергә тырышып караган иде. Ләкин анда «Төньяк балкышы» корабында хәзер башка капитан диделәр. Гасимов яңа корабка күчкән икән. Ниндигә? Анысын әйтергә теләмәделәр.

Дулкын ярга килеп сугылган кебек, диңгезчеләр дә бер булмаса бер кире әйләнеп кайта... Өмит тә шулай бер кайтып керер!

Ул кайткандыр, ул өйдә булырга тиеш...

Менә таныш йорт, кырыйлары киртләнгән күксел бетон баскыч. Икенче катка менеп җиткәнче, Зуфирәнең йөрәге ярсып тибүдән туктап калмаса гына ярар иде... Менә таныш ишек... Зуфирә коңгырт төймәгә үренергә көч тапмыйча, бераз басып торды. Әгәр дә өйдәге кыңгырау тавышыннан соң тагын элеккеге кебек ишек артыннан колакларны чыңлата торган тынлык кына ишетелсә?..

Зуфирә, күңелен язмышның иң ачы сынавына да әзер булырлык итеп, коңгырт төймәгә орынды. Менә әчтән зыңгылдаган тавыш ишетелде... Ах, бу йөрәк шул хәтле дөпелдәмәсә, чигә тамырлары сулкылдамаса! Чыннан да, аяк тавышлары бит бу, менә инде ишектәге ачкыч борыла, менә...

Зуфирә хәле бетеп стенага сөялде. Ләкин... Бу кем? Өмит урынында кем басып тора?

Уртача буйлы, ыспай гәүдәле, джинсы костюм кигән, утыз яшьләрдәге җирән сакаллы бу кеше нәрсә дип шул хәтле сөенеп авызын ерып карап тора?

— Сез... Сез биредә үзегез генәме?— дип, теленә килгән беренче сорауны бирде Зуфирә.

— Юк... Без икәү...

— Ә ул кайда?

Зуфирә йотылып эчкә карады, әмма беркемне дә күрмәде.

— Менә ул. Донна.

Сакаллы кеше янында торган зур җирән этне аркасынннан сыйпады. Зуфирә, ни дулкынланса да, бу ят кешенең йөзендәге елмаю әкренләп сүрелгәнен сизми кала алмады. Елмаюы сүнде, ә чагылышы авыз тирәсендә сакал-мыегына йогып калды. Хәер, анысы ирен тирәли төкләр аксылрак булганга гына шулай тоела иде бугай. Ир кеше ишекне ачканда Зуфирәне түгел, башка берәүне күрергә өметләнгән иде булса кирәк.

— Ә сезгә кем кирәк соң?— дигән җитди сорау ишетелде.

— Гасимов. Капитан Гасимов.

— Ул биредә тормый бит инде!

— Ничек тормый? Ул хатларында шушы адресны язган иде.

— Сез — Зуфирә буласызмы? — диде сакаллы һич көтмәгәндә. Аның сакалында сакланган елмаю тагын битенә таралды.— Әйдәгез, рәхим итегез, хуш киләсез!

Ул артка чигенеп, Зуфирәгә юл бирде.

Менә нинди шартларда яшәгән икән Зуфирәнең Өмите диңгездән кайткан чакларда! Идән тулы кәгазь тартмалар, ниндидер капчыклар, түр стенада майлы буяу белән ясалган картиналар. Аларда Камчаткага килеп кулына пумала белән буяулар алган һәркем өчен хас сюжет — өч янартау тасвирланган иде. Зуфирә күз сирпүгә аларның өйрәнчек кулы белән ясалганын, алгы план белән арткы планның бер-берсенә ябышмаганын күреп алды.

— Утырыгыз,— диде хуҗа, үзе тире җәелгән ятакка утырды. Ятакның яртысына диярлек эт тиреләре өелгән иде.

— Сез монда ярангада яшәгән кебек көн итәсез икән,— диде Зуфирә тиреләргә ишарәләп. Һәм өстәл янындагы җайсыз урындыкның кырыена гына утырды.

— Ә боларны мин үзем белән алып китәм. Итек тегәм мин алардан. Тире итексез булмый. Күп очракта карга күмелеп ятарга туры килә, ә минем сул аягым бик туңа... Мин, дөресен генә әйткәндә, сезне башкачарак күз алдына китергән идем,— диде ул актырып.

— Яшьрәк итепме?

— Әйе. Аннары татар кызлары кара күзле, түгәрәк йөзледер дип уйлый идем.

Бу кешенең сәеррәк тоелган елмаюы да, Зуфирәне танып, Өмитнең кайдалыгын әйтергә ашыкмавы Зуфирәнең эчен пошыра башлаган иде.

— Николаев мин... Вадим Николаев... Өмитнең дусты һәм тораклашы идем... Ә ул диңгездә бит хәзер.

— Кайчан кайта соң ул?

— Путина беткәч инде.

— Ә путина кайчан бетә?

— Ул хәзер плавбазага күчте... Башка кораблар кайтып беткәнне көтәчәк. Ә корабларның кайтуын көне-сәгате белән кем белсен...— Николаев Зуфирәгә туп-туры төбәп карады.— Сез кемне яратканыгызны беләсездер бит инде...

— Диңгезче ул дулкын кебек, ярга бер генә сыена да тагын кире китә, аны иярләп тә, йөгәнләп тә булмый, димәкче буласыз инде сез дә.

— Сез инде Камчатка әйтемнәрен белеп тә өлгергәнсез икән.

— Магадан мәкале ул.

— Анда да булдыгызмыни?

Зуфирә җавап бирмәде. Өмиткә дип әзерләп куйган кыйссаларын җиде ятка сөйлисе килми иде аның. Ул үзенең бер атнадан диңгезгә чыгып китәргә тиешлеген исенә төшерде. Бер атнадан! Аңарчы Өмит кайтырмы-юкмы, күрерме аны Зуфирә, юкмы... Мөгаен, күрә алмас, очрата алмас...

— Аңа радиограмма биреп була торгандыр бит?— диде Зуфирә.

Николаев аңа туры җавап бирмәде, бу юлы ул Зуфирәнең соравын ишетмәмешкә салышты.

— Ә Өмит миңа сезнең хакта күп сөйләгән иде,— дип куйды үзалдына.

Шунда Зуфирә аның фамилиясен исенә төшерде. Әйе, бер сөйләшкәндә Өмит аңа «Николаев — дөнья бәясе тора торган кеше» дигән иде түгелме? Шул кеше микәнни инде бу? Зуфирә аның ыспай гәүдәсен, елмаю сүнми торган йөзен тартынусыз-нисез тагын бер тапкыр карап чыкты.

— Гафу итегез, мин сезне чәй белән дә сыйлый алмыйм,— диде Вадим.— Без монда очып барган кошлар кебек бер туктап ял итеп кенә чыгабыз. Әле кичә генә Донна белән Гейзерлар үзәненнән кайтып төштек менә.

Аның сүзен раслагандай, җирәнсу-сары эт Зуфирәнең күзләренә ягымлы карап, сыгылмалы гәүдәсе белән аның тезләренә ышкылып үтте дә, аяк очына сузылып ятты.

— Менә бит ул ничек...— диде Вадим.— Бу минутта минем урында Өмит булса яхшырак булыр иде. Яки киресенчә...

— Аңлашыла... Минем урында шушы минутта бирегә башка берәү килеп керсә...— диде Зуфирә, ачы көлемсерәп.— Шулай бит? Сез кемнедер көтәсез?

— Без Донна белән күптән көтәбез инде...— Эт аның сүзен раслагандай йөнтәс койрыгын болгап куйды.

— Сез белмисезме: минем соңгы хатларымны алды микән ул?

Вадим тире җәйгән ятактан торып, ян стенага терәп куелган өстәл янына узды, Зуфирә аның сул аягына җиңелчә генә аксаганын сизеп алды.

— Сезнең хатларыгыз менә биредә.— Вадим майлы төргәкләр, каткан ипи сыныклары, бөгәрләнгән дәфтәрләр һәм ачык китаплар арасыннан бер уч конверт табып алды.— Мин аларны үзе кайткач тапшырырмын дигән идем,— диде.

— Китерегез монда!

Зуфирәгә хатларны ят кулларда күрү әйтеп бетермәслек авыр иде, ул аларны Вадим кулыннан ашыгып тартып алды да, кабаланып, бөгәрләп сумкасына тыкты.

Аның монда башка бер генә минут та торасы килми, ачык йөзле бу кешене дә, аның гамьсезләнеп идәндә җәелеп яткан зур этен дә күрәсе килми иде.

Шул ук вакытта ул үзенең хисләрен тыярга кирәклеген дә аңлый иде. Бу сакалбай нәрсәдер беләдер, нидер яшерә, Зуфирәнең язмышы өчен мөһим серне чишәргә теләми. Бастырып сорашу да кыен, телен тиз генә чишеп булмаслыгы көн кебек ачык. Сабыр итәргә туры килә, чөнки Өмит белән ике араны тоташтырып торган җеп шушы кеше аркылы уза...

Вадим аның уйларын укыгандай, гади генә итеп:

— Мин сезгә шалтыратырмын әле,— диде.— Берәр хәбәр булса, шунда ук сезгә җиткерермен... Мин сезне аңлыйм. Безнең икебездә дә бер ваем...

Ул тагын ямансу итеп елмаеп куйды. Тик бу юлы аның елмаюы Зуфирә өчен түгел, ә башка кеше өчен, ул зарыгып көткән кеше өчен иде булса кирәк. Әйе, һәркемнең үз ваемы, Зуфирә кайгысы белән генә яшәмиләр!

— Донна, әйдә кунакны озатып куябыз!

Эт сыгылмалы хәрәкәт белән торып басты да, ашыкмый гына ишеккә таба юнәлде.

Ә тышта күз ачкысыз буран купкан иде.

— Минә циклон килгән, быел беренче циклон, пурга башлана,— диде сагышланып Вадим. — Самолетлар очмый инде мондый чакларда.

— Озаккамы инде бу?

— Кем белгән! Бәлки өч көннән туктар да, ә бәлки атна буена барыр.

«Шулаймы? Көткән кешең тиз генә кайта алмас дип куркасыңмы, — дип үчләнеп уйлады Зуфирә. — Ә минем өчен буран нихәтле озаграк котырса, шул кадәр яхшырак. Циклон корабларны ярга таба куа, шулай түгелме?»

Ә пурга җир-күкне бер итеп котырына, кар да болытлардан үз ихтыяры белән генә төшмидер, аны бинһая зур көрәкләр белән ишеп төшерәләрдер сыман тоела иде. Зуфирә йөзен җилгә каршы борды: җил, син катырак ис, кораблар ярларга ашыксын!

*
* *

Иртән күзен ачуга Зуфирә тәрәзә янына килеп басты. Урамны ресторан бинасы каплап тора. Аның барлык стеналары күксел бетоннан катырып ясалган, бер тәрәзәсе, ишеге генә бар. Эченә яктылык түбәдәге тишекләрдән төшә, тишекләрне кар томаламасын өчен, өскә текә кыек ясап куйганнар. Кыекларның бер ягы пыяла, калган өч ягы бетон.

Камчатка архитекторларының материктагы коллегаларын уздырып мөгез чыгарырга тырышуыннан килеп чыккан сәер бер бина иде бу. Очлы кыеклар яссы түбә өстендә тырпаешкан колаклар кебек торалар, шуңа күрә халык ресторанны үз исеме белән «Авача» дип атамый, ә «Дуңгыз колагы» дип йөртә.

Өченче каттан карап торган Зуфирә «колаклар» арасында җемелдәп яткан йомшак карны күрде, ә еракта сопкаларга кагылып ак томаннар үтә иде. Вадимның сүзе дөрескә чыкмады: циклон үтеп тә киткән, пурга тынган. Зәңгәр күк чиста, кояш күтәрелеп килә.

Әмма Зуфирәнең күңелендәге сагыш китмәгән, өметсезлек болыты таралмаган иде. Нишләргә аңа, кая барырга, кемгә сүз кушарга? Зур бер шәһәрдә япа-ялгыз хис итте ул үзен.

Өстәлдәге кызыл телефон аппараты зыңгылдагач, ул сәерсенеп китте: моңарчы аны биредә кирәксенгән кеше юк иде. Тик сирәк кенә, анда да номерны ялгышып кына эләгәләр иде бу телефонга. Шуңа күрә ул башта трубканы алмаска дип уйлаган иде, өзми-куймый шалтыратып торгач кына, телефонга үрелде, талчыккан, битараф тавыш белән:

— Алло? Кем кирәк? — диде.

— Зуфирә! Сөенче!

Зуфирәнең йөрәге сулкылдап куйды.

Ләкин... бу Өмит тавышы түгел, аның тавышы калынрак, ә бу нечкәрәк, таныш та кебек үзе.

— Ник дәшмисез? Танымадыгызмы әллә? Мин бу! Вадим!

Вадим... Димәк... Өмит тә! Югыйсә нинди сөенеч булырга мөмкин?

— Хәзер үк Халактырка аэропортына килегез! Миңа вертолет бирделәр, үзәнгә кирәк-яракны илтәм! Бер капчык бәрәңге калдырып булса да, сезне алып барам!

Вадимның тавышында чиксез тантана яңгырый иде, әйтерсең лә ул алтын таулар бүләк итә. Зуфирәнең исә, киресенчә, күңеле төште.

— Я, нәрсә телсез калдыгыз? — диде Вадим отыры көррәк тавыш белән. — Такси алыгыз да — Халактыркага! Җылырак киенегез!

— Ярый... — диде Зуфирә.

Ул ашыкмый гына шкафтан төлке якалы пальтосы белән төлке бүреген алып киде, көзге каршына килеп басты. Кызыл төлке аның маңгае өстенә төшкән сары чәченә бик килешеп тора, яшәртеп җибирә.

Колагына кызы Халидәнең тавышы ишетелгәндәй булды:

— Ник үзеңә берәр чәшке бүрек алып кимисең син, әни? Чәшке бүрек модада бит хәзер. Әйдә, кибеттән якалыклар алабыз да, сиңа дөньяда юк фасонлы чәшке бүрек тектерәбез. Сызымын үзем ясап бирәм.

— Синең әниеңә чәшке бүрек килешмәс шул, кызым. Төлкенең дә кыйбатлысы, көмешсыман-карасы бармый әле миңа, җирәне, саф татарча иттереп әйтсәк, кызылы кирәк. Ишеткәнең бармы синең бер җырны: «Кызыл да гынай төлке — ураман күрке, батыр да гынай егет — ил күрке...» Аны сузып-сузып Мәрьям Рахманкулова җырлый.

— Ә матур кыз? — дип елмаеп сорый Халидә.

— Ә матур да гынай кыз — күз күрке. Белдеңме? Күз күрке булган кызга урман күрке кызыл төлке килешә...

Зуфирә ашыкмый гына урамга чыкты, узып барган машинага кулын селтәде.

Вадим аны аэропортның бер катлы бинасы янында, ап-ак кар келәме өстендә бизәк булып утырган күгелҗем тармаклы яшь каеннар төбендә каршы алды.

— Ә беләсезме, юлыбыз уңса, сез Гейзерлар үзәненә кыш көне барган беренче турист булачаксыз. Анда хәзер җәй көне дә беркемне кертмиләр, өлкәнең катгый карары бар! Халык күп йөрсә — тапталып, бозылуыннан куркалар.

— Нәрсә, капкасын бикләп куйдылармы әллә?

— О, аның капкалары әкияттәге кебек — җитмеш җиде! Үзегез баргач күрерсез әле! Камчаткада унар еллар яшәп тә, анда була алмаган кешеләр әллә ни чаклы!

Ул борылды да, сул аягына аксый төшеп, аэровокзал эченә кереп китте. Диспетчер бүлмәсендә шактый гына бәхәс булып алды. Зуфирәне утырту бәрабәренә Николаев кышлык ризыгының бер өлешен Халактыркада калдырырга тиеш булып чыкты.

Ниһаять, барысы да үлчәнде, килешенде, вертолет һавага күтәрелде. Очучылар кабинасы ягыннан брезент көпшә суздылар, аннан җылы һава өрдерелә икән. Ләкин Зуфирә ул көпшәне тезенә салып, җылынып утырырга теләмәде, уртадагы бензин тулы кызыл мичкәне, тартмаларны, капчыкларны әйләнеп, әле бер як тәрәзәгә, әле икенчесенә килде.

Уң якта иксез-чиксез зәңгәр дала — Тын океан җәйрәп ята иде. Бу — Зуфирәнең зәңгәр күзле мәхәббәтен алып киткән, ул гына да түгел, аның йөрәген, кайнар хисләрен үзенә алган киңлек.

Сул як тәрәзәдән ак түбәле, текә күкрәкле сопкалар күренә. Сопкалар арасыннан карасуланып елгалар ага, алар да, бөгәрләнеп ташланган тимер тасма шикелле, кискен борылышлар ясап, диңгез тарафына ашыгалар.

Елга буендагы уйсулыклар, сопкаларның сөзәк итәкләре урман белән капланган. Хәер, капланган дип әйтү дөрес үк булмас, чөнки мондагы урманнар бездәгечә түгел икән: кәкре-бөкре кәүсәле ташкаеннар бер-берсеннән биш-алты адым арада утыралар, кар өстендә аларның күләгәләре дә аермачык булып каралып ята. Сирәк-мирәк кенә яшел келәм кисәкләре күренеп кала — болары үрмәләп үсә торган эрбет куаклары.

Бервдә бер нәрсә дә икенчесенә күләгә төшерми, табигатьнең һәр бизәге «менә мин!» дигәндәй иркенләп, җәйрәп ята. «Әчкерсез, яхшы күңелле кешеләрнең уй-хисләре шикелле», — дип уйлап алды Зуфирә.

— Әнә, күрәсезме, сопкага аю менеп киткән, — диде Вадим Зуфирәгә якын килеп һәм, мотор гөрелтесеннән уздырыр өчен, шактый кычкырып. — Хәзер өнендә ятарга тиеш инде ул. Берәр нәрсәдән куркып уянган шатундыр, мөгаен...

Алда океанга сузылып кергән озын ярымутрау һәм аның аргы очында маяк күренде.

— Кронока борыны, — диде Вадим.

Ә аннан да ары океан зәңгәрлегеннән тар гына тасма белән аерылган зәңгәр күл ята иде. Аның карлы ярларында соры, ак кошлар кайнаша. «Кыр үрдәкләре мәллә?» Аларның бер төркеме, вертолет шавыннан өркеп булса кирәк, талгын хәрәкәт белән һавага күтәрелде.

— Аккошлар... — дип пышылдады Зуфирә, — үз күзләренә үзе ышанып җитә алмыйча. — Кар өстендә аккошлар!

— Алар моннан китмиләр, бирелә генә кышлыйлар, — диде Вадим, Зуфирәнең гаҗәпләнүенә шатланып, — Елга да, лиман да катмый, җим җитәрлек була.

Алайса, җылы суда аяклары туңмыйдыр, ләкин барыбер үзәк өзгеч булып тоелды бу күренеш Зуфирәгә — кар өстендә аккошлар.

Җанны тетрәтерлек итеп тасвирлыйсы иде бу күренешне. Иксезчиксез зәңгәр киңлекне, кырыс, мәгъръүр сопкаларны, бөгәрләнеп, таш араларыннан үзенә юл салган елгаларны һәм алар өстеннән очкан гүзәл кошларны! Кешеләр күңелендә ашкынулы, дәртле җыр кузгатырлык булсын иде ул картина!

Вертолет сопкаларга таба юнәлде. Каршыда, еракта, текә күкрәкле тауның үткен пычак белән кисеп алгандай яссы булып күренгән түбәсеннән бөтерелеп кара төтен ургылып чыкты, ялкын теле күренде.

— Карым вулканы ата! — диде Вадим кычкырып.

Менә ничек ата икән ул янартау — ерактан караганда салмак, әмма тыелгысыз көчле хәрәкәт белән сулыш алгандай, эчендәге уттөтенне биеккә, зәңгәр күккә ыргый икән ул! Әйтерсең лә эчендәге талпынуларга, сагышларга чыдый алмый!

Ә аның тирәли, күк гөмбәзенең зәңгәрлеге аркылы нинди аллы-гөлле тасмалар дугайланып сузылган тагын?

Бәй, бу бит... Бу бит салават күпере! Ул авызыннан ут-ялкынын бөркегән биек таудан зәңгәр диңгезгә таба бизәкле күперен сузган. Күз җитмәслек офыкка, Өмиткә таба...

Вертолет тарлавык буйлап оча башлады, янартау да, салават күпере дә күздән югалды. Ике яктан текә булып биек яр күтәрелә, аста таштан-ташка сикереп зәңгәр елга ага иде.

Ниһаять, килеп җиттеләр ахры, вертолет, тәгәрмәчләрен көрткә батырып, күкрәге белән кар меңдәренә ятты. Зуфирә, кабинадан чыгуга, йомшак көрткә чумды.

Сулда текә үр, уңда бушлык булып, аның артында тагын биек яр иде, алар үр белән бушлык арасындагы тар мәйданда басып торалар. Колаклар мотор шавыннан арына төшкәч, чыжылдаган, бызылдаган, сызгырган сыман сәер авазлар ишетелде.

— Менә шушы инде ул — атаклы Гейзерлар үзәне! — диде Вадим чиксез горурлык белән.

— Үзән! Кайда үзән? Таш кыяны ярып төшкән тарлавык лабаса бу!

— Ә бусы — минем йортым!

Кыя кукрәгендәге мәйданчыкта фанер белән тышланган ике катлы өй утыра иде.

Карга бата-чума шунда киттеләр, иркен өйалды аша үттеләр. Эчтә зур плитә, өстәл, эскәмия, көн күрү өчен иң кирәкле нәрсәләр генә бар икән. Ләкин күзгә иң элек ташланганы — стеналарны тоташ урап алган киштәләр һәм аларга тыгызлап тезелгән китаплар иде. Шунда ук кара такта, өстәлдә ачык дәфтәрләр. «Тәрәзәләре генә бар, югыйсә нәкъ Әбугалисина мәгарәсе булыр иде», — дип уйлап куйды Зуфирә.

— Кыш көне аскы катның тәрәзәләрен кар каплый, көрәп кенә бетерерлек булмый. Шуңа күрә икенче катны да ясарга туры килде, — диде Вадим аның күңелендә чагылып үткән сорауга җавап биреп.

Тар баскычтан менеп, өске катны да карап төштеләр — анда да шул ук кырыс мохит — каты ятак, такта өстәл, китаплар, дәфтәрләр иде.

Очучыларның өлкәнрәге мич яга башлады, яшьрәге вертолеттан әйбер-кара ташырга булышты. Вадим кыска тунын салып, күлмәкчән генә калды, җирән сакалы өстендә ике бит алмасы кызарып чыкты, маңгаен тир бөрчекләре каплады, ә үзе һаман күтәренке рух белән җитез атлап йөри. Авыр-авыр капчыкларны, әрҗәләрне күтәреп, билдән кар ерып килгәндә аның аксаганы бөтенләй сизелми иде.

Ниһаять, ул җиңел сулап тирләгән битен сөртеп алды да, эскәмия астыннан зур-зур киез итекләр тартып чыгарып, Зуфирәгә:

— Аяк киемегезне алыштырыгыз,—диде.

— Бер үзегезгә шул хәтле киез итекләр нигә соң ул?

— Монда кеше күп килә! Камчаткага аяк баскан һәр кадерле кунакка, иң зур сый итеп, гейзерларны күрсәтергә тырышалар, космонавтмы ул, академикмы, берәр танылган артистмы. Ә кунакларның күбесе—сезнең шикелле ыспай халык, ялтыравык ботинка киеп йөри.

Алар кар өстенә чыгып бастылар да уң яктагы бушлыкка таба киттеләр.

Бераздан тарлавык төбендә таштан-ташка сикереп аккан ашкын сулы елга ярына килеп басуга, кыштан яз аена күчкәндәй булдылар. Яр эргәсендә кар эрегән, тәбәнәк үлән яфраклары яшәреп ята, юеш балчыкта аяклар тая иде. Текә ярдан тагын да аска—җәй башына төштеләр. Биредә таш тишекләреннән кайнар тамчылар чәчри, су буенда төрле төстәге ташлардан түгәрәк, бизәкле мәйданчыклар ясалган.

Менә шундый мәйданчыкларның берсеннән, кызгылт чәчәклесеннән, күкрәктән кайнап чыккандай саңгырау аваз ишетелде, пар бөркелеп чыкты, аннары биек ярны узып өскә, югарыга су фонтаны күтәрелде. Елга шавын җир астыннан килгән ухылдау күмде, биткә кайнар сулыш бөркелде, күз алдында пар баганасы бөтерелде.

Менә нинди икән ул—гейзер!.. Зуфирә карап туя алмады—су таш чәчәкләргә коелып төште, җир бер көрсенде дә тынды, томан таралды. Кайнар тамчылар чәчрәвен елга челтерәве дәвам итә. Монда—җирнең кайнар кан тамырлары ачылган, йөрәк тибеше ишетелә, сулыш алганы сизелә иде.

Вадим нидер сөйли, тик аның сүзләре Зуфирәгә таман аша ишетелгәндәй була, әйтерсең кеше түгел, җир үзе сөйли иде аңа серләрен.

— Һәр гейзерның үз бизәге, үз биеклеге, ата торган вакыты бар. Алар бер-берсенә охшамаган...

«Кешеләр кебек икән?»—дип уйлый Зуфирә.

— Әйдәгез, хәзер өскә менәбез. Таеп егыла күрмәгез. Минем арттан гына барыгыз. Бу казанда кайнаган ләмнең кайнарлыгы алтмыш

градус. Ә менә бу таш тишеге «Җәһәннәм авызы» дип атала. Күрәсезме, эченнән быгырдаган аваз ишетелә. Гөнаһ нияләрен пешекли...

— Ә «оҗмах капкасы» бармы соң биредә?

— Карале, анысы бөтенләй башка килмәгән тагын,—дип кабынып китте Вадим.—Андый исемне кушардай урыннар да бар. Әнә, теге яктан агып төшкән шарлавыкны күрәсезме? Аның астына басып коенсаң, үзеңне оҗмахтагыдай итеп хис итәсең. Тотармын да шул шарлавыкка «оҗмах капкасы» дип кушармын әле!

Вадим үзе һаман алга ашкынды, тагын яңа гейзерларны, шарлавыкларны күрсәтергә ашыкты.

— Беләсезме, бу үзәнгә беренче булып аяк баскан кеше—хатынкыз булган бит, геолог, Татьяна Петровна Устинова. Кырык беренче елны, кайдадыр, кемнәрдер сугыш башларга әзерләнгән чакта, җирнең иң зур могҗизаларыннан берсен ачкан. Бер нәрсә тынгы бирми аңа: нилектән Шумная елгасы иң зәмһәрир суыкларда да бозланып катмый?

Ә Зуфирә эчтән генә Вадим белән бәхәсләште: «Юк, алай түгел, кар өстендә очкан аккошлар тынгы бирмәгән аңа. Ни өчен алар жылы якларга китмиләр, ни өчен шушы елга буенда кышлыйлар?»

Зуфирә Татьяна исемле ул хатынның кичерешләрен йөрәге белән тойгандай булды. Шулай булырга тиеш, юкка гына болай уфылдамый бит җир, аның кайнар тамырлары юкка гына ачылмаган, аларның кеше күңелләрен бер-берсенә тоташтыра торган көче булырга тиеш!

— Бер заман ул юлдашлары белән хәл алырга дип елга буена туктаган,—дип дәвам итте Вадим.—Тыныч кына утыралар икән шулай, ни күзләре белән күрсеннәр, каршыларында җир уфылдап куйган, аннары пых-пых пар бөркелгән, кайнар су атылып күтәрелгән. Котлары алынган боларның, аяк астыбыздан янартау ата башлый, ахрысы, дип курыкканнар. Бары тик кайнар су атып туктагач кына, Устинова: «Бәй, бу соң гейзер бит!»—дип кычкырып җибәргән.

— Ул ачкан могҗиза бөтен кешене таң калдырган,—дип дәвам итте Вадим сүзен.—Аңарчы бит гейзерларны бары өч җирдә—Исландиядә, Америкада, Япониядә генә бар дип исәпләгәннәр. Ә биредәге гейзерлар андагылардан да зуррак, көчлерәк, матуррак булып чыккан.

«Һәм күңелләрне сафландыра, рухны моңарчы син белмәгән биеклеккә күтәрә торганнары...»—дип өстәде Зуфирә күңеленнән. Шагыйрь Эдуардас Межелайтисның шундый юллары бар: «Мин җир белән күкне тоташтырып торам: кояш нуры минем аша җиргә үтә, җир сулышы минем аша күккә күтәрелә». Җирнең менә шушындый ноктасына килеп баскач, үзеңнең кояш нуры белән җир сулышы кушылганлыктан яралган табигать баласы икәнлегеңне аеруча нык тоясың...

Арып-талып, әмма күтәренке рух белән өйгә кире кайтып кергәч, очучылар белән бер табактан кайнар ит консервысы ашадылар, шушы үзәндә үскән алтын тамыр төнәтмәсен авыз иттеләр.

Очучыларның өлкәнрәге, түгәрәк йөзле, кыю карашлысы элекке килүләрендә булган хәлләрне искә төшереп утырды. Бер килүдә өй ишеген ачсалар, ни күзләре белән күрсеннәр, эскәмиядә росомаха ята икән. Идән астын казып кергән дә, ул кергәч идән тактасы үз урынына шап итеп кире яткан. Очучы белән Вадим моны тотмакчы булып икесе ике яктан килмәкчеләр икән. Ә теге ерткыч сары күзләрен елтыратып боларның һәр хәрәкәтен күзәтә, менә-менә өсләренә ыргылмакчы... Мондый көчле һәм сизгер җанварны коры кул белән тотып булмасын бераздан гына аңлаганнар һәм ишекне ачык калдырып бераз га чыгып торганнар...

Күңелле көлешеп, сөйләшеп утыру рәхәт иде. Ләкин очучылар ашыктыра башлады:

— Килгәндә салават күперен күрдегезме? Һава бозылырга ул, тизрәк кузгалыйк!

Әйе шул, каядыр чакыра иде ул салават күпере.

Халактырка аэропортына кояш баер алдыннан кайтып җиттеләр. Бер танышы Вадимны «Волга» машинасы белән каршы алды. Вадим каяндыр тимер кыршаулы сап-сары агач тәпән белән бер бәйләм сүс бау алып килде, аларны машинаның багажына урнаштыра алмый озак азапланды.

— Нәрсәгә кирәк ул сезгә?—дип сорады Зуфирә.

Мондый тәпәннәрне аның авыл җирендә дә күптән күргәне юк иде инде.

— Теләсә нәрсәгә ярый бу! Гөмбә тозлыйсыңмы, кәбестәме,—менә дигән.

— Ә бавы?

— Үзәндәге сукмак кырыйларына сузып куям мин аны. Килгәнкиткән кеше алай-болай ялгыш басып пешмәсен өчен. Гейзерит ташларын таптамаска да әйбәт. Тәртип кирәк безнең эштә!

Зуфирә башын чайкады:

— Кем инде хәзерге заманда тәпәннәр белән әвәрә килә!

Вадим кинәт тураеп басты, Зуфирәнең күзләренә артык җитди итеп, хәтта әрнеп карады; сакал-мыегыннан гел китми торган елмаю да бераз үзенең яктылыгын киметте сыман.

— Сез дә шулай уйлыйсызмыни?—диде ниндидер аңлашылмаган рәнҗеш белән.— Кешеләр, мәшәкатьтән котылабыз дип, үзләрен бик күп нәрсәләрдән мәхрүм итеп ташлыйлар. Инде сез дә шуны аңламагач, башкаларга ни кала? Сезнең хакта Өмит сизгер күңелле художник дип сөйли иде бит!

Зуфирәнең машинадан төшкәч тә гостиницага керәсе килмәде, урамнар буйлап китте. Ник рәнҗеде аңа Вадим, ни өчен шул хәтле әрнеп үпкәләде? Ул хаклыдыр, әлбәттә, хаклыдыр. Ләкин аның фикере, яшәешкә мөнәсәбәте белән килешмәү генә шул хәтле рәнҗүгә сәбәп була алмый бит әле!

Зуфирәнең борчылуын көчәйтеп, урам борылышы артыннан өч вулкан—өч янартау күренә башлады. Алар бик якын тоела, менә тагын бераздан яннарына ук барып җитәрсең кебек. Ләкин аларга кадәр ни ара икәнен белә Зуфирә. Аларның ак түбәләре кичке шәфәкъ нурында коена, иң биегенең түбәсеннән күксел томан күтәрелеп, югарыда ул да кып-кызыл төскә манылган. Янартау күкрәгеннән ургылып чыккан кайнар сулыш бу. Ә астарак, тау биленә күгелҗем шәл булып җиңел болыт уралган, тау итәген үзенең күләгәсе белән каплаган.

Бу күренеш белән Вадим арасында ниндидер уртаклык бардыр сыман тоелды. Вадимның да йөзе һәр чак балкып торса да, күңел түрендә ниндидер күләгә бар, ул күләгәдә яшеренгән сер аңлашылмас рәвештә Өмиткә, Зуфирәгә бәйле сыман иде...

*

* *

— Мин Өмитнең сезгә биргән бер вәгъдәсен үтәдем булса кирәк,— диде Вадим, иртәгесен телефоннан шалтыратып.—Ул сезгә гейзерларны күрсәтергә вәгъдә биргән булгандыр бит?

Зуфирә моны ачык кына хәтерләми иде. Шулай да аның өчен Өмитне беркем дә алыштыра алмасын искәртергә кирәк тапты:

— Ул миңа океанны күрсәтергә сүз биргән иде.

— Ә-ә, әлбәттә... Тын океанны беренче чиратта... Әйдәгез алайса, бүген океан янына барыйк.

Ә нигә бармаска? Зуфирәнең бүген бер эше дә юк иде.

Ярты сәгатьтән кечкенә яшел автобус гостиница ишеге төбенә килеп туктады. Вадим белән Донна Зуфирәне автобустан төшеп каршы алдылар.

— Сезнең әле шәхси автобусыгыз да бармыни?

— Камчаткадагы бөтен нәрсә минеке!—дип Вадим ярым шаярып җавап бирде.

Автобус аларны шәһәрдән алып чыкты да, итәкләре белән бер-берсенә тоташып утырган өч янартау яныннан ары алып китте. Таулар артында авыл, аның янында сыер фермасы чагылып калды, ә уңда яшелчә түтәлләре сузылып ята иде. Түтәлләр озын, араларына тирән итеп канаулар казылган—алары язын ташу сулары аксын өчен, ә җәйге коры көннәрдә сугарыр өчен кирәк икән.

Вадим элекке елларны Качматкага балыктан башка һәртөрле азыктөлекне кораблар белән материктан ташырга туры килгәнен, хәзер исә өлкә үзен яшелчә һәм ит-сөт белән тәэмин итү бурычын куйганын сөйләп барды.

Түтәлләр океан ярына ук барып тоташты.

Тын океан, исеменә туры килгәнчә, тыныч иде. Күз күреме киңлектә лазурь төсендәге зәңгәрлек белән балкып җәйрәп ята иде ул. Мондый нурлы, шул ук вакытта салкын, тыгыз җил белән себереп чистартылгандай саф зәңгәрлекне Зуфирәнең беркайчан да күргәне юк иде әле. Дөрес, ул аны кичә вертолеттан күрде, ләкин ярдан күрү бөтенләй башкача икән. Ничек итеп, нинди буяулар белән тасвирларга бу гүзәллекне? Еракта, күз күреме чигендә, диңгезнең күкрәге калкуланып, кабарып тора, су белән күк арасында бушлык бардыр кебек тоела.

Шул бушлыктан тыгыз салкын, тынгысыз җил агыла, ярга якынлашкан саен диңгезнең өстен ныграк тибрәтә, ул тибрәлү көчәеп дулкынга әверелә. Ниһаять, дулкыннар кабарынып, күбекләнеп, ярга ашкына. Читтән караганда текә сыртлы бу дулкыннар көмеш яллы зәңгәр чаптарларны хәтерләтә сыман тоелды Зуфирәгә. Иге дә, чиге дә юк ул күз иярмәс тизлек белән чапкан гүзәл тулпарлар төркеменең. Шуларның көмеш ялларына тотынып, офык сызыгының артына, җил туган җиргә барсаң иде дә, ак корабны, тыгыз җилдән һәм диңгез зәңгәрлегеннән күзләре зәңгәрләнгән ир-егетне күрсәң иде... Зуфирә, юеш комда тирән эзләр калдырып, тулпарларга каршы атлады. Иелеп суга үрелде, әмма көмеш ял урынына аяк очында ак күбек эреп юкка чыкты.

«Диңгезче—дулкын кебек, ярга бер генә сыена да кире китеп күздән югала. Аны иярләп тә, йөгәнләп тә булмый»,—дигәннәре хак икән...

— Күрәсезме, әнә, сулдарак, ниндидер җанварлар кайнаша, әллә сивучлар, әллә касаткалар инде,—диде Вадим.

Чыннан да, анда нәрсәдер бар иде. Судан әнә шома башлар калыккандай булды, елкылдап сыртлар кабарды. Якын гына да кебек үзләре. Күңел офык упкынына ашкына, анда тагын да гүзәлрәк күренешләр, күз күрмәгән җанварлар сине көтәдер кебек. Беринг та, Өмит тә, мөгаен, нәкъ менә шушылай океан ярына басып карап торганнардыр, зәңгәр киңлек аларны менә шушылай сихерләгәндер.

Кичен Вадим Зуфирәгә Авача култыгын күрсәтергә булды.

«Камчаткадагы бөтен нәрсә—минеке», дигән сүзе коры мактану гына булмаган икән, биредәге кешеләр арасында аның Зуфирә өчен бик ук

аңлашылып җитмәгән абруе бар иде. Катерда аларны зурлап каршы алдылар, капитан үзенең рубкасына чакырды.

Океаннан кайткан зур кораблар барысы да яр буендагы причалларга терәлеп туктый алмый, күпчелеге култык уртасына якорь сала. Алар белән ике арада, шәһәрдәге трамвай шикелле, кечкенә катер йөреп тора.

Эреле-ваклы баржалар арасыннан узып, катер култык иркенлегенә чыкты. Кичке эңгер-меңгердә балкып, каршы яктагы Вилючинская сопкасының карлы түбәсе генә шәфәкъ нурын тотып тора, акчарлаклар нәрсәгәдер өзгәләнеп кычкыра, катерны як-яктан саллы дулкын кыса иде.

— Су салкындыр монда,—диде Зуфирә.

— Ә монда аның җылы булганы да юк,—диде капитан.

— Әллә җәен дә коенып булмыймы?

— Коеналар үзе йөрәк януына чыдый алмаган кешеләр. Гыйшык уты көчәеп киткәндә гаҗәп шифалы, диләр.

Ярый әле, рубка караңгы иде, капитан Зуфирәнең яңаклары утлы күмердәй кызарып чыкканны күрмәде.

Катер култык киңлегенә серле сарайлар сыман үзенә чакырып торган корабларның берсеннән икенчесенә ашыкты. Килеп туктагач, аның палубасына бау култыксалы тар баскычлар төшерәләр икән, ә тәбәнәкләренең янтыгына катер үзе борыны белән генә төртелеп тора.

Өмитнең корабы нинди икән? Биектер, әлбәттә, тирбәлеп торган текә тар баскычтан ул мәгъруր кыяфәт белән, сынын туры тотып, нык адымнар белән төшәдер.

— Капитан, капитан!—дигән карлыккан тавышка Зуфирә артына борылып карады. Рубка палубадан шактый биек булганга, ишекне ачып бу сүзләрне әйткән кешенең җирән сакал баскан башы бусагадан аз гына югары күренә иде.

— Капитан, мин «Кыю»да төшәргә тиеш идем, өлгерә алмадым, зинһар, тагын бер әйләнеп кил инде.

— Авызыңны ачып тормаска иде! Икенче рейс белән килерсең!

— Капитан! Мин вахтага соңарам!

— Яп ишекне! Чит кешегә рубкага керергә ярамаганны белмисеңме әллә?

Ишек ябылды, әмма бер-ике кораб янында тукталуга, тагын ачылды:

— Капитан, ә, капитан!

Капитанның да йөрәге таш түгел икән.

— Ярар, күңел йомшак чакка туры килүең, шайтан вәсвәсәсенә бирелә инде, кунаклар хөрмәтенә генә,—дип кире «Кыю»га борылды.

Ләкин капитанның мәрхәмәте юкка булып чыкты. Катер «Кыю»ның янтыгына борынын төртү белән, буш палубага форма кигән берәү йөгереп чыкты да:

— Кирәкми! Төшермә! Кире кит!—дип, катерны кире этәргәндәй көчле хәрәкәт ясап, кулын селтәде.

Палубага бау аша үрмәләп азапланган сакаллыга капитан:

— Кире чык! Кире чык, диләр сиңа!—дип кычкырды.

Зуфирәгә кызык булып китте:

— Кешене эштән куу булды түгелме соң бу?—диде ул, Вадимга борылып.—Шушылай бер кул селтәү белән кешенең язмышы хәл ителдеме инде? Кая монда профсоюз? Кайда ике якны да тыңлап гадел хөкемен чыгаручы җәмәгатьчелек?

— Диңгез—бәхәсләшү урыны түгел,—диде Вадим.—Корабта ка-

питан сүзе—закон. Иртәгә идарәгә барыр да рәхәтләнеп бәхәсләшер әнә.

«Диңгездә законнар каты, анда сабан туйлары булмый,—дигән иде Зуфирәне эшкә алганда ак чырайлы ябык кеше.—Ял-мазар да юк анда. Балык килгәндә үз эшегездән башка да вахта торырга туры киләчәк, бар кеше белән бергә эшләрсез. Алты сәгать эш, алты сәгать ял».

Эш дигәне шул булачак икән: Зуфирә, кулына брезент бияләйләр киеп, балыкның вагыннан эресен аерып торачак. Ул үзенең Охот диңгезендә интекканнәрен исенә төшереп, тетрәнеп куйды. Рәтләп эшли алмаса, аны да шушылай бер селтәнү белән чуттан сызып ташларлар микән? Кырыс, ә кайчакта аяусыз икән диңгезнең законнары!

Алар өчәүләшеп—Зуфирә, Вадим, Донна—палубага чыгып бастылар. Корабларда төрле төстәге бихисап утлар кабызылган.

— Сез шәһәр утларының корабларга ни әйткәнен аңлыйсызмы?—дип сорады Зуфирә Вадимнан.

— Аңлыйм, әлбәттә,—дип җавап бирде Вадим.—«Сәлам сезгә кораблар, ди шәһәр, ерак диңгезләрдән исән-сау гына кайтып җиттегезме? Юллар бик авыр булмадымы? Карлы-бозлы давыллар хәлегезне алмадымы, усал дулкыннар какшатмадымы?»

— Юлларыбыз җиңел булмады, әмма без сынатмадык, дип җавап бирәләр шәһәргә кораблар, шулай бит!—дип, аның сүзен дәвам итте Зуфирә.—Без кар-бураннарга да, биек дулкыннарга да бирешмәдек, чөнки син безгә иң батыр улларыңны биреп җибәргән идең.

— Улларымның юлы уң булсын, алар альбатрослардан да кыюрак, чыдамрак булсын өчен мин бар көчемне куярмын, кораблар,—ди кала.

Вадимның бу сүзләреннән соң Зуфирә тынып калды.

Өмитнең дә корабы еракларданайләнеп кайткач кала утлары белән менә шушылай сөйләшәдер. Ләкин бармы шәһәрнең мең уты арасында бары тик зәңгәр күзле капитан өчен генә кабынганы, бармы аңа гына хәерле юл теләп җемелдәгәне?

Шушы хыялый сөйләшүгә ялгап, ишарә белән генә бу хакта Вадимнан сорарга микән әллә?

Ләкин нәрсәдер Зуфирәне тагын тыеп калды. «Түз, диңгез сабырларны, чыдамнарны гына үз итә»,—диде кала якты утлары белән.

*
* *

Алар экрен генә шәһәрнең үзәк урамы буйлап киттеләр. Мондый урам башка бер генә калада да юктыр—аның бер ягында биналар, икенче ягында причаллар, алар кырында диңгез краннары, баржалар, катерлар. Кала белән корабларның кул бирешеп күрешкән ноктасы.

Урам тын, күктән йомшак бәс коела, лампочкалар тирәсендә вак күбәләкләрдәй кар бөртекләре бөтерелә иде.

Менә алар бер кечкенә бакча турысына килеп туктадылар. Челтәрдән ясалгандай нәфис ябалдашлы агачлар ышыгында бер һәйкәл күренә. Алар бакча капкасыннан кереп, һәйкәл янына үттеләр. Гади генә иде бу һәйкәл—биек таш өстенә якорь куелган, аңа, һәйкәлнең тынычлыгын сакларга теләгәндәй, кар мендәре кунаклаган.

— Лаперуз һәйкәле,—диде Вадим.—Минемчә, безнең шәһәрдәге иң мәгънәле һәм матур һәйкәл бу. Бу кеше Франциядә туган, унбиш яшеннән корабларда йөзгән, кырык алты яшендә кораблары-ние белән юкка чыккан. Каберенең кайсы диңгез төбендә икәнен белгән кеше дә юк. Үлгәненә ике гасыр инде, җирдә аннан соң әллә ничә буын ал-

машынды, ә аңа булган мәхәббәт һаман кимеми. Мин һәйкәл янына киләм дә уйланам: бу кешене өзелеп сөйгән берәр хатын-кыз булды микән бу дөньяда? Үзе исән чакта сагынып, саргаеп яраткан бердәнбер яры булганмы икән? Нишләптер бу хакта бер генә белешмәдә дә, энциклопедиядә дә язмыйлар. Ул фәлән-фәлән диңгезләрдә йөзгән, аның карамагындагы фәнни тикшеренү кораблары фәлән дә төгән дип аталган, аның исеме белән фәлән бугаз атала... Ләкин ул бит тере кеше булган, чын мәгънәсендә ир-егет булган, башка кешеләр янып сөя белгәнне, ул сөймәгәндер дисезме?

— Ашкын йөрәкле кешеләрнең хисләре башкаларныкына караганда көчлерәктер дә әле,—диде Зуфирә.

— Соң, шулай булгач, табигый бит инде, аның күңеле мәхәббәт мәсьәләсендә дә буш булмагандыр! Ләкин ул туган илен дә, сөйгән ярын да ташлап, каядыр еракка, хәвефле юлларга чыгып киткән. Мин аны аңлыйм, кайчак шундый омтылыш була кеше күңелендә. Лаперузның ватандашы бөек фикер иясе Вольтер: «Яңа ачышлар ясаган кешеләр, шул ачыш юлында берничә адым гына ясасалар да, чын мәгънәсендә бәхетлеләр» дигән. Ләкин бу бәхет бик кыйбатка төшә түгелме соң, аның бәрабәренә кеше башка бәхетләрдән мәхрүм булмыймы! Әйтик, халык туган илдән, сөйгән ярдан аерылуны зур бәхетсезлеккә саный, ә Лаперуз кебекләр үзләрен шул бәхетсезлеккә дучар итеп, аннан зур бәхет эзләп китәләр. Ничектер, бәхет белән бәхетсезлек бер-берсенә килеп урала. Яңа ачышлар ясаган кешеләрнең язмышы күп очракта фаҗигагә дучар була. Гадәттәге чикләрнең аръягында ниләр барын белергә омтылган кеше гади кешеләргә хас бәхеттән мәхрүм итәлергә тиеш микәнни? Шушы ике бәхетне берьюлы тоеп яшәү мөмкин түгел микәнни?

Зуфирә ни дип тә җавап бирә алмады. Хәер, Вадим бу сорауны үзалдына гына бирде шикелле. Алар әкрен генә борылып бакчадан чыктылар, Донна, күләгә кебек, тын гына алар артыннан иярде.

— Мин, әлбәттә, Лаперуз түгел,—диде Вадим.—Ләкин минем үз океаным, үзем башлап үтәсе билгесез юлларым бар. Менә сез Гейзерлар үзәнендә булдыгыз бит, бәлки аңлагансыздыр.

— Әйе, ул үзе бер билгесез диңгез,—диде Зуфирә.

— Минем күңелем шунда береккән. Ләкин шушы иманымны иң якын, иң газиз кешемә аңлатудан гаҗизмен. Дөрес, ул бәлки аңлыйдыр да, ләкин ул минем бу иманымны кабул итә алмый, ул үзәнне минем кебек ярата алмый... Сез хатын-кыз, сез иҗат кешесе, хис кешесе. Бәлки миңа ярдәм итәрсез, бәлки аның күңеленә ничек ачкыч табарга икәнен әйтерсез?

Бераз тын бардылар. Вадим Зуфирәдән тиз генә җавап көтми, аның бары тик эчендәге зарын кемгәдер сөйлисе, серен уртаклашасы гына килә иде булса кирәк.

— Мин үзәндә эч пошудан беркайчан да интекмим, гейзерларның көндәлеген алып барам, хайваннарны, һава хәлен күзәтәм, күп укыйм. Ләкин мин дә адәм баласы, минем дә йөрәк таш түгел. Үзәнгә элегрәк туристларны китерәләр иде, мин аларга аңлатма биреп йөрим. Төркем арасында әле берәрсенең ягымлы елмаюы, әле берәр зифа буй-сын күзгә чалынып үтә, йөрәк сулкылдап куя.

Берничә ел шулай дәвам итте. Ләкин бәхетемә димме, бәхетсезлегемә димме, ниһаять, язмыш мине берәү белән очраштырды. Ул җәйне мин Кронока заповедлигында урманчы булып эшли идем. Гейзерлар үзәненнән ерак түгел, диңгез буенда булды бу. Кайсыдыр берәүнең акыллы башына заповедникта электр станциясе төзү фикере килгән бит. Бер заман геологлар килеп төште, трактор белән җир казыйлар,

тыр да пыр урман сукмакларыннан машина куалар. Бөтен җәнлек-җанварны куркытып бетерделәр. Ул гынамы, бер ишесе рәхәтләнде киек итенә, тиенде кызыл балыкка, уылдыкка. Үзләренә җитәрлек итеп кенә тотмыйлар, тартма-тартма тутырып өйләренә озаталар. Урманда әледән-әле мылтык ухылдап тора. Мин йөргән булам чабып, төрле оешмаларга шикаять язам, браконьерларны эзәрлеклим, мылтыкларын тартып алам, ятьмәләрен тураклыйм. Безнең арада каты сугыш башланды дияргә була. Ләкин геологлар арасында берсе,—зифа буйлы, ак йөзлесе күңелгә якынаеп китте бит. Көн саен очрап тора үзе, язын үсеп киткән гөл шикелле күңелгә һаман тирәнрәк тамыр җәя бара. Сизәм: торган саен ягымлырак елмая бу миңа...

«Бер дә гаҗәп түгел»,—дип уйлап куйды Зуфирә.

— Тиз аңлаштык без моның белән. Бергә урманнарда йөргәннәрне, кайнар елгаларда коенганнарны сөйләп тормыйм инде. Гашыйклар арасында була торган гадәти хәл анысы. Ике ай эчендә ике метр булып үсә торган шеломайник үләне шикелле тиз үсте безнең мәхәббәт. Мин, язылышыйк, кешечә яшик, дигән идем, ә ул язмышларны нығытып бәйләргә ашыкмады. Кем аңласын сезне—хатын-кызларны! Мин ул җәйне бик кызуланып теге Гейзерлар үзәнендәге йортны салу мәшәкате артыннан чаба идем. Я алла, ул йортның ничек салынганын, миңа күпмегә төшкәнен белсәгез икән! Хан сараена торырлык булды ул минем өчен! Кирәк-ярагын табасы, аны вертолет белән ташыйсы! Аның бит вертолетын да кил, бирәбез, дип тормыйлар... Аңарчы без Донна белән палаткада кышлый торган идек. Ә хәзер Ленаны ничек палаткада яшәтим? Җитмәсә бәби көтәбез. Минем бәхетне, минем гайрәтне күрсәгез иде сез ул чакта! Фантазер! Ә Ленам торган саен ныграк моңая, ләкин мин моңа әллә ни борчылмыйм, хатын-кызның четерекле чагы дип үземне тынычландырам. Ул өзми-куймый мине үзе белән Ленинградка китәргә үгетли, ә мин, монда яшибез, дим, башканы ишетергә дә теләмим, билгеле. Озак бәхәсләштек без шулай, әмма мин аны үз иманыма китерүемә ышанып яшәдем. Бер заман, Петропавловскийга врачка күренергә барам, диде бу. Ансыз булмый бит инде, беләм. Мин өйгә мич чыгарып азаплана идем, эшнең тыгыз вакыты, үзен генә вертолетка утыртып җибәрдем. Ике көн көтәм кайтканын, өч көн, инде вертолет та ике тапкыр килеп китте, ә бу кайтмый да кайтмый гына бит! Киттем моны эзләп шәһәргә. Ул Ленинградка кайтып китте, диделәр. Мин дә аның артыннан очтым. Барып таптым квартирын. Ишекне Лена үзе ачкач, аның сау-сәламәт икәнлеген күргәч, бөтен үпкәләрем онытылды, түбәм күккә тиярдәй булды. Сүз әйтә алмыйм, телем көрмәкләнә. Кире борылып чыгып киттем, бардым кибетләргә, ни бар акчама алдым күчтәнәчләр, бәби кирәк-яраклары. Кайттым. Ленага кочагы белән тоттырдым. Кич житте, Ленаның әтиәнисе, туганнары табын янына җыелды. «Котлагыз безне, дим, без бит ир белән хатын хәзер, озакламый бәбиебез дә булачак». Барысы да тасраеп миңа карап утыралар. Лена аякка баса, чыгып керик әле, ди. Чыктык күрше бүлмәгә. «Ни сөйлисең син?—ди бу.—Нинди бәби? Бернинди бәбиебез дә булмаячак безнең!» «Син... син баланы юк итәргә дә өлгердеңмени?» Мин ярсып аңа таба килә башладым. Ул куркып чыгып китте, мин караватка ауДЫМ. Кич буе янымa беркемне кертмәдем. Аннары тордым да саубуллашмый-нитми чыгып киттем. Кайттым кире заповедникка. Дөньям җимерелгән кебек йөрим шулай. Бер көнне кулыма телеграмма китереп тоттыралар: «Катер белән киләм, каршы ал!» Заповедник конторыннан газик машинасын сорап алдым. Пристаньга барабыз. Урман юлыннан каршыбызга йөк машинасы килә, выжт итеп яныбыздан узып китте. Кабинасында өч кеше,

кулларында мылтык, ауга барышлары. Мин үзебезнең шоферга кире борылып, тегеләр артыннан куарга куштым. Без куабыз—тегеләр куа, без чабабыз—тегеләр аның саен кызулый. Ну, безнең газик бит, машина артыннан ничек тә життек. Мин шоферга йөк машинасы белән янәшә барырга куштым, үзем, җаен туры китереп, тегеләрнең подножкасына күчтем. Ә аларның шоферы рульне боргалый, мине агач кәүсәсенә бәрдереп сыдыртып калдырмакчы.

Зуфирә кәкрәеп-бөкрәеп үскән ташкаен агачларын күз алдына китерде: аларга бәрдергән булсалар, Вадимның сөякләрен дә җыеп ала алмаслар иде.

— Ә мин кузовка үрмәлим,—дип дәвам итте Вадим.—Ниһаять, болар миннән котылып булмасын аңладылар. Туктадылар, берсе кабинадан атылып чыкты да, миңа төзәп атып та җибәрде. Мин төшеп азаплана идем. Пулясы аякка тиде. «Ахмак, дим, нишлисең? Төрмәдә черисең киләме әллә?»—«Син күптәннән минем бәгыремдә таш булып утырасың инде,—ди бу.—Миңа хәзер нишләсәм дә бер җавап бирәсе, үтерәм мин сине»,—ди. Күрәм: лаякыл исерек үзе. Тизрәк җиргә сикердем дә, машина артына ышыкланып, пистолетымны тартып чыгардым. Ул исерек бит, бүтән тигезә алмады, ә мин муенына, һәм, гафу итегез, касыгына тигездем. Ул арада пристань ягыннан кешеләр килеп чыкты, тегенең кулыннан мылтыгын тартып алдылар. Ә мин Ленаны күргә, «исәнме» урынына: «Син дә йөрисең шунда ачу китереп!»—дип кычкырганымны сизми дә калдым.

— Әйе шул,—диде Зуфирә уйланып.—Әгәр Лена белән мөнәсәбәтләрегез шул кадәр катлаулы булмаса, браконьерлар белән очрашу бу хәтле фаҗигале тәмамланмас иде, мөгаен. Сез артык ярсыгансыз, гасабилангансыз, сезгә карап алар ярсыган...

Зуфирә үзенең Эльвир өчен Румия белән дәгъвалашып йөргәннәрен исенә төшерде. Я алла, чыннан да шундый түбән тәгәрәгән чаклары бар идемени аның? Кемне сөясең бит, түбән кешене сөйсәң, үзеңнең шул дәрәҗәгә төшкәнеңне сизми дә каласың. Ничек диелә әле халык җырында: «Сөяр булсаң, сөймә, җаный, үзеңнән түбәннәрне!»

— Атышуда Ленаны турыдан-туры гаепләп булмый анысы,—дип дәвам итте Вадим.—Без еш кына үзебезнең сөйгән ярларга каты бәгырьле дә булабыз... Шуннан безне—ике яралыны—машина әрҗәсенә сузып салдылар. Юл дыңгырдык бит, поселокка барып җиткәнче минем имгәнгән аягымны ике кулы белән тотып кайтты Лена.

— Ә кем бәйләде, дәвалады?

— Шин салу, бәйләү хәтлесен генә үзем дә беләм анысы. Үзәндә бер ялгызы яшәргә күнеккән кешегә аны белмәү мөмкин түгел. Вертолет икенче көнне килеп житте. Петропавловскийдан мине Мәскәүгә озаттылар. Катлаулы операцияләрдән соң аягым җиде сантиметрга кыскарып калган иде. Доктор Илизаровка рәхмәс, үз методы белән озайтты мине.

— Ә Лена?

— Мәскәүдә чакта мин аны яныма китермәдем. Рәнжүем бик зур иде, гафу итә алмам кебек тоелган иде... Больницага минем янга галим карчыклар килеп йөрде, үзәннең кадерен белүчеләр. Алар мине ифрат яраталар бит.

— Ә теге браконьер?

— Ул хәзер төрмәдә. Алты ел бирделәр үзенә. Кайту белән иң беренче эшем итеп Николаевны эзләп табам, барыбер җир йөзендә яшәтмим, дигән сүзләрен китереп ирештерделәр инде. Сез хатын-кыз, әйтүе дә кыен, ләкин... кешеләр бит без!.. Минем пуля аның ирлеген зарарлаган, шуны гафу итә алмый икән.

— Әгәр ул әйткән сүзен чынлап торып үтәргә теләсә? Үзәндә бер үзегезне сагалап йөрсә? Курыкмыйсызмы?

— Беләсезме, Зуфирә, кеше өчен мәхәббәттән дә, яшәүнең үзеннән дә кадерлерәк нәрсәләр бар. Мин аны аңлатып бирә алмыйм, аны бәлки сүз белән әйтеп биреп булмыйдыр да, аны бары тик җыр белән яки буяулар белән йөрәктән-йөрәккә хис аша гына аңлатып буладыр. Башым исән чакта китә алмыйм мин үзәннән...

— Донна да ярдәм итә алмас, ахрысы, сезгә...

Зуфирә арттан күләгә шикелле ияреп килгән эткә борылып карады, тегесе аның карашын сизеп, аягына ышкылып узды.

— Минемчә, эт агрессиврак, сизгеррәк, усалрак булырга тиеш,— дип өстәде Зуфирә.— Ә бу, гафу итегез, ахмаграк та тоела миңа.

— Ахмак түгел, ул бик акыллы, бик сизгер. Мин үзем аңардагы явызлыкны бетерергә тырыштым. Җан иясен тешли белмәсен, усал итеп өрмәсен, беркемне дә әзәрлекли белмәсен, дидем. Күрәсез, ерткычны да яхшы күңелле итеп була! Ә кешеләр үзара мөнәсәбәтләрне үзләре хәл кылырга тиеш дип исәплим. Мин ул бандитка каршы торырлык көч табармын үземдә! Мине башка көчсезлегем гаҗизләндерә: ничек итеп Ленаның күңелендә үз йөрәгемдәге талпыну утын кабызырга, ничек итеп аңарда Гейзерлар үзәненә мәхәббәт уятырга? Ташлап китмәсен иде ул безне! Мине дә, үзәнне дә! Шунда минем белән бергә яшәүне бәхетнең иң зурысы дип санасын иде!

Зуфирә кыргый тарлавыктагы ялгыз йортны күз алдына китерде. Кышын тәрәзәләрен кар томалап куя икән... Әбугалисина мәгарәсе... «Ә син Әбугалисинадан уздырмакчы, мәгарәгә ялгыз гына түгел, сөйгән ярың белән кермәкче,— дип эчтән көлемсерәп уйлады ул.— Кем белән диген әле! Ленинград каласында туып үскән кыз белән! Сәнгатьнең кодрәтен чиксез дип уйлыйсыңмы әллә син? Мәгарәгә керсен өчен аны бөтенләй икенче кеше итәргә кирәк ләбаса!»

— Ә ул мине үз ягына аударырына ышана... «Бер заман кыргыйларча яшәүдән туярсың, акылга утырырсың, минем янга барыбер киләрсең, мин көтәм», дип яза...

— Әйтеп торасыз бит, берьюлы ике бәхеткә ирешеп булмыйдыр дип... Менә мин дә талпынып килдем, бик зур өметләр белән килдем, минем әле сез әйткән бәхетләрнең берсенә дә ирешә алганым юк,— диде сагышланып Зуфирә.

— Сезгә дә җиңел түгел... Һәм мин сезне өметләндерә дә алмыйм.

— Ә нигә сез миңа турысын гына әйтмисез? Ни булды соңгы өч ай эчендә?

— Мин сезгә бары бер киңәш кенә бирә алам. Театрда булдыгызмы әле сез? «Ә анңары тынлык» дигән спектакльне карагыз әле. Сезне бирегә ир кешегә, ягъни Өмиткә булган мәхәббәт кенә алып килмәгән, шулай бит? Лаперузларны, Берингларны билгесез юлларга дәшкән талпыну алып килгән сезне. Ни генә булмасын, мәхәббәтемдә бәхетле була алмадым дип, сез аяктан егылып ятмассыз.

Зуфирәгә кинәт эссе булып китте, ул бер сүз дә әйтә алмады.

* * *

Спектакль Зуфирә язмышына бөтенләй кагылышы булмаган хәлләр турында булып чыкты. Хәер, аның каенанасына булган мөнәсәбәтенә беразишарә бар иде анда. Ләкин ул хәлләр бит Зуфирә өчен үткәннәрдә калды һәм ул хәзер дә Сабира карчыкка карата кешелекле булуы, аны ахырынача караvы белән горурлана, бу мәсьәләдә аның вөҗданы саф, тыныч. Анңары, каян белсен Вадим ул хәлләрне? Әллә

Өмит сөйләгәнме? Сөйләсә дә, ул карчыкны искә алып утыруда ни мәгънә?

Зуфирә башта бик тә сәерсенде. Ләкин әкренләп ул үз борчуларын онытты, сәхнәдә барган вакыйгалар аны бөтенләй башка дөньяга, башка язмышларга алып кереп китте...

Кайдадыр бик еракта, җир шарының икенче ягында яшәп яткан карт белән карчык гомер кичергән йорт-җирләрен сатарга мәҗбүр булалар һәм балалары кулына калалар. Ләкин биш баланың берсе дә аларны үзенә алырга теләми. Бәхәсләшә, дәгъвалаша торгач, алар карт белән карчыкны бөрәм-берәм чиратлашып асрарга булалар. Шулай итеп, берсе анасын, икенчесе атасын үзенә ала. Илле ел бүе бер-берсеннән бер генә көн дә аерым яшәмәгән кешеләрне балалары аера... Алар икесе ике ерак шәһәргә китәргә тиешләр. Икесе дә инде башка очрашмаячакларын беләләр, әмма бер-берсенең күңелен аяп, бу хакта саубуллашканда ләм-мим сүз ычкындырмыйлар.

Җир шарының икенче ягында яшәп яткан карт белән карчыкның фаҗигале язмышы зур театрның иркен залында, кызыл бәрхет белән тышланган утыргычларда утырган йөзләрчә тамашачыларның күңелен биләп алды. Аеруча карчык игътибарны җәлеп итте, бөкрәебрәк килгән гәүдәсенең һәр хәрәкәте, күкрәк түреннән чыккан йомшак тавыш белән йөрәкләрне айкап ала иде ул. Бар халыкның йөрәген уч төбендә тоткандай, көлдереп, сокландырып, кызгандырып һәм елатып торды, һәркемне үз ихтыярына буйсындырды.

Соңыннан карт белән карчыкны әллә ничә тапкыр пәрдә каршына чакырып чыгардылар, туктаусыз:

— Браво, браво, молодец! — дип кычкырдылар.

Зуфирә театрга килеп яхшы эшләде, күңеле сафланып, рухы үсеп китте, әмма Вадимның кинаясе барыбер аңлашылмады.

Икенче көнне ул телефоннан шалтыратып шуны сорамакчы иде, ләкин Вадим аңа авыз ачарга ирек бирмәде:

— Кич белән безгә килегез, бездә бүген уңыш кичәсе була, — диде.

— Нинди кичә?

— Уңыш кичәсе, җәен җыйган уңышны барлыйбыз. Килегез, үкенмәссез, бездә бик кызыклы кешеләр була.

Кич җилле, буранлы иде. Автобуслар шыгрым тулы иде. Зуфирә билгеләнгән вакытка төгәл барып җитә алмады. Вадим белән Донна аны тукталышка чыгып каршы алдылар. Урамнан өйгә барып кергәнче, Вадим шуны аңлатты: алар һәр көзне шулай бер җыелып, җәен нәрсәләр күргәннәрен сөйлиләр, фотолар, слайдлар карыйлар икән.

Ишекне җиләк кебек пешкән, ак йөзле, соры күлмәкле, соргылт чәчле хатын-кыз ачты.

— Лена, — дип таныштырды аны Вадим һәм Зуфирәнең кемлеген аңлатты. Хатын ачык чырай белән сизелер-сизелмәс кенә итеп башын иде.

Бер карауда аның кемлеген бәяләп куйды Зуфирә: күп кенә хатын-кызларга хас ягымлылык балкып торган ачык йөзле, бераз пошмасрак, дөньяда үзе рәхәт яшәргә ярата торган һәм башкаларны да тынычландыра, күңелләрен күрә белә торган бер хатын иде бу. Гаилә өчен алыштыргысыз кеше, мәхәббәтле, сөйкемле хатын һәм йомшак телле, кайгыртучан, күп нәрсәне гафу итә белүчән ана булыр өчен яратылган җан иясе. Ирләрнең андыйларны яратмавы мөмкин түгел.

Лена соры песи шикелле йомшак хәрәкәт белән артка чигенде. Хәер, песи түгел, артында торган сыгылмалы гәүдәле Доннага охшаган иде ул!

Вадим Зуфирәне башка кунаклар белән дә таныштырды: озын гәүдәле, туры сынлы, ыспай киемле ир белән хатын, берсе — геолог, икен-

чесе — сейсмолог икән. Какча яңаклы, янып торган күзле яшь ирне Борис диделәр, анысы өлкә телестудиясенең операторы булып чыкты. Иң соңыннан, ничектер бераз ясалма хәрәкәт белән башын артка ташлап, туры кара чәчләрен икегә аерып озынча йөзе тирәли салындырып төшергән бер хатын-кыз урындыктан торып басты. Аның үз-үзен тотышы да, бик-үк чибәр булмаган йөзе дә, челтәрле ак кофта белән озын кара юбка кигән нечкә билле төз сынының һәр хәрәкәте дә игътибарны җәлеп итә, хәтердә сеңеп кала торган иде.

— Клара, — дип, озын бармаклы тар кулын Зуфирәгә сузды ул. — Аның күкрәк түреннән чыккан калын йомшак тавышы Зуфирәгә бик таныш булып тоелды. «Кайчан күрдем соң әле мин бу кешене? — дип уйлады Зуфирә. — Хәер, бер күрсәң онытылырлыкмыни? Күргәнем юк үзен, ә тавышы... бик таныш...»

— Сез Казаннан икәнсез, — диде Клара бәрхет күзләре белән генә елмаеп. — Безне якташлар дияргә була. Дөрес, мин үзем Чиләбе өлкәсеннән, Пласт шәһәреннән. Алай да сәхнәдә Казанская йөрим. Чөнки ирем Казаннан минем. Бәлки ишеткәнегез бардыр, Гасимов, Өмит Гасимов?

Зуфирәнең аяк астында идән чайкалып киткәндәй булды. Димәк, кичә бөтен театрны үз ихтыярына буйсындырып торган кортка — шушы артистка һәм ул... Өмитнең хатыны?

Күпмедер вакыт һушына килә алмый торды Зуфирә, менә аңына Вадимның сүзләре килеп төште, алар да әле йомшак, калын пәрдә аркылы ишетелгәндәй тоелды:

— Кызганыч, бүген менә арабызда Өмит юк, иң кызыклы кыйсса аныкы була торган иде.

Клара, башын артка ташлап, күкрәк тавышы белән көлеп җибәрде.

— Ә мин аны бүтән сезнең янга җибәрмим, җибәрмим, җибәрмим! Килсәк тә икәү җитәкләшеп килербез дә, җитәкләшеп кайтып китәрбез. Ленаны да котыртып куям, сезне ялгыз калдырмасын. Югыйсә сезнең үзегезне буйдакка санап, айлар буе монда бездән качып ята торган яман гадәтегез бар!

— Үзегез гаепле,— диде Вадим аның шаяруына кушылмыйча, житди итеп. — Араларны үзегез өзәсез. Мәңгегә өзгәндәй итәсез дә аннары ике арага тагын җеп суза башлыйсыз...

Аның бу сүзләрендә аермачык булып күңел сызлавы ярылып ятса да, Клара тагын аңламамышка салышты:

— Хатын-кызның капризы булыр инде. Ә сез гафу итәргә өйрәнегез. Шулай бит, Зуфирә, мин дөрес әйтәм бит!

Зуфирә тел тибрәтерлек хәл тапмады. Вадимның беренче очрашканда ук: «Ул бирегә кайтмас инде», — дигән сүзләре аңлашылды хәзер. Димәк, Зуфирә юлларда адашып йөргән арада, Өмит белән хатыны килешеп куйганнар икән, Вадим Зуфирәнең хатларын шуңа күрә Өмиткә бирмәгән икән...

— Кунаклар, табын янына рәхим итегез! — диде Лена.

Шунда гына Зуфирә як-ягына әйләнеп карады. Бүлмә танымаслык булып үзгәргән, капчыклар, тартмалар каядыр юкка чыккан, идән юылган, өстәлгә ак ашъяулык җәелеп, матур савыт-саба тезелгән. Тәрәзәдә сары пәрдә... Зуфирәнең элекке килүендә бар иде микән ул, әллә анысын да Лена элгәнме?

Өстәлдә чәчәкле тәлинкәләрдә кәтлитләр, итләр белән кайнарлап әзерләнгән ипи телемнәре, кызыл балык, уылдык, кысла ише ризыклар һәм ни бары бер шешә кызыл шәраб тора.

Сыйның иң зурысы — монда җыелган кешеләрнең «җәйге уңышы» иде.

Геолог төрле төстәге ташлар күрсәтә-күрсәтә, кайсы урында нинди казылма байлыклар ятканын сөйләде. Аның хатыны Толбачик вулка-

нының кайчан атачагын ни рәвешле алдан ук белгәннәрен, янартау янына галимнәрне, журналистларны алдан ук чакырып куйганнарын әйтте.

— Монда без барыбыз да үз кешеләр, яшереп-нитеп маташма, дөресен генә әйт әле: тагын кайчан җир тетрәячәк? — диде аңа иренчәгрәк тавыш белән Лена. Ул урындыкка шундый җайлап утырган, иркәләнгән мәче кебек күзләрен кыскан иде, аркасыннан сыйпасаң, мырлый башлар кебек тоела. — Усть-Камчатскийда, төнлә җир тетрәгәч, бер хатын урам уртасына ялангач килеш йөгереп чыккан, дип сөйләделәр. Ваннада яткан чагы булган, куркуыннан киенәсе барын оныткан, бичара. Тора икән шулай халык арасында шәп-шәрә килеш... Без дә шундый хәлгә калмыйк тагы!

Барысы да җиңелчә генә көлешеп алдылар.

— Коена бирегез! — диде сейсмолог шаярып.— Мин үземнең дусишләремне кыен хәлгә куймам, ванналардан чыгыгыз, дип алдан хәбәр итәрмен!

Аннары утны сүндереп, слайдлар карадылар. Какча яңаклы, янып торган күзле әлеге оператор Толбачик вулканының ничек атканын махсус вертолеттан төшереп йөргән. Чакрымнарча биеклеккә ыргытылган ут-ялкын, төтен-сөрем баганаларын, күктән коелгандай тирә-якка сибелгән зур-зур ташларны (алар вулкан бомбалары дип аталалар икән), су урынына эреп аккан ком-таш елгаларын, ул елгалар агымына эләгеп, дөрләп янган урманнарны, үзәннәрне... Нинди кечкенә, көчсез, зәгыйфь булып тоела икән Кеше бу һәлакәт, дәһшәт һәм шул ук вакытта сокландыргыч кодрәт каршында...

Ләкин барыннан да бигрәк үзәкне өзгәне, җанны тетрәткәне шушы дәһшәт каршында барча тереклек ияләренең бердәмлекләрен тою иде. Менә боланнар палатка янына сыенганнар, кешеләрдән ярдәм көтәләр, тычканнар аларның аяк арасына кереп күктән яуган ташлардан котылу чарасын эзли, эсселектән көйгән кошчыклар учка кунып тамчылап су эчә... Зур дәһшәтләр вакытында безнең барыбызны да бер язмыш көтә, без барыбыз да җир балалары, без бер-беребезгә ярдәм итәргә тиеш, ди иде гүяки бу күренешләр. Менә кайчан аермачык сизелә икән ул тереклекнең бердәмлеге — янартаулар уянып, тирә-юньгә ут кабынгач!

Вадимның слайдлары тереклек ияләренең рәхәт, тыныч, мул һәм гүзәл бер мохитта яшәүләре турында иде. Куаклар янында боланнар, жиләк ашап йөрүче аю, тездән җылы суда тыныч кына басып торучы аккошлар...

Вадим елмаеп-көлемсерәп үзе төшергән кадрларны аңлата, аның бөтен кыяфәтеннән бәхетле, тыныч булуы, хәтта бераз гамьсезлеге бөркелеп тора иде. Бу — Зуфирә белгән киеренке рухлы, таләпчән һәм хәрәкәтчән Вадим түгел иде. Ленаның гамьсезлеге йокканмы әллә аңа, әллә сөйгән яры янында бөтен җаны белән вакытлыча гына ял итүеме? Ни генә булмасын, Вадим да, үзе әйтмешли, адәм баласы бит!

Зуфирә тагын борылып Ленага карады: һаман шулай җайлы итеп, күзләрен кыса төшеп, рәхәт чигеп утыра. Җиндем дип уйлый торгандыр бәлки. Ләкин ялгыша. Бу вакытлы гына килешү, диңгезнең бераз-га гына тынып торуы, менә озакламый офык тирәнлегеннән ургылып чыккан җил аның өстен җыерчыкландырыр, дулкыннар кубар.

Ә бәлки киресенчәдер, Лена Вадимның иманын кабул иткәндер, аның белән калырга ниятләгәндер? Ай-һай, бу иркә соры песи йомшак диваннарсыз, затлы пәрдәләрсез, фирменный бутербродларсыз һәм күңелне кытыклый торган яңалыклар алып килүче дус-ишләрсез яши алырмы икән... Шәһәрдә үскән бала, аңа телевизор, трамвай, зур кибетләр, җылытылган, йомышка бөтен уңайлыклары да булган йорт кирәк... Аның каны да Вадим канына караганда сыеграктыр, мөгаен,

ул әкренрәк, талгынрак ага торгандыр... Ул канның агышын көчәйтерлек, бу йокымсыраган күңелне кузгатырлык бирәр көч бармы дөньяда? Вадим сәнгатьнең көчен артык югары бәяләми микән?

— Хәзер сүзне Кларага бирәбез,— диде кинәт калкынып, дәртләнеп киткән Лена. — Ну, Клара, котлыйбыз сине, бөтен шәһәр синә гашыйк! Соңгы ролең белән син бар кешене хәйран иткәнсең. Мин дә иртәгә үк барам. Шуннан берәр монолог укып күрсәт әле! Әйдәгез, кул чабып сорыйбыз!

Казанская бераз ясалмарак, мәһабәт хәрәкәт белән нечкә сынын турайтып торып басты. Зуфирәгә ул кыланчык булып күренде: «Кара чәч, кара юбка, ак йөз, ак кофта һәм кискен хәрәкәтләр... Саесканга охшаган», — дип уйлады ул көнчелеген тыя алмыйча.

— Спектакльне кабатлауның нигә кирәге бар? — диде Клара сәхнәдә күнеккән гадәте буенча шактый кычкырып. — Мин сезгә бер җыр җырлап күрсәтим әле. Георгий Поротовтан камчадалларның борынгы ыруг җырын отып алдым. Тыңлагыз.

Ул башын чайкап, чәчләрен таратып җибәрде, кинәт кечерәеп киткәндәй булды, кулларын түр стенадагы өч янартау сурәтенә таба сузып, күкрәк түреннән чыккан калын, йомшак тавыш һәм моңарчы Зуфирә беркайчан да ишетмәгән ят, ләкин шул ук вакытта бәгырьгә үтеп керә торган аһәң белән, моңлы һәм дәртле итеп башлап җибәрде:

Ковран тавы өсләреннән
Аккошлар очып бара...

Ул, кулларын баш өстенә күтәреп, очып китәргә теләгәндәй омтылыш ясады, челтәрле озын җиңнәр канатлардай җилпенде...

Ук атты тәзәп аларга
Бер аучы — йөзе кара...
Ук тиде аккош кызына,
Канаткаен сындырды.
Аның елау авазыннан
Таш таулар сыкрап торды...

Җырчы, сызлануны үзе кичергәндәй, кулларын тигезле-тигезсез җилпеп, сыгылып төште... Бу инде кичә театрда бөтен халыкны тетрәтеп тоткан карчык та, бераз кыланчык, саесканга охшаган артистка да түгел, бу — текә күкрәкле кыялар белән зәңгәр диңгез очрашкан бер урында, җирнең кайнар карынында яралган җан иясе иде... Ул үзенең барча тереклек белән бер тамырдан икәнлеген бөтен йөрәге белән тоеп тора, үзен ак далалар өстеннән талпынып очкан аккошлар белән бер нәселдән дип саный. Ул җирнең йөрәк тибешен зәңгәр күккә таба тәне аша үткәрә һәм кояш нурын җиргә тоташтыра... Ул табигать белән бердәмлеген, бөтен тереклек дөньясының бердәмлеген янартаулар яктысында бар галәмгә белдерә, шул бердәмлекнең тантанасын игълан итә...

Ике егет — ике аккош
Ашкынды кыз янына,
Күтәрделәр кызны алар
Көчле канатларына...

Юк, бу — җыр гына түгел, йөрәкләрдән йөрәкләргә агылган хис, тантана, тереклекнең мәңгелегенә, гаделлеккә ышаныч иде... Бик борынгы ата-бабалардан, кайчандыр тереклек яралган гасырлардан безнең йөрәккә килеп тоташкан изге моң бу...

Ковран тавы өсләреннән
Алар бергә очтылар...
Туганлыкка, тугрылыкка
Дан җырлады аккошлар...

Клара, кыргыйлык һәм нәфислек кушылган хәрәкәт белән куллары аккош канатыдай соңгы тапкыр җилпеде дә, башын иеп, йөзендә сабыр елмаю саклаган хәлдә, тынып калды.

Барысы да хисләнүдән, сокланудан гаҗиз иделәр. Зуфирә Ленага борылып карады да шаккатты: моңарчы песи булып йокымсырап утырган хатын танымаслык булып үзгәргән иде. Аның күзләре зур ачылып, анда киек җәнлек күзендәге кебек сизгер ут кабынган, гәүдәсе җыелып турайган, киеренкеләнгән, әйтерсең лә кыргый урманда ботактан-ботакка сикереп яшәүче селәүсен...

«Чын сәнгать мондыйларның да күңелен кузгатып, кан агышын кызулата ала икән... Вадим хаклы... — дип уйлады Зуфирә. — Әйе, кеше күңелен шушы рәвешле бер кузгату өчен бөтен гомереңне багышлаunion да үкенерлек түгел. Өмитнең: «Үзеңне янартаулар яктысында сынарга кирәк», дигән сүзләре менә шушы турыда булгандыр, мөгаен».

— Үзеңне «Мәнго» кызлары күрсә, көнләшүләреннән үләрләр иде, — диде, ниһаять, тынлыкны бозып Лена.

— Ах, шушылай рәхәтләнеп уйнарлык бер пьеса язучы булсын иде! — дип көрсенде Клара. — Янартаулар яктысында шушы җирдә туып-үскән саф һәм эчкерсез, олы йөрәкле нәфис кызны уйныйсым килә!

Ул хыялый күзләрен түрдәге өч янартау сурәтенә төбәде.

Зуфирәне беренче карашта ук сәерсендергән өйрәнчек рәсем иде ул, анда алгы план белән арткы планның бер-берсенә ябышмаганлыгы күзгә ташланып тора иде. Хәзер ул рәсемне өр-яңадан күргәндәй булды.

— Вадим, син әллә картиналар язуыңны ташладың инде? Кайчан алыштырасың бу иске рәсемеңне? — дип сорады сейсмолог хатын.

— Мин рәссам түгел. Оста барда кулың тый, диләр. Безнең арабызда чын рәссам бар бит әле!

Барысы да борылып Зуфирәгә төбәлделәр. «Син кем, әйдә күрсәт үзеңнең кемлегеңне, безгә тиң булсаң гына сине үз арабызга кабул итәчәкбез», — ди иде аларның карашы.

Ә Зуфирәнең янартаулар яктысында сынатмаслык казанышлары юк иде шул әле, юк иде... Ул үзен бу кешеләр арасында чит итеп тойды, ашыгып хушлаша башлады. Аны кыстамадылар. Вадим белән Донна озата чыкты.

— Ошадымы соң безнең дус-ишләр? — дип сорады Вадим.

— Нигә сез Казанская турында миңа алдан әйтеп куймадыгыз?

— Көчем җитмәде... Кешенең кан саркыган йөрәгенә тагын ничек пычак кадыйсың... Инде кичә барысын да аңлагансыздыр дип уйлаган идем, ә сез...

— Ул чыннан да искиткеч талант... Ленаны үз иманыгызга инандырырга теләсәгез, сез Кларага гына кушыгыз. Ул кеше күңелен теләсә нишләтә ала. Нигә сез бу үтенеч белән миңа мөрәҗәгать иттегез?

— Өмит белән аларның мөнәсәбәте бик катлаулы иде. Мин алар арасында буталырга яхшысынмадым. Миндә түгел кайгылары, үзләренеке дә баштан ашкан иде...

— Хәзер аралары җайланган бит инде! — диде Зуфирә сызланып. — Хәзер инде Клара белән рәхәтләнеп сөйләшә аласыз, минем кирәгем дә калмаган!

*

* *

Шулай итеп, Зуфирәнең соңгы өметен тартып алдылар. Аның йөрәгенә ут салганнарын, аны гомер үзмаслык газапларга дучар иткәннәрен белмичә, соңгы омтылышларынялкында көйдерделәр... «Туктагыз,

әйтми торыгыз миңа, минем алданасым килә, хыялларым дөньясында тагын бераз гына булса да яшисем килә... Яшьлектә генә ул һаман дөреслекне ачыкларга омтыласың, олыгая барган саен, ялганга ышанып булса да, хыялыңда гына булса да, бәхет дәрьясында гизәсе килә!» — дип пышылдады ул каршы искән җилгә. Җил аның сүзләрен алып китте, җавап итеп йөзгә усал кар бөртекләре генә китереп бәрде...

Бүлмәсенә кайтып кергәч, ул төлке якалы пальтосы белән төлке бүреген караватына ташлады да, күптән кулга алмаган этюдникны ачты. Хәзер инде ул Өмитнең портретын ни өчен яза алмаганын аңлаган иде. Ул аны бик өстән генә, зәңгәр күзле романтик, каядыр ашкынучан, тынгысыз күңелле, намуслы һәм ыспай, чибәр кеше итеп кенә күз алдына китергән. Аның язмышының бөтен катлаулыгын белмәгән, аның фаҗигаләрен күз алдына китермәгән.

Зуфирә кулында фломастер җанланды. Әйе, кешеләрне тасвирлаганда да, табигатьне сурәтләгәндә дә, бу катлаулы мәгънәне, җан газапларын һәм җиңү тантанасын — үз-үзеңне җиңү тантанасын! — тулысынча күрсәтә алсаң гына уңышка ирешәсең...

Биек сопкаларның шәфәкъ нурына коенган ак түбәләрен генә күрсәтү җитми, аларның биленә уралган болытлар күләгәсендәге җирне дә күрсәтә белергә кирәк... Иркен дингезләрдә чапкан көмеш яллы житез тулпарларның каян күтәрелгәнен һәм кая киткәнен, офык ягындагы упкынның тирәнлеген, суга бата-чума уйнаган җанварларның мәһабәтлеген аңлата белергә кирәк. Утлар кабызган корабларның матурлыгын гына түгел, аларның шәһәр утлары белән нидер сөйләшкәнен тасвирларга кирәк. Шуларның барысына да үзеңнең мәхәббәтеңне, соклануыңны, йөрәгең сызлавын куша белергә кирәк. Кечергәннәрнең төсләр һәм сызыкларга әверелеп, кеше йөрәгендә шундый ук соклану, мәхәббәт, йөрәк сызлавы һәм талпыну уятырлык булсын...

Менә Өмитнең йөзе, киерелгән каш астындагы нурлы күзләре... Бу күзләрдә аның шаулы диңгезгә мәхәббәте, батырлыгы, Зуфирә һәм Клара белән булган катлаулы мөнәсәбәте... Зуфирә аның хатыны белән ике арада нинди хәлләр булганын белеп бетерми, ләкин ике талантлы, олы йөрәкле кешенең мөнәсәбәте берничек тә гади генә була алмый... Аларның берсе дулкын, икенчесе яр булса, мөнәсәбәтләре җиңелрәк булыр иде, чөнки дулкын бер булмаса бер ярга килеп сыена... Ләкин Өмит белән Клара икесе дә диңгездәге көмеш яллы чаптарлар кебек... Гомер буе янәшә булу насыйпмы аларга? Ләкин монысы инде аларның үз эше. Зуфирәнең алар арасына керергә хакы юк... Аның шушы олы йөрәкле кешеләр алдында баш ию һәм бу чигенешнең җиңел генә бирелмәве дә чагылырга тиеш портретта...

Зуфирә кинәт үзендә бер җиңеллек сизде, аның җаны канатланган дай булды, ул канатлар аны моңарчы басып торган җирлегеннән күтәреп алып киттеләр, аның күңел күзе зирәкләнде. Шул ук вакытта тормышның бөтен ваклыклары аста калды. Зуфирә үзен бу минутта гаҗәеп кодрәтле, саф, сәләтле итеп тойды. Аның өчен тормышның олы мәгънәсе ачылды һәм ул мәгънә мәхәббәтнең үзеннән, хәтта кешенең гомереннән дә өстенрәк иде.

Онытылып эшләде Зуфирә. Кинәт идәннең бер якка шуышканын тоеп: «Ялыктым!» — дип уйлады. Ләкин өстәлдәге фломастеры тәгәрәп китеп, түшәмдәге лампочканың да чайкалып торганын күргәч, ул җир тетрәвен аңлады. Коридорда тавышлар ишетелде, кемнәрдер аның ишеге турыннан ашыгып узып китте.

Ул тәрәзә янына килде. Тышта буран тынган, кар очканы күренми иде. Зуфирә, тынын кысып, тагын идәннең шуышканын көтте. Ләкин тетрәнү башка кабатланмады. Коридорда тавышлар тынды, тышта кар өстендә яткан яктылык таплары юкка чыкты — күрәсең, тәрәзәләр караңгыланды, башка бүлмәләрдә утларны сүндерделәр.

Зуфирә дә караватка ятты, ләкин күзенә йокы кермәде, киресенчә, күңелендәге дулкын көчәйде генә. Күзләреннән ирексездән яшь акты, әмма бу күз яшьләре татлы иде. Ул үзендә бүген зур борылыш булганын, үзенең гомерендә иң бәхетле минутларын кичергәнен аңлый иде. Аңа бүген бөек сер ачылды... Бу бәхет бик сирәк кешеләргә генә бирелә, яңа утрауларга аяк баскан диңгезчеләргә, яңа ачышлар ясаган галимнәргә, кеше күңелен тетрәтә алган артистларга таныш хис иде бу. Вольтер әйткән чын бәхет иде...

«Рәхмәт сиңа, Өмит, — дип пышылдады Зуфирә. — Син миңа шушы бәхеткә ирешү юлын күрсәттең!»

Тәрәзәләрнең зәңгәрләнүен күрү белән, сикереп торып киенде ул. Аңа каядыр барырга, моңарчы эшләмәгән берәр эш кылырга кирәк иде. Ул Өмитнең бер вәгъдәсе үтәлмәгәнен исенә төшерде: кайнар күлдә коенмады бит әле Зуфирә!

Ул беренче автобус белән Паратунка авылына килеп төшкәндә, коену бассейны ачылмаган иде әле.

Зуфирә авылны карап килергә булды. Пыяла түбәле теплицаның ишек төбендә бер егет кар көрәп азаплана. Ул диңгезче киеменнән иде. Юлдан аңа таба тирән эз салынган, күрәсең, егет әле беренче кеше булып теплица янына үткән. Зуфирә, шул эзләргә басып, егет янына китте.

— Исәнмесез! Бу нинди теплицалар?

— Санаторийныкы.

— Кайнар чишмәләр белән җылытыламы?

— Шул инде, — диде егет бер дә исе китмичә генә. Ләкин аның кем белән булса да сөйләшәсе килә иде булса кирәк. Ул Зуфирәнең кыска гына сорауларына озын-озын итеп җавап бирергә тотынды, көрәк сабына таянып, үзенең Белоруссиядән икәнлеген, армиягә диңгезче хезмәтенә алынса да, корабларда йөзә алмавын, авырып китүе сәбәпле менә шушында күчерелүен сөйләп ташлады.

— Монда шул инде, кар да җил, җәйне күрми дә каласың, — диде ул сагышлы тавыш белән. — Ә безнең Белоруссиядә кыш бөтенләй булмый диярлек. Хәзер дә җып-җылы әле анда!

Ул теплица ишеген ачып, Зуфирәне эчкә алып керде. Түшәмгә хәтле үрмәләгән помидор сабаклары корый башлаган иде инде.

— Уңышны җыеп алдылар, шулай да сезгә авыз иттерерлек кенә табып була әле, — диде егет.

Һәм чыннан да эчтәнрәк ике кызыл помидор алып чыгып бирде. Шулай итеп, Зуфирәгә Камчатканың тагын бер сыен татып карау насыйп булды. Кем кулыннан диген әле, Белоруссия егете кулыннан!

Зуфирә, рәхмәт әйтеп, егетнең ак йөзенә карады. Әйе, бу егет өчен тормышның бер олы мәгънәсе ачылмый калыр, мөгаен. Өмитләр, Клаpалар, Вадимнар омтылган биеклек аны ымсындырмас. Егетнең күзләре, зәңгәр булса да, аларга диңгез зәңгәрлеге йокмаган.

Бассейн ачылган иде инде. Зуфирә кызгылт граниттан шәлпәп салынган, бакыр чүкеп ясалган сурәтләр белән бизәлгән бина эченә керде. Аңа өс-башын алыштырырга кабина күрсәттеләр, аннары бассейнга чыкканчы кайнар душта коенырга киңәш иттеләр.

Бассейн үзе бинаның икенче ягында, ачык һавада икән. Аңа таба илтә торган таш сукмакка резин көпшәләрдән кайнар су агып тора, ләкин барыбер урыны-урыны белән ялан аягың бозга басып, чирканып куя. Ләкин душта кызып чыккан тән туңарга өлгерми, ун-унбиш адымнан соң карлы ярдан кайнар күлгә керәсең...

Бассейн өстен пар каплаганга, чикләре күренми иде. Әле бик иртә булганга, Зуфирә ялгызы коенды. Ул бөтен тәнендә әйтеп бетергесез җиңеллек, рәхәтлек тоеп, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, җырлый-җырлый, бассейнны иңләп-буйлап түйганчы йөзде.

Судан элекке Зуфирә түгел, бөтенләй башка кеше чыккан иде инде. Әйтерсең лә җирнең күкрәгеннән кайнап чыккан бу шифалы су аның тәнен генә түгел, бөтен күңелен юды, аны барча ваклыклардан, шәхси тормышында булган югалтулар ачысыннан арындырды.

*
* *

— Диңгезчене тиешенчә озатырга кирәк, — диде Лена. — Соңгы кичне бергәләшеп ресторанда типтерәчәкбез.

Ул Вадим белән Зуфирәне шушы эшкә ризалатты. «Авача» гостиницасы каршындагы «Дуңгыз колагы»на керергә риза булмыйча, култык буендагы «Океан» рестораныга барырга күндерде.

Алар ишектән барып кергәндә, оркестр музыкантлары коралларын көйләп маташалар иде. Кечкенә сәхнәдән җирән чәчле таза егет сикереп төште дә, аларга каршы килеп, баш иеп сәлам бирде.

— Сез мине хәтерлисезме? — диде Вадимга. — Узган җәйне Гейзерлар үзәненә барырга ярдәм иткән идегез.

Ул шунда ук метрдотель белән сөйләште, аларны зур хөрмәт белән түрдәге өстәлләрнең берсе янына утырттылар. Лена, күзләрен мәче кебек кыса төшеп, ак муенын нәфис борып, музыкантның колагына нәрсәдер пышылдап алырга да өлгерде.

Беренче карашка, бу Казандагы «Аккош» рестораныннан күп кайтыш иде. Ләкин аның бик зур өстенлеге дә бар — биредә хөкем сөргән рух башка — икенче. Монда килгән кешеләр фидакарьлек, тырыш хезмәт белән яулап алган лаеклы бәйрәмнәрен итәләр иде. Аларның күбесе әле диңгездән кайткан гына, алар анда айлар буе алны-ялны белми эшләгәннәр, аяусыз дулкыннар белән айлар буе көрәшкәннәр, бишәр тонналы тралларны күтәргәннәр, елга булып аккан балыкны эшкәрткәннәр. Тозлы җилдә аларның йөзе каралган, каты баулардан, балык канатларыннан куллары тырналган, тирбәлеп торган палубада йөреп аяклары талган. Ниһаять, менә шәһәр аларны куанып үз кочагына алган.

Беринглар заманында да шулай булгандыр, аннан элек тә, хәзер дә шулай һәм җирдә диңгезләр һәм диңгезчеләр барында мәңге шулай булачак.

Оркестр дәртле көй уйный, халык онытылып бии, бу ашкыну теләсәң-теләмәсәң дә үзенә тарта.

— Мин бүген монда тамашачы гына, бүген королева — Зуфирә, — диде күзләрен ягымлы кысып Лена. — Вадим, чакыр даманы!

Зуфирә белән Вадим ашкынулы өермә эчендә чайкалдылар. Вадим чүгеп-чүгеп бии башлагач, Зуфирәнең күңелендә курку чалынып узды: «Ә аягы соң, аягы!» Ләкин курку шунда ук узды, алар бер көйне икенчесенә тоташтырып биеделәр дә биеделәр. Көйләр кемгәдер багышлана иде багышлануын, ләкин анысы мөһиммени! Көй — уртак хәзинә, кем күңеле белән кабул итсә — шуныкы!

Менә оркестрдагы җирән чәчле егет:

— Гейзерлар үзәненең генераль директоры Вадим Николаев һәм аның белән биегән кунагыбыз хөрмәтенә, — дип игълан итте.

Юк, монысы Зуфирә колагына ялгыш кына ишетеләдер. «Ай, былбылым»ны мондагы музыкантлар каян белсен? Ләкин әнә уйныйлар бит, өздерәләр генә, бөтен зал типтереп бии шул көйгә:

«Ай, былбылым, вай, былбылым,
Агыйделнең камышы...

Соныннан, инде чыгып китәр алдыннан, Зуфирә түзмәде, җирән чәчле музыкант янына барып сорады:

— Каян белдегез сез татар көен, каян өйрәндегез?

— Диңгезчеләр арасында татарлар күп бит, аларның да күңелен күрәсе килде, — диде музыкант. — Аннары Николаев һәм аның кунаклары хөрмәтенә нинди генә көй уйнасаң да аз, шундый кеше ул!

Шулай үтте соңгы кич, аерылышыр вакыт җитте. Озакка, ә бәлки мәңгегә. Гостиница ишек төбендә саубуллашканда, Лена, серле елмаеп, Зуфирәгә үзенең Ленинград адресын язып бирде.

Ләкин бу соңгы сөйләшүләре булмаган икән. Зуфирә бүлмәгә кереп, әйберләрен җыеп азапланганда, телефон шалтырады.

— Зуфирә, синең акча янчыгың минем сумкада калган бит, — диде Лена. — Дүрт сум акчасы һәм бер лотерей билеты белән.

— Билеты отса, отышын үзегезгә алырсыз, — диде Зуфирә.

— Ә беләсеңме, билетың отты, дияргә була. Синнән сөенче!

Зуфирә аңа әйтеп бирергә ирек бирмәде:

— Лена, кирәкми, кирәкми! Зинһар, берни әйтмә! Без хушлаштык бит инде. Мине китте дип санагыз, очты дип!

Ул җавап та көтмичә, рычагка басты һәм телефонны бөтенләй өзеп үк куйды.

Ләкин йөрәге сулкылдавын баса алмады. Бер мәлне үзе үк шалтыратмакчы иде, ләкин тыелып калды: кирәкми, кирәкми! Нигә газапларны озайтырга!

Автобус шәһәрдән караңгылы-яктылыда чыгып китте. Соңгы йортлар турыннан узгач, каерылып бер арткы тәрәзәдән карады Зуфирә: яктырып килгән һавада ике биек багана өстенә куелган ике җилкәнле корабны күрде ул. Беринг кораблары хөрмәтенә куелган кораблар — җир читендәге каланың символы иде бу. Кораблар җилкәннәрен җилпеп хәерле юл теләп калдылар сыман.

Елизово аэропортында озак көтәргә туры килмәде. Зуфирәнең юлы башта — Хабаровскига, аннан Владивостокка, аннан соң гына Находка портына иде. Ә Хабаровскига рейслар күп икән.

Үзенең рейсын игълан итүгә, Зуфирә тар ишеккә беренчеләрдән булып узды. Шул чак бөтен аэровокзалны, бөтен тирә-юньне яңгыратып, микрофоннан хатын-кыз тавышы: «Хабаровскига баручы пассажир Надыйрова, сезне белешмәләр бюросы янында көтәләр», — дип игълан бирде. «Мине! — диде Зуфирә. — Өмит!» Ул үз-үзен белештермичә кире ишеккә ташланды, ләкин аннан тыгызланып каршыга халык керә иде, ә билет тикшереп торучы форма кигән хатын, йокысы туймаудан кәефсез чыраен тагын да ныграк чытып, аны беләгеннән тотып туктатты: «Сез кая тагын? Күрмисезмени, комачаулыйсыз?» Зуфирә кинәт айнып киткәндәй булды: чыннан да кая ашкына ул? Ул, халык аша үрелеп, залга карады. Белешмәләр тәрәзәсе янында Вадимны, Доннаны, алар белән янәшә Өмитне күреп алды.

Зуфирә аңа күзләре туйганчы карый алмады, халык агымы аны үзенә ияртеп эчкә алып кереп китте.

Аннары инде ул үзен тәмам кулга алды, аэродром бетонына чыккач, халык арасында буталырга, күзгә ташланмаска тырышты. Тик самолет баскычыннан менгәндә карамый түзә алмады: тимер коймa янындагы халык арасында Өмит, йолдызлар арасындагы тулган ай шикелле, әллә каян күзгә ташланып тора иде...

Ә алда, өч янартауның якты түбәсендә иртәнге кояшның беренче нурлары балкый иде. Самолет күтәрелде дә, көньякка таба юл алды.

# Галимҗан Латыйп

## КҮҢЕЛДӘ—ЯЗ

### Түтәлләргә гөлләр күчерәм

Агач башларына тияр-тимәс
агылалар көзге болытлар.
Җәен яңгыр, кышын ак кар булып
җирне алар күпме җылыткан.

Карый кояш болытларны тишеп
урманнарга, кырлар өстенә.
Ул аз гына форсат чыккан саен,
учма-учма нурлар төшерә.

Төркем-төркем булып кыр казлары
җыеналар җылы якларга.
Соңгы тапкыр алар каңгылдашып,
хушлаштылар төшеп Сакмарга.

Без аларга изге теләк теләп,
куллар болгап калдык озатып.
Ачылганнар инде каз юллары
зәңгәр тасма булып югартын.

Җырлы кошлар җырсыз калмасын дип,
өнсез калмасын дип кешеләр,
сызганам да күлмәк җиңнәремне,
түтәлләргә гөлләр күчерәм.

### Безнең авыл

«Тау башына салынгандыр безнең авыл»...
Бер кечкенә инеше бар, урманы бар.
Бу авылдан чыгып киткән егетләрнең
Сагындырып кайтып керер юллары бар.

Урамнарны иңләп, нәфрәт җыры белән
Күтәрелде алар явыз яуга каршы.
Тынды туплар Берлин урамнары буйлап,
Җир йөзенә яңгырады Җиңү маршы.

Керде шатлык ишекләрне каерып ачып,
Җиңү килде. Язгы житү кояш иде.
Булганы юк иде әле мондый шатлык,
Бөтен дөнья бүрекләрне күккә чөйде.

Күтәрелде, җилфердәде ал байраклар,
Тамды яшьләр шатлык белән, сагыш белән.
Җиңү көне тантанасын андагыча
Һич кенә дә сөйләп биреп булмый телдән.

Кайтты солдат, авыл кайнар мунча якты,
Каклаган каз итә белән ашын салды.
Тулы түгел иде табын... — Сугыш үткән
Юллар буйлап ярты авыл ятып калды.

Көтә-көтә кайтмый калган балаларын,
Маңгайдагы җыерчыгы аналарның —
Тирәнәйде — сызым-сызым бураэналар,
Ул юлларны син сызмаган, мин сызмаган...

Мондый хәлләр җирдә кабат булмасын дип,
Бөтен авыл җиң сызганды, буды билен.
Нычка яши бер кемгә дә сер бирмичә
Күрше-күлән, туган авыл, Туган илем.

Ут ыргытып уйнаучылар — пошаманда,
Хисаплашмый кара хәзер безнең белән!
Ал байраклар нык кулларда җилфер-җилфер,
Иелмәскә, егылмаска күтәрелгән.

## Соң булса да

Акыл безгә соңлабрак керде,
соңлабрак килде егетлек.
Соң булса да
янартаулар булдык,
чуен койдык, тимер эреттек.

Чабатадан, иңгә биштәр асып,
чыгып киттек Урал ягына.
Зимагурлар исе сеңсен диеп,
авыл малаеның җанына.

Мин әткәйнең өметләре идем,
озатканда күзе яшьләнде.
— Нишлисең бит, — диде,
бу заманда
тотып буламыни яшьләрне:

Җае чыкса,
укуыңны кара,
белем кирәк хәзер кешегә.
Сиңа, улым,
хәер-дога миннән,
тап төшермә кылган эшеңә!..

Николайдан калган «мирас» белән
ерак китеп булмый, аңладым.
Шакысам да уку йортларының
ишекләрен ача алмадым.

Магнитканың кайнар цехларында
Әлифбадан эшне башладык.
Җиңел түгел иде безгә ул чак,
кыенлыктан ләкин качмадык.

Ликбезларны үтеп, ачыла төштек,
җан ныгыттык,
буын ныгыттык.
НЭП артыннан кулак фетнәләре,
төн йокысын хәтта оныттык.

...Акыл безгә соңлабрак керде,
соңлабрак килде егетлек.
Соң булса да,
янартаулар булдык,
чуен койдык, тимер эреттек.

## Ни дип җавап бирербез икән

Бик сагындым сине, Базы буе,
Бик күрәсем килде бу юлы.
Шуңа күрә очып кына кайтам,
Киткән иде алып су юлы.

Күпме сулар акты ул чактан соң,
Ничә тапкыр язлар килделәр.
Ярларың да кечерәеп калган,
Элек алар биек иделәр.

Инеш кенә булып калган сулар, —
Җитәр-җитмәс чыпчык тезенә:
Оят хәзер «минә безнең су» дип
Күрсәтергә кеше күзенә.

Ак чабаклар йөзми, акчарлаклар
Әйләнмиләр очып күлләрне.
Ә өлкәннәр: «Без яшь вакытта» дип,
Сагынып кына сөйли үткәнне.

Бу мирасны кемнәр калдырган, дип,
Киләчәкне кем ул оныткан?!
Ни дип җавап бирербез икән соң
Шундый сорау бирсә оныклар?!

# Зиннур Мансуров

## ВАКЫТ АГЫШЫ

•

### Искәртү

Күз — алтын бизгәге...
Шулай ул
кешене ел саен искәртә:
«Үтелгән вакытның кыйммәтен
алтынга күчереп исәплә!..»

Күз — алтын сарае...
Бар анда
хикмәт тә, акыл да, исәп тә...
«Син кылган эшеңнең зурлыгын
алтынга күчереп исәплә!..» —

Күз безне ел да бер искәртә...

•

Гомере буе Иделдән аерылмаучы маякчы карт турында уйлап.

Син Иделне яттан беләсеңдер:
кай урында — тирән,
кайда — сай.

Ә ялгышың — йөзгә тапкырланыр —
хәтереңне язлар алдаса...

Син Иделне яттан беләсеңдер:
кай урында—тирән,
кайда сай.

Каргыш — кемгә? —
Давыл кочагында
янар маяклар да адаша.

Син Иделне яттан beлəсеңдер:
кай урында — тирән,
кайда — сай.

Идел — гомер...

Кәгъбәләрен ача барган саен,
бусы хәйләкәррәк алдаша...

## Тererәк бул!..

Хаксызлыкка сугыш ачкан чакта
рухым аваз сала:
«Кем көчле?
Тererәк бул! —
Тартып алмасыннар
өлешеңә тигән көмешне...»

Кырыслык бир, дөнья!..
Беркатлылык
һәм сабыйлык бездә җитәр лә.
Җиңел түгел —
үзенекен алып,
үзеңнекен биреп китәргә.

Бәлки әле явызланырбыз да
әрсез бәндәләрдән үч алып.

Хаксызлыкка сугыш ачкан чакта
син уяу бул, — гадел усаллык!..

## Толстой үлгән тукталышта

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне...
М. Җәлил.

«Башка дөнья эзләп китәр өчен
каян алган икән көч?!» диләр.
«...Шушы китү аны үз-үзенә
алып кайткан», дип тә өстиләр.

Юлдашларны тыңлыйм, ә үземнең
ни дип әйтергә дә тел бармый.

...Астапово.
Никтер искә алам
читкә китеп үлгән филләрне...

## Савыт ватыклары

Бу тормышта савыт-саба
шалтырамый торамы?..

Гасырлардан ишетелә:
«Бәр чүлмәген, ор җамын!..»

Савыт-саба каршы тормый —
ул берсүзсез җиңелә.

Халыкара низагларда
кәл булмаган ни генә?!

Кеше гүя гомер буе
чүлмәк ваткан[1] бар көчкә.

Касәләрнең, я, күпмесе
ватылган соң бәхеткә?..

Тәшенерсең: җир катламын
ачып, аска тәш кенә.

...Болгар... Савыт ватыкларын
тезәм чирәм өстенә...

## Әй, табигать!..

Үзе булып калыр һәр нәрсәгә
сайлап бирәсең син үз төсен.
Күзем — шаһит: быел бер сыерчык
нигә акбүз булып үсте соң?!

Үлем-күздән яшерә алырсыңмы
шушы канатлы, тере яраңны?..

Син дә кайчак ялгышасың бугай
ак, дип әйткән сыман, караны...

## Ничек?..

Каты күзлесеннән сакланам, дип,
кулмәгеңне юдың туйдан соң.
Хәзер менә ап-ак шомыртыңа
кызыл яулык бәйләп куйгансың:

Күз тимәсен, имеш, шомыртыңа
һәр язда да шулай ак сарсын.

Ә син үзең күңел пакьлегеңне
яман күздән ничек сакларсың?..

---

[1] Сабан туенда чүлмәк ватуны күздә тотып. Автор.

Рәйсә Юсупова

# ЧӘЧӘКЛӘР БӘЙЛӘМЕ

1

Нишләргә? Ике ай газапланып та, ник бер алга китеш булсын. Әллә югыйсә... ялгышканнар инде? Бөтенесе дә. Аның колагына өч яктан өч аваз килгәндәй була.

«Менә бит... үткән заман хатын-кызының язмышы... Бүгенге тормышның кадерен белү өчен аларны онытмаска кирәк... Сәхнә иlаhи көч ул». Моны Өфе сәхнәсеннән «Кара йөзләр» спектаклен карап утырганда балалар йорты директоры Әхмәров агай әйтә. Унөч яшьлек Гөлсем йөрәгенә театр дип аталган олы сәнгатьнең бер тамчы җылы яңгыры тамгандай була.

«Беләсеңме, сеңелем, эшли алмастайны да эшләргә кирәк. Шул вакытта гына үзеңне чын кеше итеп санарга ярый».—Бусын балалар йортының уку отличнигы, комсомол секретаре, Гөлсемнең бердәнбер газизе-иманы, бертуган абыйсы Зөбәер әйтә.

«Син — чын актриса, Гөлсем... Син иҗат иткән образлар күпме йөрәкләрне тетрәндерер, җылытыр әле...»— Мәскәүдәге М. С. Щепкин исемендәге театр училищесы укытучысы профессор Михаил Николаевич Гладков сүзләре.

— Булмый. Булмый миннән, Марсель Хәкимович, күрмисезмени?!

Керфекләрдә яшь тамчылары.

— Эзләнергә кирәк, Гөлсем, эзләнергә. Эзләнергә һәм табарга!— ди режиссер.

— Эзләнмәгән кая... Базарда бәрәңгегә чират торганда да Айсылу булып сөйләнәм икән. Кешеләрнең шикле карашын тойгач кына Гөлсемгә әйләндем. Трамвай, троллейбусларда да йөз, күз хәрәкәтен, иреннәр кыймылдавын күрмәсеннәр дип, иң алга үтәм. Уйлыйм, эзлим... табылмый гына.

— Беләсеңме, Гөлсем, син киресен эшләп кара әле.

— Ничек киресен?

— Гел киресен. Айсылу көләргә тиеш булса — син ела, елар урында көл, шатланса — боек, боегу кирәк чакта — шатлан...

Шулай эшли Гөлсем һәм... таба. Күңелдәге салкын, туң, ясалма образ чынга әйләнә. Гөлсем Айсылу исемле кыз булып яши башлый. Тик акылдан шашкан кеше көлүен ничек бирергә? Гөлсем көлүе Айсылу көлүен һаман бирә алмый. Ясалма. Ялган көлү.

Тагын эзләнү... Студентлар төркемендә кызлар көләләр. Юк, «ул» түгел... Кибеттә бер апа көлә — бу да түгел... Бер кыз бала егете күкрәгенә сыенган да



көлә — бәхетле көлү... Бөтен җирдә көләләр. Көләләр, көләләр, тик шашкан кыз Айсылу көлми. Һаман көлми.

Озакламый премьера. «Миркәй белән Айсылу». Халык көтә инде. Я хода... Автор Нәкый ага Исәнбәт нәрсә әйтер? «Телең әйбәт синең, Гөлсем. Башкорт салмаклыгы да, татар сыгылмалылыгы да бар аңарда. Әмма ник Айсылуга алындың», димәсме?..

Гөлсем бүген дә иртәләде. Режиссер Марсель Сәлимҗанов килгәнче, рольне кабатларга кирәк. Бер кат, ун кат...

Тып-тын театр бинасында — кисәк аваз.

Гөлсем икенче каттан беренче катка атыла. Анда җыештыручы апа көлә-көлә күлмәк сәдәпләрен төймәли. Ычкындыра да көлә-көлә тагын сәдәпли.

«Акылга таман диләр үзен. Мескен. Күрә күрмәсен, рәхмәт яугыры. Айсылу булып көлә белүче бичара җан...»

...Зал тып-тын. Сәхнә «күге» шомлы... Менә үткән заман кызы Айсылу-Гөлсем, әти-әниләре кунакка киту белән, чит җирләрдә йөреп кайткан егете Миркәй янына ашыга. Айсылу шат, ярата, ояла. Миркәй кызның үзенә кияүгә чыгуын үтенә. Бик бәхетле бер мизгел. Бер генә мизгел. Аннан күзләрдәге бәхет очкыны янында сагыш күләгәсе. Шулай да Айсылу ояла-ояла гына ризалыгын әйтә. Тик ул белә: әтисе моңа беркайчан да риза булмаячак. Чөнки авыл бае Дәүли кодалый кызны. Айсылу Миркәйгә сөйләргә өлгерми, «дуслары» белән Дәүли күренә. «Тоттык. Динсезләрне тоттык...»

Һәм менә кыз белән егет мәчет алдында, шәригать хөкеме каршында. Айсылу агтырап калган, нахакка җәберләнүләреннән гаҗиз булып елый. Егет белән кызны, бер-берсенә бәйләп, урам буйлап йөртәләр. Кыз елаудан туктаган — ул арыган инде... Чү! Аларның өе турысы. «Син минем кызым түгел», — ди каршыга килгән газиз әткәсе. Бу коточкыч хөкемнән сыгылып төшә Айсылу. Аны курку баса: кызы түгел?!. Кызы түгел?!. Кыз акылдан шаша. Дин әһелләренең акыл «утырта» башлаулары исә Айсылу фаҗигасен тизләтә генә. Акылдан шашкан кыз я уйга кала, я моңлы җыр суза, я кинәт кенә нигәдер шатлана башлый. Айсылу сөйгәнен дә танымас була. Әмма бервакыт, Миркәйне танып, аның белән кунакка барырга вәгъдә бирә дә: «Мин сине алдадым! Алдадым! Алдадым!» — ди ул егет артыннан... Һәм көлә... Көлә Айсылу-Гөлсем. Күзләрендә җан тетрәткеч сагыш, моң. Бу көлүдән тамашачының җаны өши, тәне өши...

Спектакль тәмам. Чал чәчле Нәкый ага Исәнбәтнең дә керфекләре дымлы. Иреннәре Гөлсемгә рәхмәт сүзен пышылдый...

...Театрдан кайтучы бүгенге көн «Айсылулары» «Миркәйләренә» ныграк сыеналар!..

## 2

Әзгә генә тынган алкышлар тагын көчәйде, тагын залны күмде. Алкыш эченә кемдер аваз салды:

— Назлыгөлне сорыйбыз! Гөлсем Исәнгулованы... Назлыгөл!!!

Аягүрә баскан зал, бу авазны күтәреп алып, «Назлыгөл!» дип кул чаба иде инде.

Бөтен киеренкелегеннән бушанып, хәлсезләнеп калган Назлыгөл-Гөлсем сәхнә артындагы стенага сөялгән дә залны тыңлый. Тамашачының үзен чакыруы әле аның аңына барып җитмәгән. Искәндәр (Ренат Таҗетдинов) белән Газиз (Наил Дунаев) сәхнәгә алып чыккач та, Назлыгөл югалып калды.

Бу аягүрә баскан халыкның Назлыгөл-Гөлсемне алкышлавы кинәт аның да аңына барып җитте. Борчылулар, эзләнүләр, газаплар аша яуланган җиңү!.. Каяндыр ургылып, яңа көч керде. Гөлсем үзе дә елмаеп, Назлыгөле өчен халыкка кушылып кул чаба башлады.

Чәчәк бәйләмнәре белән сәхнәгә менүчеләрне дә ул томан аша гына күрә иде...

Озак кына вакыт алар эндәшмичә утырдылар. Тәннең бөтен күзәнәкләре рәхәт ял итә.

— Гөлсем! Бу инде, малай, синең бик зур җиңүең,— диде Наил, ниһаять.

Гөлсем эндәшмәде. Аның әле тынлык ләззәтеннән аерыласы килми.

— Карале, егетләр,— дип башлады сүзен Ренат та,— без бик сәер утырабыз икән ләбаса. Нәкъ авылдагы ат саклаучы малайлар кебек. Баксаң, янәбыздa гына урындыклар да бар...

Алар рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр. Чыннан да, Гөлсемнең кечкенә генә киенү бүлмәсе идәнендә утыралар икән ич.

— Беләсеңме, Гөлсем, мондый олы җиңү, мондый алкышларга күмелү кайбер артистларга гомер буена да килми. Күпләр моны төшләрендә дә күрми бит.

Белә, мондый алкышларның бәясен белә Гөлсем. Әмма тагын берничә айдан, Әлмәт сәхнәсендә үз гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр Назлыгөлне түгел, үзүзен уйнаячагын гына белми ул...

Ул һаман юк. Вәгъдәсе нык иде югыйсә. Әллә санга сукмавымы микән? Алай дисәң... Әлмәткә үзем киләм диде ич. Ничек кенә әйтте әле! «10 нчы июнь — иң зур бәйрәмем ул. Бу дөньяга минем өчен син туган көн. Галәм читендә булсаң да, янәңа барам, Гөлсем».

Спектакль башланырга өч сәгатьләп вакыт бар. Казанга шалтыратыргадыр бәлки?.. Юк, йөрәк акылга буйсынмый.

«Эш урынына шалтыратам».

«Булмый».

«Шалтыратам»...

— Алло, Казанмы бу?.. Володя кирәк иде миңа!

— Володя?.. Ул юк инде... Алло, кем соң әле бу?..

— Ничек «юк»? Кая китте ул?

— Җирләдек Владимирны... Бүген...

— Нә-әр-сә?..

...Кемдер аның иңнәренә кагылып куйды.

— Нишләп утырың, Гөлсем? Киенмәгәнсең дә. Халык көтә бит. Зал шыгрым тулы.

Халык. Кемне көтә халык? Зал. Ә, әйе-әйе, Назлыгөлне көтә халык. Спектакль ич. «Хуш, Назлыгөл» спектакле.

...Тышкы кыяфәте белән бүген дә ул — Назлыгөл. Искәндәр сәяркәсе. Менә алар балык шулпасы ашыйлар, шәраб эчәләр, тәмәке тарталар. Искәндәреннән канәгать Назлыгөл. «Ярый әле, шундый кайгылы көнемдә тормышның синдәй хәшәрәтләре бар». Акыл белән йөрәк бәхәсенең бер мизгеле... Газиз. Ни калган аңа?.. «Дөньяда синең кебекләр дә буламыни?..» Баксаң, Назлыгөл йөрәге әле тапталмаган икән, тартыла аның күңеле Газизгә, тартыла. «Бу син бит, Володя, син!» Йөрәк авазы... Тиздән Газиз үләргә тиеш.

— Нигә... нигә бу дөньяда яхшы кешеләр генә үлә икән?— Үкси Назлыгөл. Җаны елый, тәннең бөтен күзәнәге елый. «Ниләр булды сиңа, Володя? Ник син мине калдырдың?...»

— Акылыңа кил, Гөлсем! Син бит сәхнәдә.— Якында гына алып баручы тавышы. Меңләгән күз — тамашачы күзе... «Ярый әле... Ярый әле, мине көтүче, күзәтүче тамашачым бар. Югыйсә... Югыйсә нигә миңа яшәү». Назлыгөл-Гөлсем башын күтәрә.

## 3

— Төшенмим мин, Гөлсем. Зәмзәмбанудан изге кеше ясау нигә кирәк булды?

— Мин Зәмзәмбануны аңларга тырышам. Бары шул гына. Адәмнән яман бала тумагандыр ич... Хатын-кыз беркайчан да гүзәллеген, изгелеген, горурлыгын югалтмаска тиеш. Минем өчен бу — хакыйкать.

— Тик шуны да онытма, Гөлсем: Зәмзәмбану — тискәре тип...

Һәм менә Бөек Октябрь революциясенең 60 еллыгына багышланган «Ташкыннар» спектакле.

Сәхнәдә Зәмзәмбану-Гөлсем. Җитез, дәртле Зәмзәмбану. Җырлый-җырлый, йөгерә-йөгерә туй табынын хәзерләшә.

— Булмагезне өйләнешүче яшьләргә бирерсез,— ди каенана-әнкәсе.

«Солдаттан кайтып, фырт йөрүче Нургалигәме?.. Мирхәйдәре белән көне-төне бил бөгәләр. Бәхетле минутлар булəк иткән истәлекле булмә, җитмәсә. Юк...»

Мирхәйдәргә дә шушы фикерне әйтә Зәмзәмбану. Тик «бозау» ир хатынын аңламый, акламый да, киресенчә, аны гаепли...

Тагын бер күренеш.

Гөлчирә хат укый. Мич янында Зәмзәмбану йотылып хат тыңлый. Ире Мирхәйдәр ни язды икән? Сагынамы ул Зәмзәмбануны? Сыкрый, елый, зарлана солдат-Мирхәйдәр. Хатыны турында ник бер авыз сүз язсын!

Зәмзамбану-Гөлсем ачу белән көнбагыш яра. Бөтен торышында — үпкә, нәфрәт...

Бервакыт каенатасы Зәмзәмбануны тотнаксызлыкта гаепли.

— Кеше тикшергәнче, үз кызыңны күрсәңче,— ди килене, һәм шунда ук, ялгыш ычкындырганын аңлап, авызын каплый. Кызы Гөлчирәгә ташланган каената алдына тезләнеп:

— Мин гаепле... Гөлчирәгә тимә! Мине... мине үтер!— дип ялвара ул...

Менә Зәмзәмбану, сөенеп-шатланып, Айсылу килендәшенең ире кайтуын хәбәр итә.

Баксаң, тискәре үк тип түгел ич Гөлсемнең Зәмзәмбануы. Тормыш «кыйнавына» сүз белән көрәш ачкан бер җан икән ләбаса. Аның да сөясе дә, сөеләсе дә килә, кешеләрнең гел битәрләвеннән туйган ул... Басынкы, «тәүфыйклы» килен» буласы килми, гаилә кешеләре белән бертигез хокук даулый Зәмзәмбану.

Гөлсем Зәмзәмбану образын шулай чишә.

— Бүгенге спектакльнең иң яхшы роле өчен!.. Зәмзәмбануны яратуың, аңа ышануың өчен!— дип бер ханым аңа роза чәчәкләре суза.

## 4

Ниһаять — уңай образ. Үз гомерендә беренче һәм бердәнбер уңай роле!.. Ул — «Үзеңә хыянәт итсәң...» әсәрендә Диас Вәлиевнең Гөлсем Исәнгулова өчен язган Гөлсем образы... Тыныч карашлы, салмак адымлы, шәфкатьлелек, итагатьлелек бөркелеп торучы илле яшьләрдәге ханым.

Менә ул яшьләр өчен табын әзерли. Йөзендә мөлаемлык. Салих өстенә акыручы иренә моңсу караш. «Ичмасам бүген генә кычкырмасаң иде — туган көне ич Салихның, туган көне!?»

Хәтта Салих ташлаган кызның баласына да ярдәм итү юлын таба ул.

Тагын бер эпизод. Гөлсем үзенә кычкырган иренең күкрәген сыйпый: «Юк-бар белән йөрәгеңне бетерә күрмә, Локман». Хәтта бу очракта да ул үзе турында, үзен җәберләүләре турында түгел, башкалар турында уйлый: аларга гына начар була күрмәсен!

Спектакльнең буеннан-буена шулай — Гөлсем образын Исәнгулова изгелек, кешелеклелек символы итеп чишүгә ирешә, олы җанлы хатын-кыз образын иҗат итә. Яратып уйный һәм режиссерларның үзенә тагын һәм тагын олы, уңай образлы рольләр тапшыруын тели.

— Мин уңышларым өчен театрыбызның баш режиссеры Марсель Сәлимҗановка бурычлымын,— ди Гөлсем Исәнгулова.— Талантлы режиссер, һәр актерга киң колач җәеп иҗат итү мөмкинлеге тудыра. Марсель Хәкимович рольне вак детальләргә бүлми, киресенчә, олы максатны аңлата да шуңа ирешүдә актерның үз мөмкинлегенә таяна. Мондый иҗат итү мөмкинлеге һәр актерның талантын үстерә, үз-үзенә ышанычын арттыра, эзләнергә, уйланырга мәҗбүр итә.

Әйе. Уйлана, эзләнә, иҗат итә Гөлсем.

Сәхнәдә Туфан Миңнуллин әсәре — «Дуслар җыелган җирдә». Саҗидә ролендә — Гөлсем.

Француженка Эльмира. «Тартюф». Жан Батист Мольер әсәре.

Липочка-Гөлсем. Н. Островский. «Агай-эне ак мыек...»

Тагын рольләр, образлар. Нинди генә булмаган аларның! Классик әсәрләр, революцион рухлы спектакльләр, хәзерге чор драмалары. Нәкый ага Исәнбәтнең Бибкәй-Солтан, Зөһрә, Зөбәрҗәте, Погодинның Настясы, Мостай Кәримнең Шәфәкъ, Җәмилә, Дилбәре, Аяз Гыйләҗевнең Розасы, Нурихан Фәттахның Энҗесе, Дворецкийның Шеголевасы, Боровикның Мартасы... Спектакль саен яңа характер ача Гөлсем, һәркайсы уңышлы. Ул үз героиняларын ихлас ярата, аларга чын күңелдән ышана.

— Гөлсем Исәнгулова — хәзер театрның төп көчләреннән берсе. Ул замандашларыбызны, халкыбызның күңелен, гореф-гадәтләрен, психологиясен тирән аңлаучы актриса. Тышкы эффектлар белән генә мавыкмыйча, бер үк вакытта тышкы хәрәкәтләрнең бай арсеналыннан баш тартмаган хәлдә, геройның эчке дөньясына үтеп керергә тырыша һәм күп вакытта шуңа ирешә дә. Болар зур көч, талант, белем, ихтыяр һәм эшкә бирелгәнлек таләп итә. Гөлсем әнә шундый ихтыяр көченә ия булган, үз иҗат йөзен тапкан артистка,— ди аның турында язучы Аяз Гыйләҗев.

Нәкъ менә шуның өчен дә, Зур Совет энциклопедиясенең 25 нче томында күренекле, талантлы артистлар белән бергә аның исеме дә телгә алынган.

Шәһәргә инде төн иңгән. Бердәнбер автобус кына аваз сала. Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры артистларының өйләренә кайтышы. Арыганнар.

Татарстанның атказанган артисткасы Гөлсем Исәнгулова кулында бүген дә чәчәкләр бәйләме.

# ШӘРӘФ МӨДӘРРИСНЕҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

## Хатип Госман

# ШАГЫЙРЬ ҮТКӘН ЮЛЛАР

Студент чагым иде. Бер кичне Казан югары уку йортларының дистәменнәрчә студентлары, укучы яшьләре, факеллар яндырып урамнарга чыктылар. Испания фашистларының ерткычлыкларына каршы нәфрәт белдерү демонстрациясе иде бугай. Төнге Казан урамнары ут елгалары төсен алды. Алар салмак кына, бер юнәлештә агылалар: Ирек мәйданына!.. Безнең колонна, үз нәүбәте җиткәнче, хәзерге Лев Толстой бакчасы тирәсендә күпмедер тукталып торды. Кышкы тымызык төн. Тротуар буйларында өеп-өеп куелган кар таучыклары, яшь-җилкенчәкләрдән бер ишесе төркем-төркем бер җиргә укмашып, шаярыша, мәзәк сөйли, икенчеләре кар өемнәре тирәсендә «кала алышып» чыр-чу килә... Менә арадан башына колаклы бүрек, ә өстенә какча гына җәйге пальто кигән бер үсмер, факелын югары күтәргән килеш, чын-чынлап гайрәтләнеп: «Үлем фашистларга!» — дип, кемнедер җиңгән шикелле очынып, «кар кала» өстенә килеп менде... Кем иде соң ул? — дип сорагач, иптәшләр: «Бу — Шәрәф Мөдәррис», — диделәр. Бу исемне мин инде балалар, яшьләр матбугатында еш кына күргән идем, «Үскәндә» исемле китабы да чыккан иде. Хәзер педагогия институтының рабфагында укый икән.

Күпмедер вакыттан соң без таныштык, хәтта дуслашып та киттек. Мин инде — эштә, Шәрәф педагогия институтында студент. Үзенең бик дәртләнеп, дәрте сөенечкә әверелеп, «Нарспи» поэмасын чувашчадан татарчага күчереп йөргән чаклары. Ул теләсә кайсы кичнең теләсә кайсы сәгатендә, рөхсәт-фәлән сорап тормастан, ишегеңне шар ачар да декабрь суыгын ияртеп килеп керер. Күзләрендә хәйләкәр очкын җемелди, авыз дисәң — елмайган да, йомылырга онытып, шул килеш тукталып калган. Әлбәттә, берәр нәрсә бар... Куен кесәсеннән трубка итеп уралган кульъязма чыгара. Бу «Нарспи». Ул миңа тәрҗемәнең бер өлешен алып укый башлый. Укый торгач, күзләрен кульъязмадан ала да, каядыр бер билгесез ноктага төбәп, «Нарспи»не яттан чувашча укырга керешә. Шундый бирелеп укый, хәтта янында кеше барлыгын да бөтенләй оныта. Бара торгач, туктап, туп-туры синең күзләреңә карый. «Нинди шәп?» — ди. Тотына шуннан чуваш теленең матурлыгы турында сөйләргә, аңа искиткеч мәдхия укый. Әмма, кызганычка каршы, мин чуваш телен белмим дигәч, Шәрәфем шунда ук бөтенләй үзгәреп, мине чын-чынлап гаепләргә керешә: янәсе ничек син чуваш телен белмәскә тиеш, дип орыша, пыр-туздыра. Ә мин шуны рәхәтләнеп тыңлап утырам. Чөнки Шәрәфне беләм: ачык күңелле, туры сүзле, эчкерсез кеше, аның, халык әйтмешли, эчендәгесе тышында. Миңа аның эчкерсезлеге рәхәтлек бирә.

Берзаман «Нарспи» басылып чыкты, ләкин Шәрәф югалды. Ул безгә килми башлады. Инде 1941 ел кергән иде. Егет авылына кайткан икән дә, шуннан армиягә китеп барган.

Бөек Ватан сугышы башлану бөтен кешеләрнең тормышын кискен үзгәртеп ташлады. 1941 елның сентябрь аенда мин үзем дә инде Төньяк-көнбатыш фронтта идем. Сугыш шартларында солдатның хәле аның үзе һич уйламаганча үзгәреп торучан. Минем дә шулай.

...Безнең гаскәрләр 1942 елның январь һөҗүме вакытында, фашистларны тар-мар итеп, Старая Русса шәһәренә җиттеләр. Шунда оборонага урнаштык. Июнь башларында дивизия командованиесе мине мөһим эш белән Фронтның Политик идарәсенә җибәрде. Тиешле начальник анда минем ни өчен чакыртылуымны аңлатып бирде: Кызыл Армиянең Баш политик идарәсе Төньяк-көнбатыш фронтта чыгып килә торган «За Родину» газетасын татар телендә дә чыгарырга карар кылган икән.

Фронттагы офицер һәм солдатлар арасында татар журналистлары, язучылары юкмы икән дип, тикшереп караганнар. Шул чагында минем исемгә дә игътибар ителгән.

Мин дивизиядән әйләнеп эшкә килгәнче газетага редактор да билгеләнгән: бу — өлкән политрук Гани Гыйльманов иде. Сугышка кадәр күп еллар буе Казанда татар телендәге «Кызылармеец» газетасында эшләп, тәҗрибә туплаган журналист иде ул. Газетаның татарчасына «Ватан өчен» дигән исем бирдек. Тиз арада аның беренче саннары фронт буйлап таралып та китте.

Көннәрнең берендә редакциядә өчпочмаклы төрелгән хат тапшырдылар. Ачсам — Шәрәф яза икән. Һич уйламаганда татарча газета килеп төште. Син чыгарышасың икән, дигән. Хаты кыска, ашыгыч язылган иде. Без редакциягә шагыйрь эзли идек. Гыйльмановка Шәрәф турында сөйләп биргәч, ул моңа чынлап тотынды. Һәм, бер көн үтмәде, ул Шәрәф Мөдәррисов дигән солдатны алгы ут сызыгыннан редакциягә алырга дигән документны хәзерләп тә өлгерде. Аны мин барып алырга тиеш булдым.

Шәрәфнең фронтка инде икенче тапкыр килүе икән. Кырык беренче елны Смоленск тирәсендәге атаклы Ельня сугышларында катнашкан. Яраланган. Госпитальләрдә яткан. Сәламәтләнгәч авылына кайтып бераз торган. Аннан тагын фронтка килгән. Биредә ул минометчик.

«За родину» газетасы сугыш башланганчы Балтик буенда булган. Аның бер тимер юл эшелоныннан торган хуҗалыгында барысы да бар: редакция, хәреф җыю, линотип вагоны, цинкография, ротация һ. б. 1941 елдагы чигенү вакытында поезд күп тапкырлар дошманның бомбага тотуларына, штурмчы самолетлар һөҗүменә очраган. Кайбер журналистлар һәлак булган, яраланган... Ниһаять, биредә, Валдай янында, нарат урманы эченә юл тармагы сузып, аны ылыс асларына кертеп куйганнар. Эш өчен тыныч. Һәр аерым купе — үзе бер редакция. Без шунда эшлибез, яшибез дә. Газетаны рус, татар, латыш, литва, үзбәк, казакъ телләрендә чыгардык. Төрле милләт хәрби журналистлары «Правда»чы Борис Изаков, шагыйрьләрдән М. Светлов, С. Михалков, М. Матусовский, Бладис Лукс, Жубан Молдагалиев, Сагынгали Сейтов, әдипләр Юрий Корольков, Константин Горбунов чын мәгънәсендә бер туганнардай яшәдек, бер туганнардай берегеп эшләдек. Шәрәф белән без дә һәр вакыт шушы мохиттә булдык. Мохит бертуктаусыз кайнап тора. Журналистның офицеры да, солдаты да бер дәрәҗәдә мөһим задание ала да, пистолетын җайлап тагып, юл капчыгын аркасына аса һәм ашыгып сугыш кырына юнәлә. Алгы сызыкка барышлый ул башлап фашист самолетлары һөҗүменә очрый: алар, козгын кебек өерләре белән сызгырып килеп, өстә биек булып киләләр дә, эшелоннарга, автоколонналарга бер-бер артлы кадалып төшә-төшә бомба яудыралар. Әле анда, әле монда машиналар дөрләп яна башлый... Аннары фашист самолетлары түбәнәеп пулеметтан юл читендә һәм каналарда капланып яткан кешеләрне үтереп йөриләр... Бу хәтәрдән соң журналист артиллерия, миномет утлары астына эләгә, алардан үтеп, алгы траншеяләргә, солдатлар арасына керә. Газетага, әдәби парчаларга кирәкле материалны без әнә шулай ут эченнән алабыз... Хәбәрләр, әсәрләр траншея яки блиндаж почмагына утырып, тез өстенә куйган планшетлар өстендә языла.

Мондый шартларда Шәрәф үзенә хас илһамлану белән эшли. Ул уттан-нидән курыкмый. Тәҗрибәле солдат. Кайчакны бер-ике атнага югала. Бер чакны купе ишеге ачылып китә дә (татар редакциясе — 4 кешеле купеда) Шәрәф бәреп керә: сакал-мыек баскан. Таушалып беткән шинеленә нәрсә генә сыланмаган да, нинди генә балчык катмаган. Башында пилотка түгел, әллә нинди гөмбәгә охшашлы бер нәрсә... ә иңендә — каешланып беткән капчыгы, эчендә тузып беткән блокнот кисәге, дәфтәр калдыгы, нинди дер ташландык китап бите... Аларның һәммәсендә дә Шәрәфнең үзе генә таный ала торган язмалар. Бернича сәгать үтүгә шуннан чыга башлый иде ут бөркеп торган хәбәрләр, очерклар, шигъри парчалар!.. Ул ишек катындагы почмакка утыра да, тезенә каты нәрсә куеп яза: проза булса, мыштым гына эшли. Шигырь икән — пышылдый.

...Фронтта безгә еш кына немецча текстлар очрый. Бер шулай Шәрәфнең кулында немецча газетамы, нәрсәдер тотып, җитди кыяфәттә аптырабрак торганын күрдем. Аның мондый чагы сирәк була. «Ни булды?» — дидем. Ул аңлатып-нитеп тормады: «Немецча өйрәнергә кирәк», — диде авыр гына итеп. Өйрәнеп йөргәнен күрмәдем дә кебек, өч-дүрт айдан соң микән, ничектер, немецча бер текст туры килде, бәй, бу шунда ук укырга һәм тәрҗемә итәргә кереште. Рус теле белән дә ул мине шулай гаҗәпләндерде: аның авыл малае икәнен дә беләм, «рус телен өйрәнәсе иде!» — дип, махсус сөйләнеп йөргәнен ишеткәнем дә булмады. Казанда чакта да рус телен яхшы белүе белән сокландырганын хәтерлим. ...Бер шулай үз почмагында сәгатьләр буе мыштым гына утыргалагач, Шәрәфнең «Идел-Сылу» дигән нәсерен русчага тәрҗемә иткәне мәгълүм булды, тәрҗемәсен поездның теге башындагы Борис Романович Изаковка илтеп тә бирде. Һәм... әсәр тиздән басылып та чыкты. Фронт җыентыкларына керде. Шәрәф бөтен фронтка танылды. Аның нәсере солдатларның да, офицерларның да, хәтта генералларның да бик яратып укый торган әсәре булды. Шәрәфтән рус телендәге газета өчен махсус заказлар белән яздырта башладылар. Рус телендәге газетада аның очерклары, публицистик мәкаләләре басылды. Рядовой булса да, аңа өлкән офицерлар да зур хөрмәт белән карый торган булдылар.

Һәр шагыйрь, һәр язучының иҗатында җитлегү чоры була. Бу чорны Шәрәф фронтта кичерде дисәк, ялгыш булмас. Бөек Ватан сугышы утларына башлап язучы булып кереп киткән солдат бөек Җиңүдән соң тыныч тормышка укучылар тарафыннан танылган шагыйрь булып кайтып керде. Аның сугыш чоры иҗатын җентекләп өйрәнәсе бар әле. Шулай да бу иҗатның күзгә ташланып торган үзенчәлекләрен хәзер үк атап әйтәсе килә. Барыннан да элек бу — чын мәгънәсендә сугышның баш герое — солдат поэзиясе иде.

Фронтның алгы сызыгында һәр вакыт дәһшәт өстенлек итә. Сугышлар тынып, оборона тоткан вакытларда да биредә һәр секунд, һәр минут сак булырга туры килә. Ә сугыштан аз гына тукталып торган араларда биредә кешеләр үзләренә куаныч бирердәй кызык-көлке, сөенеч-шатлык тудырырдай нәрсәләрне табып кына торалар. Фронт тормышының бу яклары А. Твардовскийның «Василий Теркин» әсәрендә зур осталык белән тасвир ителде. Безнең Шәрәф боларның барысын да үз язмышында кичереп үтте. Шуңа күрә аның әсәрләрендә солдатның рухи дөньясы ачыла барды: ул солдатны шигъри табигатьле, нечкә күңелле чын кеше итеп күрсәтте, тәвәккәллеге белән фашизмны җимереп баруын тасвирлады. Мин хәзер аның «Синең сүзең» (1943), «Землянкада» (1943), «Кинҗәбулат» (1943), «Гөлбәдәр» (1943), «Тупчы Вәһап» (1943) кебек әсәрләрен кабат-кабат укыйм. Бу әсәрләр, бер яктан, минем күз алдымда язылган, аларны беренче булып укыган һәм фикер алышкан кеше дә — мин, икенче яктан, алар миңа бик таныш фонда язылган. Шуңардыр, алардан минем хыялым каршына чын кешеләр, фронтташларым килеп чыга. Аларның байтагысы кайта алмады. Кайтканнары кайлардадыр... Бик әсәрләнәм.

Шәрәфнең ул еллардагы эшчәнлегендә беренче урынны, әлбәттә, поэзия алып торды һәм аның төп темасы — халык геройлыгы темасы булды. Ул геройларны сугыш эчендә эзләде, алар белән дус булды, аларга сокланды, үзенең лирикасында да, эпик поэмаларында да аларның гуманизмын, фашизмга үтергеч нәфрәтләрен җырлады. Халык батырлыгына соклану аның үз иҗат эшчәнлегенә дә геройлык сыйфаты кертте.

Казанга мин 1946 елның апрель аенда кайтып төштем. Шәрәф миннән ике атна чамасы элегрәк кайткан икән. Ул бездә тукталган. Тартма сыман кечкенә бүлмәдә биш җан тора башладык.

...Аны үз семьябызга, бүлмәбезгә яздыртып, паспорт алдык. Казанда эшкә урнашу мәсьәләсе шуның белән хәл ителде. Тиздән ул үзенә фатир табып эшкә тотынды.

Беренче елларда ул «Социалистик Татарстан» редакциясендә эшләде. Вазифаларыннан берсе — газетаның тел-стиль төзеклеген тәэмин итү иде. Нәүбәттәге өзер полосадан алынган оттиск Шәрәф кулына керә, ул аны буйдан-буйга җентекләп укый, телен, стилен «чарлап чыга». Әйтергә кирәк, бу — нәкъ менә Шәрәф кенә тәмам җиренә җиткереп эшли ала торган эш иде: чөнки лингвистик аңы искиткеч сизгер, хәтере — язылмаган зур энциклопедия, катлам-катлам һәм чиксез тирән. Нинди дә булса берәр сүз турында аның белән бәхәскә керә күрмә, ул синең хәкемеңә чат ябышыр, шунда ук сүзнең йөз еллык, мең еллык, күп мең еллык тарихи юлларына кереп китәр, тарих каналлары буйлап, сине төрле-төрле халыкларның борынгы дөньяларыннан йөретеп әйләндерер... Бер сөйләшеп утырганда ул болай гына әйтеп куйды: «Инглиз телен өйрәнәм». Һәм өйрәнде: Шекспирны, Бернсне үз телләреннән татарчага тәрҗемә итеп калдырды. Ул итальян теленә дә, борынгы латинга да керешкән иде. Кызганыч, гомере иртә өзелде.

Тынычлык елларында Шәрәфнең иҗаты киң җәелеп үсеп китте. Ул зур күләмле поэмалар язды, лирик шигырьләр иҗат итте, публицистик мәкаләләр бастырды, памфлетлар бирде, драматургиягә дә өлешсез калдырмады. Моннан берничә йөз еллар элек Италиядә туган сонет жанры бөтен Көнбатыш Европа халыкларының әдәбиятында, рус әдәбиятында соңгы гасырларда бик үсте. Күтәрелде. Бөек Ватан сугышына кадәр татар поэзиясендә булмаган сонет жанрын да әдәбиятка Шәрәф алып керде һәм аның гүзәл үрнәкләрен бирде.

Шәрәф ни бары кырык дүрт яшендә вафат булды. Ләкин бу хәлгә күңел бер дә ышанмый, күнегә алмый. Кайчандыр, факеллар белән яктыртылган төндә, кала алып уйнаганда, утлы факелын тотып: «Үлем фашистларга!» дип кар тавына атлыгып менеп баскан үсмер шуннан соңгы елларда безнең дәвернең дөньяны тетрәткән бөек вакыйгаларына кереп китте. Бу юлларны язып утырганда мин аны шул вакыйгалар уртасыннан безнең көннәргә таба килә төсле итеп күрәм: менә ул утлы давылларны ерып, фашистларга каршы атакага бара...

**Байрак тотып, кинәт калку тауга**
**Менеп басты татар солдаты...**

Менә ул кан эчендә ята... Менә ул яңадан торып баса... Яңадан сугышларга ташлана... Менә ул җиңү факелын югары күтәреп Берлинга керә... Аннан — тыныч еллар, ул инде иген кырларыннан атлый... Аны төзелеш краннары каршылый һәм озатып калалар... Мин аның йөзен ачык күрәм. Әйтер сүзе бар кебек, ул аз гына елмайган төсле.

Юк шул, болар хәзер хыял гына. Әмма шагыйрь үзенең үлмәс җырлары белән әле дә безнең арада, ул җырлар килер көннәргә уза.

Туфан Миңнуллин

# ДРАМАТУРГ

Шәриф Хөсәеновның иҗат портретын яза алыр идеңме? — дип сорадылар.
— Ничек кенә язар идем әле! Чөнки мин аның иҗатын яратам! — дидем.

Сорау бирүченең тел төбендә ни ятканлыгын абайламыйча, бераз гына ялгышлык җибәргәнмен — миңа драматург Шәриф Хөсәеновның иҗат потретын язу эшен йөкләделәр.

Булдырам, язам дип әтәчләнү җиңел дә бит, эшкә тотынгач син кычкырганча ук барып чыкмый. Һәм менә интегеп утырам: нидән башларга? Ничек дәвам итәргә? Ничек очлап куярга?

Әлбәттә, бәхәссез, мин Шәриф Хөсәеновның пьесаларын укырга да, карарга да яратам. Ләкин яратам, яратам дип туктаусыз кабатлаудан портрет язылмый — сүзләр мәгънәсез шапырыну гына булып кала.

Язучы әллә ничә меңләгән кешеләр өчен иҗат итә. Шул меңнәрнең мәхәббәтен яулый алганмы Шәриф Хөсәенов дигән драматург? Яуласа, андый дәрәҗәгә ничек ирешкән? Драматург иҗатының сере нәрсәдә? Үзенчәлеге нидә?..

Сораулар да сораулар. Дөресен әйтәм, җавапларым тәгаен түгел. Тәгаенләргә җыенмыйм да, булдыра да алмас идем. Кыскасы, мин Шәриф Хөсәеновның иҗат портретын язудан баш тартып, драматург әсәрләренә бәйләнешле кайбер уйлanyлар белән генә уртаклашам.

...1978 елның 9 январенда Казан театр училищесы студентлары тамашачыларга «Зөбәйдә — адәм баласы» дип аталган диплом спектакльләрен күрсәттеләр. Трагикомедиянең авторы — драматург Шәриф Хөсәенов.

Шул спектакльне карарга бардым. Яшерен-батырын түгел, бу юлы театрга гадәттәгечә атлыгып, ашкынып чапмадым. Чөнки, беренчедән, уйнаучылар яшьләр, тәҗрибәсезләр, алар әле өлкән артистлар кебек җиренә җиткереп уйный белмиләр. Аларның уенын караганда онытылып утырмыйсың, шактый гына кытыршылыклар күреп борчылып, уңайсызланып утырасың. Икенчедән, башкарылачак әсәр дә күптән таныш — премьерасы 1965 елда ук Татар академия театрында булган иде. Ә трагикомедия үзе тагын да иртәрәк язылган. Аның яңа гына «табадан төшкән» чагын да яхшы хәтерлим.

1960 елда Шәриф Хөсәенов Мәскәүдә СССР Язучылар союзының Югары курсларында укый иде. Без — Щепкин исемендәге Мәскәү театр училищесы студентлары академия театры сәхнәсен шаулаткан «Профессор кияве»нең авторы белән күрешергә ул яши торган тулай торакка барган идек. Шунда драматург заман яшьләре турында өр-яңа пьеса язып бетергәнлеген әйтте.

Менә шул әсәрне әллә ничә тапкыр караганнан соң янәдән карарга кирәк иде миңа. Кабатлап әйтәм, теләк зур түгел иде. Чөнки заманында ярыйсы ук яңгыраган байтак пьесалар вакыт үтү белән актуальлеген югалтып искерәләр: уйлатмыйлар да, елатмыйлар да, көлдермиләр дә. Көлсәң дә авторның беркатлылыгыннан гына көләсең.

Бу юлы әсәр мине тетрәтте. Элек караганда ул кадәре ук тәэсир итмәгән иде кебек. Пьеса, искерәсе урынга, тагын да яңарган. Сәбәбе нидә?

Карап торырга әллә нинди шаккатыргыч вакыйга да юк сыман пьесада. Яңа гына унынчыны тәмамлаган Зөбәйдә исемле кызый тәрәзә төбенә менеп кунаклаган да урамда туп тибүче малайларга кычкыргалап утыра. Үзе дә аларга кушылып туп тибәр иде — ярамый, аңа институтка керергә кушканнар, һәм ул имтиханнарга әзерләнергә тиеш. Ләкин Зөбәйдәнең укырга теләге юк, аның уе бүтән нәрсәдә. Нәрсәдә? Төгәл белми. Кызый юллар чатында. Эзләнә. Тик гаиләдә аның эзләнүен күрергә, аңларга теләүче, ярдәмгә килүче юк. Барысы да 17 яшьлек Зөбәйдәгә



бала итеп карыйлар, урынлыга-урынсызга битәрләп тә куйгалыйлар, боералар. Мондый хәлгә кыз буйсынырга тели — «этләшә». Шулай дәвам итсә, кызның язмышы кайсы якка тәгәрәр иде, билгесез, ярый әле, аны аңлаучы кеше табыла. Очраклы рәвештә танышкан шофер егет кулына тотынып кала Зөбәйдәбез.

Бу вакыйганы төрлечә сөйләп чыгып була. Шәриф Хөсәеновка, оста художник буларак, вакыйганы сөйләп бирү генә кызык түгел, ул үзенең героинясы Зөбәйдә кебек эзләнә. Без барыбыз да балаларыбызның әйбәт булуын телибез. Әмма ничек әйбәт итәргә икәнен белеп бетерәбезме? Юктыр, мөгаен. Үз юлын таба алмыйча буталып йөргән кызларыбыз, егетләребез күп булмаса да, юк түгел. Аларга, драматург әйтмешли, безнең игътибарыбыз, күңел җылылыгыбыз җитмәгән. Зөбәйдәнең адәм баласы икәнен онытып җибәргәнбез. Зөбәйдәләр гаиләсендә дә шулай бит. Әнисе үлеп киткән, әтисе, вакыт юклыкны сәбәп итеп, кызына «кызым», улына «улым» дип тә әйтмәгән, Зөбәйдәне тәрбияләү эше бертуган тиешле апага тапшырылган. Аның да вакыты юк — кияүгә чыгасы бар. Әйе, барыбызның да вакыты юк — ә Зөбәйдәләр нишләргә тиеш? Ул мәсьәлә бүген уйландыра, иртәгә тагын да ныграк уйландырачак.

Драматург көннең кадагына сугам дип бер-ике айда хәл ителә торган тормыш мәсьәләләрен проблема дәрәҗәсенә күтәреп көчәнми, ул заман тудырган проблеманы тикшерә, җавап эзли. Аны кешенең киләчәге борчый. Әлеге очракта тормышның шактый ук катлаулы сукмагына яңа аяк басып, тирә-ягына күзләрен тутырып карыйкарый сокланып, аптырап, каушап, ялгышып беренче адымнарын атлаучы адәм баласы Зөбәйдә язмышы. Сак булыйк, иптәшләр. Үзебезгә атларга җиңел булсын өчен аны сукмактан читкә этәрмик, олы юлга чыгарга булышыйк аңа. Кешеләрнең Кеше икәнлегенә ышансын ул. Адәм баласын бары тик адәм баласы гына Кеше итә ала. Бу борчылу — мәңгелек. Кеше яшәгәндә ул искермәячәк. Киләчәк Зөбәйдәләре яшәгән мохит башка булыр, кешеләр хәзергегә караганда күп мәртәбәгә камилрәк булырлар, әмма Зөбәйдәнең балалыктан олылыкка күчү вакыты барыбер уйландыра, сискәндерә торган вакыйга булып калыр.

«Зөбәйдә — адәм баласы»на чаклы Шәриф Хөсәеновның Татар дәүләт академия театрында, югарыда әйтелгәнчә, «Профессор кияве» исемле комедиясе куелган иде. Әсәр зур уңыш белән барды. Чөнки 50 елларда драматургиябез шактый гына төссезләнү кичерде. Сәхнәдә бертөсле, схематик персонажлар бер пьесадан икенче пьесага күчеп йөрүче бер үк төсле сүз сөйли башладылар. Бу, әлбәттә, конфликтсыз әдәбиятның җимешләре иде. «Профессор кияве» белән Галиәсгар Камал, Кәрим Тинчурин традицияләрен яңартып, Ш. Хөсәенов сәхнәгә тормышчан, җанлы геройларны кайтарды. Алар «кешечә» уйлый, сөйли, хәрәкәт итә башладылар. Тамашачы спектакльгә агылып йөрде. Әмма Шәриф Хөсәеновны драматург иткән пьеса бу түгел иде. Язучы, тәҗрибәсе җитмәгәнлектән, бу әсәрендә шул заманның сәхнә штампларыннан да файдаланды. Схематизм кизүе аның геройларына да кагылган иде. «Зөбәйдә — адәм баласы» белән Шәриф Хөсәенов үзен өлгергән драматург итеп танытты. Театрлар аны «йолыккалый» башладылар — әсәр таләп иттеләр. Драматург үзенең кырыс холкына хас шаярту белән:

— Юк, мин бүтән пьеса язмыйм. Профессиям — врач, кешеләрне язучы булып түгел, врач булып дәвалыйм,— дип җавап бирә иде. Һәм ул дүрт-биш ел буе драматург буларак дәшмәде дә.

Ниһаять, Татар академия театрында, «Шәриф яңа пьеса укырга җыена» дигән хәбәр таралды. Хәбәр хак булып чыкты. Автор пьесаны укыды.

Сәхнәдә — «Әни килде». (Ул драма хәзер «Әниемнең ак күлмәге» дип атала). Монда да драматург үз иҗат алымына турылыклы. Драмада дөньяны селкетерлек, ах-ух килерлек вакыйга юк. Тормышта бик еш була торган хәл: шәһәрдә яшәп яткан балалары янына авылдан әниләре килә. Чыннан да искитәрлек ни нәрсә бар? Кайсы ана үз балалары янына килми?

Әйе, барысы да гадәти. Ананың төпчек улы Сәйярның туй мәҗлесенә җыйналган агай-энеләр әниләрен шатланып, куанып каршы алалар. Аның дәвалый алмаслык чир белән чирләгәнен белгәч, чын күңелдән борчылалар. Шушында гадәти үк булмаган хәл килеп чыга. Бер-ике айлык гомере калган ананы кем карарга тиешлеге турында бәхәс туа.

Хәер, кем белә, бәлки бу бәхәснең тууы да гадәтидер: без һәрберебез үзебез өчен генә яшәп, артык мәшәкатьләрдән читтәрәк торуны уңайлырак күрмибезме? Сәнап китсәң, сәбәпләре дә юк түгел: беребезнең әлегә фатиры кысанрак, анда артык кешегә урын юк, икенчебез укып ята, имтиханнарга әзерләнәсе бар, өченче-

без үзе авыру, дүртенчебез... бишенчебез... Юк, без начар кешеләр түгел, янәсе, ләкин бит менә, каһәр суккыры, нишләтәсең, шундый-шундый җитди сәбәпләр бар. Гадәти сәбәпләр.

Әсәр гади итеп язылган. Ләкин нигә соң әле шундый гади әсәр кайбер «катлаулы» пьесаларга караганда ныграк тәэсир итә, күбрәк уйландыра? 1969 елда Татар дәүләт академия театрында «Әниемнең ак күлмәге» спектаклен карагач үз-үземә шундый сорау биргән идем. Һәм 1978 елда Качалов исемендәге Зур драма театрында рус телендә карагач та кабатладым шул сорауны. Әсәрне берничә кат укып чыгарга туры килде, тик драманың тәэсир итү көче кимемәде. Бәлки минем өчен генә әсәр якындыр, минем күңел кичерешләренә тәңгәл киләдер? Алай дисәң, драма Татар академия театрында, Әлмәт театрында биш йөз тапкырдан артык уйналды. Советлар Союзындагы дистәләгән театр сәхнәләрендә куелып, уңыш белән барды һәм бара.

Шул сорауны кабатлау һаман дәвам итә. Нигә соң әле «Әниемнең ак күлмәге» караган саен, укыган саен күбрәк уйландыра? Сорауга җавап, минемчә, әсәрнең үзе кебек гади: кешенең иң зур бәхете — иң камил җан иясе булып дөньяга килүе һәм яшәве. Ә адәм баласы дөньяга килүе өчен әти-әнисенә бурычлы. Белгәнебезчә, һәрбер бурыч түләнергә тиеш. Ата-анага бурычны бары тик Кеше булып кына түләп була. «Әниемнең ак күлмәге» шул турыда.

Чын кеше микән без? Әтиләр, әниләр алдында, кешеләр алдында, ил-Ватан каршында намусыбыз чистамы, вөҗданыбыз сафмы? Бу борчылу мәңгелек, кеше яшәгәндә ул искермәячәк.

Киләчәк заман башка булыр, дөнья хәзергегә караганда күп мәртәбә камилрәк булыр, әмма чын Кеше проблемасы һәр чак актуаль һәм уйландыра торган проблема булып кала бирер.

Шәриф Хөсәенов «Мәхәббәт сагышы» дигән повесть һәм шактый гына хикәяләр авторы да. Ләкин мин аны драматург булганы өчен күбрәк хөрмәт итәм. Шуңа күрә, мәкаләне дә «Драматург» дип атадым. Әгәр дә без «Шагыйрь» дип әйтәбез икән, күз алдында шигырь язучыны гына тотмыйбыз, аңа күбрәк мәгънә салабыз. Драматург та персонажларны кара-каршы сөйләштереп язылган әйберне пьеса дип атаучы гына түгел. Драматург кеше язмышы, аның шатлык-кайгылары, уй-кичерешләре турында сәхнәдән (бары тик сәхнәдән генә) халыкчан итеп, халык үзе ышанырлык итеп сөйли алучы кеше. Сөйләгәндә аның ихлас күңелле булуы мәҗбүрдер. Шәриф Хөсәенов шундый кеше. Ул сәхнәдән Намус, Вөҗдан, Мәхәббәт, Ватан кебек бөек төшенчәләр хакында күкрәк кага-кага купшы сүзләр сөйләми, тегеләй яшәгез, болай гомер итегез дип коры акыл сатмый. Аның геройлары гади генә яши бирәләр: эшлиләр, ял итәләр, яраталар, яратмыйлар. Әмма шул гадилекнең төбендә һәр вакыт зур фәлсәфә, тормышның сәнгатьчә дөреслеге ята.

Соңгы сүз итеп тагын шуны әйтүне кирәк дип саныйм — менә ун ел инде драматург Шәриф Хөсәенов театрга яңа әсәр алып килгәне юк. Бу хәл мине һәм аның иҗатын яратучы күпләрне борчый. Сәхнәдән әйткән сүзен зур ихтирам белән кабул иткән меңләгән тамашачылар аның әйтәсе сүзләрен дә түземсезлек белән көтәләр.

Гариф Ахунов

# КПССның XXV СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫ ЯКТЫЛЫГЫНДА ТАТАРСТАН ӘДӘБИЯТЫ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

Чираттагы съездыбызны без язын, елгалар шаулап тынган, урманкырлар яшел хәтфәгә төренгән, игенче түземсезлек белән ужым басуларына күз текәгән чакта башлыйбыз. Без съездыбызны партия безнең алга үзенең «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы яңа карарында өр-яңа бурычлар куйган чакта башлыйбыз.

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең VIII—IX съездлар арасындагы оештыру эше һәм иҗат эшчәнлеге партиянең XXV съезды карарларыннан, СССР, РСФСР һәм Татарстан АССРның яңа Конституцияләрен кабул итүдән туган политик һәм хезмәт күтәренкелеге шартларында барды. Бу чорда без Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгын, совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуына 30 ел тулуны тантаналы рәвештә билгеләп уздык. Әлеге тарихи вакыйгалар безнең ил тормышына, шул исәптән язучылар иҗатына да, зур йогынты ясады.

Әдәбиятыбыз үсеше өчен шулай ук КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы, «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы, партия өлкә комитетының «Татарстан АССР Язучылар союзы партия оешмасының эше турында»гы карарлары, РСФСР язучыларының IV съезды, СССР язучыларының VI съезды карарлары гаять әһәмиятле булдылар.

КПССның XXV съезды, XXXVI һәм XXXVII партия өлкә конференцияләре культура мәсьәләләренә җитди игътибар иттеләр, язучыларны югары сыйфатлы әсәрләр иҗат итәргә чакырдылар. Менә ни өчен без бүген, чираттагы бу съездыбызда оештыру эшләребез һәм иҗат хәзинәләребез хакында аеруча җитди уйланып, таләпчән килеп сөйләшергә тиешбез. Безнең съездыбыз тирән эчтәлекле, мәгънәле булырга, әсәрләребезне бәяләвебез күп милләтле совет әдәбияты ирешкән югарылыктан торып эшләнергә тиеш.

Хисап докладында ике съезд арасында иҗат ителгән әсәрләргә аналитик планда бәя биреп бетерү ирешеп булмастай бер нәрсә, чөнки әдәби хәзинәбез бик тә бай. Шуңа күрә Язучылар союзы идарәсе аерым иптәшләргә әдәби жанрлар буенча өстәмә докладлар бирүне кирәк дип тапты. Сезнең карамакка өстәмә тугыз доклад куелачак. Ә минем бурыч — безнең әдәбиятның бүгенге үсеш тенденцияләрен һәм кайбер порблемаларын билгеләүдән гыйбарәт.

Ике съезд арасында, ягъни узган биш ел эчендә, «Казан утлары» журналында, «Идел» альманахында — 80 нән артык повесть һәм роман басылып чыккан; республиканың партия һәм комсомол газеталарында, «Азат хатын», «Ялкын», «Чаян» журналларында байтак кына хикәяләр, шигырьләр, очерклар, публицистик мәкаләләр дөнья күргән; «Татарстан коммунисты» журналы битләрендә әдәбиятка һәм сәнгатькә караган мәкаләләр басылган. Шушы еллар эчендә Татарстан китап нәшрияты безнең авторларның 500 дән артык китабын бастырып чыгарган. Республикабыз һәм илебез сәхнәләрендә безнең драматургларның илледән артык пьесасы уйналган.

Әгәр шушы гаять зур әдәби хәзинәгә җыйнап бәя бирәбез икән, без аның моннан ун-унбиш еллар элек булганга караганда баерак, төрлерәк, кызыклырак һәм сәнгатьчә югарырак булуын күрербез. Әдәбият мәйданына — прозага, поэзиягә, драматургиягә, тәрҗемә өлкәсенә һәм әдәби тәнкыйтькә яңа буын яшьләрнең килүен күрербез. Бүгенге көндә безнең республикада 154 язучылар союзы членына 700 дән артык яшь һәм башлап язучы туры килә. Алар арасында нефтьчеләр, тәзүчеләр, игенчеләр бар һәм алар өчен әдәби иҗат белән шөгыльләнү, әйтик, нефть чыгару, калалар салу, иген үстерү кебек үк зарури бер нәрсә.

Узган съездда без Татарстан әдәбияты үсешендәге төп тенденция итеп язучыларыбызның хезмәт кешесенә аеруча нык игътибар итүен билгеләп узган идек. Безнең әдәбият ук чакта заман героен алгы планга чыгарып куйган иде. Чыннан да, без сигезенче съездда эшчеләр сыйныфы һәм колхозчы крестьяннар хакында эпик әсәрләрнең — роман, повесть һәм поэмаларның күпләп язылуын шатлык белән билгеләп уздык. Бүгенге көндә дә без: Татарстан әдәбиятының үсешендә (моңа республикада татар, рус, чуваш телләрендә иҗат ителгән әсәрләр дә керә) төп тенденция булып хезмәт кешесе, заман герое кала, дип әйтә алабыз.

Бүгенге заман эшчеләр сыйныфының тормыш-көнкүрешен җентекләп өйрәнү, нефтьчеләр, химиклар, төзүчеләр арасында озаклап яшәү аркасында, безнең язучыларыбыз киң колачлы, масштаблы әсәрләр иҗат итүгә ирештеләр. Бу әсәрләр әдәби хәзинәбезне яңа материал, яңа геройлар, яңа эстетик проблемалар белән баетты. Ә. Баяновның «Ут һәм Су», Ш. Бикчуринның «Каты токым», Э. Касыймовның «Чулман — оныклар елгасы» романнары, Д. Вәлиевнең «Тормыш бүләк итәм», «Диалоглар» пьесалары, С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы», Р. Мингалимовның «Күз карасы», «Иртәгә» исемле поэмалары ике съезд арасында үзләренә җитди бәя яулады. Аларның байтагы рус телендә үзәк нәшриятларда басылып чыкты.

Бөтенсоюз аренасына исәп тоту, идея тирәнлегенә һәм сәнгатьчә югарылыкка исәп тоту — хәзерге көндә безнең иҗат эшчәнлегебезнең иң мөһим шарты. Шунысы әһәмиятле, 1978 елда тик бер «Современник» нәшрияты гына да безнең язучыларның 14 китабын рус телендә йөз меңләгән тираж белән бастырып чыгарды. Әгәр ике съезд арасында Мәскәүдә, үзәк нәшриятларда басылып чыккан китапларыбызның санын исәпләсәк, алар — 167, һәм аларның тиражы ун миллионнан артып китә. Илебез халыклары телендә басылган дистәләгән китапны да бу саннарга өстәсәк, уңышларыбызның зурлыгы тагын да ачыграк күренер. Дөресен әйткәндә, әле беркайчан да безнең әдәбиятның шул хәтле зур күләмдә бөтенсоюз аренасына чыкканы юк иде. Моны без зур казанышыбыз итеп, Язучылар союзы идарәсенең тырышлыгы дип карарга хаклыбыз.

1977 елны РСФСР Язучылар союзының Россия прозасы Советы Казанда үзенең күчмә утырышын үткәрде. Күренекле рус язучысы Сергей Залыгин җитәкчелегендәге коллектив — Мәскәүнең танылган язучылары һәм тәнкыйтьчеләре — безнең эшчеләр сыйныфына багышланган 12 роман һәм повестебызны тикшерделәр. Мәскәүдә рус телендә басылып чыккан бу әсәрләр һәммәсе дә югары бәя алды. Россия прозасы Советы бүгенге заман эшчеләр сыйныфына багышланган татар прозасының билгеле бер югарылыкка, дөресрәге, яхшы югарылыкка ирешүен билгеләп үтте.

Уй-фикер йөртеп карыйк. Эшчеләр сыйныфы хакында 12 роман һәм повесть. Республикабызның эшчеләре тормышы әле беркайчан да роман кебек киң колачлы эпик жанрда шулай күпләп чагылганы юк иде. Әлеге роман һәм повестьларда республиканың төп импульсы — аның коммунистик төзелештәге уңышлары көзгедәге кебек ачык чагылган икән, бу сугыштан соңгы елларда Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә республикабызның куәтле индустриаль өлкә булып әверелүе нәтиҗәсе. Димәк, социалистик чынбарлык әдәбиятка да җитди зур йогынты ясамый калмаган.

XXXVII партия өлкә конференциясендә КПСС өлкә комитетының хисап доклады белән чыккан Ф. Ә. Табеев Татарстан коммунистларына, республикабызның барлык хезмәт ияләренә легендар КамАЗны, Түбән Кама нефтехимия объектларын — партия Үзәк Комитетының 1978 елгы ноябрь Пленумында билгеләп узылган объектларны — төзү бәхете эләкте, диде. КамАЗ, Түбән Кама заводлары комплексын, гидроэлектростанцияне, башка предприятиеләрне, торак йортларны, культура-көнкүреш объектларын коруга республикада ел саен ике миллиард сумнан артыграк капитал салына. Ике миллиард сум! Башка бишьеллыкларда моның булганы бар идемени?! Үзеннән-үзе мәгълүм, капитал төзелешнең шундый зур программасын тормышка ашыру партиянең өлкә оешмасына, Татарстан хезмәт ияләренә, шул исәптән иҗат интеллигенциясенә, гаять зур бурычлар йөкләде. Язучыларыбыз заман һәм халык таләпләренә зур колачлы әсәрләр белән җавап бирделәр, ул әсәрләрдә иҗат кыюлыгы, интеллектуализм бар, аларда колачлап алынган заман проблемалары бар.

Язучылар оешмасы өчен принципиаль булган мондый уңышка без ансат кына ирешмәдек. Производство темасына иҗат итү җиңел эш түгел. Гади генә мисал. «Игеннәр чайкала» дигән җөмләдә без поэзия күрәбез. «Буровой вышкасы тора» дигән җөмләне техницизм дип атыйбыз. Табигать дөньясы кешеләрнең аңына һәм җанына мең еллар буена сеңә килгән, ә промышленность производствосы кешелек аңына узган гасырның икенче яртысыннан гына йогынты ясый башлаган. Болытны без ак дибез, җиңел дибез, аккош мамыгы төсле дибез. Һавада авыр кара болытлар йөзә, яңгыр болыты килә, яшен болытлары йөри дибез — никадәр билгеләмә! Заводны без зур дип әйтә алабыз, яңа дип әйтә алабыз, я тагын нинди билгеләмәсе бар? Азрак бит. Өстәвенә болар нинди билгеләмә инде — күңелгә сеңеп кала торганмыни алар?!

Татарстан язучыларының эшчеләр темасын үз итә барулары ачыграк күренсен өчен әдәбиятыбыз тарихына күз салыйк. Эшчеләр — сезонлы балыкчылар турындагы беренче повестьны татар әдәбиятының классигы Ш. Камал моннан 65 ел элек иҗат иткән. Исеме дә бик шигъри — «Акчарлаклар». Повестьта Россиянең төр-



*Съездның президиумында: (Сулдан уңга) Татарстан Верховный Советы президиумы председателе С. Г. Батыев, Мостай Кәрим, КПСС ҮК инструкторы А. В. Цветков, партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеев, шагыйрь Сибгат Хәким, драматург Туфан Миңнуллин.*

ле тарафлардан Каспий диңгезе буена бәхет эзләп килгән кешеләрнең тормышы сурәтләнелә: берәүләргә ат, берәүләргә йорт кирәк; караңгы юеш баракларда яшәп, сасыган балык чокырында көн күреп, михнәтле авыр эштән, суыктан интегеп, чирләп бетәләр; күңелләрендәге кайнар уйны, өмет-ышанычны югалтырга теләмичә, һаман яшиләр, һаман эшлиләр; шушы караңгы базда аларны якты бер нур җылытып тора: Газизә белән Гарифның мәхәббәте. Бәхетсез булу һәм өзлексез бәхеткә омтылу — повестьта әнә шул контраст кеше җаны тибрәнешләре аша ифрат көчле итеп ачылган. Бу контраст — каршылыкта «производство» темасына язылган әсәрнең әхлакый нигезе ята. Эшчеләр хакындагы әсәрләрдә үзең сурәтләгән өлкәдән әхлакый нигез табу, шуның белән укучыны кузгата алу, ихтимал, безнең бүгенге әдәбияттагы иң зур, иң җитди проблемадыр.

Шәриф Камал повестеннан соң 65 елдан артык вакыт узды, табигый, шул дәвердә эшчеләр хакында күп төрле повестьлар, поэмалар, пьесалар иҗат ителде. Заман аларны рәхимсез рәвештә аралады. Шәхси мәнфәгать белән иҗтимагый мәнфәгатьне бер бөтен итеп куша алган әсәрләр, әхлакый проблеманы, заман проблемасын зур итеп куйган әсәрләр алгарак килеп чыктылар. Х. Туфанның «Урал эскизлары», Ш. Маннурның «Чуен ташкыннар»ы, Ф. Кәримнең «Җиденче мич»е, Р. Ильясовның «Горизонт»ы, И. Туктарның «81 нче штольня»сы, Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар»ы, М. Хәсәновның «Юллар, юллар»ы, С. Хәкимнең «Үрләр аша»сы, Ә. Маликовның «Таңбатыр»ы, Х. Камал поэмалары торып калды. Ә бит ядылганы ул гына түгел иде. Күбесе онытылды. Ник?

Соңгы елларда «Литературная газета» битләрендә эшчеләр сыйныфы хакындагы әсәрләр турында тәнкыйтьчеләр белән прозаиклар, галимнәр белән социологлар байтак кына кылыч чыңлаттылар. Әмма алар, күпме генә тырышсалар да, уртак бер фикергә килә алмады. Күрәсең, килә дә алмаслар. Тормыш гел ачышларда, гел үзгәрешләрдә. Фән-техника заманы безнең алга яңадан-яңа могҗизаларны куя тора. Шул могҗизалар арасыннан кешене эзләп табу, кеше җанының «кара урманнары»на, күңел түрләренә үтеп керү бик зур тырышлыкны, фидакарьлекне таләп итә. Сәнгатьнең сүнми-сүрелми торган кануннары бар, шуларның берсе: **халык тамырына эләгү.** Федор Панферовның «Ташлы басу» романының беренче вариантын укыгач, Дм. Фурманов авторга халык тормышын, кеше характерларын тирәнрәк ачарга киңәш биргән, син халык тамырына туры килгәнсең, бу кульязмадан яхшы әсәр чыгар, дигән. А. Серафимович «Тын Дон» романын ерактан күрә белмәүче редакторлардан саклап алып калган, чөнки ул редакторлар әсәрнең тукымасыннан Дон казакларының көнкүреше картиналарын сызарга, бөтенләй төшереп калдырырга исәп тотканнар, ягъни халыкның мең еллык тарихыннан килгән рухи хәзинәне, аның асылын, аның ихтыяр көчен сызып ташларга ниятләнгәннәр.

«Халык тамыры» дигән термин миңа бик якын. Әдәбиятның халыкчанлыгы аның партиялелеге белән аерылгысыз рәвештә бәйләнгән, чөнки хезмәт халкының мәнфәгатен яклау, шул мәнфәгать белән яшәү — күп милләтле совет әдәбиятының сулышы, илһам чыганагы булып тора.

ССР язучыларының VI съездында — Г. Марков докладында да, пленар уты-

рышларда да, проблемалы комиссияләрнең утырышында да — совет язучылары заманның иң кискен проблемаларын күтәрергә, безнең җәмгыять идеаллары белән рухланган көчле рухлы характерлар тудырырга кирәклеге әйтелде.

Игътибар итегез: **безнең җәмгыять идеаллары белән рухланган характерлар тудырырга.** Димәк, без производствоны тышкы яктан сурәтләп кенә калмаска, шул производствода хезмәт итүче кешенең әхлакый перспективасын ачып бирергә тиешбез. Ләкин бу производство процессларын әдәби әсәр тукымасыннан алып ташларга дигән сүз түгел. Миңа калса, производство процессы әдәби әсәрләрдә бары тик фон гына булып йөрергә тиеш дигән төшенчә дөрес түгел, ул хәтта зарарлы. Бу теория яшьләрне — бер яшьләрне генә түгел!— тормышка өстән-өстән генә карарга өйрәтәчәк. Әгәр язучы производство процессларын яхшы белми икән, ул аңардан хезмәт поэзиясен күрергә өйрәнмәгән икән, хезмәт кешесенең дулкынландыргыч образын иҗат итә алмаячак. Ни өчен Шамил Бикчурин уңышка иреште? Ул кече яшьтән нефтьчеләр арасында. Диас Вәлиев КамАЗның беренче казыкларын кага башлаган көннән бирле Чаллыда. Аларның уңышлары шуннан килә. Ярылып яткан образлылык, үткен драматик конфликтлар, производство проблемаларын фон итеп түгел, пьесаның асылы итеп, кеше җаны тибрәнешләре белән бергә үреп бирү Д. Вәлиевнең «Тормыш бүләк итәм» пьесасында илебез тамашачыларын, бөтен ил матбугатының игътибарын җәлеп итте. И. Дворецкийның «Читтән килгән кеше» пьесасындагы кебек, Д. Вәлиев производствоны оештыручы кешеләрне күрә белгән, шулар аркылы әхлакый аспектны — коммунистның үзенә тапшырылган эшкә намус белән каравын, принципиальлеген ачып бирә алган. Шул рәвешле, технологик проблема психологик проблемага, әхлакый проблемага әйләнгән. Бикчурин белән Касыймовны алып карыйк: алар да зур осталык белән язылган хезмәт процесслары аша, шул процессны оста оештыручы кешеләр белән укучы күңеленә якыная. Нәкъ менә шушы романнар эшчеләр хакында язылган иң уңышлы әсәрләргә бирелә торган бүләкне — ВЦСПС һәм СССР Язучылар союзы бүләген яулап алуга ирештеләр. Югарыда күрсәтелгән пьесалары өчен Д. Вәлиевкә Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Ике съезд арасында эшчеләр сыйныфына багышлап язылган поэмалардан иң уңышлысы дип С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы»н санарга кирәктер. Тәҗрибәле, үзенчәлекле өлкән шагыйрь легендар КамАЗны төзүчеләр аша берничә буын совет кешеләренең җыелма образын гәүдәләндерүгә ирешә. Нәкъ менә шушы поэма безнең поэтик әсәрләребезнең идея ягыннан өлгергәнлеге һәм сәнгатьчә осталыгы мәсьәләләрен күтәрергә мөмкинлек бирә.

Әйткәнемчә, ике съезд арасында хезмәт кешеләренә багышлап язылган әсәрләр аз түгел. М. Хәсәновның «Инженерлар», «Кама таңнары» романнары, Б. Камаловның «Урамнар киңәя», М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да», М. Зариповның «Үзеңнеке үзәктә», Ж. Рәхимовның «Өлешемә чыккан көмешем», Ф. Гыйльметдиновның «Урсал тау итәгендә», Р. Кәраминең «Очар кошлар белән яшәш», К. Тимбикованың «Агым уртасында» повестьлары; Юныс Әминовның «Кан кардәшләре», «Сөйим дисәң дә» пьесалары; Татарстан китап нәшрияты тарафыннан әледән-әле басылып килгән документаль китаплар, Г. Паушкин, В. Белокопытов, Р. Вәлиевләрнең соңгы елларда бастырган очерк китаплары, Х. Камал, З. Нури, Ренат Харис, Р. Әхмәтҗанов, Г. Афзалларның шигырь бәйләмнәре, КамАЗга атап язган җырлары — исемлек зур, әсәрләр күп. Шулар арасында әдәби вакыйгага булырлыклары юк диярлек. Хезмәт кешесе турындагы әсәрләрнең ике съезд арасында күп язылуын һәм моның уңай күренеш булуын билгеләү белән бер рәттән, таләпчәнлекне арттыра, җаваплылыкны көчәйтә төшәргә кирәклеген әйтми кала алмыйбыз. Бу өлкәдә безнең тәнкыйтьчеләр сүлпән эшләделәр, яхшыны яманнан аера белмәделәр, үсеш тенденцияләрен билгеләмәделәр. Галиҗәнаб Эшчеләр сыйныфы, Ватаныбызның куәте артсын өчен, күп көч түкте, аның язучылардан да шундый ук көч түгүне таләп итәргә хакы бар.

Ике съезд арасында бүгенге авыл тормышы да Татарстан язучыларының игътибар үзәгендә булды. Бу традицион темага барлык совет әдәбиятының җитди игътибар бирүе юкка түгел. Беренчедән, авыл хуҗалыгын үстерү мәсьәләләре һәр вакыт партиянең һәм халыкның игътибарында тора,— мондый хәлнең үзеннән-үзе мәгълүм, язучыларның авылга булган карашын да үзгәртми калуы мөмкин түгел. Икенчедән, бүгенге авылның һәм авыл кешеләренең психологиясе фән-техника революциясе, урбанизация процесслары аркылы кискен рәвештә үзгәрә. Нәкъ менә шушы күренешләр безнең илдә «авыл язучылары» дип исем алган әдәбиятчыларның китапларында уйлый һәм уйлана белә торган геройны тудырдылар, нәкъ менә алар авыл хезмәтчәннәренең характерындагы әхлакый чыганакларны билгеләделәр.

Тәнкыйть буенча бөтенсоюз Советының IV пленумында ясаган чыгышында күренекле язучы Федор Абрамов бу хакта болай диде: «Авыл кешесе характерындагы әхлакый чыганакларның каян килүенә әдәбиятның беркайчан да ул хәтле игътибарлы булганы юк иде әле. Бу без яшәгән чорның үзенчәлекләре белән, авылларны кумәкләштерү чорындагы сыман зур колачлы булуы белән аңлатыла. Бүген сүз крестьян Россиясенең үзе тулаем үзгәрү турында бара, ә аның белән безнең рухи, этик, эстетик кыйммәтләребез бәйләнгән» («Вопросы литературы» журналы, 1971 ел, 8 нче сан).

Безне мәктәп эскәмиясеннән башлап

крестьянда хезмәт кешесе һәм шәхси милекче яшь дип өйрәтеп килделәр. Крестьяндагы бу ике «мин»не «Киләчәккә хатлар» поэмасында Һади Такташ бик яхшы ачып бирде. Шәхси милекчелек чирен «Онытылмас еллар» трилогиясендә Ибраһим Гази бик көчле тасвирлады, инде классикага әверелгән «Рәүфә» повестенда Афзал Шамов ышандыргыч итеп гәүдәләндерде. Без беләбез, шәхси милекчене капиталистик җәмгыять тудырган. Безнең илдә хезмәт кешесе, коллектив кешесе өстенлек алды. Әмма бер нәрсәне онытмыйк: фән-техника заманы, урбанизация процесслары җиргә булган ихтирамны, табигать белән уртаклыкны киметә төшмәде микән? Крестьянда үзен җирнең хуҗасы итеп тою хисе кимемәдеме? Болар барысы авыл турында язган язучыларны борчуга сала.

Авыл язучылары исемлеген башлап җибәргән Валентин Овечкин «Районның гадәти көннәре» исемле атаклы очерклары белән крестьян тормышын сурәтләүгә яңалык өстәде. Сугыштан соңгы авылның каршылыклары, үсеш юллары аек акыл, белән, җитди рәвештә өйрәнелә башлады. Ул заманнардан бирле өч дистә ел вакыт узды, авыл прозасы җитди уңышларга иреште. Сергей Залыгин һәм Владимир Фоменко, Василий Шукшин һәм Виктор Астафьев, Владимир Тендряков һәм Федор Абрамов, Владимир Солоухин һәм Петр Проскурин, Гавриил Троепольский һәм Георгий Радов, Василий Белов һәм Валентин Распутин — рус әдәбиятында авыл кешесе образын иҗат иткән язучылар — ил күләмендә танылдылар. Бу исемлеккә әле тагын байтак язучыны өстәп булыр иде. Ә безнең иксез-чиксез илебезнең башка әдәбиятларында алар күпме!

Безнең татар әдәбиятында авыл прозасы белән барлык язучылар диярлек шөгыльләнде. Әмма бу өлкәгә аеруча зур өлеш керткән язучылар дип Г. Бәширов, Ф. Хөсни, А. Расих, Ә. Еники, С. Рафиков, Р. Төхфәтуллин, А. Гыйләҗев, Ә. Баян, В. Нуруллин, Г. Мөхәммәтшин, М. Мәһдиев исемнәрен саный алабыз.

Безнең авыл әдәбиятының уңышлары җитди булды, әмма «Намус» романыннан кала башка әсәрләрне без рус укучысына үз вакытында һәм тиешле югарылыкта җиткерә белмәдек. Атилла Расихның «Язгы авазлар»ы да, «Ике буйдак» романы да бөтенсоюз укучысына шактый соң барып ирешә, Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым», «Авылдашым Нәби» повестьларын, чын мәгънәсендә тирән, җитди, нәфис повестьларны илебез тәнкыйтьчеләре күрми калдылар, Ә. Баян белән А. Гыйләҗев повестьлары да укучыларга озак барып житте. Гаделлек хакына тагын бер әсәрне искә төшерик: Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» повесте — хезмәт халкының күп гасырлык рухи хәзинәсен саклау кебек кискен әхлакый проблеманы күтәргән повесть. В. Распутинның шул ук проблеманы күтәргән «Соңгы срок» әсәреннән 15 еллар элек иҗат ителгән иде. Шулай булуга да карамастан, В. Распутин повесте ил күләмендә зур популярлык казанды. Ә. Еники повесте әле дә дәшми кала. Сәбәбе? Сәбәбе — икәү. Беренче чиратта моңа тәнкыйтьчеләр гаепле, алар аны үз вакытында бөтенсоюз укучысына күрсәтеп бирә белмәделәр. Икенчедән, иң яхшы китапларыбызны ил күләменә чыгаруда без бик әкрен кыймылдыйбыз. Повесть бик озак тәрҗемә ителде, өстәвенә тиешенчә тәрҗемә ителмәде, оригиналдагы көче, сәнгатьчә нәфислеге белән ил күләмендәге укучыга барып җитә алмады.

А. Расих — республикабызның әйдәп баручы язучыларыннан берсе — быел «Сынау» исемле роман тәмамлады. Чынында бу автор уйлаган трилогиянең өченче китабы булып тора. Беренче ике китабы — «Язгы авазлар» һәм «Ике буйдак» инде русча басылдылар, үзәк матбугатта һәм былтыр Казанда үткәрелгән бөтенсоюз гыйльми-иҗади конференциядә яхшы бәя алдылар. Безнең бурыч — өченче китабы дөнья күргәч (ул хәзер «Казан утлары» журналында басыла), аны шунда ук, озын-озакка сузмыйча, русчага тәрҗемә иттерү һәм зур юлга чыгару. Минем уемча, А. Расихның трилогиясе — безнең әдәбиятта зур вакыйга; анда үзенчәлекле милли характерлар, психологик һәм социаль накал, тыгыз үрелгән сюжет, яхшы мәгънәсендә вакыйгалылык һәм проблемалылык бар. Болар барысы трилогияне ил күләмендәге яхшы әсәрләр рәтенә китереп куялар.

Язучыларыбыз бүгенге авыл тормышыннан заманның кызыклы проблемаларын табалар. Нык алга киткән социализм чоры һәм фәнни-техник революция экономика белән идарә итүнең камилләшкәнрәк ысулларын таләп итәләр. Халык хуҗалыгы белән идарә итү мәсьәләләре турында барлык рангларда — партия съездларыннан, пленумнарыннан башлап, вакытлы матбугатка кадәр киң рәвештә әхлакый проблема, кеше шәхесе, җитәкче характеры кызыксындыра. Ф. Хөснинең «Мәйдан», Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын», В. Нуруллинның «Күпер чыкканда», «Аккан су юлын табар», яшь драматург Р. Хәмиднең «Синең урыныңа кайттым» пьесасында колхоз председателе образлары төрле яктан килеп сурәтләнелә. Һәр автор бу образга үз өлешен кертә. Бүгенге авылның социал-экономик, иҗтимагый-әхлакый проблемаларын аеруча калку итеп «Чоңгыллар» романында М. Хәбибуллин сурәтләде. Әсәр Н. Нефедов тәрҗемәсендә «Современник» нәшриятында русча да басылып чыкты. Бу, мөгаен, авылга фән-техника революциясе килү белән туган яңалыкларны шул ук вакытта авылда янә дә баш калкыта башлаган шәхси милекчелек чирен иркенрәк итеп күрсәтә алган беренче романдыр. Сүз уңаеннан шуны да әйтик, безнең телевидение бу роман буенча күп сериале телевизион спектакль эшләде. В. Нуруллин, Ә. Баян, Ф. Хөсни һәм башка прозаикларның әсәрләре буенча да телевизион спектакльләр эшләнеп тамашачыларга җиткерелде. Без, язучылар, республика

телевидениесенең бу эшен хуплыйбыз, чөнки бу эш безнең телевидениенең бик зур мөмкинлекләре барын гына раслап калмый, нәфис фильмнар төшерүгә әзерлекнең беренче баскычы да булып тора.

Бүгенге авыл безнең язучыларны кешенең табигатькә мөнәсәбәте җәһәтеннән дә бик нык кызыксындыра. Җир, туфрак адәм баласын гомер буе туендырып килгән, икмәкле иткән. Бүген җир-суларны пычрату, урманнарны кыру, иң уңдырышлы җирләрне су астында калдыру күренешләре барган чагында, адәм баласы табигать хакында чынлап торып, дөнья күләмендә уйламый булдыра алмый. Табигатькә булган мөнәсәбәт аны өзлексез борчып тора. Республикабызның өлкән язучыларыннан берсе Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» романындагы геройлар әнә шундый уй-тойгылар белән яшиләр. Бу роман безнең съездга бүләк булып саналырга хаклы. Авторның барлык иҗатына хас булган чын халыкчан, образлы, үткен тел, колхоз председателе Чурмантайскийның, нефтьче Харисның, әсәрнең баш герое, романтик табигатьле яшь егет Гайнанның, зирәк акыллы авыл картларының үзенчәлекле характерлары, бик җылы, дулкынландыргыч язылган лирик күренешләр, мәхәббәт сызыгы «Җидегән чишмә»не кирәкле, файдалы китап итәләр. Ике китап булып басылган бу романның бердәнбер кимчелеге (әлбәттә, минем карашка) — аның озынгарак сузылуы. Автор, аны русча бастыру өчен әзерләгәндә, укучылар һәм каләмдәш иптәшләренең фикерен искә алып, тыгызлап җиткерер дип ышанам.

Безнең язучылар: табигать кеше тормышында һәм бөтен җәмгыять үсешендә гаять зур урын тота, адәм баласының, әхлагы, җәмгыятьтәге урыны табигатькә мөнәсәбәттә дә ачыклана, дип карыйлар, кешенең рухи дөньясы баюда табигатьнең искиткеч зур йогынтысы барлыгын сәнгать алымнары белән раслыйлар. Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслан, Г. Латыйп, М. Садри, Ш. Галиев, И. Юзеев, М. Шабаев, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Г. Рәхим, С. Сөләйманова, яшь шагыйрәләр Н. Измайлова, С. Гәрәева, Л. Шакирҗанова, Р. Хәлиуллина шигырьләрендә бу фикерләр чагылыш таба. Бу идеяне «Сандугачлар килгән безгә» исемле пьесасында И. Юзеев, «Китмәгез, тургайлар» пьесасында А. Гыйләҗев истә калырлык итеп кызыклы, җанлы, яңа образларда сурәтләп бирделәр. Илдар Юзеев, драматург буларак, нәкъ әнә шул пьесасы белән ил күләменә чыкты.

Язучыларыбыз, табигать белән адәм баласы арасында акыллы, кешелекле мөнәсәбәт урнаштыру идеясен күтәреп, барлык жанрларда — прозада, поэзиядә, драматургиядә, балалар һәм үсмерләр әдәбиятында шактый ук җитди уңышларга ирештеләр, әсәрләрендә заманның мөһим проблемаларын сәнгатьчә зур итеп гәүдәләндерә алдылар.

Шул ук вакытта бүгенге авылны сурәтләүдә безнең язучыларның яулыйсы үрләре дә байтак әле. Партия Үзәк Комитетының 1978 елгы июль Пленумы карарлары яктылыгында ул үрләр тагын да ачыграк күренә. Узган 1978 елда, явым-төшемгә ифрат та бай килгән елда, безнең әдипләр күпләп авылга юл тоттылар. Газета-журналларда утыздан артык публицистик мәкалә һәм очерк басылды, репортажлар игълан ителде, тик әле ул документаль әсәрләрдә тирән социологик, гыйльми тикшеренүләр куелмады, авыл хезмәтчәннәренең катлаулы образлары ачылмады, проблемаларга тирән үтеп керү сизелмәде. Безгә бу хакта партия өлкә комитетында да кисәтү ясадылар. Тикшеренү-эзләнү дәвам итәр, тирәнрәк, мәгънәлерәк очерклар язылыр, разведка ролен үтәгән очерклардан соң хикәяләр, повестьлар, сәхнә әсәрләре, колачлырак шигъри әсәрләр дә туар дип ышанабыз. Узган юлыбызга әйләнеп карау да комачау итмәс дип уйлыйм: илленче еллар уртасында шагыйрь Әнвәр Давыдов япаялгызы авыл турында бик әйбәт бишалты поэма иҗат иткән иде, алар әле бүгенге көндә дә сәнгатьчәлекләрен, зурлыкларын югалтмаган әсәрләр булып калалар.

Бүгенге әдәбиятта гуманистик пафосның, әхлакый эзләнүләрнең көчәюе заман таләпләреннән килә. Нык алга киткән социализм иле кешесенең асылы һәм характеры турында, әхлак тәрбиясенең төп бурычлары турында КПСС Үзәк Комитетының XXV съездында ясаган докладында иптәш Л. И. Брежнев болай диде: «Шәхесне иң нык күтәргән нәрсә — аның актив тормыш позициясе, иҗтимагый бурычларны аңлап эш итүе, әйткән сүзен белән эшләгән эшеңнең берлеген көндәлек гамәлең итеп алу. Шундый позицияне булдыру — әхлак тәрбиясенең төп бурычы».

Әхлакый эзләнүләр әдәби геройның яшәү рәвешеннән аерылып торган бер өлкә түгел. Алар кеше яшәешенең барлык сфераларын иңләп алалар. Экономика да, социаль-көнкүреш сферасы да кирә моңа. Әгәр без ике съезд арасында иҗат ителгән әсәрләргә ныклап күз салсак, аларның күбесенең актив тормыш позициясен алга сөрүләре, әхлакый эзләнүләре белән истә калуларын күрербез.

М. Мәһдиев «Каз канатлары», «Кеше китә — җыры кала» повестьларында аңа хас үткенлек белән, образлы үткен тел белән кешеләрнең күмәк бер тормышта, коллективта тоткан урыннарын, үзара мөнәсәбәтләрен, тыныч-имин тормышның вакыт-вакыт, сугышка кадәрге чорда, кадерен белеп, бәһаләп җиткермәгәнлекләрен ачып сала. Мәкерле явыз дошманның хыянәтчел төстә илебезгә ябырылуы кешеләрне тыгыз сафка туплый. М. Маликованың «Язгы такыялар»ы, Ә. Гаффарның «Гозер»е, Г. Рәхимнең «Көннәр язга авышкач», «Саргаймагыз, каштаннар» повестьлары, С. Сөләймpraнованың «Гөлбадран»ы, — кайсысы бүгенге авыл, кайсысы медицина хезмәткәрләре тормышын.

нан алынган бу повестьлар лирик җылылыклары, кешегә кешечә мөнәсәбәтләре белән күңелне җылыталар, дулкынландыралар. Ф. Хөснинең егерменче еллардагы Казан мещаннарының Кабан күленнән алтын эзләүләрен сатирик планда сурәтләгән «Алтын эзләүчеләр»е, А. Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар», «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят» исемле, сугыш чорының зур йөрәкле кешеләрен яңача сурәтли алган ике повесте, Р. Ишморатовның милиция тормышындагы батырлыкны ачкан «Язмышлар» повесте, Б. Камалның комсызлыкка, мал җыю тенденциясенә каршы күтәрелгән «Канатлы кырмыска» повесте, тагын башка байтак әсәрләр әхлак темасына язылган әсәрләрнең бик тә кирәкле, кешеләрне дулкынландыра ала торган булуларын әйтеп тора.

Бер нәрсәне искәртик, әхлак темасына язылган әсәрләрнең дә тәэсир итү көче авторларның талантлы булуы белән, гражданлык йөзе белән нык бәйле. Әлеге күп санлы әсәрләрдән А. Гыйләҗев, М. Мәһдиев укучыга тиз барып җиттеләр. Шулар янына Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повестен өстәргә кирәк. Әдәби телгә, халык язмышына карата аерата сак килә белә торган талантлы прозаик Хәсән Сарьянның бу повесте гаилә тормышындагы мөнәсәбәтләрне ил күләмендәге, дәүләт күләмендәге әһәмиятле мәсьәлә итеп күтәрә, бу әсәр арабыздан яшьли киткән каләмдәш иптәшебезнең аккан җыры булып калды. «Бер ананың биш улы» рус телендә һәм башка телләрдә дә яңгырарга хаклы әсәр.

Әхлакый темаларга багышланган әсәрләребез хакында бу съезд трибунасыннан тагын менә нәрсәне әйтү кирәк: бу әсәрләрдә сез чынбарлыгыбызның киң панорамасын табарсыз, бу әсәрләрнең һәммәсендә дә кеше җанының матурлыгы, кеше күңеле омтылышлары өчен көрәш күрерсез. Алтмышынчы еллардан башлап бүгенге көнгә кадәр совет язучылары борынгы белән бүгенгенең үзара бәйләнешы мәсьәләләрен күтәрәләр. Болар ифрат катлаулы мәсьәләләр. Мәрхәмәтсезлек, комсызлык яки миһербанлылык кебек төшенчәләр кыргыз язучысы Ч. Айтматовның «Ак пароход», башкорт язучысы М. Кәримнең «Озын-озак балачак» повестьларында алгы планга чыгарып куела. Болар дөнья әдәбияты гасырлар буена куеп килгән проблемалар. Тик алар безнең заманда, гаделлек, дуслык, туганлык төшенчәләре чәчәк аткан чорда, яңача чишеләләр, яңача хәл ителәләр. Узганны онытсаң, заман белән заман тоташа алмый, фикер әзлеклелеге югала. Әгәр кешеләр ата-бабаларын онытсалар, «ул чагында берәү дә яман эшләрдән оялмаячак, чөнки балалары, балаларының балалары аларны хәтерләрендә тотмаячак. һәм берәү дә изге, яхшы эш эшләмәячәк, чөнки ул эшләрне берәү дә белмәячәк» (Ч. Айтматов — «Ак пароход»).

Чыңгыз Айтматов повестендагы Момун карт яки Мостай Кәрим повестендагы бәләкәй герой күңелендә сакланган рухи хәзинәләр безнең бүгенге рухи хәзинәбез ул, алар безнең тормыштагы комсызлыкка, үз-үзен генә кайгыртып яшәүчеләргә каршы юнәлдерелгән көрәш коралыбыз булып торалар. Берәүгә дә сер түгел, без әле комсызланып мал җыючылар белән дә, кансыз кешеләр белән дә очрашып торабыз. Бу нисбәттән Ә. Баянның «Төлке тоту кыен түгел», «Тавыш — табигать бүләге», «Алмашынучан болытлы һава» дигән повестьларына аерым тукталасым килә. Автор өч повестенда да символик образлар аша явызлыкка, каты бәгырьлелеккә, ханжалыкка, үз корсагын гына кайгыртып яшәүчеләргә каршы көрәшә. Әлеге повестьларның бу сыйфатлары мактауга лаек, тик Ә. Баянның озакка сузылган экспериментаторлыгы тәнкыйтьчеләрнең кәефен ала. Бәлкем алар, бер карaганда, хаклыдыр да. Чөнки һәр нәрсәнең ачык булуы, телнең гадилеге, фабуланың күзгә күренеп торуы, сюжет җепләренең чәбәләнеп бетмәгән булуы авторның әйтергә теләгән уен укучыга тизрәк китереп җиткерә бит. Мин талантлы, үзенчәлекле, күп яклы язучыбыз Әхсән Баянның моны тизрәк аңлавын, чын күңелдән әйтелгән киңәшләргә колак салуын теләр идем. Аңардан аның повестьлары отачак кына. Без әдәбият практикасында форма эзләүче байтак әдипләрне беләбез. Хәтта Хәсән Туфан кебек искиткеч зур талант иясенең дә поэзиягә булган юлын шигъри «күкрәүләр» белән башлавын беләбез, әмма илленче еллар ахырында ул барыбер тынычрак алымга, традицион алымга кайтып төште.

Мин әхлакый эзләнүләрне балалар һәм үсмерләр әдәбияты өлкәсеннән дә китерергә теләр идем. Илебезнең төрле якларыннан дулкынланып язган кызлар хатларында Аяз Гыйләҗев безнең яшь замандашыбызның күңел байлыгын күрә. Аның Казанда татарча, Мәскәүдә М. Ганинаның бик әйбәт тәрҗемәсендә русча басылган «Кызлар хатлары» исемле повесте байтак кына укучыларыбызны, бөтенсоюз укучысын, яшь буынны үстерү һәм тәрбияләү буенча күтәргән кызыклы проблемалары белән җәлеп итте. Аяз Гыйләҗев иҗатына кайвакыт ачыклык җитеп бетми торган була, әмма бу повесть җитди, нык уйланып язылган.

Соңгы елларда без матбугатның да, җәмәгатьчелекнең дә, иҗат интеллигенциясенең дә әхлак проблемаларына аеруча игътибарлы булуын күрәбез. Бу бәлки яшь буынны тәрбияләү ысулларының камил булмавыннан киләдер. Димәк, безгә җитешсезлекләребезне ачып сала торган, үткен итеп язылган әсәрләр кирәк, безгә юмор һәм сатира жанрын үстерү кирәк. Язучыларны ил күләмендә кинофильмнар күрсәтү практикасы да гамьсез калдыра алмый. Балалар өчен кирәкле, файдалы китаплар гаять зур көч куелып языла, ә кайвакыт бер — ни барысы бер фильм, чит ил студияләре фильмы, трюклар, урлау-үтерүләр белән тыгызлап тутырылган фильм безнең китапларны сызып ташларга, аз дигәндә аларны бер читкә куеп

калдырырга җитә кала. Кинофикация идарәсендә эшләүче җаваплы иптәшләргә ул хакта җитдирәк уйларга вакыттыр инде.

Олылар тормышы, аларның тәрбияви үрнәге бәләкәй гражданнар тормышында әһәмиятле роль уйный. Бездә олыларның батырлыгы нәниләрне сокландырырлык итеп язылган китаплар бар. Ул авторларның эшен мин аеруча билгеләп үтәр идем, чөнки алар, аерым бер өлкәне алып, бик җентекләп өйрәнделәр, шул сәбәпле зуррак уңышларга ирештеләр. Фикеремне куәтләү өчен, күренекле совет язучысы Михаил Алексеевның «Правда» битләрендә язып чыккан сүзләрен китерәм: «Әгәр әдип үз алдына алдан ук көч җитмәстәй бурыч куя икән, ягъни тормышның барлык өлкәләрен колачлап алмак була икән, ул бер өлкәне дә юньләп белмәячәк... Үзеңә ни дә булса берне, «кешенең бер өлкәсен» сайлап алырга, әнә шуңа акылың белән генә түгел, күңелең белән дә берегергә кирәк. Барыннан да бигрәк, күңелең белән! Ул чагында әлеге өлкә синең алда күз камаштырырдай матур булып ачыла». Минемчә, Ш. Рәкыйпов белән С. Шакир, кем әйтмешли, Бөек Ватан сугышы геройларына күңелләре белән беректеләр, һәм бу аларга иҗади уңышлар китерде. Алар мисалында Ә. Маликов белән Г. Шәрәфи 1945 елны милитаристик Япониягә каршы сугышта совет солдаты күрсәткән батырлыкларны ачып бирә торган повесть-истәлекләр иҗат иттеләр. Аерым бер өлкәдә специальләшкән балалар язучыларына фантаст А. Тимергалинны, мажаралы повестьлар авторы М. Насыйбуллинны кертергә була, аларның һәркайсы үз өлкәсендә берданбер, кабатланмас әдип.

Әдәби сәләтләре, дөньяны күрүләре ягыннан төрле-төрле булган прозаикларыбыз һәм шагыйрьләребез Ф. Шәфигуллин, Ф. Яруллин, Р. Миңнуллин безнең балалар әдәбиятын кызыклы яңа әсәрләр белән баеттылар. Бөтен илебезгә танылган балалар язучысы Ләбибә Ихсанова ике съезд арасында бик җитди эшләде. Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шәүкәт Галиев балалар өчен кабатланмас шигъри әсәрләр язды, Г. Тукай һәм Б. Рәхмәт традицияләрен уңышлы дәвам иттереп, үзенә бер мәктәп тудырды, әмма, үкенечкә каршы, аның поэзиясе бөтенсоюз укучысына оригиналдагы нәфислеге белән җиткерелгәне юк әле. Мәскәүнең «Детская литература» нәшрияты озаклаемый М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» исемле повестен төзәтелгән, өстәлгән яңа вариантта бастырып чыгарачак. В. Нуруллинның «Әгәр син булмасаң» китабы да шул нәшриятта дөнья күрәчәк. М. Мәһдиев әсәре республикада күптән югары бәя алды инде, ә менә В. Нуруллин әсәре хакында минем берничә җылы сүз әйтәсем килә. Повестьның герое Равил зур тормыш сынавы узып, галим булып җитешә. Автор китабында һәйбәт бер идея үткәрә: әгәр кеше бала чактан ук дөрес юлдан бара икән, булдыклылык һәм тырышлык аның юлдашы икән, андый кеше безнең илдә теләгенә ирешми калмый. Нәкъ әнә шул фикере белән, шул фикерне Равилнең колоритлы фигурасы аша сурәтләп бирүе белән повесть Мәскәү нәшриятын үзенә карата алды. Шундый ук тырыш, омтылучан малайның образын Ф. Шәфигуллин да «Малай һәм ике ат» дигән повестенда ышандырырлык итеп сурәтли; гомумән, бу биш елда Ф. Шәфигуллин иҗади яктан күзгә күренеп үсте: аңарда сирәк очрый торган сәләт — юмор сәләте ачылды; табигать биргән шушы әйбәт сәләтен язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән стена газетасында еллар буе чарлап, ул әдәбият дөньясында диңгезгә килеп чыкты. Һич арттырмый әйтергә була, соңгы елларда ул иң әйбәт юморист булып танылды, Гамил Афзал булып хәтта ул да: «Менә кем Афзал картны алмаштырачак!» — дип шатланып әйтер төсле. Юмор өлкәсендә соңгы елларда А. Яхин, Т. Миңнуллин байтак кына үткен, кыска хикәяләр иҗат иттеләр.

Ике буынның бердәмлеген Б. Камаловның хикәя-повестьларында, Г. Минскийның «Фәридә», өметле яшь язучы Н. Гиматдинованың «Су турында хикәят», «Китмә, улым» кебек хикәя-повестьларында күрергә була.

Иллюстративлыктан качарга, нәни гражданинның эчке дөньясына үтеп керергә тырышу, ихтимал, соңгы елларда балалар әдәбиятындагы үсеш-үзгәрешләрнең асылы шулдыр.

Бу биш елда Язучылар союзы идарәсе балалар һәм үсмерләр әдәбиятын гел күз уңында тотты. Иҗат оешмаларының республика күләмендәге берләштерелгән пленумында, идарә һәм иҗат секциясе утырышларында, язучыларның гомуми җыелышларында балалар һәм үсмерләр әдәбияты мәсьәләләре каралып, тикшерелеп торды.

Балалар һәм үсмерләр әдәбияты алдында торган проблемалар җитди: гомуми белем бирүче мәктәпләр, профессиональтехник училищелар тормышыннан яхшы әсәрләр бөтенләй диярлек юк; бүгенге авыл һәм эшчеләр тормышыннан да балалар язучыларының зур җитди әсәр язмаулары күзгә ташлана; туган ягыбызның революцион үткәне, галимнәр һәм гыйльми ачышлар турында кызыклы яңа китаплар кирәк; безне соңгы елларда балаларның үзләре баш герой булган әсәрләрнең бик сирәк язылуы, Тукай һәм Рәхмәт, Алиш һәм Фәйзи традицияләренең бердәм рәвештә үстерелмәве нык борчый.

Совет халкының Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыгы соңгы елларда язучыларыбыз иҗатында мөһим тармак булып саналып килә. Бу өлкәдә үзләре сугышта катнашкан, сугыш чоры авырлыкларын җилкәләрендә күтәреп чыккан ветераннар аеруча уңышлы эшләп киләләр. Курск дугасындагы дәһшәтле сугышларда катнашкан укчы взвод командиры С. Хәким, Белоруссия партизаны З. Нури, чик сакчысы Г. Паушкин, хәрби очучылар С. Баттал, Ю. Белостоцкий, сугыш вете-

раннары Т. Журавлев һәм Н. Арсланов, Х. Камал һәм Ю. Әминов, А. Расих, Н. Дәүли, М. Хөсәен, драматурглардан Р. Ишморат һәм З. Шаһиморатов — укучылар күңеленә урнашырлык повестьлар, хикәяләр, шигырь-поэмалар, сәхнә әсәрләре иҗат иттеләр. Хисам Камалның «Һәркемнең гомере бер генә» исемле романы материалның байлыгы, күзәтүләренең яңалыгы, сугыш картиналарының чынлыгы белән Бөек Ватан сугышы елъязмасында яңа сулыш булып өстәлде.

Әлерәк кенә безнең арабыздан киткән күренекле язучы Габдрахман Әпсәләмовның тормышы һәм иҗаты Ватанга, халыкка, коммунистлар партиясенә чиксез бирелгәнлекнең үрнәге булып кала. Бөек Ватан сугышы ветераны зур җәмәгать эшлеклесе, исеме илгә киң танылган язучыроманист күп милләтле совет әдәбияты үсешенә үзеннән лаеклы өлеш кертте, аның дистәдән артык романы, повесте, хикәя-очерклары, йөзләгән публицистик мәкаләсе, авыру хәлендә дә каләмен куймавы яшь буын язучыларыбызга зур һәм гыйбрәтле тәрбия мәктәбе булып калачак.

Сугыш ветераны В. Мальцев, бик озак эзләнүләрдән соң, «За чертой времени» дигән бик әйбәт, сәнгатьчә көчле повесть язды һәм шунда ук СССР Язучылар союзына член итеп алынды. Кабатлап әйтәм, Бөек Ватан сугышы елъязмасын булдыруда Ш. Рәкыйпов белән С. Шакир армый-талмый эшлиләр. Аларга бер генә теләк әйтәсе килә: документларга таянып язылган әсәрләргә язучының хыял дөньясы да кушылсын иде. Бу җәһәттән Ш. Рәкыйповның «Таңнар һаман матурмы?» повесте сәнгатьчәрәк булып чыккан, чөнки автор документлар кысасында гына бикләнеп калмаган.

Күргән-кичергәннәрне башкаларга да җиткерү теләге бездә хәрби истәлекләр жанрын тудырды. Сталинград сугышларында батырлык үрнәкләре күрсәткән генерал-лейтенант, Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин, генерал-майор Фатих Булатов, полковник Сәлмән Таһиров язмалары укучылар тарафыннан яратып кабул ителде. Истәлекләр язу, герой якташларыбызны эзләү дәвам итәргә, киңәя барырга тиеш. Идарә тарафыннан оештырылган хәрби-патриотик комиссия Ш. Рәкыйпов җитәкчелегендә җиң сызганып эшкә керешә.

Тарихи һәм тарихи-революцион темага язылган китапларыбыз белән без моннан ун-унбиш еллар элек бик әллә ни мактана алмый идек. Хәзер бу эш тә җайга салынып килә. Г. Әпсәләмовның «Күк күкрәр», А. Расихның «Ямашев», Җ. Тәрҗемановның бөек математик Лобачевский хакындагы «Көмеш дага», Н. Фәттахның «Әтил суы ака торур» романнары бу өлкәдә боз кузгалуын әйтеп торалар. Болар барысы да җитди авторлар тарафыннан җитди итеп язылган романнар. Шулар янына Т. Миңнуллинның «Канкай улы Бәхтияр», Н. Фәттахның «Кол Гали» драмаларын, элегрәк елларда иҗат ителгәннәрдән Н. Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов» драмасын, К. Нәҗминең «Язгы җилләр», Ә. Фәйзинең «Тукай» романнарын да китереп кушсак, картина тулылана төшәр. Автобиографик повестьлардан Ш. Маннурның «Агымсуларга карап», Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек», М. Әмирнең «Без бәләкәй чакларда» повестьлары укучыга күп төрле, кызыклы документаль материал бирәләр, авторларының үзенчәлекле язу алымнары, дөньяны үзләренчә танып-белүләре белән баетылып, төрле төсле, бизәкле, күп тавышлы яңа дөнья барлыкка китерәләр.

Бу әсәрләрнең уңай ягы шунда, истәлек-повестьлар әдәбиятыбыз бүгенге көн ирешкән югарылыктан торып язылганнар, җәмгыятьнең бүгенге көн мәнфәгатьләрен истә тотып сүз алып баралар; мондый караш принципиаль дөрес, чөнки аларда тарихилык та, заманчалык та саклана һәм аларның укучыга булган тәэсир көче арта төшә. Әдәбиятның җитлеккәнлеге — тарихилык белән бүгенге чынбарлыкны куша белүдә.

Безнең әдәбиятта беренче мәртәбә «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә Мәскәүдә «Тукай» китабы басылып чыкты. Филология фәннәре докторы, танылган тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме И. Нуруллинның бик күп көч салып, гомере буе Тукай иҗатын өйрәнеп язган бу китабы һәр яктан игътибарга лаеклы. Шуңа күрә ул бик тиз арада таралып бетте, үзәк матбугатта һәм республика матбугатында уңай бәя алды. Хәзер безнең бурыч — «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә Муса Җәлилнең героик тормышы турындагы китапны бастырып, илебез халыкларына җиткерү.

Моннан ун еллар элек без драматургиябезнең тормыштан һәм әдәбиятның башка жанрларыннан бик нык артта калып килүен әйтә идек. Хисап чорында хәл үзгәрә төште. Бүгенге татар драматургиясе, күп милләтле совет әдәбиятының аерылгысыз бер өлеше буларак, бердәм идея-сәнгать юнәлешендә, күзгә күренеп үсә башлады. Шуңа күрә без барлык совет драматургиясендә булган үсеш-үзгәрешләр бездә дә бар дип әйтә алабыз. Бу чынбарлыкны тирәнрәк анализлауда, иҗтимагый проблемаларны киңрәк яктыртуда, коммунистик әхлак принципларын сәнгать чаралары белән гәүдәләндерүдә күренә.

Бу биш елда бигрәк тә драматург Т. Миңнуллинның иҗаты гөрләп чәчәк атты. Аның бер генә драматургны да кабатламый торган күп яклы таланты татар сәхнәсенә «Әлдермештән Әлмәндәр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Дуслар җыелган җирдә» кебек, сәнгатьнең югары законнарына нигезләнеп иҗат ителгән әсәрләр бүләк итте. Тамашачылар һәм язучылар җәмәгатьчелеге аңа Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелүне шатланып каршыладылар. Туфан Миңнуллинның озын гомерле таланты безне әле тагын да бик күп яңа, зур,

киң колачлы әсәрләр белән шатландырыр дип өметләник.

Бу съездда без шулай ук драматург Х. Вахитның якты талантын билгеләп узарга тиешбез. Драматургия кануннарын биш бармагы кебек белгән, тырыш, хезмәт сөючән каләмдәшебез арабыздан китте, аның бай мирасы тәнкыйтьчеләребез тарафыннан җентекләп өйрәнелергә, тиешле бәясен алырга тиеш.

Без бүген зур канәгатьләнү белән Ш. Хөсәеновның «Әни килде», А. Гыйләҗевның «Без унике кыз идек», И. Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә», Ю. Әминевнең «Кан кардәшләре» пьесаларын билгеләп узабыз. Бу әсәрләрнең геройларын тынгысыз иҗади тормыш берләштерә. Бүгенге татар драматургиясендә безне уңай герой эзләү, пьесаның сюжет-композициясен кызыклы итеп корырга омтылу, жанр төрлелеге, телнең образлылыгына, драматик үткенлегенә ирешү шатландыра. Безне драматургиягә бер-бер артлы сәләтле яшьләр килү шатландыра. Р. Хәмид, Ә. Гаффар, Ф. Садриев, Ю. Сафиуллин — болар барысы да дөньяны үзләренчә күрә белгән, әзерлекле иптәшләр. Сәхнәбезне сакау тел белән язылган, хәлсез-җегәрсез пьесалар күмеп китә торган күңелсез заманнар артта калды. Сәхнәгә чын сәнгать килде.

Татар драматургиясенең бүгенге уңышлары безнең пьесаларыбызны ил күләменә алып чыкты. Мәскәү белән Ташкент, Алма-Ата белән Баку, Мурманск белән Воронеж, Ульяновск белән Краснодар, Уфа белән Кызыл (Тува АССР) хәзер безнең пьесаларны чит итмиләр. Милли драматургиянең һәм театрларның бөтен Россия фестивале татар драматурглары А. Гыйләҗев, Д. Вәлиев, Т. Миңнуллин һәм И. Юзеевне беренче дәрәҗә дипломнар белән бүләкләде.

Әйе, ике съезд арасында драматургиябез ирешкән уңышлар байтак, ләкин болар безнең эшебез ал да гөл диган сүз түгел. Тагын бер елдан без республиканың төзелүенә 60 ел тулуны тантаналы рәвештә билгеләп узарга җыенабыз. Театрларның портфельләрендә эшчеләр сыйныфы, колхозчы крестьяннар тормышы, революцион үткәнебез турында нинди пьесалар бар? Сүз җиңелчә генә куелып, шундук онытыла торган пьесалар турында түгел, К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», Т. Гыйззәтнең «Ташкыннар», М. Әмирнең «Тормыш җыры», «Миңлекамал», Р. Ишморатның «Кайту» кебек пьесалары хакында, классикага күчкән озын гомерле пьесалар хакында, дәверләргә калырлык, артистлык сәнгатен тагын да югарырак баскычка күтәрә алырлык пьесалар хакында бара.

«Театр пьесаны тудырмый, пьеса театрны тудыра»,— диган Бернард Шоу. Шулай булгач, үзеннән-үзе мәгълүм, театрлар драматургларның кадерен белергә тиеш. Шундый бер уй йөри күңелдә: театрлар әдәбият бүлеге мөдиренең авторитетын күтәрергә тиешләр. Драматургка театрда үз кеше, аның профессиональ интересларын яклый алырдай кеше кирәк. Ул режиссерның әмерен үтәп йөрүче йомышчы түгел, театр белән драматургны бәйләп тотардай кеше булырга тиеш. Әдәби журналга яки нәшриятка акыллы, талантлы редактор никадәр кирәк булса, театрларга да талантлы, акыллы белгеч шул кадәр үк кирәк. Заманында безнең Опера һәм балет театрында әдәбият бүлеген Муса Җәлил алып барган, милли опера һәм балетыбызның чәчәк аткан чоры нәкъ шул елларга, сугыш алды елларына туры килә, һәм тагын бер факт — егерменче гасырның күренекле әдибе Мохтар Ауэзовның казакъ драма театрында бүлек мөдире булып эшләве дә күп нәрсә турында сөйли булса кирәк.

Безнең поэзиябез, аның ике съезд арасындагы уңышлары турында күтәренке тавыш белән сөйләргә булыр иде, чагыштыру һәм эпитетларны кызганмый китерергә булыр иде, чөнки соңгы елларда безнең поэзиябезнең ирешкән уңышлары бәләкәй түгел; әмма, бер яктан, шагыйрьләрнең газета-журнал битләрендә алып барган бәхәсләрен, Планетада нык басып торуларын үзләре дә горурлык белән, күкрәк киереп сөйләүләрен искә алып, икенчедән, шигърияттә әле кул-аяк тимәгән проблемалар да булуын истән чыгармыйча, әңгәмәне тынычрак тонда алып бару файдалырак булыр диган фикергә килдек. Тыныч тон безгә нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнен төгәлрәк әйтеп бирергә дә мөмкинлек тудырыр.

Язучыларның узган сигезенче съездында без «өченче буын» дип аталып йөргән шагыйрьләр турында, аларның яхшы резерв булулары турында сүз алып бардык. Бу буынга без Рәдиф Гатауллинны, Ренат Харисны, Равил Фәйзуллинны, Гәрәй Рәхимне, Роберт Әхмәтҗановны, Рөстәм Мингалимовны керттек. Аларның сәләтле булуларын искә алдык. Әнә шул вакыттан бирле биш ел узды, һәм безнең өченче буын, резервтан чыгып, поэзиядә лаеклы үз урынын яулап алды. Алексей Сурков әле 1956 елны ук «батыр поэзия, солдат поэзиясе» дип атаган татар поэзиясендә үз урыныңны яулап алу ансат эш түгел. Дөньяны танып-белүләренә, сәләтләре ягыннан төрле-төрле булган әлеге шагыйрьләр инде шигырь җыентыкларын Казанда гына түгел, Мәскәүдә дә чыгарып өлгерделәр, башкала тәнкыйтьчеләренең уңай бәясен дә ишеттеләр. Аларның кайберләре Татарстанның дәүләт һәм комсомол премияләренә лаек булды.

Нәкъ менә шушы буын, ашкынып алга омтылуы, бик кыю шигъри экспериментлар ясавы белән, алтмышынчы елларның тыныч кына, салмак кына аккан шигъри агымына давыл алып керде, үзе артыннан шигырь сөючә яшьләрне ияртеп, аларның янага, тынгысызлыкка булган сусауларын баса алды; аларның гасабилы, хәтта вакыт-вакыт хаослы тавышларыннан, татар теле стихиясенә кайбер ятрак элементлар да өстәп җибәрүләреннән, без Хәсән Туфан, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким, Нури Арсланов кебек өлкән буын шагыйрьләрнең поэтик



*Казагыстан Язучылар союзы идарәсе секретаре Шерхан Мортазаев (сулда Гариф Ахуновка: «Иҗатыгыз шушы келәмдәге гөлләрдәй чәчәк атсын!» дип казакъ каләмдәшләренең бүләген тапшыра.*

үзенчәлекләрен аермачыграк абайлый башладык; безгә урта буын шагыйрьләрдән Гамил Афзал, Зәки Нури, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, Шәүкәт Галиев, Әхсән Баян, Хисам Камал, Илдар Юзеев, Гөлшат Зәйнашева, Рәшит Гәрәйләрнең уйланучан-сабыр, ашыкмаучан-традицион алымнары хәтта ваемсызрак кебек тә тоела башлады; Тукайлар, Такташлар, Җәлилләр традициясе белән заман омтылышларын бергә кушып язган Кадыйр Сибгатуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Разил Вәлиев, Әхмәт Рәшитов, Фәннүр Сафиннар һәм бер төркем шагыйрьләр әлеге «өченче буын»ның ташкын-шарлавыгында үз юллары барлыгын сиздерергә керештеләр. Кыскасы, әлеге буын соңгы сүбүләр ролен дә үтәде түгелме икән әле?

Алтмышынчы еллар башында аксакал шагыйрьләребездән берсе: «Гамьсез Гулливерлар, ни карыйсыз, лилипутлар килә шигырьгә?!» дип өндәү авазы салган иде, шул өндәүне яңа буыннар күтәреп алды һәм безнең поэзиябез карлик-лилипутларга поэзия цехын тотырырга мөмкинлек бирмәде.

Бүген без съездга зур горурлану белән хәбәр итәбез: безнең поэзиядә Тукай һәм Такташ рухы яши, Муса Җәлил тарафыннан Бөек Ватан сугышы фронтларыннан алып чыгылган совет иленең гражданлык поэзиясе байрагы юл күрсәтеп бара. Әнә шул байракны кер кундырмый саклау, гражданлык поэзиясенә бер генә минутка да кимеп калырга, икенче планга чыгарга юл куймыйча, гел алга, гел алга омтылу — безнең иң изге бурычыбыз. Шул ук вакытта сюжетлы, геройлы эпик поэзиягә, поэмаларга таба йөз белән борылу — безнең кичектергесез бурычыбыз. Поэма өлкәсендә С. Хәким, И. Юзеев, Р. Мингалимовлардан кала шагыйрьләребезнең күбесе сүлпән эшләде.

Партиянең XXV съездында һәр яклап тәрәккый иткән, рухи бай шәхесне тәрбияләү мәсьәләсе иҗтимагый аңны активлаштыру, әдәбият тәнкыйтенә дә яңа сулыш өрде. Съезд карарлары, КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары тәнкыйтьчеләргә һәм әдәбият галимнәренә халыкны тәрбияләүдә, идеологик көрәштә, культурабызны үстерешүдә үз рольләрен яхшырак аңларга булыштылар.

Тәнкыйтьчеләребезнең профессиональ осталыклары үсә төште. Тәнкыйть әдәби әсәрләрне тирәнрәк анализлый башлады, аның фәннилеге артты — философия, тарих, социология белән бәйләныш көчәйде, әдәби тәнкыйть теоретик гомумиләштерүләргә таба юл алды.

Әдәбият галимнәре тәнкыйтьчеләргә караганда зуррак уңышка ирештеләр. Бу өлкәдә методологик дәрәҗә күтәрелде. М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Халит, И. Нуруллин, Й. Нигъмәтуллина, М. Усманов,

Х. Хәйри, Б. Гыйззәт, А. Әхмәдуллин, И. Илялова, Т. Галиуллин, Ф. Хатипов, Ф. Урманчеев, Р. Сверигин хезмәтләре басылып чыкты. Н. Юзиевнең татар шигыренә багышланган хезмәтләре Татарстан АССРның Г. Тукай премиясенә лаек булуы тәнкыйть фикеренең җитлеккәнлеге, социал-эстетик позицияләренең төгәллеге турында сөйли. Партия Үзәк Комитеты «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында тәнкыйтьчеләрдән әнә шуны таләп итә бит.

Әмма бүгенге заманның җанлы тәнкыйте әдәбият белеменнән шактый артта калып килә. Бу өлкәдә Р. Мостафин, Ф. Мусин, И. Ахунҗановтан кала әллә ни активлык күрсәткән тәнкыйтьче күренми шикелле. Алар өчесе дә ил күләменә чыктылар, «Правда», «Литературная газета» битләрендә, «Вопросы литературы», «Дружба народов» журналларында мәкаләләр бастыралар. Р. Мостафин белән Ф. Мусин ике съезд арасында «Современник» һәм «Советская Россия» нәшриятларында татар әдәбияты проблемаларына багышланган аерым китаплар бастырып чыгардылар. Бу актив тәнкыйтьчеләр төркемендә Ф. Миңнуллинны да күрәсе килә. Беренче китабында аның заманны һәм язучының стилен тою, нечкәләп бәя бирү сәләте күренде. Соңгы вакытта ул «Казан утлары» журналында һәм республика газеталары битләрендә сирәгрәк күренә башлады.

«Казан утлары» журналы битләрендәге тәнкыйть бүлеге материаллары белән танышкач, соңгы вакытта әдәби тәнкыйтьнең җанлана төшүен күрү читен түгел, төрле жанрлар хакында бәхәсләр оештырылды, китаплар ешрак рецензияләнә башлады, әдәби әсәрләрнең сәнгатьчәлелеген таләп итү арта төште. Шулай да биредә зур җитди кузәтүләр, теге яки бу жанрның үсешенә карата махсус мәкаләләр азрак әле. Күбесенчә ел йомгакларында сөйләнгән докладларны яки «Казан утлары»ның аерым саннарын тикшергәндәге материалларны мәкаләгә әйләндерергә тырышабыз. Тәнкыйтчеләребездә әдәбият язмышы өчен борчылу, янып-көеп эшләү җитми.

«Казан утлары» журналы һәм «Социалистик Татарстан» газетасы съезд алды трибунасына урынны бик юмарт бирделәр. «Социалистик Татарстан» әдәбиятта заманчалык турындагы сөйләшүне бик яхшы оештырды, тик тәнкыйтьчеләребез бу мул мәйданны ике съезд арасында иҗат ителгән гаять зур әдәби хәзинәне аналитик планда тикшерүгә, зур гомумиләштерүләр ясауга ныклап файдалана белмәделәр. Бу шулай ук тәнкыйтьчеләребезнең гражданлык активлыгы җитмәүдән килә булса кирәк.

Тәнкыйтьтәге артталыкны бетерү өчен Язучылар союзы идарәсе аз тырышмады. Тәнкыйтьчеләр секциясенең эше нык җанланды, секция членнарының активлыгы бүгенге әдәби процессны, актуаль теоретик һәм практик мәсьәләләрне барлауга юнәлдерелде. Тәнкыйтьчеләр секциясе үзенең эшен башка секцияләр, әйтик, проза секциясе белән, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы белән берглэп алып барырга тырышты. Проза, поэзия, әдәби тәнкыйтьнең үзе турында гаять файдалы зур сөйләшүләр оештырылды, тик алар газета-журналлар битләрендә мәкаләләр, тикшеренүләр рәвешендә басылып чыкмадылар. Секциянең яшь тәнкыйтьчеләр М. Вәлиев, Р. Кукушкин, Ә. Мәхмүдов, Р. Мөхәммәдиевләр белән эш алып баруын, республикада һәм илдә үткәрелгән чараларда башлап йөрүен уңай күренеш дип бәяләргә тиешбез.

Эшлисе эш күп. Без тәнкыйтьчеләребез бастырган мәкаләләрнең колачлы, акыллы булуын телибез. Әдәбият хакындагы сөйләшүнең зур социаль гомумиләштерүләргә күтәрелүен, әдәби әсәрләребездә куелган заман проблемаларын ачыклап, күрсәтеп баруын, укучыларның һәм язучылар җәмәгатьчелегенең игътибарын шул проблемаларга юнәлдерүен, татар әдәбияты казанышларын үз вакытында һәм ышандыргыч итеп бөтенсоюз укучысына җиткерүен телибез.

Без соңгы елларда яшь язучыларның бик озак җитлегүе хакында сүз алып барабыз. Чынбарлык белән күзгә-күз очраштырмый торып, үзенә тапшырылган эш өчен, коллектив өчен җаваплылык хисе тәрбияләми торып, яшьләрнең тиз өлгерүен өмет итү — буш хыял. Барыбызга да таныш схема — ясле, мәтәп, институт, нәшрият коридорлары, яңа тормышны төзүдә бер генә мәртәбә дә катнашмау, — яшь авторларның сәләте бетүгә алып бара. Әдәби осталык эстетик категория генә түгел, ул язучының партия һәм халык алдындагы бурычын тоюы. Художникның бәхете — дөньяның яңа офыкларын ачу, кеше характерларын олы итеп үзенчә сурәтләү. Тормыш эченә чуммый торып моңа ирешү мөмкин түгел.

КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карарында яшь авторларның тормыш белән элемтәсен өзлексез рәвештә ныгытырга, аларның иҗтимагый активлыгын арттырырга, яшьләргә кызыклы эшләр кушарга, аларны коммунистик идеаллар өчен ныклы көрәшчеләр итеп тәрбияләргә кирәк, диелә.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм партия оешмасы ике съезд арасында яшь язучыларның иҗтимагый активлыгын арттыру, тормыш белән бәйләнешен ныгыту өчен байтак кына эш эшләделәр. Ел саен иҗат союзларының ВЛКСМ өлкә комитеты белән берләп, республика күләмендәге семинарлары үткәрелеп килә. Татарстан районнарында берничә мәртәбә үткәрелгән зона конференцияләре яңа яшь авторлар табуда ярдәм итте. Яшь язучылар тәрбияләүдә иҗат союзларының һәм культура учреждениеләренең берләштерелгән пленумы күренекле роль уйнады. Пленум бик аның иҗат семинарлары җыелган тәҗрибәне гомумиләштерергә, сәләтле яңа исемнәр ачарга мөмкинлек бирел кенә

калмадылар, кимчелекләребезне күрергә дә булыштылар. Игътибар беләнрәк карагач, соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган 38 китапның 29 яшь шагыйрьләрнеке, нибары 9 гына яшь прозаикларныкы икәне беленде. Өстәвенә яшьләр үзләренең хикәя-повестьларында, башлыча, авыр сугыш заманарының истәлеген сөйлиләр булып чыкты. Аларның игътибары заман героена юнәлтелде.

КПСС Үзәк Комитетының иҗат яшьләре белән эшләүгә багышланган карарында яшьләр белән эшләү буенча советлар яки комиссияләр төзү, газета-журнал редколлегияләренә яшь авторларны кертү күздә тотыла. Болар — зур һәм җитди мәсьәләләр, шуңа күрә иркенрәк тукталырга рөхсәт итегез.

Барыгызга да мәгълүм, VIII съездга кадәр Татарстан Язучылар союзы идарәсенә 17 кеше сайланган иде, аларның уникесе алтмыш һәм җитмеш яшьләрендә, тик бишәве генә илле яшьләр тирәсендәге иптәшләр иде. Дөресен әйтик, нормаль хәл түгел бу. Шуңа күрә VIII съезд, язучылар оешмасының югары органы, килеп туган хәлне төзәтү кирәк дип тапты. Беренчедән, идарәгә 17 түгел, 21 кеше сайланды, икенчедән, оештыру эшендә тәҗрибәләре зур булган аксакаллар белән бергә, урта һәм яшь буын вәкилләре сайланды. Шулай итеп, өлкәннәр белән яшьләр мөнәсәбәте тигезләнде, оештыру-иҗат эшләрен алып бару җиңеләя төште, шул сәбәпле хисап чорында без байтак кына файдалы эшләр эшли алдык. Әмма редколлегияләрдәге хәл бик әллә ни үзгәрмәде: сәләтле яшь язучылардан без «Казан утлары» журналы редколлегиясенә беркемне дә тәкъдим итмәдек. Моның нәтиҗәләре шундук күренде: редколлегия члены яки эш белән күмелгән кешеләр булып чыктылар, ялыну-ялваруга да карамастан, кульязмаларны укырга алмыйлар, яки артык салмак табигатьле икәннәрен расладылар: җәмәгать эше белән үзләрен күмәргә ашыкмыйлар, редколлегиягә хөрмәтле урында булу өчен генә сайланганнар икән. Язучылар союзы идарәсенең тугызынчы съезды сайлаячак яңа составы «Казан утлары» белән «Идел» альманахының редколлегиясен яңарту турында да уйлар дип ышанабыз. Минемчә, яшьләрне җаваплы эшләргә кыюрак тартырга, аларның җәмәгать активлыгын беренче адымнарыннан ук тәрбияли башларга кирәк, чөнки совет әдәбиятының байрагын алар алып барасы, безнең сәнгатьнең зурлыгы, сафлыгы өчен халык һәм партия алдында алар җавап бирәсе.

Партия безнең яшьләргә карата сизгер һәм зирәк мөнәсәбәттә булуыбызны таләп итә. «Яшь художникләр белән үткәрелә торган барлык эш, диелә Карарда, сизгер һәм ихтирамлы булырга, шул ук вакытта таләпчәнлек, принципиальлек белән үрелеп барырга тиеш. Кайбер яшь язучылар Карардагы формулировканың беренче кисәгенә — сизгер һәм ихтирамлы булу ягына — тотынып алалар да үзләрен бертуктаусыз кайгыртып торуны таләп итә башлыйлар. Әнә шундый чамадан тыш сизгерлек һәм ихтирамлылык аркасында, формулировканың «таләпчәнлек белән принципиальлек» дигән икенче өлеше алып ташлану сәбәпле, бездә перспективасыз, өметсез каләм ияләре ишәя башлады; алар әдәбияттан ерак торалар, әмма ашык-пошык язып өйгән шигырь яки хикәя тауларына чиксез кайгыртучанлык таләп итәләр. Без, уйлап-нитеп тормастан, аларны яшь язучылар исемлегенә кертәбез, ул исемлекне типографиядә ишәйтәбез, әлеге хәсрәт язучылар, тормышта исә гаять дәрәҗәдә өлгер, булдыклы кешеләр, барлык инстанцияләргә, партия Үзәк Комитетына кадәр, хат яудырырга тотыналар: янәсе, алар белән шөгыльләнмиләр, аларны кайгыртмыйлар, аларны кысалар. Өстәвенә үзләренең әдәбиятка яраклы кешеләр икәнлекләрен раслар өчен, хатларына кушып, без бастырган исемлекне җибәрәләр. Күрәсең, безгә бу ачы тәҗрибәдән сабак алырга вакыттыр: әйле-шәйле язып йөрүчеләрне яшь язучы дип әйтергә ашыкмыйк, партиябезнең сизгерлек һәм ихтирамлылык дигән күрсәтмәсен, аның икенче күрсәтмәсе — таләпчәнлек һәм принципиальлек белән куша белик.

Яшьләр белән эшләүдә, югарыда әйткәнебезчә, безнең уңай тәҗрибәбез дә җитәрлек. Шушы елның февраль аенда РСФСР Язучылар союзы секретариаты безнең идарәнең яшьләр белән эшләве хакында хисап тыңлады, безнең эшебезне хуплады, Яр-Чаллыда Язучылар союзы бүлеге ачу һәм «Идел» альманахын яшьләр журналы итеп оештыру турындагы мәсьәләне аерым карарга дигән фикергә килде. РСФСР Язучылар союзы идарәсенең моңарчы әйткән сүзен җилгә очырганы юк, бу чаралар да тормышка ашырылыр дип ышанабыз.

Әгәр без хәзер артыбызга борылып, 1974 елның маенда үткәрелгән VIII съезд көннәреннән башлап эшләгән эшләребезгә күз салсак, партиягә һәм халыкка хаклы рәвештә әйтә алабыз: шушы чор өчен үзебез билгеләгән, партия өлкә комитеты яхшы дип тапкан чараларның барысы да тормышка ашырылды. Туган әдәбиятыбызның үсеш юлындагы прицнипиаль мәсьәләләргә: язучылар оешмасының эшчәнлеген көчәйтү, иҗат эшенә мөмкинлекләр тудыру, яңа яшь алмаш әзерләүне игътибар үзәгендә тоту, язучыларның үзара дуслыгын, татулыгын булдыру, аларны олы максатлар тирәсенә туплау, әдипләрнең тормыш белән, халык белән элемтәсен ныгыту, Язучылар союзы члены һәм яшьләрнең иҗтимагый-гражданлык активлыгын көчәйтү, әдәбиятыбызны ил күләменә чыгару — менә шушы зур һәм җитди мәсьәләләргә язучылар коллективының игътибары юнәлтелде. VIII съездда сайланган идарә членнарының иң зур күпчелеге эшкә, бурычларны аңлауга сәләтле икәнлекләрен күрсәттеләр. Узган биш ел безнең өчен иҗтимагый чаралар үткәрү ягыннан да, иҗади өлгерлек ягыннан да нәтиҗәле булды.

Без ике съезд арасында халкыбызның бөек уллары Тукай һәм Җәлил юбилейларын үткәрдек. Татар совет әдәбияты тарихында беренче мәртәбә без бөтенсоюз комиссияләре оештырылуга ирештек, шул сәбәпле Тукай һәм Җәлил мирасы безнең илдә һәм чит илләрдә киң пропагандаланды. Аларның китаплары Мәскәүдә, туганлаш республикаларда, социалистик хезмәттәшлек илләрендә басылып чыкты. Казанда һәм Мәскәүдә, Кырлайда һәм Оренбургта, илебезнең төрле калаларында үткәрелгән юбилей тантаналары күп милләтле совет культурасының олы бәйрәменә әйләнде. Моңа тагын Каюм Насыйриның 150 еллыгы, Галиәсгар Камалның 100 еллыгын, Галимҗан Ибраһимов белән Фатих Әмирханның 90 еллыгын, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Шамил Усманов, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим бәйрәмнәрен дә кертергә кирәк. Бу бәйрәмнәрне үткәргән чакта СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, Татарстан китап нәшрияты зур эш башкардылар — бәхеткә каршы, бу зур гыйльми-практик оешмалар белән Язучылар союзының дуслыгы елдан-ел ныгый, бу исә үз нәүбәтендә безгә җитди, принципиаль мәсьәләләрне бергәләп хәл итәргә мөмкинлек бирә.

Хисап чорында Язучылар союзы идарәсе традицион ел йомгакларын үткәрүне дәвам иттерде, аның сыйфатын яхшыртырга тырышты. «Казан утлары» журналында басылган әсәрләрне тикшерү, иҗат секцияләре җитәкчеләренең, Язучылар союзы аппаратындагы җаваплы иптәшләрнең хисапларын тыңлау алып барылды.

Ел саен, зур күтәренкелек белән, поэзия көне үткәрелде. Шигырь бәйрәме соңгы елларда Казан һәм Яңа кырлай белән генә чикләнеп калмый, Түбән Камада, Чаллыда, Әлмәттә дә үткәрелә.

Ике съезд арасында Казанда Европа һәм Азия илләреннән 30 язучы-тәрҗемәче булып китте. Алар республиканың экономикасы һәм культурасы белән таныштылар.

Казанга узган елны әдәбиятның Горький көннәрендә катнашу өчен илебезнең 120 язучысы килде, алар республикабыз башкаласының күп кенә предприятиеләрендә, Яр-Чаллы шәһәрендә КамАЗда булдылар.

Казанда, хисап чорында, иҗат союзларының һәм культура оешмаларының берләштерелгән өч пленумы үткәреде: беренче пленум балалар әдәбиятына һәм сәнгатенә багышланды, икенче пленум Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгына, өченче пленум КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Л. И. Брежневның «Кече җир», «Яңару», «Чирәм җир» китапларыннан килеп туган бурычларыбыз хакында сөйләшүгә багышланды. Пленум чын мәгънәсендә партияле бу китапларның совет кешеләре тормышында дәреслек булып хезмәт итүләрен, Леонид Ильич Брежневка әнә шул китаплары һәм тынычлык өчен көрәштәге эшчәнлеге өчен Ленин премиясе бирелүне зур канәгатьләнү белән каршылауларын билгеләп узды.

Һәм, ниһаять, безнең тагын бер зур эшебез — Казанда бөтенсоюз фәнни-иҗади конференция үткәрү. Конференция Совет Көнчыгыш әдәбиятларында социалистик реализмның эстетика һәм поэтикасы кебек актуаль проблемага багышланды. Конференциянең киң колачлылыгы аны әзерләүчеләрдән дә күренә. СССР һәм Татарстан АССР Язучылар союзы идарәләре, СССР Фәннәр академиясенең А. М. Горький исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты — әнә шул иҗат оешмалары һәм гыйльми институтлар үзләре үк конференциянең нинди югарылыкта һәм нинди колач белән үткәрелүен әйтеп торалар. Конференция илебездәге төрки телләрендәге әдәбиятлар үсеше өчен генә түгел, барлык совет әдәбияты үсеше өчен дә файдалы эш эшләде, чөнки биздә шундый күп язучылар һәм галимнәр бүгенге этапта әдәбият үсеше проблемалары, әдәбиятларыбызның бурычлары тикшерелгәне юк иде әле.

Республикабыз язучыларының VIII—IX съездлары арасында безнең идарә үткәргән әлеге зур һәм җитди әдәби-иҗтимагый чараларның яхшы нәтиҗәләренә без шатланабыз, әмма без боларны үзебез эшләгән эш итеп кенә карамыйбыз, партия Үзәк Комитеты, КПСС өлкә комитеты, республикабыз хөкүмәте, СССР һәм РСФСР Язучылары союзы идарәләренең безгә карата күрсәткән зур ышанычы, игътибары һәм ярдәме итеп карыйбыз.

Язучылар союзы идарәсе һәм аппаратта эшләгән иптәшләр безнең эшебезгә партия өлкә комитетының культура бүлеге тарафыннан, секретариат һәм идеология эше өчен җаваплы иптәшләр тарафыннан нинди зур игътибар күрсәтелгәнен яхшы беләләр. Бу елларда безнең алда күп төрле эшләр торды, яңа башлангычлар һәм яңа чараларны тормышка ашыру бездән энергия, тапкырлык, җитезлек таләп итте.

Мин бүген, язучылар съездында хисап биргән чакта, безгә ярдәм иткән, эчкерсез булышкан барлык иптәшләргә рәхмәт әйтәбез. Тыныч-сабыр иҗат атмосферасы тудырганнары, максатлы рәвештә җитәкчелек иткәннәре, безгә ихтирам белән караганнары өчен рәхмәт әйтәбез.

Илебез әдәбиятларының аралашуы, берберсен баетышуы елдан-ел арта, рухи хәзинәләребезне уртаклашу көчәя бара. Совет власте елларында, 60 ел эчендә, рус әдәбиятының һәм дөнья культурасының иң яхшы үрнәкләреннән өйрәнү безнең культурабызны яңа баскычка күтәрде. Мәнә шуңа күрә хәзер матур әдәбиятны тәрҗемә итү, тәрҗемәчеләрнең профессиональ осталыкларын күтәрү — гаять мөһим бурыч булып әверелде.

Безнең республикада тәрҗемә ике өлкәгә бүленә. Берсе — татар теленә, икенчесе — татар теленнән тәрҗемә итү. Беренче өлкәнең зур традицияләре һәм,— һич арттырмый әйтергә мөмкин — бик яхшы нәтиҗәләре бар. Казан югары уку йортлары һәм Татарстан китап нәшрияты тәрбияләп үстергән профессиональ тәрҗемәчеләр: Яхъя Халитов, Кыям Миңлебаев, Рәис Даутов, Таһир Нурмөхәммәтов — бер яктан, барлык язучылар коллективы — икенче яктан,— татар теленә рус әдәбияты классикларын: Пушкин, Гоголь, Некрасов, Толстой, Куприн, Достоевскийны; совет әдәбияты классикларын: Шолохов, Твардовский, Шевченко, Михалков, Гамзатов, Айтматов һ. б. һ. б. шактый күп тәрҗемә иттеләр. Бездә Бальзак, Гюго, Шекспир, Бомарше, Гейне, Гете, Лондон, Байрон, Хемингуэйнең — барлык ил һәм континент язучыларының тәрҗемәләре бар. Моннан берничә ел элек, Һиндстанга сәяхәтем вакытында, һинд язучыларына үземнең тәрҗемәмдә Р. Тагорның бер томлыгын бүләк иткәч, Һиндстан язучыларының бездә 19 мәртәбә басылып чыгуын, бу эшнең әле революциягә кадәрле үк башланган булуын әйткәч, Һиндстандагы каләмдәшләребез гаҗәпсенеп калдылар, рәхмәт йөзеннән миңа өстәл лампасы бүләк иттеләр, бу бүләк сезгә һинд әдәбиятын тагын да тәрҗемә итәргә кирәклекне исегезгә төшереп торсын, диделәр.

Кайвакыт без эшләгән эшебезнең зурлыгына, файдалы булуына хисап та биреп бетермибез бугай. Дөнья әдәбиятының, рус һәм совет классикасының татар теленә тәрҗемә ителүе безне баета, әдәби-эстетик үсешебезгә этәргеч булып хезмәт итә.

Әдәби тәрҗеменең икенче өлкәсе, ягъни татар әдәбиятын рус теленә, рус теле аша башка телләргә тәрҗемә итү, татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен илебез халыкларына тәкъдим итү канәгатьләнерлек булмый. Совет власте елларында рус теленә генә дә 600 дән артык китабыбыз тәрҗемә ителгән. Бу — бик күп, ифрат күп. Тиражы да аның 50 милионнан артык. Без моңа күз йоммыйбыз, без моның өчен шатланабыз, әмма шул ук вакытта сагаябыз да. Аларның барысы да оригиналдагы нәфислеге белән барып җиткәнме илебез халыкларына? Әйтү кыен. Русчага тәрҗемә ителгән китапларыбыз күңел кушканча түгел әле. Бу биш елда Татарстан Язучылар союзы идарәсе, яхшы китапларыбызны русчага чыгару өчен, яхшы тәрҗемәчеләр табу өчен максимум көч куйды. Тәрҗемә эше күзгә күренеп алга китсә дә, бу өлкәдә соңгы елларда күренекле рус язучылары эшләсәләр дә, без әле теләгебезгә ирештек дип әйтә алмыйбыз. Сүз дә юк, татар прозасы, поэзиясе, драматургиясе һәм балалар әдәбияты, әйтик, моннан унбишегерме еллар элек булганга караганда әйбәтрәк, сыйфатлырак тәрҗемә ителә, татар әдәбиятының дуслары Николай Нефедов, Елена Корнеева, («Современник» нәшрияты), Евгения Имбовиц («Советская Россия» нәшрияты), Галина Московская («Детская литература» нәшрияты) безгә кирәкле талантлы тәрҗемәчеләрне гел эзлиләр, табалар, үзләре дә тәрҗемә эшенә өлеш кертәләр. Безнең әсәрләребезне яхшы тәрҗемә иткән рус язучыларына без шушы биек трибунадан рәхмәт хисләребезне белдерәбез, Мәскәү нәшриятларына, башкалабызның газета-журналларына аларның безнең съездда катнашкан вәкилләренә рәхмәт хисебезне белдерәбез. Бу — ихлас күңелдән әйтелгән сүз. Әмма татар китабын бөтенсоюз укучысына җиткергән чакта безнең үзебезгә бәйле кимчелекләр дә бар. Язучылар союзы хезмәткәрләре, идарә членнары, сеңгерләре өзелгәнче тартсалар да, китап бастыру эшен күңел булганчы башкарып чыга алмаячаклар. Безнең үз эшебез — оештыру һәм иҗат итү эшебез бар. Әгәр Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтын алсак, соңгы елларда ул татар әдәбияты классикларының томлыкларын бастыру эше белән бик ныклап шөгыльләнде һәм әледән-әле бу сораугa килеп төртелде: текст әзерләүче кадрларны каян алырга, акча һәм кәгазь каян алырга? Бу өлкәдә хәл ителмәгән проблемалар күп әле. Минемчә, безгә барлык көчне, барлык средстволарны бер урынга туплаган оештыручы үзәк кирәк. Бу үзәк Язучылар союзында да, Г. Ибраһимов исемендәге институтта да түгел, Татарстан китап нәшриятында булырга тиеш. Әгәр без дәүләт күләмендәге әһәмиятле бу эшкә хуҗаларча карасак, Татарстан китап нәшриятына барлык кадрларны, акча средстволарын һәм тулы вәкаләтне биреп, анда татар классикларын бастырып чыгару буенча аерым редакция ачсак, гасырлар буена зарыгып яткан әдәби мирасыбыз хәрәкәтенә килер һәм без күкрәк киереп, иркенләп бер сулыш алырбыз.

Язучылар союзы идарәсенең оештыру эшләре һәм иҗади эшчәнлеге хакындагы белешмә китабы сезгә таратылды. Сез аны инде карап чыккансыздыр дип уйлыйм. Анда Татарстан язучыларының VIII съездында сайланган идарәнең эшчәнлеге тулы чагыла. Идарә президиумының, барлык иҗат секцияләренең, җәмәгать комиссияләренең, яшьләр белән эшләү бүлегенең, матур әдәбиятны пропагандалау бюросының, әдәби фондның, безнең матбугат органнарыбыз булган «Казан утлары» журналы һәм «Идел» альманахының, язучыларның Г. Тукай исемендәге клубының һәм китапханәсенең эше анда җентекләп язылган. Шуңа күрә мин биш ел эчендә алар башкарган эшләргә тукталмыйм.

Сезнең игътибарыгызны тагын бер мәртәбә үзәк мәсьәләгә юнәлтәм. VIII съездда сайланган идарә үзенең эшчәнлегенә әдәби процессны партия куйган бурычларга юнәлтүне, Татарстан әдәбиятының гомуми күтәрелешенә ирешүне, язучыларга уңайлы иҗат шартлары булдыруны төп

мәсьәлә итеп карады һәм шул юнәлештә эшләде.

Бу бурычны без, Язучылар союзының партбюросы белән кулга-кул тотынып, бергәләп үтәргә тырыштык. Коммунист язучылар — алар бездә 154 язучылар союзы членының 96 сын тәшкил итәләр — партия һәм халык таләпләрен үтәүдә, оешманың үзәге, төп көче булдылар.

Татарстан язучыларының VIII съездыннан соң биш ел вакыт узды. Әдәбиятта зур казанышларга ирешү өчен биш ел күп вакыт түгел. Әмма, әдәби бишьеллыгыбызны анализлаганда, без моңа тагын сигез гасырлык әдәби тарихыбызны кушарга онытмыйк. Безнең бүгенге әдәбиятыбызның тамырлары халкыбызның борынгы культурасына барып тоташа. Безнең халык һәрбер гасырда үзенең күренекле улларын әдәбият мәйданына чыгара килгән: Кол Галидән башлап Тукайга тикле бу шулай бара, һәм ул әдипләр татар шигъриятенең көчен, татар әдәби теленең җегәрен, матурлыгын, гасырлар буена Идел һәм Кама буйларында утрак тормыш белән яшәгән, берәүгә дә янамаган, тынычимин рәвештә көн күргән халыкның меңеллык рухи байлыгын дөньяга күрсәтеп бирә алдылар.

Чик баганаларының теге ягындагы безнең дошманнарыбыз татар халкының экономикасы һәм культурасы артка кала дип кычкырырга, күңелләрендә оетып асраган хыялларын чынбарлык итеп күрсәтергә яраталар. Әшәке буржуаз пропагандага җавап итеп, әлеге бишьеллыкка татар совет әдәбиятының совет власте еларында, ягъни алтмыш ел эчендә ирешкән гаять зур уңышларын өстәргә онытмыйк: бүгенге татар әдәбияты революция давылларында, совет строе өчен кан коелы сугышларда туган социалистик реализм әдәбияты традицияләрен ишәйтә.

Партия Үзәк Комитеты «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы яңа карарында безнең алга яңа бурычлар куйды, безне, совет язучыларын, озак елларга исәп тотып эшләнгән программа белән коралландырды.

Социалистик реализм методы совет язучыларының күңелендә туган уйларны тормышка ашырыр өчен зур мөмкинлекләр ача. Социалистик реализм сәнгате язучылардан тормыш белән тыгыз элемтәдә булуны, заманның төп проблемаларын үз вакытында күтәреп чыгуны таләп итә. Аның бу сыйфатлары партиянең XXV съезды билгеләгән коммунистик төзелешнең яңа чорында тагын да ныграк усәчәк, киңәячәк. Партия сызган юлдан барып, илебезнең даны-куәте артсын өчен армый-талмый көрәшкән совет кешесенең үзе башкарган бөек эшләр, үзе уйлаган уйлар хакында бездән тирән һәм дулкынландыргыч итеп язылган китаплар көтәргә хакы бар.

Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетын, КПСС өлкә комитетын ышандырырга рөхсәт итегез: Татарстан язучылары, заманның катлаулы проблемаларын хәл иткәндә, ныклы сыйнфый позициядә торырлар, партиялелек һәм халыкчанлык принципларына турылыклы булган хәлдә, КПССның XXV съезды һәм аннан соңгы пленумнары карарлары белән рухланып, безнең бөек чорыбызга, коммунизм төзүче бөек халкыбызга лаеклы әсәрләр иҗат итәрләр.

## Атилла Расих

# ПРОЗАБЫЗ ТУРЫНДА

Әгәр татар совет язучыларының узган сигезенче съездан соң иҗат иткән прозаик әсәрләрен күз алдыннан кичерсәк, иң беренче чиратта түбәндәге үзенчәлекләргә игътибар итәрбез: проза әсәрләребез идея-эчтәлеккә баеды; жанр ягыннан һәм тематика үзенчәлегеннән төрләнә төште; аерым жанрлар буенча язучыларыбызның специальләшү процессы көчәйде; күпчелегебез үзенең төп эше итеп повесть язуны алды, тарихи-революцион темага язу һәм күләмле тарихи әсәрләр язу жанлана барды; Бөек Ватан сугышына һәм аерым күренекле шәхесләргә багышланган документаль әсәрләр төркеме пәйда булды; стиль һәм алым өлкәсендә кыю гыйна эзләнүләр күзгә ташлана. Менә болар барысы да безнең милли прозабызның бүгенге билгеләре.

Иҗат ителгән әсәрләрнең саны да артканнан-арта бара. Мәсәлән, ике съезд арасындагы биш елда Татарстан китап нәшрияты татар телендә алты оригиналь роман, утыз дүрт повесть, бер дистә хикәяләр җыентыгы басып чыгарды. Болар өстенә вакытлы матбугатыбызда, аерата «Казан утлары»нда, «Азат хатын»да, «Чаян»да, «Идел» альманахында һ. б. органнарда басылган роман, хикәя, повестьларыбызны исәпкә алсак, барлыгы 80 әсәр дөнья күргән. Азмы бу? Аз дип булмый. Аерата повестьларның күп язылуын күрми узу мөмкин түгел. Димәк, хәлнең торышын бу җәһәттән шәп дияргә буладыр! Бәлки

эшләр ал да гел дип әйтергә дә ярыйдыр әле? Юк.

Әдәбиятта сан мөһим бер күрсәткеч булса да, барыбызга да күптән мәгълүм булганча, аның дәрәҗәсен, торышын ахыр чиктә сыйфат хәл итә. Димәк, жанрның торышын ачыклау өчен безгә иҗат ителгән продукциянең характерлы бер өлешен тезис рәвешендә генә булса да күздән кичерергә кирәк.

Заман темасына язылган күләмле җитди әсәрләрнең берсе Гомәр Бәшировның журналда кыскартылып, нәшриятта ике китапка бүленеп дөнья күргән «Җидегән чишмә» романы булды. Роман прозабызның олы остасына хас әйбәт, саллы тел белән укучының күңелендә җылы тойгылар уятырлык итеп язылган. Андагы уңай образлар: Гайнан, Минһаҗ карт, агроном Фәйрүзә, Камил укучының хәтерендә калырлык калку сурәтләнгәннәр.

Әсәрнең сюжеты жанрына хас булганча катлаулы. Анда төп мәсьәлә — табигатьне саклау проблемасыннан тыш, иҗтимагый тормышыбыз һәм көнкүрешебезнең бик күп яклары яктыртыла. Кыскасы, мин аны күренекле иҗат җимешләренең берсе дип исәплим. Ләкин шулай да авторның бу романы котелгәннән кайтышрак кебек. Эш нидә соң? Төп докладчы әйткәнчә, артык озын ул. Шуның аркасында, ахры, эчтәлек белән күләм арасындагы нисбәт бозылгалый, әсәр сулпәнләнә, сюжет оеткысы итеп алынган объектив сыегая, кечерәя төшә.

Прозабызның җигелеп эшләүче төп көчләре хәзер урта буын вәкилләре. Алар аерата актив эшләделәр. Шундыйлар арасыннан заман темасына шактый уңышлы повестьлар иҗат итүчеләрне саный китсәк, зур исемлек булыр иде. Гадәттә, докладлар исемлекләр белән чуарланса, моны бик өнәмиләр. Мин дә башыма проза турында съездда чыгыш ясау мәшәкате төшкәнче шундыйрак бер фикердә йөри идем. Ләкин бүгенге чыгышка материал әзерли башлагач, бу карашның нигездә ялгыш булуын аңладым. Я, әйтегез, иптәшләр, съезд кадәр съездда биш ел буена барлык иҗат егәрлекләрен җигеп, күз нурларын түгеп, армый-талмый бүгенге көн, заман темасына өлеш керткән иптәшләрне ничек телгә алмаска! Алар Мәҗит Рафиков, Эдуард Касыймов, Рафаил Төхфәтуллин, Миргазиян Юныс, Габдулла Шәрәфи, Шамил Бикчурин, Хәниф Хәйруллин, Ләбибә Ихсанова, Марсель Зарипов, Фәнис Яруллин, Мәдинә Маликова, Фәнил Мансуров, Рәисә Ишморатова, Илдар Низамов һ. б. Бу авторларның һәрберсе турында тиешле сүз әйтү өчен билгеләнгән вакыт та бәлки азрак булыр иде әле. Ләкин мин бары урта буын прозаикларының уңышларын һәм кимчелекләрен чагылдырган әдипләргә генә туктала алам.

Шуларның берсе — Мөхәммәт Мәһдиев. Ул биш ел эчендә ике повесть язып бастырды: «Каз канатлары» һәм «Кеше китә — җыры кала». Мәһдиев оста һәм бик үзенчәлекле прозаик. Андагы тапкырлыкны, андагы юмор байлыгын беркем дә инкяр итмидер. Шуңа күрә аның ике повесте да укучы тарафыннан җылы каршы алынды. Иҗатына халкыбызның риясыз оптимизмы хас булган бу авторның соңгы повесте «Кеше китә — җыры кала» аерата уңышлы. Димәк, ул көннәнкөн үсә, үзенең осталыгын чарлаганнанчарлый бара.

Мин Мәһдиевнең иҗат алымын мозаик алым дип атар идем. Аның бу әсәрләрендә баштан ахырга кадәр сузылган сюжет канвасы ярылып ятмый, автор күбәләк кебек бер чәчәктән икенчесенә ашыгып күчәргә ярата. Әгәр хәтерләсәгез, Мәһдиев кулланган адым мәрхүм Кави Нәҗмигә дә хас иде. Күренекле прозаикларыбыздан Фатих Хөснинең дә байтак кына әсәрләре шундый ук алымга тартым стильдә язылганнар. Руста исә мондый алымның уңышлы үрнәкләрен Илья Эренбург бирде. Ләкин бу олы язучыларның әсәрләре үтәли сузылган сюжетка корылган бит! Алар вакыйга канвасын детальләрдән торган чылбырдай ясыйлар. Моның турында Мәһдиев киләчәктә уйласын иде.

Әле күптән түгел генә Аяз Гыйләҗев үзенең повестьлар җыентыгын бастырып чыгарды. Күренекле һәм эшлекле прозаик буларак ул бу биш ел арасында язган «Язгы кәрваннар»ы һәм «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»е белән үзенең нинди зур осталыкка ия булуын күрсәтте. Бу җыентыкта авторның элеккеге ике повестеннан тыш, соңгы елларда язылган «Мең чакрым юл» исемле яңа повесте дә дөнья күргән. Ун табактан артыграк күләмдәге әсәрдә автор, минемчә, укучыга яңа сүз алып килә. Бу повестьның яңалыгы, беренчедән, тискәре персонажның алгы планга чыгарылып тасвирлануы булса, икенчедән, төп персонажның безнең прозабыз өчен яңа, оригинал образ булуында. Тискәре персонажны баш каһарман итеп, аны эре планда күрсәтергә хаклымы язучы? Әйе, хаклы, әгәр дә без шул тискәре персонаж аша чынбарлыкны расларга, начарлык гыйбрәтендә яхшылыкны хупларга омтылабыз икән. Аяз Гыйләҗев бу повестенда нәкъ менә шундый принциптан чыгып эш итә дә инде. Тик шулай да әсәрне укып чыкканнан соң укучыда кайбер сораулар, шик-шөбһәләр дә туа. Мәсәлән, ни өчен соң әле Әскәр кебек шундый явыз персонаж артык беркатлы? Аннан соң, минемчә, автор нигездә әйбәт әсәрендә кирәгеннән артык куе буяулар кулланып ялгышкан кебек.

Ике съезд арасында заман темасына берничә повесть язып бастырган Әхсән Баян иҗаты турында бирedә төпле сөйләшү булырга тиеш дип уйлыйм мин. Без бу авторны талантлы шагыйрь һәм драматург дип беләбез. Аның уңышлы шигырь һәм поэмалары, драма әсәрләре моңа дәлил. «Яшьлегемне эзлим» исемле беренче повесте белән проза мәйданына аяк басып, ул яңа жанрда да үзенең шәп әсәрләр тудырачагына заявка

ясады. Чыннан да, бераздан КамАЗ тормышына багышланган «Ут һәм Су» романы белән прозабызга шактый зур өлеш кертеп Әхсән Баян укучының ышанычын нигезле аклады. Инде узган бишьеллык башында ул шулай ук шактый уңышлы «Тау ягы повесте»н язды. Ә соңгы вакытта эш ничегрәк тора соң? Башта, шул кадәресен әйтеп узарга кирәк: бу автор һәр әсәрендә эзләнүчән, оригинальлеккә омтылучан язучы. Ул прозада яңа сүз әйтергә тели. «Төлке тоту кыен түгел», «Тавыш — табигать бүләге», «Аязучан болытлы һава». Болар соңгы өч елда басылган повесть исемнәре. Оригиналь исемнәр. Әсәрләрнең эчтәлеге белән танышкач исә, аларның шулай ук гайре табигый оригиналь икәнлеген беләбез. Ләкин шулай да үсәме соң безнең Әхсән Баян прозаик буларак? Соңгы әсәрләрендә ул ясалмалыкка һәм йөгәнсез шартлылыкка йөз тота башлады, минемчә. Мәсәлән, «Төлке тоту кыен түгел» исемле повестьта төп персонаж әсәр буена бакчасына язгы ташудан кереп калган боз кисәген ватып утыра. «Тавыш — табигать бүләге» исемле повестьта персонажларның ни исеме әйтелми, ни портреты бирелми. Баш персонаж булырга тиешле фәнни хезмәткәрнең кыланышлары һич ышандырмый. Нәрсә бу, әдәби әсәрдә символлардан файдалану мөмкинлеген шулай аңлавымы язучының? Соңгы повесте «Аязучан болытлы һава» исемле дидек. Бәлки ул уңышлыдыр? Бәлки автор җитдиләнә төшкәндер, каләмдәшләренең сүзенә колак сала башлагандыр. Әйе, бәхеткә каршы, бу әсәр отышлырак. Ләкин артык күп сүзле, информацион. Персонажларның тискәресе бик тискәре, уңае бик уңай. Кыскасы, тагын бер тапкыр яшьлегән эзләсен иде Әхсән Баян.

Заман темасына язылган әсәрләрдән мин Мәхмүт Хәсәновның «Кама таңнары»ның дәвамы «Инженерлар» исемле романын да хәтергә төшерер идем. Республикабызның нефть төбәгендә яшәүче бу Әхсән Баян кебек үк тырыш прозаикның техник интеллигенциягә багышланган романы турында укучы да, тәнкыйтьтә үзенең риясыз сүзен әйтте. Шулай да мин бу әсәре белән автор художник буларак алга таба атлавын дәвам иттерә дип исәплим. Мәгълүм булганча, Мәхмүтнең «Саумы, кояш!» исемле романы авторның әдәби зәвык һәм осталык җәһәтеннән дә шактый җитлеккән язучы икәнлеген күрсәтте. «Инженерлар» романының исә уңай ягы авторның заман белән бергә атларга омтылуында, хезмәт проблемасын алга куеп сүз коруында. Әсәрне югары художестволы дәрәҗәдә язу, әлбәттә, бик мөһим. Ләкин анда сүзнең ни турыда баруы да игътибардан читтә калмаска тиеш бит әле! Заман темасына язганда бүгенге көн өчен хас күренешләрне читләтеп узу — ул инде художество дәрәслегенең бик зур компонентын санга сукмау булыр иде. Мәхмүт Хәсәнов килечәктә тормышның тирән катлауларына тагын да кыюрак адымнар белән керә барыр, язачак әйберен шөбрәк әйрәнер һәм үзенең осталыгын һич иренмичә үстерер, схематизм элементларыннан, буш шалтыраулардан качар дип ышанабыз. Моңа аның бөтен мөмкинлекләре бар.

Сүз Мәхмүт Хәсәнов иҗатына бәйләнештә производство темасына кагылгач, мин шул уңайдан соңгы вакытта журнал битләрендә дөнья күргән ике әсәр турында әйтеп китмәкче булам. Рафкать Кәрамиевнең «Очар кошлар белән янәшә», Кояш Тимбикованың «Агым уртасында» повестьлары күздә тотыла. Алар икесе дә ифрат кирәкле темага, эшче сыйныфы вәкилләренә багышланган әсәрләр. Беренчесе Оргсинтез, икенчесе КамАЗ төзелеше материалына нигезләнеп язылган. Авторларның материалны яхшы өйрәнгәнлекләренә бернинди шик-шөбһә юк. Ләкин инде матбугатта, җыелышларда әйтелгән тәнкыйтькә караганда, бу әсәрләр көтелгән дәрәҗәгә җиткерелмичә дөнья күргәннәр.

Ни өчен шулай килеп чыга? Юкса, авторларны тәҗрибәсез яки сәләтсез кешеләр дип булмый бит. Бу хәлнең сәбәбе иң элек бездә производство, тегәлрәк әйткәндә, завод, төзелеш темасына язу традициясе җитәрлек булмауда, минемчә. Өлге, үрнәк хезмәтен үтәүче әсәрләребез бу өлкәдә шулай ук бер-яклырак. Чөнки аларда башлыча эре план белән субъект түгел, ә объект тасвир ителә килде. Ә проза әсәренең кагыйдәсе катгый, кырыс — нинди генә темага язсак та, вакыйгаларда конфликт производство технологиясенә, производство нечкәлекләренә нигезләнгән булса да, әсәрдә беренче планда тулы канлы замандашыбызның образы торырга тиеш. Билгеле, мондый әсәр язу җиңел түгел. Монда теманың ачкычын табарга кирәк. Безгә, проза осталарына, шул ачкычсыз эш итү мөмкин түгел. Ә бит мондый темаларга шәп проза әсәрләре язу эшче сыйныфының фәрманы ул. Без бу боерыкны намус белән үтәргә тиешле кешеләр.

Бездә стиле, алымнары, хәтта сюжет канвасы яхшы эшкәртелгән традицион әсәрләр үрнәгендәге повестьлар, хикәяләр, романнар да языла. Шундый ук алым белән заман темасына әсәрләрне урта буын вәкилләреннән Хәсән Сарьян язды. Арабыздан вакытсыз киткән бу каләмдәшебез сәләтле язучы һәм зур тел белгече иде. Аның повесть һәм хикәяләре үзләренең филигран осталыкта эшләнгәнлекләре, тормышчан һәм гуманистик рух белән сугарылганлыклары, музыкаль теле белән аерылып торалар. Мәрхүм бу ике съезд арасында илһамланып, дәртләнеп үзенең «Бер ананың биш улы» исемле повестен язды. Барыгызга да мәгълүм, бу повесть та гаилә мөнәсәбәтләренә, ахлак һәм вөҗданлык мәсьәләләренә багышланган. Аны безнең соңгы елларда иҗат ителгән иң яхшы әсәрләрдән дип әйтер идем мин.

Мөсәгыйт Хәбибуллин безне бүгенге колхоз кешеләренә багышланган «Чоңгыллар» исемле романы белән куандыр-

ды. Бу әсәр авторның әһәмиятле темаларны күтәрергә сәләтле проза остасы икәнлеген исбатлады. Биредә дә авыл хуҗалыгы производствосы темасы әхлакый тема белән бергә үрелеп бара.

Мин Вакыйф Нуруллинның без әле генә «Казан утлары»нда укыган «Аккан су юлын табар» исемле повестен дә шул планда язылган әсәр дип әйтер идем. Анда сүз авыл хуҗалыгы производствосы, колхоз председателе турында гына бармый, ә бик истә калырлык коллизияләр, конфликтлар аша әхлак, әдәп, мөнәсәбәтләр проблемасы хакында бара.

Билгеле, бу исемлекне тагын да арттырырга була, чөнки безнең күпчелегебез һәр әсәрендәге теге яки бу рәвештә мораль темага кагылмый калмый.

Инде килеп шартлы рәвештә традицион дип атаган алымга хөрмәт күрсәтеп иҗат итүче актив прозаикларыбызның берсе булган Барлас Камал иҗатына да мөрәҗәгать итмәкче булам.

Бу автор матбугатта өч яңа повесть бастырды: «Канатлы кырмыска», «Ярсөяр әрәмәсе», «Канат ярганда». Моңарчы тәнкыйть Барлас Камалны артык иркәләмәде. Аның әсәрләреннән схематизм, иллюстрациячелек элементлары табып килде. Ләкин мин бу прозаигыбызга алай каты бәрелергә уйламыйм. Барлас — музыкаль һәм җор тел белән яза белгән тырыш язучы. Табигать күренешләрен ул матур, җанлы итеп тасвирлый. Аның персонажлары исә тормышчан, һәр көн безнең арада, безнең белән аралашкан кешеләр. Автор аларны төрле ситуацияләрдә, төрле ракурста күрсәтә ала. Мин аның «Канатлы кырмыска»сын уңышлы әсәрләре рәтенә кертер идем. Ул тормышчанлыгы белән ота. Соңрак язылган «Ярсөяр әрәмәсе» дә начар түгел — мавыктыргыч һәм уйландыра торган повесть иҗат иткән Барлас. Ләкин шулай да Барлас Камал иҗатында тәнкыйтькә дә «азык» юк түгел әле. Кызганычка каршы, кимчелекләр аның мин уңай бәя биргән «Канатлы кырмыска» повестенда да, «Ярсөяр әрәмәсе»ндә дә бар. Автор төп сюжет линиясен үстерәсе, образны психологик тирәнлектә ачасы урында әсәрен төп максатка хезмәт итми торган, вак кына вакыйгалар белән чуарларга ярата, сүз уйнату белән мавыга башлый. Нәтиҗәдә образ тоныклана төшә. Барлас телгә бай, җор язучы дидек. Бу чыннан да шулай. Әгәр дә ул бу байлык өстенә чама белү сәләтен дә үстерә төшсә, бигрәк тә шәп булыр иде. Мәкальләр, әйтемнәр, уңышлы гыйбарәләр образны җанландыру, халыкчанландыру өчен бик кирәк. Мәгәр урынлы рәвештә һәм тиешле микъдарда булсалар гына ул шулай. Мәсәлән, персонажлар елау урынына һәр вакыт балавыз сыксалар, күңелсезләнү урынына балталарын суга төшерсәләр, карулашу урынына тел шомартсалар, сүз дәшү яки көлү урынына теш агартсалар, үпкәләү урынына йон кабартсалар, ачулану урынына холык пәриләрен аягүрә бастырсалар — бу инде жаргончылыкка тартым бер нәрсәгә әйләнә башлый. Шуны да әйтергә кирәк, автор бик гади, бик мәгълүм хакыйкатьләрне үз персонажларыннан кабатлатырга ярата, ни өчендер ә[...]ләренә атаклы кешеләр исемен пачкалап кертүне кирәк таба. Примитив бер алым буларак, бу укучыны ничектер рәнҗетә башлый. Барлас Камал бу чирләреннән котыла бара, әлбәттә. Теләк бер генә: тизрәк бөтенләйгә арынсын иде бу кимчелекләрдән.

Яңа темага к[...] мин бирелүе ихтимал булга[...] сорауга алдан ук җавап сүзе әйтерг[...] булам: ни өчен син безнең олы[...] язучыларыбыздан Фатих Хөсни һә[...] Әмирхан Еники иҗатларына тукталмадың, [...] алар да бит ике съезд арасында акт[...] эшләделәр. Гүзәл әсәрләр тудырдылар, заман темасына да яздылар дип сорарлар, әлбәттә. Әйе, алар икесе дә безнең сафның уң флангында торучы каләм осталары. Үзегезгә мәгълүм, күптән түгел генә без аларның олы юбилейларын уздырдык. Анда аларның иҗатларына тулы анализлы объектив бәя бирелде. Юбилейлар вакытында мин дә радиодан чыгыш ясап, матбугатта катнашып үз сүземне әйттем. Шуңа күрә биредә кабатлануны кирәк санамыйм. Ләкин шулай да узган бишьеллык башында бу проза осталарының үзләре өчен яңа бер жанрда көчләрен сынап карауларын әйтеп үтим. Фатих Хөсни үзенә хас темадагы ике повестьтан тыш «Алтын эзләүчеләр» исемле әсәр тудырды. Әмирхан Еники «Гөләндәм туташ хатирәсе» исемле повесть язып бастырды. «Алтын эзләүчеләр»не Фатих Хөснинең тарихка мөрәҗәгате дип карарга була, яңалыгы аның шунда — ул сатирик әсәр. «Гөләндәм туташ хатирәсе» исә Әмирхан Еники өчен шулай ук яңа, чөнки ул чын мәгънәсендә тарихи, алай гына да түгел — документаль. Анда сүз безнең сөекле композиторыбыз Салих Сәйдәшев турында бара. Бу әсәрләрнең икесен дә укучы һәм тәнкыйть җылы кабул итте.

Коллективыбызда тарихи һәм тарихи-революцион темага да әсәрләр иҗат ителде. Шулар арасында милли ленинианага күренекле өлеш булып кергән әсәр «Күк күкрәр» романы дип әйтсәм ялгышмамдыр. Үзенең тырышлыгы, якты гражданлык хисләре, эшкә фидакарь бирелгәнлеге барыбызга да үрнәк итерлек әдип Габдрахман Әпсәләмовның бу романы күләмле прозабызда даһи юлбашчы турындагы беренче әсәр. Автор бу романында Владимир Ильичның без яшәгән төбәктә узган яшьлек чорын истә калырлык итеп тасвирлый. Мәрхүм әдип төп докладта әйтелгәнчә безнең прозабызның популярлыгын Татарстанда гына түгел, бөтенсоюз күләмендә күтәрде. Аннан да популяррак прозаигыбыз булмады сугыштан соңгы елларда дисәм, ялгышмам.

Мәрхүм Габдрахман Әпсәләмовның соңгы романы да тарихи әсәр. Ул халкыбызның горурлыгы булган ялкынлы герой шагыйребез Муса Җәлил турында.



*Нәкый Исәнбәт (сулда) Мирсәй Әмиргә: «Әйтәсе фикер дә бар, аксакалларга трибунага күтәрелү генә авыр»...*

Бу «Агыла болыт» исемле әсәрне укыганда ирексездән романның авторына карата риясыз соклану хисләре кичерәсең. Әдип бу соңгы әсәрен бик каты авыру килеш, күзләре, кул-аягы үзенә начар буйсынган бер хәлдә язды. Безнең күз алдыбызда башкарылды бу Корчагиннарны хәтерләткән каһарманлык. Әсәрнең бәлки кимчелекләре дә бардыр. Ләкин аның сафлыгы, ихласлыгы игътибарны яулап ала, дулкынландыра. Ирексездән күңел Муса кебек каһарман шагыйрьләр һәм Әпсәләмов кебек фидакарь әдипләрне тудырган халкыбыз өчен горурлык, шатлык хисләре белән тула.

Ике съезд арасында Гариф Ахунов беренче бишьеллык батыры Мирсәет Ардуанов турында «Ардуан батыр» исемле повесть язды. Бу — авторның тарихи темага уңышлы бер разведкасы иде. Автор соңыннан күбрәк вакытын күләмле җитди тарихи әсәр иҗат итүгә бирде. Мәгълүм булганча, бу роман вакыйгалары революция алды көннәреннән башланып без яшәгән чорга килеп җитәчәк трилогия. Эпопея булырга тиешле бу әсәренең беренче китабын дөньяга чыгарды. Һич икеләнүсез әйтергә була: «Идел кызы» (беренче китап) — язучының җитди казанышы.

Нидән тора соң бу әсәрнең уңышы? Минемчә, аның иң беренче чиратта бик матур, образлы тел белән язылуында. Авторның казанышы тагы шунда, минемчә, ул моңарчы әдәбиятыбызда өзер өлге, бер үк калып буенчарак ясалып килгән образларны оригиналь ракурста, яңача күрә алган. Моңа мисал итеп, указсыз мулла Габбас образын китерергә була. Ә романда төп каһарман Идел кызы — Нурия булырга тиеш. Ләкин ул беренче китапта, ни кадәр мөлаем булып иста калмасын, әсәрнең үзәген тәшкил итәрлек образ түгел әле. Ул һәм башка, хәтта әлегә пунктир белән генә билгеләнгән Мулланур Вахитов образы да язылясы китапларда җитлегеп, тиешле конденциягә ирешер дип ышанасы килә.

Безнең Мирсәй Әмир олы, күренекле һәм картлыкка һич бирешмичә һаман янып, дәртләнеп эшләүче иң актив язучыларыбыздан. Соңгы елларда ул тарихи-документаль әсәрләр тудыру өлкәсендә нык кына эшләде. Аның «Без бәләкәй чакларда» һәм «Үсә төшкәч» дигән автобиографик язмалары басылып чыкты. Укучы аларны җылы каршы алды. Әгәр автор «Үсә төшкәч» повестенда информация ысулын азрак кулланып, персонажларын гамәлдә күбрәк күрсәтсә, әсәр тагы да уңышлырак чыккан булыр иде, минемчә.

Проза өлкәсендә актив эшли башлаган шагыйребез Шәйхи Маннур эшчәнлеге турында җылы сүз әйтми уза алмыйм. Шагыйрь сигезенче съезддан соң ике повесть язды. «Агым суларга карап», (автобиографик повесть) һәм «Чын сөю бармы?» (новеллистик повесть). Тәнкыйть

бу әсәрләр турында үзенең уңай фикерен әйтте инде.

Шәйхи Маннурның прозасы турында сүз кузгалгач, мин шагыйрьләребезнең прозага мөрәҗәгать итүләрен әдәбиятыбыз өчен уңай бер күренеш дип билгеләп үтүне кирәк саныйм. Шагыйрьләрнең проза өлкәсендә нинди уңыш казана алуларына бер мисал итеп Әдип Маликовның «Яшьлек утравым» исемле автобиографик повестен һәм шагыйрь Хисам Камалның «Һәркемнең гомере бер генә», исемле романын китерер идем. Бу әсәрләр соңгы елларда дөнья күрде. Вакыйгалар сугыш чоры турында. Әсәрләр оста һәм шагыйрьләрчә җылы, тыгыз язылган, әйтерсең авторлар гомер буе проза өлкәсендә эшләп тәҗрибә туплаган кешеләр. Менә нәрсә бит ул шагыйрьнең проза баскычына керүе! Моны без башка шагыйрьләрдән Фәнис Яруллин, Саҗидә Сөләйманова, Фаил Шәфигуллин, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Разил Вәлиев иҗатында да күрдек. Ә гомумән әйбәтме соң ул күп жанрлар белән эш итү? Кайберәүләр шигырь өлкәсендә дә, прозада да, драматургиядә дә бер үк авторның язуы әйбәт диләр. Ләкин осталыкны югары ноктага күтәрү өчен, минемчә, язучы үзенең сәләтен ачыклаганнан соң, бер жанрны гына төп һөнәр итеп сайларга тиештер. Бу минем прозабызны тагы да югарырак күтәрик, прозаик аңа бөтен игътибарын бирсен, әсәрләребез бөтен ил күләмендә яңгырарлык булсын дигән теләктән чыгып әйтелгән фикер.

Тарихи-революцион темага язылган әсәрләр белән бер рәттән бездә тарихи романнар да языла. Болгар бабаларыбыз турында үзенең «Әтил суы ака торур» исемле романын язып киң катлау укучының игътибарын казанган күренекле язучы Нурихан Фәттах та бу бишьеллыкта тик ятмады. Ул борынгы заман темасына багышланган «Сызгыра торган уклар» исемле роман яза.

Хәрби теманы үзенең төп иҗат эше итеп алган Шамил Рәкыйпов турында аерым сүз әйтүне урынлы саныйм. Ул Бөек Ватан сугышы каһарманнары эзеннән йөрүче иң актив әдип. Ике съезд арасында «Кипарислар җыры» исемле повесть һәм «Геройлар үлмиләр» дигән кечкенә повестьлар һәм очерклар җыентыгы бастырып чыгарды. «Кипарислар җыры» каһарман очучыбыз Мәгубә Сыртлановага багышланган. Матур тел белән язылган, лирик җылылык сулышы бөркелеп тора торган әсәр.

Алда ук әйтелгәнчә, хәзер безнең прозага авторларның специальләшә баруы хас. Моны дәлилләү өчен әле генә әйтелгән хәрби-патриотик тема мәсьәләсен һәм диңгез темасына гына язучы Миргазиян Юныс иҗатын китерергә була. Миргазиян, мәсәлән, бу чорда ике әйбәт повесть язды: «Тозлы җил», «Теләп алган давыл», Ләкин бездәге специальләшү тематик яктан гына бармады, ул жанрларга да кагылды. Моңа мисал итеп фантастика жанрында гына язучы Адлер Тимергалинны искә алырга була. Альберт Яхин үзен сатирага багышлаган, детектив жанрны Мәгъсүм Насыйбуллин, Рәисә Ишморатова алга сөрә. Аларның уңышлары бар, кимчелекле яклары да юк түгел. Әмма бер жанрга гына бирелеп эшләүләре, үзләре яраткан жанрның серләрен, технологиясен үзләштерүдәге тырышлыклары бушка китмәгәнлеге укучыга ачык.

Минемчә, бу процесс тагы да көчәя төшәр. Алда әле, «күтәрелмәгән чирәмнәр» күп. Мәсәлән, безнең күпчелегебез авылда туып үскән. Ләкин арабызда үзенең иҗатын бары бүгенге авылга, — басым ясап әйтәм, — бары бүгенге авылга гына багышлаган, даими рәвештә аның пульсын тоеп торучы берәр язучыбыз бармы соң? Безнең ир-ат язучыларыбыз барысы да совет армиясендә хезмәт иткән кешеләр, ләкин арабызда үзен бары армиягә, бүгенге армия тормышын язуга багышлаган әдип бармы? Аннан соң фәнни-фантастика жанрының безнең татар прозаикларын зарыгып көткәнлеген басым ясап әйтәсе килә. Культурабыз үсә, фән һәр өйнең ишеген кага. Проза осталарыбыз арасында гына да никә фән эшлеклесе бар. Минемчә фәнни-фантастика жанры безнең әдәбиятта чәчәк атарга тиеш. Саный китсәң, мисалларны тагы табарга була. Өмет — яшьләрдә.

Прозабызга алмаш каләм осталары тәрбияләү принципиаль мәсьәлә. Оптимистик күтәренкелек белән әйтәсе килә, милли прозабызның үрентеләре күзгә күренеп тернәкләнә, үсә. Яшьләр әдәбият мәйданына яңа форма, яңа сүз алып киләләр. Әйткәнемне дәлилләү өчен мин Әхәт Гаффаровның исемен телгә алыр идем. Бу тырыш һәм актив әдип проза өлкәсендә профессиональ осталыкка ашкына, моны үзенең «Кашан җыры» исемле повесте белән күрсәтте дә инде. Яшьләр турында сүз кузгаткач, Марсель Галиевне дә читләтеп узу мөмкин түгел. Ул бу арада ике повесть язып бастырды. Дөрес, баштагысы («Кар абагалар») тормыш материалы булудан да бигрәк әдәбияттан кергән әсәргә охшаш иде. Автор беренче әсәреннән соң ишеткән сүзләргә, күрәсең, колак салган. Чөнки әле күптән түгел чыккан «Ул чакта» исемле повесте әйбәт тәэсир калдыра.

Мин Фәрит Гыйльметдиновның «Урсай тау итәгендә» исемле кечкенә повестен да шулай ук яшь язучының уңышы дип саныйм. Җәмит Рәхимов та безне үзенең «Өлешемә тигән көмешем» исемле повесте белән куандырды. Яшьләр турында сүз чыккач, байтак авторлар исемен әйтеп булыр иде. Мәсәлән, Азат Ганиевне, Тәүфыйк Әйдине, Азат Вергазовны, Газиз Кашаповны һ. б. Соңгы елларда гына матбугатта күренә башлаган Нәбирә Гыйматдинова узган ел «Су хикәяте» исемле әсәре белән безнең игътибарны җәлеп итте. Камил Кәримов, Рафис Гыйззәтуллин һәм башка яшь язучылар про-

забызга ашкынып килэлэр. Ышанып әйтергә була: прозабызның киләчәге өметле.

Сүз хикәягә кагылса, без һәр вакыт хикәя аз языла дип зарланабыз. Хәлбуки бу өлкәдә безнең армый-талмый эшләүчеләребез аз түгел. Бездә хикәянең Афзал Шамов, Гариф Галиев, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни кебек танылган олы осталары бар. Бу өлкәдә урта һәм яшь буын вәкилләреннән бик күпләребез эшли. Ләкин шулай да хикәя аз чыга. Матбугат, аерата көндәлек матбугат, аңа кытлык кичерә. Сүз, әлбәттә, чын, әйбәт, югары сыйфатлы хикәя турында бара (әйтик, Әмирхан Еникинең без әле күптән түгел генә укыган «Тынычлану» исемле әсәре кебек). Бәлки редакция почталарын тикшереп карасаң, килгән хикәяләрнең саны элеккедән артыграктыр да, әмма аларның сыйфаты түбән булуын без вакытлы матбугатта басылган хикәяләрдән чыгып та ачык төсмерлибез.

Хикәя жанрын үстерү өчен билгеле чаралар һичшиксез күрелергә тиеш. Аңа ярдәм кирәк. Сүз дә юк. Мәгәр әле шул хәлендә дә ул, без теләгән кызулыкта булмаса да, алга бара. Башка жанрлар белән аралаштырып, зур әсәрләргә материал туплаган арада булса да, әдипләр хикәя язгалыйлар. Ике съезд арасында бу өлкәдә мәрхүм Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Ә. Еники, Г. Минский, С. Сабиров, урта буын вәкилләреннән М. Хәбибуллин, Р. Төхфәтуллин, Ш. Бикчурин, Г. Шәрәфи, Л. Ихсанова, Ф. Яруллин, М. Хуҗин, Батулла, Р. Фәизов һәм башкалар тырышып эшләделәр.

Бу чыгышта мин игътибарны күбрәк проза әсәрләребезнең сыйфатына юнәлтергә тырыштым. Фикеремчә, безгә идея сафлыгын тиешле югарылыкта тоткан хәлдә, осталыгыбызны тагын да арттыруга игътибарны көчәйтергә кирәк. Моны тормыш таләп итә, моны укучы, заман таләп итә, ниһаять, моны сыйфат һәм нәтиҗәлелек мәсьәләләренең актуальлекләрен гаять югары күтәргән партиянең XXV съезды карарлары таләп итә.

Проза әсәрләребезнең төп кимчелеге эмоциональ көчкә җитәрлек ия булмауларында. Алар күп очракта җылытмыйлар, күңел кылларын тибрәтмичә генә читләтеп узалар. Ни өчен шулай? Моның сәбәпләре күп төрле. Кайчакта бу тормышның яки кеше психологиясенең нюансларын тотып ала белмәвебездән, кайчагында матур максат — теләкләрне артык күп сүзлелек дәрьясында сыегайтып җибәрүдән, кайчагында вакыйганы дөрес ракурста кискен фокус ноктасына электерә белмәвебездән, ә кайчак телдәге чатаклыкларыбыздан, ә инде еш кына очракта примитивизм кәсафәте яки персонажны гамәлдә күрсәтәсе урында информация генә язып сурәтләүдән килә. Кыскасы, сәбәпләре күп. Мондый кимчелекләрдән котылу өчен иң беренче чиратта без осталыгыбызны үстерергә тиеш булабыз. Димәк, ару-талуны белмәстән эшләргә, эзләнергә кирәк.

Безнең әсәрләребезгә кайчакта гражданлык хисе җитенкерәми кебек. Мин бу изге тойгыны ил кайгысы, халык кичерешләре, партия таләбе белән кабынып яшәү дип аңлыйм. Бу исә бездән зур активлык таләп итә. Безнең әсәрләребездә бүген җитлеккән проблемалар, кичектермәслек мәсьәләләр күтәрелергә тиеш. Проза илне тук, бөтен, шәүкәтле иткән производство белән якыннан таныш булган хәлдә, аның кешеләренә йогынты ясарлык әсәрләр тудырырга тиеш. Производство тормышына әхлак, әдәп, вөҗданлылык, кешелеклелек, интернационализм проблемалары да тыгыз бәйләнгән. Прозабызның элек-электән килгән традицион темасын, халкыбызга хас гади сыйфатларны укучының исенә төшереп тору, үстерү, шуны гомум кешелек хәзинәсенә әдәбият аша, нәфис сүз ярдәме белән җиткерү бурычлары тора алда.

Безнең проза телебез байый бара һәм нык кына алга китте. Ләкин бу өлкәдә дә эшлисе эшләребез, киңәш-табыш корасыларыбыз, бәхәсләшеп телгә игътибарны тагын да арттырасыларыбыз бар әле. Кызганычка каршы, соңгы елларда проза телебезне диалектизмнар белән чүпләү күренешләре көчәйде. Бу күп очракта телне баетмый, ә жаргончылыкка илтә. Күп очракта теге яки бу автор, ана телен тирәнтен белмәү аркасында, я булмаса эзләнергә иренүдән рус теленнән калькалар ясау яки сүзлекләрдә күз явын алган гарәп, фарсы сүзләре белән мавыга башлый. Мондый күренешләр дә безнең әдәби телне баетуга булышмый һәм, шивәчелек кебек үк, әдәбиятка аю хезмәте күрсәтә.

Әдәби хәрәкәт, өзлексез аккан судай, үз юлын дәвам иттерә. Ул кайчакта тарлавыкларга эләгә, кискен борылышлар ясый, кайчак иркен мәйданнарга килеп чыга, тик бер генә минутка да туктал мый, һаман, һаман алга бара бирә. Гомуми әдәби хәрәкәтебезнең аерылгысыз бер өлеше булган милли прозабыз да шундый хәрәкәттә. Аның елдамрак барган чаклары була, тирәнәйгән яки саегып киткән очракларга да тарыга. Ләкин бу һаман юлда, бурычын һаман намус белән үтәргә омтыла, үзенең халыкка, илгә, партиягә хезмәт иткәнлеген белеп ага.

**Нил Юзиев**

# ХӘЗЕРГЕ ТАТАР СОВЕТ ПОЭЗИЯСЕНЕҢ ҮСЕШ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ

Татар поэзиясе язучыларның VIII съездыннан соң тарихи үсешнең яңа бер вакыт биеклегенә — XX гасырның соңгы чирегенә аяк атлады. Офыкта ерак та түгел XXI гасыр шәүләләнә. Соңгы чирек поэзиясе — бер яктан, XX гасырга хезмәт күрсәтүче, икенче яктан, XXI гасырга күпер салучы шигърият. Салынып яткан шул күпернең бүгенге торышы ничегрәк соң? Аны кемнәр төзи?

Оешмабызда 40 шагыйрь исәптә тора. Союз члены булмаганнары һәм булырга йөз тотканнары да аз түгел. Үткән чорлар белән чагыштырганда шагыйрьләр дә ишлерәк, әсәрләре дә күбрәк, җыентыклары да калынрак.

Соңгы биш ел эчендә китап булып яки газета-журналларда басылган шигъри әсәрләр белән танышу «ике съезд арасында шагыйрьләр шәп эшләгәннәр, иҗат ялкыннары сүрелмәгән, илһамнары кимемәгән!» — дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Бу фикерне кайбер саннар белән дә ныгытып була. 1974—1978 елларда, мәсәлән, Татарстан китап нәшриятында гына хәзерге исән шагыйрьләрнең татарча 115, русча 9 җыентыгы дөнья күргән. Мәскәү нәшриятларында аларның 19 шигырь җыентыгы басылган.

Поэзия җәмәгатьчелекнең даими игътибар үзәгендә тора дисәк хата булмас. Ел йомгакларында аның торышына һәр елны тәфсилле анализ ясалды, «Казан утлары» журналы хәзерге поэзиядә гражданлыкның чагылуы турында махсус сөйләшү оештырды. Гомумән алганда, талантлы шагыйрьләрнең тырыш хезмәте, акыл һәм йөрәк эше әдәби җәмәгатьчелек һәм укучылар тарафыннан да, әдәби оешмалар һәм хөкүмәтебез тарафыннан да уңай бәяләнә. Татар поэзиясенең абруе бөтенсоюз мәйданында да кечкенәдән түгел. Моңа 200 томнан торган бөтендөнья әдәбияты китапханәсендә борынгыдан алып бүгенгегә кадәр чордагы 17 шагыйребезнең әсәрләре урын алуы да мисал була ала. Бередә, мәсәлән, күп милләтле совет поэзиясе томнарында Такташ, Җәлил һәм Ерикәйләр белән бергә үк татар совет поэзиясенең җанлы тарихы булып яшәгән Х. Туфанның лирик әсәрләре, Җәлилнең сугышчан гражданлык рухын бүгенге поэзиядә сүрелдерми алып баручы С. Хәкимнең шигырьләре һәм алар белән янәшә үк яшьрәк буын вәкилләреннән Равил Фәйзуллин шигырьләре урнаштырылган. РСФСР Язучылар союзында тикшерү вакытында И. Юзеев һәм Р. Харис әсәрләре югары бәя алды. Әлеге янәшәлектә үк күренеп тора: тормыштагы табигый процесс— буыннар эстафетасы, буыннар яңаруы поэзиядә дә бара. Поэзиягә килгән яшьләрнең көр авазлары шигъриятнең гомум оркестрында шактый ачык һәм көчле яңгырый. Үткән съездларда яшьрәк буын шагыйрьләр исемлегендә йөргән Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Гәрәй Рәхим, Р. Мингалимов, Р. Гатауллин кебекләр хәзер поэзия йөген җигелеп тартучы көчкә һәм үзләре яшьрәк буыннарга кул бирүче урта буынга әверелде. Аларның әсәрләре рус теленә дә тәрҗемә ителеп, китаплары үзәк матбугатта да уңай бәя алуга ирешә. Ике съезд арасында аеруча Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов һәм К. Сибгатуллиннарның иҗаты тагы да тирәнәеп, бер-берсен кабатламаган үзенчәлекле яклары белән ачылып китте. «Утлы бозлар», «Исәнме, йөрәк», «Гамь» җыентыкларында бүгенге поэзия үсешенең әһәмиятле тенденцияләрен күрергә мөмкин.

Соңгы еллардагы тагын бер әһәмиятле күренешне аерып әйтеп үтү сорала. Г. Зәйнашева, С. Сөләйманова, Э. Мөэминова, К. Булатова кебек хатын-кызлар элегрәк елларда поэзиягә ялгыз-ялгыз киләләр иде. Хәзер — төркемләшеп киләләр. Хәтта аларны Әлмәт шагыйрәләре, Чаллы шагыйрәләре, Казан шагыйрәләре дип исемләргә була. Хикмәт күпләп килүдә генә дә түгел, ә аларның кеше күңеленең эчке тирбәлешләрен, серләрен хатын-кызларга хас нечкә күңел күзе белән күреп, самими җырлый алуларында.

Соңгы елларда Ф. Яруллин, Рәшит Әхмәтҗанов, З. Насыйбуллин, Р. Миңнуллин, Ф. Сафин, Ш. Маннапов, Р. Вәлиев, М. Галиев, Р. Бәшәров, Ә. Гадел, Х. Әюпов кебек яшь шагыйрьләрнең дә тавышлары ачыграк һәм үзенчәлеклерәк ишетелә бара. Болар барысы да поэзия эстафетасының ышанычлы кулларга, өметле яшьләргә күчүе турында сөйләргә мөмкинлек бирә. Һәр буынның поэзиягә килүендә эчке зарурият бар. Үзләре белән алар үз буыннарының уй-хисләрен, моңнарын-аһәңнәрен алып киләләр. Шуңа да буыннар алмашынуы поэзия тарихында билгеле бер эз калдыра. Әмма шул ук вакытта поэзия эстафетасының яңа буыннар кулына күчүен спорттагы эстафета рәвешендәрәк кабул итүдән һәм аңлатудан да сакланырга кирәк. Бездә исә кайвакыт шундый омтылышлар күренеп ала. Спортта эстафета тапшырылгач, тапшыручы кеше йөгерүдән я йөзүдән — кыскасы, ярышудан туктый. Поэзиядә, сәнгатьтә иҗат ярышы, иҗат эшчәнлеге туктамый — дәвам итә. Моңа берничә буын шагыйрьләренә мәслихәт биргән, һәм үзләре бүген дә дәртләнеп иҗат иткән Х .Туфан, С. Хәким, Н. Арсланов,

Ә. Исхак, Ш. Маннур кебек поэзия аксакалларының әсәрләре дә, З. Нури, Н. Дәүли, М. Садри, Ә. Маликов, Г. Латыйп кебек өлкәнрәк буын шагыйрьләренең иҗатлары да, Ш. Галиев, Г. Афзал, И. Юзеев, Х. Камал, Ә. Баян, М. Шабаев, Р. Гәрәй, С. Сөләйманова, Роберт Әхмәтҗанов кебек поэзиягә сугыштан соң 50 нче елларда килгән шагыйрьләрнең төрле жанрлардагы бай иҗат эшчәнлекләре дә мисал була ала. Төрле буыннарның бердәм иҗат җимеше һәм омтылышы гына бүгенге поэзиянең көчен һәм куәтен билгели. Бүгенге поэзиябез шушы нигездә төрле төсләргә, төрле моңнарга бай шигърият булып, Такташ, Җәлил традицияләренә турылыклы шигърият булып күз алдына килә.

Шушы уңайдан әдәбият практикасында поэзиядәге аерым фактларны һәм буыннар мөнәсәбәтен бәяләүдә вакыт-вакыт очрап куя торган бер якка авышып китү күренешләренә дә тукталып үтү кирәктер. Чөнки әлеге авышу әдәби процесска шактый йогынтылы тәэсир ясый. 200 томлык бөтендөнья әдәбияты томнарында татар поэзиясе әсәрләреннән генә урын алып, проза һәм драматургия әсәрләренең кермәгәне әдәбиятының тарихын һәм бүгенгесен яктыртуда әнә шундый авышуларны китереп чыгаруга сәбәпче булды. Шул нигездә шагыйрьләрне башка жанрдагы каләмдәшләреннән аерган һәм аларга каршы куйган һавалы чагыштырулар туды. Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан кебек классик, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи кебек остаз шагыйрьләрнең томнарда урын алмавы, әлбәттә, эчне пошыра. Ә бит томнарда бездән 17 әдипнең әсәрләре урнаштырылган. Шушы чикләнгән мәйданда да әдәбиятыбызның үткәнен һәм хәзергесен чагыштырмача тулырак итеп күрсәтергә мөмкин булыр иде. Күрәсең, мондый җитди басмалардагы материалларны хәзерләү эшенә җитәрлек җаваплылык белән карамаганбыз. Аларны хәзерләүдә Татарстандагы фәнни оешмаларның ни өчен катнаштырылмавы да аңлашылмый. Һәрхәлдә, әлеге хөрмәткә лаеклы фәнни басманың татар әдәбиятының үсү дәрәҗәсен һәм әдипләрнең дөнья классикасына керү-кермәвен бөтен тирәллеге белән ачып биргән өлге буларак хезмәт итүе шикле. Газета, радио, телевидение редакцияләре һәм тәнкыйть шушы нигездә туган икенче бер авышуга юл куйды. Алар сөйләшүне әсәрләре урын алган бөтен шагыйрьләр иҗаты буенча тигез алып бармыйча, дан дилбегәсен һәм эстафетаны иң яшь буын вәкиле Равил Фәйзуллинга тоттырып, аның шигъри тулпарын гына алга чыгардылар. Нәтиҗәдә шагыйрьләр сабан туенда җиңүче таҗын тик бер шагыйрьгә генә кияргә туры килде һәм әдәбият бәйгәме спорт ярышы рәвешен алды, буыннар эстафетасы спорттагыча хәл ителде.

Шушы нигездә аерым тәнкыйтьчеләрдә татар поэзиясенең үткәнен һәм бүгенгесен яңачарак бәяләү омтылышы туды. Яшьрәк тәнкыйтьчеләрнең чыгышларында хәзерге поэзиядә барлыкка килгән яңалыкларны 60 нчы еллар уртасында әдәбиятка килгән шагыйрьләр буынына кайтарып калдыру һәм бөтенесен дә алар буыны яки Равил Фәйзуллин эшчәнлеге белән генә ялгыш аңлату очрый башлады. Үзенә күрә шуны нигезләгән «шигъри шартлау» теориясе дә туды. Бу теория буенча татар совет поэзиясе гүясе ике шартлау кичергән: берсе 20 нче еллар, икенчесе — 60 нчы еллар уртасында. Беренчесе поэзиядә тик форма яңаруын, «яңа эстетик нормалар,сурәтләү чаралары арсеналының киңәюен» барлыкка китерсә, икенчесе «фикер поэзиясенең югары баскычка күтәрелүенә» ярдәм иткән. З. Мансуров фикеренчә, икенче шартлауга кадәр «фикер поэзиясе шигъри әсәр эчендәге бер автономия — ягъни интеллектуаль элемент буларак кына» яшәгән. Поэзиягә «акыл тешен» тик хәзерге яшьләр генә чыгарган. Такташ, М. Җәлил, Туфан, Ә. Фәйзи шикелле шагыйрьләребезнең әсәрләрендә «интеллектуаль элемент» кына тапкач, Тукайларда нәрсә кала инде? Киресенчә — Тукай, Дәрдмәнд, Такташларны «акыл теше» чыккан шагыйрьләр итеп карау бүгенге поэзияне, аның талантлы вәкилләрен һич тә түбәнсетми бит. Татар поэзиясенең үсеше, әлбәттә, тигез генә бармаган. Аның нык яңару кичергән вакытлары бар һәм аны күрсәтергә кирәк. Без тигезләү ягында түгел. Ә урынлы-урынсыз шартлата башласак поэзиябездән нәрсә калыр? Шартлау төшенчәсе бит ул иң беренче чиратта җимерү, вату ягын күздә тота.

Традицияләрнең дәвамлылыгы якынлыкка яки охшашлыкка нигезләнү белән бергә үз эченә билгеле дәрәҗәдә инкарь итүне, якынлыктан һәм охшашлыктан качу моментын да ала. Шунсыз үсеш юк, яңару юк. Ә бу процесс исә гаять катлаулы һәм каршылыклы. Бүгенге поэзияне заман югарылыгына күтәрәбез дип без кайвакыт үткәнне урынсыз кире кагу юлына басабыз. Мәсьәләгә җитдирәк һәм саграк килергә кирәк. Әдәбият-сәнгать үсеше техникадагы яңалыктан нык аерылып торуын теоретик яктан ачык итеп аңлатып бирә алсак та, мәсьәләгә практик якын килгәндә әдәбиятның шул чорның матурлык законнары буенча зарури тууын онытып җибәргәлибез. Әйтик, Такташ, Җәлил шигырьләренең шундый үтә социаль характерда һәм героик пафослы булуларын чор сораган. 20—30 нчы, 40—50 нче еллар поэзиясе яңа җәмгыять төзүнең героик-социаль пафосын һәм эпик картинасын ачык чагылдыруы белән үзенчәлекле. Революцион чынбарлык таләбе булган шушы тенденция табигый рәвештә героик-социаль пафослы лирик әсәрләрне һәм хикәяләүгә нигезләнгән сюжетлы-вакыйгалы әсәрләрне — эпик поэмаларны, шигъри повестьларны, сюжетлы җырларны һәм шигырьләрне активлаштырды, лириканы эпик як белән баетуга китерде. Без еш кына тибеп китәргә яраткан 40—50 нче еллар поэзиясе дә фикерсез-хиссез, тасвирый шигырьләрдән генә тормый. Шул елларда лирик җәүһәрләрен иҗат иткән Х. Туфанны искә алу да җитә торгандыр. 50 нче еллар ахырыннан безнең җәмгыять үсешенең яңа



*Сугыш елларында очраша алмаган белорус язучысы Анатолий Прокша (сулда) белән белоруссия партизаны — шагыйрь Зәки Нурины съезд кавыштырды.*

этабы башлану әдәбиятта да яңа үзгәрешләр туугa сәбәпче булды. Чор башка — җыр башка дип юкка гына әйтмиләр бит. Яңа хасиятләр, әлбәттә, кинәт кенә барлыкка килмәделәр, алар шул ук беренче дәвердән бу якка атлаган Х. Туфан, С. Хәким, Ә. Фәйзи, Ә. Давыдов кебек шагыйрьләр иҗатында бөреләнде, тамыр җәйделәр. Сугыштан соң поэзиягә килгән яңа буын шагыйрьләрдә — Ш. Галиев, Г. Афзаллар буынында исә үткәндәге искергән хасиятләрне инкяр итү — буш риторик купшылыкны, коры декларативлыкны кире кагу шактый ачык рәвеш алды. Аларның уңышлы эзләнүләре исә поэзиягә 60 нчы елларда килгән яңа буынга яңа юлларны эзләргә юллар ачты. Әмма яңару рухы Р. Мингалимовлар буыны белән генә чикләнми. Әдәбиятның бөтен буыннарында да 60 нчы еллар урталарында яңару һәм эзләнү рухы көчле булды. Н. Арслановның, мәсәлән, шагыйрь буларак яңадан тууы нәкъ 60 нчы еллар башына һәм уртасына туры килә. Башка шагыйрьләр иҗаты да шул елларда нык үзгәрделәр. Димәк, яңаруны берничә шагыйрьнең шәхси кыюлыгы гына һәм яңа нигездә бөтенләй яңача язарга тотынулары гына билгеләмәде. Ул чактагы яшь шагыйрьләр үзләре бөтен ил күләмендәге гомуми яңару дулкынына килеп кerделәр. Үзләренә кадәр үк — Х. Туфан, Ә. Давыдовларда ук башланган яңаруны дәвам иттеләр. Эстетик яңару гомумән бөтен әдәбият һәм ил күләмендә барды — без аны Я. Смеляковта да, М. Кәримдә дә, Р. Гамзатовта да ачык күрәбез. Әлеге яңару ул социалистик җәмгыятьнең үсеше белән, шул еллардагы яңа иҗтимагый-эстетик атмосфера белән билгеләнде.

Поэзиядә фәлсәфи-рухи башлангычның, аналитик-тикшерү рухының көчәюе шигъри фикерләүнең эчтәлегенә дә, формасына да сизелерлек йогынты ясый. Сәнгатьчә фикерләүнең эчтәлегендә ул тема-мотивларның төрләнүе һәм әхлакый-рухи эзләнүләрнең, шәхесне тикшерүнең активлашуы рәвешендә чагыла. Бу үзенчәлекне, мәсәлән, Н. Арслановның «Уйлар_сагышлар», Саҗидә Сөләймангованың «Кызыл каурыйлар» һәм алардан яшьрәк Р. Фәйзуллин («Шигырьләр, поэмалар»), Р. Харис («Уйлы туйра»), Г. Рәхим («Моңнарым») җыентыкларына күз салуда да ачык күрергә мөмкин. Соңгылары үзләренең күңел биографияләрен тыенкырак ачсалар һәм күңел пәрдәсен күтәреп үк бетермәсәләр, Н. Арсланов ныграк ача төшә. Саҗидә һәм Равилләр исә үз күңел дөньяларын шәрран-яра ачып салалар: эчке янулары, тетрәүләре, ярсу-өзгәләнүләре, —барысы да шигырьдә. Ул хәзерге заман кешесенең эчке азатлыкка ныграк ирешүен чагылдыра. Бүгенге поэзиядә психологизмның киң урын алуы, эчке рухи дөньяны тикшерүнең тирәнәюе һәм баюы күзгә ачык ташлана. Шул ук вакытта шагыйрьләрдә эчке йөрәк серен ачуга

капма-каршы булган икенче тенденция дә — тыштагы олы дөньяны, социаль-политик чынбарлыкны, халыкның үткәнен-бүгенгесен тикшерү омтылышы да көчле икәнен әйтергә кирәк.

**Үз халкыңның киләчәген,**
**Үткәнен, бүгенгесен,**
**Кайгысының, шатлыгының**
**Зурлыгын белер өчен,**
**Еракка китеп кара!**

— ди М. Әгъләмов. «Еракка китеп карау» омтылышы гомумән хәзерге поэзиядә елдан-ел көчәя һәм тирәнәя барган тенденция. Бүгенге тормыштагы олы социаль-әхлакый үзгәрешләрне, зур яңалыкларны шагыйрьләр үткәннәр фонында гомумиләштереп күрсәтергә яраталар. С. Хәким поэмасының исеме ук — «Дәверләр капкасы». Камадагы олы тәзелештә тарих катламнары аралаша, төрле юллар, буыннар очраша. Шагыйрь дә әнә шул буыннарны тоташтыра торган тарихи җепләрне, әхлакый катламнарны эзли, шуларга игътибарны юнәлтә. Шушы ук омтылыш һәм тарихи тойгының көчәюе И. Юзеевның «Таш диварлар авазы» һәм «Өзелмәс кыллар» поэмаларында да, Р. Харисның «Казан» ораториясе һәм «Рәссам» поэмасына да, Р. Мингалимовның «Юл өстендә тургай» һәм Ф. Сафинның «Ак канатлы егет» поэмаларына да хас.

Үткәнгә борылып карауда, әлбәттә, гөнаһ юк. Шул ук вакытта кайбер лирик шигырьләрнең герое кебек үткәнгә борылып карап, иң борынгы бабаларын һәм аларның бәйгеләрдә җиңелүен күз алдына китереп, күзләреннән «әрнүле һәм сагышлы яшьләр» агызып торуда да зарурият юктыр. Бу яктан Н. Арслановның лирик шигырьләре тарихка тирәнрәк үтүләре, тарих катламнарын сәнгатьчә тирәнрәк ачулары белән аерылыбрак торуын әйтергә кирәк. Ул археолог сыман тынгысыз казынып, төрки халыкларының тарих катламнарында калган әхлакый-рухи байлыгын, әдәби-культура-тел мирасын бүгенгегә якынлаштырырга омтыла, шул юнәлештә нәтиҗәле эзләнүләр алып бара.

«Минем аша Вакыт ага»,— ди Харис. Бер яктан, шагыйрьләр үткән белән бүгенгенең ни рәвешле тоташуын ачу юлында эзләнсәләр, икенче яктан, бүгенге белән киләчәкнең бәйләнешенә игътибар юнәлтәләр. Күпчелек әсәрләрдә хаклы рәвештә бүгенге яшәешнең шатлыклы аһәңнәре өстенлек итә, әмма әгәр поэзия әнә шундый аһәңнәрдән генә торса, тормыштагы матурлыкны һәм гармонияне суратлау белән генә шөгыльләнсә, аның кешегә кирәклеге дә шул кадәр генә булыр иде. Поэзиянең уйландыра һәм сискәндерә торган хасияте дә бар. Шагыйрьләр җир тормышындагы, табигатьтәге, кеше әхлагындагы үзгәрешләрне күреп борчылалар. «Йоклап яткан авыр набат сыман олы борчу җанда уянды»,— ди Зөлфәт һәм ул шушы олы борчуны сискәндерерлек итеп, тәэсирле итеп күрсәтә дә белә. «Иәрәгенә кадәр экскаваторлар казып кергән» сазлыкның Бөек Төн белән бәхилләшүе яки «Янабыз» шигырендә сайрап торган килеш янган былбыл, утлы йомгакка әверелгән кызыл тиен — бу күренешләр укучыны да ваемсыз калдырмый, терекләкнең язмышы, аны саклауда кешенең җаваплылыгы тагы да артырга тиешлеге, кешенең әхлаклылыгы турында уйландыра, мәсьәләнең куелышы хәвефләндерә.

Табигать, планета язмышы өчен борчылу авазы хәзер шагыйрьләр игътибарын үзенә ныграк тарта бара. Шагыйрьләрдә мәсьәләне әхлакый-фәлсәфи гомумиләштеребрәк суратлауга игътибарның көчлерәк икәнлеген һәм бу юлдагы эзләнүләрнең дөнья поэзиясе югарылыгында баруын әйтергә кирәк.

Әлбәттә, дөньядагы, илдәге көндәлек конкрет вакыйгаларга да шагыйрьләр күз ташлыйлар, аерым актуаль темаларны публицистик ялкын белән сурәтлиләр. Бу яктан С. Хәким, Н. Дәүли, М. Садри, Р. Гатауллин, Роберт Әхмәтҗановларның эшчәнлеген аеруча билгеләп үтәргә кирәктер. КамАЗ турында байтак шигъри әсәрләр язылды. Авылның гадәти көндәлек тормышы Рәшит Гәрәй, Н. Мадьяров, К. Сибгатуллинда, укытучылар тормышы К. Булатовада, диңгезчеләр тормышы Ф. Шәфигуллинда шигърияте яклары белән ачыла. Шулай да поэзиядә хәзер үзен шактый нык сиздерә башлаган тенденция — конкрет вакыйгаларга игътибарның йомшый төшүен дә күрмичә мөмкин түгел. Монда сүз шагыйрьнең үз биографиясенә кагылышлы конкретлык турында бармый. Сүз ил тормышындагы, дөньядагы әһәмиятле фактларны, күренешләрне, вакыйгаларны яктырту, аларны халык тарихына, ил биографиясенә беркетү турында, бу өлкәдә шагыйрьләрнең активлыклары кимү турында бара.

Соңгы вакытларда әлеге тенденцияне теоретик ныгыткан: «Үзең барып, күреп белгәнне генә яз! Үзеңнең күргәнеңә генә мөнәсәбәтеңне белдер!»— диган, шагыйрьнең ихтыяры һәм язу мөмкинлекләрен чикләгән ялгыш концепция дә барлыкка килде. Такташ бит Чемберлинны да күрмәгән, Шанхайда да, Лондонда, Рурда да булмаган — ә шундагы тарихи-политик вакыйга-фактларга үз мөнәсәбәтен белдереп нинди тәэсирле шигырьләр язган! Көндәлек вакыйгалардан читләшү ахыр чиктә поэзиядә тормыш тулылыгын күрсәтүгә, шәхеснең социаль бәйләнешләренең күптөрлелегендә күрсәтүгә комачаулык ясавы көн кебек ачык. Хәзерге тормышта заман кешесе политикага, җир шарындагы һәр төрле вакыйгаларга тагы да ныграк якынайды, ә безнең әдәбиятта, киресенчә, политика һәм гадәти конкрет тормыш Такташ, Җәлилләр чоры белән чагыштырганда шигырьдән читләшә төште. Поэзия үсешендәге әлеге тенденция, әлбәттә, уйландыра.

Шагыйрьләрнең күбесендә хәтта хәзерге тормышта барган кискен социаль-демографик процессларның кешегә, семьяга, җәмгыятькә ясаган тәэсиреннән, яңалыгыннан өрку, алардан читләшеп, поэзиянең традицион мәңгелек темаларына ныграк

ябышу, шуларны калкан итеп, алар артына посу тенденциясе сизелә. Моны, мәсәлән, сөю-мәхәббәт темасының яктыртылышында да ачык күрергә мөмкин. Тормышта мәхәббәт-гаилә мәсьәләләре күп катлаулырак, хәл ителәсе мәсьәләләр күбрәк. Көнкүрештә чын мәгънәсендә гаилә революциясе бара. Бу революциянең асылы гаиләнең башы ир кеше булган патриархаль семьядан ир һәм хатынның тигез хокуклыгына корылган «биархат» гаиләгә, күп буынлы семьядан — ата-ана һәм балалардан торган аз буынлыга, күп балалы гаиләдән — аз балалыга күчүдә. Бу процесс бездә дә — татарларда да элекке гаилә өлгесе һәм нигезе бөтенләй яңа нигезгә күчә бара. Семья революциясе, башка революцияләр шикелле үк, бик күп төрле конфликтлар, психологик коллизияләр тудыра. Хәлбуки бу үтә катлаулы һәм озакка сузылган авыр процессның безнең поэзиядә тиешенчә тирәнлеге белән ачылганы юк әле. Шагыйрьләр күбесенчә игътибарларын мәхәббәтнең беренче этабына — гаилә коруга кадәрге чорына юнәлтәләр һәм мәхәббәт гармониясен традицион ачкычтарак хәл итәләр. Көнкүреш-семья өлкәсендәге кискен үзгәрешләр, психологик конфликтлар 60 нчы еллардан активрак һәм кыюрак яктыртылуын да әйтеп үтәргә кирәк. С. Хәкимнең «Суд залында» циклы, Ә. Баян, Х. Камал поэмалары, Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясе, Ш. Хөсәеновның «Әни килде» драмасы семьядагы катлаулы мөнәсәбәтләргә игътибарны юнәлтүләре белән әһәмиятле роль уйнадылар. Соңгы елларда әлеге традиция тирәнәясе урында йомшый төште.

60 нчы еллардагы һәм 70 нче еллар башындагы юмор-сатира белән чагыштырганда бүгенге поэзиядә көлү көче дә нык кына йомшады, аның кыюлыгы һәм сугышчанлыгы кимеде. Көлкеле ситуацияләргә, вакыйга-хәлләргә нигезләнгән сюжетлы шигырьләр бик нык кимүгә йөз тотып (поэмалар турында әйтеп торасы да юк), көлкеле шигырь күбесенчә үткен фикер әйтүгә яисә мәзәк сөйләүгә корылган кыска шигырь, дүрт юллык рәвешен алып бара. Бу өлкәдә актив эшләп килүче ветераннардан тик З. Нури гына шигырьдәге көлкегә даими тугрылык саклый дисәк, хата булмастыр. Г. Рәхим, Ф. Яруллин, Ф. Шәфигуллиннар аерым шигырьләре белән үзләренең көлдерә алу сәләтләре һәм осталыклары бар икәнлекләрен күрсәтә алсалар да, әлеге стихияләре поэзиядә тулы килеш ачылып китә алмыйча тора. Ш. Галиев үзе болай көлүеннән туктаганы юк, тик ул көлү буенча җигелеб рәк балалар өчен эшли. Аның «Әз-мәз мәзәк яки Котбетдиннең кырык тартмасы» исемле мәзәкләр җыелмасы һәм «Хикмәтле сүзләр»е авторның көлү чишмәсе һәм үткен фикерлелеге кибәргә җыенмавын янә бер тапкыр раслады. Г. Афзал да юморескалар язып көчен прозада сынап карады. И. Юзеев, Ф. Яруллин кебек шагыйрьләрнең көлү сәләтләре нигездә комедияләрендә тулырак ачылды. Шул рәвешчә, хәзер көлү зурлар поэзиясенә караганда балалар поэзиясендә, прозада һәм драматургиядә тернәкләнеп бара. КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары безгә көлү көчен һәм тәнкыйть рухын бөтен жанрларда үстерү чаралары турында ныклап уйланырга этәрә.

Сурәтле фикерләүнең эчтәлегендә генә түгел, формасында да күп төрле һәм капма-каршы тенденцияләр яши. Бүгенге шигырьнең төп характерын берничә сүз белән генә аңлатуы, әлбәттә, кыен. Әмма шунысын ачык итеп әйтеп була: ул заман һәм заман кешесе белән бергә үзгәрә бара: аның аһәңе һәм структурасы яңара, төрләнә һәм катлаулана, шигъри сүзнең егәрлеге, энергиясе һәм нюанслары арта, күренеш-детальләрнең мәгънәлелекләре көчәя... Лирик башлангыч тирәнәя. Ул жанрларга да, әсәрнең төзелешенә дә нык кына тәэсир ясый. Вакыйга сюжетыннан фикер, хис сюжетына авышуны, мәсәлән поэма жанрында ачык күзәтергә мөмкин. Хәтта бу авышу поэмада җанлы кешене, образ-характерны югалтуга илтмиме дигән борчу да уятып куя. Шигырьне традицион бизәкләреннән арындырып, фикерне ялангачландырып сурәтләү омтылышы да бар. Поляк шагыйре Ружевич эстетикасына охшаш булган бу омтылыш та вакытвакыт бер якка авышу рәвешен ала — шул нигездә аерым әсәрләрдә риторика, декларативлык баш калкытып ала.

Шигырьнең төп хасияте бар — яхшы шигырь хис һәм фикер бердәмлегендә яши, шуңа омтыла. Кичереш нигезендә туган мондый тип шигырь кешелекнең гаҗәп олы казанышы булды һәм поэзиянең төп үсеше әле дә шушы олы юлдан бара. Шул ук вакытта әдәбиятларның бай тарихы шуны да искәртә: акыл һәм хиснең тигез пропорцияләрдә генә яшәве канун түгел. Төрле чорларда, төрле халыкларда бу мөнәсәбәт теге яки бу якка үзгәреп-авышып тора. Бер үк чорда да хис һәм акыл шигъриятенең төрле стиль юнәлешләре яшәргә, хәтта бер үк шагыйрьдә төрле шигырь типлары очрарга мөмкин. Хикмәт аларны ничек бәяләүдә.

Безнең поэзиядә 20 нче еллардан алып 60 нчы елларгача — һ. Такташ, М. Җәлил, Ш. Маннур, Ә. Исхак, Ф. Кәрим, Ш. Мөдәррис, С. Хәким һ. б. күпчелек очракта лирик шигырь кичереш-образ буларак ачылды. Теориядә дә ул шулай,— кичереш, хис лирик шигырьнең төп хасияте буларак карала. Әмма поэзия бу рамкага гына сыймый, мондый тип шигырьләр белән генә чикләнми. Элек тә сыймаган чаклары булган (мәсәлән, Акмулла, Тукай, Гафурилар). 60—70 нче еллар поэзиясен дә әлеге критерий (хис-кичереш-йөрәкнең беренче планда булуы) белән генә аңлатып бетереп булмый. Л. Мартынов, Э. Межелайтис шигырьләре башкарак характерда язылулары белән аерылып торалар. Н. Арсланов, Р. Харисов, Р. Фәйзуллин шигырьләрендә дә йөрәк эчкәрәк, акылга табарак авышты, фикер шигърияте алгарак чыкты. Поэзиянең артка китүеме, нәсихәт-

ле-хикмәтле шигырь чорларына кайтуымы бу? Түгелдер. Бу — үткәнгә кире әйләнеп кайту түгел, ә үткәннең тәҗрибәсен яңа югарылыкта файдалану. Әлбәттә, арада үткәнне кабатлаудан узмаган, гади нәсихәт әйтү рухындагы үтә рациональ шигырьләр дә очрап куя. Әмма алары төп юл түгел. Хәзерге тормышта фикер куәсенең көчәюе, заманның интеллектуаль якка авышуы сурәтле фикерләү характерына да нык кына йогынты ясап тора, эмоциональлекнең яңа рәвешен тудыра. Бу мәсьәләгә хәзер әдәби тәнкыйть тә игътибар итә, шагыйрьләр дә фикер әйтә. Шушы стиль юнәлеше тарафдары Э. Межелайтис, мәсәлән, болай ди: «...яшәвен дәвам иттерер өчен, үзен саклап калыр өчен поэзия катлаулырак рәвеш ала, акыллырак, фәлсәфәлерәк була бара. Тик хискә генә таянган поэзия фикер поэзиясенә юл бирә. Ни эшләмәк кирәк — гасыры шундый!»

Әлеге сүзләрдә, минемчә, хәзерге поэзиядәге аерым үзгәрешләр нигездә дөрес тотып алынган. Дөрестән дә, байтак әдәбиятларда, шул исәптән бездә дә, шигырь катлаулырак рәвеш ала бара, аның фәлсәфи ягы көчәя. Әмма шул ук вакытта мин үзем хис-кичерешкә нигезләнгән шигырь өлгесен фикер шигъриятенә мондый ук кискенлек белән каршы кую ягында түгел. Әйбәт хис шигыренең дөньяны танып-белү әһәмияттен кичерәйтмик инде без, аны поэзиянең искерә төшкән һәм искерә барган юнәлеше итеп тә санамыйк. Ул поэзиянең төп юлы булып килде һәм әгәр дә шигърият бу юлдан читкә тайпылса аның киләчәге матур булмас, ул яңадан хис-кичерешләр дөньясына әйләнеп кайтырга тиеш булыр. Тарихта бит инде фикерне генә дөньяны танып-белүнең кодрәтле көче итеп санаган, рационалистик поэзия өстенлек алган дәверләр булмады түгел. Кешелек мондый тип шигырьләр белән генә канәгатьләнергә һәм чикләнергә теләмәде, үзенең Гейне, Гете, Пушкин, Есенин, Такташ кебек шагыйрьләрен тудырды. Хис-кичереш тибы шигыренең урыны хәзер дә шигъриятнең түрендә. Ул хәзер дә поэзия иленең тулы хокуклы гражданины. Ул киләчәккә дә шулай барыр. Фикер һәм хисне бер-берсенә каршы кую, берсенә генә өстенлек бирү турында урынсыз бәхәсләр, сүз көрәштерүләр алып барганчы, ике шигырь тибының да яшәргә хаклылыгы, бер-берсен тулыландырып яшәүләре турында сүз алып барсак — дөресрәк һәм нигезлерәк, поэзиянең бүгенгесе һәм киләчәге өчен отышлырак һәм файдалырак булыр.

Татар поэзиясенең үткәне мактанырлык булган кебек, бүгенгесе дә матур, киләчәге дә ышанычлы һәм якты. XXI гасырга салынып яткан шигъри күпернең нигезе нык, терәкләре хәзерге заманның әйбәт материалыннан — бик тә кешелекле уй-хисләреннән салына.

## Азат Әхмәдуллин

# ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНЕҢ ХӘЗЕРГЕ ХӘЛЕ

Республикабыз язучыларының сигезенче съездыннан соң җәмгысе илле пьеса язылып, шуларның кырыгы сәхнәгә куелды. Алар театр сәнгатебез үсешендә гаять зур, кайчакта исә хәлиткеч роль уйный торган жанрны анализлау, кимчелекләрен һәм яңару перспективаларын билгеләү, тәнкыйди фикерләр әйтү һәм гомумиләштерүләр ясау өчен әйбәт материал бирә. Кеше образын гәүдәләндергәндә декларативлыктан кискен арынырга, характерлар байлыгын һәм катлаулылыгын тирән ачарга омтылу бүгенге драматургия үсешенә иң хас сыйфат булып тора. Алтмышынчы елларда ук көчәйгән жанр һәм стиль төрлелеген эзләү яңа уңышларга китерде. Жанр үсешендә бу елларда заман мәсьәләләренә игътибар арту, социалистик чынбарлыкны тулырак чагылдыру күзгә бәрелде. Безнең авторларның сәнгатьчә уйлануларында совет кешесенең иҗтимагый кыйммәте һәм активлыгы, социалистик шәхеснең идея-әхлак потенциалы, әйләнә-тирәгә, үз тормышына иҗади мөнәсәбәте үзәк урынны алды.

Интеллектуаль, фәлсәфи башлангыч көчәю бүгенге драматургия үсешенең бер үзенчәлеге булып тора. Тормыш кешеләрдән фикер йөртүдә иҗади активлык, мөстәкыйльлек, катлаулы мәсьәләләрне чишүдә тирән белемгә ия булуны таләп итә. Бу, үз чиратында, кешенең камилләшүе, интеллектуаль үсештә яңа югарылыкка күтәрүенә китерә. Димәк, интеллектуальлек ул мода гына түгел, бүгенге художество процессының бер закончалыгы буларак, сәхнә сәнгатендә чагылыш таба торган үзенчәлек.

Туган көненнән бирле совет драматургиясендә беренче чиратта башкаларның ихтыяҗын яхшы күрә һәм аңлый торган каһарман үзәктә тора. Мондый каһарман шәхси мәнфәгатьләрдән баш тарта белә һәм шуның белән дикъкатьне җәлеп итә. Фәнни-техник революция бу геройның офыкларын киңәйтте. Д. Вәлиев, драма-

тург буларак, беренче чиратта менә шундый каһарманнар белән эш итә. «Диалоглар» пьесасында да без менә шуны күрәбез. Монда ул үткен иҗтимагый проблемалар күтәрә һәм аларны җәмгыятебезнең алга баруын раслап, партияле принципиаль карашлардан чыгып хәл итә. Пьесаның герое — төзелә торган заводның генераль директоры Громких башка каһарманнар белән үзенчәлекле бәхәс-диалогларга керепһәм тирән рухи кичерешләр аша катлаулы хәлләрдә дөрес чишелеш таба. «Дәвам» драмасындагы Саттаров, «Диалоглар»дагы Громких, Әхмәтев образларында киләчәк кешеләренең чалымнары күренә. Гадәтләнгәнчә хуҗалык итү, күнегелгәнчә фикер йөртү инерциясен ялгыз гына җиңү кыен. Бу пьесалардагы конфликт башлыча менә шуннан гыйбарәт. Драматург, шулай итеп, заманыбызның бер мөһим конфликтының асылын дөрес тотып алган. Тик шунысын да әйтергә кирәк, конфликтны хәл итү формасы әле «Диалоглар»да тәмам табылып җитмәгән. Диалоглар драматик хәрәкәтне җанландырырга ярдәм итсә дә, монда әле киеренке вакыйга оешып бетмәгән. Әхмәтевнең хәтерен җуюы шундый вакыйга барлыкка китерү өчен басма салу гына. Ул әле уйланылган киеренкелекнең барлык кисәкләрен үзенә буйсындыра алмаган. Вакыйгалар киеренкелеге җитмәү күп кенә бүгенге пьесаларның тәэсир көчен киметә. Д. Вәлиевнең тирән фәлсәфи әсәренә дә менә шушы кимчелек хас.

Театр сәнгате үсешенең хәзерге чорында иҗтимагый әһәмиятле уңай яклары булуга карамастан, интеллектуаль драманың үз кыенлыклары, үз кимчелекләре дә бар. Игътибарны образның эчке үсешенә — каһарман фикере үзгәрүенә юнәлтү теге яки бу дәрәҗәдә драматик хәрәкәтнең тышкы билгеләрен фәкыйрьләндерүгә һәм, барыннан да элек, сюжет агышы җанлылыгын югалтуга алып бара. Драматурглар моны үзләре дә күрә, шунлыктан, геройларның сүлпәнлегеннән котылыр өчен, башка сурәтләү чаралары һәм ысулларына мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, драматургиядә гыйбрәтле хикәятләр еш файдаланыла башлады. Кайвакыт драматик материал сәхнә хәрәкәтен күп сызык буенча оештыруны күздә тотып сайлап алына. Вакыйгаларны берьюлы берничә урында җәеп җибәрү ысулы да кулланыла. Мисалга, Т. Миңнуллин «Дуслар җыелган җирдә» пьесасында конфликтлы хәлнең башлангыч ноктасын бер дә күздән җуймый — кино темасын кире әйләндереп карагaн төсле, әледән-әле шуңа борылып кайта. Мондый экскурслар ярдәмендә каһарманнарының кичерешләрен үзара чагыштырып күрсәтүгә ирешә. Кешенең тормыштагы урыны, җәмгыять алдында җаваплылыгы турындагы уйлар киеренкелеге шулай тулырак ачыла.

Барлык башка чорлардагы кебек, бүгенге драма жанрының үсеш тенденцияләрен дә, барыннан да элек, уңай герой образларын тудыру билгели — төп игътибар замандашларыбызның бай эчке дөньясын, рухи сафлыгын, иманының ныклыгын, хисләренең катлаулылыгын гәүдәләндерүгә юнәлдерелә. Шунлыктан әдәп-әхлак мәсьәләләренә, психологик анализ тулылыгына дикъкать итү үсә. Авторлар образны кабатланмас йөзе белән күрсәтү өчен байтак иҗади энергия сарыф итә, моңа каһарманның вак идеалларын, килде-китте тойгыларын ачу ярдәмендә түгел, геройның башкалар өчен даими янарга омтылуын гәүдәләндерү аша ирешергә тырыша.

Арабыздан вакытсыз киткән гаять оста драматург Х. Вахитның бөтен иҗаты сәхнә сәнгатенең менә шушы үзәк бурычын хәл итүгә багышланган иде. Аның пьесалары соңгы егерме елда татар театрлары репертуарында үзәк урынны алды. Х. Вахит тамашачыларның бөтен бер буынын тәрбияләде һәм үз аудиториясен булдыруга иреште. Мәхәббәт бәрелешләре аша ул яшь буынның хезмәткә омтылышын, иҗатка талпынуын, кешеләр арасындагы матур мөнәсәбәтләрне сурәтләде. Х. Вахит соңгы ике съезд арасында да иң актив эшләүчеләрнең берсе булып калды — биш пьеса һәм опера өчен либретто язды. Аның бу пьесаларында якты буяулар мул. Автор җәмгыятебезнең көр күңел белән яшәвен чагылдырып, тамашачыларга дәрт, якты идеаллар җиңүенә ышаныч өсти. Х. Вахит үз заманын нечкә сиземли, пьесаларына да бүгенге көн сыйфатларын иркен кертә белә иде. Шул ук вакытта аның әсәрләрендә эчтәлек тирәнәя бару, образларны психологик яктан дөрес һәм кабатланмас рәвештә сурәтләү дә көчәя бару күзгә ташлана. Мавыктыргыч сюжетлы, тапкыр комедияләрендә ул шулай ук эчке мәгънә байлыгына, уңай геройларны алгы сызыкка чыгарып күрсәтүгә омтылды. «Ике килен-килендәш», «Талак, талак» әсәрләре дә авторның комик сюжетлар кора белүен раслады.

Ике съезд арасында үзенчәлекле һәм актив драматург Т. Миңнуллинның иҗади йөзе тәмам формалашты. Шушы чорда ул җиде сәхнә әсәре барлыкка китерде. Тема һәм проблемаларының актуальлеге, яңалыгы, каһарманнарының халыкчан образлы теле, вакыйгаларының үткен конфликтка корылуы Т. Миңнуллин драмаларын һәм комедияләренең уңышын тәэмин итте. Автор туган тел егәрлеген тоеп, төгәлләнгән күренешләр сурәтли белә. Ул күренешләрнең иң җыйнак дигәннәре дә төрле холык буяуларына, кәеф төсмерләренә бай. Драматург образ һәм вакыйгаларның эчке үсешен тирән тоя һәм күренешләрне әсәрнең үзәк идеясе тирәсендә укмаштыра белә. Аның диалогларында комиклык драмага һәм хәтта фаҗигагә (яки киресенчә) күтелмәгәнчә күп тапкырлар күчә. Бүген беренче чиратта Т. Миңнуллин иҗатында татар драматургиясенең төп сыйфатлары — көчле яклары да, аерым кимчелекләре дә ачык чагыла.

Т. Миңнуллин иҗатына заман темаларына кыю мөрәҗәгать итү һәм замандашларыбызның үзенчәлекле характерларын гәүдәләндерү хас. Гомумиләштереп әйт-

кәндә, ул моңа ике алым белән ирешә. «Миләүшәнең туган көне», «Уйланыр чак», «Дуслар җыелган җирдә» кебек пьесаларында авторның төп игътибары әхлак-әдәп мәсьәләләренә юнәлә. Бу әсәрләрне характеры буенча «пьеса-бәхәс» дип билгеләргә була. Аларның каһарманнары тормыштагы үз урыннарын эзләү һәм табу барышында кайбер кимчелекләрдән арыналар. Бу пьесаларда яшәеш фәлсәфәсе тикшерелә. Аларга фикер чоңгылларына, психологик буяулар төрлелегенә үтеп керү омтылышы хас.

Т. Миңнуллин драматургиясендә сәхнә әдәбиятыбызның төп үсеш юлын чагылдыра торган икенче юнәлеш тә һаман ачыграк төс ала. Моңа үзәгенә уңай герой образы куелган пьесалары мисал. Мондый каһарман иҗтимагый тормышта үз урынын, үз бурычын яхшы аңлаган замандашларыбызның вәкиле. Олы сәнгать дөньяга барыннан да элек уңай каһарман күзе белән карый. Шуның белән ул кешелекнең революцион асылын, аның үсешен чагылдыра. Коммунистик идеяләр белән коралланганлыктан, чын каһарман-замандашыбызның дөньяга карашы гаять киң. Андый образларны сурәтләүгә Т. Миңнулллин байтак яңалык кертә алды. Әмма ул моңа берьюлы ирешмәде. Аның, колачлы уңай каһарманнар гәүдәләндерү өчен башта оригиналь тискәре геройлар барлыкка китерергә кирәк, дип иман китергән чаклары да бар иде. Автор, теләсә-теләмәсә дә, шулай итеп, ул чакта чынбарлыкка иң әүвәл тискәре геройлар күзе белән карарга өндәде. Әгәр бу тормышка ашса, яхшылык тәрәзәдән түгел, төннектән генә төшәр, тәрәзәләр шул зәгыйфь яктылыкны чагылдырыр гына иде. Бәхеткә каршы, драматург андый карашлардан бик тиз ваз кичте. «Ир-егетләр», «Үзебез сайлаган язмыш» пьесаларында инде ул социалистик җәмгыятебезнең нигезен заманының алдынгы идеяләре белән рухланган кешеләр тәшкил итә дигән фикер үткәрде. Бу юл аны яңа уңышларга — оригиналь образлар тудыруга алып килде.

Комедиянең төп вазифасы һәм максаты — кимчелекләрне фаш итү, чынбарлыкның җитешсез якларыннан, кешенең тискәре сыйфатларыннан көлү. Баш каһарманы уңай герой булган комедияләрнең бик сирәк язылуы һәм шуңа күрә аларның икеләтә югары бәяләнүе үзеннән-үзе аңлашыла.

Т. Миңнуллин иҗатының башыннан ук менә шундый образга таба хәрәкәт итте. «Нигез ташлары»ндагы Гарифулла карт аның беренче сизелерлек уңышы булды. Бу образның яңалыгы традицион аксакалның яңа сыйфатлар белән баетылуында иде. Гадәттә андый карт зирәк, мәһабәт һәм, кагыйдә буларак, салкын канлы итеп сурәтләнә иде. Т. Миңнуллин карты да акыл иясе, әмма ул кызу канлы, һәр вакыт үз тирәсендәгеләрнең авырткан җирләренә кагылырга, тәнкыйть итәргә һәвәс җан. Каһарманының мондый сыйфатларын «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасында драматург тагын да үстерә төште, замандашыбызның халыкчан образын барлыкка китерде. М. Сәлимҗанов тарафыннан Татар академия театрында бик уңышлы куелган спектакльдә СССР халык артисты Ш. Биктимеров нәкъ менә шундый геройны сокланырлык итеп гәүдәләндерде. Спектакльдә җиңелчә юмор һәм җитди көлү, сатира һәм фаҗига, лиризм һәм драматизм, моңсулык һәм оптимизм бергә үреп бирелә. Капма-каршы жанрларның органик рәвештә тыгыз бәйләнешкә керүе һәм кушылуы нәтиҗәсендә менә шулай гаҗәп дәрәҗәдә бер бөтенгә укмашкан комик трагедия барлыкка килә.

Драматург вакыйгаларны җанландыру, яшәеш хакындагы актуаль фәлсәфи фикерләрне тулырак ачу һәм аңа тамашачылар игътибарын җәлеп итү өчен шартлы формаларга да мөрәҗәгать итә. Шундый пьесаларның берсе — «Ай булмаса, йолдыз бар» быел Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Бу пьеса — гади совет хатын-кызының чыдамлыгы, рухи көче чыганакларының бетмәс-төкәнмәслеге, әхлакый сафлыгы һәм идея ягыннан бирелгәнлеге турында. Мәдинә — кешенең иң яхшы сыйфатларын үзенә туплаган, олы максатка ия, ярдәм итүнең кадерен белә торган замандашыбыз образы. Театрларыбыз бүген беренче чиратта нәкъ менә шундый геройларга мохтаҗ.

Әлмәндәр һәм Мәдинә, Саттаров һәм Громких, Гамир Ханов («Сөймим дисәң дә») һәм Хисами («Кан кардәшләре»), Хәмзин («Сандугачлар килгән безгә») һәм Халик Бикташев («Кыр казлары артыннан»), Урал Шабанов («Җан җылысы») һәм Ахун Галиевич («Китмәгез, тургайлар») кебек соңгы елларда иҗат ителгән образлар татар драматургиясендә замандашларыбызны гәүдәләндерүдә мәгълүм казанышларга ирешкәнлегебезне күрсәтә. Әмма, безнеңчә, замандашыбыз образын сурәтләүдә үсеш перспективасы драматургларыбызның тагын бер адым алга атлавын таләп итә. Югыйсә, эстетик категория буларак, яңа геройны аңлауда тар карашлар тамыр җибәрүе мөмкин. Бу тарлык хәзерге заман герое сыйфатында саклану прозасында гына ачыла торган персонажлар чыгыш ясауда күренә. Әлмәндәр бик тапкыр, оста һәм зирәк рәвештә үлем пәйгамбәре Әҗәл атакаларын кире кайтара. Язмыш Мәдинәне рәхимсез сыный, авырлыклар аның башына дулкын арты дулкын ишелеп кенә тора. Дөрес, «Үзебез сайлаган язмыш»ның баш каһарманы Илгиз Туктаров башта кимчелекләргә, искелеккә үзе һөҗүм итә, әмма бераздан ул да пассив оборонага күчә. «Диалоглар»да Громких газапланып кыен хәлдән котылу юлын эзли. Әле аны тапкач та, ул үз позициясен дәвамлы рәвештә якларга туры килачәген белә.

Сүз дә юк, ныклыгы белән язмышын үзе идарә итүгә ирешкән Мәдинә кебек образлар сәхнәне бизәп тора һәм гаять зур тәрбияви әһәмияткә ия. Тик сәхнә, беренче чиратта, үзе актив һөҗүм итә һәм язмыштан, табигатьтән, төрле очрак-

лардан, инертлык һәм башка зарарлы гадәтләрдән, хәтта үзеннән дә бер-бер артлы позицияләр яулап ала торган геройларга мохтаҗ! Бүгенге мещанлыкка, кешедәге эре һәм вак кимчелекләргә, тормыш җитешсезлекләренә каршы юнәлтелгән сугышчан дәрт, гүзәл тынгысызлыкка ия Корчагин, Миңлекамал, Княжко шикелле каһарман образларына сусый.

Актив драматург А. Гыйләҗев элек һәр вакыт мещанлыкны камчыларга, тормыштагы инертлыкка каршы чыгыш ясарга хирыс иде. Аның каһарманнары яшәештә үз идеалларын эзләүче буларак гәүдәләнделәр иде. Бу яктан А. Яхин белән бергә иҗат иткән Шамил Усманов образы гына аерылып торды. «Сары чәчәк ата көнбагыш» һәм «Җан җылысы» пьесаларында автор югары идеалларга бирелгәнлеге һәм тугрылыгы белән гүзәл һәм көчле характерларны үзәккә куярга омтылды. «Җан җылысы» драмасында мәсәлән, партоешма секретаре Урал Шабанов нефтьчеләр коллективының гына түгел, күп санлы һәм үзенчәлекле Шабановлар нәселенең дә рухын гәүдәләндерә. Иң яхшы соңгы пьесаларның берсе булган «Кар астында кайнар чишмә» лирик комедиясендә А. Гыйләҗев тормышка, физик хезмәткә, кешеләргә дөрес мөнәсәбәте белән яшьләргә үрнәк булырлык каһарманнарны үзәккә куеп сурәтли. Бу пьесаларда авторның позициясе ачык, тамашачы нәрсә күздә тотылганны яхшы аңлый.

Әмма ике съезд арасында А. Гыйләҗев иҗат иткән алты пьеса турында да шушы фикерне әйтеп булмый. Аларның һәммәсенә дә автор позициясенең аныклыгы, идея-художество фикеренең ачыклыгы җитеп бетми. Мисалга Качалов исемендәге зур драма театры куйган «Югалган көн» әсәре, мөгаен, формасы ягыннан А. Гыйләҗев иҗат иткән иң кызыклы пьесаларның берседер. Әмма шуның мисалында сәнгать әсәренең кыйммәтен форма гына билгеләмәвенә тагын бер мәртәбә инанырга мөмкин. Спектакль сәхнәдә озак яши алмады. «Югалган көн»дә кешегә һәм табигатькә сак мөнәсәбәт хаҗәтлеге кебек җитди проблема куелган. Әмма анда вакыйгаларны беркадәр реаль җирлектән аера торган сыйфатлар бар. Алар автор идеясен кабул итүне кыенлаштыра. Очраклы самолетта ике урынны бүлешү әхлакый-этик якны уйлап кына хәл итelә, ә бу исә иҗтимагый бәйләнешләрне дөрес күзалларга зыян китерә. Үз әсәренә иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләр бергә килеп төенләнгән хәлләрне, вакыйгаларны нигез иткәндә автор аеруча төгәл булырга тиеш. Бу җәһәттән А. Гыйләҗев әсәрләрендә әле тәнкыйтькә мохтаҗ яклар бар. «Я кайтырбыз, я кайтмабыз» пьесасы да образлар системасы белән бик үк уңышлы түгел. Хәтта аның исемендә үк ниндидер котылгысызлык, өметсезлек сизелә. «Китмәгез, тургайлар» әсәрендә проблема абстракт гуманизм рухында хәл ителә. Бу тулаем алганда кызыклы һәм тормышчан драманың дәрәҗәсен шулай ук төшерә.

Автор фикеренең аныксызлыгы Әхәт Гаффарның беренче пьесасы «Иртәгә улың булам»га хас иде. Төп конфликтның тиешенчә уйланып җиткерелмәве, колхоз председателе Әмирхан Тимергалиннның улы Әсфәндияргә мөнәсәбәте логик яктан акланмау нәкъ менә шуңа китерә. Дөрес, драма шома — ата белән улның татулануы белән бетә, әмма тамашачылар өчен бәхәсләшүчеләрнең кайсы хаклы булуы барыбер караңгы кала.

Ә. Гаффар — драматурглар сафын тулыландырган актив һәм кызыклы яшь авторларның берсе. Аның сугыштан соңгы авылны чагылдырган «Язлар моңы» драмасы шушы темага багышланган иң яхшы сәхнә әсәрләренең берсе. Шактый оригиналь конфликты, үзенчәлекле вакыйгалары һәм, бигрәк тә тормышчан характерлары сугыш утын кичкән, әмма иң яхшы рухи сыйфатларын җуймаган кешеләребезнең әхлакый пакьлеген, бөеклеген чагылдыра. Проблеманың буыннан-буынга күчеп киңү яссылыгында уңышлы чишелүе аеруча күңелле.

Ә. Гаффар «Җиләк вакыты бер генә», «Соңгы ләкләк» дигән игътибарга лаеклы тагын ике пьеса авторы. Ул шушы әсәрләрендә үк образлы-шигъри фикерләү, символика тарафдары икәнлеген күрсәтте. Аның каһарманнары образлы гыйбарәләрне, канатлы сүзләрне, оригиналь чагыштыру һәм метафораларны бик еш куллана. Сәләтле авторга шигърияттле театр өлкәсендәге эзләнүләрен дәвам итүен, әмма шул ук вакытта тел гадилегенә генә түгел, метафора, символ, сәхнә образлары ачыклыгына да иң җитди игътибар бирүен телисе килә.

Хәзерге драматургиябезнең шигърияттле театр булдырырга омтылуын И. Юзеев, Ю. Әминев, Ә. Баяннар иҗатыннан башка күзаллау мөмкин түгел.

И. Юзеев драматургиясенең үзенчәлекләре һаман җетерәк күренә, аның театрга шигърияттән килүе һаман ачыграк сизелә бара. Бөтенсоюз күләмендә танылган «Сандугачлар килгән безгә» драмасыннан соң ул ике съезд арасында «Кыр казлары артыннан», «Командировка» пьесаларын иҗат итте. Республика Дәүләт драма һәм комедия театры, аның режиссеры Равил Тумашев белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, автор сәхнә сәнгате серләренә һаман тирәнрәк үтеп керә бара. Оригиналь сюжет бормаларын таба, әсәрләренең теле сөйләм бизәкләре белән бай. Аның каһарманнары тормышка якынайганнан-якыная, эчке дөньясы бай кешеләргә хас булганча, олы кичерешләр белән яшиләр.

Төп идея белән тыгыз бәйләнеп сюжет үсешен билгели һәм әсәрнең буеннанбуена дәвам итә торган шигъри детальләрнең вакыйгалар агышына эчке мәгънә бирүе, чынбарлык закончалыкларын образлырак ачарга булышуы мәгълүм. «Кыр казлары артыннан» драмасында И. Юзеевның шундый детальне археологик битлек образында табарга омтылуы мактауга лаек. Пьесаның үзәк персонажы Мәлик Бикташевның ата-бабаларыбыз материаль культура мирасына мөнәсәбәте

аның рухи-әхлакый йөзен билгели. Бу кешенең барысын да үзенеке итәргә, һәммә нәрсәне, тарихи үткәненә, үсеш перспективасына игътибар бирмәстән, үзенчә генә бәяләргә омтылуы ахыр чиктә мещан идеологиясенең һәлакәткә очравына китерә. «Сугышчан мещанлык» фәлсәфәсенең череклеге буыннан-буынга күчү планында ышандырырлык итеп ачыла. И. Юзеев пьесаларының шигърияткә эчтәлеге шулай ук авторның хезмәт кешесенә ихтирамлы мөнәсәбәте белән дә билгеләнә, ул ихтирамны һәр образ, персонажларның һәр репликасында тоярга мөмкин.

Үз геройларына мөнәсәбәте белән Ю. Әминев драматургиясе дә шигърияткә театрга якын. Бу автор чынбарлык законлылыкларын барыннан да элек кешене кеше итә торган табигать кануннары, адәм баласының рухи матурлыгы аша ачарга омтыла. Шул ягы белән ул драматургиябездә М. Фәйзине хәтерләтә. Тик М. Фәйзи геройлары антогонистик җәмгыятьтә хәрәкәт иткәнлектән, кешедәге гүзәллек романтик шартларда ачылырга тиеш була. Ю. Әминев каһарманнарының кешелек сыйфатлары совет чынбарлыгы иҗтимагый шартларын чагылдыра һәм алар матур сыйфатларны үстерер өчен уңай шартларга ия. Бу каһарманнар завод цехында хәрәкәт итәме («Кан кардәшләре»), сәүдә өлкәсендә («Сафура бураннары») яки нефть чыгарудамы («Сөймим дисәң дә»...), алар беренче чиратта социалистик җәмгыятьнең актив членлы булараk сурәтләнә һәм шулай истә кала. Хәтта тискәре персонажларда да уңай сыйфатлар югалып бетми. Ю. Әминовның нефтьчеләр темасына тугрылыклы автор икәнлеген дә искәртәсе килә, аның «Сөймим дисәң дә...» әсәре шул тармакны яктырткан иң уңышлы пьесаларның берсе. Драматург иҗаты хәзер чәчәк ату чорына керде, әдәбият тикшеренүчеләре өчен ул бай материал бирә.

Тугызынчы съездга без кадрлар әзерләүдә җитди уңышлар белән килдек. Югарыда телгә алынган Ә. Гаффардан тыш Ю. Сафиуллин, Ризван Хәмит тә үзләрен кызыклы, өметле авторлар итеп таныттылар. Сафиуллинның «Әллә өйләнергә инде?» әсәрен драма һәм комедия театры уңышлы сәхнәләштерде. Автор күптән түгел «Ни булган бу ирләргә?» исемле яңа пьесасын төгәлләде. Р. Хәмитнең «Синең урыныңа кайттым» драмасы академия театрында куелды. Әлмәт театры игълааннарында да яңа исем пәйда булды: Ф. Садриев «Их сез, егетләр» комедиясе һәм «Җир белән күк арасында» драмасы белән чыгыш ясады. Р. Батулланың «Туйдан соң», Г. Зәйнашеваның «Комиссия килгәч» пьесалары һ. б. әсәрләр буенча да нигездә уңышлы спектакльләр барлыкка килде. Р. Мингалимов, М. Галиевләрнең дә беренче пьесаларын тәмамлаулары мәгълүм. Соңгы елларда, бигрәк тә КПСС ҮКның «Иҗат яшьләре белән эшләү» карары һәм аны иҗат союзлары белән берлектә партиябез өлкә комитеты тормышка ашырган конкрет чаралар нәтиҗәсендә яшь язучылар, шул исәптән, яшь драматурглар белән эшләү дә бермә-бер җанланды. Аның матур нәтиҗәләре күз алдында.

Иҗатның башка тармакларындагы кебек, драматургиядә дә гел уңышлы әсәрләр генә барлыкка килеп тормый. Монда да кимчелекләр, югалтулар бар. Аларның кайберләре югарыда санап үтелде. Тематик яктан да җитешсезлекләр хәтсез. Мисалга, тарихи-революцион, революционгероик драмалар өлкәсендә хәлебез мөшкел. Т. Миңнуллинның «Канкай углы Бәхтияр» пьесасыннан тыш без бу темага багышланган бер генә әсәр дә атый алмыйбыз. Совет Татарстанының алтмыш еллыгын халкыбызның героик үткәненә, бөек юлбашчыбыз Ленин тарафыннан нигез салынган республикабызның данлы тарихына багышланган идея-художество ягыннан кереңекле пьесалар белән каршылау — драматургларыбызның намус эше.

Без бүген милли театр сәнгатебезнең үсешенә булыша, тамашачыларны яңа фикерләр белән баета, аларны әле татылмаган яңа кичерешләр белән сугара торган дистәләрчә сәхнә әсәрләре барлыкка килүен шатлык белән билгеләп үтәбез. Билгеле, алар әле бөек замандашларыбызны, бүгенге героик тормышыбызны җитәрлек дәрәҗәдә тулы чагылдыра алмый. Әмма уңышларыбыз яңа казанышларга, колачлы сәнгатьчә ачышларга инде ерак калмагандыр дип өметләнергә нигез бирә.

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ИКЕ СЪЕЗД АРАСЫНДА ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬНЕҢ ҮСЕШЕ

Әдәби тәнкыйтебез КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы гаять әһәмиятле карары йогынтысында үсте. Бу карар әдәбият белеменең бер тармагы буларак әдәби тәнкыйть торышына җәмәгатьчелекнең игътибарын да җәлеп итте, Чөнки карарда тәнкыйтьнең әдәбият фронтындагы күп тармакларны әйдәп баручы сугышчан жанр икәнлегенә басым ясалды.

Тәнкыйтьчеләребез үзләре дә хәзерге заман әдәбияты һәм тәнкыйтьнең актуаль мәсьәләләренә элеккегә караганда күбрәк игътибар бирә башладылар. Союз каршындагы тәнкыйтьчеләр секциясенең утырышларында теоретик, проблемалы мәсьәләләр тикшерү гадәткә керде. Соңгы елларда, мәсәлән, анда «Хәзерге татар романының художество үзенчәлекләре», «Хәзерге татар поэтикасы», «Бүгенге татар прозасында стиль төрлелекләре», «Рецензияләрне ничек язарга?», «Революция һәм язмышлар» һ. б. темаларга сөйләшүләр, бәхәсләр булып узды. 1977 елда тәнкыйтьчеләр прозаиклар белән бергәләп «Бүгенге татар прозасына нәрсә җитми?» дигән темага дискуссия оештырдылар. «Бүгенге татар прозасында эшче образы» дигән темага бөтенроссия тәнкыйтьчеләренең семинары Казанда уздырылу да безнең тәнкыйтьнең үскәнлеген күрсәтә иде. Әдәбият теориясе өлкәсендә дә эш җанланып китте. Шуңа сизелерлек өлеш керткән хезмәтләр дөньяга чыкты. Болар арасыннан, беренче чиратта, «Метод, жанр, стиль» исемле коллектив җыентыкны, И. Нигъмәтуллинаның «Художество әсәрләрен комплекслы өйрәнү методологиясе» исемле хезмәтен һәм И. Нуруллинның «Әдәбият теориясе (беренче кисәк)» хезмәтләрен күрсәтеп үтәргә кирәк.

Ә иң зур уңышлардан берсе — безнең хезмәтләрнең Мәскәү нәшриятларында басылып чыгуы. «Современник» нәшриятында Флүн Мусинның «Тормыш координатлары буйлап» дигән китабы бу өлкәдә беренче карлыгач булды. Дөрес, егерменче елларда татар әдәби тәнкыйтенә караган хезмәтләр (Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, Г. Нигъмәти китаплары) Мәскәүдә басылган иде. Димәк, традицияләр бар. Әле күптән түгел генә Мәскәүдә Р. Мостафинның шагыйрь Сибгат Хәким иҗатына багышланган монографиясе басылу да шатлыклы күренеш. Сибгат Хәкимне, Хәсән Туфанны бөтенсоюз укучысына күрсәтергә — Рәсүл Гамзатов, Кайсын Кулиев, Мостай Кәрим, Давыт Күгелтиневләрне күрсәткән кебек сурәтләргә, укучыга җиткерергә күптән вакыт иде.

Соңгы елларда әдәби тәнкыйть өлкәсендә иң актив эшләгән галимнәрдән берсе, һичшиксез, Тәлгать Галиуллин. Аның «Социалистик реализм юлыннан» — исемле китабы поэзиядәге аеруча актуаль мәсьәләләрне күтәргән хезмәт. Т. Галиуллинның тикшеренүләренә татар поэзиясе уңышларын бөтен совет әдәбияты ирешкән югарылыклар белән системалы рәвештә чагыштырып бару хас. Автор татар шагыйрьләренең әсәрләрен тикшергәндә бүгенге заманның иң эре белгечләре Л. Тимофеев, М. Храпченко, Г. Ломидзе, А. Иезуитов, А. Квятковский кебек галимнәрнең хезмәтләренә таянып фикер йөртә.

Татар әдәби хәрәкәтендәге теоретик юнәлешнең көчәюен А. Әхмәдуллинның «Ничек сурәтләргә сине, замандаш?» исемле китабы да ачык дәлилли. Бу китапта бүгенге драматургия тудырган сәхнә әсәрләре анализланды. Кем ул замандаш? Төп сыйфатлары нинди? Безнең көн геройлары арасында нинди конфликтлар туа ала һәм драматургия бу конфликтны ничек чишә — тәнкыйтьче әнә шулар турында уйлана.

Фактлар белән эш итә белү, документальлек, белешмәләргә таяну әдәбият фәненең дәрәҗәсен билгели. Алтмышынчы еллардан бирле безнең әдәбият фәнендә байтак белешмәлекләр басылып чыкты. Моны нигездә университет каршындагы Лобачевский исемендәге гыйльми китапханә хезмәткәрләре башкарып килде. Инде бу эшкә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты хезмәткәрләре дә тотынды. 1917 елдан алып 1973 елга кадәр булган әдәби хрониканы туплаган китап — «Әдәбият баскычлары» әнә шундый кыйммәтле белешмәлекләрдән берсе. Бу — әдәбият тарихының нигезен, әдәби тормыш барышының төп документларын туплаган хезмәт. Дөрес, әлегә ул тулылыкка дәгъва итә алмый. Анда әдәби процессның бөтен вакыйгалары да күрсәтелмәгән һәм болар алдагы басмада тулырак чагылыш табарга тиеш. Татарстан китап нәшрияты Ф. Әгъзәмовның «Яшәү көче» исемле хезмәтен бастырып чыгарды. Ул социалистик реализм әдәбиятындагы партиялелек, интернационализм принципларын, социалистик җәмгыятьтә иҗат ирекe турында фикер йөртә.

Отчет чоры бүгенге әдәби проблемаларга караган газета-журнал мәкаләләре җыентыкларының дөнья күрүе белән характерлы булды. Монда, беренче чиратта, әдәби тәнкыйтьне баеткан Н. Юзиев, Ф. Миңнуллин, Р. Мостафин, Г. Халит, Х. Хәйри, И. Ахунҗанов, Х. Сарьян хезмәтләрен атап үтәргә кирәк. Нәшрият яшь тәнкыйтьчеләргә дә игътибарын арттырды. Мансур Вәлиевнең беренче китабы «Яшьләр мәйданга чыга» дип исемләнгән. Бу автор әдәби тәнкыйть өлкәсенә студент елларында ук килде. Аның әдәбият турындагы фикерләүләренә тирән эрудициялелек, бәхәскә тартым сораулы мәкаләләр, проблемалылык хас. Ул авторлар белән полемика алып барырга, аларның яңа әсәрләрендә әйтеп бетермәгән фикерләрен ачыкларга тырыша.

Саналган хезмәтләрнең барысына да бәя биреп чыгу бу урында мөмкин булмас, әлбәттә. Шулай да аларда күзгә ташланган кайбер кимчелекләр һәм югалтуларны бер ноктага туплап әйтеп үтәргә кирәк. КПСС Үзәк Комитетының мәгълүм карарында тәнкыйть хезмәтләрендә, рецензияләрдә бер-береңне мактау рухы, мәкаләләрнең өстән-өстән генә язылуы, тәнкыйтьчеләрнең сәнгать күренешләрен тормыш белән бәйләп караулары җитмәве турында әйтелгән иде. Кызганычка каршы, бу кимчелекләр безнең тәнкыйть хезмәтләрендә үзләрен сиздереп алалар әле. Бу өлкәдә китап нәшри-

яты хезмәткәрләре дә, тәнкыйтьче авторлар үзләре дә уйланырга тиешләр.

Хәзерге әдәбият фәненең үзенчәлекләреннән берсе — поэтика һәм стилистика мәсьәләләре белән кызыксынуның артуы. Бу өлкәдә зур совет әдәбиятында соңгы елларда байтак тирән һәм күләмле хезмәтләр күренде. Безнең әдәбият белгечләренең, тәнкыйтьчеләрнең бу юнәлештә шактый эшлисеЛәре бар әле. Бүгенге әдәбиятта хезмәт кешесе темасы, авыл темасы, сугыш темасы һәм рухи бушлыкка һөҗүм тенденцияләре турында аерым проблемалы тикшеренүләрнең булмавы безне бик нык уйландырырга тиеш.

Әдәбият, әдәби тәнкыйть тарихы буенча безнең галимнәребез күп кырлы, нәтиҗәле эш башкардылар. Бу уңайдан Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты хезмәткәрләренең мактаулы эшен беренче чиратта телгә алырга кирәк. Алар инициативасы белән ике съезд арасында Ф. Бурнаш, К. Нәҗмиләрнең 20—40 нчы еллардагы тәнкыйть мирасы тупланып аерым китаплар итеп чыгарылды. Әдәбият сөючеләр, галимнәр мәрхүм Гази Кашшафның татар сәнгатенә караган мәкаләләр җыентыгын («Күңел көзгесе») да яратып каршыладылар. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә Гази Кашшаф һәр очракта да намуслы, саф күңелле, ярдәмчел булды. Шул сыйфатлар аның мәкаләләрен һәр вакыт эмоциональ ышандыргыч итәләр иде. Бүгенге урта буын язучылары, тәнкыйтьчеләре мәрхүмне һәр вакыт үзләренең остазлары дип йөртәләр иде һәм бу китапның дөньяга чыгуы шәкертләрнең остазларына ихтирам билгесе, игътибар билгесе буларак бәяләнергә тиешле.

Ике съезд арасында Октябрь революциясенә кадәрге әдәби мирасны барлау, бастырып чыгару буенча да байтак эш башкарылды. Энгель Нигъмәтуллинның рус телендә чыккан монографиясе («Раздвигая века и границы») татар әдәбиятын бөтенләй без күреп-ишетеп белмәгән чыганаклар белән бәйли. Автор XX йөз башы татар әдәби-эстетик фикерен Европа әдәби-эстетик фикере белән тоташтыручы җепләрне эзли, Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирханнарның эстетик карашларына Руссо, Гете, Шекспирларның эстетикасы йогынтысын өйрәнә.

Татар әдәбияты тарихына караган хезмәтләрдән соңгы елларда чыккан «Татар әдипләре» (М. Гайнуллин), «Тукай» (И. Нуруллин), «Галимҗан Ибраһимов» (Яңа басма, М. Хәсәнов), «Тукай лирикасы» (Н. Лаисов), «Шигърият гомере» (Х. Госман) китапларын атап үтәргә кирәк. Озак еллар буе өйрәнеп, соңгы вакытта гына дөньяга чыккан «Сугышчан поэзия» (З. Мәҗитов) исемле хезмәт тә поэзиябез тарихының куәтле бер чорын — Бөек Ватан сугышы чорын яктыртуы белән әһәмиятле.

Татар совет театры тарихын өйрәнү буенча да конкрет эш башкарылды. Г. Ибраһимов исемендәге институт хезмәткәрләре чыгарган «Татар совет театры» исемле җыентыкта Г. Камал исемендәге театрның, Мәскәү, Оренбург, Астраханьдагы татар театрларының, колхоз-совхоз театрларының үткән юллары, театр буларак формалашулары яктыртыла. Әмма китапка тупланган бүлекләрнең гыйльми дәрәҗәсе бертигез түгел. Кызганычка каршы, төгәлсезлекләр дә киткән. Гомумән, бердәм проблема булмавы, бердәм концепциянең җитмәве бу хезмәтнең дәрәҗәсен шактый киметә.

Әдәби мирасны үзләштерү, өйрәнү буенча, шулай итеп, күзгә күренерлек эшләр башкарылган. Тәнкыйтьчеләр, гыйльми учреждениеләр, союз идарәсе һәм китап нәшрияты бу юнәлештәге эшчәнлекләрен киләчәктә дә шулай актив алып барырлар дип ышанырга кирәк. Киләчәктә, ихтимал, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Җ. Вәлиди, Г. Кәрам кебек тәнкыйтьчеләрнең мирасын бастырып чыгару турында уйларга кирәктер. Ниһаять, Г. Нигъмәти хезмәтләренең ике томлыгын чыгару юнәлешендә эш башларга күптән вакыт. Әдәбият белгечләрен «Татар поэзиясе антологиясе» дә күптән инде канәгатьләндерми.

1956—60 нчы елларда әдәбият галимнәре (аеруча Мөхәммәт ага Гайнуллин) үткәндәге әдәби мирасны барлау, бастыру буенча зур һәм мактаулы эш башкарганнар иде. Алар чыгарган китаплар күптән инде китап киштәләрендә юк. Ул еллардан бирле өр-яңа бер буын яшьләр үсеп җитте. Безгә әдәби мирас турында бу яшьләрнең кулларына тоттырырлык яңа басмаларны кабат эшләргә вакыт җитте. Әйтик, З. Бигиев, Кандалый, Ш. Мөхәммәдев, З. Һади, З. Бәшири, Идрис Богданов, С. Сүнчәләй, З. Ярмәки, М. Укмасый, Н. Думави, С. Рәмиев, Дәрдмәнд, С. Җәләл, С. Рахманколый, Г. Рәхим, Б. Сирин, Д. Гобәйди кебек әдипләрнең әсәрләрен кабат чыгару турында уйлый башласак һич тә иртә булмас.

Әдәби тәнкыйтьне алга таба үстерүдә республикабызда чыга торган журналлар һәм газеталар зур роль уйный. Әдәби тәнкыйтькә «Социалистик Татарстан» газетасының файдалы өлешен беркем дә инкяр итә алмас. «Татарстан коммунисты» журналында шулай ук татар әдәбиятының мөһим проблемаларына кагылышлы күләмле тәнкыйть мәкаләләре басылды. Әдәби тәнкыйтьне үстерүдә, табигый ки, «беренче скрипканы» Язучылар союзының органы «Казан утлары» журналы уйный. Әнә шуңа күрә, КПСС Үзәк Комитетының мәгълүм карары чыкканнан соң озак та үтмичә, Язучылар союзы идарәсе һәм партия оешмасы әдәбият-сәнгать тәнкыйтен үстерү буенча эш планы кабул иткәндә журнал эшчәнлегенә кагылышлы бик күп мөһим чаралар билгеләделәр. Бу планны тормышка ашыруның беренче нәтиҗәләре озак көттермәде: журналда тәнкыйть мәкаләләренең саны артты. Мондый үсеш әле дә дәвам итә. Әлбәт-



*Шагыйрь, драматург Илдар Юзеев (сулда) Әмирхан Еникидән проза язарга рөхсәт сорый...*

тә, әдәбият турында сөйләгәндә санкүләм белән сөйләү ничектер кабул ителмәгән. Хикмәт санда түгел. Әмма соңгы елларда чыккан әдәби тәнкыйть мәкаләләренең сыйфаты турында да ышаныч белән шуны әйтергә була: аларның эстетик көче, кыюлыгы, үткенлеге һәм идея юнәлеше элеккеге еллардагы мәкаләләрдән күп өстен. Хәзерге тәнкыйть мәкаләләрендә догматик фикер йөртү, тупаслык, субъектив бәя, күсәк күтәрү кебек ямьсез күренешләр бетте диярлек. Бүгенге көн тәнкыйть мәкаләләре өчен әдәби әсәрне төгәл эстетик критерийларга таянып анализлау характерлы. Мондый мәкаләләр, әлбәттә, тәнкыйтьнең һәм бу мәкалә басылган матбугат органының абруен күтәрәләр — «Казан утлары» журналында соңгы елларда басылган аеруча уңышлы, тирән фикер, конкрет проблемалы мәкаләләр (Ф. Мусин, Ф. Миңнуллин, Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев, Ш. Әхмәдуллин, Т. Галиуллин мәкаләләре) моның ачык мисалы.

ФТР чорында журнал татар әдәбиятында бүгенге кеше образын тасвирлау мәсьәләсен ешрак күтәрә башлады. Бу мәсьәләдә Ф. Хатипов, Р. Бикмөхәммәтов, Д. Вәлиевләр аеруча кызыклы мәкаләләр белән чыктылар.

Соңгы елларда тәнкыйтьнең үз проблемалары турында да байтак мәкалә дөнья күрде. Тәнкыйтьчеләр бездә әлегә стиль, поэтика мәсьәләләрен өйрәнүнең бик нык артта калганлыгын күтәреп чыктылар. Тәнкыйть хезмәтләренә кагылышлы рецензияләрдә дә кыюлык арта төште. Ф. Әгъзәмов, Х. Җарьян, Г. Халит тарафыннан чыгарылган әдәби тәнкыйть хезмәтләренең, Ф. Бурнаш мирасы буенча төзелгән тәнкыйть мәкаләләре җыентыгының кимчелекләре тәнкыйтьтә урынлы билгеләнеп үтелде.

Әдәби тәнкыйтьтә, шулай итеп, эшлекле тон, эшлекле атмосфера урнашты. Бу эшлекле тон елдан-ел киңрәк колач җәя бара. Әмма эшлеклелеккә омтылу соңгы вакытта тәнкыйть хезмәтендә эмоциональлеккә зарар китерә башлады. Кайбер мәкаләләрнең, мәсәлән, күләме артык зур була — ә күләм арту белән бу мәкаләләрнең фикри яктан тирәнәюе һич тә сизелми.

Безнең әдәби тәнкыйтьтә бик матур традиция — татар әдәбияты классикларының юбилейларын ул язучыларның әдәби-эстетик мирасларын тагын да киңрәк планда өйрәнү, тирәнәйтү юнәлешендә билгеләп үтү традициясе бар. Ике съезд

арасында Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Ибраһимов, М. Җәлилләрнең зур юбилейлары билгеләнеп үтелде. Бу уңайдан әдәби тәнкыйтьтә әдипләрнең биографиясен, иҗтимагый эшчәнлекләрен, идея-эстетик байлыкларын тагы да тулырак ачкан зур күләмле чыгышлар дөнья күрде. Мондыйлардан, беренче чиратта, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиевнең Г. Ибраһимов турындагы күләмле мәкаләсен, галимнәр М. Хәсәнов, Я. Абдуллин, Г. Халит, Н. Юзиев, А. Әхмәдуллин, Р. Ганиева, И. Абдуллин, Ү. Гыймадиев, Ш. Хамматов, Р. Мөхәммәдиевләрнең аерым тикшеренүләрен атап үтәргә кирәк.

Әдәби тәнкыйтьтә җәлилчеләр көрәшен, аларның әдәби мирасын өйрәнү, тикшерү әле дә дәвам итә. Бу юнәлештә эш, әдәбият эчендәге генә эш булып калмыйча, ахыр исәптә идеологик көрәшнең бер тармагына әйләнде. Журналда В. Воздвиженский һәм М. Маннуроваларның җәлилчеләр хәрәкәтен француз Каршылык хәрәкәте белән бәйли торган әдәби-эстетик категорияләр уртаклыгы турындагы кызыклы мәкаләсе чыкты. Дөрес, бу мәкаләдә әлегә дәлилләр җитеп бетми, әмма шунысы әһәмиятле: монда җәлилчеләр хәрәкәтен бөтеневрона антифашистик хәрәкәтенең бер тармагы икәнлеген исбатларга тырышу омтылышы бар. Мондый мәкаләләрнең әһәмияте тагын шуның белән дә арта: Көнбатышта, җәлилчеләр хәрәкәтенең нигезендә бары тик милли хисләр генә яткан, дигән уйдырма нәрсәләр басыла. «Казан утлары» журналы Көнбатыштагы «идеологлар»ның мондый фальсификацияләренә вакытында тиешле отпор биреп бара. Мәсәлән, соңгы елларда гына журналда М. Абдуллин, А. Яхиннарның көнбатыштагы сатлык җаннарны фаш иткән үткен мәкаләләре басылды. Журнал киләчәктә дә бу традицияне дәвам итәр дип ышанырга кирәк.

Безнең әдәби тәнкыйтьнең зур өлешен яңа чыккан китапларга рецензияләр алып тора. Язучылар союзында бер вакытлар нәшрияттә басылып чыккан барлык китапларны да матбугатта рецензияләргә кирәк дигән фикер йөргән иде. Бу фикер, безгә калса, нигездә дөрес. Кызганычка каршы, безнең тәнкыйть әлегә барлык китапларны да рецензияләп бара алмый. Ихтимал, башкала газета-журналлары үрнәгенчә, яңа чыккан берничә әсәргә әледән-әле обзор мәкаләләр биреп бару максатка ярашлы булыр. Аерым рецензияләүгә, ихтимал, әдәбиятта күренеш (явление) булырдай әсәрләрне алу кирәктер. Белинский, Добролюбовлар, бездә — Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Җ. Вәлидиләр шулайрак язганнар бит. Ә язучылар саны ул заманда да аз булмаган.

Әдәби тәнкыйть, нәкъ әдәбиятның үзе кебек үк, яңалыкны, яңа формаларны ярата. Соңгы елларда бездә моңа таба кызыклы гына омтылышлар булды. Мәсәлән, хәзер безнең тәнкыйтьтә язучы белән тәнкыйтьче диалогы, ике тәнкыйтьче яки ике язучы әңгәмәләре гадәти бер нормага кереп бара. Кайвакытта әдәби әсәр авторы белән очрашмаган көе үк тәнкыйтьче аның белән бәхәскә керә һәм үз сорауларына язучыдан җаваплар алу формасын тудыра. Болардан тыш әдәби тәнкыйтькә бик күп укучылар коллективы тартыла. «Казан утлары» журналы, мәсәлән, әледән-әле яңа әсәр турында укучы фикерен урнаштырып бара. Бу фикерләр язучыга укучы ихтыяҗларын, укучы таләпләрен белеп барырга ярдәм итә. Ләкин бу рубриканы алып барганда икенче читкә сикерү мөмкинлеге үзен сиздерә: барлык укучының да фикере тиешле әдәби-эстетик критерий булай алмый. Шуңа күрә журнал теге яки бу графоманның примитив фикереннән югарырак торырга, укучыларда әдәби зәвык тәрбияләүне беренче планга куярга тиеш.

Очраклы хәлдерме, әмма әдәби тәнкыйтебездә бер үзенчәлек бар: бездә күбрәк поэзия турында сүз алып баралар. Болай санап карасаң, тәнкыйтьчеләр арасында поэзия буенча белгечләр икеөч кенә кебек. Ләкин поэзия тәнкыйтенә бик күп кеше катнаша, күбрәк — шагыйрьләр үзләре. Никадәр күп кеше катнашса — шул кадәр яңа фикерме дип уйлыйсы килә. Тәнкыйтьче һәм шагыйрь, шагыйрь һәм шагыйрь, яшь шагыйрь белән өлкән шагыйрь сөйләшүләре. Барысы да эрудицияле — әле Виктор Хара, әле Есенин, әле Блокны искә төшерәләр. Барысы да әйтәләр: бүгенге поэзия өчен психологик нечкәлек хас диләр. Әйтерсең С. Рәмиев, Дәрдмәнд, Тукай заманы поэзиясе өчен бу сыйфат хас булмаган. Яшь шагыйрь өлкән остазы турында яза. Я, әйтегез әле, берәр тәнкыйди фикер әйтә аламы ул аның адресына? Аңа нинди мөмкинлек кенә кала соң? Мәдхия җырларга. Әйдәгез, «тәнкыйтьнең» мондый формасын мәҗлестәге тамадага тапшырыйк. Поэзия турында язучы яшьләр «обойма» ысулын бик яраталар. Алар иҗади аһәңнәрнең, һәр шагыйрьнең үз авазын аерып торырга бик омтылмыйлар. Традицияләр турында сүз барганда алар Тукай, Такташ, Җәлил, Ф. Кәрим дип тезеп китәләр һәм Ф. Бурнаш, Ә. Фәйзи кебекләрне искә алып тормыйлар. Бүгенге көн шагыйрьләре турында сүз барганда Хәсән Туфан, Сибгат Хәким дип китәләр. Әмма алар иҗатының үзенчәлекләрен күрсәтмиләр. Өченче обойма — Ш. Галиев, И. Юзеев, Г. Афзал. Дүртенче төркем кайвакыт Роб. Әхмәтҗанов, ә еширак Р. Фәйзуллин исеменнән башлана да аннары һәр вакыт диярлек Г. Рәхим, Р. Гатауллин, М. Әгъләмов, Зөлфәт, Р. Миңгалимов, Р. Харисларны эченә алган коры санау китә. Хәзер исә яңа рәт башланды: Р. Миңнуллин, Ф. Сафин... Яшьләргә мондый обойма стиленнән качарга кирәк. Бүгенге күп кырлы рухи ихтыяҗ дөньясында һәр шагыйрьнең үз урынын билгеләргә иде.

Кайбер тәнкыйть мәкаләләре терминнарның гадәттән тыш күплеге белән укучыны куркыта. Әдәби тәнкыйтьтә андый кроссвордлардан бер файда да юк.

Мәшһүр тәнкыйтьче В. Г. Белинскийны гына искә төшерик: ул иң гади рус сүзләре белән үз заманы һәм аңарга кадәрге рус әдәбиятын аркылыга-буйга сөреп чыга һәм, терминнар белән мавыкмыйча, әдәби әсәрне тормышка нисбәтле рәвештә тикшерүгә төп игътибарын юнәлтә.

Бу уңайдан ничек итеп А. Безыменскийның егерменче елларда язган шигырен хәтерләмисең:

**Довольно неба**
**и мудрости вещей,**
**давайте простых гвоздей!**

Әдәби тәнкыйтьнең торышы турында сөйләшкәндә безнең тәнкыйть публицистикага таба авышты дигән фикерне еш кына ишетергә туры килә. Безнең әдәби тәнкыйтебездә, традиция буенча, язучылар үзләре бик актив катнашалар. Әмма язучының мондый чыгышы зур күпчелегендә публицистик характерда була. Кызганычка каршы, мондый чыгышларны без әдәби тәнкыйть продукциясе буларак күрсәтәбез. Ләкин публицистик тон профессионал тәнкыйтьчеләрнең хезмәтләрен дә биләп алды. Тарихка мөрәҗәгать итик: Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Н. Нигъмәти кебек тәнкыйтьчеләрдә публицистик рух бар идеме? Бар гына түгел, көчле иде. Әмма публицистик рух аларда ялкынлы эмоциональлек һәм гыйльми-теоретик тирән анализга нигезләнгән була иде.

Алдарак без әдәби тәнкыйтьтә әдәбиятның бүгенге проблемаларына кагылган зур хезмәтләрнең җитмәвен әйткән идек. Ул мәсьәләне киңәйтебрәк фикер йөрткәндә нәрсәләр җитмәве ачыклана төшә: безнең чорда бөтен бер буынны тәрбияләрлек, үрнәк булырлык әдәби герой бармы? Тәнкыйть шул юнәлештә нәрсәләр эшли, нинди эш алып бара? Безнең күз алдында яңа кеше формалаша — без аны КамАЗ кебек зур промышленность төбәкләрендә күрәбез — әдәбият шул яңалыкларны тотып аламы, шул үзгәрешләрне сәнгатьчә чагылдырамы? Тәнкыйть бу өлкәдә ниләр әйтте? Эзләнә китсәң, тәнкыйтьнең бурычлары һәм нагрузкасы арткаңнан-арта бара. Зур-зур тикшеренүләр-монографияләр, коллектив җыентыклар кирәклеге ачыклана. Боларны тудыру өчен безнең тәнкыйтьчеләргә нәрсәләр комачаулый соң? Ихтимал, тәнкыйтьчеләрнең, Крылов мәсәлендәгечә, йөкне төрле якка тартуы комачаулыйдыр. Игътибар итик: Язучылар союзы тирәсендә эшләүче тәнкыйтьчеләр — бүгенге әдәбият проблемалары белән шөгыльләнүчеләр — ике-өч кенә кеше — калган тәнкыйтьчеләр Г. Ибраһимов исемендәге гыйльми институтта, университетның татар әдәбияты, Казан һәм Алабуга педагогия институтлары кафедраларына тупланганнар. Һәр кафедраның, һәр секторның үз юнәлеше, үз планы бар. Бу мәсьәләдә координация, әлбәттә, җитеп бетми. Боларның берсе фольклор, икенчесе бүгенге әдәбият, өченчесе борынгы, унтугызынчы, егерменче йөз башы әдәбияты белән шөгыльләнә, җыентыклар, гыйльми язмалар чыгара. Гыйльми язмалар дигәннән, бу мәсьәләдә Казан дәүләт педагогия институты татар әдәбияты кафедрасының активлыгын аерым билгеләп үтәргә кирәк. Анда ел саен диярлек башлыча бүгенге әдәбият мәсьәләләренә кагылышлы мәкаләләр тупланган җыентыклар чыгып килә. Бу эшне хупларга кирәк. Тик шунысы бар: бу язмаларда төгәлсезлекләр, текстологик хаталар, ә кайчакта сай эчтәлекле мәкаләгә гадәттән тыш зур исемнәр куелып чыгарыла.

Безнең әдәби тәнкыйтьтә язучының теле мәсьәләсенә игътибар кирәгеннән артык бирелә. Бу мәсьәләгә кагылмаган бер генә рецензия юктыр. Нигә шулай? Безнеңчә, моның сәбәбе шунда: язучылар отрядына язучының төп коралы булган телне тиешле дәрәҗәдә белеп бетермәгән кешеләр килә. Гаҗәп, әмма факт. Югарыда китерелгән мисаллардан нинди нәтиҗә ясап була соң? Әдәби тәнкыйть, әгәр үзенең генераль линиясеннән аз гына читкә тайпылдымы, шундук вак-төяк белән, башка белгечләр шөгыльләнергә тиешле мәсьәләләр белән мавыга һәм төп максатын оныта.

Безнең тәнкыйтьне поэтика мәсьәләләре дә борчымый кала алмый. Тәнкыйтьне без еш кына яңа әсәрнең эчтәлеген шәрехләп чыгу планында язылган рецензия формасында аңлыйбыз. Әмма эш башкачарак тора бит. Тәнкыйтьнең поэтика мәсьәләләренә күз йомуы әдәбиятның күп төрле компонентларына тискәре йогынты ясый. Безнең әдәбият фәнендә, тәнкыйтьтә, мәсәлән, әдәби әсәрләрнең исемнәре турында беркемнең дә сүз алып барганы юк. Әнә шуңа күрә безнең кайбер язучылар әдәби әсәрләренә исем кушканда ук җиңел юл белән китәләр. Роман, повесть, хикәя, драма, комедияләргә исем ансат кына куела: халык җырыннан бер юл, мәкаль-әйтемнән бер кисәк аласың да — вәссәлам! — исем әзер. Геройларның да исемнәре еш кына берниндн поэтик мәгънәгә ия булмый, геройның эчке дөньясына туры килми. Боларның барысын да әдәби тәнкыйть искә төшереп барырга, юл күрсәтергә тиеш.

Тәнкыйтькә тагын нинди дә булса дәгъва белдерергә кирәк икән, сүз уңаеннан шуларны да искәртеп үтик: тәнкыйтьчеләр, артык тыйнаклыктанмы, үзәк матбугатка чыгарга һич тә омтылмыйлар. Югыйсә, «Литературная газета», «Литературная Россия» газеталарының, башка үзәк әдәби журналларның битләрендә күренерлек, катнашырлык белгечләребез юк түгел. Күрәсең, яңалыкны вакытында тотып алу, тою, ул яңалыкка аваз бирү омтылышы җитеп бетми. Яңа әсәрләргә бәя биргәндә дә кайберәүләр иске аршин белән эш итәләр. Хәлбуки, әдәбият үзе стиль, жанр, тематика, композиция ягыннан сыйфат үзгәрешләрен кичерә. Әдәбияттагы бу яңалыкларны Д. Гранин «бер жанрның икенче жанр территория-

сенә бәреп керүе» дип атады. Бездә хәзер роман-автобиография, повесть-истәлек, повесть-сәяхәтнамә, хикәяләрдән торган роман яки повесть һ. б. төрләр барлыкка килде. Жанрлар «буталуы» төрле буын язучыларына кагылды. Шуңа күрә, тәнкыйтьчеләр аңламас дип шикләнгәндәй, язучылар үз әсәренең исемнәрендә жанрларын ачыклый торган сүз куша башладылар. И. Юзеев, мәсәлән, бер әсәрен «Моңсу комедия», А. Гыйләҗев «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят», Ә. Баянов «Тау ягы повесте» дип, искәртмәле исемнәр белән атадылар. Кызганычка каршы, мондый жанрлар «мутациясен» кабул итәргә, аңларга безнең тәнкыйтьчеләребезнең күбесе әзер түгел. Яңаны сиземләү, заман сулышын язучыдан да алдан тою — тәнкыйтьчедән менә шулар таләп ителә.

Әдәбияттагы әхлак проблемаларын күтәрү, өйрәнү мәсьәләсендә дә тәнкыйть алдында зур бурычлар тора әле. Әгәр инде без, безнең тәнкыйтебез өлгергән, җитлеккән тармак дип әйтәбез икән — аңа нәкъ менә әхлак проблемалары белән шөгыльләнергә вакыт. Әхлак тәрбиясенең әһәмияте турында Л. И. Брежнев КПССның XXV съездында аеруча басым ясап әйткән иде. Әйе, хәзер һәркем өчен ачык: җәмгыятебез коммунизмга таба барган саен кешеләрдәге әхлакый сыйфатларның кыйммәте арта барачак. Бу — бәхәссез. КПСС Үзәк Комитетының 1979 ел май аенда кабул иткән идеология, политик тәрбия эшен тагы да яхшырту турында карары язучылар, тәнкыйтьчеләр алдына нәкъ шундый бурычлар куюы — моның ачык дәлиле.

Шәүкәт Галиев

# БАЛАЛАР — ТОРМЫШ ЧӘЧӘКЛӘРЕ, ҖИМЕШЛӘРЕ НИНДИ БУЛЫР?

**Әй сукты бәйрәм сәгате бәрхет тау башларында.**
**Мәйданга малайлар кереп көрәшә башладылар...**
**Көрәшәләр болыннарда, урманда-аланнарда.**
**Тәгәрәп алмаш өлгерә көрәшче агайларга!**
**Татарстан карап тора сабан туе кызганны.**
**Малайлар күккә менәләр балакларын сызганып.**
**Малайлар атта киләләр, тояклар җирне кага.**
**Көчле малайлар үскәнне хәбәр итеп дөньяга**
**Тояклар җирне кага.**

Сабан туенда көрәшне әүвәл-әүвәлдән малайлар башлап җибәргән. Юк, мәзәк өчен түгел бу, мәйдан тоткан ир-егетләрнең сөлге тапшырасы варисларны сынап каравы. Тормыш мәйданында кеше өчен көрәшкә дә башлап балалар әдәбияты чыга, өлкән жанрлардан шактый алда чыга — тәпи йөрү әлифбасыннан шәхес булу фәлсәфәсенә хәтле өйрәтә, көрәшкә әзерли.

Татар совет балалар әдәбиятын, беренче адымнарыннан ук, чын патриотлар һәм көрәшчеләр тәрбияләргә омтылган Такташлар, Җәлилләр җитәкләгән. Әйтерсең лә дөнья язмышын хәл итәсе көрәшкә кыю һәм тәвәккәл сугышчы әзерли алар! Аркадий Гайдар болай дигән иде: «...ул кешеләр хәйлә өчен генә үзләрен балалар язучысы дип йөрткәннәр. Чынлыкта исә алар кызыл йолдызлы нык, көчле гвардия әзерләгәннәр». Аның сүзләре рас килде. Әдәбиятыбызның комиссарлары Җәлилләр, Алишлар, Кәримнәр үзләре дә, алар әзерләгән «кызыл йолдызлы гвардия»дә гасырның хәлиткеч сынавында — фашизм белән көрәштә иман ныклыгы, антка тугрылык күрсәтте һәм җиңеп чыкты! Р. Мостафинның «Кечкенә Муса турында хикәяләр»е укучыларга әнә шул батырлык чыганакларының кайдан башлануын күрсәтә.

Тормышта һәм әдәбиятта батырлык традициясе дәвам итә. Түбән Кама егете Рифкать Миргазизов хәрби өйрәнүләр вакытында, иптәшләрен саклап калыр өчен, шартлый торган гранатаны гәүдәсе белән каплады... Шәмәрдән мәктәбен тәмамлаган, тепловоз машинисты Рәшит Галимов та йөзләгән кешеләрне коткарып үзе һәлак булды... 1977 һәм 1978 елларда булды бу хәлләр. Газинур Гафиятуллинны, Бари Шәвәлиевне үстергән халыкның уллары тыныч елларда да батырлыкны кабатлыйлар. Батырлык турында язылган китапларыбызны укып үскән укучыларыбыз ич болар, дип горурланып куясың.

Ш. Рәкыйпов үзенең яңа китабын «Геройлар үлмиләр!» дип исемләгән. Ничә еллар инде эзтабар язучы Батырлык фәне дәресләре алып бара — батырларны терелтергә, онытмаска өйрәтә. Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен го-

мерләрен биргән кешеләр турында бөртекләп мәгълүматлар җыя, укучыларга җиткерә тора.

М. Юныс та, кырыс диңгезче буларак, публицистик мәкаләләрендә кыенлыкларны җиңәргә әзер булып, көчле булып үсәргә өнди. Океан-диңгезләр кичеп, әдәбиятыбызның географиясен дә киңәйтеп, Татарстан малайларын кызыктырып йөри ул. Чит илләрдә гыйбрәт алып, туган җир кадерен тойдырып, сагынуын сиздереп йөри. Күбесе диңгезче дә булмас, ә яңа киңлекләргә омтылыш, тынгысызлык гомергә калыр. Чын кеше, илгә тугрылыклы хезмәт итүче булырга өйрәтә язучы.

Буйга гына түгел, уйга да үсә бала. Дөнья белән таныша-таныша, «ник? нәрсә?» дип сорый-сорый үсә. Аның уенында да уй була — олыларга охшарга тырыша, алар эшләгәнне эшлисе килә. Уенчык белән зур тормышны модельләштерә бала. Олылар үзләре дә: архитекторлар — салачак шәһәрне, инженерлар плотинаны макетта төзеп уйнамыймыни? Әле безнең эрага кадәр Аристотель: «Балаларның уеннары ук киләчәктә эшләячәк эшләренә охшарга тиеш»,— дигән бит. Ягъни шәхес булып җитешүнең бер шарты — ул хезмәт. Эш тәмен яшьтән тоеп үсәргә тиеш бала.

Фаил Шәфигуллинның «Бер малай, өч аргамак» повесте — Рәсим исемле малайның сугыштан соңгы елларда өлкәннәр белән иңгә-иң торып колхозда эшләве турында. Бүгенге яшьтәшләре Рәсимне яратып кабул итте. Онытылып бара торган икмәк кадерен искә төшерде язучы... Фаил балалар психологиясен яхшы белә, алар дөньясына бик табигый күчә ала. Юкса бу хикмәтле чикне теләсә кем уза да алмый бит. Шуңа күрә андый авторларның язганнары балалар турында булса да, олылар өчен килеп чыга. Баланың мавыктыргыч дөньясын ачу ягыннан кызыклы андый әсәрләр, әмма сабый күзе белән карау һәм нарасыйларча әйтеп бирү җитми. Үзебезне хәзерге балалар урынына куеп карарга тырышсак та, бала чагыбыз күзе белән карыйбыз, әсәрләр дә шул чордан языла. Хәзергеләр үзгә, катлаулырак, каршылыклы һәм кыенрак. Ф. Шәфигуллинның бүгенге балалар турындагы хикәяләре дә кызыклы, автор заманга хас характерларны күреп алып, бала белән уртак телне тиз таба. Фәнис Яруллинның «Яшел утрау хуҗалары» повесте да бала психологиясен белеп язылган. Яшь язучы К. Кәримов «Тылсымлы тәрәзә» дигән хикәя язды. Бала күңеле белән тоя белә ул, бу жанрда үзе ачкан тылсымлы тәрәзәсе бар. Ләкин киләчәктә тәрәзәдән генә карап чикләнмәс, киңрәк офыкларга чыгар дип ышанабыз.

Хәзер «хезмәт» сүзе «техника» сүзеннән аерылгысыз. Замана баласы машинаны без ат яраткан кебек ярата. Маһирлыклары шул дәрәҗәдә ки, «Оста куллар түгәрәге»н «Акыллы башлар түгәрәге» дип әйтерлек. Менә шуларга азык булырлык китаплар кирәк. Бүгенге мәктәп тормышыннан әсәрләр аз әле, уңышлылары тагын да азрак. Оста корылган сюжеты мавыктырып, хыялны ияртеп китә торган яңа повестьлар, хикәяләр көтә укучы!

Бала күңелен тәрбияләүдә ягымлы бер укытучы бар, ул — табигать. Сабый үзе дә аның бер өлеше. Таллар, чишмәләр, маэмайлар белән уртак тел таба ул, уртак сере бар. Чебиләр, мәчеләр турында язуга өстәнрәк караучылар ялгыша — ул мөлаем җан ияләре бала күңелен олы дөньяга тоташтырган элемтәчеләр. Шуларны кайгыртып бала шәфкать, миһербанга өйрәнә. Димәк, табигатьне сакларга өйрәтү — баланың үз табигатен дә саклау дигән сүз.

Африкадагы галәмәт тереклек ияләрен — фил, жирафларны яхшырак беләбез бугай. Алар турында бик күп кызыклы әсәрләр язылган шул. Г. Хәсәнов баланы бер дә еракка түгел, туган төбәккә — таныш тыкрыкларга, якын әрәмәләргә сәяхәткә алып чыга. Баксаң, бездә дә гаҗәп-хәйран җәнлекләр, кошлар, үсемлекләр бар икән! «Чү! Сайрар кошым оя тибә!» дигән китап әнә шул вазифаны үти, исеме белән үк табигатькә үтә сак булырга көйли. Г. Хәсәнов хикәяләренең дә үзенә хас көе, «сайравы» бар. Әмма китаптан-китапка күчеп «тыңлагач», бер төрлерәк моң тоясың, хәтта чит аһәңнәр дә сизелә... Төрле кошларның сайравын укучыга төрлечә ишеттерү алымнарын эзләргә иде.

Г. Хәсәнов бу изге эшкә А. Алиш хәерфатихасы белән керешүен әйтә. Табигатьне яратып, кызыклырак һәм мавыктыргычрак итеп язучы яшьләребез булыр, Алиш васыяте онытылмас дип ышанабыз. «Яшь ленинчы» газетасы «Туган ягым — яшел бишек» исемле даими дәресләре белән шул бурычны үти — балаларны сүздә генә түгел, эштә дә активлыкка — табигатьне сакларга өйрәтә. Бу изге эшне оештыруда өлкән язучыбыз Гомәр ага Бәширов халкыбызның күркәм традициясен дәвам итә — чишмә саклаучы аксакал сыман, бала күңеленең сафлыгын кайгырта.

Җан ияләре өчен җан атып торган яхшы күңелле, ярдәмчел малай турында Г. Шәрәфи бер төркем хикәяләр язды. Укучылар бик сизгер — «Күрше малае»н тиз күреп алдылар, үз иттеләр. Без дә ышанып җиттек — Габдулла табигате белән тәмам балалар язучысы икән!

Тагын бер табыш турында әйтәсе килә. Ул Ш. Бикчуринның «Табылдык» хикәясе, шул хикәядәге малай һәм маэмай. Аларның кыланмышларын күзәтә торгач, рәхәт бер дөньядан күңелгә яктылык иңүен, җылылык күчүен тоясың. Бер дә сәерсенмәгез, бала чакта этләр дә кешелеккә өйрәтә!

Г. Троепольскийның «Акбай кара колак» әсәре күңелләрне тетрәтеп, җан ияләренә миһербанлы карауның бер сабагы буларак бөтен илгә шаулаган иде. Н. Дәүли дә «Карабай — йорт эте» исемле повесть язды, тик авазы йорттан ары китә алмады... Акбай белән Карабайны сугыштырырга җыенмыйм. Әмма Сарбай — И. Газиның «Сарбай — сары эт»е һаман да онытылмый. Хикмәт әсәргә үз дулкынлануңны, үз ачынуыңны ни дәрәҗәдә салудадыр.

Г. Сабитовның «Карурманның күзе бар» исемле китабы дулкынландыргыч итеп, чын шигъри югарылыкта язылган. Әти-әни, туган туфрак кадерен белергә, үкенмәслек итеп яшәргә уйландырып, сискәндереп куйган гыйбрәтләр бар анда. Тәэсирләнеп укылган мондый әсәрләр онытылмый, күңелгә сеңеп кала.

Балалар бәгырь җимеше генә түгел, тәрбия җимеше дә. Ата-бабадан килгән яхшы гадәтләрне, бакчачы кебек, «ялгап» тәм өстәмәгәндә, алмагачның кыргый, багалмаңның әче, файдасыз булуы да ихтимал. Җирдәге тереклек иләрен тәмам кырылып бетүдән саклау өчен «Кызыл Китап»ка теркиләр. Табигатьне саклау әнә шулай, дөньякүләм актуаль проблемаларның берсенә әверелә. Кешенең дә кайбер кешелек сыйфатларын югалтмас өчен үзебез язасы «кызыл китап»ларга теркәргә — укучы күңеленә сеңдерергә кирәк.

Сүзне тикмәгә генә Р. Мингалимов шигыре белән башламадык. Эзләнүчән һәм үзенчәлекле шагыйрьләрнең берсе ул. «Бәхетле исем» китабында хәзерге иртә өлгерә торган, геометрия нигезләрен уен итеп мәктәпкәчә үзләштереп, беренче класста алгебраик табышмакларны рәхәтләнеп чишкән баланың образлы фикерләрен, үзенчә кузаллавын күрәсең. Мондый мөстәкыйльлек бик кирәк. Хикмәт баланың иҗади уйларга, кыю эзләнергә өйрәнүендә. Бу сыйфатлар шәхескә мәгънәле һәм омтылышлы рухи дөнья тудырырга ярдәм итә. Әмма «тузга язмаган» хәлләр турында сөйләгәндә кайара автор чама хисен югалткалый, өсте-өстенә өелгән табышмак-образлар белән мавыгып китә.

Х. Халиковның рәсемле нәни-нәни китаплары ел саен дөнья күрә. Аларны ачкач та, балалар бакчасын, класс ишеген ачкандай, шау-шулы, җанлы дөньяга керәсең. «Октябрятлар шәһәре» исемле җыентыкта нәкъ менә бүгенге малайлар һәм кызлар. Шигырьләр җыйнак, чын табышы булмый торып юк-бар бизәк күрсәтергә чакырмый шагыйрь. Әмма кайчакта шигырьләре бер бизәкле булып кала, инде төсләр калейдоскопы белән эш итәргә вакыттыр. Хәкимҗан моны үзе дә белә, эзләнүе, сәхнәләштерелгән уеннар язуы шуның бер чагылышы.

Соңгы елларда балалар шигыренең үзенчәлекле, чын сыйфатлары өстенлек итте. Монда Р. Миңнуллинның да өлеше зур. Поэзиягә самимилеге белән нәниләр дулкынына көйләнгән, туган телнең тәмен тоеп һәм тойдырып, әкгәмәдәш тә, уендаш та булган шагыйрь килде. Тансыклап һәм яратып балалар тормышына кушылды ул. Беренче китабы «Акбай цирк карый» дип атала, икенчесен дә өлгертте. Р. Миңнуллин эзләнүләр стихиясендә, формасы төрләнәнә, эчтәлек яңа табышлар белән баеый барыр дип ышанабыз.

Беренче китабын балалар өчен язып башлаган Р. Фәйзуллин да яңадан балаларны искә төшерде. Ул шигырьләрдә шагыйрь үзгә табигыйрак, замана баласы белән уртак дулкынга көйләнеп, алар дөньясына үтеп яза,

Иҗатларын тулаем балалар әдәбиятына багышлаган яшьләр дә бар. Беренче китапларын чыгарган Җ. Дәрзаманов, Р. Вәлиев, Р. Бәшәров балалар өчен яза алуларын күрсәттеләр. Аларга күбрәк эшләргә кирәк.

Балалар шигыре гади булырга тиеш. Әмма беркатлы түгел, ә катлаулы эчтәлекнең формула дәрәҗәсенә җиткерелеп, тәмам ачылып, төп сыйфатлары табылу. Олылар шигырендә катлаулы гадилек булса, балалар өчен гади катлаулылык кирәк.

Җырлар турында берничә сүз. Балалар поэзиясендәге кызыклы үзгәрешләрнең әлегәчә тиешле музыкаль гәүдәләнеш таба алганы юк. Яратып, үзеннән-үзе җырланып киткән нинди җырны атый алабыз? «Крокодил Гена җыры» да, Әзербәйҗаннан килгән «Чебиләр» дә тәрҗемә бит. Үзебездә үстерергә вакыттыр аларны. Музыкаль инкубаторда түгел, әлбәттә. Әлегә исә иң гайрәтлесе дә радиокомитет капкасына менеп кычкырудан узалмый.

Җырга ихтыяҗ, тансыклык гаять зур. Кыска гына вакыт эчендә «Ләйсән» ансамбле ничек танылып өлгерде — даны Азнакайлардан әллә кайларга җитте! Бала күңеле буш тора алмый — кыска дулкыннарда ерак араларны тиз үткән чит-ят куллар сузыла — үз җырларын җырлатып, үз көйләренә биетмәкчеләр. «Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың» диләр. Кем җырын җырласаң, шуның чанасында булмассыңмы? Балаларга үзебезнең җырны — совет җырын җырлатыйк! Модалар чикләрне визасыз гына уза. Шәфкатьсезлек, кансызлык дигән йогышлы чир тараткан чит фильмнарның балаларыбызның күңел чикләрен бозуы аеруча борчый. Яшерен-батырын түгел, көнкүрештә үзебез дә тискәре үрнәкләргә урын калдырабыз. Ә бит тормыш кинофильм түгел, яше тулмаганнарны читтә калдыра алмыйсың — барын да күреп, сеңдереп үсәләр. Балалар язучысы боларны һәммәсен истә тотарга, әсәрләре белән «дәвалау» юлларын табарга тиеш.

Поэзиядәге бер мавыгу турында моңа хәтле дә әйтелгәләде. Әзер «музыкага» ияреп язылган шигырьләр турында бара сүз. Эзләнү-табышсыз иҗат юк, иҗатның мәгънәсе шунда лабаса! Элгәрләргә охшатып сан арттыру сыйфат өстәми, яңа йолдыз ачарга, шуны ачу юлларын табарга кирәк. Киленчәкләрдә сынамыш бар: йөкле чагында кемгә сокланып карасаң, бала шуңа охшый ди. Әлеге шагыйрьләрнең дә, артык сокланып карауданмы, әсәрләре бүтәннәргә охшаш туа. Үз иҗатыңа турылыклы булып, үз илһамыңа охшаш әсәрләр тудыруга ни җитә!

Укытучы беренчедәгеләргә хәреф өйрәтә башлагач, классында утырып калган бер малай: «Былтыргы «А» ич бу!» — дип кычкырып җибәргән, диләр. Әдәбиятта булган мотивларны кабатлау, икенчеләпек — бала укыгач та әлеге мәзәктәгечә: «Былтыргы «А» ич бу!» — диярлек әсәрләр прозада да очрый. М. Хәсәновның «Динозаврлар илендә!», «Шайтан малае», «Без

6 «А»дан» повестьлары да быелгы «А» булып житә алмаганнар...

Балалар әдәбияты, аның барлык жанрлары да, талантлы әсәрләрне генә кабул итә. Олыларда шома гына үтәрдәй урта кул әсәрләр монда кычкырып, үзен фаш итеп тора. Ә шулай да алар шактый күренә әле, илһамсыз, илаһи ялкынсыз язылган әсәрләр балалар әдәбиятының абруена зыян китерә.

«Нәниләр өчен язучы кеше үзен бәхетле тоярга тиеш. Үзенең укучылары — сабыйлар кебек үк бәхетле тоярга тиеш»,—ди К. Чуковский. Т. Миңнуллинның «Иптәш командир» исемле пьесалар китабында шул якты атмосфера, игътибарны читкә җибәрмичә иярләп бара торган эзлекле хәрәкәт, ачыклык, тапкырлык бар! Сурәтләнгән чорлар төрле булса да, бик актуаль алар, бүгенге тамашачыга адресланганнар. Т. Миңнуллинга: «Балалар әдәбиятына хезмәт ит, «Иптәш командир», алар синең белән бергә атлый!»— дисәк бик дөрес булыр.

Батулланың музыкаль әкиятләре кызыксынып каршыланды, пьесалары курчак театры сәхнәсеннән төшми. Ул аларны «Пәһлеваннар иле» исемле җыентыкка да туплап чыгарды. Батулла иҗат стихиясе белән шушы жанр язучысы. Заманча, тапкыр фикерле үз табышын, үз тавышын ишетәсе килә — яңалыкны ақардан күтәргә урын бар.

Курчак театры өчен Н. Фәттах, Н. Дәүли, Г. Рәхим пьесалар язды, алар уйналып килә. Берничә яшь язучының да театр белән элемтәгә керүе мәгълүм. Шаять тә чын репертуар булырлык, шатлыклы ачышлар да, шаулыйсы вакыйгалар да булыр әле.

А. Тимергалинның «Космостан кунаклар», «Адашкан йолдыз» җыентыкларындагы мажаралы һәм фантастик повестьларын, хикәяләрен укыгач, бүгенге әкиятләр шул тирәдә түгел микән, дисең. Ул әсәрләр хыял офыкларын киңәйтә, омтылучан күңелләрне кызыктырып, парадокслар тәмен тоярга, иҗади эзләнергә өйрәтә. Автор укучыны социаль мөнәсәбәтләр галәменә дә алып чыга — хикәяләрдә буржуаз җәмгыятьнең кешелексез әхлагын, байлык хакимлек иткән дөнья күренешләрен таныйсың.

Әкиятләр шигырь белән дә, проза белән дә язылa тора. Тик алар чын мәгънәсендә яңа булса икән! Халык иҗатының әзер калыплары, алымнары инерция буенча әкияттән-әкияткә күчеп кенә йөри. Һич арына алмыйбыз шул шаукымнан. Бүгенге балаларны кызыктырырлык заманча әкиятләр кирәк. Формасы, эчтәлеге, геройлары белән яңа! Фәлсәфи фикерле, мавыктыргыч һәм тапкыр, ягъни чын әкият булсын иде! Дөнья әдәбиятында искә алырдай эзләнүләр бар. Шул тәҗрибәгә таянып, үзебезнең җирлеккә хас булганнарын ачасы иде.

Һәрнәрсә камилләшкән чорда кеше күңеленә ачкыч табу җиңел түгел. Бала күңеленә үтим дисәң, минемчә, юмор белән э итәргә кирәк. Баланың зирәк, оптимистик табигатен чагылдырган сыйфат ул. Бу жанр бала күңеленә иң якын юлны белә. Соңгы еллардагы уңышлы әсәрләрнең авторлары да юмористлар: Ф. Шәфигуллин, Т. Миңнуллин, Ф. Яруллин, Батулла, Х. Халиков, Р. Миңнуллин.

Сатирикларга эшләр шактый әле. Әйтик, балаларда күренгән, эчне пошырган кайбер ят гадәтләр — әдәпсезлек, тәүфикъсызлык, гамьсезлек, эш яратмау... Сатираның эше — профилактика — «авыруны» башланган чорда — бала чагында кисәтү җиңелрәк.

Табигыйлек, ихласлык — балалар әдәбиятының төп сыйфатлары. Моңа туган телнең нечкәлекләре аша гына ирешеп була. Җансыз тел белән бала җанына үтеп булмый. Уртак тел табу өчен канатлы тел, талантлы тел кирәк. «Сезнең алларда җырларга сандугач теле кирәк!» ди халык. Нарасый күңеле саф, аның белән дә сандугач телендә сөйләшү тиеш. Язып-язып та өйрәнчеклектән чыга алмаганнарның фаҗигасе — телләре ачылмауда.

Әдәбиятта һәр жанрның үсеше һәм танылуы язучы сәләтенә генә түгел, тәнкыйтьче эшчәнлегенә дә бәйле. Балалар әдәбиятында кызыклы эзләнүләр, формада, эчтәлектә булсын, төрле авторларда төрле табышлар бар. Әмма алар күренми кала килде.

Хикмәт әдәбият белгечләренең балалар әдәбиятының үзенчәлекләрен тоя алмавында, әзерлеге, сәләте белән шул дәрәҗәдәге шәхеснең булмавында иде. Бала күңеленә шагыйрь булып үтә алган Р. Кукушкин балалар шигърияте серләренә дә ачкыч тапты. Моңа бу жанрда бер гасырлык күтәрелмәгән чирәм булуы да ярдәм итте. Р. Кукушкин йөздән артык шагыйрьне өйрәнеп, төрле этапларга хас үзенчәлекләрне ачкан, гомумиләштерүләр ясаган, балалар поэзиясенең үсеш тенденцияләрен ачыклаган беренче белгеч. Аның «Шигъри бишек» исемле зур хезмәте фольклордан бүгенгечә булган араны эченә ала.

Балалар әдәбияты тәнкыйтендә, бигрәк тә проза һәм драматургия белгечләренә, вакантлы урыннар кала килә, җиң сызганып эшлисе эшләр күтә.

Халыкта шундый гадәт бар — аш вакытында килгән кешегә: «Мактап йөрисең!»— диләр. Яңадан-яңа тәнкыйтьчеләр әдәби табынга рәхим итсен, яңа китапка өлгерсәләр, тәнкыйтьләсәләр дә, «Мактап йөрисең!»— диярбез.

Республика матбугаты, аеруча «Яшь ленинчы» газетасы белән «Ялкын» журналы балалар өчен язылган әсәрләргә урынны мул бирә, яңа исемнәр белән очраштыра. Балалар язган шигырь, хикәяләрне, үз рәсемнәре белән бизәп, аерым китап итеп чыгару матур традициягә әйләнде.

Телевидение балалар әдәбиятын пропагандалауның үтемле формасын тапты. «Шигъри тәлгәшләр»не балалар көтеп ала. Шагыйрь Роберт Миңнуллин тапшыруларны балалар яратырлык итеп, бик табигый итеп алып бара.

Балалар өчен дистәләгән китаплар чыга, газета-журналлардагы әсәрләр меңләгән

укучы кулына керә. Шулай да балаларга иң якын торганы — дәреслек. Хәзерге дәреслекләр, матур киенгән балалар шикелле, тәсле рәсемнәр белән бизәлеп чыга. Эчтәлек тә яхшыра төште. Шулай да кайберләрендә әдәби үрнәкләр сайлауда зәвык җитми, бирелгән бәяләр сай. Дәреслек, кулланмалар мавыктыргыч, кызыклы булып, баланың тиктормас табигатен искә алса, тапкырлыкка өйрәтсә икән! Бу өлкәдә илдәге тәҗрибәне өйрәнгән очракта, заман дәрәҗәсендә булган кызыклы алымнар табылыр дип көтәргә була. Бәлкем «Күңел җимешләре» дигән дәреслек язган Тукаебыз тәҗрибәсен яңартып, язучы белән галимнең иҗади дуслыгыннан туар ул җимеш?

«Бездә бер дигән балалар әдәбияты бар, ул зур совет әдәбиятының аерылгысыз өлеше буларак үсә»,— дигән иде Л. И. Брежнев укытучыларның Бөтенсоюз съездында. Бу сүзләрне үзебезнең балалар әдәбияты турында да әйтелгән дип, чын канәгатьләнү хисе белән кабул иттек. Әдәбиятыбызның зурлыгын һәм дәрәҗәсен, рухи байлыгын күз алдына китерү өчен китап киштәләренә күз төшерү дә кирәк. Менә «Татар балалар әдәбияты китапханәсе» дип исемләнгән җыйнак, матур китаплар, тышларында күренекле исемнәр... Фольклор томы. К. Насыйри, Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Гафури, Такташ, Җәлил, Алиш, Ф. Кәрим, Кутуй, Ә. Фәйзи, Б. Рәхмәт... Шулар белән янәшәдә: Н. Исәнбәт, Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Маннур... Гомерен балалар әдәбиятына багышлаган А. Әхмәт, Д. Аппакова, Г. Гобәй, Л. Ихсанова, Г. Бакиров, Н. Гайсин, Җ. Тәрҗеманов, Ә. Бикчәнтәева, Г. Латыйп, З. Туфайлова, Газиз Мөхәммәтшин. Балалар әдәбиятына күренекле өлеш керткән К. Нәҗми, Ф. Хөсни, М. Әмир, А. Расих, Ә. Ихсак китаплары. Боларга бүген актив эшләүче язучылар өстәлә...

Дөрес, егерме томлы «Татар балалар әдәбияты китапханәсе» сериясе әле безнең нияттә генә. Әмма заман сынавы үткән ул хәзинәләрне барлап, фәнни әзерләп, Мәскәүдә чыга торган илле томлык үрнәгендә туплап, китапка зарыккан укучыга җиткерер чак җитте! Балалар әдәбиятының киләчәгенә, яңа иҗат көчләре килүгә тәэсире зур булыр иде бу басманың. Балалар елында укучылар теләге шундый. Өметләре акланыр, теләкләре кабул булыр дип ышана алар, съездның теләктәшлегенә исәп тоталар. Татарстан китап нәшрияты бу юнәлештә бик кыйммәтле инициатива күрсәтте. Быел, тарихыбызда беренче буларак, балалар поэзиясе антологиясе дөнья күрәчәк. Бу алтын фондта йөздән артык шагыйрьнең исеме бар. Чиратта — проза, драматургия антологияләре, балалар әдәбиятына багышланган мәкаләләр тупланмасы.

Матур-матур китаплар чыга тора. Әмма нәниләр өчен төсле, рәсемле китаплар да бер генә тираж белән басыла. Ә ихтыяҗ зур, кая барсаң да сорыйлар китапны. Авылларда бигрәк тә кытлык. Таткниготорг, Татпотребсоюзның бу мәсьәләгә мөнәсәбәтне үзгәртүе кирәк: әйбәт китапларга — зур тираж булсын! Укучыларның балалар елындагы наказы бу. Балалар язучысы өчен һәр ел — Балалар елы булган сыман, китап сәүдәсе оешмаларының игътибары да даими булыр дип көтәбез.

Ике съезд арасында безнең балалар әдәбиятын югары бәяләгән, бөтенсоюз күләмендәге вакыйга — «Детская литература» журналының махсус саны булды. КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиевнең кереш мәкаләсе белән ачылган бу санда актуаль бурычлар һәм проблемаларга багышлап галимнәрнең, язучыларның чыгышлары бирелде. Гомумән, бу елларда балалар әдәбиятына игътибар әйбәт булды. Язучылар союзы идарәсе, аның председателе Г. Ахунов бу өлкәдәге җитди бурычларны үтәүдә бик кирәкле эшләр башкарды.

Прозада, поэзиядә, драматургиядә яңа сыйфат үзгәрешләре булды — яңа исемнәр, яңа эзләнүләр, яңа табышлар. Ирешелгәннәр шуны ачыклады — эшләнәсе эшләр кызыклырак һәм күбрәк икән! Безнең балалар әдәбияты җаваплы бурычларны бөтенсоюз дәрәҗәсендә хәл итәргә алына. Шушы югары таләпчәнлек рухы киләчәктән яңа ачышлар көтәргә ышаныч бирә.

Ерак юлга чыгар алдыннан тын калып, утырып алу гадәте бар. Съездыбыз да киләчәккә юл чыгар алдыннан, башкарасы эшләр турында уйлашып-сөйләшеп алу. Үзебезнең жанрга кагылышлы берничә актуаль фикер белән уртаклашмакчы булам:

— «Бездә әле балалар язучыларының хезмәтләрен исәпкә алмау, ул язучының иҗатына зурлар өчен язылган әсәрләр белән бер дәрәҗәдә бәя бирмәү шушы көнгә кадәр яшәп килә».

— «Татар совет әдәбиятында зур ук урын тоткан язучыларыбызның күбесе әле балалар әдәбиятыннан әсәр биргәннәре юк».

— «Балалар драматургиясен һәм балалар җыр-музыкасын үстерүне бөтен кискенлеге белән куярга кирәк».

— «Балалар китапларының теле мәсьәләсе аеруча мөһим урын тота. Бу турыда тел-әдәбият белгечләре белән нык тикшеренү, эшләү кирәк».

— «Язучылар балалар өчен язган әсәрләрен үзләренең бала чактагы аң үсешләренә карап кына үлчиләр».

— «Ильич кайгыртуы белән кайгыртыгыз, Ильич яратуы белән яратыгыз безнең балаларыбызны!»

Бу фикерләр моннан 45 ел элек, 1934 елны, татар совет язучыларының беренче съезды уңае белән Муса Җәлил һәм Фатих Кәрим тарафыннан әйтелгәннәр... Никадәр алдан күрүчән булган безнең классиклар — бу таләпләр бүген дә көн тәртибендә кала.

Башлаганча, сабан туе белән очлыйк та сүзне. Балалар әдәбияты сабан туе карусельдәй кызыктырып, җилкендереп күңелләрне очарга өйрәтә. Әмма башларны әй-

ләндереп, балаларны агач атка атландырып калдырмас, илһам канатларында киләчәккә алып китәр дип ышандырабыз!

Максаты бер еллык кеше — иген чәчә, гомерлек дигәне — агач утырта, максаты мәңгелек кеше бала тәрбияләү өчен китап яза диләр. 1979 ел — Балалар елы. Ел гына түгел, киләчәк тә балаларныкы — безнең максатныкы. Иҗат иткәндә Ильич васыятен истә тотыйк: «Иң яхшысы — балаларга!» Балалар яхшы булсын! Алар нинди булса, киләчәк шундый булыр!

**Марсель Зарипов**

# ЗАМАН ҺӘМ ТРАДИЦИЯЛӘР БӘЙЛӘНЕШЕ

Йоласы шундый инде, съездга җыелганбыз икән — барасы юлдагы маякларны билгеләүдән элгәре, узган арага күз салабыз. Безгә республика язучыларының очерк һәм публицистика жанрында ниләр эшләгәнен дә барлап үтәргә кирәк. Бу өлкәдә хәл зарланырлык түгел. Беренчедән, ошбу жанр материаллары кояшка үрелеп үссен өчен шактый киң мәйдан бар: «Казан утлары», «Азат хатын», «Ялкын» журналлары, яшь язучыларның «Идел» альманахы, «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», «Татарстан яшьләре» һәм «Комсомолец Татарии» газеталары битләре. Педагоглар һәм укучылар турында яки алар өчен шундый ук язмаларны әдипләрдән «Совет мәктәбе» белән «Ялкын» журналлары да, «Яшь ленинчы» газетасы да һәр вакыт көтә. Хәтта алай гына да түгел — заказлар бирә, язуыбызны үтенә һәм урынлы таләп итә. Кыскасы, яз гына, китер генә — яхшы сыйфатлылары редакцияләр портфелендә яки өстәл тартмасында ятып калмаячак. «Казан утлары» бер үзе генә дә ике съезд арасында илледән артык күләмле әдәби очерк урнаштырды. Һәр санда берәр әсәрдән генә исәпләсәң дә, шактый санлы килеп чыга: илле-алтмыш басма табак!

Публицистикага хас документальлекне, формалар һәм алымнарны татар язучылары художество әсәрләрендә дә кулланалар, әмма бу инде — үзенә аерым тема. Мин, аңа кагылып тормастан, «саф очерк»лар тупланган җыентыкларны гына күздән кичерергә уйлыйм.

Без җитди, гаять җитди һәм бик зур эшне тәгәлләдек — КамАЗ турында китаплар сериясе чыгардык. Аларда илебездә генә түгел, ә бөтен дөньяга билгеле гигантның тарихы — заводлар булачак урында кагылган беренче казыктан башлап конвейердан беренче автомобиль төшкәнгә кадәр булган вакыйгалар, замандашларыбызның батыр хезмәте сурәтләнә. Сериянең беренче китабы 1971 нче елда дөнья күргән иде, соңгысы былтыр басылып чыкты. Авторлары — зур төзелештә катнашучылар, Мәскәү, Ленинград, союздаш республикалар журналистлары һәм язучылары. Әлеге тупланмада Татарстан әдипләренең өлеше дә зур. Автономияле республикаларда һәм өлкәләрдә барган үзгәртеп корулар турындагы китап белән без «Туганлык» дигән яңа серияне башлап җибәрдек. Аңа Идел-Урал географик регионындагы нәшриятлар чыгарган җыентыклар керәчәк. Без үзебездә басылып чыгасы китапны яздык, Уфа, Ярославль шәһәрләрендә дөнья күрәчәк җыентыкларда катнашабыз. Соңгы елларда журналистлар һәм язучыларның Түбән Кама химкомбинатына да игътибары көчәйде. Аның кешеләре турында зур китап — «Түбән Кама репортажы» былтыр чыкты. Соң булса да уң булсын! Чулман буеның нефтехимиклары һәм төзүчеләренә багышланган китаплардан Р. Хисмәтуллинның җыентыгы әзерләнде.

Очерк жанрында җанлану сизелә. Ш. Рәкыйпов, С. Шакир, И. Беляев, В. Ихсанова, Т. Журавлев, И. Низамов, Н. Орешина, Ә. Маликов, А. Хәсәнов, Э. Ларичева, В. Белокопытов, Р. Фәхретдинов, Җ. Рәхимов, М. Миншин, М. Маликова, К. Латыйпов очерк китаплары яздылар. Күз генә тимәсен, Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов та очерк жанрында бер җилкенеп алды — «Без бит Арча яклары» дигән китапта якташлары турында җылы сүзен әйтте.

Болар барысы да — нинди материалга нигезләнеп язылмасыннар, нинди генә экономик яки әхлакый проблемаларга багышланмасын, ни дәрәҗәдә уңышлы яки кимчелекле булмасын — барыбер кирәкле, файдалы китаплар. Алар безнең төп максатыбызга яңа кеше тәрбияләүгә хезмәт итә.

Кеше эшчәнлегенең башка төрләре кебек үк, әдәби иҗатның нәтиҗәлелеге дә шул хезмәт тудырган кыйммәтләр саны белән билгеләнә. Ләкин монда бер аерма бар. Әдәби иҗатның кыйммәте язылган томнар исәбендә һәм аларның калынлыгында түгел. Кечкенә генә асылташлар хакына зур-зур таш-таулар актарыла. Шуның кебек үк, кыйммәтле фикер җәүһәрен табып, аны укучыга җиткерү өчен, журналистлар һәм язучылар да тормыштагы бик күп вакыйгаларны, иң әһәмиятле фактларны эзли.

Галимнәр инде шуны исәпләп караган:

2035 елда җир шарындагы нефть запаслары яндырылып бетәчәк. Күмер, металл, энергетика ресурслары да мәңгегә җитәрлек бетмәс-төкәнмәс түгел. Шул ук вакытта безгә мәгълүм: җир асты хәзинәләреннән алынган байлыкның нибары 5 проценты гына файдалы эшкә китә, калганы файдасыз «калдыкка» чыга. Безнең чорда кешелек дөньясы үз бишеге булган планетаны чүп-чар базына әверелдерү алдында тора. Ләкин төп куркыныч анда гына да түгел. Белгечләрнең әйтүенә караганда, Җирдә тормыш алып барырлык төрле ресурсларны Галәмдә бик күп итеп табарга мөмкин, әмма алардан кирәгенчә, нәтиҗәле итеп файдалану өчен кешеләрдә акыл җитәрме — менә монысы үтә четрекле проблема. Хикмәтнең нәкъ шунысы — кеше акылын үстерү мәсьәләсе язучылар өлеше. Г. Паушкинның «Табигатьнең алмаз фонды» очеркында шундый киң, колачлы тема күтәрелә. Белүемчә, язучы аны да читкә куйган, бу юнәлештә уйлануларын дәвам иттереп, яңа әсәр язарга җыенмый.

«Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла» дигәндәй, бу сүзләр башка язучыларга да кагыла. Зур темадан бер-ике бөртек җим табып укучыга бүләк итәләр дә, эзләнү мәйданыннан чыгалар. Кабатлап әйтик, мондый хәл очерк жанрында эшләүчеләрнең күбесенә хас.

Публицистика өлкәсендәге тагын бер җитмәгән як — авторлар карашының тарлыгы, тормышны өйрәнүдә фәнни алымнарны кулланмау яки аларны белмәү, күбрәк өстә яткан вакыйгаларны гына каләм очына эләктереп алу. Егерменче гасырда яшибез, кеше микродөнья чикләрен ачты, токомаклар — җир кояшлары кабызды, тере күзәнәкләрне синтезларга җыена. Мондый шартларда документалист — әдип һәм журналист — бер үк вакытта оста каләм иясе дә ,бик күп фәннәрдән хәбәрдар белгеч тә булырга тиеш. Бары шул чагында гына очеркларда, публицистик язмаларда илкүләм зур проблемаларны күтәрергә, аларны хәл итү юлларын билгеләргә мөмкин.

Проблемаларның ваклыгы, алга куелган бурычлар турында язганда художник осталыгы җитенкерәмәү безнең документалист-язучыларыбызны бөтенсоюз укучысына чыгаруда бер киртә булып тора дип уйлыйм. Соңгы биш елда Мәскәү нәшриятларында Татарстан әдипләренең 165 китабы чыкты, ләкин алар арасында бүгенге көн очеркларь тупланган җыентыклар юк. Татар язучылары «Волга», «Нева», «Октябрь» журналларында басыла, «Литературная газета», «Литературная Россия» газеталарында дөнья күрә, «Правда», «Известия», «Труд», «Советская Россия» газеталарында чыккалый. Ләкин бу системалы түгел. Татар телендә дөнья күргән очерк китаплары русчага бөтенләй тәрҗемә ителми диярлек. «Оста языйм дисәң — яхшы бел!» — безнең көннәрдә очерк һәм публицистика өлкәсендә эш итүче һәр язучыга куела торган төп таләп шундый. Йөзә белмәгән — тирән суга кермәс, ә аның чумып энҗе эзләвен исә көтәсе дә юк. Шуның шикелле, тормыш вакыйгаларының асылын өйрәнгәндә, таныш булмаган фактлар очраса, без алардан читләшергә тырышабыз. Өйрәнү өчен үтә четрекле булып тоелган мәсәләләргә җитүебез була — аптырабрак калабыз. Турысын әйткәндә, үзебезгә иң якын авылда барган социаль-экономик үзгәрешләрне дә аз өйрәнәбез бит, тирәнрәк чумарга тырышмыйбыз. КПСС Үзәк Комитетының 1978 ел июль Пленумы карарыннан соң республикабыз колхозларында һәм совхозларында игенче хезмәтен индустриаль нигезгә күчерү, авыл белән шәһәр арасындагы аерманы бетерү юнәлешендәге эшләр гаять киң колач алды. Боларны күрергә, әдәбиятта, барыннан да бигрәк документаль жанрларда, моны дөрес, тулы итеп, бөтен тирәнлеге һәм катлаулылыгы белән чагылдырырга кирәк ләбаса.

Автогигантта эш башланып кына киткән чорда аның турында язу җиңелрәк иде. Язучылар да күп булды. Хәзер исә язучыларыбыз аны торган саен сирәгрәк телгә алалар. Хәлбуки, Чаллы төзелешендә хәлләр элеккедән катлаулырак: автогигантның икенче чираты корыла, төзелеп беткән корпуслар ходка җибәрелә, машиналар эшләп чыгаруны арттыру өчен көрәш бара, Гигант төзелештә иң мөһим проблема — кешеләрне тәрбияләү, формалаштыру. Һәм бу эш бер көнгә дә, бер сәгатькә дә кичектерелә алмый. Менә кайда язучының илһамландыргыч, акыллы сүзе су белән һава кебек кирәк! Ләкин әдипләребез дәшми. Ни булды? Гигант төзелеш мәйданында үсеп чыккан хезмәт геройлары кызыксындырмый башладымы әллә? Юк, аларда кызыксыну көчле, әмма шуны канәгатьләндерү өчен эзләнү авырлашты. Тормышның өске катламнарына гына күз салу җитми хәзер, тирәндә яткан процессларны табарга, күрергә, өйрәнергә кирәк булып чыкты. Документалист-язучыларыбызның күбесе шушы «көтелмәгән» каршылыкка килеп төртелде. Аны җиңеп үтү өчен һәм әдәби көч, һәм шәхеснең рухи ныклыгы, һәм физик тырышлык кирәк.

Тарихка күз салсак, нәкъ шундый «каршылыкны» җимереп үткән язучыларның документаль жанрда зур уңышка ирешкәнен күрербез. Валентин Катаев Магнитка тавы итәгендә казылган тирән котлованнан «Время, вперед!» дигән китабын алып чыкты. Геройлары — Апас ягы кешеләре, Хәбибулла Галиуллин бригадасы бетончылары. Тынгысыз Мариэтта Шагинян төзелешләрдә йөреп «Гидроцентраль»не язды... Татарстан язучыларына кучик. Нонна Орешина очучылар турында китап язарга җыенгач, бу эшнең әлифбасын өйрәнүдән башлады, геройлары тапшыра торган «техминумум»ны үтеп, парашютта сикерергә өйрәнде һәм тавыш тизлегеннән кызурак очучы хәрби истребительләрне үзләштерде. Нәтиҗәсе — күз алдыбызда: Нонна Орешина «Время сжатых секунд» дигән документаль китап язды! Берничә очеркы «Правда» һәм «Советская Россия» газеталарында басылды. Тагын бер мисал. Ра-

вил Вәлиев КамАЗ төзелешендә монтажчы булып эшләде һәм төзүчеләр турында китап чыгарды. Авторны Язучылар союзына алганда аның документаль әсәрләренә югары бәя бирелде. Мәдинә Маликова ике китап язып өендерде: берсе БАМнан һәм Камчаткадан юлъязмалар, икенчесе — халык традицияләре һәм йолалары турында. Соңгысы фәнни хезмәткәр белән берлектә язылган. Фән кешесе белән иҗади дуслык язучыны уңышка китерә. Безнең очеркларга күп вакыт нәкъ менә шундый фәнни эзләнү, теманы тирәнтен өйрәнү җитенкерәми.

КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарында совет әдәбиятының, иҗат оешмаларының бу өлкәдәге роле һаман үсә барырга тиешлеге әйтелә. Бу бурыч иҗат эшчәнлегенең иң өлгер, иң оператив жанры булган очеркка да кагыла.

Язучыны тәнкыйть итү, аңа мең дә бер киңәш бирү, нәрсә турында ничек язарга өйрәтү — иң җиңеле. Ләкин бер хакыйкатьне онытмыйк: киңәшләрне акыл иясе бирә, ә эшне осталар эшли! Безгә очерк һәм публицистика өлкәсендәге эшебезнең бүгенге хәленә дөрес бәя бирергә кирәк. Бу жанрны, гомумән, документаль әдәбиятны «үги бала» итмәскә, үз иҗатларын шуңа багышлаган язучыларга игътибарлырак булырга иде. Соңгы елларда союз идарәсе аларның иҗат эшчәнлеге һәм шул эшчәнлекнең җимешләре — документаль әсәрләр белән күбрәк кызыксына башлады. Былтыр очерк һәм публицистика секциясенең оештырылуы шуның бер дәлиле.

Сугышчан жанрны үстерү юнәлешендә беренче эшебез — шул өлкәдә даими эшләрлек очеркистлар булдыру дип уйлыйм, язучыларыбыз зур авырлык белән табыла торган, ләкин бик ләззәтле бу әдәби ризыктан баш тартмасын иде. Аеруча яшьләргә игътибар итәргә кирәк Каләм тибрәтүче яшьләрнең күбесе шигырь яза, прозаиклар да бар, ләкин очеркка һәм публицистикага омтылучы яшь каләмнәр юк. Әллә бу жанрдан шүрләү көчле, әллә аны игътибарга лаек дип санамыйлар инде?! Кыскасы, очерк һәм публицистика өлкәсендә хәл шундый: бөтен коллективыбыз белән тотынсак кына авыр йөкле бу олауны кузгатып җибәрә һәм юлда кызулый алырбыз шикелле.

Җанлы әдәби процесс барышы шуны раслый ки, бөек язучылар бер жанрда гына иҗат итми, алар үткен, йөгерек документаль әсәрләр язарга да өлгерә. Документаль жанрга мөрәҗәгать итү талант иясен тормышның кайнап торган чишмәсеннән ыргылган яңа идеяләр, фикерләр белән баета. Әйтик, Герцен һәм Успенский талант үзенчәлекләре ягыннан очеркистлар һәм публицистлар булганнар, ләкин алар сокангыч художество әсәрләре дә иҗат иткән. Хәзерге совет әдәбиятында да прозаик һәм шагыйрьләрнең — Даниил Гранин, Владимир Чивилихин, Глеб Горышин һәм башкаларның очерк китаплары еш чыга. Үзебезнең Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Муса Җәлил саф шагыйрь яки саф прозаик кына булганнармыни?!

Союз идарәсе әмере белән очерк язылып булмый, әлбәттә, һәр әдип үз йөрәгендә шыткан темага тотына, үзенә яхшы билгеле, аңлаешлы, күңелен борчыган яки сөендергән нәрсәләр хакында яза. Әмма иҗат кешесе бүгенге кайнап торган тормышны дөрес аңлый, аның вакыйгаларын йөрәк аша кичерә белсен — шул юнәлештә аңа булышлык итү кирәк. Геройлары белән күбрәк аралашсын ул, чынбарлык күренешләрен аңларга һәм шуны сурәтләргә теләк тусын аның күңелендә.

Былтыр һава шартлары бик авыр килгән урак өстендә союз идарәсе әдипләрне колхозларга һәм совхозларга командировкага җибәрде. Авыл эшчәннәренең героик хезмәтен үз күзләре белән күргән язучылар дистәләгән очерк һәм публицистик язмалар бирделәр. Алар газеталарда басылды, радиодан яңгырады. Гариф Ахунов, Мөсәгыйт Хәбибуллин «Җир һәм кеше» темасына көн кадагына суга торган язмалар циклы белән чыгыш ясадылар.

Үз заманында М. Горький завод, фабрика һәм төзелешләрнең тарихын язарга кирәк дигән иде. Хәзер инде тарих сәхифәләреннән колхозлар оештырыла башлауның илле еллыгы, стахановчылык хәрәкәтенең ярты гасырлык елъязмасы язылган. Яхшы башлангычны бүген дә дәвам иттерик. Документаль жанрны үстерүнең оештыру формасы буларак, язучылар белән колхозлар һәм совхозлар, заводлар һәм фабрикалар, нефть промыселлары һәм төзелешләр арасында иҗат договорлары төзү уңай нәтиҗәләр бирә. Шулай ук хезмәт алдынгылары, хуҗалык итүнең мөһим проблемалары, табигатьне саклау, яңа кеше тәрбияләү, партия эше проблемаларына багышланган китаплар язу өчен нәшриятларның әдипләргә заказ бирүен дә практикага кертү әйбәт булыр иде. Кызганычка каршы, язучыларыбызның күбесе нәшриятның документаль жанр белән эш итүче редакцияләренә кермәскә-сугылмаска тырыша, ә нәшрият исә актуаль темага язылган, бик кирәкле публицистик язмалар «үзләре тәпиләп килер» дип көтә шикелле.

Кыскасы, съездда очерк һәм публицистика үсешенең хәзерге тенденцияләрен һәм юлларын билгеләргә, бу өлкәдә булган мөмкинлекләрне, яңа формаларны һәм эш алымнарын барларга кирәк. Киләчәктә безнең әдипләребез заман белән бердәм атлап барырлык, совет халкының иҗади эшчәнлегендә язучыларыбызның катнашуы активрак һәм нәтиҗәлерәк булсын. Бөек хезмәт кешеләренең тормышны яңарту өчен алып барган зур көрәшен тулырак сурәтлик, әсәрләребез кешеләрне Ватаныбызның тугрылыклы гражданнары һәм патриотлары итеп тәрбияләү бурычын тагын да яхшырак үтәсеннәр.

# Илдар Юзеев

# ШӘҖӘРӘНЕҢ ОЧЫ КЕМНӘРДӘ?

Хәзер безнең оешмабызда 153 Язучылар союзы члены бар. Бу сан тагын да күбрәк булырга тиеш иде. Ватан сугышында без әдәбиятыбызның нигезен тәшкил иткән, халкыбызның горурлыгы булган язучыларыбызны, шуның өстенә, зур өмет баглаган, бүгенге көндә әдәбиятыбызның күрке булып шушы залда утырырга тиешле бик күп яшь талантларыбызны югалттык. Бу — әдәбиятыбызның санына да, сыйфатына да тәэсир итми калмагандыр, билгеле. Әмма халык талантлары, саф чишмәләр сыман, тегеннән дә, моннан да бәреп чыга торалар. Татар әдәбияты беркайчан да тарлык күрсәтмәде, ул диңгезгә әверелгәнчә, төрле төбәкләр, өлкәләр, республикалардан килеп кушылган чишмәләр, елгалар хисабына баеды, үсте, зурайды.

Бүген безнең исемлектә Язучылар союзы члены булмаган, матбугатта әсәрләре басылган 700 дән артык яшь башлап язучы бар (исемлеккә укучы балалар кермәгән). Кайберәүләр бу санга мыек астыннан көлеп, шикләнеп карыйлар, янәсе 700 язучы буламыни? Янәсе, чын талант үзе бәреп чыга, алар белән эшләү үзен аклар микән? Әйе, әдәбиятны шәхесләр, олы талантлар тудыра. Әмма шуны да онытмыйк: кечкенә Апушны, зуп-зур Тукай булганчы, кемнәрдер үзенең җылы канаты астына алган, башыннан сыйпаган, беренче шигырьләрен бастырырга ярдәм иткән. Муса Җәлилнең әдәбияттагы язмышы унбер яшендә «Кызылармеец» газетасында басылган «Кечкенә Җәлил шигырьләре»ннән башланган. Тукай дәверендә дә әдәбиятка омтылучыларның саны аз булмагандыр. Шулардан Тукай, Камал, Дәрдмәнд, Әмирханнар калган... Әмма олы әдипләрне тудыру өчен әдәбиятка омтылучы йөзләр, меңнәр кирәк булган.

КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы һәм КПСС өлкә комитетының 1975 елгы карарларыннан соң, әдәбиятның алмашы белән эшләү яңа баскычка күтәрелде. Язучылар союзы идарәсе бу мөһим эштә партия, совет, комсомол, профсоюз оешмаларының, газета-журнал редакцияләренең, китап нәшриятының, радио һәм телевидениенең даими ярдәменә таянды. Яшь авторлар тәрбияләү мәсьәләсе гомумдәүләт эше сыйфатында иҗат союзларының берләштерелгән пленумында каралды һәм анда яшь әдәбиятчыларның идея-теоретик әзерлеген һәм әдәби осталыгын күтәрү буенча план эшләнде.

Союзның консультация бюросы яшь авторлар белән эшләү бүлеге дип үзгәртелде, бу бүлеккә җитәкчелек итәргә идарә һәм партбюро членнары куелды. Бүлек мөдирләренең берсе союз идарәсе председателенең урынбасары итеп билгеләнде. Союз каршында яшь авторлар белән эшләү комиссиясе төзелеп, аның составына Ш. Галиев (председатель), Ш. Маннур, Т. Миңнуллин, М. Скороходов, А. Гыйләҗев, Ә. Баянов, М. Шабаев, Г. Рәхим һәм М. Вәлиев (секретарь) кертелде. Айга бер тапкыр үткәрелә торган утырышларда әдәби берләшмә шефконсультантларының отчетлары тыңланды, «Идел» альманахының яңа саннары тикшерелде, китап нәшриятына яшь авторларның беренче китаплары тәкъдим ителде. Партбюро һәм идарәнең берләштерелгән утырышында тикшерелеп, комиссиянең эше яхшы дип табылды.

Күп санлы яшь авторлар белән эшләүдә без төрле формалар кулланабыз.

ВЛКСМ өлкә комитеты һәм иҗат союзлары белән берлектә һәр елны яшьләрнең республика семинарлары үткәрелә. Соңгы биш елда биш семинар уздырылды. Ике көнлек бу семинарларда яшь авторлар сәнгатьнең төрле өлкәләрендә иҗат итүче яшьтәшләре белән очрашалар. Экономика, политика, әдәбият һәм сәнгать проблемалары куелган лекцияләр тыңлыйлар, диспутларда катнашалар. Һәр семинарга 150—200 яшь әдәбиятчы чакырыла. Яшьләргә политик һәм эстетик тәрбия бирүдә бу семинарларның әһәмияте бик зур.

Иҗат яшьләре белән эшләү өчен ВЛКСМ өлкә комитеты каршындагы совет та (председателе Диас Вәлиев) үз эшен башлап җибәрде. Утырышларның берсендә художник Н. Әлмиевнең иҗаты тикшерелде, икенчесе төсле музыкага багышланды. Төсле музыка! Техника белән сәнгатьнең гармониясенә омтылган Казан яшьләренең кыю ачышы — сәнгатьнең яңа бер төре — художниклар һәм архитекторлар иҗатына да тәэсир итә. Без яшәгән бөек һәм катлаулы чорның эчтәлеген яңа чаралар белән чагылдыру юлларын эзләгән яшь язучылар да техникадагы һәм сәнгатьтәге мондый ачышлардан калышмасыннар иде!..

1975 елның ноябрендә ВЛКСМ өлкә комитеты белән берлектә үткәрелгән Камаз... Киңәшмәгә хезмәт темасына язучы яшь авторлар чакырылды. Анда Казан, Чаллы, Әлмәт шәһәрләрендә эшләүче һәм иҗат итүче үзенчәлекле сәләтләр ачылды. Киңәшмәгә кадәр Камгэсэнергострой КамАЗ турындагы иң яхшы әсәргә конкурс игълан иткән иде. КамАЗ төзүчеләр Мәхмүт Газизов һәм Инна Лимонова лауреат исеменә лаек булдылар.

Куанычлы хәл: соңгы елларда әдәбиятка тормышны читтән торып күзәтүчеләр түгел, бәлки язылачак әсәрләренә кирәсе геройлар белән бергә эшләүче, шәһәр, завод, комбинатларны үз куллары белән төзүче, тормышка фәлсәфи бәя бирергә сәләтле югары белемле яшь көчләр килә. Менә шуңа күрә дә Мәхмүт Газизов, Павел Алешков, Евгений Кувайцев, Хәниф Хөснуллин, Сәлимә Шәрипова, Ямаш Игәнәй, Нур Әхмәдиев шигырьләренә, Фәрит Гыйльметдинов, Нәбирә Гыйматдинова повестьларына тормышчанлык, конкретлык, җылылык хас. Фәлсәфә дә, проблема да уйлап чыгарылган түгел, тормышның үзеннән.

Илебездә барган бөек төзелешләрдә үзләре катнашкан яшь авторлар соңгы елларда әдәбиятка масштаблы уйлый белүче актив геройларны алып килделәр. Шулай ук алар хезмәт кешесенең җанына, психологиясенә тирәнрәк үтеп керделәр. Чаллы яшь шагыйрьләренең берничә тапкыр «Новый мир» журналында урын алуы — яшьләр алып килгән бу әйбәт сыйфатның союз аренасында да танылуын күрсәтә.

Чаллыдагы бөек үзгәрешләр турында өлкәннәр дә, яшьләр дә күп кенә уңышлы әсәрләр иҗат иттеләр. Әмма бөтен дөньяны үзенә караткан гигант төзелеш аның үз дәрәҗәсендә, монументаль югарылыкта ачылырлык талантны көтә әле. Сине көтә, яшь язучы! Бу хакта сүз 1976 елны 110 яшь автор катнашында уздырылган республика семинарында да, быел март аенда булып үткән яшь тәнкыйтьчеләр семинарында да алып барылды.

Тәнкыйть — һәр вакыт яшь булырга тиеш. Тәнкыйть картайдымы, әдәбият тынычлана, үсүдән туктый. Соңгы елларда безнең тәнкыйтебез М. Вәлиев, Р. Мөхәммәдиев, Р. Кукушкин, Ә. Мәхмүдов, Ф. Зөлкарнәев кебек сәләтле яшьләр хисабына яшәрде.

Моннан 15 ел элек, «Ялкын» журналында эшләгәндә, Адав-Толымбай мәктәбенә барып, 8 класс укучысы Равил Кукушкинның балалар өчен язылган шигырьләрен алып кайткан һәм журналда бастырган идек. Ул шагыйрь булып китмәде китүен, әмма без бүген балалар әдәбияты буенча эшләүче тәнкыйтьче Равил Кукушкинның, каләмдәшләре Р. Мөхәммәдиев һәм Р. Свиригиннар белән бергә СССР Язучылар союзына тәкъдим ителүен сөенеп әйтәбез. Аларга әйбәт әсәрләрне үз вакытында күреп алу, яшьләрчә өлгерлек, активлык, үз сүзен кыю әйтергә, яшьтәшләренә юнәлеш бирергә омтылу хас. Алар әдәби әсәргә бөтенсоюз һәм бөтендөнья әдәбияты ирешкән казанышлар биеклегеннән килеп бәя бирергә тырышалар. Бу — яшь тәнкыйтьнең әдәбиятны алга чакыра торган әйбәт сыйфаты. Шушы олы таләп белән килгәндә генә әдәбиятыбызның сыйфат ягыннан яңа югарылыкка күтәрелүенә ирешергә мөмкин. Әмма яшь тәнкыйть үзе дә тәнкыйтькә мохтаҗ әле. Кайбер мәкаләләрдә әдәбиятның үсеш тенденциясен анализлаганда берьяклылык сизелә. Урта кул яки зәгыйфь әсәрләргә үз вакытында принципиаль тәнкыйть сүзе әйтелми. Яшь тәнкыйтьче шуны онытмасын иде: тәнкыйть ул — банкет түгел.

Шигырьдә фикер һәм хис нисбәте турында кызыклы бәхәсләр булып алды. Язучылар союзы каршындагы дискуссия клубында да әдәби процесста туган сорауларга җавап эзләнә. Әйе, хискә караганда фикергә ныграк таянып уңышка ирешкән шагыйрьләр булган һәм бар. Әмма бер шагыйрьнең кабатланмас үзенчәлеген бөтен поэзиягә тагарга, «бүгенге заман шигърияте бары тик акылга гына таянырга тиеш» дигән кебегрәк юнәлешкә чакыру дөрес булмас. Акыл белән Хис, очрашырга каңгырып Сак белән Сок шикелле яшәсәләр, шигырь дә укучы белән кавыша алмас. Мең еллык поэзиябез күгендә кемнәр балкый?! Акыллы кешенең җанын тирән ачып биргән бөек акыл һәм хис иясе!

Берьяклылык — яшь тәнкыйтьнең тәҗрибәсезлегеннән килә. Бу бәла әдәби осталыкта бигрәк тә сизелә.* Кызганычка каршы, осталыкка чакырып язган күп тәнкыйть материалларының үзләренә осталык җитми. Аларга әдәби жанр таләбеннән чыгып карасак, художество чараларының, алымнарының, телнең ярлылыгын күрербез. Тәнкыйтьче беркайчан да үзенең язучы икәнен, художестволы хезмәт язарга тиешлеген онытмасын иде! Кошны бер сайравыннан танып алган кебек, укучы тәнкыйтьчене дә бер җөмләсеннән танып алсын иде.

Әдәбиятыбызның иң яшь жанры — драматургия. Узган съездда без бер генә яшь драматургның да фамилиясен атый алмаган идек. Бу юлы, инде пьесаларын театрларда куйдырган һәм елдан-ел үсә барган Р. Хәмидуллин, Ә. Гаффаров, Ф. Садриев, Ю. Сафиуллиннарның исемнәрен сөенеч белән телгә алабыз. Алар драматургиягә яшьлек дәрте, заман геройлары, көчле характерлар, яңа ситуацияләр алып килделәр. Казанда Мәскәү драматурглары һәм тәнкыйтьчеләре катнашында узган семинарда алар иҗатына әйбәт бәя бирелде һәм кайбер әсәрләре рус теленә тәрҗемә ителде. Яшь драматургларны тәрбияләүдә Туфан Миңнуллин һәм Аяз Гыйләҗевләрнең вакытларын кызганмыйча эшләүләрен мактап телгә алмыйча мөмкин түгел. Бүген без куанып әйтә алабыз: драматургиябезнең киләчәге зур һәм өметле! Бу — театрларның да яшь драматурглар иҗатына игътибарны арттыру нәтиҗәсе.

Яшь авторлар белән индивидуаль эш һәр вакыт әйбәт нәтиҗәләр бирә. Башкортстанда яшәүче Зиннур Насыйбуллинның кульязмасы белән танышканнан соң, без аны Казанга чакырып алдык, эшкә урнаштырдык, һәм, ныклап эшләткәннән соң, җыентыгын Татарстан китап нәшриятында чыгардык. Шундый ук ярдәм Куйбышев өлкәсендә яшәүче Гакиль Сагировка, Башкортстаннан Кәүсәрия Шафиковага күрсәтелде.

Әдәбиятыбызның бүгенгесен дә, киләчәген дә кайгыртып яшәгән, яшьләрнең

бернича буынын тәрбияләп үстергән Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Г. Паушкин кебек остазлары булган әдәбият беркайчан да үсүдән туктамас!

Республикабызда утызга якын әдәби берләшмә эшли. Аларның һәрберсенә тәҗрибәле язучылар — шеф-консультантлар беркетелгән. Лениногроскидагы әдәби берләшмә (аны озак еллар буе Шамил Бикчурин җитәкләде) егерме еллык, Түбән Камадагы берләшмә (җитәкчесе — Р. Хисмәтуллин) ун еллык юбилейларын билгеләп үттеләр. Чаллыдагы «Ләйсән» (җитәкчесе — Равил Вәлиев), «Орфей» (җитәкчесе Е. Кувайцев) берләшмәләре, Арча (шеф-консультант Х. Халиков), Апас (А. Шәрәфетдинов), Әлмәт (С. Сөләйманова) берләшмәләре дә нәтиҗәле эшлиләр. Әгерҗе районы К. Маркс исемендәге колхозда оешкан түгәрәк (җитәкчесе Ә. Фәтхетдинова) колхоз талантларын туплаган. Берләшмәләргә ярдәм итү өчен, аларны җитәкләүчеләрнең сүлпән эшләве, ныклы бердәмлек булмавы яки бөтенләй таркалулары күңелне борчый. Күпме генә тырышсак та, бай традицияләре һәм иҗат көчләре булган университет һәм педагогия институтындагы әдәби түгәрәкләрне һаман әле җанландырып җибәрә алмыйбыз. Яшь иҗатчылар гел игътибар гына көтеп ятмасыннар, үзләре дә актив булсыннар иде.

Республикабыздагы яшь талантларны барлау, аларга конкрет ярдәм күрсәтү максатыннан чыгып, яшь язучыларның зона конференцияләре уздырылды. Бу — яшьләр белән эшләүнең яңа бер формасы. 1977 елда үткәрелгән Апас конференциясендә йөзгә якын яшь автор катнашты. Шул ук елны уздырылган Чаллы зонасы конференциясе дүрт районның яшь талантларын җыйнады. Анда «КамАЗ — совет әдәбиятында» дигән доклад, аксакалларның әдәби осталык турындагы чыгышлары, әдәби берләшмәләрнең отчетлары тыңланды. Семинар утырышларында яшь язучылардан 50 авторның кульязмасы тикшерелде. Конференция тәкъдиме белән Мәхмүт Газизов һәм Равил Вәлиев СССР Язучылар союзына кабул ителде. Шул ук «Ләйсән» берләшмәсе членнарының иң яхшы әсәрләре, Хәниф Хөснуллинның шигырьләр җыентыгы Татарстан китап нәшриятына тапшырылды. Әйбәт дип табылган башка әсәрләр республика матбугатында, «Волга» журналында дөнья күрделәр, радио һәм телевидение аша яңгырадылар. Шундый ук конференцияләр узган елны Арча һәм Азнакай зоналарында да үткәрелде. Конференцияләр һәм секцияләр тәкъдим иткән авторлардан Н. Мадьяров, Ш. Маннапов, М. Галиев, Ә. Гадел, Разил Вәлиев, Ә. Рәшитов СССР язучылар союзына кабул ителделәр.

Әдәбиятыбызның иртәгәсе турында гына түгел, ераграк киләчәге хакында да уйлау безне образлы уйлау сәләтенә ия булган бала чак иленә илтте. Күп очракта талант бик иртә, мәктәп яшендә үк ачыла. Мин, мәсәлән, әдәбиятка килүем белән ал галстук таккан пионер чагыма, мәктәптәге иҗат түгәрәкләренә, кульязма журналларга бурычлымын. «Ялкын» журналы һәм «Яшь ленинчы» газеталары мәктәп яшендәге балаларның беренче язмаларын бастырып, бик дөрес эшлиләр. Татарстан китап нәшрияты укучы балалар иҗатын туплаган биш китап бастырып чыгарды. Анда 400 ләп укучы катнашкан. Бу ихлас шигырьләрне, хикәяләрне укыганда, Азнакайдагы «Ләйсән» ансамблен тыңлагандагы сыман, сөенечле хисләр кичерәсең. Киләчәк әдәбиятыбыз авазының саф яңгырашын ишетәсең... Барысы да язучы булып китмәсләр дә, киләчәктә аларның әдәбият патриотлары булачакларына шик юк. Җитди әдәбиятның укучылары да талантлы булырга тиеш бит әле! Бу китаплардагы иң кечкенә автор — Фәния Гайнуллина — өченче класс укучысы, Өчмунчадан... С. Хәкимнең шигыре искә төште:

**Кайдан татар шагыйрьләре!**
**Мактап, хуплап мин кул чабам.**
**Талантлылар, ә үзләре**
**Такталачык, Дүртмунчадан...**

Килсеннәр әдәбиятка, килсеннәр... Дүртөйледән дә, Өчмунчадан да, Дүртмунчадан да... Сәләтләре, әйтер сүзләре бар икән — бала чактан килсеннәр! Пионер матбугатында, шушы китапларда беренче язмалары басылган авторлар арасыннан М. Әгъләмов, Р. Низамиев, З. Мансуров, Ф. Сафин, Р. Бәшәров, Р. Тимершиннар үзенчәлекле язучылар булып үсеп китте. Димәк, мәктәп яшендәге нәни иҗатчылар белән эшләү тәҗрибәсе үзен аклый.

Күптән түгел Язучылар союзына унынчы класс укучылары Ркаил Зәйдуллин (Чувашстаннан) һәм Ләис Зөлкарнәевне (Башкортстаннан) чакырып алып, өлкән язучылар катнашында зур сөйләшү үткәрдек. Аларның инде «минә бу ичмасам шигырь» дип әйтерлек, өлгергән, профессиональ дәрәҗәдәге шигырьләре бар. Традицион да, яңа да! Мең яшьлек поэзиябез әнә шундый яшьләр хисабына яшәрә, тулылана барсын! Ркаил һәм Ләис, безнең рекомендация буенча, югары уку йортларына керергә әзерләнәләр.

Моннан ике ел элек, рус секциясе 17 яшьлек Аяз Хәсәновның табигать турында язылган үзенчәлекле хикәяләрен тикшергән иде. Менә быел инде аның Татарстан китап нәшриятында беренче китабы басылып чыкты. Бик яшьли кызыклы прозаик килә әдәбиятка!

Татарстан китап нәшрияты һәр елны яшь авторларның 10—15 китабын бастырып чыгара. 1978 елда да яшьләрнең 15 китабы дөнья күргән. Рус телендә чыккан «Город моей мечты» җыентыгында КамАЗ төзүче 27 авторның әсәрләре тупланган. Соңгы дүрт елда рус телендә биш коллектив җыентык чыкты. Әмма коллектив җыентыкларны төзүгә тагын да таләпчәнрәк карарга кирәк. Кайбер җыентыкларда яшь авторларның шигырьләре бер-берсеннән фамилияләре белән генә аерылып торалар, аларда нинди дә булса үзенчәлек табу мөмкин түгел. Нәшрият «Яшь шагыйрьнең, яшь тәнкыйтьченең беренче китабы» дигән серияне укучыларга тәкъдим итә

башлады. Р. Миңнуллин, Р. Вәлиев, Ф. Сафин, М. Вәлиев, М. Галиев, З. Мансуров, Ә. Гадел, Э. Мостафин китапларында соңгы елларда килгән яшь әдипләребезнең эзләнүләре, табышлары, яңа сүз әйтергә омтылышлары ачык күренде. Китаплары тәкъдим ителгән Ф. Гыйльметдинов, Н. Гиматдинова, Р. Мөхәммәдиев, Р. Кукушкин, Н. Измайлова, Л. Шакирҗанова, Р. Низамиев, Р. Юнусов, Х. Әюпов әсәрләрендә дә 70 нче еллар кешесенең уй-хисе, хезмәте, мәхәббәте һәрберсендә үзенчәлекле ачылыш тапкан. 18 яшь шагыйрәнең шигырьләреннән төзелгән «Кызлар җыры» җыентыгы да җылы каршыланды.

Үз эшенең остасы булган яшьләрне кабул итү комиссиясе Язучылар союзына алырга әзер тора. Бу комиссиянең составында С. Хәким (председатель), Т. Журавлев, А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин, Н. Юзиев һәм Р. Даутовлар эшли. 1974 елдан бүгенге көнгә кадәр комиссия аша СССР язучылар союзы члены булып 26 яшь язучы үткән. Бик күп яшь көчләре булган оешмабыз өчен бер караганда, бу бик аз. Әмма бу сан безнең оешманың сан артыннан кумавын, яшь язучыларга искиткеч зур таләп белән килүен дә күрсәтә. РСФСР Язучылар союзы секретариатында эшебезгә әйбәт бәя биргәндә, безгә бу сыйфатыбызны басым ясап әйттеләр. Өлкән иптәшләрнең әйтүенә караганда, Ватан сугышына кадәр Язучылар союзы членнарының саны утыздан артмаган, әмма аларның барысы да диярлек әдәбиятта исемнәре калырлык шәхесләр булганнар. Тик шулай да, таләпне киметмичә, оешмабызны яшәртү, сыйфат хисабына санны арттыру турында да даими кайгыртып торырга кирәк.

Яшь язучыларның беренче әсәрләренә путевка биргән «Идел» альманахы елга ике тапкыр 10.000 данә тираж белән чыга башлады. Анда басылган әсәрләрнең идея-художество дәрәҗәсе күтәрелде, альманах үзе дә журнал кыяфәтен ала бара. Хәзер редакция портфелендә 58 табак күләмендә повестьлар, 40 хикәя, бик күп шигырьләр бар. Елдан-ел сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да үскән яшь иҗат көчләре матбугат мәйданына сыймый башлады. «Идел» альманахын журнал итү мәсьәләсе моңа кадәр бик күп җыелышларда күтәрелгән иде. РСФСР язучылар союзы секретариаты да безнең үтенечне хуплады. Үтенечебезнең уңай хәл ителүен көтеп калабыз һәм яшьләр өчен әдәби журнал булыр дип ышанабыз.

Яшьләрнең белемен күтәрүгә дә зур игътибар бирелә. Талантлы яшьләрне югары уку йортларына тәкъдим итәбез. Ризван Хәмидуллин драматурглар курсын, 8 яшь язучы читтән торып М. Горький исемендәге әдәбият институтында укыйлар. Чаллыдагы «Орфей»чылар үз берләшмәләрен шаярып «әдәбият институтының филиалы» дип атыйлар. Бу институтны үткән ел тәмамлаган тәрҗемәчеләребез иҗат эшенә тотындылар. Соңгы елларда безнең татарчадан турыдан-туры тәрҗемә итә торган үз кадрларыбыз үсеп чыкты. Равил Бохараев, Солтан Шәмсетдинов, Рәшит Ахунов, Рөстәм Хәкимов, Роза Кожевниковаларның җитди адымнары бигрәк тә сөендерә.

Яшь әдипләребез бөтенсоюз күләмендә үткәрелә торган чараларда да актив катнашалар. Яшь язучыларның VI Бөтенсоюз киңәшмәсендә катнашкан Ә. Гаффаров, Р. Бохараев, М. Галиев һәм Равил Вәлиевләрнең иҗатларына әйбәт бәя бирелгән иде. Быелгы киңәшмәгә безнең оешмадан Н. Гыйматдинова, Р. Ахунов, Е. Кувайцев, П. Юлаев, Н. Алешков бардылар.

Яшь алмашны тәрбияләү эшендә безнең оешмабыз, күренгәнчә, шактый тәҗрибә туплады. Әмма әле алда хәл итәсе күп кенә мәсьәләләр бар. Яшь язучыларны политик-әхлакый тәрбияләү эшенә барлык язучылар да тартылмаган. Күп кенә яшь язучыларыбызның тормыш белән бәйләнешләре йомшак, эрудицияләре чамалы, шунлыктан аларның әсәрләрендә халкыбызның бай рухи тормышы сай чагыла, тормышчанлык, фәлсәфи тирәнлек җитми. Тормышның эчендә кайнап та, әдәби осталык җитмәгәнлектән, уңышсыз әсәрләр язылу очраклары да бар. Иҗтимагый активлык, гражданлык өлгергәнлеге аз булу нәтиҗәсендә кайбер яшьләрнең әсәрләрендә авторның тормышка актив мөнәсәбәтен күрү кыен. Киләчәктә бу кимчелекләрне булдырмау өчен, яшь кадрларны идея-әхлак яктан тәрбияләүдә оешмабызның һәрбер коммунисты, һәрбер язучысы үзен җаваплы тоярга тиеш, КПСС Үзәк комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карары безне әнә шуңа чакыра.

Яшь авторлар белән эшләүне киләчәктә тагын да яхшырту, камилләштерү максатыннан чыгып, Язучылар союзы идарәсе перспектив эш планы төзеде. Киләсе елларда да, республикабызның барлык иҗат көчләрен барлап чыгу өчен, зона конференцияләре, семинарлар үткәреләчәк.

Әдәби алмаш хәзерләү — һәр вакыт игътибар үзәгендә. Әдәбиятыбызның хәзерге халәте төрле буынның бер кайчан да күрелмәгәнчә бердәмлеге, киләчәктә тагын да көчлерәк булырга омтылышы белән аерылып тора. Аның агымы көчле, ташкын булып килүче елгалары да, ачылмаган чишмәләре дә чиксез. Моннан мең ел чамасы элек Кол Галиләрдән башланган әдәбиятыбыз шәҗәрәсенең очы сезнең кулларда, яшь каләмдәшләр. Каләм, акыл һәм йөрәк белән халыкка партиябезгә хезмәт итү — мактаулы һәм җаваплы вазыйфа — сезгә көчә бара, яшь талантлар! Үз-үзеңә таләп, талант, гражданлык сыйфатларын бермә-бер көчәйтеп, яңа биеклекләргә — Тукай, Ибраһимов, Такташ, Җәлилләр һәм бүген безнең арабызда яшәгән остазларыбыз күтәрелгән югарылыкка ирешик! Яшь талант тарихта күрелмәгән тиңсез төзелешләр, яңа мөнәсәбәтләр тудырган, хәтта йөрәк тибешен дә тизләткән бөек чорыбыз дәрәҗәсенә күтәрелсен! Бүген башланган, киләчәктә язылачак иң камил әсәрләрегездән сәлам сезгә, кадерле дуслар!

Геннадий Паушкин

# АЛГА БАРЫРГА КИРӘК

„Безнең артта шундый күренекле әдәбият, шундый алыплар таудай калкып тора ки, укучыларны алардан бер генә көнгә яки сәгатькә аерыр өчен дә һәрберебез башта моңа нинди хакы барлыгын уйлап карарга тиеш»,— дигән иде Виктор Астафьев.

Безнең бүгенге әдәбиятыбыз да югары үрләргә күтәрелде, әсәрләре совет классикасына әверелгән Чыңгыз Айтматов, Виктор Астафьев, Юрий Бондарев, Василь Быков, Валентин Распутин, Юрий Трифонов, Василий Шукшиннарга борылып карамыйча язу хәзер инде мөмкин түгел. Хәзер инде без язучыларны башкала яки өлкәнекенә бүлеп маташмыйбыз: кендеге кайда берегүенә карамастан, барыбызның да юлы бер генә — әсәрләрең заманнан, тирәлектән аерылса һәм үле тел белән язылса, провинциалга әйләнүеңне көт тә тор.

Без йөрәктә һәм хәтердә калганны язабыз. Хәтер исә вак, әһәмиятсез нәрсәләрне вакыт иләгендә иләп, асыл таштай кадерле бөртекләрне генә саклый. Кайчагында без кичәгене онытып, күп еллар элек булганнарны истә тотабыз. Революция һәм гражданнар сугышы ветераннары үзләре көрәшкән давыллы елларны, без исә Бөек Ватан сугышының озын юлларын онытмыйбыз. Хәтер күрү сәләтебезне көчәйтә, вакыт арасы безнең буын михнәт чигеп туплаган тарихи тәҗрибәне кабат баштан кичерергә мәҗбүр итә. Сугыш турындагы иң яхшы китапларыбыз прозабызда басымның вакыйгалар хроникасын бирүдән психологик, әхлакый якларны яктыртуга күчүен, ә моның үз нәүбәтендә социаль-фәлсәфи гомумиләштерүгә алып килүен күрсәтә. Бөек Ватан сугышы темасының торган саен тирәнәя барачагы, киң колачлы яңа эпик яңгыраш үрләренә күтәреләчәге ачык. Ватан сугышы темасының саегасы юк — сугыш һәм тынычлык мәсьәләләрен кырыс сыналу елларына борылып карамыйча хәл итү мөмкин түгел.

Ватан сугышы хакында илле ел, йөз ел үткәч тә язарлар, әмма Казан язучысы Т. Журавлевның рядовой Антиповы барыбер сафта калыр. Әгәр хәрби әдәбиятыбызның барлык каһарманнарын да саный башласак, В. Мальцевның «Вакыт чиге артында» повестендагы солдатлары да, Д. Сычев, В. Костригин һәм А. Королев тасвирлаган егетләр дә, башка хикәя һәм повестьларыбыздагы геройларыбыз да бергә җыйналса, тулы бер гвардия отряды тупланыр иде. Безнең һәрберебез, сәләтебез мөмкинлек биргәнчә, егерме миллион гомерне кискән сугышның көннәрен һәм сәгатьләрен — вакытны гәүдәләндерергә тырышабыз. Элекке взвод командиры В. Мальцев «Тынлыкны саклау анты» повестенда тау башында оборона тоткан ротаның үзенең барлыгын белгертмәү өчен тавыш чыгармаска ант итүен һәм шул антны бозмыйча Карпат сыртында һәлак булуын әдәби тәҗрибә туплаган прозаикның нык кулы белән язып чыкты һәм шулай коралдашлары алдындагы изге бурычын үтәде. Бу фаҗигале хикәя укучыларны битараф калдырмас дип уйлыйм. Казан язучыларының сугыш темасына иҗат ителгән повестьларында һәм хикәяләрендә уйлап чыгарылган берни дә юк. Ул әсәрләрнең барысы да фронт юлларын үзләре белән бергә узган кешеләргә багышланган.

Прозаикларыбызның әсәрләре һаман документальлеккә таба омтылган, укучыларның ихтыяҗларына сизгер җавап биргән хәзерге совет әдәбиятының төп үсеш юлына аваздаш. «Кысылган секундлар мизгеле» исемле очерклар китабын чыгарганчы Н. Орешинага очучы осталыгы һәм күнекмәләрен үзләштерергә туры килә. Ул планерчылар белән оча, беренче категория судья таныклыгын ала, зона ярышларында катнаша, парашютта сикерә. Орешина тавыш тизлегеннән тизрәк оча торган самолетларны да идарә итә. Кайда да акыллы, яхшы күңелле кешеләргә тап була. Бу китабын ул әнә шул танышларына, иптәшләренә һәм дусларына багышлый.

Язучы тормышы җиңел булмый, китабыбызның һәркайсы безгә җиңел генә бирелми. «Щельяда сәяхәт» әсәрен язар өчен М. Скороходовка моннан йөзләрчә ел элек легендар Мангазеяга салынган юл буйлап диңгезче Буторин белән карбаста өч мең чакрым йөзеп үтәргә туры килә. Бу китапта укучыларның, бигрәк тә маҗаралар белән мавыгучы үсмерләрнең мәхәббәтен казанды.

М. Елизарованың шул исемдәге пьесасы буенча «Давыл хәбәрчесенең яшьлеге» дип аталган китабына якташларыбыз турында хикәяләр һәм очерклар да тупланган. Шаляпин, Деренков, Горькийның дусты Иван Картиковский, Н. К. Крупская турындагы очеркларның кызыксыну уятуын әйтеп китәргә кирәк.

Безнең һәркайсыбызның эшкәртә торган үз кишәрлеге, үз темасы бар. Өлкән

язучыбыз С. Б. Радзиевская үзенең бөтен иҗатын балаларга багышлады, табигатькә, барлык җан ияләренә мәхәббәт тәрбияли торган дистәләрчә кызыклы китаплар язды.

Соңгы биш елда рус секциясе членнары утызлап китап бастырды. Үзәк нәшриятларда Р. Кутуй, Д. Вәлиев, Ю. Белостоцкийларның проза җыентыклары, И. Кәлимуллинның шигырьләр китабы чыкты. Безнеңчә, Р. Кутуйның «Хикәяләр һәм повестьлар»ы — 1978 елның иң яхшы китабы.

Күптән түгел без Ярослав Гашекның безнең туган республикабызда да яшәвен һәм көрәшүен озак еллар өйрәнгән С. Антоновны Язучылар союзына тәкъдим иттек.

Н. Беляев «Казан дәфтәре» исемле яңа шигырьләр китабы әзерләде, аңа күренекле шагыйрь Сибгат Хәким сүз башы язды. «Китапта бар да бар — мәхәббәт һәм яшьлек, көнкүреш мәшәкатьләренә күмелгән анага багышланган шигырьләр, көндәлек ыгы-зыгылардан туйгач, асылган керләрен күлдәвекләр буйлап сөйрәп киткән наратлар турында, сугыштан соңгы базар турында язылган шигырьләр дә... Кеше һәм табигать, шигърият һәм геология, Русия тарихы, рус әдәбияты вәкилләре Радищев, Герцен...» Китап еллар буе күңелдә йөри, «тынлык дәвамлырак булган саен, сөйләм гаҗәбрәк».

Н. Беляевның татарчадан бик күп шигырьләр тәрҗемә итүен, күренекле татар шагыйрьләренең байтак әйбәт әсәрләре рус укучысына аның хезмәте аркасында барып җитүен дә әйтергә кирәк.

«Современник» нәшриятында «еллар кырыс прозага этәрсә» дә, шигърият белән аерылышмаган Р. Кутуйның шигырьләре басылырга әзерләнә. В. Модестов хезмәт командировкасыннан «Алжир шигырьләре» циклы белән кайтты. В. Лавришко КамАЗ төзүчеләр хакында поэма язуын дәвам итә.

Без ике съезд арасында барлык жанрларда да чыгыш ясадык дигән идем. Әмма романчыларыбыз бу чорда тынлык саклады. Киләчәктә К. Лебедев һәм Я. Винецкий да телгә килер дип өметләнәбез.

Ике съезд арасында Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты драматург Д. Вәлиевнең таланты ачылып китте. Аның беренче пьесасы «Сиңа тормыш бүләк итәм» илебезнең кырыклап сәхнәсендә куелып, яшь автор исемен бөтен Союзга таратты. Икенче пьесасы «Диалоглар» да уңыш казанды. Былтыр исә нәшриятыбызда «Намус хөкеме» җыентыгы дөнья күрде. Китапка өч драматик повесть кергән, хәзер инде тамашачылар гына түгел, укучылар да пьесаларында заманыбызның үткен мәсьәләләрен кузгаткан талантлы драматургның иҗаты белән таныша ала. Чынбарлык күренешләрен фәлсәфи кабул итү, тормыш процессларының асылына үтеп керү, кешене җәмгыять алдындагы, кешеләр алдындагы бурычы белән бәрелештерә торган хәлләрне барлау һәм башка әхлак мәсьәләләрен күтәрү яшь язучының пьесаларын югары гражданлык проблемалары хәл ителә торган бүгенге драматургиябезнең алгы сафына чыгарды.

Партиябез ҮКның иҗади яшьләр белән эшләү турындагы карары безгә яшь алмаш тәрбияләүнең күп кенә мәсьәләләрен тиз арада хәл итәргә булышты. Чаллыдагы «Орфей», М. Горький музее каршындагы әдәби берләшмәләр дә нык һәм үсте. Рус телендә башлап язучыларның биш күмәк җыентыгы басылды. «Гасыр чалымнары», «Кавышу», «Икмәк һәм розалар» дигән шигырь җыентыкларында, «Шаулама, арыш» исемле хикәяләр китабында һәм «Орфей»чыларның шигырьләр һәм проза җыентыгы «Хыялым шәһәре»ндә алтмыш авторның әсәре дөнья күрде. Хәзерге вакытта «Орфей»чыларның алтысы М. Горький исемендәге әдәбият институтында читтән торып укый. Яшь язучыларның Бөтенсоюз киңәшмәсендә Н. Алешков, Е. Кувайцев, И. Лимонова һәм П. Юлаевлар катнашты. Казан шагыйрәсе Э. Блинова Агния Бартода семинарда булды. Әлмәттә күптәннән бирле В. Мальцев җитәкли торган әдәби берләшмә эшли. Анда әсәрләре инде республикабыз укучылары арасында танылган Д. Матвеев һәм И. Винокуровалар активлык күрсәтә. Ике съезд арасында уздырылган семинарларда һәм рус секциясе утырышларында без йөздән артык яшь авторның иҗатын тикшердек. Әмма Язучылар союзына член итеп кырыктан узганнарны гына кабул иттек. Безгә яшьрәк авторларга игътибарны көчәйтергә, алар белән аерым эшләргә кирәк.

Әдәбиятыбыз киңлеккә үсә төсле, әмма шул ук вакытта бездә тәзек һәм «шома» язучылар да күбәйде, тагын егерме елдан соң да үзешчән булып калачак үзешчән шагыйрьләр үрчеде. Шулар арасыннан чын талантларны табасы бар: илһам ясалма булмаган җирдә генә шигърият тишелеп чыга.

Мин рус секциясенең казанышлары хакында сөйләдем. Хәзер инде хәл ителмәгән бурычларны да искә алыйк. Без әле бүгенге көннең үткен проблемаларын күтәргән һәм совет әдәбиятында вакыйга булырлык әсәрләр, замандашыбыз турында яхшы повестьлар һәм романнар иҗат итә алмадык. Югыйсә моның өчен бөтен шартларыбыз бар, кызыклы тормыш материалы, конфликтлы вакыйгалар эзләп тә әллә кая барасы юк.

Әдәбиятта кыялар булган, бар һәм булачак. Соңгы бишьеллыкта без биек калкулыкка күтәрелдек һәм алдагы үрнең тагын да текәрәк булуын, аңа менү өчен күп көч һәм гайрәт кирәк икәнлеген күрдек. Тик башка чара юк — алга барырга кирәк.

**Әдип Маликов**

# ҺӘРВАКЫТ ЮЛДА

Полк разведкасында хезмәт иткәндә шулай була иде: хәрби өйрәнүләрдә яки сугышка кергәндә безнең разведка взводын бүлгәләп, өләшеп бетерәләр. Полк штабына да, дивизия штабына да кирәгебез чыга. Дошман тылына да җибәрәләр. Взвод командиры соңыннан исән-сау калганнарны җыеп барлый башлый.

Әлмәт бүлеге язучыларының иҗатлары барлык докладларга сибелде. Кабыргалар сынмады шикелле... Мондый зур, кайнар чыгышлардан соң, миңа иң ахырдан перекличка ясарга гына кала.

Үткән белән бүгенге арасында гаҗәеп зур аермалык яши. Без аны Татарстанның нефть районнары индустриясе пейзажы, андагы киң колачлы төзелешләр адымы һәм халык культурасының үсеше аша бигрәк тә ачык күрәбез.

Элек даннары басу капкасыннан узмаган, салам ягып, кап, чыпта сугып, чабата үреп көн иткән авылларның исемнәре нефть мәйданнарына күчте, завод, шәһәр исемнәренә әйләнде. Байлыкларын бизмәнгә салып үлчәгән, төенчеккә төйнәп йөрткән халык бүген миллиард сумнар, миллион тонналар белән эш итә.

Керосинга тилмереп яшәгән бабайларыбызның уллары, кызлары, оныклары бүген нефть, газ идарәләрен җитәклиләр. Хезмәт батырлары, нефть якларының үз галимнәре, язучылары үсеп чыкты.

Әлмәт тирәсеннән, урман эчләп, Уфа якларына яшерен юл — ат караклары юлы узган. Хәзер аннан дөньяда тиңе булмаган Самотлор — Уфа — Әлмәт нефть магистрале сузылды, ул бөек «Дуслык» юлына килеп кушылды. Ил табынына җир байлыгы агыла. Җир байлыгы белән бергә, рухи азык бара.

Нефть якларында яшәүче язучыларның әсәрләре бүген Татарстан чикләрен узып, рус, украин, башкорт, чех телләренә тәрҗемә ителәләр, тугандаш республикалар телләрендә яңгырыйлар.

Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлеге төзелешләр шау-шуы эчендә, Татарстан нефть индустриясе белән бергә үсеп чыкты. Әдәби разведкадан — публицистик мәкаләләрдән, очерклардан башлап, «Хәзинә», «Каты токым» кебек бөтен илгә танылган романнарга, шигъри репортажлардан — күләмле поэмаларга килде.

Әлмәт бүлеге 14 союз членын берләштерә. Ике съезд арасында 4 союз членына артты: Х. Хәйруллин, Җ. Рәхимов, А. Ганиев, В. Мальцев. Соңгы биш ел эчендә Казан һәм Мәскәү нәшриятларында, тәрҗемәләрне һәм кабаттан басылганнарны да исәпкә алсак, авторларыбызның иллеләп китабы басылды. Шулар арасында без М. Хәсәновның «Кама таңнары», Р. Төхфәтуллинның «Акбүз ат», Ш. Бикчуринның «Алтын җирдә ятмый» повестьлар, хикәяләр җыентыкларын, Хәниф Хәйруллинның «Картлык... кемгә шатлык!», Җ. Рәхимовның «Өлешемә тигән көмешем», В. Мальцевның «За чертой времени», Г. Кашаповның «Сәмум җиле» повестьларын, Ю. Әминовның, С. Кальметовның пьеса җыентыкларын күрәбез. Шулай ук «Казан утлары» журналында С. Сөләйманованың «Гөлбадран», Р. Төхфәтуллинның «Китә казлар», Ф. Гыйльметдиновның «Урсай тау итәгендә», Хәким Хәйруллинның «Ургыл» романы, балалар өчен Җ. Рәхимовның «Девон хәбәрчесе», М. Хәсәновның «Диназаврлар өнендә», «Шайтан малае», «Без алтынчы «А»дан» («Ялкын») кебек повестьлары дөнья күрде.

С. Сөләйманованың «Кызыл каурыйлар», К. Булатованың «Һәр язның үз җыры», Р. Бәшәровның «Бәйрәм» исемле шигырь җыентыклары чыкты.

Шигырь китапханәсеннән Г. Афзалның «Айлы кичләр» исемле җыентыгы Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясенә лаек булды, хезмәт кешесе темасына үткәрелгән бөтенсоюз конкурсында Ш. Бикчурин иҗат иткән «Каты токым» романының бүләкләнүе барыбыз өчен дә сөенечле хәл.

Очерк, сугышчан жанр буларак, һәр вакыт алга юл ярып бара, һәр вакыт разведкада.

Җәмит Рәхимовның «Батырлык чакрымнары» исемле очерклар китабы укучыларның игътибарын үзенә тартты. Себер якларында иҗат командировкасыннан йөреп кайткач, автор бай материал арасында югалып калмаган, ә иң кирәкләрен, типик булган күренешләрне, вакыйгаларны сайлап ала белгән. Самотлор — Уфа — Әлмәт нефть үткәргече маршрутындагы очрашулар, аларның батыр хезмәтләре хәтердә уелып калырлык, кызыклы тормыш детальләре аша бирелгән.

Ат караклары үзләренең гөнаһларын яшерү өчен аулак юллар сайлаганнар. Ә нефтьче-төзүчеләр юан торбаларны кешеләргә, табигатькә, иген кырларына уңайлы булсын өчен яшерәләр җир куенына. Күзгә күренмәс магистральләр буйлап, меңнәрчә километрларга күпме яшерен энергия, күпме чимал агыла! Эшелоннарга төялеп түгел, ә «үз аягы» белән бара нефть. Торба салучыларның күзгә күренмәс батыр хезмәтләре гасырлар данына торырлык.

Җ. Рәхимовның Себер юлларындагы бай тәэсирләре очерк рамкалары белән генә чикләнмәс. Алар масштаблы, киң колачлы повесть яки романга заявка сыман.

Басылган әсәрләребез арасында хезмәт кешесе һәм замандаш образларын үзәккә куйган, бүгенге чынбарлыктан актуаль мәсьәләләрне күтәргән җитди әсәрләр шактый.

Соңгы елларда нефтьчеләр тормышын чагылдырган проза әсәрләре арасында Җ. Рәхимовның «Өлешемә тигән көмешем» повесте үзенә бер урын алып тора. Атилла абзый бу әсәр турында әйтте. Геройлары — безгә таныш, күңелебезгә якын кешеләр — республикабыз йөзен үзгәртеп коручы нефтьчеләр, төзүчеләр, игенчеләр, бай күңелле, намуслы, ярдәмчел кешеләр. Производство һәм кеше язмышы әсәрдә бер тукыма тәшкил итә, бергә үрелеп бара.

Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк, «Современник» нәшрияты тормыш эчендә туган, заман сулышы бәреп торган әсәрләргә һәр вакыт өстенлек бирә. Аның Татарстан авторларына еш мөрәҗәгать итүе юкка гына түгелдер. Әлмәт бүлегеннән Ш. Бикчурин, Р. Төхфәтуллин, С. Сөләйманова китаплары чыгуга, хәзер М. Хәсәновның «Саумы, кояш», Х. Хәйруллинның «Ургыл» исемле романнары редакцияләнеп ята.

Җ. Рәхимов күзгә күренеп үсә, ул нефтьчеләр тормышын яктырту ягыннан соңгы елларда шактый күп эшләде. Девон нефтен ачучы батырларыбыз, аларның күп кырлы хезмәте, Татарстан нефть индустриясенең туу турында, Г. Ахуновның «Артышлы тау итәгендә» повестеннан башка, балалар өчен әсәрләр юк чутында аз иде.

Җ. Рәхимовның «Ялкын» журналының берничә санында басылган «Девон хәбәрчесе» повесте бу бушлыкны тутыруда яңа бер адым. Шөгер якларында беренче нефть скважинасын бораулый башлау, бораулаучылар тормышы, бу яңалык уңае белән, авыл кешеләренең уй-фикер йөртүләре балаларча самими, тапкыр тел белән сурәтләнгән. Шулар арасында кечкенә Җәмит үзе дә йөгереп йөри шикелле.

Җ. Рәхимов тормышны тирәнтен белеп, эченә кереп яза. Аның шушы нефть чыккан якларда туып үскән булуы, шул як кешеләре белән якыннан аралашып, алар белән бер коллективта эшләп, бер һаваны сулап яшәве һәр әсәрендә сизелеп тора. Бу хәл исә әсәргә табигыйлек бирә, укучыны ышандыра, артыннан ияртә.

Яшь язучы Фәрит Гыйльметдинов та әдәбиятта уңышлы адым ясады. Аның нефть вышкалары төзүче яшьләр тормышыннан алып язылган «Урсай тау итәгендә» исемле повесте безгә сөенеч китерде. Тәнкыйть аны шунда ук күреп алды. Әле мәктәп эскәмиясеннән генә килгән, эшчеләр коллективына яңа аяк баскан Әндәм. Аның алдында яңа дөнья, яңа кичерешләр. Аңарда бүгенге яшьләребезнең күркәм сыйфатлары — эзләнү, яңага омтылу, торгынлык һәм катып калганлык белән килешмәүчәнлек кебек сыйфатлар шактый калку чагыла. Ф. Гыйльметдинов хәзер электр батырма насослар заводында инженер булып эшли. Бүгенге эшче психологиясен тирән өйрәнеп, зур проблемалар күтәргән проза әсәрләре бирергә аның инде хәзерлеге бар, теле үткен, юморга бай. Завод әле төзелеш чорын кичерә. Яңа техника сынала, кешеләр сынала. Нефть промышленностенда торкан урыны һәм эш масштабы ягыннан бу завод дөньякүләм әһәмияткә ия булачак. Шундый коллектив эчендә кайнап яшәү яшь язучы өчен зур бәхет.

Тегерменгә керсәң, онга буялмыйча чыкмыйсың, диләр. Драматург Ю. Әминов Миңлебай газ эшкәртү заводы цехында эшләп алгач, завод тормышыннан «Кан кардәшләр» исемле пьеса биргән иде. Шуннан соң ул бораулаучылар бригадасына беркетелде, үзенең элекке укучысы, хәзер атаклы бораулау остасы, Дәүләт премиясе лауреаты Дамир Нуретдинов кул астында эшләде. Бораулаучылар тормышын колачлаган «Сөймим дисәң дә» исемле җитди комедиясе иҗат ителде. Остазлар һәм шәкертләр, уртак эшкә мөнәсәбәт — вакыйгалар шул тирәдә. КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарында болай диелә: «Җитәкчеләрнең, хуҗалык кадрларының эшенә бәя биргәндә, производство планнарын үтәү күрсәткечләрен генә түгел, бәлки коллективта дисциплина дәрәҗәсен, моральполитик климатны, хезмәт һәм көнкүреш шартларын да исәпкә алырга кирәк». Бу сүзләрдә гаять тирән мәгънә ята. Ю. Әминов «Сөймим дисәң дә» әсәрендә нәкъ әнә шул мораль-политик климатны ачып бирергә омтыла да. Ике бригада арасында ярыш мавыктыргыч, ышандырырлык детальләр аша гәүдәләнә. Кырыс та, мөлаем да Гамир һәм Ядкәрнең җанын, күңелен күреп-аңлап, алар белән бергә рухи баеп барасың. Монда метр күрсәткечләре өчен генә түгел, ә кешеләрнең сафлыгы, рухи матурлыгы, кеше җанының гүзәллеге өчен көрәш бара.

Ю. Әминов берөзлексез эзләнә, иҗатында яңара бара. Хәзер Әлмәт театрында зур уңыш белән барган «Очрашырбыз, Гөлсылу» комедиясе урта мәктәпне тәмамлап, ВУЗга керү теләге белән янып йөргән яшьләргә багышланган. ВУЗга элегү авырлыкларын үзләренә табыш чыганагы итеп файдаланучы кайбер намуссыз затлар кискен рәвештә фаш ителә бу комедиядә. Мораль һәм этик тәрбия бирү ягыннан «Очрашырбыз, Гөлсылу» спектакле дә, һичшиксез, үзенең ролен үтәячәк. Ю. Әминов эзеннән яшь драматург Фоат Садриев үсеп килә. Аның үз юлына, олы драматургия юлына чыгуына шик юк.

Язучыларыбыз әсәрләрендә төрле темаларга мөрәҗәгать итәләр. Чөнки тормыш үзе дә күп кырлы. Р. Төхфәтуллинның «Китә казлар», В. Мальцевның «За чертой времени» повестьлары, яшь язучы Г. Кашаповның «Сәмум җиле» повесте Бөек Ватан сугышы героикасын, тылдагы кешеләрнең батырлыкларын һәм Совет Армиясенең бүгенге тормышын чагылдыр-

са, Хәниф Хәйруллин «Картлык... кемгә шатлык?» повестенда колхоз тормышы фонында мораль, әхлак мәсьәләләрен күтәрә. С. Сөләймәнованың «Гөлбадран» повесте медицина һәм сәнгать кешеләренә багышланган.

Р. Төхфәтуллин менә утыз елга якын инде укучыларын яңадан-яңа хикәяләр, повестьлар белән сөендереп тора. Кеше кичерешләрен ул табигать тасвиры янәшәсенә куеп ачарга ярата. Кеше табигатьтән үзенә көч, дәрт, моң ала. «Китә казлар» повестендагы казлар каңгылдавы әле колак төбендә. Йөз чакрымны тәпиләп килгән, фронт ягына юл тотучы казлар... Тылның фронт белән бәйләнеше, сугыш чорының кыенлыклары тетрәндергеч детальләр аша, Бауман урамына сыеша алмый барган казларның үзәк өзгеч каңгылдавы аша, хәтердә калырлык итеп, оптимистик рухта тасвирлана. Р. Төхфәтуллин әсәрләрендә хезмәт кешесе образы төп урынны алып тора. Тормыш, хезмәт һәм иҗат. Менә шул бердәмлек булмаганда, чын мәгънәсендә тормышчан сәнгать әсәрләре тудыруы кыен. Ул яктан безнең нефть районнарында яшәүче язучылар бәхетле. Аларның күпчелеге производстводан аерылмыйча иҗат итәләр. Әлбәттә, моның кыен яклары да бар. Ә ахыргы нәтиҗә барыбер уңай якка.

Халык белән аралашып, тормыш белән бер сулышта яшәү иҗатка уңай йогынты ясамыйча калмый. Үзенең бай тормыш биографиясе булган язучы иҗатында да үз юлы белән бара, ул башкаларны кабатлауга мохтаҗ түгел.

Шагыйрьне үз чоры белән конкрет шартларда гына күз алдына китерергә мөмкин.

**Гөлләрең шиңгәндә,**
**Кайгылар килгәндә,**
**Дөньяда мин барын онытма!**

Шагыйрь җаны менә шундый. Ул синең яклаучың, авыр минутларда көч, рух бирүчең булып килә. Кеше шатлыгын урлап йөрүчеләргә нәфрәт белдерә. Ил кайгысы белән кайгыра, ил шатлыгы белән шатлана. Г. Афзалның «Борылам да карыйм» циклыннан алынган бу юллар аның бөтен иҗатына хас.

«Айлы кичләр» исемле җыентыгына кереш сүзендә филология фәннәре докторы Нил Юзиев болай ди: «Безне шагыйрьнең ирләрчә кыюлыгы, түземлелеге, авырлыкларга баш имәве, тормышка олы мәхәббәте, куйган максатыннан тайпылмыйча, дөньядан олы хәзинә эзләве үзенә тарта, сокландыра». Әйе, шагыйрь максатына кыю бара, дөньяга горур карый, һәр адымда үзен көрәшче итеп сизә.

Шагыйрә С. Сөләймәнованың «Казан утлары» журналында басылган «Сузган ике кулым» шигыре — туу һәм кешенең тормыштагы урыны турында, кешелекле булу турында фәлсәфи уйланулар. Шагыйрә төчеләнми, кыланмый, шигырьләрендә — ихлас чынбарлык, табигатьнең һәр үләненә сөенә белү, зур тормыш өчен көрәшү пафосы. Бу сыйфатлар аның соңгы елларда Казанда, «Советский писатель» һәм «Современник» нәшриятларында басылып чыккан «Красные перья», «Предсказанье» исемле шигырь җыентыкларында ачык чагылыш тапты.

Шагыйрә К. Булатованың шигырьләре «Казан утлары», «Азат хатын» журналларында, республика газеталарында, «Кызыл таң»да еш күренә. Шагыйрә күзәтүчән, шигырьләре тормыштан килә. Уңышлы лирик шигырьләре арасында җиңел кулдан язылган шигъри репортажлар да очрап куя. Әйтергә кирәк, талантын тулы көченә җикми шагыйрә. Көрәсең, укытучылык хезмәте аның вакытын күбрәк суыра.

Соңгы елларда яшь шагыйрьләребез шактый активлашты. Нур Әхмәдиев, Роберт Рәкыйпов, Венера Туктарова, Таһир Шәмсуаров, Шәрига Таһирова — һәр кайсы үз юлы, үз моңы белән, тормышның үзеннән килә торган өметле иптәшләр. Нур белән Робертның шигырь җыентыклары Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителде.

Барлык яшь шагыйрьләргә хас уртак кимчелек: күләмле әсәрләргә, поэмаларга тотынырга кыюлыклары җитми. Шигырьләрендә еш кына тема тарлыгы үзен сиздерә, олы язмышларга мөрәҗәгать җитми. Масштаблы фикер йөртү һәм хезмәт кешесе образын зур итеп күтәрү ягыннан «Казан утлары» журналында басылган «Белоглазов урамы» шигыре аерылып тора. Авторы — нефтьче-инженер Илдар Әхсәнов. Кайнар кеше турында кайнар шигырь. Девон нефтенә гомерен багышлаган атаклы бораулау остасы Михаил Белоглазов истәлегенә багышлана. Кайнар йөрәк тибешен девон сулышына биреп яшәгән бораулау остасының хезмәте мәңгелек. Бүген ул өйләрне, калаларны җылыта, туган җирдән алгы сызыкка җыр булып агыла.

Әдәби алмаш турында кайгырту торган саен активрак, конкретрак төс ала бара. Партия Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы мәгълүм карары моңа аеруча зур этәргеч бирде. Вакытлы матбугат битләрендә, радио, телевидение тапшыруларында яшь каләмнәр иҗатына һәр вакыт яшел урам. Иҗат яшьләренә юнәлеш бирүдә, аларны үстерүдә, чыныктыруда әдәбият берләшмәләренең роле гаять зур. 1955 елдан бирле яшәп килгән Әлмәт, 20 еллык юбилеен уздырган Лениногорск берләшмәләре яшь язучыларны тәрбияләүдә нәтиҗәле эш башкарып киләләр. Азнакай, Баулы әдәби берләшмәләрендә эш җанлана төште. Бүлек бюросы алар белән даими элемтәдә тора. Нефть районнарында яшәүче авторлар ай саен диярлек Әлмәткә, язучылар бүлеге утырышына чакырылалар, әсәрләр тикшерүдә катнашалар, тәҗрибә уртаклашалар. Алар өчен әледән-әле индивидуаль семинарлар, консультацияләр үткәрелә. Моннан берничә ел элек Әлмәттә «Хезмәт кешесе — совет әдәбиятының баш герое» диган

темага зур киңәшмә булды. Партия өлкә комитетының культура бүлеге һәм Культура министрлыгыннан, Татарстан Язучылар союзыннан җитәкче иптәшләр чыгыш ясаган бу җыелыштa нефть ягында яшәүче барлык яшь язучылар да катнашты. Ул үзенең эшлекле төстә үтүе белән хәтердә калды.

Әлмәт бүлеге — хәрәкәтчән оешма. Язучылар, иҗат максатлары белән, ерак юлларга чыгалар. Ш. Бикчурин Татарстан һәм Себер нефтьчеләре дуслыгына багышланган яңа романына материал җыю өчен Түмән якларында булды. Җ. Рәхимов Әлмәт — Уфа — Самотлор маршрутларын йөреп чыкты, башта әйткәнебезчә, «Батырлык чакрымнары» исемле очерклар китабы бирде. В. Мальцев үзе сугышып узган эзләр буенча Карпатка барып җитте. Бөек Ватан сугышы темасына яңа повестен тәгәлләде. Йөрү әйбәт, әлбәттә, әмма үз өеңдә ни барын да онытып бетермәскә кирәк.

Әдәбиятны пропагандалау буенча да шактый зур эш алып барыла. Ике съезд арасында 150 ләп әдәби кичә, әдәби очрашулар, укучылар конференцияләре үткәрелде. Аларның радиусы да шулай ук киң: Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә шәһәрләре, нефтьчеләр поселоклары, район колхозлары, Польша, Болгария...

Совет китабы айлыгы уңае белән Ш. Бикчурин Чехословакиягә чакырылган иде. Ул Братислава университетының рус теле һәм әдәбияты кафедрасы студентлары һәм профессорлары алдында чыгыш ясый, Татарстан нефтьчеләре турында сөйли, студентлар соравы буенча, Җәлил шигырьләрен укый. Чехословакиядә Шамил, күренекле рус язучылары В. Солоухин, Доризо белән бергә, унбиш очрашуда катнаша, «Каты токым» романын словак теленда укучы дуслары белән очраша.

Яшь шагыйрь һәм композитор Разим Вәлиуллин, Лениногорск үзешчәннәре белән бергә, Польшада, шагыйрә С. Сөләйманова Әлмәт үзешчәннәре белән Болгариядә булып кайттылар.

Тәнкыйть сүзләрен без съездга чаклы, үзебезнең кече сабан туйда, бүлек язучыларының апрель аенда булып узган отчет-сайлау җыелышында әйтештек. Оештыру эшләрендә, иҗатыбызда да кимчелекләр юк түгел.

Беренчедән, иҗатта янып торган яшьләребез аз. Кайберләре канат чыгаргач кына узәккә очалар. Бер карасаң — бу әйбәт тә. Үсеп җиткәнне башка чыгару гомер-гомергә килгән гадәт ич. Бер әдәбиятка хезмәт итәбез. Шулай да тормыш эченнән килгән иҗат яшьләренең тормыштан аерылмаулары, үз җирлекләрен югалтмаулары яхшы.

Икенчедән, күзәтү сәләтенең кими төшүе, бер урынга күнегү. Кул астындагы тормыш материалын еш кына тирәнтен каерып ала белмибез, аны читтән эзлибез. Әлбәттә, үзеңдәген яхшырак белү өчен, еракларга урап кайту да начар түгел. Әмма туган як, торган як мотивлары язучының иҗатында ярылып ятырга тиеш.

Алыйк Әлмәт районындагы «Ярыш» колхозын. Иртәнге якта Абдрахман, Тайсуган авылларының урам чатларында, тыкрык башларында төркем-төркем җыелган бик күп кешеләрне күрәсең. Менә выжт иттереп кенә йомшак автобуслар килеп туктый. Ишекләр ачылып, беренче сигнал булуга, әлеге төркемнәрдән җилләр исә.

Ике авылны берләштергән «Ярыш» колхозыннан нефть промыселларына, шәһәр предприятиеләренә эшкә көн саен 920 кеше чыгып китә. Меңгә якын эшчеләр, техник-инженерлар авыл һавасын сулап, үз өйләрендә яшиләр, яшелчә-җимеш үстерәләр, мал-туар карыйлар, ә хезмәтләре буенча шәһәр кешеләре булып исәпләнәләр. Бу — тышкы үзгәрешләр генә түгел. Бу үзгәрешләр кеше психологиясенә үтеп керә. Психологик яңарыш.

Республикабызның куәтле нефть индустриясе авыл иңенә таянып үсте. Авыл кешеләре нефть чыгарырга өйрәнделәр, белгечләр, галимнәр булып киттеләр, миллиард яшьлек девонны буйсындырдылар. Әйтик, Ленин комсомолы исемендәге Миңлебай газ эшкәртү гигантында бүген «Ярыш» колхозыннан 580 кеше эшли икән, бу бик табигый хәл. Заводны төзи башлаганда урындагы шушы эшче көчләргә, резервларга исәп тотылган иде.

Завод бүген колхозга ярдәм итә. Завод эшкәрткән коры газ «Ярыш» колхозы өйләрен, терлекчелек фермаларын җылыта. «Ярыш» колхозындагы күп кенә яңа төзелешләр шәһәр предприятиеләре ярдәмендә башкарыла. Кайнар урак өстендә газ заводыннан уннарча механизаторлар туган авыллары кырларында эшлиләр. Шәһәр — авылга, авыл — шәһәргә. Шулай ук ике арада культура элемтәләре дә ныгый бара. Иҗат кешесен (ә Габдрахман авылында ике язучы яши) тамырлары тирәнгә киткән, зур киләчәге булган мондый үзгәрешләр дулкынландырмыйча калмаска тиеш.

Бүгенге заманга тиң, киң колачлы, масштаблы әсәрләр әле язылмаган. Тормыш катламнарын тирәннән айкап алу җитми. Үзактә бүгенге кеше образы торган эпик поэмалар жанрын да онытып барабыз шикелле. Сюжетлы поэмаларны кыерсыту шуңа китерде. Сувенер шигырьләр өстенлек алды. «Казан утлары» журналында барган бәхәсләрдә күпчелек авторлар кеше хисләрен җырлаган, тормыш бөркелеп торган гражданлык поэзиясен яклап чыктылар. Ул гомер-гомергә шулай булды һәм шулай булып калачак та.

Л. И. Брежневның «Чирәм җир» исемле китабында турыдан-туры язучыларга, сәнгать осталарына мөрәҗәгать иткән юллар бар: «Әдәбият һәм сәнгать эшлекләре алдында халык батырлыгын чагылдырудан да мавыктыргычрак һәм рухландыргычрак бурыч юк».

## М. Ф. Вәлиев

# ИҖАТКА — ТАЛӘПЧӘНЛЕК

Әдәбият халыкка көннән-көн якынрак, үзрәк була барганлыктан, язучылар съезды — республикабыз тормышында күренекле вакыйга. Соңгы съездддан соң үткән биш ел аз вакыт түгел. Бу чорда язучылар оешмасы сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да шактый үсте, әле кайчан гына беренче тәҗрибә ясаучы авторлар иҗатта җитди адымнар атлады. Буын ныгыткан язучыларыбыз, аксакалларыбыз да әһәмиятле яңа әсәрләр барлыкка китерде. Әдәбиятыбыз бөтенсоюз аренасында киңрәк яңгырады — күп кенә әсәрләр русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә басылып чыкты. Кардәш әдәбиятлар белән элемтәләребез дә киңәйде — Казанда байтак кызыклы һәм файдалы конференцияләр, симпозиумнар, илебез язучылары белән очрашулар уздырылды. Республикабыз язучылары укучылар белән бәйләнешләрен үстереп, тормыш хакыйдагы белемнәрен тагы да тирәнәйттеләр. Моны язучылар оешмасының уңай казанышы итеп танымау мөмкин түгел.

Безнең һәрберебез — үз чорының баласы. Соңгы биш елдагы эшчәнлегебезнең кайсы гына тармагын алмыйк — һәммәсе КПССның XXV съезды, Октябрьның алтмыш еллыгы, СССРның яңа Конституциясен кабул итү, Л. И. Брежнев әсәрләре дөньяга килү кебек күренекле вакыйгаларның күәтле тәэсире астында узды. Үсешнең күләме һәм тизлеге, тормышның идея-политик яктан байлыгы белән бу чор иҗади эшчәнлек өчен бәрәкәтле җирлек бирә. Шунлыктан язучы хезмәтенә булган таләпләр дә бермә-бер күтәрелә төшә. Бу — халыкның культурасы, рухи ихтыяҗлары үсү, тормыш шартлары катлаулану, идеологик көрәш кискенләшү һәм җәмгыять тормышында тәрбиянең роле күтәрелү белән аңлатыла. КПСС Үзәк Комитетының идеология һәм политик тәрбия эшләрен көчәйтү турындагы карары, язучыларга кагылган пунктларны да эченә алуы өчен генә түгел, ә бу программ документ буларак бөтен характеры, асылы белән иҗат эшчәннәре өчен гадәттән тыш әһәмияткә ия. Бөтен тармакларда тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген күтәрү, аны тормышта барган процесслар белән мөмкин кадәр тыгызрак бәйләү, шалтырау, формализм, штамптан арынып, кешеләр белән үз итеп серләшү, мәсьәләне гади һәм үтемле итеп аңлату язучы хезмәтенә турыдан-туры кагыла. Карарда кимчелекләргә, ямьсез күренешләргә каршы көрәшү, һәр өлкәдә сәламәт шартлар булдыру, кешеләрне тәрбияләүдә төрле рангтагы җитәкчеләрнең, коммунистларның җаваплылыгын күтәрү хакында ачыктан-ачык әйтелгән. Укучыны тәрбияләү, аңарда иң матур идеяләр, әдәп-әхлак сыйфатларын тернәкләндерү язучының төп бурычы булып тора. КПСС ҮК карары аңа уйланып һәм актив хәрәкәткә килер өчен мул азык бирә. Ул язучыларны партия позициясенә басып тормыш күренешләрен киңрәк колачларга, партияле идея көрәшчеләренең беренче сафларында барырга чакыра. Үз эшебезне таләпчән, тәнкыйди анализларга, алга олы бурычлар куярга өнди.

Менә шул нигезләрдән чыгып, язучылар оешмасы эшчәнлегенең кайбер якларына мин конкретрак тукталырга телим. Инде икенче көн әдәбиятыбызның үсеш проблемалары турында файдалы һәм төпле сөйләшү баруын, кызыклы һәм эчтәлекле байтак докладлар һәм чыгышлар тыңлавыбызны баштан ук искәртеп куясым килә. Бу миңа кайбер мәсьәләләргә гомуми характерда гына кагылырга мөмкинлек бирә.

Ике съезд арасында прозаикларыбыз сикsәннән артык яңа роман һәм повесть, йөзләрчә очерклар иҗат итте. Шагыйрьләребез дә актив һәм нәтиҗәле эшләде. Унҗиде татар шагыйренең әсәре «Бөтен дөнья әдәбияты китапханәсе» сериясенә кертелде. Кайбер драматургларыбызның пьесалары байтак сәхнәләрдә зур уңыш белән бара. Республикабызның бүгенге тормышы, хезмәт казанышлары күп санлы публицистик чыгышларда чагылыш тапты. Татарстанның промышленность баһадирлары турында очерк китаплары барлыкка китерелде. Бу — бик әйбәт, мондый уңыш язучылар оешмасының сөенерлек нәтиҗәләргә ирешүе хакында сөйли.

Әмма без әдәби казанышларыбызны барлаганда бигрәк тә сыйфат ягына, әсәрләрнең бөтенсоюз күләмендә яңгырый алуына игътибар итәргә тиеш. Әдәбиятыбыз тулаем югары бәяләнсә дә, кызганычка каршы, бу таләпкә күп әсәрләр җавап бирә алмый әле. Безгә ни комачаулый соң? Объектив сәбәпләр, принципта, юк кебек. Язучыларга бездәге кеше материалы уңышлы җирлек бирә. Бездә менә

дигән шәхесләр яши, хезмәт итә, аларның үзара мөнәсәбәтләре күп кырлы һәм катлаулы, тормышларында олы иҗтимагый үзгәрешләр абайлана. Республикабызда дөньяны гаҗәпләндерә торган киң колачлы төзелешләр бара. КамАЗ, нефть химиясе, энергетика өлкәсендәге алга китеш Татарстанның гына түгел, бөтен илбезнең горурлыгы булып тора. Бездә зур масштаблы әсәрләр яза алырлык талантлы язучылар да бар. Алайса, эш нәрсәгә терәлеп тора соң?

Без еш кына күп эшләр эшләнүе, мирасыбызның байлыгы, хәлебезнең кемнәрдәндер яхшырак булуы хакында телгә алырга яратабыз. Кыскасы, казанышларыбызны күпертебрәк бәялибез, әмма бу безнең файдага түгел, күрәсең. Тормыш хәрәкәттә һәм үсештә. Безнең әдәбиятыбыз кайбер милли әдәбиятларга кайчандыр остазлык иткән булса, хәзер инде үзебезгә дә алардан өйрәнү комачауламый. Партиябезнең ленинчыл милли политикасы нәтиҗәсендә алар хәзер менә аякка шулай нык басты. Димәк, үз-үзебезне алдауга юл куймыйча, ирешелгәнне яңа үрләргә күтәрелү өчен таяныч мәйданы итеп кенә санарга кирәк.

Без культура өлкәсенең байтак тармакларында бөтенсоюз аренасына ныклы адымнар белән чыктык. Әмма анда мәртәбәле урын алырга карашлар тарлыгы, әллә кайчангы тәҗрибәгә таянып вак нәрсәләр күтәрү, тавышның «куелмаганлыгы» комачаулый. Бездә әсәрләре Татарстанда лаеклы рәвештә танылган хөрмәтле язучылар аз түгел, әмма бөтенсоюз киңлегенә чыгып, иң яхшылар янәшәсенә басканда, алар чүгеп, югалып кала. Быел экраннарда татар халкының матур традицияләре хакында яңа фильм күрсәтеләчәк, тик аның сценарием татар язучысы язмады. Дәгъвалар күп булып та, ул дәгъваларның эш белән ныгытылмавына әле хәтсез мисаллар китерергә мөмкин бездә. Кайбер хәл ителмәгән мәсьәләләр өчен гаепне үзеннән башка теләсә кемгә аударырга әзер затлар да житәрлек. Ә бит бүгенге шартлар Татарстан язучыларына иң югары таләпләрне канәгатьләндерерлек әсәрләр иҗат итәргә мөмкинлек бирә.

Әдәбиятның абруе, өлгергәнлеге беренче чиратта зур тормыш юлы узган өлкән язучылар эшчәнлеге белән билгеләнә. Үзебез дә белгәнчә, язмыш безгә андый затларны юмарт биргән. Әмма күренекле язучыларның кайберләре әһәмиятсезрәк темаларны яктырта, хатирәләргә чума яки нәтиҗәле иҗаттан бөтенләй читләшә. Әдәбиятыбыз осталарының иҗади активлык саклавы, беркайчан да яктысы тоныкланмый торган маяк булып калулары зарур.

Әдәбиятның йөзе һәм перспективасы яшь иҗатчылар үсүгә, аларның җимеш бирә башлавына бәйләнгән. Сәнгатебезнең шушы өлкәсенә күп кенә сәләтле автор килүен, әдәбиятыбызның данын тарату өчен ул буынның инде шактый эш күрсәтүен без горурлык белән белдерә алабыз. Безнең өметебез, киләчәгебез шулар кулында. Алар язучы хезмәтенең җитдилеген, тормышны тирәнтен өйрәнергә, фәнни коммунизм теориясе һәм практикасы белән коралланырга, үзенең кешелек сыйфатларын камилләштерергә тиешлекне тирәнтен аңласа һәм моңа ирешкәндә генә киләчәк иҗат әйбәт булыр. Яшь язучыларның үз иҗатына олы гражданлык, ватанчыллык тойгыларыннан, интернационалистик традицияләрдән чыгып якын килүе, әсәрләрен җитлеккән социализм дәверендә, фәнни-техник һәм иҗтимагый үзгәрешләр кичәйгән чорга муафыйк итеп язулары кирәк.

Без барыбыз да илебездә яшь иҗат көчләренә нинди зур игътибар бирелүнең шаһиты. Татарстанда бу өлкәдә матур казанышлар булу докладларның берсендә җентекләп яктыртылды. Бу җәһәттән кайбер якларга гына тукталып үтәсем килә. Мине беренче чиратта яшь язучыларның җитәрлек хезмәт тәҗрибәсе һәм, гомумән, тормыш тәҗрибәсе дә тупламас борын иртәрәк профессиональләшүе борчый — чөнки тормышның зәгыйфь белү соңыннан аларның үсешенә тискәре йогынты ясый. Беренче әсәрләрендә үк бала чак, үсмер чак хатирәләрен файдаланып бетергәч, алар абстракт рәвештә акыл сата, күптән мәгълүм нәрсәләрне кабатлый башлый.

Яшьләр белән эшләүне отчетларда бик саллы күрсәтә торган гомуми чараларга гына кайтарып калдырырга ярамый, алар белән даими һәм аерым-аерым да шөгыльләнергә кирәк. Яшь язучы кирәкле матдә белән илаһи уптым берьюлы тутырып куела торган савыт түгел. Югары уку йортларында һәм хәтта аспирантурада белем алуларына, нәшриятта һәм башка җирләрдә эшләүләренә карамастан, яшьләргә һәр вакыт тиешле юнәлештә тәэсир итеп торырга, аларны илебезнең революцион тарихы белән кызыксындырырга кирәк, чөнки әле дә кайбер яшьләрнең политик яктан өлгереп җитмәве, милли чикләнгәнлеге, әхлакый таркаулыгы очраштыргалый тора. Кайсы вакыт: болар кайда үсте, укыды, кем җырын җырлый икән дип аптырап каласың.

Язучылар союзы партия оешмасына килгәндә, яшьләр белән планлы рәвештә шөгыльләнүне ул игътибар үзәгендә тотарга тиеш. Бу эшкә тәҗрибәле, күренекле әдәби багажы һәм иҗатка партияле мөнәсәбәте белән абруй казанган өлкәннәрне җәлеп итәргә, шул ук вакытта яшьләрне зарарлы йогынтылардан сакларга кирәк.

Чыгышымның беренче өлешен йомгаклап, бай традицияләргә, хөрмәт казанган әдәби мираска ия Татарстан язучылары, үсештәге тормыш таләпләрен истә тотып үз алларына олы бурычлар куярга һәм идеалларыбыз тормышка ашуына ярдәм итәрлек яңа, яхшы әсәрләр тудырырга сәләтле дип әйтәсем килә.

Югарыда куелган бурычларны үтәү шактый дәрәҗәдә язучыларның тормышка ничек бәйләнгән булуына, иҗтимагый үсеш тенденцияләрен нечкә тоюына, киләчәкне оптимистик рухта күрүенә һәм шул дөньяны әсәрендә нинди микъдарда талантлы гәүдәләндерә алуына бәйләнгән. Тормыш-

ка актив мөнәсәбәт язучыларга аеруча кирәк сыйфат. Без инде күптән производство темасын примитив кузаллауны оныттык һәм аны чагылдыруга кеше эшчәнлеге, аның психологиясе, фәлсәфәсе, әхлагы, җәмгыять файдасына җитә торган профессиональ күнекмәләре һәм тормыш тәҗрибәсе аша алынырга тиешлекне төшенәбез. Җәмгыятебезнең төп көче булган эшчеләр сыйныфының актив хәрәкәтен, эчке дөньясын коммунистик ноктадан карап сурәтләү аеруча әһәмияткә ия. Бу темага язылган иң яхшы әсәрләрдә республикабыздагы яңа төзелешләр материалында җәмгыятебезнең бүгенге иҗтимагый һәм рухи проблемалары, тенденцияләре сәнгатьчә тәпле яктыртылды.

Әмма без үзебезгә тәнкыйть күзе белән карарга тиеш. Съездда дөрес искәртелгәнчә, КамАЗ төзү, нефть индустриясен үстерү темалары белән мавыгуыбыз нәкъ менә кызыклырак тәҗрибә туплангач, күп меңле, күп милләтле коллективлар оешуына үзебез дә шаһит булгач кына юкка чыкты. Зур иҗтимагый, экономик мәсьәләләр чишелә, фәнни-техник прогресс тормышка ашырыла һәм шул процесста, әлбәттә, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр дә кызыклы һәм күп кырлы була, совет кешеләренең иң яхшы сыйфатлары да шул процесста формалаша. Моны җентекләп күзәтү, барысы белән дә тирәнтен кызыксыну әһәмияте вакыт узу белән югалмаслык әсәр язарга нигез бирә алыр иде.

Авылда зур гына иҗтимагый үзгәрешләр барлыкка килү игенчеләр һәм терлекчеләр темасын яктыртуга шулай ук башкачарак керешүне таләп итә. Авыл хезмәт ияләренең тормыш шартлары яхшырды, профессиональ әзерлеге, культурасы һәм белеме күтәрелде. Шуны яхшы тойган, күргән язучылар гына замандашларыбызны дөрес чагылдыра ала.

Без барыбыз да мәктәптә, югары уку йортында, политик уку системасында марксизмны өйрәндек. Шуннан чыгып, иҗади интеллигенция вәкилләре үзләрен марксизм-ленинизм теориясен инде җитәрлек тирән үзләштергән саный башлый. Әмма алар шәхес һәм тарих, шәхеснең җәмгыятьтәге әхлак кануннарына мөнәсәбәте, марксистик гуманизмның табигате, сыйнфый һәм идеологик көрәшнең бүгенге проблемалары, җәмгыятебезнең үсеш нечкәлекләрен сурәтләргә керешү белән эрудицияләре җитмәвен тоя башлый. Шуңа күрә КПСС Үзәк Комитетының идеологик тәрбияне камилләштерү турындагы карарын Язучылар союзы идарәсе һәм партия оешмасы һәр чак истә тотып эшләргә тиеш.

Съездда тәнкыйтькә багышланган махсус доклад та сөйләнде. Бездә укучыларга сәнгать әсәрен таныргә, әдәби зәвыгын үстерергә булыша алырлык тәнкыйть барлыкка килде. Әмма язучы аңына тәэсир итәрлек, иҗат процессының алгы сафында барырлык, милли республика шартларында әдәбиятның үсеш закончалыкларын ачарлык, төп тенденцияләрне фәнни анализлый алырлык тәнкыйть тәмам ныгып җитмәде әле. Тәнкыйтькә тиз онытыла торган җитезлектән бигрәк тирәнлек, объективлык, дәлиллек, партиягә бирелгәнлек, әдәбият язмышын аталарча кайгырту кирәгрәк.

Бер уйлаганда, бездә тәнкыйтьчеләр аз түгел — егермеләп кеше бар. Әмма аларның күбесе фәнни-педагогик һәм нәшрият эшләре белән мәшгуль, тәнкыйтьче буларак әдәби процесс өчен үзен җаваплы санамый, вакыт җитмәү белән аклана. Андый иптәшләргә: әгәр син тәнкыйтьче икән, рәхим итеп бу эш өчен вакыт та таба бел инде, диярго генә кала. Шуның белән бергә, кайбер учреждение җитәкчеләренә үз хезмәткәрләренең файдалы һәм иҗтимагый кыйммәткә ия әдәби-тәнкыйть эшчәнлеген үсендерергә, бу хезмәт өчен таләп ителгән вакытны эш планнарын расламганда исәпкә алырга кирәктер. Яшь тәнкыйтьчеләр әзерләүне дә күздән ычкындыру ярамас. Бу мәсьәләне хәл иткәндә Язучылар союзы, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты, университет һәм пединститутлар тырышлыкларын бергә берләштерергә тиеш.

Язучылар съезды эшләнгән эшләрне анализлау, хәл ителмәгән мәсьәләләрне барлау, яңа бурычлар билгеләү җәһәтеннән олы әһәмияткә ия. Съездның эше нәкъ менә шушы яссылыкта дәвам итүе күңелле. Эшлекле һәм принципиаль сөйләшү язучыларыбыз иҗатын дөрес бәяләргә, киләчәк офыкларына үткен караш ташларга ярдәм итәчәге бәхәссез. Язучылар үз иҗатлары нәтиҗәсен айнык акыл, белән, реалистларча һәм таләпчән рәвештә КПСС Үзәк Комитеты карарлары рухында тикшерер, киләчәктәге эшчәнлекләрендә әдәби процесска мөнәсәбәттә шул карарлар яктылыгында эш итәрләр дип көтәбез.

Съездда катнашучыларны, алар йөзендә барлык язучыларны партиябез өлкә комитеты исеменнән чын күңелдән кайнар котларга, коммунизм төзүче халкыбыз ихтыяҗы хакына яңа иҗади уңышларга ирешүләрен теләргә рөхсәт итегез!

Бу съездда кардәш республикалардан һәм өлкәләрдән килгән кунаклар, РСФСР Язучылар союзы вәкилләре дә катнаша. Аларның республикабыз язучылары эше белән кызыксынуы, милли әдәбиятлар дуслыгын ныгытырга өлеш кертүе бездә ихтирам һәм рәхмәт хисләре уята. Олы Россия Язучылар союзының председателе С. В. Михалковның инде икенче мәртәбә рәттән, бу юлы чын мәгънәсендә бер самолеттан икенчесенә күчеп утырып, съездыбызга килүе аеруча игътибарга лаек. Бу — Михалковның безне яратуы, әдәбиятыбызга зур хөрмәт белән каравы хакында сөйли. Съездыбызга килгән кунакларга эшебездә катнашулары, Татарстан язучылары хезмәтен югары бәяләүләре өчен рәхмәт әйтсәм, мин, мөгаен, уртак фикерне белдергән булырмын. Кунакларыбызга шулай ук сәламәтлек, иминлек, иҗатларында уңышлар телик!

## Зәки Нури

# ТАГЫН ДА КЫЮРАК АДЫМНАР БЕЛӘН

Без бирегә—республикабыз әдипләренең иң олы мәҗлесенә—биш еллык иҗат юлыбызны күздән кичерәбез, чын хуҗаларча кайгыртучанлык белән үзебез туплаган яңа иҗади тәҗрибәне гомумиләштерәбез, тормышка үтеп керү осталыгыбыз ничек һәм күпмегә артуы, әдәби хезмәтебезнең халык күңелен ничек тибрәтүе хакында сүз алып барабыз. Киләчәк үсеш юлларын, яуланачак иҗади үрләрне билгеләү өчен бик кирәкле киңәшү-сөйләшү бу.

Әдәбиятыбызның бүгенге торышына карап, зур горурлык белән шуны әйтергә мөмкин: иҗади эзләнүләр һәм омтылыш-талпынышлар өчен иң уңай шартлар тудырылган бу елларда без җитлеккән социализм биеклекләренә күтәрелгән җәмгыятебездә барган үзгәреш-яңарышларга сизгеррәк карый башладык, аларны идея-художество җәһәтеннән дөрес итеп, тулырак, тирәнрәк ачарга, гражданлык пафосы белән дәртләнеп, партиялелек һәм халыкчанлык принциплары нигезендә сурәтләргә омтылышны көчәйттек. Иҗат эшчәнлегебезнең тематик һәм интернациональ офыклары күзгә күренеп киңәя, активлыгыбыз елдан-елга арта. Болар—күңелне сөендерә, яңа иҗади талпынышларга рухландыра торган күренеш.

Ирешелгән уңышларыбызның олы юлы орденлы журналыбыз—«Казан утлары» сәхифәләре аша уза дисәк, һич арттыру булмас. Без инде журналның 60 еллыгы бусагасына бастык. Сиксән меңнән артык укучысы булган басмабыз бүгенге татар совет әдәбиятының үзәгендә тора, аның һәркайсыбыз өчен кадерле булган йөзек кашы.

Язучылар союзының органы, әдәби тормышның өзлексез хәрәкәттәге халәтен чагылдыручы көзге буларак, «Казан утлары» журналы әдипләребезнең иҗат эшчәнлеген активлаштыру, осталыгын күтәрү һәм аларның иң яхшы әсәрләрен укучыларга җиткерү буенча оператив эш алып барды һәм бара. Журнал эшчәнлеге максатка ярашлы итеп билгеләнгән программага нигезләнә. Бу программаның төп юнәлешләрен генә телгә алып узыйк:

Беренче. Язучыларга социаль заказ бирү, иҗтимагый әһәмияте зур булган әсәрләр иҗат ителүгә йогынты ясау һәм шуларны беренче чиратта бастырып чыгару.

Икенче. Укучыларны төрле буын язучыларының иҗаты, кабатланмас художество үзенчәлекләре, стильләре, юнәлешләре белән таныштыру, аларның иҗатын киң пропагандалау.

Өченче. Журналның барлык саннарын да әдәби-эстетик кыйммәте зур булган әсәрләр белән чыгару. Аның һәр саны—әдәбиятыбызда күренеш, еллык җыелмасы—әдәбият тарихында эз калдырырлык булсын! Жанрларның төрлелегенә һәм әсәрләрдә күтәрелә торган проблемаларның оперативлыгына да игътибар ителә, билгеле.

Дүртенче. Каләм тибрәтеп, иҗат эшендә көч сынаучы яшьләрнең иң лаеклыларына, иң талантлыларына әдәбиятта үз урыннарын табарга, ныгып тамыр җәярга, канат ярырга булышу.

«Казан утлары»ның ике съезд арасында дөнья күргән барлык 60 томы да (һәркайсы 12 басма табак күләмендә) нәкъ менә шул максатларны күздә тотып эшләнгән иде. Журнал сәхифәләрендә 11 роман, 46 повесть, 11 поэма, дистәләрчә очерк, йөзләрчә шигырь басылды. Әдәбият белеме һәм тәнкыйть мәкаләләре, халык иҗаты, культурабыз тарихына һәм әдәбиятыбызның интернациональ бәйләнешләренә багышланган бик күп фәнни язмалар урнаштырылды. Съездда без тыңлаган докладта да, ярдәмче докладларда да алар барысы да диярлек беренче итеп телгә алынды, уңай бәяләнде.

«Яшьләр иҗаты»—безнең журналда даими рубрика. Әдәбиятка килүче яшь алмашның әсәрләре зур таләпләр иләгеннән үткәрелә, аларның иң яхшылары сайлап алына. Бу мәсьәләдә берәүгә дә ташлама юк. Яхшы әсәр—шигырьме ул, хикәяме, повестьмы—дүрт куллап кабул ителә, күтәреп алына. Пешеп җитмәгән кульязма килә икән, бигайбә, аңа журнал битләрендә урын юк! Әмма яшьләрнең югары таләпләргә җавап бирерлек әсәрләре шактый күп булды. Укучыларга тәкъдим ителгән яңа исемнәр кырыктан ашты. Алар 1978 елда үткәрелгән «Замандаш» конкурсында да актив катнаштылар. Әдәби иҗат ярышы, каләм көчен һәм осталыкны сынау бүгенге гигант төзелешләрдә катнашучы совет кешеләренең рухи дөньясын ачуга, һәр вакыт тынгысыз, эзләнүчән, күңел күзен киләчәккә төбәп, аның якты һәм киң офыкларын ерактан күрә белгән геройларның психологиясендә, яшәү рәвешендә барлыкка килгән, бөреләнгән яңа сыйфатларны гәүдәләндерүгә багышланды. Һәм сөенечле йомгак: конкурсның өч премиясен дә яшь авторлар—Рөстәм Мингалимов, Нәбирә Гыйматдинова һәм Камил Кәримов алды.

Редакция каршында яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәге эшләп килә. Анда актив катнашучылардан берничә кеше иң яхшы рецензиягә уткәрелгән конкурста бүләкләнде. Язучылар союзына кабул ителгән һәр талантны журнал үз укучыларына «Безнең сафка» дигән рубрикада урнаштырыла торган иҗади характеристика белән таныштыра. Әдәби хезмәтнең тирән серләре һәм иҗат тәҗрибәсе турында аксакалларыбызның чыгышлары оештырыла, фән әһелләренең махсус мәкаләләре языла.

Күренгәнчә, әдәби алмаш үстерү һәм тәрбияләү юнәлешендә Союз идарәсе дә, журнал да зур кайгыртучанлык күрсәтә, күп нәрсә эшли. Әмма, кызганычка каршы, яшьләрнең кайберләре моның кадерен белеп бетерми дияргә туры килә. Алар, мәсәлән, язучыларның гомуми җыелышына килми калуны да берникә куймый. Ә бит бу — зур нәрсә, яшь иптәшнең пассивлыгын расвый торган хәл, борчылырлык күренеш.

Бирәдә мин съезд игътибарын редакциянең публицистика һәм очерклар бүлеге редакторы Әхәт Гаффар тарафыннан язылган информацион белешмәдә күтәрелгән бер мәсьәләгә юнәлтеп узу урынлы булыр дип уйлыйм. Ул болай дип яза: «Очерк һәм публицистика мәйданына килүче яшь көчләр күп түгел. Ә бит бу жанр, үзенең табигате һәм асылы белән, язучының коммунистик төзелештә турыдан-туры катнашуын билгели, аның гомуми эшебез өчен шатлык-борчылуларын, халыкка бүген әйтергә теләгән уй-фикерләрен чагылдыра. Ни өчендер, яшьләребез шушындый сугышчан жанрга карата салкын канлылык, битарафлык күрсәтә. Безгә бу хакта ныклап уйларга кирәк. Күпмедер вакыттан соң, бу жанрны үстерүнең бөтен мәшәкатьавырлыклары хәзерге яшьләр җилкәсенә төшәчәк. Шуңа күрә, аларга мондый киңәш әйтәсе килә: үз йөрәгең кушканны бүген утәмәсәң, иртәгә синең намусыңны башкалар уятыр». Бик урынлы әйтелгән, кисәтүле киңәш бу, иптәшләр. Уз изге ниятән әйтелә. Укучыларыбыз үзләрен һәм замандашларын булачак китапларның геройлары итеп күрергә телиләр. Алар моңа лаек та.

Үсемлеккә дым, һава, кояш кирәк булган кебек, чордашларыбызның күңелләрендәге коммунистик әхлак орлыклары бөре ярсын өчен аларның зур эшләрен, кешелеген, фидакарьлеген, мораль дөньясын яктырткан яхшы китаплар кирәк. Яхшы китап, Шолохов сүзләре белән әйткәндә, зур сугышта җиңүгә тиң нәрсә ул. Чыннан да шулай бит: яхшы китаплардан башка яхшы тормыш була алмый.

Утызынчы елларда күренекле әдип, каләм остасы Шәриф Камал эшчеләр тормышыннан яхшы китап язу өчен Бондюгка (хәзерге Менделеевск шәһәре) китеп, булачак геройлары арасында яши, шундагы партия оешмасына учетка баса. Аңарчы Каспий балыкчылары арасында тормыш мәктәбен узган зур әдипнең бу адымы бүген барыбызга да, бигрәк тә яшь язучыларга, гыйбрәтле, минемчә. Тормышны читтән торып түгел, үзегендә яшәп өйрәнү хәерләрәк, нәтиҗәлерәк.

Космонавтларның идарә үзәге бар, ул орбитадагы космик корабларның очышын күзәтә, аларга Җирдән командалар тапшыра, галәм гизүчеләргә булышып тора. Минем уйлавымча, безнең Союз идарәсе һәм иҗат секцияләре дә шундый үзәк булырга тиешләр. Алар һәр язучының иҗат эшчәнлеген белеп торсын, һәр жанр үсешендәге яңалыкларны үз вакытында билгеләсен, яшь авторларга булышсын. Ләкин безнең һәркайсыбызга әлеге «үзәк»тән бирелгән командаларны көтеп ятудан бигрәк, үз йөрәкләребезнең әмерен ишетә белергә кирәк. Язмый калган көнең булмасын! Бер юл, бер җөмлә булса да яз! Иҗат эшчәнлегенең сыйфатын, дәрәҗәсен кайгырт. Әдип хезмәтенең һәр сәгате, һәр көне — удар һәм хәлиткеч!

Бөек Горький үз заманында язучы хезмәтен чәчәктән чәчәккә күченеп ширбәт җыйнаучы бал корты тырышлыгына тиңләгән иде. Ә галимнәр исәпләп чыгарган: бер килограмм бал җыю өчен, бал корты 76 мең очыш ясарга тиеш икән! Әдәбият кәрәзләребез мөлдерәмә тулы булсын дисәк — әнә шулай армый-талмый талпынырга, әнә шундый киеренкелек белән эшләргә кирәк.

Тагын бер мәсьәлә, иптәшләр! Съезд исеменнән безнең журналга кагылышлы конкрет тәкъдим белән югары инстанцияләргә мөрәҗәгать итү зарури дип уйлыйм. Мәгълүм булганча, «Казан утлары» Татарстанда гына түгел, Советлар Союзының барлык республикаларында, крайларында, өлкәләрендә тарала. Аның Бөтенсоюз каталогына кертелүе бик урынлы. 1970 елгы халык санын алу мәгълүматларына караганда, илебездә татар халкы — 5 миллион 930 мең кеше. Шуның 4 миллионнан күбрәге Татарстаннан читтә яши. «Казан утлары» журналының план белән бирелгән тиражыннан 65—70 процентны шулар алдыра. Бу хәл бер яктан, куанычлы булса — укучыларыбыз күп! — икенче яктан, журналны таратуда зур кыенлыклар тудыра: республикабыздан читтә яшәүчеләр арасында журналны пропагандалау һәм аңа язылуны оештыру буенча Казаннан торып берни дә эшләп булмый, чөнки Татарстан оешмаларының андый вәкаләте юк, башка республика, край һәм өлкәләрнең «Союзпечать» органнары белән журнал редакциясе турыдан-туры бәйле түгел. Шуңа күрә дә журналны РСФСР Язучылар союзы органы да итәргә кирәк дигән тәкъдим кертелгән иде. Ләкин РСФСР Язучылар союзы идарәсе, журналны укырга, контрольлек итәргә мөмкинлек юк дип, бу тәкъдимне тикшерүгә куймады. Хәзер хәл тамырдан үзгәрде: РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретарьлары итеп милли республикалар һәм өлкәләрнең язучылар оешмалары җитәкчеләре сайланды. Күп кенә татар язучылары һәм галимнәре Мәскәүдә яши — димәк, журнал эшен күзәтергә мөмкинлек бар. «Казан утлары» журналы РСФСР Язучылар союзы органы итеп тә танылса, без аны бөтен Федерация

территориясендә турыдан-туры үз катнашыбыз белән дә таратышырга рәсми мөмкинлек алыр идек, бу юнәлештә җиң сызганып, җилкенеп эшләргә юл ачылыр иде.

Татарстанның үзендә дә журнал алдыручылар санын арттырырга мөмкинлекләр бар әле. Әйтик, «Хотогу солух» («Поляр йолдызы») журналын һәр өч якут семьясыннан берсе алдыра. Һәр өч гаиләнең беосе! Ә безнең Татарстан районнарында «Казан утлары»н күп дигәндә, 1000 кешегә 40—50 данә (Чистай, Азнакай районнары), иң азы — мең кешегә 20—17 данә (Мамадыш, Зеленый Дол районнары) яздыралар. Быел, киләсе ел өчен язылу барышында, язучыларыбызның уртак тырышлыгы белән республикабызда журналны алдыручылар санын арттырырга кирәк.

Съездда әйтелгән киңәш, теләк һәм тәнкыйть сүзләреннән дөрес нәтиҗәләр ясасак, бу юлы мәҗлесебездән соңгы һәр ел безнең иҗатыбызны һичшиксез яңа бер баскычка күтәрер, сафларыбызда оешканлыкны һәм бердәмлекне арттырып, үзүзебезгә, башкарган эшләребезгә тагын да таләпчәнрәк карарга өйрәтер.

Әйдәгез, каләмдәш дуслар, съездыбыз билгеләгән бурычларны күңелләргә салып, әдәбиятыбызның яңа үрләренә тагын да кыюрак адымнар белән юл ярыйк!


## Сергей Михалков

РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе, Социалистик Хезмәт Герое


# ЭШЛЕКЛЕ СӨЙЛӘШҮ

Кадерле иптәшләр!

КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарында тәрбия эшенең кешеләр аңына һәм хисенә тәэсир итү көчен зәгыйфьләндерә торган кимчелекләр күрсәтелгән. Алар — еш очрый торган формализм, өстән-өстән генә уздырыла торган, штампка әйләнеп беткән пропаганда алымнары, үтемле, кызыклы яңа формалар эзлисе урында, күптән билгеле әйберләрне механик рәвештә кабатлау. Укучыны, тыңлаучыны рухи яктан баетучы теоретик гомумиләштерүләр, җитди уйланылган анализлар еш кына тышкы матур сүзләр белән алмаштырыла — бу күренешләрне безнең практикадан бөтенләй алып ташларга вакыт. Ни өчен мин бу хакта искә төшердем соң? Нәкъ менә бүгенге форумда — язучылар съездында бу хакта һич кенә дә онытырга ярамый.

Съездда сөйләшү, дөресен әйтергә кирәк, эшлекле, кызыклы һәм файдалы төстә узды. Докладларда да (мин аларның татарча сөйләнгәннәренең тәрҗемәләрен укып чыктым), чыгышларда да, хәтта съездга килгән кунакларның котлауларында да берникди яңгыравыклы фразалар, купшы сүзләр ишетелмәде. Сүз — эш турында, әдәбият турында барды. Бу, әлбәттә, бик яхшы.

Иң элек мин Татарстан язучылары оешмасының РСФСР Язучылар союзындагы зур абруе турында әйтеп үтәргә тиешмен. Татар әдәбиятының Россия Федерациясендәге иң актив, иң алдынгы әдәбиятларның берсе икәнлеген без яхшы беләбез. Союз җитәкчеләренең СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим ителгән кандидатларга булган зур таләпчәнлеге дә күптән мәгълүм. Шуңа күрә дә без секретариат утырышларында Казан тәкъдиме буенча тикшерелгән кандидатларны, зур ышаныч һәм җаваплылык тойгысы белән, һәр вакыт диярлек бертавыштан кабул итәбез.

Татар прозасының һәм поэзиясенең уңышлары — бәхәссез. Ул уңышлар съездда урынлы билгеләп үтелде. «Современник», «Советский писатель» кебек Мәскәү нәшриятларында рус телендә басылып чыккан китаплар саны да шул хакта сөйли. Сездә яшь иҗат көчләре белән эшләүгә дә зур әһәмият бирелә. Бу хактагы чыгышны мин аеруча кызыксыну белән тыңладым. Республикабыз, чыннан да, илебезнең иң кайнар ноктасына урнашкан. Язучыларның зур отряды, чыннан да, КамАЗдагы зур төзелешләрдән, нефть промыселларыннан үсеп чыга. Нәкъ менә шул төзелешләрдә катнашучылардан кайберләре соңыннан язучылар булып та өлгерә. Бөек Ватан сугышында катнашучылар белән дә шулай булды бит. Гади солдатлар, офицерлар, тупчылар, разведчиклар, политработниклар сугыштан соң язучылар булып, дөньякүләм танылган язучылар булып киттеләр. Әгәр дә Сталинград янында Михаил Алексеевны үтергән булсалар, политрукны гына үтергән булырлар иде, ә инде җитдирәк уйлап карасак, әле ул вакытта язучы булмаган, әмма булачак зур язучы Михаил Алексеев һәлак булган булыр иде. Бөек Ватан сугышы кебек илебез өчен хәлиткеч көрәштә катнашып язучы булган каләм осталары бездә бик күп! Менә бүген дә гигант төзелешләрдә катнашкан сезнең күп санлы яшь язучылардан, кем белә, бәлки күпме дә булса Ажаевлар, Алексеевлар, Бондаревлар үсеп чыгар? Аларны игътибарсыз калдырмаска, канатландырырга, юл бирергә генә кирәк. Ләкин яшьләргә игътибарлы булу, аларны

тәрбияләү — һәр яшь язучының әдәби үчти-үчти иттерүчесе булырга тиеш дигән сүз түгел. Бик еш кына шулай да була: яшь язучыга төрлечә ярдәм итәләр, аңа хәтта язышалар, кульязмасын тартып-сузып әдәби әсәр дәрәҗәсенә җиткерәләр, аннары шул «җимеш» кайда да булса басылып та чыга. Ә яшь иптәш инде рецензияләр таләп итә башлый, күрмиләр, танымыйлар дип зарлана, инде үзен «җирнең кендеге» дип хис итә... Әдәбиятка бары тик талантлы яшьләрне генә алып керергә кирәк. Сәләтсезләрнең исә күзенә туры карап дөресе әйтелергә тиеш. Андыйлар башка файдалы хезмәт белән шөгыльләнсеннәр.

Инде журнал мәсьәләсенә килгәндә, яшьләр журналы сезгә, әлбәттә, кирәк. Без моны бик яхшы аңлыйбыз. Өлкә комитетының беренче секретаре иптәш Табеев белән дә без бүген бу хакта җентекләп сөйләштек. Без, үз чиратыбызда, журнал булдыру өчен барысын да эшләячәкбез. Чөнки журнал — кирәк! Журналсыз басылыр җир юк. Чәчәр өчен чәчүлек җир кирәк. Аннары гына уңыш җыеп алырга мөмкин. Язучы да, басылыр мәйданы булмагач, үзенең сәләтен, хезмәтен күрсәтә алмый.

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, иҗат яшьләренә булган бездәге кебек кайгыртучан мөнәсәбәт бер генә капиталистик илдә дә юк. Кызганычка каршы, үзләренә күрсәтелгән зур игътибарны яшьләр бәяләп җиткермиләр әле. Уйлап кына карагыз: без шагыйрьләрне, язучыларны, тәнкыйтьчеләрне, драматургларны, очеркчыларны бөтен Россиядән зона киңәшмәләренә җыябыз, аларны Мәскәүгә яки иҗат йортына китерәбез, әсәрләрен тикшерү өчен зур-зур язучыларны үз эшләреннән аерабыз. Алар атналар буена яшьләр белән шөгыльләнә: лекцияләр укыйлар, киңәшләр бирәләр, әсәрләрен матбугатка юллыйлар, ә яшьләрнең осталыклары инде җитлеккән кайберләрен Язучылар союзы членлыгына тәкъдим итәләр. Тагын кайсы илдә яшьләргә шундый игътибарлы мөнәсәбәтләр бар?! Әдәбиятка керү бездә бик авыр дигән сүзләрне еш кына ишетергә туры килә. Бу, әлбәттә, һич тә дөрес түгел. Киресенчә, бездә әдәбиятка керү җиңел, артык җиңел. Шуңа күрә дә бик күп беренче җыентыкларын, китапларын чыгарган авторлар гомер буе беренче китап авторлары булып кына калалар да. Алар шуннан ары китә алмый, китсәләр дә, бер урында тапталалар. Баксаң, алар инде союз членнары булып алганнар: аларга эшләү өчен шартлар кирәк, иҗат йортларыннан урын кирәк... Кызганычка каршы, иҗатның башка төрләрендә дә шундый ук хәл. Әйтик, яшь кинорежиссер дипломнан соң дәүләт акчасына картина төшерергә мөмкинлек ала. Ул урта кул, хәтта урта кулдан да түбәнрәк фильм төшерә. Аңа тагын төшерергә мөмкинлек бирәләр. Бу юлы да дәүләт акчасына! Аннары өченчесе, дүртенчесе, бишенчесенә тотына һәм бу эш әлеге иптәш кайчакта хәтта СССР халык артисты булганчы шулай дәвам итә. Ә капиталистик илдә яшь режиссер картина төшерер өчен кемнәндер 300 мең доллар акча ала аламы соң? Юк, әлбәттә. Яшьләр генә түгел, дөньяның зур-зур режиссерлары да күп чакта фильм төшерер өчен акча таба алмый интегәләр.

Мин күптән түгел Кипрда булып кайттым. Халыкара Балалар елы уңае белән, анда интеллигенция вәкилләре, аерым алганда, язучылар белән очраштым. Шул очрашуларның берсендә Кипр Язучылар союзы президенты минем үзебезнең союз турында, яшьләр белән ничек эшләвебез турында сөйләгәннәремне тыңлап торды да, болай диде: «Мин кырык ел инде әдәбиятта эшлим, әмма Советлар Союзында чыга торган «Иностранная литература» журналыннан башка бер генә җирдән дә гонорар алганым булмады. Китапларымны һәр вакыт үз акчама бастырдым, үзем саттым». Китапханә директоры булып эшләгән килеш, ул китапларын ничә данә бастыргандыр дисез? 500—600—700 данә... Менә нинди ул Көнбатыш язучысының хәлләре. Хәер, бу хакта сез үзегез дә яхшы беләсез. Әмма боларны үзебезнең яшьләргә даими сөйләргә кирәк. Яшьләр бу турыда, Көнбатыштагы иҗат интеллигенциясенең ничек яшәве хакында чын дөреслекне белергә тиеш.

Без бүген, иптәшләр, тормышыбызның яңа чорына керәбез. Безнең бөтен иҗат эшчәнлегебез, иҗат тормышыбыз КПСС Үзәк Комитетының әлеге карары яктылыгында каралырга, бәяләнергә бурычлы. Ул карарны тикшерү генә, аның хакында фикер алышу гына, сөйләшү генә җитми, аның күрсәтмәләренә һәр вакыт әйләнеп кайтырга туры киләчәк. Чөнки ул карар алдагы бик күп елларга исәпләп кабул ителгән. Шуңа күрә дә аны үтәү җиңел генә булмаячак.

Аннары бу карарның турыдан-туры безгә — язучыларга, аеруча сатирикларга караган өлешләре дә күп. Шунысын да әйтергә кирәк, сатира партиябез тарафыннан һәр чак якла免ып килендә, аның игътибар үзәгендә булды. Моңа дәлилләр җитәрлек. Унсигез ел дәвамында яшәп килүче «Фитиль» киножурналын гына алыйк. Шушы чор эчендә безгә Үзәк Комитет тарафыннан бер генә тапкыр да кисәтү ясалмады. Ул гына да түгел, иптәшләр СССР Дәүләт премиясе белән бүләкләнделәр. Матбугат битләрендә сатирага булган яхшы бәяләр дә партиянең турыдан-туры ярдәме ул. Шулай да сатира акрын үсә әле, шул исәптән, Татарстанда да. Ә татарлар исә юморга аеруча тартылучан халык. Димәк, сездә сатира-юмор аеруча нык алга китә һәм коммунизм төзүдә партиябезгә зур булышлык итә ала. Без тәрбия эшенең яңа формаларын эзләргә тиешбез, язучылар, газета-журнал редакторлары бүгенге көннең актуаль мәсьәләләрен ачыктан-ачык тикшерүгә курыкмаска тиешләр. Ләкин күп кешеләрнең аңын бер көндә генә, бер елда гына үзгәртеп булмый. Менә бу өлкәдә юмор хисен белүче һәм аңлаучы татар язучыларына

эш житәрлек. Аларның үткен сатирик каләме заман адымыннан артта калган, бүгенге тормыш пульсын аңламаучы кешеләрдән көлеп, аларны фаш итеп партиябезгә зур ярдәм күрсәтә алыр иде. Кыскасы, бик күп эшләргә кирәк әле безгә. Бу җәһәттән мин газета редакцияләрендә эшләүче язучыларны, бигрәк тә яшьләрне, аеруча уңай яктан телгә алып узар идем. Мин аларны хөрмәт итәм һәм аларга һәр чак булышырга тырышам. Ни өчен дисәгез, бүгенге көндә язучы өчен публицистика өлкәсендә эшләүдән дә мактаулырак эш юк. Язучыга бернинди дан-шөһрәт китермәүче әлеге «кара эштән» һич тә кыенсынмаска кирәк. Ләкин безнең арада хезмәт алдынгылары турында, эшчеләр, колхозчылар турында очерклар язуны түбәнлеккә санаучы кайбер иптәшләр дә бар әле. Аларга шигырь генә булсын! Партиябезгә булышу йөзеннән бүгенге матбугат куйган олы бурычларны алар читләтеп узарга тырыша. Әмма рус әдәбияты, мәсәлән, үз вакытында публицистик мәкаләләр белән чыгыш ясамаган бер генә классикны да белми. Чехов та, Пушкин да, Толстой һәм Короленко да, Маяковский да — барысы да кайчандыр вакытлы матбугатта эшләгәннәр.

Әйтәсе килгән сүзләр менә шушылар иде, хөрмәтле иптәшләр! Барыгызга да яңа иҗат уңышлары телим. Татарстанның язучылар оешмасы моннан соң да актив һәм дисциплиналы, бердәм коллектив булыр, коммунизм төзүчеләрнең алгы сафында барыр дип ышанам.

# СЪЕЗД КАБУЛ ИТКӘН КАРАР

*Татарстан язучыларының тугызынчы съезды КПССның тарихи XXV съезды карарлары барлыкка китергән иҗади күтәренкелек, совет халкы тарафыннан бу карарларның уңышлы төстә тормышка ашырылуы шартларында үтте.*

*Сигезенче һәм тугызынчы съездлар арасында узган бишьеллык дөньякүләм әһәмияткә ия булган мөһим вакыйгалар — Бөек Октябрь революциясенең 60 еллыгы һәм совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенең 30 еллыгы белән билгеләнде.*

*Тормышыбызның бөтен барышына, шул исәптән, язучылар иҗатына СССРның, союздаш һәм автономияле республикаларның яңа Конституцияләрен кабул итү яңа илһам өстәде.*

*Әдәбиятыбыз үсеше өчен бу елларда КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында», «Иҗат яшьләре белән эшләү турында», «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарлары зур әһәмияткә ия булды.*

*Хәзерге дөньяда әдәбиятның роле һәм тоткан урыны тайпылышсыз үсә, язучылар кеше акылы һәм йөрәге өчен барган рәхимсез көрәшнең алгы сызыгында торалар. Үз эшчәнлекләрен һәрьяклап активлаштыру, укучыларга яңаны иҗат итүче халкыбызның героик казанышларын талантлы тасвирлый, фән-техника революциясе тудырган яңа социаль-әхлакый процесслар турында сөйли торган көчле әсәрләр бирү — совет әдәбиятчыларының намус эше.*

*Халыкара мәйданда идеология көрәшенең нык кискенләшүен исәпкә алып, Татарстан язучылары съезды республика әдәбиятчыларын империалистик пропаганданың котырынган һөҗүменә каршы сыналган коралыбыз — ялкынлы сугышчан әдәби сүзне мөмкин кадәр нәтиҗәле файдаланып җавап бирергә чакыра. Монда КПСС ҮК Генеральный Секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе иптәш Леонид Ильич Брежневның «Кече җир», «Яңарыш» һәм «Чирәм җир» әсәрләре безне илһамландыра торган үрнәк булып хезмәт итә.*

*«Иҗат союзлары алдына художество интеллигенциясенә идея-политик тәрбия һәм марксистик-ленинчыл белем бирүне камилләштерү бурычы куелды. Югары идеялелек, гражданлык хисләре тәрбияләү, язучы, сурәтче, композиторларның, театр һәм кино эшлеклеләренең, журналистларның иҗат активлылыгын үстерү турында даими кайгыртырга, игътибарны совет халкының героик казанышларын, социалистик җәмгыять үсеше проблемаларын талантлы сурәтли, идея дошманнарыбызны тетрәтә торган яңа әдәбият һәм сәнгать әсәрләре тудыруга юнәлтергә»,— диелә КПСС Үзәк Комитетының «Идеология, политик тәрбия эшен тагын да яхшырту турында»гы карарында.*

*Татарстан язучылары КПСС Үзәк Комитетының бу күрсәтмәләрен тайпылышсыз үтәлергә тиешле кулланма буларак кабул итәләр.*

*Съезд узган әдәби бишьеллыкта язучыларның хезмәт коллективлары белән элемтәләре тагын да ныгуын һәм тирәнәюен билгеләп үтә. Прозаик, шагыйрь, дра-*



*Партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев (сулда). РСФСР Язучылар Союзы идарәсе председателе Сергей Михалков. «Юморга бай татарлар «Фитиль» киножурналына нигә язмыйлар икән?»—дип кайгыра кунак.*

*матург, тәнкыйтьчеләребез республика заводларында һәм төзелешләрендә, колхозларда һәм уку йортларында еш була һәм көтеп алына торган кунаклар. Ныгый барган бу элемтәләр Татарстан язучылары иҗатына уңай тәэсир ясады. Китапларыбыздагы хезмәт кешесе образы торган саен тормышчанрак, тулы канлы, ышандыручан, бай рухлырак була бара.*

*Партиянең әдәбият һәм сәнгать эшлекләре турында даими кайгыртуы нәтиҗәсендә без бу елларда иҗат өчен иң уңай шартларда эшләдек, КПСС өлкә комитетының, республикабыз хөкүмәтенең, СССР һәм РСФСР Язучылар союзлары идарәсенең даими ярдәмен, игътибарын тойдык.*

*Узган биш елда Татарстан Язучылар союзы идарәсе республикабыз әдәбиятчыларының җәмәгать һәм иҗат активлыгын көчәйтүгә булыша торган байтак чаралар үткәрде. Татар халкының бөек уллары Габдулла Тукай һәм Муса Җәлилгә багышланган юбилей комиссияләре төзелде, Казанда һәм Мәскәүдә, тугандаш республикаларда һәм чит илләрдә Тукай, Җәлил китаплары басылды. Каюм Насыйри, Галиәсгар Камал, Шамил Усманов, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим юбилейлары киң һәм тантаналы рәвештә билгеләп узылды.*

*Узган бишьеллыкта иҗат союзларының берләштерелгән традицион пленумнары, язучыларның әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышлары, шигырь бәйрәмнәре, яшь әдәбиятчыларның республика семинарлары һәм зона конференцияләре югары дәрәҗәдә үтте, иҗат секцияләре җитәкчеләренең хисап бирүләре даими рәвештә тыңланды.*

*Съезд отчет чорында республика язучыларының эшчеләр сыйныфы, авыл хезмәтчәннәренә багышланган, тарихи-революцион һәм сугыш темасына караган шактый гына әсәрләр иҗат итүен канәгатьләнү белән билгеләп үтә. Балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты өлкәсендә дә әйбәт кенә уңышларга ирешелде. Очерк һәм публицистиканың роле сизелерлек күтәрелде. Авыл районнарында булып кайткан язучыларыбыз бары узган елда гына да газета-журнал битләрендә утызга якын*

*очерк һәм публицистик мәкалә бастырды. Татарстан Язучылар Союзы идарәсе, КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарын үтәп, тәнкыйтьчеләрнең һәм әдәбиятчыларның эшен сизелерлек активлаштырды. Беренче тапкыр яшь тәнкыйтьчеләрнең республика семинары уздырылды, анда илледән артык кеше катнашты. Драматургларыбызның уңышлары аеруча сөендерә. Бу елларда аларның илледән артык пьесасы илебезнең дистәләрчә сәхнәсендә барды.*

*Ике съезд арасында Татарстан китап нәшрияты биш йөздән артык китап чыгарды, аларның шактые рус теленә тәрҗемә ителде, үзәк нәшриятларда басылып, бөтенсоюз укучысына җиткерелде.*

*Бу чорда әдәби алмаш әзерләүгә, яшь язучыларның осталыгын күтәрүгә һәм идея үсешен кайгыртуга аерым игътибар бирелде. Съезд киләчәктә дә яшь каләмнәрнең иҗат һәм җәмәгать активлыгын үстерергә кирәк дип саный.*

*Съезд квалификацияле тәрҗемәчеләрнең зур отряды тырышлыгы белән рус, совет һәм чит илләр әдәбиятының иң яхшы әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителүен билгеләп китә. Ике съезд арасында татарчага тәрҗемә өлкәсендә яңа уңышларга ирешелде. Хәзер татар әдәбияты элекке ун-унбиш ел белән чагыштырганда рус теленә шактый яхшырак һәм киңрәк тәрҗемә ителсә дә, безне әле татарчадан русчага тәрҗемәнең сыйфаты да, күләме дә канәгатьләндерми. Съезд Татарстан китап нәшрияты каршында киң хокукларга ия булган һәм тиешле кадрлар белән тәэмин ителгән тәрҗемә үзәге оештыруны максатка яраклы дип тапты.*

*Татарстан язучыларының тугызынчы съезды карар бирә:*

*1. Татарстан Язучылар союзы идарәсенең отчет чорындагы эшчәнлеген хупларга.*

*2. Татарстан Язучылар союзы идарәсенә, республиканың барлык әдәбиятчыларына үзләренең бөтен җәмәгать һәм иҗат эшчәнлекләрендә КПССның тарихи XXV съезды карарларын, сәнгатьнең партиялелеге һәм халыкчанлыгы турындагы ленинчыл принципларны тайпылышсыз үти торган кулланма итеп алырга тәкъдим итә. КПССның XXVI съездын каршылаганда республика язучылары ирешелгән уңышларны ныгытырга, игътибарны хәл ителмәгән мәсьәләләргә юнәлдерергә, үз эшчәнлекләрендәге кимчелекләрне тәнкыйть күзлегеннән чыгып анализларга һәм аларны бетерү өчен нәтиҗәле чаралар күрергә тиешләр.*

*3. Татарстан Язучылар союзының яңа идарәсенә съездда куелган мәсьәләләрне, әйтелгән тәкъдимнәрне һәм тәнкыйть фикерләрен җентекләп өйрәнү, якын елларда аларны тормышка ашыру бурычы йөкләнә.*

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Бу елда Сез журналның тагын бер санын алачаксыз әле. Нәкъ бер айдан кулларыгызга 12 нче сан килеп керер. Анда ниләр барлыгы, мөгаен, Сезне хәзер үк кызыксындыра торгандыр. Шуңа күрә журналның эчтәлеген кыскача язып үтәргә булдык.

Декабрь аенда чыгачак журнал шагыйрә Саҗидә Сөләймmanagованың «Сабыр канатларым»дигән гомуми исемгә тупланган шигырьләре белән ачылачак. Авторның хискә бай, тирән эчтәлекле, матурлыкка өндәүче яңа әсәрләрен Сез яратып укырсыз.

Проза әсәрләрен көтеп алучыларга Ә. Шәмигнең «Яңа язлар» повесте, Батулла һәм Ә. Гаффар хикәяләре тәкъдим ителә.

Билгеле булганча, журнал күптән инде киләсе елда билгеләнәчәк олы бәйрәмнәр: В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу, Татарстан автономияле республикасы төзелүгә 60 ел тулу көннәре уңаеннан яңа әсәрләр бирер килә. 12 нче санда Татарстанның хезмәт баһадирларына багышланган «Уренгойның ак боланы» исемле очерк басылачак. Аның авторы — нефтьчеләр тормышын яхшы белүче журналист Изаил Зарипов. Очерклар бүлегендә тагын бер бик мөһим мәсьәлә күтәргән язма бар. Журналист М. Рафиков республикада балык үрчетү проблемасына, бу юлда туган кыенлыкларга тукталa.

Шигырь сөючеләр 12 нче санда К. Латыйпов, Р. Зәкиев, Ә. Рәшитов, Ә. Мәхмүдов, Н. Әминева шигырьләре, Г. Шамуков мәсәлләре белән танышачаклар.

Әдәби тәнкыйть һәм сәнгать мәсьәләләренә караган материаллар бу санда аеруча мул. Монда Н. Исәнбәт, Г. Халит, В. Хангилдин, М. Госманов, Х. Гобәйдуллин, Х. Гайнетдинов мәкаләләре урнаштырылачак.

Бу санда «Яшьләр иҗаты», «Безнең календарь», «Әдәбият-сәнгать яңалыклары» кебек традицион рубрикалардан соң 1979 елда журнал битләрендә басылган әсәрләрнең исемлеге дә чыгачак.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210